ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ

ЧЫҢГЫЗНАМӘ

«МИЛЛИ КИТАП»

ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ

«ЧЫҢГЫЗНАМӘ»

тарихи дастаннар

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2019

УДК 82.3(2=632.3) – 441
ББК 398.1(512.145)
Ч 88

Төзүчесе, басмага әзерләүче
һәм мәкаләләр авторы –
археограф, текстолог
Раиф Мәрданов

Ч 88 «Чыңгызнамә»: тарихи дастаннар / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2019. – 288 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 23 нче китап).

Китапта «Чыңгызнамә» («Дәфтәри Чыңгызнамә») исеме белән бер җыентыкта туплап йөртелгән «Чыңгыз хан нәселе», «Аксак Тимер», «Гайса улы Амәт» һ.б. борынгы татар дастаннары нәшер ителде.

Төрле күләмдәге дастан текстлары 15 кульязма күчермәдән тупланды. Аларның күпчелеге Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә саклана һәм беренче мәртәбә басыла.

Кереш мәкаләдә «Чыңгызнамә» китабының өйрәнелү тарихы, авторлык мәсьәләсе, кайсы чорга каравы, хәзергәчә сакланган күчермәләре һәм башка мәгълүматлар тәфсилләп язылды.

ISBN 978-5-88473-093-9

УДК 82.3(2=632.3) – 441
ББК 398.1(512.145)

© Мәрданов Р.Ф., 2019
© «Милли китап» нәшрияты, 2019

ТАРИХИ ДАСТАННАР ТУПЛАМЫ

«Чыңгызнамә» («Дәфтәри Чыңгызнамә») – тарихи, әдәби һәм фольклор үзенчәлекләрен берләштергән һәм халык тарафыннан яратып укылган дастаннар китабы.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «Чыңгызнамә» китабының төрле күләмдәге текстлары хәзерге вакытка унбер берәмлекне тәшкил итүе текстларын туплап чыгару фикеренә этәрде. Нәтиҗәдә, башка оешмалардагы берничә кулъязманы да өстәп, «Татар археографиясе» сериясенең бу басмасында барлыгы 15 текст бастырылды.

Татар энциклопедиясендә мондый мәгълүмат бирелгән: «Дәфтәре Чыңгызнамә» («Дастаны Чыңгызнамә»), 17 йөз ахыры татар әдәбияты ядкәре. Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларындагы тарихи язмаларга һәм риваятьләргә нигезләнеп, билгесез автор тарафыннан төзелгән. «Дәфтәре Чыңгызнамә»нең авторы дип 1670–71 еллардагы Крәстиян сугышында катнашкан дин эшлеклесе Идрис хафиз фаразлана. Әсәр Чыңгыз хан нәселе, Аксак Тимер, Гайсә улы Әмәт, Идегәй, төрле ханнарның яшәү урыны, биләмәләре турындагы 6 повесть-бүлектән тора; соңгы өлеше «Татар елъязмасы» буларак та мәгълүм...»[1]

Тарихчы галим Миркасыйм Госмановның хезмәтендә «Дәфтәри Чыңгызнамә» китабы җентекләп өйрәнелгән[2].

«Чыңгызнамә», «Дәфтәри Чыңгызнамә», «Әхвале Чыңгыз хан вә Аксак Тимер», «Китабе дастани нәсли Чыңгыз хан вә Аксак Тимер...», «Дастаннар китабы», «Дастаннар мәҗмугасы» һәм башка төрле исемнәр белән аталып йөртелгән китапның төп тексты алты дастан-бүлектән тора. Төрле кулъязма күчермәләрдә һәм басмаларда алар төрлечә (бүлек мәгънәсендәге «фасыл», «кыйсем» сүзләре кушылып) аталган булсалар да, һәммәсендә дә диярлек «дастан» сүзе бар. Ягъни,

– «Дастане нәсли Чыңгыз хан» (беренче бүлек);
– «Дастане Аксак Тимер» (икенче бүлек);
– «Дастане Гайса угылы Амәт» (өченче бүлек);

[1] Татар энциклопедиясе. Т. 2: Г–Й. – Казан: Татар энцикл. ин-ты, 2010. – Б. 239. Авторы турындагы фараз энциклопедиядәге мәкалә ахырында күрсәтелгән чыганакларның берсендә дә язылмаган.

[2] Усманов М. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв.: «Сборник летописей», «Дафтар-и Чингиз-наме», «Таварих-и Булгария», татарские шаджара. – Казань: изд-во ун-та, 1972. – 223 с.

– «Дастане Идегәй би» (дүртенче бүлек);

– «Дастане әл-мәҗалис вәл-мәкян» (бишенче бүлек);

– «Дастане тарих» (алтынчы бүлек).

Фарсы теленнән кергән «дастан» сүзе «поэма, эпос» дигәнне белдерә. Киңрәк рәвештә ул «тарих, баштан узган вакыйга, повесть, хикәят, әкият, көй» мәгънәләренә дә ия. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә дастанга карата: «1) тормышта булган хәлләр, вакыйгалар турында буыннан-буынга сөйләнеп килә торган хикәя; 2) әһәмиятле, тарихи вакыйгалар хакында язылган күләмле әдәби әсәр; эпопея» дигән аңлатма бирелгән[3].

Тарихи риваятьләр нигезендә халык иҗатының бай сурәтләү бизәкләренә төрелгән хикәятләр җыентыгы, гомуми исемнәреннән берсе – «Чыңгызнамә» дип аталган китапның эчтәлеген кыскача күзаллап китик. Беренче бүлектә Чыңгыз ханның Нух пәйгамбәрдән башланып үзенә кадәрге легендар нәсел шәҗәрәсе һәм үзеннән соң XVII гасыр уртасына кадәр дәвам иткән бер тармагы язылган. Аннан соң Чыңгызның уйдырма әбисенең (әтисе Дуйын-Бәйанның әнисе Голәмәлик) нәсел тармагы тасвирланган. Чыңгызның могҗизалы тууы, тәхет өчен көндәшлек аркасында казакъ булып таулар-урманнар арасына китүе, аны бикләр эзләп табып, арба белән (беренче вариант текстында арбага алтын тәхет урнаштырып[4]) тартып кайтулары, Чыңгызның өйләнүе, дүрт улы дөньяга килүе тасвирланган. Шуннан соң Чыңгыз ханның күп җирләрне үзенә буйсындырып, гаделлек белән идарә итүе, бикләренә махсус тамга, оран һәм башка атрибутлар тәгаенләп, гаскәр башлыклары итеп куюы, ханның һәм улларының, шулай ук бикләрнең күбә исемнәре бәян ителгән. Дастан ахырында Чыңгыз ханның иксез-чиксез биләмәсен дүрт улына бүлеп бирүе һәм үзе турында кыскача биографик мәгълүмат (дөньяга килгән елы, гомер озынлыгы, ханлыкка утыруы һәм идарә иткән вакыты, вафаты) язылып, дастан тәмамланган.

Аксак Тимер дастаны Чыңгыз хан улы Җәдайның куркыныч төш күрүе белән башланган. Аңа Алмалык дигән авылдагы бер нәсел токымыннан туачак угыл хәвеф китерәчәген юрыйлар. Авырлы хәлендәге хатынны җәфаласалар да, ул аксак бала таба. Аксак Тимер ятим үсеп, казакълыкка чыга, юлбасарга әйләнә, гаскәр туплап, көч яки хәйлә белән илләр-калалар яулый. Хаҗитарханны басып алганнан соң Идел буйлап Болгар шәһәренә килә. Зур каршылыкны җиңеп Болгарны ала, Габдулла ханны һәм 124 бикне һәлак итә. Шулай да ханның ике улын – Алтынбик белән Галимбикне

[3] Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда. Т. I: А–Й. – Казан: Татар. китап нәшр., 1977. – Б. 292.

[4] Китап текстының ике төрле варианты турында алга таба тәфсилләп язылачак.

яшереп саклап калалар. Аннан соң Тимер Бүләрне яуларга юнәлә. Бүләрлеләр – бараҗ халкының элекке ватаны турында сөйләнә. Бүләр шәһәрен сугышмыйча бирәләр, андагы элекке Җадәш исемле бик улларының берсе Тау ягына, икенчесе Зәй буена китеп урнашулары һәм аларның нәсел тармаклары бәян ителгән. Аксак Тимер Мәскәү ягына юнәлсә дә, сугышмыйча, кайбер могҗизалар күрсәтеп, Амәт һәм Самәт ханнар идарәсендәге халыкны мөселманлыкка күчереп, Урта Азиягә юнәлгән һәм шунда дөнья куйган.

Гайса улы Амәт турындагы дастанда Җанибәк ханның хатыны кыз тудырса, аны үтерергә кушып та үтерелмәве һәм читтәге агасы Бирдебәк тәрбиясендә үсүе турында сүз бара. Хан ачуланып, Бирдебәкне үзенә китергән кешегә кызын бирәчәген вәгъдә иткәч, Гайса улы Амәт бара. Четерекле вакыйгалар кичереп, Бирдебәк белән кызын алып кайткан Амәткә Җанибәк хан вәгъдәсендә тормыйча, кызны башка берәүгә бирергә ниятли. Амәт кызны урлап кача, уллары дөньяга килә. Җанибәк аларны кайтарыр өчен гаскәр җибәргәч, баланы бишеге белән агач ботагына элеп куеп, сугышалар. Күпмедер вакыт үткәч, баланы Әстерханда сал агызучылар табып, Салчы дип исем биргәннәр. Ул үсеп җиткәч, тәртипсез бер каракка әверелгән.

Идегәй бигә багышланган бүлектә аның Әбүбәкер сахабадан килгән нәсел шәҗәрәсендәге буыннар саналып, кайсы Мисырда, кайсы Кәгъбәдә һ.б. урыннарда патша-солтан булганлыклары искәртелгән. Баба Түкләс исемлесенең улы һәм аның дәвамчылары Идел-Җаек буйларына килеп, ислам динен таратулары, Идегәй би Туктамыш ханның олысын биләве һәм үзеннән соң улы Нуразын мирза хакимлек итүе турында язылган.

Беренче вариант текстында «Дастане мөддәт», ә икенче вариант текстларында «Дастане мәҗалис вәл-мәкян» дип аталган бүлектә кала һәм елга исемнәре аталып, кайсы хан биләмәсендә икәнлекләре кыскача гына әйтелгән. Аларда тарихта мәгълүм ханнар белән бергә, билгесез (ихтимал, уйдырма) исемнәр дә теркәлгән.

Китапның ахыргы «Дастане тарих» бүлегендә, нигездә, Идел-Урал төбәгендәге мөселман татар-башкортлар тарихындагы төп вакыйгалар хронологик тәртиптә язылган. Арада Русия тарихына бәйле мәгълүматлар да бар. Болгарны Аксак Тимер җимерү хәбәре белән башланган, елъязма рәвешендәге бу бүлектә Иске Казан каласының корылуы, яңа Казан шәһәренең төзелүе, Казанны руслар алуы, Казан ханнарының исемнәре, ачлык-эпидемияләр, халык баш күтәрүләре турындагы хәбәрләр теркәлгән. Кульязмаларның күпчелеге 1681–1683 елларда Сәед Җәгъфәр җитәкчелегендәге халык күтәрелеше турында язу белән төгәлләнгән. Кайбер күчермәләрдә исә XVIII гасыр башына хәтле дәвам иткән, ә аерым

кулъязмаларда Россия күләмендәге, гомумхалык, татар-мөселманнар язмышына, нинди дә булса төбәк яки авыл тарихына һәм җәмәгатенә бәйле, кайчакларда ырудаш-кардәшләр һәм гаилә кысаларындагы вакыйга-хәлләр XIX гасыр уртасына һәм ахырларына кадәр теркәп барылган. Тарихчы Рафаэль Шәйхиев «Чыңгызнамә»дәге елъязмалар тәэсире белән татарларда «вакаигънамә» жанры формалашып үстерелгән һәм XIX гасырда аеруча киң таралган дип язды[5].

Гомумән, «Чыңгызнамә» китабындагы шактый мәгълүматлар халык авыз иҗатына, шәҗәрә һәм нәсел тарихларына күчеп төрләнгән һәм тармакланган. Шулай ук галимнәрнең фәнни эзләнүләренә дә зур йогынты ясаган. Хөсәен Фәезхановның татар тарихы турында кыскача рәвештә татар һәм рус чыганакларына нигезләнеп, 1859–1860 нчы елларда язган хезмәтендә «Чыңгызнамә» китабы мәгълүматларын файдаланганлыгы күренә. Андагы Болгар шәһәренең Тимерләң тарафыннан җимерелүе, Габдулла ханның һәм биләренең үтерелүе, ханның ике улын урманга яшереп саклап калулары һ.б. вакыйгалар «Чыңгызнамә»дән алынуында шик юк[6]. Шулай ук Хөсәен Әмирхани, Гайнетдин Әхмәрев, Һади Атласи һәм башка тарихчыларның хезмәтләрендә дә «Чыңгызнамә»дәге мәгълүматлар өлешчә кулланылган.

XVIII гасырның икенче яртысында татар тарихы турында фарсы телендә язылган елъязманың башындагы өлеше «Чыңгызнамә»дәге мәгълүматларга бик якын[7] булуын да искәртергә кирәк. Бер вариантының XIX гасыр башындагы күчермәсе татарчага тәрҗемәдә нәшер ителде[8]. Сәлах Атнагуловта сакланган, 1937 елда басылып чыккан елъязма фарсы телендәге текстка бик якын[9].

Кулъязмаларда «Чыңгызнамә» китабының алты дастаны бербөтен рәвешендә һәммәсе дә булган кебек, алар аерым-аерым яки берничә бүлеге

---

[5] Шайхиев Р. Татарская народно-краеведческая литература XIX–XX вв. – Казань: изд-во ун-та, 1990. – С. 24.

[6] [Фәезханов Х]. Кыскача татар тарихы / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2011. – Б. 21-22, 33.

[7] Мустакимов И. Термин «Золотой престол» в Поволжье по данным арабографичных источников: к вопросу о статусе г. Булгара на ордынском и постордынском пространстве // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2008. – №1. – С. 155–156; История татар с древнейших времён. В семи томах. Т. IV: Татарские государства XV–XVIII вв. – Казань, 2014. – С. 900.

[8] «Инде алмаган ни калды? (Милли фаҗигабезне яктыртучы фарсы чыганагы) // Безнең мирас. – 2015. – №1. – Б. 4–7. Бу мәкаләдә «гәүр» (кяфер) сүзе ялгышлык белән «Гур (Иван Грозный)» дип аңлатылуы дөрес үк түгел. Чөнки аннан соңгы чорлар турында сүз барганда да шул ук текстта «гур» атамасы теркәлгән.

[9] История Татарии в документах и материалах. – М.: Соцэкгиз, 1937. – С. 122–124.

бергә күчерелгән очраклар да бар. Соңгы ике бүлеге бергә аеруча күп күчерелгән һәм, табигый, кулъязмаларда күбрәк сакланган.

«Чыңгызнамә» («Дәфтәри Чыңгызнамә») XIX гасырда ук татар, рус һәм Европа галимнәренең игътибар үзәгендә булган, аның белән кызыксыну XX гасыр башында да кимемәгән һәм хәзер дә дәвам итә. Казан университеты лекторы Ибраһим Хәлфин, шулай ук галимнәр һәм иҗтиһадлы кешеләрдән Х.Френ, В.Луганский, К.Фукс, И.Березин, С.Күкләшев, Р.Җиһаншин, Н.Катанов, И.Покровский, В.Бартольд, Җ.Вәлиди, Г.Гобәйдуллин, Г.Рәхим, В.Панов һәм башка затлар «Чыңгызнамә» әсәрен өйрәнүгә, текстологик анализлауга, бастырып чыгаруга зур әһәмият биргәннәр һәм тырышлык куйганнар.

«Чыңгызнамә» китабы, гомумиләштереп әйткәндә, тел тарихы, тарихи, әдәби һәм фольклор ядкәре буларак өйрәнелгән. Ибраһим Хәлфин аны Казан университеты студентларына татар телен өйрәнү өчен хрестоматия рәвешендә әзерләп бастырган. Чыңгыз нәселе турындагы дастанны 1835 елда бастырган В.Луганский аны «татар әкияте» дип атаган. Чыңгыз нәселе һәм Аксак Тимер турындагы дастаннарның текстларын 1934 елда рус телендә бастырып чыгарган В.Панов та аларны бары тик фольклор иҗаты буларак бәяләгән. С.Күкләшев хрестоматиясенә кертелгән «Гайса улы Амәт» дастаны әдәбият әсәре буларак кулланылган[10]. Гали Рәхим «Чыңгызнамә» турында болай дип язган: «Әсәрне язучы үзе анда язылган хикәяләргә ышанып, тарихи вакыйгаларга караган күк карап язган булырга ошый. Без, әлбәттә, бу китаптагы хорафат вә легендаларга тарихноктаи нәзарыннан карый алмыйбыз һәм аларда тарихи дөрестлек эзләмибез дә. Безнең өчен бу кыйссаларның әһәмияте бары тик аларның Чыңгыз һәм Тимер шикелле төрк-татар тарихының ике зур шәхесе хакында халык хыялында туган легенда булулары ягыннан гына. Шулай итеп, без бу әсәргә мәхыз әдәби яктан гына карыйбыз»[11].

Галимнәрне һәм татар укучысын аеруча кызыксындырган тарихи хәбәрләр иң әүвәл К.Фукс тарафыннан 1817 елда Казан шәһәренең кыскача тарихына багышланган хезмәтендә бастырылган. Ул үзендәге татар кулъязмасын файдалануын белдергән. Аннан соң тарихи вакыйгалар бүлеге 1822 елда И.Хәлфин китабында кайбер төзәтмәләр һәм искәрмәләр

[10] С.Күкләшев хрестоматиясендәге Амәт турындагы дастан уңаеннан галим Хатыйп Миңнегуловның кызыклы фикерләре бар *(Миңнегулов Х., Садретдинов Ш. XIX йөз татар хрестоматияләре: тикшерүләр, текстлар. – Казан: ун-т нәшр., 1982. – Б. 76, 86–87).*

[11] Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы. Беренче җилд: борынгы дәвер. Өченче бүлек: 17, 18 һәм 19 нчы гасырларда иске әдәбият. – Казан: Татарстан җөмһүриятенең дәүләт нәшрияты, 1922. – Б. 39. *Ноктаи нәзар* – караш; *мәхыз* – бары тик.

белән нәшер ителгән. Татар елъязмаларын XIX гасыр ахырында – XX гасыр башында С.Шпилевский, Н.Катанов, Х.Әмирханов, Ш.Мәрҗани, Г.Әхмәрев, Р.Фәхретдин, Г.Гобәйдуллин тикшергәннәр һәм аларның текстларын бастыруга әһәмият биргәннәр. «Тарих дастаны»н тәфсилләп тикшергән Н.Катанов 1899 елда аны «татар елъязмасы» дип атаган. Әлеге мавыктыргыч чыганак һәм аның өйрәнелү тарихы турында Газиз Гобәйдуллин, Гали Рәхим, Миркасыйм Госманов хезмәтләрендә тәфсилле язылган. Шулай да татар тарихында беренче профессорлардан Газиз Гобәйдуллинның бу мәсьәләне өйрәнүгә керткән өлешен искә төшереп китәргә ихтыяҗ бар.

Газиз Гобәйдуллин «Чыңгызнамә» китабының бу бүлеге турында кабат-кабат һәм өстәмә яңа мәгълүматлары белән бергә, кызыклы фикерләрен белдереп килгән булса да, аның елъязмаларны өйрәнүдәге мөһим фәнни хезмәте тиешенчә бәяләнеп җитмәгән. Һәрхәлдә, М.Госманов китабында (1972) Ш.Мәрҗани кәгазьләре арасында табылган вакаигънамә текстын Г.Гобәйдуллин «Мәрҗани» мәҗмугасында 1915 елда (китапта ялгыш – «1913 елда») бастырганлыгы һәм 1923 елда елъязманың тагын ике текстын бастыруы турында 100 нче биттәге астөшермәдә ике җөмлә белән генә искәртеп үтелгән. Әлеге китапның 121 нче битендә Г.Гобәйдуллинның «Мәгариф» журналындагы 1923 елгы мәкаләсендә восстание җитәкчесе Җангалине шундый ук исемдәге бүтән шәхес белән бутавы, аны бары тик 1925 елда гына ачыклавы турында кыскача язылган. Ләкин бу мәгълүмат дөрес түгел. Чөнки «Мәгариф» журналының 1923 елгы 7-8 нче (сентябрь-октябрь) санындагы мәкаләдә Җангали ачыклап язылмаган булса да, шул ук елда «Безнең юл» журналының 8-9 нчы (март-апрель) санындагы мәкаләсендә Г.Гобәйдуллин Җангали шәхесе турында хак мәгълүматны биргән[12].

Газиз Гобәйдуллин Казан университетының тарих бүлеге студенты вакытында, 1915 елда Ш.Мәрҗанигә багышлап чыгарылган фәнни җыентыктагы күләмле мәкаләсендә беренче мәртәбә татар елъязмаларына да тукталган. Аннан соң Гали Рәхим белән бергә хәзерләгән «Татар әдәбияты тарихы» китабында махсус «Вакаигънамәләр» бүлегендә җентекле тикшергән һәм шунда: «Чыңгыз хан вә Аксак Тимер» исемле бер хорафи-тарихи мәҗмуганың ахырына гыйлавә кыйлып йөртелгән» елъязманы татарлардагы андый төр чыганаклардан шул вакытка билгеле булган бердәнбере дип атаган[13]. Г.Гобәйдуллин вакаигънамәләрнең үзенчәлекләрен аңлатып, алардагы даталарның һиҗри белән хисаплауга бәйле

[12] Газиз Г. Стенька Разин һәм татар крестьяннары // Безнең юл. – 1923. – №8-9. – Б. 29.

[13] Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы. Беренче җилд: борынгы дәвер. Өченче бүлек..., 1922. – Б. 47. *Гыйлавә кыйлып* – кушып, өстәп.

хаталары булуын да искәрткән. Ул Каюм Насыйри кулъязмалары арасында сакланган ике вакаигънамә текстын да бастырган[14]. Галим вакаигънамәнең дәвамлылыгын һәм татар рухының үзгәрешен дөрес бәяләп, болай дип язган: «...әсәрнең бер генә кеше тарафыннан язылмыйчы, вакыйгаларны төрле кешеләр арттырып барганын, ягъни «коллективное творчество» булганын белдерә». Әүвәлдән алып 1824 елга кадәр дәвам иткән елъязма тексты уңаеннан ул мондый фикер әйткән: «...миладе ел, руми айлар белән башланып киткәне – соңгы катлаудыр (наслоение). Бу ике катлауда фикерләр дә төрле – беренчесендә хөкүмәткә протест, ләгънәт ачы сизелсә, икенчесендә патшаларга тарилкә тоту күренеп тора. Димәк, 18 нче гасырда әле бездә каршылык вә протестлык рухы бетмәгән, әмма 19 нчы гасыр керү белән ул рух югалган төсле сизелә. Монда татар летописе инде Елизавета вә Анна шикелле, татарларны мадди вә мәгънәви иң каты кыскан патшаларга да бер сүз әйтә алмый, ул тәмам мәхкүм бер кеше булып киткән»[15]. Газиз Гобәйдуллиның XVIII гасырдагы татар тарих фәнендәге халәте турындагы бу фикере М.Госманов тарафыннан «кризис» дип аталып үстерелде.

1925 елда рус телендә басылып чыккан күләмле мәкаләсендә дә Г.Гобәйдуллин «Чыңгызнамә» китабын һәм татар елъязмаларындагы мәгълүматларны мисал итеп китергән[16]. «Татар әдәбияты тарихы»ның икенче басмасында «Вакаигънамәләр» бүлеге тагын да камилләшкән. Анда кулъязма күчермәләренең бер өлеше Сәед Җәгъфәр күтәрелеше белән тәмамланса, башка бер төркеме Пётр патшаның 1722 елгы Персия походы белән тәгәлләнгәнлеге әйтелгән. Шулай ук елъязма даталарына анализ ясалган һәм аерым хәбәрләрнең, кыска гына булсалар да, бик мөһимлегенә игътибар юнәлтелгән. Гомумән, Г.Гобәйдуллин бу теманы дәвам итеп үстерәчәк галим, туганы Гали Рәхимнең иҗади һәм фәнни эшчәнлегенә

[14] Газиз Г. Ике кулъязма // Мәгариф. – 1923. – №17–18. – Б. 66–73. Авторы бу мәкаләсенең бик күп матбага хаталары белән чыкканлыгын 1926 елда Беренче Бөтенсоюз Тюркология съездындагы докладында искәрткән *(Развитие исторической литературы у тюрко-татарских народов // Газиз Гобәйдуллин: фәнни-биографик җыентык = Газиз Губайдуллин: научно-биографический сборник / төз.-авт.: С.Гобәйдуллин, Э.Кульпин-Гобәйдуллин, Р.Мәрданов, И.Һадиев. – Казан: Рухият, 2002. – Б.117)*. Гали Рәхим дә Г.Газиз мәкаләсенең күп хаталар белән чыкканлыгы турында язган *(Гали Рәхим: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык / төз. Мәрданов Р., Һадиев И. – Казан: Җыен, 2008. – Б. 130)*.

[15] Газиз Г. Ике кулъязма... – Б. 72–73. *Тарилкә* – тәлинкә, *летопись* – елъязма; *мәхкүм* – хөкем ителгән. Соңрак Г.Рәхимнең һәм М.Госмановның рус телендәге хезмәтләрендә бик еш кулланылган «наслоение» гыйбарәсе елъязма өстәмәләренә карата иң әүвәл Г.Гобәйдуллин мәкаләсендә язылган.

[16] Из прошлого татар // Газиз Гобәйдуллин: фәнни-биографик җыентык..., 2002. – Б. 135–177.

зур йогынты ясаганын да игътибардан чыгармаска кирәк. Г.Рәхимнең татар елъязмаларына багышланган махсус фәнни хезмәте 1930 нчы елда бастырырга әзерләнгән[17] булса да, авторының 1931 елда кулга алынуы сәбәпле, нәшер ителмичә калган. Үз кулъязмасында 73 битне тәшкил иткән күләмле фәнни тикшеренүендә Г.Рәхим вакаигънамәләрне тәфсилләп өйрәнгән, әһәмиятле фикерләре белән уртаклашкан, мөһим нәтиҗәләр ясаган. М.Госманов әлеге хезмәтне татар елъязмалары турында иң югары дәрәҗәдә башкарылган дип бәяләгән[18]. Г.Рәхим хезмәтенең рус телендәге тексты (татарча текстлары төшереп калдырылып) 2004 елда, ә тулы тексты 2008 елда гына басылып чыкты[19].

XIX гасыр башыннан алып 1930 нчы елларга хәтле «Чыңгызнамә» шактый киң өйрәнелгән булса, аннан соңгы берничә дистә елда бу китап турында мәгълүмат юк диярлек. Моның төп сәбәпләреннән берсе, һичшиксез, СССРның югары җитәкчелеге, коммунистлар партиясе – ВКП(б)ның Татарстандагы сәяси-идеологик эшләр турындагы 1944 елның 9 август карары булган.

1963 елда басылган «Борынгы татар әдәбияты» китабында «Гыйса углы Амәт» дастаны (1859 елда дөнья күргән Салихҗан Күкләшев хрестоматиясеннән алынып) һәм Хәлфин китабындагы тарих бүлеге өлешчә күчереп бастырылган[20]. «Хикәяте Гыйса углы Амәт» 1984 елда чыккан «Дастаннар» китабына да кертелгән[21].

---

[17] Тарих, археология һәм этнография җәмгыятенең 1929 елдагы утырышында укылган доклад нигезендә басмага әзерләнгән бу хезмәтне Татарстан Главлиты 1930 елның 10 мартында нәшер итәргә рөхсәт биргән.

[18] Усманов М. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв..., 1972. – С. 101. Гомумән, елъязмалар темасына караган, 1970 нче еллар башына кадәрге публикацияләр турында М.Госманов китабында киң мәгълүмат бирелгән.

[19] Рахим А. Новые списки татарских летописей // Проблемы истории Казани: современный взгляд: сб. статей. – Казань: Ин-т истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2004. – С. 555–593; Рахим А. Новые списки татарских летописей // Гали Рәхим: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык..., 2008. – Б. 125–192. Татар телендәге тарихи чыганаклар белән эш итүчеләр соңгы чорда да «Чыңгызнамә»дәге елъязмаларга әһәмият биреп килә. Мәсәлән, М.Әхмәтҗанов китабында махсус «Татар елъязмалары» бүлеге бар, И.Мөстәкыймов елъязмалардагы борынгырак мәгълүматларны тикшерүгә зур әһәмият бирде *(Әхмәтҗанов М. Татар кулъязма китабы. – Казан: Татар. китап нәшр., 2000. – Б. 128–141; Мустакимов И. Термин «Золотой престол» в Поволжье по данным арабографичных источников: к вопросу о статусе г. Булгара на ордынском и постордынском пространстве // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2008. – №1. – С. 142–157).*

[20] Борынгы татар әдәбияты / төз.: Мөхәммәтов Х., Хисмәтуллин Х., Абилов Ш., Беляева Ү., Исәнбаев С. – Казан: Татар. китап нәшр., 1963. – Б. 176–180, 418–419.

[21] Татар халык иҗаты. Дастаннар / төз. Ф.Әхмәтова. – Казан: Татар. китап нәшр.,

Археограф галим Альберт Фәтхи Казан дәүләт университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендәге татар кульязмалары тасвирламасының 1968 елда басылган җыентыгында, нигездә, Ибраһим Хәлфингә бәйле рәвештә «Чыңгызнамә» турында да мәгълүмат бастырган[22].

Тарихчы галим Миркасыйм Госмановның 1972 елгы хезмәтендә «Дәфтәри Чыңгызнамә» һәм аның өйрәнелү тарихы фәнни нигездә тәфсилләп тикшерелгән[23]. М.Госманов аның документаль-тарихи трактат түгеллеген, тарихи материалга һәм авторның чиксез хыялына нигезләнгән ярымфольклор дастаны килеп чыкканлыгын әйткән һәм, шуңа күрә, тарихи Чыңгыз хан белән аноним авторның Чыңгыз ханы – төрле кешеләр дип һәм беренче нәүбәттә тарихи-әдәби әсәр дип тәгаенләгән[24].

Әдәбият галиме Мәсгуд Гайнетдинов «Дастаннар китабы» исемендә махсус мәкаләсен бастырган[25]. Ул «Чыңгызнамә» китабын «тарихи әсәр, фәнни әсәр итеп санауны бүгенге көнгә кадәр яшәп килгән зур кимчелек», әдәби әсәр буларак, аның үзәк темасы «казак чыгып китү» һәм «идеаль казак-герой» дип белдергән[26]. М.Гайнетдинов соңрак та «Дәфтәре Чыңгызнамә – «Дастаннар китабы» әдәби әсәр» дип, «борынгы тарих турында легендалаштырылган хикәятләр тупламы» дип язган[27].

Галим Вахит Хаковның татар елъязмалары теленә багышланган махсус мәкаләсе мәгълүм[28]. Татар әдәбияты тарихын өйрәнгән галим Ша-

---

1984. – Б. 102–105.

[22] Кульязмалар тасвирламасы. XII чыгарылыш: Татар әдипләре һәм галимнәренең кульязмалары. Өченче бүлек / төз. А.Фәтхи. – Казан: ун-т нәшр., 1968. – Б. 18, 27–29.

[23] Усманов М. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв..., 1972. – 223 с.

[24] Шунда ук. – Б. 131–132.

[25] Гайнетдинов М. Дастаннар китабы: язылуына 300 ел тулу уңае белән // Казан утлары. – 1979. – №10. – Б. 172–175. Әлеге мәкалә тулыландырылган һәм кайбер төзәтмәләр кертелгән хәлдә галимнең 2001 елгы җыентыгында һәм «Татар әдәбияты тарихы» сигез томлыгының 2 нче томында басылды: Татар елнамәсе – «Дастаннар китабы» // Гайнетдин М. Хакыйкать юлыннан: әдәби тәнкыйть. – Казан: Татар. китап нәшр., 2001. – Б. 22–36; Гайнетдинов М. «Дәфтәре Чыңгызнамә» // Татар әдәбияты тарихы. Сигез томда. Т. 2: XV–XVII гасырлар. – Казан: Татар. китап нәшр., 2014. – Б. 206–211.

[26] Гайнетдинов М. Дастаннар китабы..., – 1979. – Б. 172–173.

[27] Гайнетдинов М. «Дәфтәре Чыңгызнамә» // Татар әдәбияты тарихы. Сигез томда. Т. 2. ..., 2014. – Б. 206.

[28] Хаков В. О татарских летописях и их языке // Структура и история татарского языка. – Казань: изд-во ун-та, 1982. – С. 100–109. Бу публикациядәге дүрт биттә кульязма факсимилеләре бирелгән.

кир Абиловның «Дастаннар мәҗмугасы» исемле мәкаләсе шулай ук «Чыңгызнамә» китабына багышланган[29].

«Чыңгызнамә»нең үзгәртелгән һәм иректә хикәяләү сыйфатындагы кайбер өлешләре 1987 елда басылган «Риваятьләр һәм легендалар» китабына да кертелгән. Анда 1882 елгы басмадан алынган өзекләре «Бараҗ нәселе» һәм «Казан тарихы» дип исемләнгән риваятьләр рәвешендә урын алган. Өлкән яшьтәге милләттәшебез Ш.Сабировның телдән сөйләгәне буенча язып алынган «Аксак Тимер» риваятенең дә төп чыганагы «Чыңгызнамә» китабы булганлыгы аңлашыла. Сөйләнгәннәр буенча теркәлгән «Иске Казан каласының корылуы» турындагы риваять тексты шулай ук «Чыңгызнамә»гә нигезләнгән[30].

Галим Сәлим Гыйләҗетдинов 2000 һәм 2011 елларда «Чыңгызнамә» текстын гарәп графикасыннан күчереп бастырып чыгарды[31].

Россия Фәннәр академиясенең Санкт-Петербург шәһәрендә урнашкан Көнчыгыш кулъязмалары институтындагы төрки кулъязмалар каталогының авторы Л.В.Дмитриева бу китапны «Чыңгыз хан вә Аксак Тимер» дип исемләп, фольклор бүлегендә тасвирлаган. Аны шулай ук «чәчмә хикәят», «риваятьләр җыентыгы» дип тә атаган. Кулъязма җыентыкларда аерым өлешләре (фасыл, дастаннар) мөстәкыйль текстлар рәвешендә еш очравын һәм әлеге каталогта исәпкә алынган җыентыкларда гомуми исеме юклыгын искәрткән[32].

Миркасыйм Госманов һәм Мария Иванич «Дәфтәри Чыңгызнамә» текстын латин хәрефләрендәге транскрипция рәвешендә, алман телендәге мәкаләләр һәм искәрмә-аңлатмалар белән 2002 елда Венгриядә бастырдылар[33].

Археограф галим Марсель Әхмәтҗанов Татарстан Фәннәр ака-

---

[29] Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. Т. I: урта гасырлар дәвере. – Казан: Татар. китап нәшр., 1984. – Б. 347–356. 1999 елда рус телендә нәшер ителгән китапта да Ш.Абиловның «Дастаннар китабы» (Книга дастанов) мәкаләсе дә бар *(Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв.). – Казань: Фэн, 1999. – С. 177–180).*

[30] Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар / төз. С.Гыйләҗетдинов. – Казан: Татар. китап нәшр., 1987. – Б. 31–33, 45–47, 58–59, 297–298, 304.

[31] Дәфтәре Чыңгыз-намә / басмага әзерләүче: С.Гыйләҗетдинов. – Казан: «Иман» нәшр., 2000. – 44 б.; Мирастан биш сәхифә: XVII–XIX гасырлар әдәби-тарихи ядкярләре / төз. С.Гыйләҗетдинов. – Казан: Татар. китап нәшр., 2011. – Б. 37–96.

[32] Дмитриева Л.В. Каталог тюркских рукописей Института востоковедения Российской Академии наук. – М.: Вост. лит., 2002. – С. 480.

[33] Ivanics Mária, Usmanov Mirkasym A. Das Buch der Dschingis-Legende (Däftär-i Čingiz-nāmä). I. (Vorwort, Einführung, Transkription, Wörterbuch, Faksimiles). – Szeged, 2002. – S. 328.

демиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Кулъязмалар һәм текстология бүлеге мирасханәсе фондында 2006 елга кадәр тупланган җиде берәмлек «Чыңгызнамә» күчермәләренең тәфсилле тасвиры белән таныштырды[34].

Әйтелгәннәрдән тыш, фәнни хезмәтләрдә һәм аерым мәкаләләрдә «Чыңгызнамә» текстына мөрәҗәгать итүчеләр булып тора. М.Әхмәтҗанов татар шәҗәрәләренә багышланган хезмәтләрендә «Чыңгызнамә»дәге шәҗәрәләрне даими игътибар үзәгендә тотты, шулай ук «бараҗ» атамасы һәм Болгар чорына бәйле башка вакыйгалар белән аралаштырып «Чыңгызнамә» һәм бүтән иске әсәрләрнең XX гасырда фальсификацияләнүе турында язды[35]. Мария Иванич Чыңгыз хан нәселенә багышланган дастанда язылган бикләрнең исемнәрен тарихи чыганаклар һәм шәҗәрәләр белән бәйләп, алар арасында ярымлегендар затлар белән бергә XIV гасыр ахырында яшәгән реаль шәхесләр булган дип белдерде һәм башка кызыклы фикерләре белән уртаклашты[36]. Тарих фәннәре докторы Дамир Исхаков та бу әсәргә еш мөрәҗәгать итеп, аңлатмалар яза һәм фикерләрен белдерә[37]. Кайбер тарихчылар Аксак Тимернең Болгарга һөҗүме уңаеннан аңа багышланган дастанны кабат тикшерделәр һәм бу мәсьәләдә кызык-

---

[34] Әхмәтҗанов М. «Дәфтәре Чыңгызнамә» китабы кулъязмаларын өйрәнү юлында бер тәҗрибә // Татар әдәбияты текстологиясе мәсьәләләре (Урта гасырлар – XX йөз башы). – Казан, 2006. – Б. 16–24.

[35] Ахметзянов М. Татарские шеджере: исследование татарских шеджере в источниковедческом и лингвистическом аспектах по спискам XIX–XX вв. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1991. – 158 с.; Әхмәтҗанов М. Татар шәҗәрәләре. – Казан: Татар. китап нәшр., 1995. – 128 б.; Әхмәтҗанов М. Татар кулъязма китабы. – Казан: Татар. китап нәшр., 2000. – Б. 37–40, 90; Әхмәтҗанов М. Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы. – Казан: Мәгариф, 2002. – Б. 113–114.

[36] Иванич М. «Дафтар-и Чингиз-наме» как источник по истории кочевых обществ // Источниковедение истории Улуса Джучи (Золотой Орды): от Калки до Астрахани. 1223–1556. – Казань: изд-во «Мастер Лайн», 2002. – С. 316–319.

[37] Исхаков Д. Некоторые данные о средневековой этнической ситуации в юго-восточных районах Татарстана (XIV–XVI вв.) // Проблемы изучения истории заселения и образования населённых пунктов Альметьевского региона: сб. статей. – Казань: РИЦ «Дом печати», 2000. – С. 29–45; Исхаков Д. Родословные и эпические произведения как источник изучения истории сословий Улуса Джучи и татарских ханств // Источниковедение истории Улуса Джучи (Золотой Орды): от Калки до Астрахани. 1223–1556. – Казань: изд-во «Мастер Лайн», 2002. – С. 329–366; Исхаков Д. Бер шәҗәрә артыннан // Туган җир: төбәк тарихы буенча журнал = Родной край: краеведческий журнал. – 2018. – №1. – Б. 62–67; Исхаков Д. «Дәфтәре Чыңгызнамә» әсәренең бер урынына комментарий // Туган җир = Родной край. – 2018. – №2. – Б. 25–28; Исхаков Д. Халкыбызның эпик әсәрләрендә яшеренгән милли тарихыбыз // Туган җир = Родной край. – 2018. – №3. – Б. 14–27.

сынулар дәвам итә[38]. Тарихчы галим Ильяс Мөстәкыймовның 2009 елгы мәкаләсе аеруча мөһим яңалыклардан булды, ул, «Чыңгызнамә»нең башка бер вариантындагы тарихи мәгълүматларны ачыклап, фәнни нигезле аңлатмалары белән уртаклашты[39]. Татар тарихына багышланган җидетомлык хезмәттә галимнәр тарафыннан «Чыңгызнамә»нең әдәби кыйммәте һәм тарихи мәгълүматлары турында язылды, шулай ук аның авторлыгын Идрис хафизга нисбәт итү дә шиккә алынды[40].

«Чыңгызнамә» китабы фәннең кайсы тармагына һәм нинди жанрга каравы турындагы фикерләрне җыеп караганда, тарихчылар, табигый, аның тарихи мәгълүматына күбрәк әһәмият биргән, ә әдәбиятчылар әдәби җәһәтенә игътибар юнәлткәннәр. Һәрхәлдә, «Чыңгызнамә»не саф тарихи яки саф әдәби генә дип бүлеп карау юк диярлек. Чөнки мондый төр борынгы дәвер язма истәлеген тулаем аерым бер тармакка гына нисбәт итү дөрес була алмый.

Китапның башындагы Чыңгыз хан, Аксак Тимер һәм Гайса улы Амәткә багышланган өч бүлегендә тарихи исемнәр һәм вакыйгалар кулланылса да, алар күбрәк әдәби һәм халык авыз иҗаты әсәрләре буларак күзаллана. Ул бүлекләр күләмнәре ягыннан да зуррак. «Чыңгызнамә»нең ахырындагы кечкенә өч бүлекне (Идегәй, ханнар биләмәләре, тарихи вакыйгалар елъязмасы) әдәбиятка шартлы рәвештә кертергә дә читен. Алардан берсе Идегәйнең уйдырма шәҗәрәсендәге исемнәр саналган берничә бит күләмендә, икенчесе – тарихка якын булса да, шактый буталчык һәм хакыйкатьтән ерак мәгълүматлардан торган, бер бит чамасындагы коры язма, ә ахыргысы – татар халкы тарихын дөресрәк яктырткан елъязма рәвешендәге берничә бит күләмен биләгән текст. Соңгысының, татар телендәге язма тарихи чыганаклар аз булганлыктан, тарихчы галимнәр һәм тарихи мәгълүматка мохтаҗ белгечләрнең игътибарын электән алып хәзергәчә (гасырлар дәвамында) җәлеп иткәнлеге гаҗәп түгел.

«Чыңгызнамә»дәге «дастан» дигән атамаларны рус телендәге элекке китапларда һәм хезмәтләрдә «повесть» дип бирү, бәлки, ярагандыр, әмма үз телебездә XXI гасырда нәшер ителгән «Татар энциклопедиясе»нә мон-

---

38 Измайлов И. Нашествие Аксак-Тимура на Болгар: мнимая реальность и татарская историческая традиция // Источники и исследования по истории татарского народа: материалы к учебным курсам в честь юбилея акад. АН РТ М.А.Усманова / сост. Усманова Д., Мустафина Д. – Казань: изд-во ун-та, 2006. – С. 99–128.

39 Мустакимов И. Об одном списке «Дафтар-и Чингиз-наме» // Средневековые тюрко-татарские государства. Вып. 1. – Казань, 2009. – С. 122–131.

40 История татар с древнейших времён. В семи томах. Т. V: татарский народ в составе Российского государства (вторая пол. XVI – XVIII вв.). – Казань, 2014. – С. 563–564, 585–587.

дый билгеләмә ятышмый. Анда китапны «6 повесть-бүлектән тора» дигән сүзләр зур күләмле әсәрләргә дәгъва итә. Тик, әйтеп үтелгәнчә, «Чыңгызнамә»нең ахыргы өч бүлеге әдәби әсәр дип аталырлык түгел һәм «повесть» төшенчәсенә бөтенләй туры килми.

«Чыңгызнамә» китабының кульязмалары

«Чыңгызнамә»нең тулы тексты һәм аерым бүлекләре элек кульязма күчермәләр рәвешендә күп таралган һәм хәзергәчә дә шактый сакланган.

XVIII гасырда Сенаттагы тикшерү эше өчен «Чыңгызнамә» кульязмасының Көньяк Урал төбәгендәге бер нөсхәсеннән ертып алынган өлеше Мәскәү шәһәрендәге Россия дәүләт борынгы актлар архивында сакланган. Ул кульязма 1737 елда рус теленә тәрҗемә ителгән. Ләкин тәрҗемәсе булуга карап, шул заманда ук фәнни әйләнешкә кергән һәм өйрәнелә башлаган дигән кебек фикерләр ялгыш. Чөнки ул империячел дәүләтнең яшерен сәяси тикшерү эше өчен җәлеп ителгән һәм тар даирә дәүләт чиновникларына гына мәгълүм булып, архив киштәсендә гасырлар дәвамында билгесез хәлдә сакланган.

Китап текстының аерым өлешләрен татар, рус һәм Европа матбугатында бастырып чыгарган галимнәр һәм тикшеренүчеләр халыкта сакланган төрле кульязма нөсхәләреннән файдаланганнар. Казан университеты галиме Ибраһим Хәлфин «Чыңгызнамә»не 1822 елда китап итеп бастырганда берничә күчермәсен файдаланып, иң ышанычлыларына таянып эш иткәнлеген искәрткән. Татар археографлары Гали Рәхим, Сәед Вахиди, Альберт Фәтхи хезмәтләрендә «Чыңгызнамә»нең күчермәләре күп булганлыгы әйтелгән.

Татар телендәге тарихи чыганакларны махсус өйрәнгән галим М.Госманов «Дәфтәри Чыңгызнамә»нең сакланган кульязмаларының исәбе күп дип яза[41]. Ул үзе тикшергән һәм исәпкә алган 26 кульязма күчермәдә китапның тулы текстын (аз-маз өзеклекләре булганнары белән), ягъни алты бүлеген дә тәшкил иткәннәре – 9, тулы булмаган (берничә яки ялгыз бер бүлектән торган) – 7 һәм фрагментар (гадәттә, соңгы – вакаигънамә бүлеге булганнары) – 10 данә дип язган[42]. Әйтелгән 26 күчермәгә өстәп, Госманов әдип Нәкый Исәнбәттә XVIII гасырга караган тулы бер нөсхә һәм педагог Зәйнәп Максутованың шәхси китапханәсендә дефектлы нөсхә саклануын белдергән. Шулай ук Лондондагы Британия музеенда, Берлин-

---

[41] Усманов М. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв..., 1972. – С. 101.

[42] Шунда ук. – Б. 102. Китапта күрсәтелгән саклану урыннары һәм шифрларын дикъкать белән караганда, тулы текстлылары – 8 берәмлек һәм тулы түгелләре – 8 берәмлек икәнлеге күренә.

дагы Король китапханәсендә, Париждагы Милли китапханәдә һәм Казакъстан ССР китапханәсендә әсәрнең тулы күчермәләре саклануын искәрткән. Элекке чорда «Дәфтәри Чыңгызнамә»не өйрәнгән һәм бастырган галимнәрдән К.Фукс, Ш.Мәрҗани, Х.Әмирхан, Г.Гобәйдуллин һ.б. кулланган, матбугатта телгә алынган нөсхәләрен дә кушып исәпләп, барлыгы 40-тан артык кулъязма күчермәсе фәнгә билгеле дип язган. Шулардан җиде кулъязма археограф Сәед Вахиди коллекциясеннән икәнлеген күрсәткән[43]. (Монда әйтелгән Фукс, Мәрҗани һ.б. затларга бәйле әүвәлгеләрен исәпкә алмаганда, төгәл 32 күчермә турында сүз бара).

Госманов китабында язылганнардан ун (тулы булмаган һәм фрагмент хәлендәге) күчермә Казан университеты китапханәсендә саклануы әйтелгән һәм аларның шифрлары күрсәтелгән[44]. Тик, кайбер шифрларның ялгыш икәнлеген бу басманы әзерләү дәвамында ачыкладык. Галимнең китабында «Т762» дип басылган шифр дөреслектә «726т», ә китапта «вакаигъ варианты» диелгән «Т1658» шифрында «вакыйгат» дип исемләнгән башка әйбер – 1897 елгы халык исәбен алуга бәйле чуалыш турындагы язма булып чыкты[45]. Шул рәвешле, Госманов хезмәтендә телгә алынган чынбарлыктагы кулъязмалар 31 икәнлеге ачыкланды.

Әйтелгән «726т» шифрлы кечкенә форматлы кулъязманың юка тактадан эшләнгән арткы тышлыгы сакланып калган. Шул тышлыкның эчке ягында шәмәхә кара белән латин хәрефләрендә «Проф. Газиз Гобәйдуллиннән бүләк. 1935. Каз. Унив. көтепханәсенә» дип язылган. Бу мәгълүмат кулъязманың мәгънәви әһәмиятен тагын да арттыра. Ул «Чыңгызнамә» китабы турында үзе дә мәкаләләр язган һәм Гали Рәхим белән «Татар әдәбияты тарихы» китапларында тәфсилле тикшерүләр бастырган, танылган тарихчы галим кулында булган кулъязма истәлек булуы белән кызыклы. Аны бүләк итеп биргән вакытта (1935 елда) туганы Г.Рәхим университет китапханәсендә эшләгән.

М.Госманов китабында З.Максутова китапханәсендәге дигән күчермә хәзерге вакытта Татарстан Республикасының Милли музеенда саклана.

Кулъязмаларның исәбе турында М.Госманов хезмәтендәге мәгълүмат башка китапларга һәм мәкаләләргә күчеп килде. Аның нигезендә «Татар энциклопедиясе»нең 2 томында кабатланган «40 тан артык күчермәсе

[43] Шунда ук. – Б. 103.

[44] Шулар арасында «587т» шифрлы кулъязманың 17–19 кәгазьләрендә алтынчы (тарих) бүлеге генә бар диелгән. Ләкин андагы 13–14 кәгазьләрдә башка китаплардагы мәгълүматлар белән аралашкан бишенче (ханнарның биләмәләре турындагы) бүлек тә бар.

[45] Бусында да, алда әйтелгән «Т762» кебек, кулъязма шифры саннарының урыннарында ялгышлык китмәде микән дип тикшерү уңай нәтиҗә бирмәде.

билгеле» дигән сүз, әлбәттә, чынбарлыкны чагылдырмый торган, искергән сан иде[46].

Венгриядә басылган «Дәфтәри Чыңгызнамә» китабының керешендә М.Госманов тарафыннан элегрәк әйтелгән 40 кульязма күчермәсеннән тыш, тагын 5 күчермәсе барлыгы күрсәтелгән. Аларның берсе Шотландия башкаласы Эдинбург университеты китапханәсендә тулы текстлы һәм дүртесе Казан университеты китапханәсендәге, М.Госмановның 1972 елгы хезмәтенә кермәгән күчермәләр.

Болардан тыш, Казан университеты китапханәсендәге «2495т» шифрлы кульязма турында М.Әхмәтҗанов китабында язылды[47].

Әйтелгәннәргә өстәп шул ук китапханәдәге «216т» шифрлы, 1818 елда И.Хәлфин кулы белән күчерелгән өлешләрен (алар турында киләсе бүлектә тулырак язылды), шулай ук моңарчы билгесез калып килгәннәрдән Чыңгыз хан нәселе турындагы дастаннан башка бүлекләре булган «4198т», вакаигънамә тексты язылган «4199т» шифрлы, ахыргы бүлектәге Казан алыну турындагы мәгълүмат фрагменты теркәлгән «1870т» кульязманы да исәпкә алырга кирәк. Нәтиҗәдә, Казан университеты китапханәсендәге төрле күчермәләр 18 берәмлекне тәшкил итә. Кызганыч ки, алар арасында тулы текстлысы юк. «Чыңгызнамә»нең бөтен бүлекләре дә булган «726т» шифрлы, дефектлы кульязма Чыңгыз хан нәселе турындагы беренче бүлегенең ахырыннан гына башлана. Текст тулылыгы буенча икенче урындагы кульязмада беренче бүлеге юк һәм 1886 елгы ул күчермә бик күп хаталар белән язылган (мәсәлән, «кяфер урыс» дигән сүз «хяфер үмән» диелгән). Калган кульязмаларның берсендә өч бүлек, дүртесендә – ике бүлек һәм унберендә берәр бүлек текстлары (төрле тулылыкта һәм фрагмент дәрәҗәсендә) теркәлгән.

Россия Фәннәр академиясенең Санкт-Петербург Көнчыгыш кульязмалары институтындагы төрки кульязмалар каталогында тасвирланган «С695» шифрлы күчермә М.Госманов китабында күрсәтелмәгән. Каталогтагы мәгълүматка караганда, Чыңгыз хан нәселе һәм Аксак Тимер дастанының 1834 елгы кульязмасы шәркыять галимнәренең берсе (кем икәнлеге төгәл билгеле түгел) тарафыннан И.Хәлфин басмасыннан күчерелгән һәм русчага тәрҗемәсе дә теркәлгән[48].

---

[46] Югыйсә, энциклопедиянең бу басмасыннан сигез ел элегрәк чыккан кыскача белешмәсендә «Дәфтәре Чыңгызнамә»нең «60 тан артык кульязмасы билгеле» дигән сүзләр хакыйкатькә якынрак *(Татар энциклопедия сүзлеге. – Казан: Татар энцикл. ин-ты, 2002. – Б. 197)*.

[47] Әхмәтҗанов М. Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы..., 2002. – Б. 93–94.

[48] Дмитриева Л.В. Каталог тюркских рукописей Института востоковедения..., 2002. – С. 481–483.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә хәзерге вакытта «Чыңгызнамә» текстлары төрлечә күләмле (тулы диярлек һәм фрагмент рәвешендәгеләр) барлыгы 11 берәмлекне тәшкил итә. Алар китапханә фондына 1995–2017 еллар арасында алынган.

Татарстан Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының язма һәм музыкаль мирас үзәгендә, басма чыганаклардан ачыклануынча, «Чыңгызнамә»нең төрле күләмдәге 12 күчермәсе бар[49]. Бу кульъязмаларның икесе элегрәк Шакир Абилов карамагында булган. Тик ул кульъязмалар, Шакир Абилов язганча[50], тулы күчермәләр түгел һәм берсенең датасы элек белдерелгәнчә 1716 елга карамый икән. Г.Ибраһимов исемендәге институтта саклана торган күчермәләрдән тулырак текстлысы (Ш.Абиловтан алынган) «6428» саны белән саклана торган кульъязмада. Гомумән, әйтелгән күчермәләрдә «Чыңгызнамә»нең беренче бүлеге – 5, икенче бүлеге – 7, өченче бүлеге – 3, дүртенче бүлеге – 2 һәм алтынчы бүлеге – 4 кульъязмада (шулардан берсе И.Хәлфин басмасыннан) тулы һәм фрагмент хәлендә сакланган.

«Чыңгызнамә»нең тагын бер тулы булмаган текстлы күчермәсе Р.Мәрдановның шәхси архивында саклана.

Башкортстанның Тарих, тел һәм әдәбият институты китапханәсендә «Чыңгызнамә»нең 1801 елда күчерелгән тулы текстлы диярлек бер күчермәсе барлыгы билгеле[51].

Нәтиҗәдә, ачыклап туплаган мәгълүматларыбыз буенча, «Чыңгызнамә» («Дәфтәри Чыңгызнамә») китабының китапханәләрдә, фәнни

---

[49] Әхмәтҗанов М. Татар кульъязма китабы..., 2000. – Б. 133; Әхмәтҗанов М. «Дәфтәре Чыңгызнамә» китабы кульъязмаларын өйрәнү юлында бер тәҗрибә..., 2006. – Б. 16–24; Франк А. Исламская историография и «булгарская» идентичность татар и башкир в России / пер. с англ. И.Хайбутдиновой. – Казань, 2008. – С. 30, 250; Ахметзянов М. Татарская археография: отчеты о результатах археографических экспедиций (1972–2010 гг.). Часть 1. – Казань, 2011. – С. 48–49; Әхмәтҗанов М. Татар археографиясе: соңгы елларда археографик экспедицияләр вакытында тупланган кульъязмаларның тасвирламалары (1972–2012). Алтынчы кисәк. – Казан, 2016. – Б. 70; Әхмәтҗанов М. Татар археографиясе: соңгы елларда археографик экспедицияләр вакытында тупланган кульъязмаларның тасвирламалары. Сигезенче кисәк. – Казан, 2011. – Б. 158.

[50] Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. Т. I: урта гасырлар дәвере..., 1984. – Б. 348–349. Ш.Абилов карамагында булган кульъязмаларның берсенең тексты өлешчә басылды: Әхмәтҗанов М. Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы. – Казан: Татар. китап нәшр., 2009. – Б. 10–15.

[51] Булгаков Р., Галяутдинов И. Описание восточных рукописей Института истории, языка и литературы. Часть I: тюркские рукописи. – Уфа: АН РБ, Гилем, 2009. – С. 56–58.

оешмаларда, музей һәм шәхси тупламнарда хәзерге вакытта барлыгы 62 берәмлек кулъязма күчермәсе бар (Казанда 44 күчермә, Петербургта – 14, Мәскәүдә – 2, Уфа шәһәрендә – 1, Касыйм шәһәре музеенда – 1). Әлеге санга М.Госманов китабында телгә алынган Лондон, Париж, Берлин һәм Казакъстан оешмаларындагы дүрт һәм 2002 елгы китапта әйтелгән Эдинбург университеты китапханәсендәге нөсхәләрне өстәсәк – 67 күчермә барлыгы тәгаен билгеле дип әйтә алабыз[52].

Китапның басмалары

Бу бүлекчәдә «Чыңгызнамә»нең текстлары тулы (яисә тулырак) дөнья күргән басма китапларга күзәтү ясап үтәбез.

1822 елгы басма

Казан университетының Шәрык телләре кафедрасын 1807–1817 елларда җитәкләгән Х.Френ һәм университет советы тәкъдиме нигезендә галим Ибраһим Хәлфин студентларга татар телен өйрәтү өчен яңа дәреслек язарга алынган. Х.Френның 1817 елның сентябреннән С.-Петербургта Фәннәр академиясендә эшли башлавын исәпкә алганда, И.Хәлфин Чыңгыз хан нәселе турындагы китапны 1817 елга кадәр үк хәзерләргә керешкәнлеге аңлашыла. Хәлфин кулъязмасында китапның тексты 1818 елда төгәлләнгәнлеге күрсәтелгән.

Титул битләре татар һәм рус телләрендә, китап исеме өчен шактый озын рәвештә болай дип бирелгән: Әхвале Чыңыз хан вә Аксак Тимер, вә тәварихлара махсус бәгъзе кыйсем-кыйтгалар замим вә тилмизләрә сәһеләтчөн җәмигъ лөгатьләрене хоруфе һиҗа үзрә тәртиб әйләйүб, императорның Казан университеты димәклә мәгъруф баш мәдрәсәсе нәфгычөн мәзкүр университетның лекторы, титулярный советник Ибраһим бине Исхак Хәлфийүн иҗад вә тәкърир әйләмешем. Фи бәлдәти Казан, 1819 сәнә миладилә, 1234 сәнә һиҗрәтлә = Жизнь Джингиз-хана и Аксак Тимура с присовокуплением разных отрывков до истории касающихся, коих все слова для обучающихся расположены по алфавиту, в пользу воспитанников Императорского Казанского университета, составленная лектором оного университета Ибрагимом Хальфином»[53].

---

[52] Бу исәпкә ачыкланган хәтле күчермәләр генә кертелде. Н.Исәнбәтнең шәхси архивында М.Госманов язган бер күчермә генә исәпләнсә дә, анда, кайбер мәгълүматларга караганда, «Чыңгызнамә»нең берничә күчермәсе булган. Уфа шәһәрендәге мәгълүматларыбыз да тулы түгел. Ә М.Госманов исәбендәге Фукс, Мәрҗани һ.б. кулланган дигәннәрен үзебез санамадык.

[53] Китапны төзүченең фамилиясе русча титул битендә «Хальфин» һәм татарча титулында хәрәкәләр белән «Хәлфийүн» дип басылган. Ибраһим Хәлфин башка

Барлыгы 1200 данә тираж белән нәшер ителгән бу китапның төп тексты типографиядә 1819 елда, ә сүзлек өлеше 1821 елда басылган. (Шул сәбәптән аның чыгу елы татарча титулында – 1819, ә русчасында – 1822 ел дип күрсәтелгән). Россия уку йортлары өчен махсус әзерләнгән бу хезмәте өчен Ибраһим Хәлфин патша тарафыннан бриллиант кашлы йөзек белән бүләкләнгән[54].

Китапның басылган елы титул битләрендә төрлечә күрсәтелгәнгә күрә, элегрәк буталып язучылар аз булмаган (андыйлар хәзер дә бар), әлеге даталар кайчагында китапның ике басмасы булган кебек тә ялгышуларга китергән. Гомумән, иске басма китапларның тышлыкларында һәм титул битләрендә берничә төрле ел күрсәтелгән очракларда кагыйдә буенча, соңгырак елы нигез итеп алына.

Китап тиражының күпмеседер Россиядәге уку йортларына таратылган һәм сатылган, ә калган өлеше 1842 елгы янгын вакытында типографиянең башка милке белән харап булган[55].

Китап җыйнак форматта, XIX гасыр башында Россиядә эшләнгән (тиражының бер өлеше зәңгәрсу төстәге) кәгазьгә басылган. Зурлыгы 13,5х21 см (катыргы тышлыгы 14х21,5 см) тәшкил итә.

Бит саннары ике өлештән тора: кереш һәм төп текстныкы – 91, сүзлек һәм типография хаталары һәм төзәтмәләренең таблицасы өлеше 71 бит (төзәтмәләр 68–71 битләрдә). Китапның пагинация куелган гомуми күләме 162 битне тәшкил итә. Арада пагинация куелмаган берничә бите дә бар.

Университет студентларына атап язылганга күрә, китапның башындагы кереш сүзе русча («Предисловие», 1–2 битләрдә кыскача) һәм татарча («Мөкаддимә», 3–8 битләрдә, киңрәк итеп) басылган[56]. 4 нче һәм 5 нче битләрдә ике кәгазьдән торган, кушымта рәвешендәге рәсемнәр бирелгән. Китап бите зурлыгындагы беренче кушымтада Идел буенда (Бол-

---

очракларда да татарча текстларда фамилиясен үз кулы белән шул рәвештә язган. Бу китап турында язылган мәкаләләрдә һәм хезмәтләрдә әлеге үзенчәлеге искәртелмичә, Хәлфин дип кенә йөртелде. *Бәгъзе* – кайбер; *замим* – өстәмә; *тилмиз* – укучы; *сәһеләтчөн* – җиңеллек өчен; *лөгать* – сүзлек; *хоруфе һиҗа үзрә тәртиб әйләйүб* – алфавит буенча тезеп; *димәклә мәгъруф* – исеме белән танылган; *нәфгычөн* – файдалану өчен; *мәзкүр* – әйтелгән; *тәкърир әйләмешем* – аңлаттым; *фи бәлдәти* – шәһәрендә.

[54] Каримуллин А. У истоков татарской книги. Изд-е 2-е, испр. и пер. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1992. – С. 133.

[55] Шунда ук. – Б. 138.

[56] Кереш мәкаләнең 3–6 битләрдәге өлеше Габдрахман Сәгъдинең әдәбият тарихына багышланган хезмәтендә күчереп бастырылган *(Сәгъди Г. Татар әдәбияты тарихы: дәреслек-кулланма. – Казан: Татарстан дәүләт нәшрияты басмасы, 1926. – Б. 39)*.

гарда) сугылган гарәп язулы 12 төрле тәңкә сурәтләре басылган. Аларның кайберләрендәге тамга рәсемнәре турында китап керешендә искәртелгән һәм шулай ук Чыңгыз хан тарафыннан бикләргә тәгаенләнгән тамгалар турында язганда И.Хәлфин аерым тамга сурәтенә күрә «тәңкәләрдә дә күренә» рәвешендә искәрткән. Кушымтаның икенчесе китап форматыннан зуррак, 20х21 см күләмендә һәм ул бөкләп куела торган булган. Анда фарсы телендә кыска шигъри юллар язылган озынча шәкелдәге 4 савыт рәсеме, кәгазьнең аскы өлешендә язуларның татарчага тәрҗемәсе басылган. Ике кушымта битенең дә икенче яклары чиста (буш) калган.

Алардан соң китапның төп тексты һәм шмуцтитул белән башланган алфавит тәртибендәге татарча-русча сүзлек бирелгән. Сүзлек өлеше 35 нче биткә хәтле текст астөшермәсендә дә урын алган.

«Чыңгызнамә» китабының төп алты бүлектән торганлыгын язган идек. Хәлфин басмасында алар «кыйсем» сүзе белән аталып, алты бүлектән торса да, анда «Гайса угылы Амәт» дастанының тексты юк. Әмма текстның башындагы Чыңгыз хан шәҗәрәсе аерым бүлек итеп аталган. Шуңа күрә, Амәт дастаны кермичә калса да, китапта алты бүлек-кыйсем хасил булган.

Амәт турындагы дастанның бу китапка ни өчен керми калуының сәбәбе мәгълүм түгел. Югыйсә, аны И.Хәлфин басмага әзерләгәнлеге китапның русча керешеннән һәм башка дәлилләрдән аңлашыла. Кереш өлешендә текстта кемнәр турында сүз барганлыгы кыскача бәян ителеп, Чыңгыз хан, Аксак Тимер («Тимурлан»), Идегәй, Бирдебәк, Гайса исемнәре аталган («...повествуется... о некоторых ханах, Идигей беке, Бердибеке и Гайсе хане»). Кереш мәкаләдә әйтелгән Бирдебәк һәм Гайса исемнәре бары тик Амәт турындагы дастанда гына бар. Текстны Хәлфин берничә кулъязмадан чагыштырып әзерләгәнлеген исәпкә алганда, бөтенесендә дә Амәткә багышланган бүлек булмаганлыгы бик шикле. Шулай ук М.Госманов Көнчыгышны өйрәнү институтындагы (Ленинград шәһәре) «В344» шифрлы кулъязма И.Хәлфин басмасына нигез булгандыр дип белдергән күчермәдә дә Амәткә багышланган бүлек бар. М.Госманов Хәлфингә Амәт дастаны мәгълүм булган дип («...хотя И.Халфину, судя по его же словам в начале книги был известен его текст»), ул бүлекнең китапта булмавын 1822 елда нәшер ителгән хезмәтнең үзенчәлекләреннән берсе дип язган[57].

Китап керешендә әйтелгәннән тыш, Амәт турындагы дастан текстында гына булган дистәдән артык сүзнең (кушландырмак, рузгяр, түшәмәк, һәзар, сукта һ.б.) 1822 елгы басманың сүзлегендә булуы – ул бүлекнең И.Хәлфин тарафыннан хәзерләнгәнлеген ачык раслый. Димәк, Амәт турындагы бүлек И.Хәлфингә билгеле булу гына түгел, ә аның тарафыннан

[57] Усманов М. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв..., 1972. – С. 99.

бастырырга әзерләнгән булган. Күрәсең, китапның текстындагы ул өлеше цензура тарафыннан кыскартылган яисә башка сәбәпләрдән төшереп калдырылган. Ничек булса да, Амәт дастанының 1822 елгы китапка кертелмәвенең сәбәпчесе Ибраһим Хәлфин түгел.

1822 елда басылган китапның теле кулъязма текстларыннан бераз аермалы. Ягъни, И.Хәлфин «Чыңгызнамә»не XIX гасыр башындагы татар-төрки китап теленә якынайта төшкән. Төп текстны саклаган хәлдә, кайбер сүзләрне төрекчә гыйбарәләргә алмаштырган, урыны-урыны белән редакцияләгән (төзәткән, кыскарткан, өстәгән). Нәтиҗәдә, «Чыңгызнамә»нең сөйләм теленә якын, чагыштырмача гади тексты бу китапта азмы-күпме госманлы төрек китапларына охшап киткән.

Китапның тарихи вакыйгалар бүлегендә «Чыңгызнамә» кулъязмаларындагы 1089 (1678) елда төрле фетнәләр чыгып, мөселманнарны чукындыру турындагы мәгълүмат бу басмада булмавын исә бары тик цензура белән бәйләп аңлатырга мөмкин. Юкса, И.Хәлфин белән Х.Френ кулланган дип фаразланган күчермәнең 2002 елгы китаптагы факсимилесендә (252 биттә) текстның ул өлеше бар.

Кулъязма текстларда, гадәттә, парлы сүз дәрәҗәсендәге «кяфер урыс» яисә синоним рәвешле «кяфер» генә дип язылган урыннар И.Хәлфин китабында күбесенчә «урыс» дип үзгәртелгән. Анысы да, шиксез, цензура төзәтмәсе, XIX гасырда нәшер ителгән бүтән басмаларда да «кяфер» сүзе цензорлар тарафыннан мөмкин хәтле киметелгән-сызылган[58].

«Чыңгызнамә» күчермәләрендәге соңгырак өстәмә – Хәлфин басмасындагы ахыргы бүлектә 1708 елгы баш күтәрү турында язылган 90–91 битләрдәге бер нәрсәгә игътибар юнәлтик. Андагы текст кулъязмаларында «мөселман» дип язылган сүзләр И.Хәлфин китабында күпчелек очракта «татар» дип үзгәртелгән. Бу гыйбарә Хәлфин тарафыннан алмаштырылганмы, цензура үзгәрткәнме – билгеле түгел.

1822 елда басылган китапта Чыңгыз ханның «кош баш» дигән тамгасы озын томшыклы натураль кош башы сурәтендә бирелгән (55 биттә). Ә кулъязмаларның һәммәсендә әлеге тамга рәсеме символик ишарә рәвешендә генә ясалган. Аксак Тимергә багышланган дастан эчендә Гөбенә елгасы буена күчеп урнашкан Инсан бик турында язганда, «...тамгалары кошбаш» дип, нәкъ шундый ук – Чыңгыз ханныкы рәвешендәге сурәт бирелгән. Текстның

[58] Мәсәлән, Каюм Насыйриның 1881 елгы календарендагы «Казан бәете»нең төп чыганагында ун мәртәбә язылган «кяфер» сүзе «руслар, урыс, урыс халкы» кебек гыйбарәләр белән алмаштырылган *(Габделкаюм мулла Габденнасыйр угылы. Календарь: 1881 нче елга. – Казан: ун-т табыгханәсе, 1880. – Б. 36–37; «Гәүһәр Болгарга килдем...»: тарихи бәетләр / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап», 2013. – Б. 112).*

бу урынындагы тамга рәсеме кульязмаларда очрамый, шулай ук башка басмаларның берсендә дә юк һәм ул барысында да «куш кәшан» дип аталган. Кульязма текстларда исә, Хәлфин басмасынннан аермалы буларак, әлеге тамга исеме Зәйгә килеп урнашкан Ихсан бик нәселенә нисбәт итеп язылган. (Дастанның кульязма текстларында теркәлгән Инсан һәм Ихсанның дәвамчылары рәвешендәге шәҗәрә буыннары 1822 елгы басмада юк).

Китапта, тамга рәсемнәреннән тыш, Аксак Тимер дастаны тексты эчендә (70-71 битләр арасындагы аерым кәгазьдә) Истанбул шәһәренең түгәрәк рәвештәге лабиринтсыман схематик сурәте урнаштырылган.

Ибраһим Хәлфин әзерләгән һәм 1822 елда Казан университеты бастырган «Әхвале Чыңыз хан...» китабы Казан һәм башка калалардагы университетларда уку әсбабы буларак файдаланылган. Ә татарлар арасында популяр булу-булмавы турында тәгаен генә әйтергә читен. Ихтимал, халык кулында «Чыңгызнамә»нең кульязма текстлары да күп булуы сәбәпле, басма варианты әлләни таралмагандыр. Шулай да, Хәлфин басмасының кайбер бүлекләре XIX гасырның икенче яртысында күчерелгән мисаллар бар. Шәркыять галимнәренең берсе И.Хәлфин басмасыннан 1834 елда күчергән һәм русчага тәрҗемә ителгән кульязмасы турында алдарак язып үттек. 1864 елда Верный (хәзерге Казакъстандагы Алма-Ата) шәһәре мәдрәсәсендә күчерелгән бер нөсхәсенең тарихи вакыйгаларга багышланган соңгы бүлеге Н.Катанов тарафыннан 1906 елда бастырылган[59]. Катанов ул хакта берни әйтмәгән булса да, текстның беренче юлындагы ук «мөхәкъкак кауль илән сикез йөз» дигән, И.Хәлфин китабына гына хас өстәмәсе һәм, гомумән, текстның кайбер вак хаталарыннан тыш, тәңгәл килүе аның 1822 елгы китаптан күчерелгәнлеген белдерә[60]. Хәлфин басмасының кайбер бүлекләре күчерелгән 1870 елгы икенче бер кульязманың тексты

[59] Катанов Н.Ф., Покровский И.М. Отрывок из одной татарской летописи о Казани и казанском ханстве // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском Казанском университете. Т. XXI. Вып. 4. – Казань: типо-лит. имп. ун-та, 1906. – С. 315–317. Кайбер хезмәтләрдә әлеге җыентык 1905 елда басылган дип күрсәтелгән. Ләкин бу басманың тышлык һәм титул битләрендә елы 1905 диелсә дә, шунда ук «Вышел 17 февраля 1906 г.» дигән өстәмәсе бар. 1906 елда дөнья күргән бу текст 1937 елгы документлар җыентыгына искәрмәләр белән кертелгән *(История Татарии в документах и материалах. – М.: Соцэкгиз, 1937. – С. 95–96, 129).*

[60] Тарихчы Равил Фәхретдиновның фәнни хезмәтендә «Дәфтәри Чыңгызнамә»дәге тарихи мәгълүматлардан Болгар җимерелү, Иске һәм Яңа Казан шәһәрләре нигезләнү мәсьәләләре шактый киң һәм җентекләп тикшерелгән *(Фахрутдинов Р. Очерки по истории Волжской Булгарии. – М.: Наука, 1984. – С. 153–161).* Ләкин Болгарның җимерелүе турында 700 нче дигән елга карата И.Хәлфиннең «ышанычлырак хәбәр буенча 800 нче ел» дигән өстәмәсе төп чыганакның бер варианты дип ялгыш тәкъдим ителгән. Шулай ук Хәлфин китабыннан күчерелеп, Н.Катанов 1906 елда бастырган тексты да мөстәкыйль вариант буларак тасвирланган.



6

فی داستان نسل چنگیز

بسم الله الرحمن الرحیم

حضرت نوح پیغمبر علیه السلام نینک تورت اوغلی وتقی تورت قزی بار ایردی بری حام
بری سام بری کنعان تورتنچی یافث ایردی تقی اولوغ قزی نینک آطی رحب
ایردی ایکنچی سینینک آطی رحب ایردی اوچونچی سینینک آطی رحت
ایردی تورتنچی سینینک آطی رحت ایردی اما رحب اوزی نینک صلبی قزی
ایردی رحب رحت رحت اوچاکوسی نوح پیغمبر علیه السلام نینک
دعاسیله کوچوک دین ایشاک دین ماچی دین اولوب ایردیلار اما حام نینک
نسلی عرب خلقی دور سام نینک نسلی عجم خلقی دور کنعان طوفانده هلاک
اولدی نسلی کیسلدی یافث نینک نسلی روم خلقی دور یافث نی ابولجا خان
تیب ایتورلار ابولجا خان اوغلی یاقرخان آننک اوغلی اوجان خان آننک اوغلی
اوز خان آننک اوغلی کوک خان آننک اوغلی بوغاره خان آننک اوغلی قراخان
آننک اوغلی کونوم خان آننک اوغلی روجام خان آننک اوغلی سام سوجی آننک
اوغلی سالرسوجی آننک اوغلی سکاررون آننک اوغلی قجومرکان آننک اوغلی قجومان
آننک اوغلی قرادمان آننک اوغلی تورمتای چچان آننک اوغلی تومااول مرکان آننک

فی 30, ев, داستان повѣсть, исторія. شجره родословие. حضرت господинъ, господь. پیغمبر пророкъ. السلام почтение, поклонъ. اوغل сынъ. تقی еще. قز дочь. ایرماق، اولمق быть. اولوغ большой, старшiй. آط : اد имя. اما но, ибо. صلبی родной. طوفان потопъ. کوچوک щенокъ. ایشاک оселъ. ماچی кошка. خلق народъ. هلاک اولمق погибнуть. کیسلمک пресѣчься. ایتمک сказать, говорить.

Ибраһим Хәлфин кулъязмасы

кулыгыздагы шушы китапта нәшер ителә. Тикшереп карагач, аны күчергән кеше Хәлфин китабыннан тыш, «Чыңгызнамә»нең кулъязма нөсхәләре белән дә таныш булганлыгы ачыкланды.

Ибраһим Хәлфин кулъязмасында китапның тексты 1818 елда әзерләп тәгәлләнгән булган дигән идек. Галим кулъязмасының бер өлеше хәзерге вакытка кадәр университет китапханәсендә сакланган. Аның турында моннан ярты гасыр элек үк Альберт Фәтхи тасвирламасында тәфсилле мәгълүмат бирелгән. Университет китапханәсендә «216т» шифры белән саклана торган, фәнни яктан кыйммәтле кулъязма турында А.Фәтхи хезмәтендә болай язылган: «216т (э.№2667). Әхвәле Чингиз хан вә Аксак Тимер. Казан, 1818, И.Хәлфиннең үз кулы белән күчерелгән, 12 кәгазь, 18х22,5. Борынгы татар әдәбиятының хатирәсе, татар һәм башка төрки халыкларның тарихына багышланган «Дастаны Чингиз хан вә Аксак Тимер» әсәренең И.Хәлфин тарафыннан басмага әзерләгәндәге караламаларының кайбер кисәкләре»[61]. Тасвирламада бу әсәрнең басылып чыккан нөсхәсе турында да мәгълүмат бирелгән. И.Хәлфин кулъязмасындагы һәр битнең тасвиры А.Фәтхи тарафыннан аңлатып язылган. Анда тагын болай диелгән: «Каралама түбәндәге материалларны эченә ала: 1) 3 кәгазь – китапның башындагы татарча кереш сүз – «Мөкаддимә». Текст нигездә басма белән (3–8 бит) туры килә, ләкин редакцион үзгәлек бар. Караламада сүз башының тексты бүлекчәләргә бүленмәгән, димәк, И.Хәлфин моны басарга биргәндә яңадан эшләп чыккан: сызган, бозган, өстәгән, тулыландырган... Кереш сүзнең азагында «1818 сәнә» дип, әсәрнең тәмамлану елы күрсәтелгән»[62].

1822 елгы басманың 9–35 битләрендәге текст астөшермәләрендә татарча-русча сүзлекчә биреп барылган. «216т» кулъязмасының 4–11б кәгазьләре нәкъ шул сүзлекчәле өлешкә туры килә. Дөрес, тексттагы кайбер сүзләр басма китапта үзгәргән.

«216т» шифрлы кулъязма эченә зур форматлы (21,5х33,5 см) бер кәгазь өстәп тегелгән. Аның турында А.Фәтхи тасвирламасында «Буй уңаена язылган өлешендә Чыңгыз хан шәҗәрәсе килә (И.Хәлфин бастырган китапта 9–11 бит). Иң уңаена язылган 10 юллы «Табәкаи Чингиз хан» исемле текстта Чингиз нәселе шәҗәрәсе, биләгән җирләренең чикләре һәм кайбер вакыйгаларның хронологиясе бирелә. Бу кәгазьнең икенче ягының (б кәгазь) сулъяк яртысында басмада «Кыйссаи Чингиз хан» дип алынган бүлекнең башы килә. 25 юллы бу текст басмадагыдан (12–15 бит) бераз

---

[61] Кулъязмалар тасвирламасы. XII чыгарылыш..., 1968. – Б. 27.
[62] Шунда ук. – Б. 28.

аерыла, бу кульязмадагы өзек борынгырак бер нөсхәнең күчермәсе булырга тиеш»[63].

Миркасыйм Госманов хезмәтендә Ленинградтагы «В344» шифрлы кульязманың И.Хәлфин һәм Х.М.Френ кулланган булу ихтималы белдерелсә дә[64], 1968 елда чыккан тасвирлама китабындагы кызыклы мәгълүмат һәм, бигрәк тә, «216т» шифрлы кульязма турында бер сүз дә әйтелмәгән. Хәлфиннең әлеге автографик кульязма парчаларына башка галимнәрнең дә әһәмият биргәнлеге безгә мәгълүм түгел[65].

Университет китапханәсендәге «216т» шифрлы кульязма истәлектәге каралама битләрнең берсендә – А.Фәтхи әйтеп үткән зур форматлы кәгазьдә – Чыңгыз ханның шәҗәрәсе һәм биләгән җирләре турындагы текст өлешенә аерым тукталыйк. Язмалардан күренгәнчә, И.Хәлфин басманы әзерләү дәвамында «Чыңгызнамә» текстына Чыңгыз хан турында ышанычлы чыганаклардагы мәгълүматны өстәү ниятендә дә булган икән. «Чыңгызнамә»нең башындагы шәҗәрә текстында Чыңгыз исеме язылган урынына нәкъ шул тарихи мәгълүматны өстәү өчен сызылган ишарәсе бар. Ахыр чиктә, ул мәгълүмат басма китапка кермәгән. И.Хәлфиннең автографик кульязмасында 3а һәм 13б кәгазьләрдә калган ул текст өлеше түбәндәгечә.

«Табәкаи Чыңыз ханиан ибтидасы улдур ки, биш йөз илле сәнәдә Чыңыз вөҗүдә килде, адыны Тимүҗин[66] ку[й]дылар. Унөч йәшенә вардукда атасы вафат улуб, кемсәйә илтифат итмәйен, сигез йыл пөр шаһи хәл улды. Хакъ Тәгалә дәүләт вирүб, тарихның биш йөз туксан тукызында тәхетенә кичүб, Хытай вә Хотанны мөсәххәр әйләде, йегерме биш йыл падишаһ улды вә гаракына варуб, тәмам мәмалике забыт әйләйүб, мөгаззам падишаһ улды. Адыны Чыңыз хан ку[й]дылар кем – олуг падишаһларның падишаһы димәкдүр. Тарихның алты йөз унтүрте сәнәседә Бохарайа вармышдур вә Бохара ләшкәре йөз бең әр ирмешләр иркән, мөнһәзим улганлардур. Андин Сәмәркандә варды, солтан Харәзем ләшкәрилә Сәмаир хан вә Улагъ хан билә иркәнләр, мөнһәзим улмышлардур. Тарихның алты йөз йегер[ме] түрте вә маһы рамазан шәрифдә вә йәше йитмеш өчдә вафаты улмышдур. Вә ушал каульдә Чыңызның угланлары: Күлкән хан, Чыгытай хан, Алагәй

[63] Шунда ук. – Б. 28. Әлеге өзек борынгырак диелсә дә, ул бу җыентыкта сүз барачак I вариант текстына туры килми.

[64] Усманов М. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв..., 1972. – С. 98, 99, 103.

[65] Мәгълүмат тулылыгы өчен искәртик, әлеге кульязманың 4а кәгазенең фоторәсемен «Татар китабы» альбомында бастырган идек *(Татар китабы = Татарская книга: альбом / төз. Мәрданов Р., Һадиев И. – Казан: Татар. китап нәшр., 2013. – Б. 107).*

[66] Кульязмада «Нимучин» дип ялгыш язылган.

хан, Көйүк хан, Тули (вә йә Тулаби) хан, Җуҗи (вә йә Йүчи) хан дәйү бәйан улынурлар[67].

Вә Җуҗи хандин йиде угыл калды, мәшһүрракы Бату хан атасы йиренә ултыруб, кыбчак, алан вә ас, вә Русь вә Болгарны дотды. Сарай шәһәренә тәхтә кичде румийә илә 1237 сәнәдә ки, рус гаскәрен Коломнада тар-мар идүб, Рүзән вә Мәскау, Суздаль, Владимир, Растув, Йараслув, Тверь вә гайре кальгаләре хәраб әйләйүб. Әмма рус җәмәгатьләре икенче кәррәт гаскәр җыйуб хәреб улдукда ... рус ханы Йүрикне бәгъзе кенәзләр илә дотуб кател әйләмеш. Вә унбиш сәнә ханлык идүб, соңра ... ...щдур»[68].

Монда язылганнар, безнең фикеребезчә, милли тарихыбыз фәненең үсешен өйрәнү өчен бер факт буларак та исәпкә алынырга лаек иде. Чөнки болар Казан университетында эшләгән татар галименең үз кулъязмасында сакланган ядкәр парчалары.

***

Сүз уңаеннан шул ук «216т» шифрлы кулъязмада Ибраһим Хәлфиннең икенче бер тарихи хезмәтенең кереш өлешен тәшкил иткән кәгазьләр сакланып калган булуы да татар тарихы фәне өчен бик мөһим дип саныйбыз. Танылган галимнең бер үк шифр белән саклана торган кулъязмасы турында сүз барганга һәм фәнни яктан әһәмиятен исәпкә алып, аңа да тукталып үтәбез.

Фән әһелләренең игътибарыннан читтә калып килгән әлеге кулъязма турында А.Фәтхинең әйтелгән тасвирламасында түбәндәгечә мәгълүмат бирелгән: «216 т (э.№2667). Төхфәт-эл-җәдидә фи тәварихы кадими Казан. Казан, 1827. Автограф. Нәсех. 2 кәгазь, 17x22. Өч битле (1б–2б кәгазь) бу кулъязма И.Хәлфиннең Казан тарихына багышланган «Төхфәт-эл-җәдидә фи тәварихы кадими Казан» (татарча әйткәндә «Борынгы Казан тарихыннан

---

[67] Кулъязмада Күлкән хан исеменнән соң «Күк хан, Сәвенеч хан, Кишлек хан» исемнәре дә язылган. Ләкин алар текстка ниндидер ялгышлык белән кергән, чөнки ул шәхесләр, чынлыкта, Бохараны Чыңгыз хан явыннан саклаучыларның җитәкчеләре булган. Текстта һиҗри буенча язылган даталардан 550 ел – милади 1155 елга, 599 ел – 1202 елга, 614 ел – 1218 елга, 624 елның рамазан ае – 1227 елның август-сентябрь айларына туры килә.

[68] Кулъязма чите ертылган булуы сәбәпле текст ахырындагы берничә сүз танылмый. *Табәка* – асылзат нәсел, династия; *ибтида* – башлангыч; *вөҗүд* – туу; *вардукта* – җиткәндә; *кемсәйә* – һичкемгә; *пөр шаһи хәл* – камил ханлык; *вирүб* – биреп; *мөсәххәр әйләде* – яулап алды; *гаракына варуб* – киңәеп, көчәеп; *мәмалике забыт әйләйүб* – мәмләкәтләрне басып алып; *мөгаззам* – бөек; *адыны* – исемен; *ләшкәр* – гаскәр; *бең* – мең; *әр* – ир, сугышчы; *ирмешләр иркән* – булганнар икән; *мөнһәзим улган* – тар-мар ителгән; *билә* – бергә; *ушал* – шул; *кауль* – сүз, хәбәр; *дәйү* – дип; *кәррәт* – мәртәбә; *бәгъзе* – кайбер; *дотуб* – тотып; *кател әйләмеш* – үтергән.

яңа истәлек») исемле әсәренең кереш сүзеннән гыйбарәт. Бу әсәр үзе сакланмаган, гыйльми әдәбиятта да аның турында мәгълүмат юк. Әсәргә кереш сүзләрнең гадәттә әсәр эшләнеп беткәч, җәмәгатьчелеккә, басмага тәкъдим ителер алдыннан язылуын исәпкә алганда, бу әсәр тәмамланган булган дип уйларга кирәк. Кереш сүзнең каралама түгел, ә акка күчерелгән нөсхә булуы да шуны ук күрсәтеп тора. Кереш сүздә И.Хәлфин әсәрне язуның сәбәпләре, эчтәлеге, Казан тарихы буенча чыганаклар хакында фикер йөртә. Әсәрне язуының сәбәпләрен әйтә. И.Хәлфиннең бу китабының үз дәверендә басылмавы һәм фәндә билгесез калуы цензура белән бәйле булырга тиеш, чөнки нәкъ менә шул дәвердә цензура җирле тарихка карата каты тыйгын сала. И.Хәлфиннең монда тасвирланган кулъязмалары 1920 елларның азагында Татар китап палатасы тарафыннан сатып алынган»[69].

«Төхфәтел-җәдидә...» хезмәтенең авторы Ибраһим Хәлфин керешен «бисмиллаһ...» белән башлап, Аллаһы Тәгаләгә һәм рәсүленә мактаулардан соң түбәндәгечә язган. «...Сәбәбе тәэлиф бу габде би-бизагать Ибраһим бине Исхак Хәлфийүн мәмләкәтемезә хезмәт вә мөэмин карендәшләредән хәер-фатиха илә йад улынмакымы таләб вә җәлеб идүб, Казан шәһәренең кадими бөнйады илә әхваль вә хәвадисәтләрене, вә ханларыны вә анларның солтанәтләрене, вә рус хәлайыкы илә ничәмә кәррә газа вә хәребләрене, вә соңрада хикмәте Йәздани вә газабе Илаһи илә «төэтиәл-мөлкә мән тәшаэү» айәте шәриф фәхвасенчә, дийаре Казанга рус хәлайыкының зафәрләре, нитәк хәраб вә бәгъдә нитәк забыт әйләмәкләрене һәрчәнд бәгъзесе бу замана дик бәйнән-нас сәмәган зикер улынуб калынурса да, ләкин безем ул заманлардагы мөселман җәмәгатьләре әүвәлән – әмир Тимүрнең дийаре Болгар вә әтрафларыны вәйран кыйлмакы, икенче – Дәште Кыбчак вә Урду ханлары бер-бере ара җәң идешүләре, өченче – соңрада рус хәлайыкы куәтләнүб, анлар илә чук җәң вә җидаль, вә әтрафе Казан, вә гайре мәкәнләрдә дәхи чук-чук мөһликәтлекләр сәбәбле, тәварихлар китабәт итмәйә имкән улынмадыкданмы йәки китабәт кыйлмыш исәләр дә, ул замандагы дошман хәлайыклары әлләренә дөшүб, тәләф улынмакларынданмы – бонлар хосусларында безләрә һәрничүк бер тәварих вә төхфә йазуб калдурдуклары бу анә дик һичкайда вә һичбер йирдә мәсмуг вә мөшаһәдә улынмадукларындан отру, бәгъзе әһле ислам тәварихы гөзидәләрендән әхәз вә иҗмалән бәдд идүб вә ахырында ки шәһри Казан хосусында игътибарлу рус тәварихларына зарури мөрәҗәгать вә анлардан имкянем кадәр тәрҗемә вә бонда тәртибләренчә бәрабәр җәмегъ әйләмәкемлә, бу китабы «Төхфәтел-җәдид фи тәварихы кадими Казан» дәйү тәсмийә әйләмешем. Илтимас

[69] Кулъязмалар тасвирламасы. XII чыгарылыш..., 1968. – Б. 29.

идәрем ки, тапуларыңызда бу кечекчә хезмәтем хөсне зан иделүб, сәһүләре гафу улына ирде?

Фи сәнәи һижри 1243 вә фи сәнәи милад 1827 бу китаба шөруг улынды вә билләһи тәүфыйк»[70].

Хәлфиннең бу хезмәте басылмыйча калуның сәбәбе, А.Фәтхи фикеренчә, цензура тыюдан булуы никадәр чынбарлыкка туры килгәндер – әйтергә читен. Һәрхәлдә, университет каршында 1812 елда оештырылган цензура комитеты 1827 елда ябылган һәм көнчыгыш телләрендә чыгачак китапларга аерым цензор итеп профессор А.Казимбәк билгеләнгән. Галим Әбрар Кәримуллин язуынча, 1829 елдан соң университет үзе чыгарган китаплар бернинди цензурасыз басылган[71]. Хәлфин хезмәтенең басылмавы аның 1829 елның гыйнварында вафат булуы белән бәйледер. Чөнки, «үзе юкның сүзе юк» дигән кебек, аның вафатыннан соң кайгыртып йөреп, бастырып чыгару хәстәрен күрерлек мөмкинлек булмаган, чөнки И.Хәлфин үлгәннән соң аның улы Шаһиәхмәтне университет типографиясенә хәреф җыючы итеп тә алмаганнар. Гәрчә ул гимназиядә укыганда ук әтисенә типография басмалары корректураларын укыганда булышып, тәҗрибә туплаган. Аны эшкә алмыйча, хәрби хезмәткә керергә тәкъдим иткәннәр[72].

Ибраһим Хәлфиннең «Төхфәтел-җәдидә...» китабы басылмаган һәм кульязмасы тулаем сакланмаган булуга карамастан, аның датасы күрсәтелгән үз мәгълүматына нигезләнеп, факт буларак тәкъдир ителергә тиеш. Һәрхәлдә, ул – татар халкының тарихын фәнни нигездә өйрәнүгә

---

[70] Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе сирәк һәм кульязма китаплар бүлеге, «216т» шифрлы кульязма, 1а–2а кәгазьләр. *Сәбәбе тәэлиф* – язуның сәбәбе; *габде би-бизагать* – фәкыйрь кол; *бөнйад* – нигезләнү; *хәвадисәт* – вакыйгалар; *кәррә* – мәртәбә; *хәреб* – сугыш; *хикмәте Йәздани вә газабе Илаһи* – Тәңре хикмәте һәм Аллаһ газабы; *«төэтиәл-мөлкә мән тәшаэү»* – патшалыкны кемгә теләсәң, шуңа бирәсең *(Коръәннең «Әлү Гыймран» сүрәсендәге 26 аятьтән)*; *фәхвасенчә* – мәгънәсенчә; *дийар* – йорт, ил; *зафәр* – җиңү; *нитәк* – ничек; *һәрчәнд* – никадәр; *дик* – хәтле; *бәйнән-нас* – халык арасында; *сәмәган зикер улынуб калынурса* – ишетелеп сөйләнеп калса; *әүвәлән* – башта; *җәң* – сугыш; *җидаль* – җәнҗал; *гайре мәкян* – башка урын; *дәхи* – тагын; *чук-чук* – бик күп; *мөһликәт* – һәлакәтләр; *китабәт итмәйә* – язарга; *имкян* – мөмкинлек; *әл* – кул; *тәләф улынмак* – юкка чыгу; *бонлар* – болар; *төхфә* – әсәр; *ан* – вакыт; *мәсмуг вә мөшаһәдә* – ишетелгән һәм күрелгән; *отру* – күрә; *тәварихы гөзидә* – сайланма тарихлар; *әхәз вә иҗмалән бәдд идүб* – алып һәм кыскача аерып; *җәмегъ әйләмәкемлә* – туплап; *тәсмийә әйләмешем* – исем куйдым; *илтимас идәрем* – үтенәм; *тапуларыңызда* – сезгә хезмәт итүдә; *хөсне зан* – яхшы уй; *сәһү* – хата; *шөруг улынды* – башланды; *билләһи тәүфыйк* – Аллаһ ярдәм итсен.

[71] Кәримуллин Ә. Китап дөньясына сәяхәт: татар басма сүзенең сәхифәләреннән. – Казан: Татар. китап нәшр., 1979. – Б. 44.

[72] Каримуллин А. У истоков татарской книги..., 1992. – С. 128.

гыйльми оешмада хезмәт иткән татар галимнәреннән Ибраһим Хәлфин XIX гасыр башында керешкән дигән нәтиҗә ясарга ышанычлы дәлил.

1882 елгы басма

«Чыңгызнамә» китабының тулы тексты Казан шәһәрендә Кукубин (Коковин) матбагасында Казан өязе Мөндеш авылының Рәхимҗан Җиһаншаһ улы акчасына нәшер ителгән. Аның исеме титулында «Һәза китабе фасли дастани нәсли Чынңыз хан вә һәм Аксак Тимер нәселендән бәйан идәр: тарих йиде йөз йылында» дип бирелгән[73].

Уртача форматтагы, күләме 45 биттән торган бу басмада китапның бөтен бүлекләре дә бар. Китапка кереш сүз һәм аңлатма кебек бернәрсә дә язылмаган. Ул иске кулъязма нөсхәдән күчереп басылганга күрә, хаталары (аеруча, архаик сүзләрдә) шактый күп.

М.Госманов бу басманы «Дәфтәри Чыңгызнамә»нең тулы текстын тәшкил итүен күздә тотып һәм аны нәшер итүче карамагында шактый борынгы һәм сыйфатлы күчермәсе булган дип, югары бәяләгән. Аны «Җиһаншин басмасы» дип атап, тәнкыйди текст өчен нигез итеп алырга мөмкин дигән[74].

2000 елгы басма

Казан шәһәрендәге «Иман» нәшриятында 2000 елда дөнья күргән «Дәфтәре Чыңгыз-намә» исемле китап 44 бит күләмендә. Аны галим Сәлим Гыйләҗетдинов басмага әзерләп, сүзлек һәм аңлатмалар язган. «Сүз башы»нда «Чыңгызнамә» әсәре «хәзерге татар теленә якынлаштырылып һәм гамәлдәге алфавит белән аерым китап итеп киң катлау укучыларына беренче тапкыр тәкъдим ителә. Ул 1882 елда Рәхимҗан Җиһаншин ярдәме белән чыккан китап буенча әзерләнде... Бер генә чыганактан файдаланылганга күрә, анда кайбер кимчелекләр дә юк түгелдер» дип белдерелгән[75].

Хаталары булуга карамастан, гамәлдәге татар язуында һәм хәзерге укучыларга аңлаешлырак тулы тексты беренче тапкыр аерым китап

---

[73] Китап исемендәге «Чынңыз» исеме «Чынгиз» дип тә укылырга мөмкин. Элекке Казан өязенә кергән Мөндеш исемле авыллар хәзерге Арча һәм Әтнә районнарында бар. «Татар энциклопедиясе»нең 2 нче томында (239 биттә): «Дәфтәре Чыңгызнамә»нең иң тулы басмасын 1882 дә Ф.Җиһаншин нәшер итә» дип, Рәхимҗан исеме ялгыш «Ф» инициалы белән басылган.

[74] Усманов М. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв..., 1972. – С. 99.

[75] Дәфтәре Чыңгыз-намә / басмага хәзерләүче С.Гыйләҗетдинов. – Казан: «Иман» нәшр., 2000. – Б. 4.

хәлендә басылуы ягыннан бу хезмәт азмы-күпме үз бурычын үтәде дияргә мөмкин[76].

2002 елгы басма

Мажар галимәсе Мария Иванич белән тарихчы галим Миркасыйм Госманов тарафыннан хәзерләнеп, Венгриянең Сегед шәһәрендә Урал-Алтай фәнни берләшмәсенең 44 нче китабы буларак, алман һәм татар телләрендә 2002 елда нәшер ителгән китапның гомуми күләме 328 битне тәшкил итә[77]. Беренче том буларак билгеләнгән бу китапның 1–7 нче битләрендә М.Госмановның кереш мәкаләсе, 9–25 нче битләрдә әсәрнең үзе турында мәгълүмат бирелгән, бу китапта басыла торган текстка нигез итеп алынган Россия Фәннәр академиясенең Санкт-Петербург шәһәрендәге Көнчыгыш кулъязмалары институтында (ККИ) саклана торган өч кулъязма һәм 1882 елда Казанда Рәхимҗан Җиһанша улы нәшер иткән басма турында кыскача тасвир язылган. Шунда ук текст транскрипциясе һәм басманың техник үзенчәлекләре турында аңлатма бирелгән. Китапның 25–28 нче битләрендә бу темага караган әдәбият исемлеге урын алган. 30 нчы битендә гарәп хәрефләре һәм латинча транскрипция алфавиты басылган. 31–93 нче битләрдә «Дәфтәри Чыңгызнамә»нең латин хәрефләрендәге транскрипция тексты, күпсанлы астөшермәләрендә төп чыганак итеп кулланылган кулъязмалар һәм басма китаплардагы аермалы урыннары һәм бүтән искәрмә-аңлатмалар бирелгән. Китапның 97–203 нче битләрендә тексттагы сүзләрнең алманча мәгънәләрен белдергән сүзлек урын алган. 207–324 нче битләрдә бу басма өчен кулланылган өч кулъязманың факсимиле-фотокүчермәләре басылган. Шулардан 207–252 нче битләрдә «О» дип тамгаланган кулъязма (ККИ – «В344» шифрлы), 253–288 нче битләрдә «В» хәрефе белән билгеләнгәне (ККИ – «В2640») һәм 289–324 нче битләрдә «С» хәрефе белән тәгаенләнгән кулъязма (ККИ – «В2587»). Китапның ахыргы битләрендә Урал-Алтай фәнни берләшмәсе нәшер иткән 43 басманың исемлеге тәкъдим ителгән.

Венгриядә нәшер ителгән әлеге китапка филология фәннәре докторы Фәһимә Хисамованың рецензиясе басылды[78]. Галимә «Дәфтәри Чың-

[76] С.Гыйләҗетдинов 2011 елда «Чыңгызнамә» текстын яңадан әзерләп бастырганда шушы (2000 елгы) китапны искә алып, бер генә чыганакка нигезләнеп эшләнүе сәбәпле «шактый ялгышлар киткән» дип язды *(Мирастан биш сәхифә..., 2011. – Б. 39)*.
[77] Ivanics Mária, Usmanov Mirkasym A. Das Buch der Dschingis-Legende (Däftär-i Čingiz-nāmä). I. (Vorwort, Einführung, Transkription, Wörterbuch, Faksimiles). – Szeged, 2002. – S. 328.
[78] Хисамова Ф. Әдәби телебезнең кыйммәтле ядкяре // Казан утлары. – 2003. – №8. – Б. 180–183.

гызнамә»не «әдәби-тарихи чыганак буларак та, тел җәһәтеннән дә гаять кызыклы һәм кыйммәтле язма ядкяр» дип бәяли һәм «тарихи чыганак һәм үзенчәлекле ярым фольклор, ярым әдәби әсәр» дип атый[79]. Рецензия мәкаләсе «...бу зур хезмәтнең бер өлеше, дөресрәге, беренче томы гына әле. Икенче том исә «Дәфтәр...» текстының алманчага тулы тәрҗемәсеннән, әсәрдә теркәлгән фактларның, фикерләрнең тәфсилле аңлатмаларыннан торырга тиеш булса кирәк» дигән юллар белән тәмамланган. (Китапның икенче томы басылып чыкканмы-юкмы – безгә билгесез).

Венгриядә чыккан әлеге җитди хезмәт Казандагы төп гыйльми китапханәләрдә, шул исәптән Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә бар. Кызганычка каршы, китапның алман телендә булуы белән бергә, транскрипция тексты да бездәге фән әһелләре файдалану өчен катлаулы. Безнең телдә язылган татар язма истәлеге (тәҗрибәле тел галиме билгеләгәнчә, «фәнни таләпләргә тулысынча җавап бирердәй төгәл хезмәт»[80]) тулы хәлендә Казанда басылган булса, әлбәттә, халкыбызга зур хөрмәт үрнәгеннән хисапланыр иде.

Сегед басмасында «Дәфтәри Чыңгызнамә» текстының транскрипциясе, тюркология фәнендә кабул ителгәнчә бирелгән һәм аның төгәл фәнни хезмәт булуын шиккә алмыйбыз. Ләкин текстның андагыча бирелеше безнең галимнәр өчен читенлек тудырган нәрсәләрне искәртмичә булмый. Әйтик, латин алфавитына нигезләнгән шактый үзенчәлекле хәрефләр белән бирелгән транскрипция тексты, гарәп язулы кульязма текстындагыча, бернинди дә тыныш билгеләре (яисә аларга охшаш шартлы ишарә тамга) белән күрсәтелмәве шактый уңайсыз. Дөрес, бу басмага нигез итеп алынган «О» нөсхә кульязманың һәр битендәге юл башын белдерә торган саннар куелган. Ләкин ул мәсьәләне хәл итми. Теле чагыштырмача җиңел дип каралса да, «Чыңгызнамә» текстындагы шактый архаиклашкан сүзләрне җөмлә итеп оештырып, мәгънәсенә төшенү авыр. Шулай ук XVII гасыр ахырына нисбәтле татар телендәге әдәби-тарихи ядкәрнең теле транскрипциядә берничә гасырга борынгырак әсәрләр рәвешендә, гомумтөрки телгә охшатылган. Ягъни, үз чорының хакыйкый татар теленнән ераклашкан. Гади генә татар сүзләреннән «ил»не *эл* дип, «китте» сүзен *кетти*, «булур, булсун» сүзләрен *болур, болсун* рәвешендә, «илле, ис, ирде, ирмеш, ишетеб, киң, күз, күрде» сүзләрен *элли, әс, эрди, әрмеш, эшитиб, кенг, гөз, көрде* дип, шулай ук «бик»не *бег* һәм «Тимер»не *Темир* кыяфәтендәге язылышлар мисал өчен җитсә кирәк. Галимнәр «Әлеге әсәр XVII йөз ахырында нәкъ татарлар яшәгән төбәкләрнең берсендә (Зәй елгасы буйларында) халыкның

[79] Шунда ук. – Б. 180–181.
[80] Шунда ук. – Б. 181.

сөйләм теленә бик якын» дип билгеләгән татар теле шундый рәвештә булганына ышанырлык түгел. Чит илдә басылган хезмәтнең менә мондый хикмәтләре китап текстын өйрәнергә теләгән галимнәр өчен өстәмә кыенлык икәнлеген танымыйча булмый.

Бу басмада төрле характердагы текстологик җитешсезлекләр һәм бәхәсле урыннарның булуын да әйтергә кирәк. Кайберләрен генә искәртеп китәбез. Мәсәлән, хезмәтнең 55 нче битендә (Чыңгыз хан дастанында) иң астагы юлда «...йәнә йәшүрүб калмасун» гыйбарәсендәге «йәшүрүб» сүзе хаталы басылган. Әлеге сүз шул ук китапта бирелгән өч факсимиледә дә (228, 267, 304 битләрдә) һәм 1882 елгы басмада (19 биттә) «йәшерүн» рәвешендә.

Китапның Аксак Тимер дастаны текстында, 67 биттәге «...ол кәлгән элчи-нинг башын кесүб олтүрдиләр» дигән җөмләдә «кесүб» (кисүб) сүзе Венгрия басмасы өчен төп нигез булган «О» нөсхә кулъязмасының бит читендәге өстәмә буенча куелган. Әмма ул сүз «В», «С» кулъязмаларында һәм 1882 елгы басмада юк. Шулай ук, бүтән күчермәләрдә дә, шул исәптән, безнең шушы җыентыктагы текстларда да юк. Күрәсең, «О» нөсхәсендәге «кисүб» сүзе кәгазь читенә Х.М.Френ тарафыннан өстәлгән булгандыр. Аксак Тимер дастанында «баш кисү» гыйбарәсе тагын булса да, әйтелгән урында (67 биттә) ул сүз артык. Фикеребезчә, әлеге «илченең башын үлтүрделәр» дигәндә текстта язылган 300 кешелек «илчелек» миссиясен үтәүчеләрнең баш кешесе (башлыгы) күздә тотылган. Һәрхәлдә, контексттан шулай аңлашыла. Ягъни, «Аксак Тимернең чирүе ул килгән илченең башын үлтерделәр, үзгәләрен – барчасын үзләренә юлдаш кылдылар».

Тагын бер мисал шул ук дастанда, 69 биттә «Аксак Темир... чәрүвегә чапул йибәрде» дигәндә «чапул» дип язылган сүз «В» нөсхә кулъязмасының факсимилесендә «чабулу» дип язылган, ә 1882 елгы басмада «йул» дип басылган. Ләкин текст астөшермәсендә бу сүзнең бүтәнчә бирелешләре искәртелмгән. Китапның татарча-алманча сүзлегендә (139 биттә): «чапул – Bote» (ягъни, «йомышчы, курьер» дип, дөрес мәгънәле рәвешендә тәрҗемәсе урын алган. «В» нөсхәсен күчергән кеше «чабулу» (чабулы – чапкын) мәгънәсен аңласа да, архаиклашкан сүзнең язылышына төшенеп бетмәгән булса кирәк. Әлеге сүз гарәп хәрефләре белән «чапул» сурәтендә, биш хәреф белән язылган, Хәлфин басмасында һәм борынгы төрки тел сүзлекләрендә дә ул шулай бирелгән. (Хәрәкәләр белән язылган булса, әлбәттә, дөрес укылган булыр иде). Хакыйкатьтә, ул «чапул» дип түгел, ә «чапавыл» дип укылырга һәм транскрипциясендә дә шулай язылырга

тиеш иде. «Чапкын, курьер» мәгънәсенә ия булган «чапавыл» сүзе борынгы төрки телдәге «каравыл» «йасавыл» һәм «бокавыл» кебек сүзләргә охшаш.

Аксак Тимер дастанындагы тагын бер сүзнең Венгрия басмасында бирелешенә игътибар итик. Китапның 76 нчы битендә «бир улу бег-нинг акыллы һулклу тул калган һатуны бар эрди» дигән җөмләдә «һулклу» (холыклы) дигән сүз шулай ук «О» нөсхә кулъязманың бит читендәге өстәмәсеннән (243 бит) алынган. Ә «В» һәм «С» нөсхәләрендә (278 һәм 317 битләрдә) әлеге сүз «услык» (гакыллык-услык) дип язылган, транскрипциянең астөшермәсендә «усул[л]ык» дип күрсәтелгән. 1882 елгы басмада андый сүз бөтенләй юк. Транскрипциядә тыныш билгеләре булмаганлыктан, анда тәкъдим ителгән «акыллы холыклы» сүзләре арасында өтер яисә сызыкча билгесе булырга мөмкин дип фаразларга була. Ә андый билгеләр булмаганда холык сүзен акыллы дип сыйфатлау телебезгә хас түгел, шулай ук парлы сүз итеп әйтү дә хас булмаган. Татар язма һәм сөйләм теленә «холыксыз» сүзе хас булса да, аның капма-каршысы «яхшы (күркәм) холыклы» рәвешендәге кулланылышы билгеле. Димәк, әйтелгән транскрипция текстында «акыллы холыклы» сүзләре арасында өтер куелу ихтимал дип исәпләгәндә дә, «холыклы» сүзенең мәгънәсен тулырак ача торган «яхшы» сүзе булыр иде. Ә «В» һәм «С» нөсхәләрендә «услык» дип язылган сүз башка кулъязмаларда да (шул исәптән, безнең җыентыктагы текстларда) «услык», «услыг» (ягъни, услы – зирәк, зиһенле). Шул ук дастанның бүтән урыннарында да әлеге сүз «исе-осы» рәвешендә теркәлгән.

«Дәфтәри Чыңгызнамә»нең Сегед басмасындагы транскрипциясендә боларга охшаш җитешсез урыннар тагын да бар. Китерелгән мисаллар вак текстологик мәсьәләләр кебек тоелса да, аларны күрсәтүебез, беренчедән, «төгәл фәнни хезмәт» дип бәяләнгән китапка киләчәктә мөрәҗәгать итүчеләр аның абсолют төгәл үк түгеллеген истә тотсыннар өчен. Икенчедән, безнең бу җыентыкның «Татар археографиясе» дигән сериядә нәшер ителүе археография һәм текстологиягә турыдан-туры караган мәсьәләләргә аеруча игътибарлы булуны таләп итә.

2011 елгы басма

Сәлим Гыйләҗетдинов тарафыннан әзерләп бастырылган күләмле китаптагы XVII–XVIII гасырларның әдәби-тарихи ядкәрләре арасында «Дәфтәре Чыңгыз намә»нең дә тексты хәзерге татар әдәби теленә күчермәдә һәм «текстның транскрипциясе» рәвешендә дөньяга чыкты[81].

Мондый китапның басылуы һәм текстларның аңлатмалар, сүзлекләр

[81] Мирастан биш сәхифә: XVII–XIX гасырлар әдәби-тарихи ядкярләре / төз. С.Гыйләҗетдинов. – Казан: Татар. китап нәшр., 2011. – Б. 37–96.

белән тулыландырылып киң катлау укучыларга тәкъдим ителүе, һичшиксез, борынгы мирасыбызны танытуда зур һәм файдалы адым булды. Анда басылган һәр әсәр турында кыскача кереш сүзләр дә язылган. «Дәфтәре Чыңгыз намә»гә карата керештә С.Гыйләҗетдинов 2000 елда үзе әзерләп чыгарган китапны да искәртеп, «...текстның тулы транскрипциясе дә бирелде, ә хәзерге татар әдәби теленә күчермәсе Хәлфин басмасы белән чагыштырып яңадан эшләнде» дип язган.

«Мирастан биш сәхифә» китабының һәм анда «Чыңгызнамә»нең нәшер ителүен хуплаган хәлдә, кайбер җитешсезлекләрен дә искәртмичә булмый. Бу китапта текстның «транскрипциясе» дигән гыйбарә төгәл түгел. Мондый очракта «транслитерация» сүзен куллану тиешле. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә бу ике терминның төгәл аңлатмалары бар[82]. (Сүз уңаеннан әйтик, «Чыңгызнамә»нең 2002 елгы басмасындагы текстка карата транскрипция термины дөрес кулланылган).

1822 елгы басмада борынгы тәңкә рәсемнәре һәм алардагы тамгалар турында И.Хәлфин искәрмәләр биргәнлеген язып үткән идек. Хәлфиннең андый искәрмәләре 2011 елгы китап текстына дә кушылган. Әмма төгәл күрсәтелмәгәч, алар әсәрнең төп текстына (башка кулъязмаларга да) хас кебек аңлашыла. Юкса, «Чыңгызнамә» кулъязмаларының берсендә дә ыру тамгаларының тәңкәләрдәге тамга-билгеләргә охшашлыгы турында язылмаган. Ягъни, тәңкәләр турындагы мәгълүмат бары тик Хәлфин китабыннан килә. Төп чыганаклар белән эш итмәүче кайбер фән әһелләре мондый очракларда мәсьәләнең асылына төшенмичә, ялгышулары бик мөмкин.

Хәлфин китабындагы (53 биттә) Чыңгыз хан Боркыт бигә, «тамгаң һәмзә улсун, сыйфаты ошбудыр» дип, гарәп әлифбасындагы «һәмзә» хәрефе рәвешендә ясалган тамганың сурәте С.Гыйләҗетдинов әзерләгән текст эчендә (53, 79 битләрдә) нәкъ шундый ук булса да, ул 1882 елгы басма китаптагыча, «һәз» дип ялгыш аталган[83]. Бу һәм башка шактый мисаллардан аңлашылуынча, «Чыңгызнамә»нең 2011 елгы басмасы, гәрчә «Хәлфин басмасы белән чагыштырып» эшләнүе белдерелсә дә, ул гамәл, күрәсең, төгәл үтәлмәгән.

Гыйләҗетдинов нигезләнгән элекке китаплардагы кайбер исемнәрдә «кәф» (йомшак «к») һәм «каф» (каты «къ») хәрефләре белән язылган очраклар бу басмада буталган урыннар да шактый. Мәсәлән, 1822 һәм 1882 еллардагы китапларда «Шәйбакъ» рәвешендә, соңгы хәрефе «каф» (къ) белән

[82] Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда. Т. III: Т–Һ. – Казан: Татар. китап нәшр., 1981. – Б. 136.

[83] Кайбер тарихчылар нәкъ шушы 2011 елгы басмага нигезләнеп, мәкаләләрендә «һәз» дип язган мисаллар бар инде.

бирелгән исем 2011 елгы басмада (40, 69 битләрдә) «Шәбәк» дип, ә йомшак «к» хәрефе белән языла торган «әшкярә» сүзе (74 биттә) «ашкара», шул ук биттәге «алтын биләү» мәгънәсендә булырга тиешле «алтын изарлык» сүзтезмәсе китапта «алтын изәрлек»кә әверелгән һәм алтынны изү турындагы бозык мәгънә килеп чыккан. Дөрес, «ашкара» да, «изәрлек» сүзе дә текстның хәзерге әдәби телгә күчерелгән өлешендә бөтенләй төшереп калдырылган. Иске китапларда йомшак «к» хәрефе белән басылган Көрләвеч исемен Күрләвеч яки Гөрләвеч дип тә укырга мөмкин, әмма С.Гыйләҗетдинов текстындагы Курлавычның беренче хәрефе каты «къ» белән язылган дип аңлашыла.

Башка төр ялгышларга килсәк, 1822 елгы басмада «җагалбай», ә 1882 елгысында «чафалбай» дип аталган ыру тамгасы исеме 2011 елда никтер «гәфалбай»га әверелгән (53, 79 битләр).

Иске басмаларда «эче сәнең (синең), тышы мәнең (минең) булсун» дип басылган җөмләдәге сүзләрдән кайберләре 2011 елгы китапта «эчесенең, тышысының» дип бирелгән (70 бит) һәм хәзерге телдәге текстта да «эче булсын, тышы булсын» (41 бит) дип, ялгыш тәкъдим ителгән.

1822 елда дөнья күргән китапта (28 биттә): «...Алангу тол калды тиб, үдәргә, ... үдәрин үдәрләделәр» рәвешендә, ә 1882 елгы китапта (7 биттә) бик хаталы басылган текстның бу сүзләре 2011 елгы басмада (72 биттә) «тибүдәргә», «үдәрин үдәрләделәр» дип басылган. Ә текстның хәзерге әдәби телгә күчермәсендә «тибүдәргә» дигәне «дип», ә «үдәрин үдәрләделәр» дигән гыйбарә «юлга чыктылар» рәвешендә ялгыш бирелгән. Югыйсә, архаик «үдәр, үдәрләмәк» сүзләре Хәлфин китабының сүзлегендә «мәрхүмне искә алу» дип аңлатылган.

Хәлфин басмасында (37 биттә) «...без исергән кеше тик булуб ултурганча, йаләремезне тартуб чикәлек ...тора салуб», 1882 елгы китапта «безләр исергән тик булуб ултурганча, йалларымызны тартуб чикәлең, бүре булса чыкар!» – тиделәр. Андин тора салуб...» дигән текст өлешендәге сүзләр 2011 елгы басмада «йалларымызны тартыб чыгалың... тура салыб» рәвешендә (73 бит), ә хәзерге телгә күчермәсендә (46 бит) «без исерек күк, ялларыбыздан тартып чыгар» дип, ялгыш тәкъдим ителгән, «тура салыб» сүзтезмәсе бөтенләй төшереп калдырылган.

1822 елгы китапта «сезнең шайыңыз бара алман» дип (46–47 битләр), 1882 елгысында исә «сезнең шайаныңызны бирә алмандур» дип, хаталы басылган җөмләнең бер өлеше 2011 елгы басмада (76 биттә) «шайаныңызны бирә алмандыр» диелгән һәм хәзерге телгә күчермәдә «сезнең белән бара алмыйм» дип тәкъдим ителгән. «Кебек, хәтле, кадәр» мәгънәләренә ия булган диалекталь «шае» сүзе хәзерге вакытта да Казан шәһәре һәм

якын-тирә төбәк татарларының сөйләмендә кулланыла. Шул ук 2011 ел басмасының 82 нче битендә «угланлар шайы бара алмады» дигән очракта «балалар кебек бара алмады» дип дөрес бирелгән.

Хәлфин басмасында (86 биттә) «Хәким ханны йир йотуб» рәвешендә, ә 1882 елгы китапта (42 биттә) «Хәким ханны йире торны» буларак, шактый хаталы рәвештәге сүзләр С.Гыйләҗетдинов тарафыннан «Хәким ханның йире (җире) турында» дип, ялгыш мәгънәдә басылган (67, 91 битләр).

Китерелгән мисаллар бу китаптагы текстологик кимчелекләрнең аз түгеллеген күзаллар өчен җитәрлек дип, монда сүзебезне чиклибез.

Гомумән, «Чыңгызнамә»нең соңгы чорда басылып чыккан текстларындагы җитешсезлекләр һәм текстологик хилафлыкларны киләчәктә бу ядкәргә мөрәҗәгать итәчәк белгечләргә файдасы булсын дигән максат белән искәрттек.

Тәнкыйди текст турында

«Чыңгызнамә»нең тәнкыйди тексты чалымнары моннан ике гасыр элек үк Ибраһим Хәлфин хезмәтендә тәҗрибә кылынган. Ул үзе әзерләп бастырган китапның керешендә берничә кульязма кулланып, ышанычлырагына өстенлек бирүен әйткән. Бу – турыдан-туры тәнкыйди текст хәзерләүне күздә тотмаса да, азмы-күпме шуның бер чаткысы дияргә мөмкин.

Гали Рәхим һәм археограф Сәед Вахиди «Чыңгызнамә»нең 1822 һәм 1882 еллардагы басмалары турында язганда, аларның икесе дә тәнкыйди һәм фәнни басма буларак нәшер ителмәгәнлеген искәрткәннәр.

Миркасыйм Госманов 1882 елгы басманы язма истәлекнең тәнкыйди текст өчен нигез була ала дигәнен алдарак әйтеп үттек.

Әлеге мәсьәләдә Мәсгуд Гайнетдинов болай дип язган: «Бу ун еллыкта әдәбиятыбызның шушы күренекле әсәре язылуга 300 ел тула. Бик күп нөсхәләре билгеле булуга да карамастан, аның әле һаман җентекләп фәнни төгәллеккә китерелгән тексты эшләнмәгән»[84].

Сәлим Гыйләҗетдинов «Чыңгызнамә»нең 1882 елгы басма тексты буенча хәзерге татар теленә якынлаштырып, гамәлдәге алфавитка күчермәсен тәкъдим иткән сүз башында: «Бу әсәрнең күпсанлы кульязма нөсхәләре бар. Киләчәктә аның фәнни-тәнкыйди тексты да дөнья күрер дигән өметтә калабыз» дип белдергән[85]. Бу фикерен ул 2011 елгы басмада да кабатлап, «Дәфтәре Чыңгызнамә» һәм Мөслиминең «Тәварихы Болгария»-сенең билгеле кульязма нөсхәләре бихисап күп һәм аларның тәнкыйди

[84] Гайнетдинов М. Дастаннар китабы..., 1979. – Б. 175.
[85] Дәфтәре Чыңгыз-намә..., 2000. – Б. 4.

текстларын эшләү татар текстологларының һәм тел белгечләренең мөһим бурычы булып кала», – дип язды[86].

2002 елда алман телендәге мәкаләләр һәм аңлатмалар белән, дүрт текст (өч кулъязма күчермәсе һәм 1882 елгы басма) нигезендәге латин хәрефләрендә басылган транскрипция тексты берникадәр тәнкыйди текстка туры килә дә кебек, аны шулай дип атаучылар да бар.

Дамир Исхаков бу мәсьәләдә «XIX йөзнең беренче яртысыннан ук басылып килүенә карамастан, аның критик тексты әлегә кадәр эшләнмәде. Хәлбуки, мондый текст булдырылырга тиеш...» дип белдерде[87].

«Чыңгызнамә»нең тәнкыйди тексты эшләнергә тиеш дигән галимнәрнең теләкләре, ихтимал, бер заман тормышка ашар. Бу уңайдан фрагмент дәрәҗәсендәге генә булса да, бөтен кулъязмалары күздән кичерелеп, җентекләп өйрәнелсә, яхшы булыр иде. Чөнки һәр кулъязмада яңалык өстәлергә мөмкин. Ләкин текстның ике төрле вариантын берләштереп кушу мөмкин түгел һәм кирәкми дә. Бары тик II вариант текстларының җыелма – тәнкыйди текстын эшләү турында сүз бара. Нәшер ителүенә 200 ел тулып килә торган 1822 елгы китапны, бәлки үз хәлендә, транслитерация белән, шулай ук хәзерге укучылар өчен дә аңлаешлы, камилрәк вариантта бастырып буладыр.

Авторлык мәсьәләсе, китапның калыбы һәм кайсы вакытка каравы

«Чыңгызнамә» («Дәфтәри Чыңгызнамә») – күпчелек галимнәр тарафыннан халык авыз иҗаты әсәрләре нигезендә билгесез автор тарафыннан язылган дип санала. Бу мәсьәләгә М.Госманов хезмәтендә зур игътибар бирелгән һәм этрафлы тикшерелгән.

Миркасыйм Госманов әсәрнең авторы билгесез дип яза. Ул «Дәфтәри Чыңгызнамә» өзегенең 1737 елда русчага тәрҗемәсендә кулъязманы күчерүчесен «писал Мустафа Кутлумухамметев» дигән сүзләргә күрә, аны ялгыш авторы итеп буталулар булуын искәрткән[88]. Госманов хезмәтендә аноним авторның шәхесе турында махсус бүлекчә бар. Анда билгесез автор турында мәгълүматлар булмаса да, талантлы кеше икәнлеге әйтелгән. Авторның рухани булганлыгы зур шик астына алынган һәм ул дөньяви ин-

---

86 Мирастан биш сәхифә..., 2011. – Б. 6.

87 Исхаков Д. «Дәфтәре Чыңгыз-намә» әсәренең бер урынына комментарий // Туган җир = Родной край. – 2018. – №2. – Б. 25.

88 Усманов М. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв..., 1972. – С. 123. Әлеге хата фикергә хәзер дә ияреп ялгышулар күзәтелә *(Ахметзянов М. О татарских рукописных книгах // Научный Татарстан. – 2012. – №2. – С. 130)*.

теллигенция вәкиле дип аталган[89]. М.Госманов үз фикерен, әсәрнең теле җиңел һәм дини терминология аз кулланылган булуы белән дәлилләгән. Риваятьләрдәге мәҗүси карашларның тәнкыйть ителмәвенә, авторның дини фанатизмнан азат булуына игътибар юнәлткән. Шулай итеп, галим «Дәфтәри Чыңгызнамә»нең авторы бары тик дөньяви кеше генә була алган дип, катгый фикер белдергән[90]. Ул шулай ук автор үз исемен бик тырышып һәм оста яшергән, әмма моның сәбәбе аңлашылмый дип яза һәм фаразларын белдерә (127–128 битләр). Авторның үткәндәге идеаль хәлләрне данлаган хәлдә, үз заманының караңгылыгын гына тасвирлавы һәм киләчәкне бөтенләй күзалламавы искәртелеп, соң чиктәге пессимист («законченный пессимист») дип бәяләнгән (132 бит). Идел буенда төгәл генә кайсы төбәктә яшәгәнлеге билгесез булса да, кайбер мәгълүматлар аның Зәй буена бәйле икәнлегенә ишарә итә, дип яза М.Госманов (127, 177 битләр). Шул ук вакытта ул «Дәфтәри Чыңгызнамә» идея-сәяси юнәлештә берләштерелгән аерым дастаннар, заманча әйткәндә, тематик очерклар җыентыгына күбрәк охшаган дигән фикер дә белдергән (125 бит).

Автор турындагы фикерләр уңаеннан түбәндәгеләрне искәртик. Әсәрнең авторы мулла түгел, ә дөньяви интеллигенция вәкиле дигән караш М.Госманов китабының коммунистик идеология хөкем сөргән елларда басылуына күрә, күпмедер дәрәҗәдә аңлашыла. Аноним авторның каршылыклы демократизмы һәм сыйнфый чикләнгәнлеге, шуңа карамастан бу мәсьәләне күтәрүе белән уңай дип атавы, монархиягә каршы, идеаль хөкемдар турында хыялланган булуы кебек фикерләр дә коммунистик заманга туры китереп әйтелгән. Әмма элекке дәверләрдән, гасырлар дәвамында татар халкының тормыш-яшәешендә дин иң мөһим урынны билгәнлеккә күрә ниндидер, «дөньяви интеллигенция» турында әйтү чынбарлыктан ерак. Феодал-байлар, сәүдәгәрләр һәм муллалар – югары сыйныф вәкилләре, гадәттә, үзара тыгыз бәйләнештә һәм еш кына бер үк нәсел-гаилә кешеләре булган, ләбаса. XIX гасырдагы әдипләр һәм галимнәрнең дә (шул исәптән, тарихчылар) мулла яки мулла нәселеннән булганлыгын истә тотканда, бер үк шәхесне мулла, тарихчы, шагыйрь яисә башкача интеллигенция вәкиле дип кенә аерып карау мөмкин түгел. Мондый хәл әле XX гасыр башында да дәвам иткән.

Аноним автор исемен яшерүе уңаеннан, А.Фәтхинең XVI–XVIII

[89] Усманов М. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв..., 1972. – С. 125–127.

[90] Шунда ук. – Б 127. Китапта болай диелгән: «Автором «Дафтар-и Чингиз-наме» мог быть только светский человек, скорее всего представитель татарского высшего феодально-аристократического общества, оказавшегося в силу объективных условий в оппозиции к царизму, его социальной и национальной политике».

гасырлардагы татар авторларына карата әйткән фикерләренә, аеруча «Аларга әсәрнең язучысы кем булуыннан бигрәк, әсәрнең үзе, фикере, мәгънәсе кыйммәтлерәк булган»[91] дигән сүзләренә игътибар итү җитәдер.

Ә әсәрнең теле җиңел, дини терминология белән чуарланмаган булуы, галимнәр язуынча, «Чыңгызнамә»дә халык иҗаты ядкәрләре киң кулланылган булуга да бәйле. Шулай ук элеккерәк чорлардагы, нигездә, гарәп һәм фарсы телләреннән тәрҗемә ителгән саф дини (шәригать мәсьәләләренә, намаз тәртипләренә һ.б. багышланган) әсәрләрнең иске татар теле, чагыштырмача, җиңел. Бу, бигрәк тә, XVIII гасыр ахырларына кадәрге текстларга хас күренеш[92].

«Чыңгызнамә» китабын зур тырышлык белән өйрәнгән галимнәрдән Гали Рәхимнең авторлык турындагы карашлары бер төрле генә түгел. Ул, әлеге язма истәлекнең тоташы белән аерым автор каләменә нисбәтле булуына караганда, мәҗмуга рәвешендә язып йөртелгән дастаннарны аерым бер кеше эшкәрткән һәм шомарткан дип санаган. Г.Рәхим бу турыда: «Фикеребезчә, бу китапны язучы яки, һич булмаганда, үзенчә эшләп чыгаручы кеше Казан татарларыннан булса кирәк. Чөнки аның теленең төбе татарчага бик ошаган» дигән[93]. Авторлык мәсьәләсендә Г.Рәхим фикерләрен тәгаенләп болай язган: «Гомумән, бу мәҗмуганың тел вә өслүбе баштанаяк бер характерда булып аның төрле бүлекләре өчен гомуми булган, шуның белән бергә башка тарихи әсәрләрдә истигъмаль ителми торган сүз вә гыйбарәләрнең очравы аның кайчандыр бер заманда баштанаяк бер кеше каләме белән эшләнеп чыкканына дәлаләт итә»[94].

Китапның башындагы Чыңгыз хан шәҗәрәсе Касыйм (Ханкирмән)

---

[91] Кульязмалар тасвирламасы. XII чыгарылыш..., 1968. – Б. 8.

[92] Мәсәлән, Татарстан Республикасы Милли китапханәсе фондында саклана торган XVII гасыр кульязмаларындагы ике дини текстка күз салыйк. Бер кульязмада шәһидлек турында: «Хәреб йирендә кылыч йә ук йә сөнге зәхмәте берлә үлсә, шәһид булур. Аны йумагайлар, намаз кыйлгайлар, кийәр туныны кәфен кыйлгайлар. Имди ирне тукуш йирендә терек күрделәр, утага килеб үлде – аны йугайлар. Моның тик ирне тукуш йирендә үлүк табтылар: һич әгъзасындин җәрәхәте йук – йугайлар...» *(«1295т» шифрлы кульязма, 1а кәгазь)*. Икенче кульязмада зәкят турында: «Мәсьәлә. Әмма әгәр кем ирсәнең ике йөз тәнкәседин ун йә унбиш тәнкә кем булса, күрмәк кирәк кем – булганы тәнкә йылның әүвәлегә йакын булса, зәкят ваҗиб булмас. Әмма йылның уртасында андаг булса, малның барчасыга булса, андин зәкят ваҗиб булмас. Әгәр бу нәрсәләр кем әйтелде, әгәр сәүдә өчүн булса, зәкят ваҗиб булур...» *(«1770т» шифрлы кульязма, 77б кәгазь). Хәреб, тукуш* – сугыш; *ута* – өй; *кем ирсә* – берәү; *андаг* – шундый; *ваҗиб* – тиеш.

[93] Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы. Беренче җилд: борынгы дәвер. Өченче бүлек..., 1922. – Б. 30.

[94] Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы. Феодализм дәвере. Икенче басма. – Казан: Татарстан матбугат һәм нәшрият комбинаты, 1925. – Б. 93.

ханнарына килеп тоташуын күздә тотып, Г.Рәхим каләм иясе турында «фикеребезчә, аның Ханкирмәнле булып, Касыйм ханнарының сарайларына якын бер кеше булуын күрсәтә» дип тә белдергән[95]. Ләкин ул 1927 елгы мәкаләсендә китапның авторын касыймлы диюгә сак якын килергә кирәклеген искәрткән. Г.Рәхим үзен бу фикергә этәргән сәбәп итеп кәгазе, тышлыгы гына түгел, хәтта язуы (почеркы) белән дә Баруди китапханәсендәге (хәзерге «40т» шифрлы) кульъязмага бик охшаш «Чыңгызнамә» тексты теркәлгән ядкәрне шул елда Арча кантонының Олы Мәңгәр авылында табуын дәлилгә китергән[96].

Гали Рәхимнең әлеге фикере аеруча игътибарга лаек: «Бу әсәргә баштанаяк бер генә кеше тарафыннан, бер вакытта язылган китап түгел, бәлки төрле кешеләр тарафыннан язылган кисәкләрдән күчерүчеләр кулы белән оештырылган бер мәҗмуга дип карарга тиеш була. Мондый мәҗмугалар борынгы татар китаплары арасында бик күп очрый торган гади (типичный) бер әйбер. Безнең китап күчерүчеләр һәрвакыт төрле җирдә таралып йөри торган, күбесенчә бер-берсенә бер дә мөнәсәбәте булмаган китап вә рисаләләрне, шулай ук аерым кәгазь парчаларындагы язуларны бер китапка теркәп яза торган булганнар. Бу әсәрнең дә шундый мәҗмугалар җөмләсеннән булуында шөбһә юк. Без аның хакында аерым бер китап шикелле итеп сөйлибез икән, тик аның иң күп урынын ишгаль иткән һәм төп мөндәрәҗәсен тәшкил иткән Чыңгыз хан белән Аксак Тимер хакындагы хикәяләрне эченә алган икенче һәм өченче кыйсемнәре турысында сөйлибез»[97].

«Чыңгызнамә»не тикшергән галимнәрдән Мәсгуд Гайнетдинов: «Автор сюжетка күп проблемалылыкны йөкли алуда җитлеккән талант осталыгын күрсәтә... «Дастаннар китабы»ның авторы – талантлы әдип, үз чоры өчен гаять югары эрудицияле галим» дип язды[98]. М.Гайнетдинов соңрак «Чыңгызнамә» әсәренең авторы билгесез, тик ул «Җамигыттәварих» авторы Кадыйргали бәк булырга мөмкин дип, шул ук вакытта «төп өлешне берничә автор язган дип тә уйларга була» дигән фаразын белдерде[99].

---

[95] Шунда ук. – Б. 91.

[96] Гали Рәхим: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык..., 2008. – Б. 213.

[97] Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы. Беренче җилд: борынгы дәвер. Өченче бүлек..., 1922. – Б. 37.

[98] Гайнетдинов М. Дастаннар китабы..., 1979. – Б. 175.

[99] Гайнетдин М. XVIII гасыр татар диаспорасы әдәбияты // Җалаерлы Кадыйргали бик. Җәмигъ әт-тәварих: халыклар тарихлары җыентыгы. – Казан: «Иман» нәшр., 2010. – Б. 12–13; Гайнетдинов М. «Дәфтәре Чыңгызнамә» // Татар әдәбияты тарихы. Сигез томда. Т. 2..., 2014. – Б. 206. «Җамигыт-тәварих» белән

Сәлим Гыйләҗетдинов «билгесез авторның «Дәфтәре Чыңгыз намә»се (Касыйм, XVIII гасыр башы)» дип тәгаенли. Шулай ук ул: «Җамигыт-тәварих» һәм «Дәфтәре Чыңгыз намә» – бер-берсе белән аерылгысыз бәйләнгән. Алар икесе дә Касыйм шәһәрендә язылганнар. Икесенең бер үк кулъязмага теркәлүләре моны тагын бер кат раслый» дип яза һәм «Идегәй дастаны» икесендә дә кабатлануын өстәмә дәлил итеп китерә[100]. С.Гыйләҗетдиновның авторны касыймлы дип ышандырырга теләп, ике әсәр тексты бер үк кулъязмада булуы турындагы сүзләре нигезсез. Чөнки тематик яктан бер төрле (бу очракта, тарихка бәйле) текстлар бергә җыентык рәвешендә күчереп һәм туплап йөртелүе мәгълүм. «Чыңгызнамә» тексты еш кына Мөслиминең «Тәварихы Болгарийә»се, Т.Ялчыголның «Тарихнамәи Болгар»ы белән бер җыентыкларда теркәлгәнлеге, хәтта кайчакларда бер-берсе белән аралаштырып язылулары – аларның авторлары бер җирлекнеке һәм бер үк кеше дигәнне аңлатмый. С.Гыйләҗетдиновның ике тарихи текстның бер кулъязмада булуы турындагы сүзләрендә бердәнбер очрак – «40т» шифрлы (Баруди китапханәсеннән кергән) кулъязма күздә тотылган. Шулай ук аның «Идегәй дастаны» икесендә дә булуы турындагы расламасы да уңышсыз, чөнки «Чыңгызнамә»нең «40т» күчермәсендә ул бүлек бөтенләй юк.

Авторы касыймлы булган дигәнгә карата тагын шуны искәртергә кирәк, «Чыңгызнамә» текстында Казан шәһәре турында язылган урыннары булса да, Касыйм каласы бер тапкыр да телгә алынмаган. Турыдан-туры Касыйм белән бәйле Шаһгалинең исеме дә Казан турында язганда гына әйтелгән. «Чыңгызнамә»не Касыймга бәйләү омтылышында китапның иң башындагы Чыңгыз хан шәҗәрәсенең Касыймга килеп тоташуы күздә тотылганлыгы мәгълүм. Әмма, нәкъ менә Кадыйргали бәкнең «Җамигыт-тәварих»ы теркәлгән «40т» кулъязмасындагы I вариант текстында андый шәҗәрә бөтенләй юк. Боларны исәпкә алганда, «Чыңгызнамә» Касыймда иҗат ителгән дигән фикерләрнең нигезе ышанычсыз икәнлеге күренә.

«Чыңгызнамә»нең авторы дип 1670-71 еллардагы крестьяннар

«Чыңгызнамә» китапларының авторы бер үк дигән фараз нигезле түгел. Һәрхәлдә, аларның текстларында бер үк авторныкы дип әйтерлек тел-стиль дәлилләре юк. «Чыңгызнамә»нең бөтен бүлекләренә хас «һәрайинә», «ахры бар» кебек, өслүб үзенчәлекләрен билгели торган сүзләр «Җамигыт-тәварих»та бөтенләй юк. Анда «Чыңгызнамә»дәге «ахры бар» сүзе мәгънәсендә «бил-ахир» дигән сүз кулланылган. Шулай ук, «Җамигыт-тәварих»та «Чыңгиз» дип (ике «кәф» белән), ә «Дәфтәри Чыңгызнамә» текстында «Чыңгыз» рәвешендә («кәф» һәм «гайн» хәрефләре белән) төрлечә язылган булуы да бер үк автор иҗаты түгеллеген белдерә.

[100] Мирастан биш сәхифә..., 2011. – Б. 5–6.

күтәрелешендә катнашкан дин эшлеклесе Идрис хафиз фаразлануы турында «Татар энциклопедиясе»нең 2 томында (239 биттә) язылган. Ләкин чыганакларда андый фикер юклыгын мәкаләбезнең башында искәрттек. Димәк, Идрис хафизга бәйле фаразның дәлиле юк. Энциклопедиядәге «Дәфтәре Чыңгызнамә» һәм Идрис хафиз турындагы мәгълүматның авторы М.Әхмәтҗанов 2011 елгы китапка язган кереш мәкаләсендә «Дәфтәре Чыңгызнамә»не язучыны «билгесез автор» дип кенә атаган[101].

Авторлык мәсьәләсендә башка төрле карашлар да булган. Мәсәлән, әдәбият галиме Габрахман Сәгъди «Бу китапны татар язган булу ихтималы да юк. Аны төркестанлы берәү язган»[102] дип катгый фикерен белдергән. Ә башкорт галиме Габделкадыйр Инан «Чыңгызнамә»не башкорт авылларының берсендә татар-монгол яуларыннан соң (һәрхәлдә, XVI гасырдан да калмыйча) язылган дигән. Г.Инан һәм Башкортстан галиме Гайса Хөсәенов «Чыңгызнамә»гә башкорт тарихи риваятьләре, эпосы һәм шәҗәрәләре көчле йогынты ясаганлыгын белдергәннәр. Г.Хөсәенов та «Чыңгызнамә»нең авторы башкорт булган дип язган, М.Нәдергулов та шул фикерне хуплаган[103].

«Чыңгызнамә»нең исемен, авторын һәм язылган вакытын ачыкларга омтылышларны өйрәнгәч, бу мәсьәләне хәл иткәндә кайбер галимнәрнең шаблонсыман мөнәсәбәткә нигезләнгән булулары аңлашыла. (Ягъни, китапның яки әсәрнең төгәл исеме һәм авторы булырга тиеш, шулай ук иҗат ителгән вакытын ачык билгеләү зарур дигән нигезсез шаблон). Әмма, М.Госмановның шактый ышанычлы диярлек дәлилләр белән «Дәфтәри

[101] Шунда ук. – Б. 4. Энциклопедиядәге фаразга нигезләнеп, борынгы Чаллы каласы төбәгенең (хәзерге Балык Бистәсе районындагы) мәшһүр шәхесе Идрис хафиз исеме белән бәйләргә омтылышлар да бар *(Безнең мирас. – 2018. – №1. – Б. 63).*

[102] Сәгъди Г. Әдәбият тарихымы, язмалар тарихымы? // Безнең юл. – 1923. – №12. – Б. 44.

[103] Надергулов М. Историко-функциональные жанры башкирской литературы (генезис, типология, традиции). – Уфа: Китап, 2002. – С. 10, 13, 89. Китап авторы үзе дә «Чыңгызнамә» XVI гасыр ахыры – XVII гасыр башында язылган ди (Б. 79). Бу китапта махсус «Анонимное «Чингизname» дип аталган бүлек бар (Б.78–99). Гомумән, «Чыңгызнамә», Мөслиминең «Тәварихы Болгарийә», Ялчыголның «Тарихнамәи Болгар» китаплары, шәҗәрәләр турында язылган әлеге китап М.Госмановның 1972 елда басылган хезмәтен хәтерләтә. Әмма «тараварих» дип бозык язылган (11 бит), Гали Рәхим фикерен телгә алып, аның хезмәте урынына астөшермәдә С.Күкләшевнең «Диване хикәяте татар» чыганагын күрсәткән (81 бит), шулай ук китапның форзац битләрендә (эчтәлегенә бөтенләй туры килмәсә дә) гарәп хәрефләре белән «Нур театры» дигән язу урнаштырган (җитмәсә, «театр» сүзен «тилтер» дип хаталы биргән) басмага, каршылыклы фикерләренә һәм язма мирасның шактый өлешен башкортныкы дип бәяләүгә күз йомган хәлдә, нинди генә акыллы фикерләре булса да, ышанасы килми.

Чыңгызнамә» дип тәкъдим иткән исем-атамасы, авторы турындагы фикерләре һәм иҗат ителгән вакыты да фәндә тиешенчә кабул ителмәде. Шакир Абилов бу ядкәрне «Дастаннар мәҗмугасы» рәвешендә, ә Мәсгуд Гайнетдинов «Дастаннар китабы» дип, үзләре дөрес дип тапкан исем белән атадылар һәм тарихи әсәр түгел, ә әдәбият истәлеге дип билгеләделәр. М.Гайнетдинов аның авторы Зәй буенда яшәгән кеше түгел, ә Касыйм татары дип фаразлап, Кадыйргали бәк булуы ихтимал дигән фикергә килде, язылган вакытын исә 1600–1602 елларда башланып, 1685 елда төгәлләнгән дип тәгаенләде[104].

Авторлык турындагы фикерләргә өстәп үз карашыбыз белән дә уртаклашыйк. Г.Рәхим фикеренә кушылып, «Чыңгызнамә»нең аерым бер авторы дип тәгаенләүгә караганда, аны бу җыентыкның төзүчесе (автор-төзүче) яисә редакцияләп әдәби эшкәрткән каләм иясе дип атау дөресрәк булыр дип саныйбыз. Исемен безгә тарих сакламаган әлеге затның табигый сәләте, һичшиксез, югары булган. Ләкин аны бу китапны иҗат иткән кеше булудан бигрәк, мәгълүм текстларны үзенчә эшкәртеп, нәфисләп һәм баетып бер тәртипкә китерүче буларак тәкъдир итәргә кирәк. XIX гасыр башында Ибраһим Хәлфин дә әлеге китапны бераз үзгәрткәләп оештырган, әмма, аңа карап Хәлфинне автор дип әйтеп булмый. Шуның кебек үк, билгесез бер зат әүвәлдән килгән төрле дастан һәм риваятьләрне берләштереп, мөмкин кадәр бер өслүбкә китереп, шомартып җыентык-мәҗмуга итеп төзегән икән, аны да тулы мәгънәсендә автор дип атау мөмкин булмас иде.

Китаптагы дастаннар, асылда, халык иҗаты ядкәрләре булганлыктан, «Чыңгызнамә» китабын оештыручыны билгесез диюгә караганда, аның авторы гомумиләштерелеп, татар халкы диелсә, дөресрәктер. Аксак Тимер дастанындагы «Ошбу олуг Идел», «Ошбу Зәй тамагы» һәм «Тарих дастаны»нда «Ошбу Уфа тамагы» кебек язылышлардагы «ошбу» сүзе әлеге текстларны эшкәрткән каләм иясенең Идел-Урал төбәгенә бәйлелеген күрсәтә. «Чыңгызнамә»нең хәзерге вакытка билгеле кульъязма күчермәләренең зур күпчелеге (44 берәмлек) Казан шәһәрендә саклану факты да китапны төзегән затның Урта Идел–Казан төбәгенә бәйле булуына ишарә итә.

Татар археографиясендә еш очрый торган күренешне искә төшерсәк, татар кульъязма китаплары арасында еш кына бер төптә төрле мәсьәләләргә караган текстлар һәм әсәрләр туплап йөртелгән кебек, тематик яктан берләштерелгәннәре дә булган. Беренче төрдәгеләрен Г.Рәхим «мәҗмуга»

---

[104] Гайнетдинов М. «Дәфтәре Чыңгызнамә» // Татар әдәбияты тарихы. Сигез томда. Т. 2..., 2014. – Б. 208.

дип атап, андыйларны бик төгәл характерлаган[105]. Бертөрле яки якын темага язылган әсәрләр йә аларның аерым өлешләре кыскача (абзацлап, яртышар битләп) җыентык сыйфатында туплап йөртелгән. Намаз кагыйдәләре турында төрле чыганаклардан алынган күчермәләр бер дәфтәрдә, фикъһ мәсьәләсенә караган текстлар бер мәҗмугада, шигъри әсәрләр бер җыентыкта, бәет-мөнәҗәтләр янә аерым, гарәп теле грамматикасы белән тәҗвид кагыйдәләре бергә, тыйбб-медицина буенча эреле-ваклы күчермәләр башка кульязмада, кечкенә сүрәләр һәм кыска күләмле догалар җыйнак догалыкларда һ.б. рәвешле – үзләренчә тематик яктан классификацияләнгән хәлдә дә язып йөртелгән. Шулар кебек үк, тарихка багышланган әсәрләр һәм төрле тарихи хәбәрләр белән вакыйгалар аерым җыентыкларга тупланган. Казан университеты китапханәсендәге «40т» шифрлы кульязмада «Җамигыт-тәварих» белән «Дәфтәри Чыңгызнамә» бер мәҗмугада булуы, «Чыңгызнамә» тексты теркәлгән башка кульязмаларда еш кына «Тәварихы Болгарийә» һәм Таҗетдин Ялчыголның «Тарихнамәи Болгар» әсәре бергә язылган хәлдә йөртелүе дә тематик җыентыклар булганына дәлил. «Чыңгызнамә» исеме белән танылган китап та, мәҗмугаларда электән күчереп йөртелгән һәм төрле чорларга караган текстларны бергә туплап, мөмкин кадәр бер тәртипкә тезеп, телен һәм стилен бераз шомартып булдырылган җыентыкка күбрәк охшый. Андагы кайбер даталар һәм тарихи фактларга нигезләнеп фикер йөрткәндә, аның XVII гасыр ахырында эшкәртелгәнлеге аңлашыла.

Галимнәр электән үк игътибар иткәнчә, Чыңгыз хан, Аксак Тимер һәм Амәт турындагы дастаннар әүвәлгерәк чорлардан килгән. «Тарих дастаны» өлеше исә аерым бер автор тарафыннан гына иҗат ителмичә, электән язылып һәм өстәлеп килгән мәгълүматларны бергә туплап оештырылганга күбрәк тарта. Ул бүлекнең соңгырак гасырларда өстәлеп һәм дәвам итә баруы да татар археографиясенә хас күренеш.

Китаптагы Аксак Тимер дастанының ахырындагы «әл-кыйсса» дип бирелгән дүрт кыска хикәят шулай ук төрле риваятьләрнең мәҗмугаларда язылып йөртелгән аерым күчермәләрен бергә туплаганга бик охшаган. Ягъни, Аксак Тимернең авыруга салынып, Истанбулны хәйлә белән алуы; бараҗ халкы арасына чыгып йөрүе; бер карчыкның тирмәсен бәйләгән каеш-баулары өзелүгә бәйле вакыйга һәм Аксак Тимернең Бохарага китүе текстта дүрт кечкенә кыйсса рәвешендә язылган. Алар белән беррәттән, «әл-кыйсса» дип аерып үк язылмаса да, бертуганнар Инсан бик белән Ихсан бикнең нәселләрен бәян иткән өлеше дә аерым мәгълүмат булып, шул үк дастанга өстәлгән дип фаразларга мөмкин. Аннан соң төп текстны дәвам

[105] Шунда ук. – Б. 84–85.

итү өчен «Имди йәнә сүзне башдин сүзләйәле» дигән бәйләгеч җөмлә дә шуңа ишарә итә.

«Идегәй дастаны»ның «Җамигыт-тәварих»та да булуы –«Чыңгызнамә»нең җыелма китап сыйфатына бер дәлил. Идегәй би нәселенә багышланган бүлек Кадыйргали бәкнең «Җамигыт-тәварих» әсәрендәге «Дастане Идегәй би» бүлегенең яртысыннан күбрәк өлешенә туры килә. Ике китаптагы текст, кайбер исем-атамалардагы зур булмаган аермаларны исәпкә алмаганда, үзгәрешсез диярлек. Тик «Чыңгызнамә»дәге Идегәй бүлегенең ахыры кыска гына тәмамланган, ә «Җамигыт-тәварих»та Идегәй вафатыннан соң хакимлек иткән биләр турында текст дәвам итеп, шактый гына мәгълүмат язылган. «Чыңгызнамә»гә Идегәй турындагы бүлек «Җамигыт-тәварих»тан алынган дип исәпләнсә дә, бу фикер бик үк ышанычлы түгел. М.Госманов «Чыңгызнамә»дәгесен Кадыйргали бәк әсәрендәге текстның кыскача версиясе дип атаган, «Җамигыт-тәварих»тагы Идегәй шәҗәрәсенең «Чыңгызнамә»гә кертелгәнлеге «Җамигыт-тәварих» күчермәләре татарлар арасында таралган булуын күрсәтә һәм аның «Дәфтәри Чыңгызнамә»гә йогынтысы моның белән генә чикләнми дип язган[106]. «Чыңгызнамә»не бербөтен әсәр буларак аерым автор XVII гасыр ахырында иҗат иткән дип М.Госмановча фикер йөрткәндә, шулай исәпләргә мөмкин булыр иде. Ләкин Идегәй би турындагы бүлекләрнең төп шәҗәрә өлеше бер үк төрле булган хәлдә, «Җамигыт-тәварих»та дәвамы шактый төгәл һәм тулы язылган булып, «Чыңгызнамә»нең бөтен күчермәләрендә дә кыскалыгына күрә, берсе икенчесеннән алынган дип расларга читен. Ихтимал, бу очракта, ике китаптагы Идегәй би шәҗәрәсе дә әүвәлгерәк бер үк, башка бер чыганактан алынган. Кадыйргали бәк бүтән төр мәгълүматлар нигезендә аны үзе яшәгән заманга кадәр дәвам итеп язган булса, «Чыңгызнамә» («Дәфтәри Чыңгызнамә») текстында Идегәй би шәҗәрәсе элекке төп чыганактагыча калган булуы мөмкин. Югыйсә, күчереп кенә куелган булса, ни өчен тулы хәлендә күчерелмәгән дигән урынлы сорау туа. Шулай ук «Чыңгызнамә»нең төрле күчермәләрендә «Мисырда» дигән сүзнең «Сарсарада» (яки «Сарсарда») дигән бозык язылышы «Җамигыт-тәварих»та да Идегәйнең борынгы бабалары дип исемләнгән дүрт солтан исеменә карата язылган. Мондый хаталы язылышның бер китаптан икенчесенә турыдан-туры күчерелүенә караганда, әлеге шәҗәрәнең алардан да элеккерәк күчермәләре булып, «Сарсара» атамалары борынгырак чордан килгән хата дип уйлыйбыз. М.Госмановның «Җамигыт-тәварих»ның «Дәфтәри Чыңгызнамә»гә бүтән йогынтылары

[106] Усманов М. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв..., 1972. – С. 116.

дигәне дә, чынлыкта, ике китапта уртак чыганаклар кулланылу нәтиҗәсе[107]. Ә Идегәй шәҗәрәсендәге иң борынгы бабасы итеп Әбүбәкер хәлифәне күрсәтү суфыйлар (шул исәптән нәкышбәндиләр) арасында киң таралган. Әбүбәкер иң беренче суфый сахәбә дип санала, элек бөтен тарикатьләр дә үз силсиләләрен Мөхәммәт пәйгамбәрнең сахәбәләреннән берсенә бәйләгәннәр. XIV–XV гасырлар – суфыйчылыкның зур үсеш алган чоры булуын исәпкә алганда, Идегәй бинең уйдырма шәҗәрәсе дә Әбүбәкердән башлануы гаҗәп түгел.

«Чыңгызнамә»нең бербөтен рәвешендәге төгәл генә исеме-атамасы булмавы шулай ук аның җыентык калыбы хасиятенә ишарә итә. Китаптагы кайбер (Аксак Тимер, Амәт, Идегәй, ханнарның биләмәләре турындагы) бүлекләрнең ахырларында «Валлаһу әгъләмү бис-саваби» («чын дөреслекне Аллаһ белә») дигән гыйбарә бар. Менә мондый сүзләр, гадәттә, кулъязма җыентыкларга төрле китаплардан күчереп алынган кыскача язмалар яисә кем дә булса сөйләгәнне теркәгән очракларда текст ахырына өстәлгән. «Чыңгызнамә»дәге шундый гыйбарәләр – төрле бүлек рәвешендәге мөстәкыйль текстларның җыелма буларак бергә тупланганына ишарә итә.

Әлеге китапны кайбер галимнәрнең шартлы рәвештәге «Дастаннар мәҗмугасы» яки «Дастаннар китабы» дип атарга тәкъдим итүләре дә «Чыңгызнамә»нең җыентык сыйфатына бәйле.

«Чыңгызнамә»нең бер әсәр рәвешендә тупланганлыгы аның икенче бер чордашы – суфыйчылык әдәбияты җыентыгы «Бакырган китабы»н да искә төшерә. «Бакырган китабы» – шулай ук XVII гасыр ахырында төрле шагыйрьләрнең әсәрләре бергә җыелган шигърият антологиясенең бер үрнәге[108]. Тематик яктан төрле әсәрләр булсалар да, «Чыңгызнамә» белән «Бакырган»ның китаби калыпларының кайбер охшаш яклары бар. Әйткәнебезчә, алар икесе дә бер чорда – XVII гасыр ахырында төзелгәннәр. Икесенең дә исемнәре китапларның тулы эчтәлегенә туры килеп бетми. «Чыңгызнамә» турында алда сүз булды, ә «Бакырган»

---

[107] Галим Аллен Франк та әйтелгән ике китапта бер үк чыганактан алынган шәҗәрә кулланылган булуы ихтимал дигән фикер белдергән *(Франк А. Исламская историография и «булгарская» идентичность татар и башкир в России..., 2008. – С. 31).*

[108] Бу мәсьәләгә беренчеләрдән булып әдәбият галиме Гали Рәхим игътибар иткән. Ул «Бакырган китабы» турындагы мәкаләсендә «таркау әсәрләрдән җыелып бер-ике кеше тарафыннан тәртип ителгән бер мәҗмуга» дип, анда ничә шагыйрьнең күпме шигыре кергәнлеген һ.б. ачыклап язган *(Газиз Г., Рәхим Г. Татар әдәбияты тарихы. Беренче җилд: борынгы дәвер. Икенче бүлек. – Казан: Татарстан җөмһүриятенең дәүләт нәшрияты, [1923]. – Б. 102–108).* Борынгы язма ядкәрләрне өйрәнгән галимә Зәйнәп Максудова «Бакырган китабы»н махсус тикшереп, аны нәкъ менә Мәүлә Колый төзегән дигән нәтиҗәгә килгән.

китабы» шулай ук аерым бер автор – Сөләйман Бакырганый әсәрләре генә тупланганлыгын белдерми. Димәк, китапның «Бакырган китабы» дигән исеме дә «Чыңгызнамә» («Дәфтәри Чыңгызнамә») кебек үк шартлы. Алар җыентыктагы беренче шигъри әсәргә яки дастан текстына күрә шулай исемләнгәннәр. Гомумән, элек татарларда китапның беренче гыйбарәсенә бәйләп атау күренеше киң таралган булган. «Бакырган китабы» исеме андагы беренче шигырьнең «Бакыргандин сәфәр кыйлсам...» дигән юлларына нисбәт ителгән дип саныйбыз[109]. Әлеге китапта XII–XVII гасырларда яшәгән дистәләгән авторның шигырьләре тупланган.

«Бакырган китабы»ның чыганак буларак әһәмияте турында галим Габдрахман Таһирҗанов язганнарны искә алу бик урынлы булыр. Ул авторлар турында мәгълүмат биреп, болай ди: «Бу авторларның Кол Шәриф белән Касыйм шәехтән башкалары – тугандаш халыкларның әдәбият тарихларында мәгълүм шәхесләр. Ләкин үзенә күрә антология кыяфәтен алган «Бакырган китабы»нда тагы Бәйза, Бәһбүди, Кол Шәрәфи, Мискини кебек шагыйрьләр дә очрый. Аларның исемнәре югарыда телгә алынган Нәвои китабында да, Хәсән Нисариның «Мөзәккер әл-әхбаб» исемле зур антологиясендә дә, Үзбәкстанда чыгарылган сигез томлык кулъязмалар тасвирламасында да, шулай ук башка белешмәләрдә дә очрамый. Шуңа күрә аларның кайберләре болгар-татар җирлегендә формалашкан шагыйрьләр булуы бик тә ихтимал. «Бакырган китабы»ның Урта Идел буенда төзелгән булуын игътибарга алсак, безнең фикер тагы да куәтләнә төшә. (Урта Азиядә бу антология күчермәләренең юк дәрәҗәсендә аз очравы бу фикергә тагын көч бирә)»[110].

«Бакырган китабы» исеме астында тупланган шигъри әсәрләр алда

[109] Гали Рәхим җыентыктагы беренче шигырь ахырында (гомумән, ул китапта бер генә мәртәбә) автор буларак язылган Сөләйман Бакырганый исеменә бәйледер дип фаразлаган. Әмма шигъри калыптагы «Кисекбаш» китабын татарлар беренче сүзе буенча «Башлагали» дип атаганны, XIII гасырның мәшһүр шагыйрьләреннән Шәрәфетдин Бусыйриның «Касыйдәи бөрдә» исемле шигъри әсәрен беренче юлындагы башлангыч сүзләре «Әмин тәзәккүр...»гә бәйләп, татарлар «Әмин тәзәк» дип йөрткәнен, Фәридетдин Гаттарның «Пәнднамә» әсәрен беренче сүзләре буенча «Хәмде би-хәдд» дип атау гадәте булганны исәпкә алганда, «Бакырган китабы»ның да исеме текстындагы беренче сүздән алынган. Мондый мисаллар тагын да бар.

[110] Таһирҗанов Г. Тарихтан – әдәбиятка. – Казан: Татар. китап нәшр., 1979. – Б. 63. «Бакырган» җыентыгын соңгырак чорда әдәбият галиме Фәрит Яхин тикшерде һәм анда барлыгы 20 шагыйрьнең 143 шигъри әсәре теркәлгәнен, шуларның өчтән бере Сөләйман Бакырганыйныкы икәнлеген, бу китап XVIII гасырда Пугачёв күтәрелеше алдыннан яисә шул елларда төзелгән дип белдерде *(Бакырган китабы: XII–XVIII йөз төрки-татар шагыйрьләре әсәрләре / төз. Ф.Яхин. – Казан: Татар. китап нәшр., 2000. – Б.3–8).*

әйтеп узылган тематик җыентыклар булганлыгы турындагы фикергә өстәмә бер дәлил булып тора. Иң мөһиме – «Бакырган» китабы»нда алты гасыр эчендә иҗат ителгән әсәрләр бергә җыелган булу факты – «Чыңгызнамә»дә тупланган дастаннарның да төп нигезләре бер чорга (һәрхәлдә, XVII гасырга) гына карамаганын раслый.

Китаптагы дастаннарның кайчан һәм кайсы гасырда иҗат ителгән булуын төгәл генә әйтеп булмый. Шулай да, аларның бәйсез татар ханлыклары чорына караган ядкәрләр икәнлеге аңлашыла. Китаптагы беренче дастанның ахырында Чыңгыз ханның дүрт улын төрле урдаларга хан итеп куюы тасвирланган һәм «ул шәһәрләрдәге ханларның асылы-төбе болардур, асылы Чыңыз хандиндур» дип төгәлләнгән. Әлеге җөмләдә язылганга нигезләнеп фикер йөрткәндә, бу дастанның шушы – хәзергәчә мәгълүм төп тексты бәйсез татар ханлыклары яшәп килгән чордан – XVI гасыр урталарына кадәр оештырылган дип әйтергә мөмкин. Дастанның иң ахырындагы сүзләре «...вафат булды, сүзе дөнйада калды» дип төгәлләнүе дә шуңа ишарә итә, ягъни «сүзе» дигәндә «хөкеме-боерыгы», ул корган нигезе дип аңларга кирәк. Бу очракта, Чыңгыз хан тәгаенләгән ханлыклар дәвам итеп килүе күздә тотылган.

1925 елда нәшер ителгән «Татар әдәбияты тарихы» китабында: «Дастане Чыңгыз хан...» китабы эчендә «Фасыл фи дастани Гайса угылы Амәт» аталган бер тарихи хикәя бар. Бу хикәянең каһарманнары Җанбик, Бирдебик, Тайдулы шикелле Сарай хан вә ханшалары. Бу хикәя гәрчә Алтын Урда заманында ук язылмаса да, әле халыкның күңелендә Алтын Урда ханнары хакындагы легендалар онытылып бетмәгән бер дәвердә язылган булуы ихтимал»[111] дип, хикәятнең иҗат ителгән заманы борынгырак булуы күрсәтелгән.

«Чыңгызнамә»дәге ханнарның биләмәләре турындагы кыска гына бүлектә «Казан – Шыгали ханның йортыдур» дигән мәгълүматка нигезләнеп фикер йөртсәк, ул бүлек шулай ук XVI гасыр уртасыннан соңрак язылмаган дип фаразларга мөмкин. Һәрхәлдә, Шыгали турындагы сүзләр электән язып йөртелгән хәбәрләргә өстәп теркәлгән дип тә карарга була.

Күчмә сюжетлар һәм аларның чалымнары

Шәрык әдәбиятында һәм фольклор әсәрләрендә борынгы чорлардан ук бөтен килеш яисә өлешләп күчеп килгән сюжетлар булуы мәгълүм. Гомумән, борынгы дәвер әдәбиятларына һәм Шәрык-мөселман әдәби әсәрләренә хас сюжет күчешләре – әүвәлдән мәгълүм иҗади алым. Бигрәк тә, мөселман халыкларының әдәбиятына назыйрә жанры – бер

[111] Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы. Феодализм дәвере..., 1925. – Б. 80.

үк сюжет нигезендә яңа әсәр язу күренеше – киң таралган. Кайбер күчмә сюжет өлгеләре «Чыңгызнамә» («Дәфтәри Чыңгызнамә») исеме астында берләштерелгән дастаннарда да очрый.

Шуларның кайберләренә тукталып китәбез. Чыңгыз нәселе дастанындагы Алтын хан исеме «Тәварихы гөзидә» әсәренең кыскартылган варианты «Шәйбанинамә» текстында да бар. Шулай ук Әбелгазыйның «Шәҗәрәи төркийә» әсәрендә Чин (Кытай) хакиме буларак Алтын хан телгә алынган. Борынгы Шәрык хикәятләренә нигезләнеп төрле жанрларда иҗат ителгән бихисап әсәрләрдә дә зирәк кыз Турандыкның әтисе Алтын (Алтын хан) буларак тасвирланган. Шул ук сюжетка корылган «Мәликә китабы»ндагы кайбер чалымнар Чыңгыз нәселенә багышланган дастанда да очрый. Мәсәлән, дастан башындагы хан үзенең акыллы һәм гүзәл кызын зур сарайда яшереп саклап тоту мотивы «Мәликә китабы»нда да бар. «Мәликә китабы»ның XVII гасырдагы «Дастане җайә» дип аталган кулъязма күчермәсендә Мәликә исеменең нигезе «М.л.к.» дип, шуңа сузык авазларны белдерә торган хәрәкәләр өстәп язылган һәм ул Мәликә дип укыла. Бу язылыш Чыңгыз хан дастанындагы Голәмәлик исеменә охшаш. Ихтимал, әүвәлгерәк күчермәләрдә бу исем дә хәрәкәләр белән язылып, чынлыкта Гыйльмемәликә (гыйлем иясе мәгънәсендә) булгандыр дип фаразларга мөмкин. Гомумән, борынгырак төрки-татар текстларында хәрәкәләр кулланылганлыгы мәгълүм.

Дастан башында Голәмәликнең нәселен дәвам итәр өчен кошлар һәм җәнлекләр белән бергә көймә белән йөздереп җибәрү күренешендә Нух пәйгамбәр көймәсенә берникадәр охшашлык бар. Чыңгыз хан нәселенең бу китаптагы шәҗәрәсе Нух пәйгамбәрдән башланган булуын һәм Чыңгызның булачак хатыны Бөртә Кучынның да ханга мөрәҗәгать итеп, Нух галәйһиссәлам заманындагы туфан суын һәм җан ияләренең нәселләре киселмәсен дип көймәдә коткарылу вакыйгасын искә алуына игътибар иткәндә, бу сюжет өлгесенең очраклы түгеллеге күзаллана. Шулай ук Аллаһы Тәгаләнең Нух пәйгамбәргә биргән изгелеген Чыңгыз ханга да тәкъдир иткән кебек мәгънә салынган дип карарга да була.

Әдәбият галиме Хатыйп Миңнегулов борынгы чорның мәшһүр шәхесе Атилла, риваятьләр буенча, могҗизалы рәвештә – нурдан йөккә узу нәтиҗәсендә дөньяга килгәнен искә алып, моның Чыңгыз хан турындагы дастанга охшашлыгын искәрткән[112].

Чыңгыз ханның дөньяга килүе турындагы могҗизада вафат булган әтисенең рухы тирмә төнлегеннән төшүе турындагы риваять

[112] Миннегулов Х. Татарская литература и Восточная классика: вопросы взаимосвязей и поэтики. – Казань: изд-во ун-та, 1993. – С. 31.

«Шәйбанинамә»дә язылган. Анда Алангу, Дубун Бәйан һәм тирмәдән яктылык кереп, бала табу вакыйгалары теркәлгән. Әбелгазыйның «Шәҗәрәи төркийә» китабында Дубын-Бәйан вафат булгач, таңда Алангуның чатыр төнлегеннән берәү яктылык булып иңә һәм шуннан ук чыгып китә. Алангу йөкле була. Туганнары ризасызлык белдерәләр. Алангу чатырына сак куела. Бервакыт шулай ук төнлектән яктылык иңә һәм кире чыгып китүен күрәләр – менә болар «Чыңгызнамә»дәге дастан белән уртак. Бу рәвешле сюжет өлгесе Алтын Урда чоры төрки-татар шагыйре Котб әсәрендә дә бар. Галим Г.Таһирҗанов язуынча, Котб 1342 елда язып тәмамлаган «Хөсрәү вә Ширин» әсәре өчен калып итеп алган Шәрыкның мәшһүр фарсы шагыйре Низами поэмасындагы шаһ сарайларын Алтын Урдага хас тирмә һәм чатырларга әйләндерү белән бергә, төнлектән төшеп, төнлектән чыгып китү рәвешендәге тасвирлар кулланган[113].

Гали Рәхим дә болай дип белдергән: «Китапта Чыңгыз һәм Тимер хакында сөйләнә торган хорафи хикәяләр, шөбһәсез, аны язучының үз башыннан чыкмаганнар. Ул аларны кайдан булса да алган. Ихтимал, ул бу риваятьләрне колактан ишетмеш буенча, ихтимал ки, башка китаплардан алып язгандыр. Ике ихтималның соңгысы дөрестлеккә якынрак дип уйлана. Бәлки бу әсәрен язганда безнең мөхәрриренең күз алдында Урта Азиядә язылган бер-бер китап булгандыр. Китапта байтак кына бик борынгы төрк сүзләренең очравын шул юл белән генә аңларга мөмкин»[114].

Маҗар галимәсе Мария Иваничның 1998 елның җәендә Казан шәһәрендә үткән фәнни семинар җыентыгындагы мәкаләсе аерым игътибарга лаек. Ул Чыңгыз хан нәселенә багышланган дастанда борынгы төрки, монгол һәм Алтын Урда чорларына караган риваятьләр чагылыш тапкан дип белдерә. Дуйын-Бәйанның әнисе Голәмәликнең сарайда бикләп тотылып, нурдан бала табуы уйгурларның борынгы бабалары барлыкка килү турындагы риваятькә охшашлыгын искәртеп, әлеге нурдан яралу мотивының Евразиядә тунгуслардан фарсылар аша грек мифологиясенә кадәр таралганлыгы турында яза. Чыңгызның дөньяга килүенең могҗизалы тасвиры борынгы монгол һәм фарсы елъязмаларында нурдан бала туу турындагы элекке риваятьләрдән үзгәргәнен дәлилли. Хан булганнан соң Чыңгыз үзен дошман иткән ыруларның башлыкларын һәлак итеп, аларның балаларын исән калдыру күренеше шулай ук борынгы монгол һәм фарсы чыганакларына бәйле дип яза[115].

---

113 Таһирҗанов Г. Тарихтан – әдәбиятка. – Казан: Татар. китап нәшр., 1979. – Б. 129.
114 Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы. Беренче җилд: борынгы дәвер. Өченче бүлек..., 1922. – Б. 33.
115 Иванич М. «Дафтар-и Чингиз-наме» как источник по истории кочевых обществ...,

«Чыңгызнамә» текстындагы тамгалар һәм башка атрибутларда да сюжет күчмәлеге күренә. Рәшидеддиннең XIV гасыр башында язылган «Җамигыт-тәварих» әсәрендә легендар Угыз ханның үз улларына тамгалар һәм башка атрибутлар өләшүе турында язылган сюжет «Чыңгызнамә»дә Чыңгыз хан тарафыннан биләргә өләшү буларак кабатланган. М.Госманов әлеге ике әсәрдәге тамга сурәтләренең бер-берсенә бик охшаш булуын искәрткән[116].

Аксак Тимер турындагы дастанның төш күрү турындагы тасвир белән башлануы фольклор һәм борынгы әсәрләрнең шактыена хас.

Тарихчы Гамирҗан Дәүләтшин Аксак Тимер дастанындагы бараҗ халкының аждаһага каршы көрәшен искә алып, «Шәһәр салынасы урынны аждаһалардан азат итү һәм аларга каршы көрәш сюжеты X–XI гасыр фарсы-таҗик шагыйре Фирдәүсинең «Шаһнамә»сендә үк очрый. Билгеле булганча, ул борынгы риваятьләргә нигезләнеп язылган» ди һәм әлеге сюжет өлгесенең борынгы төрки чорларда ук таралган булуына игътибар юнәлтә[117]. Г.Дәүләтшин, гомумән, Болгар дәүләте чорында күп илләр белән тыгыз сәүдә, дини-сәяси багланышлар халык авыз иҗатына урта гасырлар дөньясында «күчеп йөрүче» күп сюжетлар үтеп керүгә сәбәпче булган дип яза[118].

Аксак Тимернең кием-кыяфәтен үзгәртеп, халык фикерен сорап-белеп йөрүе «Мең дә бер кичә» кебек борынгы әкият сюжетларыннан күпләргә таныш. «Чыңгызнамә» текстындагы башка кайбер охшашлыкларны татар халык әкиятләрендә, риваятьләрдә һәм дастаннарда да күрергә мөмкин.

Башкортстан галиме М.Нәдергулов Аксак Тимер турындагы дастан текстында сүз барган Амәт, Самәтләргә бәйле мифологик сюжет «Чыңгызнамә»гә кайбер башкорт ыруларының шәҗәрә язмаларыннан күчкән булу ихтималы зур дип язган[119]. Әмма бу очракта һәм, гомумән, Чыңгыз хан дастанындагы бикләрнең исемнәренә бәйле рәвештә, бәлки, киресенчә «Чыңгызнамә»дә язылган ярымлегендар мәгълүматлар башкорт шәҗәрәләренә нигез булып киткәндер? Бу уңайдан XVIII гасыр башында каракалпаклар ханы буларак танылган Солтанморат Көчек улының «Дәфтәри Чыңгызнамә» китабындагы Чыңгыз хан нәселенең уйды-

2002. – С. 314–316, 320.

[116] Усманов М. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв..., 1972. – С. 109–110.

[117] Дәүләтшин Г. Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. – Казан: Татар. китап нәшр., 1999. – Б. 153–155.

[118] Шунда ук. – Б. 166.

[119] Надергулов М. Историко-функциональные жанры башкирской литературы..., 2002. – С. 94, 99.

рма шәҗәрәсен дәлил итеп куллану факты[120] шундый фаразга да этәрә. «Чыңгызнамә»дәге бикләр исеменә бәйле башкорт шәҗәрә язмалары Солтанморат хан нигезләнгән бер үк чыганак буенча оештырылмаган иде микән дип, мәсьәләне шул яктан да карарга мөмкин бит.

Казакъ галиме Чокан Вәлиханов теркәп калдырган Идегәй белән Туктамыш турындагы риваятьнең Идегәй шәҗәрәсе мәгълүматларында да охшашлык бар[121]. Ә Идегәй турындагы дастанның төп өлеше «Чыңгызнамә»дә һәм Кадыйргали бәкнең «Җамигыт-тәварих» китабында бер төрле булуы – аерым сюжет һәм текст өлгеләренең күчешенә ачык дәлил.

«Чыңгызнамә» текстының кайбер татар бәетләренә дә турыдан-туры тәэсире булган. Мәсәлән, Газиз Гобәйдуллин «Чыңгызнамә» китабының вакаигънамәләр бүлеге турындагы тәфсилле мәкаләсе ахырына К.Насыйри календаренда чыккан «Казан бәете»нең өзеген күчереп, «хәтта аерым гыйбарәләре үк теге вакаигънамәне искә төшерүенә» игътибар юнәлткән[122].

Гомумән, 29 дүртьюллык күләмендәге ул тарихи бәетнең ун дүртьюллыгы (мәсәлән, без әзерләп чыгарган китаптагы «Казан алынган хакындагы бәет»нең 1, 2, 3, 11, 12, 14, 15, 17, 18, 29 нчы саннар белән билгеләнгәннәре[123]) «Чыңгызнамә»дән алынган дип шикләнмичә әйтергә мөмкин. Мәсәлән, Г.Гобәйдуллин мәкаләсендә дә әйтелгән:

Тарихы йите йөздә
Килде Тимер Болгарга,
Габдулла хан кулындан
Болгар шәһәрен алдыйа.

Ул бөлекнең соңында
Казан суы буенда,
Ике угылы килүбән
Казан шәһәрен салдыйа.

Болардан тыш, 3 нче дүртьюллыкта «Чыңгызнамә» текстына хас «ахры бары» сүзләре, шулай ук башка дүртьюллыклардагы тоткын Шыгалинең Казанга хан итеп куелуы, аның дарыга су коюы, мөселманнар «бихәбәр» булганлыгы, «Ошбу Зөйә тагында урыс кала салдыйа» кебек һ.б. текст өлешләре «Чыңгызнамә»дәге вакаигънамә бүлегенең турыдан-туры

---

[120] Тексты шушы китапта II вариантның «Беренче текст»ы буларак басылды.
[121] Сказание об Едигее и Токтамыше: киргизский текст по рукописи, принадлежавшей Ч.Ч.Валиханову, издал проф. П.М.Мелиоранский. – СПб: типо-лит. И.Бораганского и Ко, 1905. – 62 с.
[122] Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы. Феодализм дәвере..., 1925. – Б. 113.
[123] «Гәүһәр Болгарга килдем...»: тарихи бәетләр / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап», 2013. – Б. 91–95.

тәэсирен күрсәтеп тора. Бәетнең ахырындагы 29 нчы дүртьюллык бу рәвешле:

Тукыз йөз илле тукузда
Сычкан йылы иде анда,
Гакъръб икенче көнендә
Ибан-урыс алдыйа.

Әйтелгән бәетнең яулап алучыларга каршы көрәшкән каһарманнар турындагы өлешеннән калганы (монда күрсәтелгән дүртьюллыклар), фикеребезчә, «Чыңгызнамә» китабы тәэсирендә XVII гасыр ахыры – XVIII гасыр башында иҗат ителгән.

Югарыда әйтеп үтелгән сюжет күчешләрен истә тотканда, «Чыңгызнамә» китабындагы башка мәгълүматларның да бүтән чыганаклардан күчерелгән булуы ихтимал дип карарга кирәк.

Мисалга китерелгән күчмә өлгеләрнең бу китапта шактый булуы – аның борынгылыгын күрсәтү белән беррәттән, төрле дастан һәм бүтән риваятьләрне бергә җыеп туплаудан хасил китап икәнлегенә дә ишарә итә.

Кайбер күчмә сюжет мисаллары мәкаләбезнең башка бүлекләрендә дә бар.

Текстның I варианты

Безнең бу җыентыктагы төрле күләмгә ия текстларның гомуми саны 15 берәмлекне тәшкил итә һәм бөтенесе дә матбугатта беренче мәртәбә нәшер ителә. Алар текстологик үзенчәлекләренә күрә шартлы рәвештәге ике вариант итеп тәкъдим ителде. Гомумән, «Чыңгызнамә»нең күп кульязмаларда таралыш алган һәм XIX гасырдан башлап күп галимнәр өйрәнгән, шулай ук китап һәм матбугатта басылганнары, нигездә, исеме билгесез каләм әһеле тарафыннан җыйналып әдәби һәм текстологик эшкәртү кичергән бер үк вариантка нисбәтле. Андыйларны без II вариант дип билгеләдек. Ә «Чыңгызнамә»нең 1922 елда Гали Рәхим тарафыннан ачыкланган һәм гомуми мәгълүматы басылган, аннары бары тик соңгы заманда гына (XXI гасыр башында) яңадан игътибар бирелеп, өйрәнелгән, хәзерге вакытка бер генә күчермә нөсхәдә билгеле, башка текстлардан аермалысын шартлы рәвештә I вариант дип атадык.

«Чыңгызнамә»нең I вариант тексты теркәлгән кульязма, башка кыйммәтле язма истәлекләр белән бергә, Галимҗан Барудиның китапханәсе дәүләт оешмасына (Казандагы Мәркәз Шәрык көтепханәсенә) тапшырылганнан соң фән дөньясына танылган. Аны беренче мәртәбә Гали Рәхим 1922 елда ачыклаган һәм Г.Гобәйдуллин белән соавторлыктагы

«Татар әдәбияты тарихы» исемле, 1922 елгы китапта язган[124]. Кулъязмадагы «Җамигыт-тәварих»ка багышланган мәкаләсендә Г.Рәхим: «Кулъязманың ахырына «Дәфтәри Чиңгезнамә» сәрләүхәсе астында 20 битле бер хикәя теркәлгән. Бу хикәя Казанда басылган «Әхвале Чыңыз хан вә Аксак Тимер» дигән китапның бер кыйсеменең бераз гына үзгәртелгәне»[125] дип искәрткән. Китапның 35 битендә текстларда бераз аермалар барлыгын әйткән. Аннан соң төгәлрәк итеп Г.Рәхим түбәндәгечә язган: «Хәлфин бастырган нөсхә белән Баруди көтепханәсендә табылган нөсхәнең ахырларында аерма бар: Баруди нөсхәсендәге хикәя Чыңгызның арбага утырып иленә кайтуы белән тәмам булып, өзелеп кала. Аннан соңгы өч биттә асыл хикәягә тәгаллекы аз булган әйберләр хакында сөйләнә. Мәсәлән, Чыңгызның угылы Йүчи(Җүчи)нең нәселе һәм аларның тарихыннан кайбер вакыйгалар шикелле «дастан» дип башланган аерым бабта Чыңгыздан башлап төрле ханнарның көбә(тимер кием-?)ләренең исемнәре санала һәм «Үз йортыбызны җую» хакында бик матур сүзләр белән тәәссеф бәйан ителә. «Дастане мөддәт» аталган бабта «Имди ханларның йортларындин Кәф уралының» дип, кайсы «йорт» кайсы ханныкы булуы хакында сөйләнә. Бу баб Хәлфин нөсхәсендәге «Бишенче кыйсем»гә мокабилдер. Баруди нөсхәсендә Чыңгызның ханлыкка утыруы, аннан соңгы эшләре, бикләренә тамгалар вә башка билгеләр өләшүе хакында бер нәрсә юк. Ике нөсхә арасында кеше исемнәренең язылуында да беркадәр башкалык бар. Мәсәлән, Хәлфиннекендә «Җынгиз», Барудиныкында «Чыңгыз»; Чыңгызның угыллары Хәлфиннекендә «Йүҗи, Җәдай, Кирәй, Тули», Барудиныкында «Йүчи, Чәдай, Күкдай, Тули»; арба пире беренчесендә «Калдар би», икенчесендә «Балын угылы Кайулдар». Тимер хакында Баруди нөсхәсенең ахырында «Мир Тимер хан нәселләре болардур» сәрләүхәсе астында биш кенә юл язылган» дип, текстның ул өлеше күчереп басылган[126].

Шуннан соң әдәбият тарихы китабының 1925 елгы басмасы һәм Гали Рәхимнең рус телендә аерым мәкаләсе дөнья күргән[127]. Әлеге мәкалә «Җамигыт-тәварих»ка багышланган һәм шул ук кулъязма җыентыктагы «Чың-

---

[124] Үзендә басылу вакыты итеп 1922 ел күрсәтелгән ул китап, чынлыкта, 1923 елның гыйнварында чыккан.
[125] Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы. Беренче җилд: борынгы дәвер. Өченче бүлек..., 1922. – Б. 16.
[126] Шунда ук. – Б. 42–43. *Тәгаллекъ* – бәйләнеш; *тәәссеф* – үкенеч; *баб* – бүлек; *мокабил* – тиңдәш.
[127] Рахим А. О новом списке татарского исторического сочинения XVII века // Вестник Научного общества татароведения. №7. – Казань: издание Академического центра Татнаркомпроса, 1927. – С 133–148; То же // Гали Рәхим: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык..., 2008. – Б. 193–213.

гызнамә» турында ике кечкенә абзацта әйтелгән. Г.Рәхим кульязма ахырындагы 20 биттә «Дәфтәри Чыңгызнамә» тексты теркәлгән булуын язып, күрәсең, кульязманы күчергән кешенең кул астында кәгазе булмаганга, Чыңгыз хан нәселе турындагы беренче бүлеген генә күчергән, ә Аксак Тимергә берничә юл гына багышланган дип искәрткән. Русча мәкаләгә өстәп кульязманың ике битеннән фотокүчермә дә бирелгән.

1922 елда ачыкланган кульязманың шул ук елда өйрәнелеп, фәнни әйләнешкә кертелү оперативлыгы, һичшиксез, зур соклану тудыра[128]. Әмма «Чыңгызнамә»нең бу күчермәсе турында Г.Рәхимнең киңрәк язган 1922 ел басмасындагы мәгълүматы 1925 елда чыккан «Татар әдәбияты тарихы»ның икенче басмасында һәм 1927 елгы рус телендәге мәкаләсендә тулы хәлендә кабатланмаган, кыскача берничә җөмлә белән генә чикләнгән. Бу, әлбәттә, үз чорының сәяси-иҗтимагый үзенчәлекләре белән бәйле. Ягъни, коммунистик идеологиянең елдан-ел көчәеп баруы нәтиҗәсендә югары эксплуататор сыйныфына, ханнарга, кансыз хакимнәргә багышланган борынгы әсәрләргә мөнәсәбәт катгый үзгәргән. Шул ук Г.Рәхим белән Газиз Гобәйдуллин язган «Татар әдәбияты тарихы» хезмәтенең 1922 елгы һәм 1925 елгы басмаларында ук иҗтимагый-сәяси үзгәреш сизелеп тора[129].

---

[128] Бу уңайдан Ибраһим Хәлфиннең 1827 елда ук тарихи хезмәт язган булуы турында моннан ярты гасыр элек үк А.Фәтхинең тасвирламасында мәгълүмат чыкканын искә төшерик. Рус телендә 2013 елда дөнья күргән җидетомлык татар тарихы китапларының бары тик берсендә – VI томында XIX гасыр башында Казан университетында эшләгән галим И.Хәлфин турында махсус мәкалә булса да, анда Хәлфиннең тарихи әсәре турында бер сүз дә юк *(История татар с древнейших времён. В семи томах. Т. VI: формирование татарской нации: XIX–начало XX вв. – Казань, 2013. – С. 745–746, 788)*. Югыйсә, татар тарихын Ш.Мәрҗанигә хәтле үк чын фәнни нигездә өйрәнә башлаган, университетта эшләгән татар галиме турында тулырак язылган булса, тарихи яктан дөрес булыр һәм җидетомлыкның мәртәбәсе дә күтәрелер иде. Һәрхәлдә, Татарстан һәм Россия, хәтта мәшһүр чит ил галимнәре катнашкан, Республиканың Фәннәр академиясе исеменнән нәшер ителгән фундаменталь хезмәттә мәгълүматның тулы булуы зарур. Бу очракта, замандаш галимнәребезнең татар телендәге төрле дәвер чыганаклар, татарча басылган фәнни хезмәтләр, китаплар һәм мәкаләләр белән эш итүдә чикләнгәнлеге һәм, бигрәк тә илтифатсызлыгы, сәбәпче.

[129] Боларга өстәп китап авторларының социаль чыгышлары – эшче-крестьяннарга дошман буржуаз сыйныфтан (бай-сәүдәгәрләрдән) булулары да зур комачау тудырганлыгын истә тотарга кирәк. 1922–1925 елларда – Г.Рәхим белән Г.Гобәйдуллинның иң актив гыйльми эшчәнлекләре чорында республиканың үзәк матбугатында шактый тупас мәкаләләр нәшер ителә башлаган һәм 1930 елга таба көчәйгән *(Сәгъди Г. Әдәбият тарихымы, язмалар тарихымы? // Безнең юл. – 1923. – №12. – Б. 40–44; Сәгъди Г. «Татар әдәбияты тарихы»ндагы хаталар // Мәгариф. – 1925. – №8. – Б. 86–93, №9. – Б. 107–123; Сәгъди Г. Татар әдәбиятын тикшерүдә кайбер хаталар // Безнең юл. – 1927. – №1. – Б. 24–28, №2. – Б. 35–38*

Авторлар үзләре белдергәнчә, әдәбият тарихының нәкъ шул томы буенча аерым «нәмүнәлек» (хрестоматия) бастыру күздә тотылганга[130], мисалларга киң тукталмаганнар. Моны замана идеологиясе белән бәйле рәвештә кайбер мәсьәләләрне яктыртудан тыелганнар дип тә аңларга кирәк.

«Чыңгызнамә» текстының үзенчәлекле күчермәсе сакланган кульъязмага Г.Рәхимнән соң мөрәҗәгать иткән галимнәр кыскача искәртеп үтү белән генә чикләнгәннәр, аның үзенчәлекләре булуын әйтмәгәннәр.

Мәсьәләне тәфсилләп өйрәнгән Миркасыйм Госманов хезмәтендә дә мәгълүмат аз. Анда кульъязманың кыскача тасвиры бирелеп, «Җамигыттәварих»тан соң калган буш битләргә бер үк кул белән Чыңгыз хан, Тимерләң һ.б. турында билгеле дастаннарның башлангыч өлешләре язылган диелгән[131]. «Чыңгыз» дастаны бүлегенең «башлангыч өлеше» дигән сүз дөреслеккә туры килми. Чөнки бу күчермәдә аның яртысыннан күбрәк өлеше язылган. Аксак Тимер турындагы дастан башы дигәне дә туры килеп бетми. Башка дастан-бүлекләр бөтенләй бүтәнчә, ягъни «Чыңгызнамә»нең киң таралган II вариантындагы бүлекләр кебек түгел диярлек. М.Госманов китабының 102 битендә «Т40» шифрлы кульъязмада әсәрнең I бүлегенең тулы булмаган тексты язылганлыгы, шулай ук 104 биттә аның иң элекке күчермәләрдән берсе (1732 елгы) икәнлеге күрсәтелгән. Әмма М.Госмановның «Первая глава в ней также начинается со слов: «Теперь дафтар Чингиз-хана» дигәне ялгыш. Чөнки башка күчермәләрдә әлеге җөмлә «Имди Чыңыз ханның дәфтәре» дип башланган булса, «40т» күчермәсендә ул бүтәнчәрәк: «Дәфтәрнең әүвәл башындин сөйләйәлек» диелгән.

Әдәбият галиме Шакир Абилов «Чыңгызнамә» турында язганда сүз

һ.б.). Гали Рәхим 1921 елда ук татар әдәбияты тарихына багышланган лекциясенә бәйләп, ул заман өчен аеруча куркынычлы сүз белән – «контрреволюционер» дип бәяләнгән *(«Мөхбир». Халыкны ник агулыйлар? // Татарстан хәбәрләре. – 1921. – 4 июль).* Академүзәк кушуы буенча әзерләнгән «Татар әдәбияты тарихы» китаплары басылып чыкканчы әлеге гыйльми оешманың җитәкчесе Галимҗан Ибраһимов аларның эчтәлекләре белән таныш булган һәм рецензияләгән. Әмма «Татар әдәбияты тарихының» ике китабы чыккач та, ул үзе үк тарихи-әдәби үсешнең марксистик яссылыкта бирелмәвен тәнкыйть иткән *(Ибраһимов Г. Татар әдәбияты тарихына материаллар // Татарстан. – 1923. – 6 февраль).* Танылган татар галиме, Г.Рәхимнең фикердәше һәм туганы Газиз Гобәйдуллин эзәрлекләүләр нәтиҗәсендә 1925 елда Бакуга күчеп китәргә мәҗбүр булган. Г.Рәхим 1931 елда буржуаз милләтче буларак кулга алынып, биш елга хөкем ителгән, аннан соң 1937 елда яңадан репрессияләнгән.

[130] Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы. Беренче җилд: борынгы дәвер. Өченче бүлек..., 1922. – Б. V.

[131] Усманов М. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв..., 1972. – С. 36.

уңаеннан: «Т40» санлы КДУ кулъязмасында беренче дастан белән елъязмалар гына бар»[132] дип язып үткән. Ләкин кулъязмада беренче дастан тексты тулы түгел һәм анда елъязмалар өлеше юк.

Шул рәвешле, Гали Рәхим 1922 елгы китапта язган мәгълүматтан соң, «40т» шифрлы кулъязмадагы «Чыңгызнамә»нең башка текстлардан аермалы булуына тиешенчә әһәмият бирелмәгән.

***

Гали Рәхимнең алда искәртеп үтелгән фәнни өлгерлеге сәбәбеннәндер, М.Госманов «Җамигыт-тәварих» һәм «Чыңгызнамә» турында язганда «Татар әдәбияты тарихы»ның 1922 елда чыккан басмасына мөрәҗәгать итмәгән. Һәрхәлдә, аның хезмәтендә кулланылган әдәбият исемлегендә дә, астөшермәдә дә ул китапның исеме юк, фәкать 1925 елгы басма гына бар. Ә анысында, әйткәнебезчә, «Чыңгызнамә»нең Баруди китапханәсеннән кергән күчермәсе турында мәгълүмат аз. Әмма А.Фәтхинең 1968 елгы кулъязмалар тасвирламасында «Җамигыт-тәварих» һәм «Чыңгызнамә» текстлары булган «40т» шифрлы ядкәр турында «бу нөсхә тасвирланган, тикшерелгән» дип, «Татар әдәбияты тарихы»ның ике басмасы һәм Г.Рәхимнең русча мәкаләсе күрсәтелгән[133]. Шул ук тасвирламада И.Хәлфин автографлары турындагы мәгълүматта да «40т» кулъязмасы искә алынып, «Татар әдәбияты тарихы» китаплары аталган. Менә боларга галимнәрнең игътибары җитмәгән.

Бәлки 1968 елгы тасвирлама китабы тоткарлык белән басылган һәм М.Госманов хезмәте 1972 елда нәшер ителгәнче тоткарлангандыр дияргә дә урын юк. Чөнки, Госманов китабында кулланылган әдәбият «Библиография»сендә 1968 елда нәшер ителгән бер китап (207 биттә) һәм 1969 елда чыккан дүрт китап (205, 209, 211 һәм 214 битләрдә) исеме кергән. Тик алар арасында А.Фәтхи хезмәте юк. Вәләкин М.Госманов китабында Мөслиминең «Тәварихы Болгарийә» әсәре уңаеннан 136 биттәге астөшермәдә 1968 елгы тасвирламасына бәйле рәвештә А.Фәтхи карашы телгә алынган. Китапның 159 битендә Т.Ялчыгол әсәре турында язганда А.Фәтхинең шул ук тасвиры икенче мәртәбә искә алынып, астөшермәдә сылтама бирелгән. Госманов китабында шактый уңай бәяләнгән «Җамигыт-тәварих» һәм «Дәфтәри Чыңгызнамә» турында язганда шул әсәрләрнең тасвирлары булган Фәтхи хезмәте бөтенләй телгә алынмаган хәлдә, Мөслими белән Ялчыгол китаплары рәхимсез тәнкыйтькә дучар ителгән бүлекләрдә генә Фәтхигә сылтама бирелүе сәер манзара тудыра. Өстәвенә,

[132] Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. Т. I: урта гасырлар дәвере..., 1984. – Б. 348.
[133] Кулъязмалар тасвирламасы. XII чыгарылыш..., 1968. – Б. 18.

А.Фәтхи тасвирламаларының өч чыгарылышына (шул исәптән, 1968 елгы басмага) карата М.Госманов махсус мәкалә язган[134]. Анда, аерым алганда, «төзүче ... иң әһәмиятле махсус әдәбият исемлеген тәкъдим итә, ягъни мәсьәлә белән якыннан кызыксынган кешеләр өчен кайдан нәрсә эзләргә кирәклеген күрсәтә» дигән юллар бар һәм 1968 елгы басмада кульязмалары тасвирланган шәхесләр арасында И.Хәлфин фамилиясе дә аталган. 1968 елда дөнья күргән тасвирламага галим Әнвәр Шәриповның 1970 ел башында чыккан рецензиясендә шулай ук «Ибраһим Хәлфин кульязмалары да... тасвирланган» дигән мәгълүмат бар[135]. Менә боларны исәпкә алганда, бер яктан, тарихчы галимнең нинди принциплар нигезендә эш йөрткәнлеге аптырашта калдырса, икенче җәһәттән, тасвирлама мәгълүматларына тиешле игътибар бирелсә, Госмановның үз фәнни хезмәте тагын да камилрәк булыр иде дигән фикергә этәрә.

***

Тарихчы Ильяс Мөстәкыймов бу текстның моңарчы билгеле булган башкаларыннан аермалы һәм үзенчәлекле булуын матбугат аша фән дөньясына киңрәк рәвештә таныттты[136]. И.Мөстәкыймов мәкаләсендә әлеге кульязма җыентыкны беренче булып тәфсилләп Гали Рәхим өйрәнгән булуы әйтелгән[137]. Аннан соң Казан федераль университетының Фәнни китапханәсендә «40т» шифры белән саклана торган, 1732 елга караган данлыклы кульязмага М.Сәфәргалиев, М.Госманов, И.Галәветдинов (күбрәк «Җамигыт-тәварих» тексты өчен) мөрәҗәгать иткәнен язган. Мөстәкыймов «Чыңгызнамә»нең бу күчермәсен аерым вариант дип атый, аның тексты тулы түгел һәм урыны белән буталчык булса да, Җучи Олысы тарихы өчен билгесез һәм аз билгеле мәгълүматларга ия икәнлеген яза. Ул шулай ук әлеге текстны эчтәлеге һәм композициясе ягыннан «Дәфтәри Чыңгызнамә»нең башка күчермәләреннән шактый аерылып тора, ди. Чыңгыз хан турындагы хикәяттә тулы булмаган унлап дастан фрагменты бар, шулардан 8 дастанны якынча чамалап була (шулардан өчесенең генә

[134] Госманов М. Файдалы хезмәт // Казан утлары. – 1969. – №7. – Б. 179–181.

[135] Шәрипов Ә. Борынгы кульязмалар илендә // Совет мәктәбе. – 1970. – №2. – Б. 61–62.

[136] Мустакимов И. Об одном списке «Дафтар-и Чингиз-наме» // Средневековые тюрко-татарские государства. Вып. 1. – Казань, 2009. – С. 122–131.

[137] И.Мөстәкыймов бу мәкаләсендә Г.Рәхимнең рус телендәге (1927 ел) мәкаләсенә генә ишарә итүенә караганда, 1922 елгы китап мәгълүматына әһәмият бирмәгән һәм моңа элгәреге галимнәрнең «оперативлыгы» сәбәпче булгандыр. Ягъни, 1922 елда ачыкланган кульязма турында шул ук елда чыккан китапта нәрсәдер язылган булу мөмкинлеге күз алдына китерелмәгәндер.

исемнәре күрсәтелгән, икесе исемсез һәм текстта өчесенең фрагментларын эчтәлекләре буенча гына аерып карарга мөмкин дип яза И.Мөстәкыймов.

«Чыңгызнамә»нең башка текстларыннан аермалы урыннар дип, И.Мөстәкыймов бу кулъязмада «монгол» этнотопонимы (бүтәннәрдә: «калмак»), Чыңгыз ханның бер кардәше Кагынҗар «катаган» ыруының башы (башкаларда: Хатай, Хытай) булганын һәм Чыңгыз ханның арбасына биләр алтын тәхетен урнаштыруны күрсәткән.

Мәкалә авторы бу кулъязмадагы дастан текстларының бер өлеше Үтәмеш хаҗиның 1550 елгы хезмәте, авторы билгесез «Тәварихы гөзидә...» (1502–1504 еллар) һәм Әбелгазыйның 1665 елгы әсәрләренә аваздаш булуын белдереп, ханнар һәм бикләргә бәйле чагыштырулар үткәргән.

Кулъязманың 78а кәгазендәге Җанибәк хан заманындагы бикләрнең исемнәре язылган өлеше, тарихи әһәмияте ягыннан И.Мөстәкыймов мәкаләсендә башка чыганаклар белән чагыштырылып, җентекләп анализланган (мәкаләнең яртысыннан күбрәк өлеше шул мәсьәләгә багышланган).

«Дәфтәри Чыңгызнамә» күчермәсенең шул ук 78а һәм 78б кәгазьләрендәге ханнарның көбәләре турындагы өлеше аеруча кызыклы. Мөстәкыймов билгеле булган бүтән текстларда «көбә» сүзе урынына «савыт» сүзе кулланылганын әйтеп, бу кулъязмада исемнәре саналган ханнарны төркемләп күрсәткән. Алар: бөтен монгол ханы Чыңгыз хан; Алтын Урда ханнары Йүчи, Саин һ.б.; Казан ханнары Ибраһим, Сафагәрәй, Шаһгали; Әстерхан ханнары Аккүбәк белән Ямгырчы; Себер ханнары Күчем, Гали, Әхмәтгәрәй; казакъ(?) хакимнәре Касыйм хан, Иркилде солтан, Аваз хан; легендар һәм ярымлегендар Бартак, Тугалы, Бүләр һәм Самәт.

«Текст ахырында Туктамыш, Йүчи һәм Чыңгыз хан улларының исемнәре күрсәтелгән мәгълүматта яңалык булмаса да, Туктамышның ике улын Кырымга хан итеп куюлары турындагы хәбәр тарихи әһәмияткә ия», – дип яза мәкалә авторы.

Мәкалә ахырында «Дәфтәри Чыңгызнамә»нең бу күчермәсендә башка нөсхәләрдә булмаган гаять кызыклы һәм мөһим мәгълүматлар теркәлгән булуын ассызыклап, И.Мөстәкыймов әлеге кулъязмадагы текст әсәрнең әүвәлгерәк редакциясе булуы ихтимал дигән фаразын белдергән. Мәкалә авторы шулай ук, алда әйтеп үтелгән тарихи әсәрләр белән охшашлыгын искәртеп, бу күчермәдә телдән сөйләнгән риваятьләр һәм Алтын Урда тарихына багышланган, әмма хәзергәчә килеп ирешмәгән язма чыганаклар да кулланылган булса кирәк, ди. Мәкаләнең кушымтасында төрле чыганаклар нигезендә Туктамыш уллары һәм Җүчи улларының исемнәре күрсәтелгән чагыштырма өч таблица урын алган. Гомумән, Ильяс

Мөстәкыймов тарафыннан «Дәфтәри Чыңгызнамә»нең әлеге варианты тарихи яктан шактый җентекләп тикшерелгән.

Татар тарихына багышланган җидетомлыкның дүртенче томында И.Мөстәкыймов «Дәфтәри Чыңгызнамә»нең әлеге күчермәсе турында язып, аны әсәрнең башка версиясе (яки редакциясе) сыйфатында искә алды[138]. Ул шунда ук Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты мирасханәсендә дә шул версиягә охшаш дефектлы бер күчермә саклануын белдерде, анысында башка кульязмаларда очрамаган, Әстерхан ханлыгы турындагы мәгълүматлар барлыгын язды.

***

Моннан унбиш еллар элек Гали Рәхимгә багышланган китапка[139] материаллар туплаганда университет китапханәсендәге «Чыңгызнамә» тексты башкача булуы безнең дә игътибарны җәлеп иткән иде.

Әлеге кульязманы өстән-өстәнрәк кенә күздән кичергән вакытта Чыңгыз хан турындагы дастанның текстындагы аермаларны күреп җиткермәскә мөмкин. Әмма игътибар белән укыганда текстның бүтәнчә икәнлеген чамалау кыен түгел. II варианттагысы белән чагыштырганда бу текстта сүзләр-гыйбарәләр һәм атама-исемнәрнең аермалы икәнлеге, шулай ук өстәмә җөмләләр булуы күренә. Текстның кайбер өлешләре бүтәнчәлеге белән бергә, кыскарак яисә киңрәк хикәяләнгән урыннары бар. Ыру-кабилә исемнәре сизелерлек күп аталган. Кайбер җөмләләр эшкәртелмәгән кебек һәм аңлаешсызрак булуы да күзгә ташлана. (Андый кимчелекләрнең бер өлеше кульязма күчергән кешеләрнең игътибар дәрәҗәсенә бәйле).

Беренче вариант текстындагы архаиклашкан *ку, төукерсә, баганагы, бугаз, сыу* кебек сүзләр һәм язылышлар икенче вариант текстларында *коруг, төкерсә, баягы, буаз, су* дип теркәлгән. I варианттагы мирас булып калган алтынлы-көмешле билбау мәгънәсендәге – «курлы кур» архаиклашканга күрә II вариантта «футаллы фута»га (ялтыравыклы-алтынлы билбауга) алыштырылган. Дөрес, анысы да хәзерге заман өчен искергән гыйбарә. Шулай ук I варианттагы борынгы язылышка ия «Торгу» тавы икенче вариант текстларында «Тора», беренчедәге «углан» сүзе икенчесендә «бала», «тулуг» сүзе «тәрәзә», «күк кәбтәр» гыйбарәсе «күк күгәрчен»

---

[138] История татар с древнейших времён. В семи томах. Т. IV: Татарские государства XV–XVIII вв. – Казань, 2014. – С. 15.

[139] Гали Рәхим: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык..., 2008. – 480 б.

диелгән. Беренче вариант текстында Чыңгыз нурдан яралган дип язылган булса, икенче вариантта «нурдан-Кояшдан» диелгән.

Гомумән, ике текстта аермалы урыннар шактый, берсендә булган җөмләләр икенчесендә юк. Мәсәлән, I вариантта дастан башында Голәмәлик өчен «кырык колач алтын сарай төзеделәр» диелсә, икенче вариант текстларында ул «таш сарай» итеп тасвирланган. II вариант текстларында Тумавыл Голәмәликкә «сөйүгемнең нишаны» (мәхәббәтем билгесе) дип белдергән агач, кош һәм тамга турында I вариантта язылмаган.

Беренче вариант текстында Дуйын-Бәйанның халыкка әйткән васыять сүзләренең бер өлеше икенче вариантта Голәмәлик тарафыннан әйтелгән итеп кушылган һәм текст мәгънәсе бераз үзгәргән. Беренче вариантта Голәмәлик Дуйын-Бәйанга хакимлек итәргә мөмкинлек булсын дип теләп, аның энеләре Бүдәнәтай белән Бөлгүтайны читкә җибәрүен Тумавыл Мәргәннән сораган. Аларны маңгулга җибәрәләр, Тумавыл Мәргән үлгәч Дуйын-Бәйан хан булып кала, Алаңгу белән икесенең өч уллары: Бүдәнҗар, Кагынҗар һәм Салҗут дөньяга килә. Дуйын-Бәйан үләр алдыннан халыкка васыять итеп үзенең шул өч улы хан тәхетенә лаек түгеллеген әйткән һәм вафат булганнан соң яктылык булып иңеп, Алаңгу йөккә узачагын һәм бер угыллары туачагын белдергән. Ә Дуйын-Бәйанның үз уллары ханлыкка ярамавы турында әйткән сүзләре II вариант текстларында Бүдәнәтай белән Билгүтайга карата Голәмәлик сүзләре буларак үзгәртелгән һәм шул сәбәпле текстка буталчык кергән.

I вариант текстында Дуйын-Бәйан вафат булгач, аның энеләре Бүдәнәтай белән Бөлгүтай җиңгәләре Алаңгуның хәсрәтен уртаклашырга киләләр. Кайтып китәргә җыенгач, Алаңгу үзенең өч улына үгет-киңәш бирүләрен сорый. Алар бик төпле киңәшләрен биреп кайтып киткәннәр. Ягъни, Бүдәнәтай белән Бөлгүтай ипле-төпле һәм бик акыллы буларак тасвирланган. (Гомумән, аларның нәсихәтләре Чыңгыз ханның кагыйдә-киңәш сүзләренә охшаш).

Икенче вариантта да алар шул рәвештә үк диярлек тасвирланган, бары тик Голәмәлик авызыннан әйтелгән «Үзе хәлен белмәсләр, күзе малга туймаслар...» дип, Бүдәнәтай белән Билгүтайны яманланган юллар гына текстның ямен бозып һәм мәгънәсен үзгәртеп, буталчык тудырган. Моны тулырак күзаллар өчен Голәмәлик сүзләренең дастан тексты вариантларында ничек булганлыгына игътибар итик.

I вариант	*II вариант*
Қоланға ийәргән – чәчәккә аунар, Дуңызға ийәргән – балчықға аунар. Сән хан баласы ирдең Мән сәнгә ийәреб ни күрдүм?	Қоланға ийәргән – чәчәккә аунар, Дуңузға ийәргән – балчықға аунар. Сән хан уғылы дәгелсән, Йортқа лайық дәгелсән, – дийерләр. Үзе хәлен белмәсләр Күзе малға туймаслар. Бу Бүдәнәтай, Билгүтай Йортқа лайық ирмәсләр. Мән арслан баласы ирүрмән, Сезгә килеб нә күрүдүм?

Чыңгыз хан нәселе турындагы дастанның ике төрле варианты эчтәлекләрендәге менә бу җитди аерма төп мәсьәләгә ачыклык кертә. Ягъни, I вариант дастанның борынгырак текстын тәшкил итә, ә II вариант тексты борынгысын үзгәртүдән хасил булганлыгы ачык аңлашыла. Иске вариант текстындагы бер җөмләнең урынын күчереп, аңа кеше исемнәрен өстәүдән аңлашылмаслык дәрәҗәдәге бутау килеп чыккан. Менә бу очрак – кульязманы күчергән кешеләр үзгәртүенә генә бәйле түгел, ә текстны эшкәрткән каләм иясенең кимчелеге. Чөнки II вариант күчермәләренең ул өлеше сакланган кульязмаларда Голәмәлик әйткән сүзләрдә зур аермалар юк.

Дастанның мәгънәсенә андый ук дәрәҗәдә зарар китерерлек булмаса да, ике варианттагы текстларның тезмә белән бирелгән өлешләрендә аермалар бар.

I вариантта Чыңгыз анасына Көргүрлән[140] дигән таудагы «йыш кара йыгач»та торачагын әйткән. Ә II вариант текстларында Көргүрлән дигән «кара тауның башында биш-алты агач» рәвешендә язылган. Болардан беренче вариантта «еш кара агач» – «куе кара урман», зур урман дигән мәгънәне белдерсә, икенче вариантта «кара» (биек, зур) мәгънәсе тауга нисбәт ителеп, агачлары санаулы гына итеп язылган.

Беренче вариант текстында Чыңгыз хан бикләрдән ничә ыру белән бергә булуларын сораганда икегә бүленеп (аргысы һәм биргесе дип), барлыгы 20 ыру исеме аталган. Ә икенче вариант текстында ыру исемнәре саналмыйча, «тугыз ырудан» дип кенә әйтелгән. Менә бу очракта да төгәл ыру атамалары күрсәтелгән текст варианты әүвәлгерәк булганлыгы һәм инде

[140] Рәшидеддиннең «Җамигыт-тәварих» әсәрендә Чыңгыз ханның төп «йорты» (ватаны) Келуран (хәзерге Монголиядәге Керулен) елгасы тирәсендә дигән мәгълүмат бар.

күбесе онытылып, архаиклашкан ыру-кабилә исемнәрен санаудан мәгънә күрелмәгәнгәдер, исәбе генә әйтелгән вариант соңгырак дип аңлашыла.

Гомумән, беренче вариант текстындагы Чыңгыз хан нәселенә багышланган дастанда утызлап ыру һәм кабилә исемнәре теркәлгән: кыйат, моңгул, катаган, салҗут, төмән маңгыт, төрекмән, кыбчак, йөз, маңгыт, тәләңүт, чыгытай, кирәйәт, оңут, оргут, арнау, тама, барлас, уйсын һ.б. Шул ук тексттагы Җанибәк хан заманындагы бикләрнең исемнәре язылган икенче дастанда 16 ыру исеме теркәлгән: маңытай, уйшын, алчын, ак маңгыт, инҗеле, сиҗут, кыбчак, ширин, аргын, барын, боркыт, җәлайыр һ.б. Ә икенче вариантның Чыңгыз хан нәселе турындагы дастанда бары тик алты төрле ыру-кабилә: төрекмән, кыйат, калмак, катай, салҗут, үзбәк исемнәре генә язылган. Дөрес, ул текстта бикләрнең исемнәре ыру исемнәренә тәңгәл яки аваздаш булганнары да бар. Тик алар кеше исемнәре рәвешендә, хәтта Уйшын Майкы бикнең үз исеме булып киткән «Уйшын» дигән өлеше, шулай ук Кыбчак исеме дә ыру исеме буларак тасвирланмаган.

Ике варианттагы текстларда да Чыңгыз ханның бикләре белән табышу куанычыннан мәҗлес оештырганлыгы турында язылган. Беренче вариантта «төкәнмәс аракы, бал, чагыр, шәраб, сүнмәс чырак торур» дип тасвирлангач, Чыңгыз хан: «Бу аракы берлә чагыр-шәраб безгә нәрсә бирмәсдүр!» дигән һәм бикләре аны хуплаган. Икенче вариант текстында эчемлекләрнең төрләре саналмыйча, бары тик «төрлү шәрабләр эчтеләр» диелгән. Бу мисал да, үз нәүбәтендә, беренче вариант текстының әүвәлгерәк булуына бер дәлил дип карарга кирәк. Ягъни, мөселманнарга дин буенча тыелган исертеч эчемлекләр турындагы тасвир өлеше соңрак бераз йомшартыла төшкән[141].

Текстлардагы тагын бер җитди аермага тукталыйк. I вариант текстында Чыңгыз хан үзен эзләп килгән бикләргә мөрәҗәгать итеп атларны җибәрик ди, ә II вариантта бикләр үзләре атларын иреккә җибәргәннәр. Гади генә фикер йөрткәндә дә, иерархия буенча өстенлеккә ия ханнан узып, бикләр андый карар кабул итәр идеме дигән сорау туа. Димәк, I вариант текстындагы бу эпизод мантыйкый яктан дөресрәк икәнлеге күренә.

Чыңгыз хан нәселенә багышланган дастанның ике төрле вариант текстларындагы аермалы урыннарның тагын кайберләренә игътибар итик.

---

[141] Моңа берникадәр охшаш – шәригать өйрәтмәләренә хилаф шәраб эчү һәм башка маҗараларның «Мәликә китабы»ның борынгырак текстларында (мәсәлән, XVII гасыр ахыры күчермәсендә) булып та, соңрак төшереп калдырылуына игътибар иткән идек *(Дастане җәйә (Мәликә китабы) / төз. Р.Мәрданов. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2017. – Б. 30)*.

I вариант	*II вариант*
...бу ике уғылын моңғулға йибәрде, дай хашқадан йитешәр хашқа қуштылар. Бу ике уғул моңғулға киттеләр *(72а кәгазь)*	...ике уғылы Бүдәнәтай, Билгүтайны қалмаққа ийәбәрде, тәқи икесенә йитешәр нөгәр қушты. Улар қалмақда барыб мәқам-йорт тоттылар *(Икенче текст, 3а кәгазь)*
...Дуйын-Бәйанға қыз алды. Нур тағында Кәнти дигән шәһәр бар ирде, ул шәһәрдә йите солтан бар ирде, анларның иң кечесе Толунсул дигәннең қызын алдылар. Ул қызның аты Аланғу дигән ирде *(72а–72б кәгазьләр)*	...Дуйын-Бәйанға қыз алдылар. Алтун хан нәселендән йите солтан бар ирде, аның кечесе Төлүкле дигән ирде. Аның қызы Аланғуны... *(Икенче текст, 3б кәгазь)*
төңлүкдән көн булуб инәрмән, ишекдин бүре булуб чықармән *(72б кәгазь)*	көн булуб инәрмән, бүре булуб чықармән *(Икенче текст, 4а кәгазь)*
ил инанғудай кешедән өч кеше бар ирде: бересе – төрекмән Килмөхәммәд дигән ирде, андин бересе – қыбчақ Қарабай дигән ирде, йәнә бересе йөз Уравыж дигән ирде *(74б кәгазь)*	өч кешенең атлары болардур: берсе – Қыбчақ дигән ирде, икенчесе – Килмөхәммәд дигән ирде, өчүнчесе Урдач дигән ирде *(Өченче текст, 25б кәгазь)*
тулуғдан ингән көнгә қурлы қурыңызны салыңыз *(75б кәгазь)*	тәрәзәдән төшкән көнгә футаллы футаңызны салыңыз *(Икенче текст, 13а кәгазь)*
Өч уғул: берсе йөзнең булур ирде, берсе маңғытның, берсе «ақтуған» оранлы илнең булур ирде. Бу өч уғул берлә қазақ киттеләр *(76а кәгазь)*	қазақ чықыб китәйен тиб киңәш итеб, бер ике-өч йегет үзенә ийәртеб, анасы Аланғуға килде *(Икенче текст, 13б кәгазь)*

I вариант күчермәсендә, әйткәнебезчә, Чыңгыз турындагы дастанның ахыры юк. Аннан соң кечерәк күләмле тагын берничә текст (икесе – «дастан» дип исемләнеп) язылган. Аларның ханнар һәм бикләрнең исемнәре саналган өлеше «Чыңгызнамә»нең бүтән (II вариант) күчермәләрендә юк. Ә ханнарның көбәләре турындагы дастан башка текстлардагыга аваздаш булса да, монда күпчелеге тарихта исемнәре билгеле ханнарга бәйләп әйтелгән. Ә II вариант текстларында исә, шундый ук исемнәрдәге

көбә-савытлар Чыңгыз хан тарафыннан бикләренә махсус бирелгән рәвештә хикәяләнә.

Исемсез бер кыйтгада хан дәүләтенең шәүкәтле заманы узганга уфтанулы тезмә дастан фрагменты бик кызыклы. II вариант текстларында бусының чалымнары да юк диярлек. Бары тик «Амәт-Сәлимәт ханның заманында тай тулаб тәхет бозулды» дигән юллар II вариантның Аксак Тимергә багышланган дастанындагы «әл-кыйсса»ларның берсенә аваздаш. «Әл-кыйсса»да Аксак Тимер явы якынлашканда күчеп китү вакытындагы бер күренеш тасвирланган. Анда бер карчыкның тирмәсен бәйләгән каеш өзелеп, ыгы-зыгы чыгып, «тай дулады, йылкы өрүкте» дип һәм халык та төрле якка тузып, ул арада Аксак Тимер гаскәре ябырылып, тар-мар итүе хикәяләнгән. Аннан соң Амәт белән Самәтне Аксак Тимер мөселманлыкка күндергән. I вариант текстында тай дулап тәхет бозылу турындагы сүзләрдә якынлашкан яудан куркып, үзара паникага бирелүдән килеп чыккан дип аңлашыла[142].

«Дастане мөддәт» дип аталган бүлекчә ханнар биләмәсе турында II вариант текстларында бишенче бүлек буларак исәпләнгән текст кебек дияргә мөмкин. Ләкин кайбер аермалы урыннары бар.

Ахырдагы кечкенә мәгълүматларда Туктамыш хан уллары, Йүчи хан уллары, Чыңгыз ханның дүрт улы һәм Мир Тимер хан нәселләре турында кыскача теркәлгән. Соңгысында Аксак Тимернең берничә буын бабасының исемнәре язылган. Аксак Тимер турында, ихтимал, шундый рәвештәге генә мәгълүмат та язып йөртелгәндер.

Чыңгыз улларының исемнәре II варианттагыча ук түгеллегенә Г.Рәхим игътибар иткәнлеген язып үткән идек. «Күкдай (Күгдәй)» рәвешендәге язылыш, чынлыкта, «Үгедәй» исеменең башындагы «ү» авазын белдергән «әлиф» һәм «уау» хәрефләрен күчергәндәге ялгышлыктан килеп чыккан. Ягъни, «әлиф» хәрефенең түбәнге очы сулгарак борып язылуы сәбәпле «уау»га кушылган һәм күчерүче кеше «кәф»нең кыйгач сызыксыман элементы төшеп калган дип кабул иткән, шул рәвешле «кү» иҗеге хасил булган[143]. Үгедәй исеменең II вариант текстларында исем башындагы

[142] Борынгы чорларда ук киң популярлык алган «Мең дә бер кичә» китабының «Гомәр ибне Ногман патша һәм аның уллары...» әкиятендә карчык, бүрек, ат һәм ком бураны күтәрелү турындагы эпизодны искә алганда, монда күчмә сюжет чалымнары да бар *(Мең дә бер кичә. – Казан: Татар. китап нәшр., 1970. – Б. 112).*

[143] Моны нәкъ шушы кульязманы күчергән кеше ялгыш язган дигән сүз түгел. Ихтимал, аның протографында ук шул рәвештә язылган булгандыр. Дөрес, әлеге кульязмадагы «әлиф» хәрефләренең дә аскы очлары сулгарак борылып, кайбер очракларда «ра» хәрефенә охшап, үзеннән соң килгән хәрефләргә ялганып-орынып торуы күзәтелә һәм моңа азмы-күпме протограф йогынтысы да булгандыр дип фаразларга мөмкин.

«әлиф» белән «уау»ның күчермәләрдә бөтенләй төшеп калуыннан һәм «дәл» хәрефен «ра»га охшатып «К.р.ә.й.» (Кирәй) дигән язудан килеп чыкканын да искәртик. I вариант текстындагы Кайулдар исеме II вариант текстларында Калдар буларак язылуында да «йу» иҗегенең төшеп калуы сәбәпче булган. (Борынгырак чыганакларда, мәсәлән, Әбелгазый хезмәтендә, Чыңгыз хан заманындагы Койулдар исеме теркәлгән).

Беренче вариант кулъязмасында көбәләрнең ханнар исемнәренә бәйләп һәм аерым дастан рәвешендә язылган булуына караганда, ул, күрәсең, иске кулъязма җыентыкларда шул рәвешле теркәп йөртелгән мөстәкыйль бер кыйтга булгандыр. Ә берничә дастанга шундый аерым кыйтга-парчаларны да кушып эшкәртеп, бербөтен текст (II вариант) рәвешенә китергән кеше әлеге көбә исемнәрен Чыңгыз турындагы дастанга өстәп, андагы бикләр исемнәренә бәйләп җибәргәндер дип фаразларга мөмкин. М.Госмановның моны күчергән кешеләр тарафыннан кертелгән үзгәреш булса кирәк дип каравы[144] ышанычлы түгел. Әгәр дә көбәләр турындагы текст өлеше, дастан дип аерым исемләнмичә, тоташ хикәяләү рәвешендә бирелеп, бикләр исеме урынына ханнар язылган булса, Госманов фикере белән килешергә дә булыр иде.

I вариант текстында Чыңгыз ханның шәҗәрәсе булмавын да әйтергә кирәк. Дөрес, текстның алдында бер бит ярым урын (69б һәм 70а кәгазьнең яртысы) язылмыйча буш калган. Текстны күчергән кеше аннан алда – 69а кәгазьдә язылып төгәлләнгән «Җамигыт-тәварих»тан аерылып торсын өченме яисә бүтән сәбәптәнме буш урын калдырган. «Чыңгызнамә»нең бу кулъязмага күчерелгән протографта шәҗәрә өлеше булып та, ул дефектлы яисә тулы түгеллегенә бәйле рәвештә буш урын калдырылган дип тә уйларга мөмкин. Һәрхәлдә, моңа төгәл җавап табарга читен. Бәлки бу кулъязманың 77б кәгазендәге Чыңгыз ханның үзеннән башлап дәвам иткән шәҗәрә өлеше II вариант текстларындагы күләмле шәҗәрә язмасының башлангычы сыйфатында өстәлгәндер. Баруди кулъязмасы варианты текстында шәҗәрә булмауны күздә тотып, Гали Рәхим дә: «вакаигънамә вә шәҗәрә шикелле әйберләрнең исә күчерүчеләр тарафыннан соңыннан дәвам иттерелүләре бик мөмкин вә була торган эш» дип аңлаткан[145].

---

144 Усманов М. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв..., 1972. – С. 110.

145 Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы. Феодализм дәвере..., 1925. – Б. 92. Чыңгыз хан нәселе шәҗәрәсенең XVII гасыр уртасына кадәр дәвам иткән варианты «Чыңгызнамә»не аерым китап итеп оештырган вакытта иң алга соңрак өстәлгән булуы мөмкин. Гомумән, электән үк Нух пәйгамбәрдән дәвам итеп килгән шәҗәрә баштарак Чыңгыз һәм аның улларына кадәр язылган булып, вакытлар узган саен буыннар өстәлә баруы бик ихтимал. Моңа дәлил итеп Солтанморатның 1727 елгы хатын китерергә мөмкин. Анда «Чыңгызнамә» күчермәләрендә язып йөртелгән

Язганнарны йомгаклап, «Чыңгызнамә»нең беренче вариант күчермәсендәге Чыңгыз хан турындагы дастанның сакланган хәтле өлеше башка күчермәләрдән аермалы булуы, шулай ук анда бүтән кульязмаларда бөтенләй булмаган текст өлешләре теркәлүе – «40т» шифрлы язма истәлектә тарихи темага караган төрле текстларның тупланганын күрсәтә. Әлеге кульязма, гомумән, элекке дәвердәге, аерым бер кеше тарафыннан эшкәртелмәгән вариантның хәзергәчә килеп ирешкән бер күчермәсе дип әйтергә мөмкин. Ә нәкъ шундый – төрле чыганаклардан алынган тарихи мәгълүматлар һәм тарихи риваятьләр-хикәятләр бергә туплап язып йөртелгән җыентыкларның берсе оста каләм иясе кулына кереп, эшкәртелүе сәбәпле күчермәләре күп таралган. Беренче вариант кульязмасындагы архаик сүзләрнең күбрәк булуы, кайбер җөмләләр һәм аерым вакыйгаларның корама-кытыршырак телдә, борынгы чордагы ыру-кабилә исемнәренең шулай ук искергәнлеге һәм онытылып баруы сәбәпле, II нче вариант текстын әзерләгән кеше андыйларны, мөмкин кадәр төшереп калдырган дип аңлашыла. Һәрхәлдә, II вариант тексты әүвәлгерәк булып, I вариантныкы соңгырак дип каралса, архаиклык һәм искелекләрнең ул текстка кемдер тарафыннан өстәлгән булу ихтималы мантыйкка ярашмый.

Әйтелгән «40т» шифрлы кульязмадагы «Дәфтәри Чыңгызнамә»нең Чыңгыз хан дастаны (күләме ягыннан башка текстлар белән чагыштырганда, тулы текстның яртысыннан бераз гына артыграк) һәм аннан соңгы бер-берсенә бәйсез кечерәк күләмле дастан-бүлекчәләр тарихка караган төрле чыганаклардан күчерелгән мәҗмуга характерында булганлыгы ачыграк күренә.

Киләчәктә I вариант текстының башка күчермәләре тулырак хәлдә яисә өзек-фрагмент рәвешендә табылуы да мөмкин.

Бу вариантның бердәнбер күчермәсендә хаталы язулар да бар һәм шуңа күрә, кайбер сүзләрнең төгәл мәгънәсенә төшенмичә, безнең тарафтан ялгыш укылышлар да калгандыр.

II вариант текстлары

Бу җыентыкта безнең тарафтан шартлы рәвештә икенче вариант дип тәгаенләнгән төрле күләмдәге 14 текст урын алды. Аларның күпчелеге (2, 5–8, 10–14 саннары белән билгеләнгәннәре) Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә саклана торган, шулай ук Татарстан Милли

XVII гасыр уртасындагы Борһансолтаннан исемнәр дәвам итеп арттырылган. «Чыңгызнамә» текстының ахыргы бүлегендәге тарихи вакыйгаларны соңгырак күчерүчеләр дәвам итеп язып барулары да мондый фаразны куәтли. Чөнки шәҗәрә өлеше, биләмәләр һәм вакаигънамә бүлекләре дәвамлы мәгълүматка хас күренеш.

музее һәм башка урыннардагы кульъязмалардан алынды. Һәрберсенең төп саклану урыны турында мәгълүмат текст янында күрсәтелде. Шулай ук бу җыентыкка текстлары кергән күчермәләрнең тасвирламасы китап ахырында аерым тупланды. Монда исә җыентыктагы текстларның башка төр үзенчәлекләренә тукталабыз.

II вариант текстларыннан «Беренче» дип аталганында Чыңгыз ханның шәҗәрә өлеше, «Икенче» дип билгеләнгәнендә (аерым өзеклекләре булса да) «Чыңгызнамә»нең бөтен бүлекләре бар. Гомумән, бу китапта Чыңгыз хан нәселенә багышланган дастан – дүрт текстта, Аксак Тимер турындагы дастан – биш текстта, Гайса улы Амәт һәм Идегәй турындагы дастаннар – ике текстта, ханнарның биләмәләренә багышланган дастан – биш текстта һәм тарих (елъязма) бүлеге – җиде текстта (төрле – тулы яисә тулы булмаган күләмдә) урын алган. Шулардан төгәл даталары билгеле булганнарының иң элеккеләре: 1727 елга караган «Беренче текст», төгәл елы билгесезләрдән «Дүртенче текст» XVII гасыр кәгазенә XVIII гасыр башында күчерелгән һәм «Тугызынчы текст» та XVIII йөз башына нисбәтле.

Бу варианттагы «Беренче текст» – Чыңгыз хан турындагы дастан башындагы шәҗәрә өлеше – Сенатның яшерен тикшерү эшендә сакланган хат текстыннан алынды. Ул XVIII гасырның беренче яртысында Россия империясенең көнчыгыштагы колонизация сәясәтенә каршы татар-башкорт хәрәкәте җитәкчеләреннән берсе Солтанморат Көчек улының Казакъ ханы Әбелхәергә 1727 елда юллаган күләмле хатында язылган. Әлеге текст фрагменты Россия дәүләт борынгы актлар архивындагы күләмле эштә (248 фонд, 17 тасвир, 1164 саклану берәмлегендә) сакланган. Солтанморат хатының башында үзенең затлы токымнан, Чыңгыз хан нәселенә нисбәтле булуының дәлиле итеп «Дәфтәри Чыңгызнамә»дәге шәҗәрә текстын китергән. Чыңгыз ханга кадәрге буыннары уйдырма булган шәҗәрә Солтанморатка һәм аның агасы белән энесенә кадәр дәвам иттерелгән.

Бу хат Мәсгуд Гайнетдинов мәкаләләрендә «Чыңгызнамә»нең халыкны көрәшкә әйдәгән «казакъ чыгып китү», баш күтәрү кирәклегенә өндәгән дип язуының бер чагылышы дияргә мөмкин. Хатта «казакълык» каһарманлыгы һәм ихтыяҗы өлешләренә ишарә ителмәсә дә, уйдырма шәҗәрәнең кулланылуы – аның халыкка тәэсирен раслый. Тарихи шәхесләрнең ярым мифик нәсел шәҗәрәләре үз чорларында аерым бер ният белән уйлап чыгарылган һәм төрле максатларда кулланылган. Солтанморатның хатында шундый уйдырма шәҗәрәгә бәйләнешле мисалны күрәбез. «Чыңгызнамә»дәге (һәм «Җамигыт-тәварих» әсәрендәге) Идегәй

бинең уйдырма шәҗәрәсе дә аның асылзат икәнлеген дәлилләү максатына яраклаштырылган[146].

Мәскәү архивындагы шул ук эштәге XVIII гасыр башына караган «Чыңгызнамә» күчермәсе (Идегәйгә багышланган бүлекнең ахыргы өлеше һәм аннан соңгы ике бүлеге) бу китапта «Тугызынчы текст» дип аталып тәкъдим ителде. Аларның рус теленә 1737 елда тәрҗемә ителгән өлешендә хаталары булса да, кайбер өстәмәләр һәм аңлатмалары кызыклы. Русчага тәрҗемәсе кулъязмалар тасвирламасында бирелде.

Китапта «Икенче текст» дип билгеләнгән, XIX гасыр башына караган кулъязма тексты, дефектлары һәм өзеклекләре булса да, башкалар белән чагыштырганда тулырак һәм камилрәк.

«Икенче текст»тагы Чыңгыз ханның биләренә әйткән: «Имди бу көндин соң сез – мәнең, мән – сезнең тиде!» – җөмләсе башка текстлардагыдан тулырак. Чөнки шул ук җөмлә «Өченче текст»та «Имди бу көндин соң сезнеңмән!», ә «Дүртенче текст»та «Имди бу көндин соң сез – мәнеңсез!» дип язылган.

«Икенче текст»тагы Аксак Тимер дастанының башында «Әмма Хакъ Тәгаләнең тәкъдире нитәк булса – андаг булур» дигән җөмлә тулырак һәм төгәлрәк. Чөнки өченче һәм бишенче текстлардагы «Әмма Хакъ Тәгаләнең тәкъдире нитәк булур», «Алтынчы текст» кулъязмасында да шуңа охшаш, «Җиденче текст»та һәм 1822 елгы китапта «Хакъ Тәгаләнең тәкъдире нитәк бозулур» (62 биттә), 1882 ел басмасында (24 биттә) «Хакъ Тәгаләнең тәкъдире нитәк бозур», ә 2002 елгы китапның транскрипциясендә (64 биттә) «Хакъ Тәгаләнең тәкъдире нәтәк бузулур» дип басылган.

Аксак Тимернең Хаҗитарханнан Болгарны алырга зур гаскәр белән күп көймәләрдә килүе турында хикәяләгәндә бу китаптагы икенче, бишенче, алтынчы һәм җиденче текстларда «ошбу Идел суының тыш йагындан килделәр» (ягъни, яр буйлап) дигән җөмлә бар. Ул 1822 елгы басмада «кайсысы суның тыш йакындан килделәр» дип, 1882 елгы китапта (30 биттә) хаталы рәвештә «орушуб ул сәфәрнең тыш йагындан килделәр» буларак,

[146] Ерак гасырлар катламындагы уйдырма нәсел тармаклары төп дәлил итеп файдаланылуына бик гаҗәпләнәсе дә юк. Чөнки, электән килгән бай традиция әзсез югалмаган, ул соңгы замангача иске шәҗәрәләрдәге ялгышларга ияреп алданулар, хәтта аерым затларның нәсел җепләрен, дәлилсез-нисез генә фаразлап, үткән тарихтагы ханнарга һәм морзаларга, Г.Тукай кебек мәшһүрләргә ялгап кую күренеше дәвам итә. Тарихи дәлил-расламалар табу мөмкинлеге булган хәлдә дә, хәзерге заманның мифлаштыру шаукымы шактый зарарлы. Уйдырмаларга ышанып хаталанучылар, суфыйчылык силсиләсен шәҗәрә дип буталучылар да күренгәли. Хәзерге чорда шундый ялгышлар булуын исәпкә алганда, өч гасыр элеккеге Солтанморатлар заманындагы хикмәтләргә аптырарлык түгел.

2011 елгы китапта да (85 биттә) шулай ук диярлек, фәкать «сәфәрнең» сүзе «шәһәрнең» дип төзәтелеп, ә хәзерге әдәби телгә күчермәсендә (60 бит) «кайбер сугышчылары шәһәрне алырга көймәнең тышыннан килделәр» рәвешендә (аңлаешсыз мәгънәдә) басылган. 2002 ел китабының транскрипция текстында Идел атамасы бөтенләй юк, ә «ошбу чәрү киши-ләри сув-нынг таш йагындан...» дип бирелгән. Ләкин шул текстка нигез итеп алынган «О» нөсхә кулъязма факсимилесендә (241 биттә) тексттагы юл арасында һәм бит читендә дә: «Ошбу Идүл суының» дигән өстәмә теркәлгән.

Икенче һәм алтынчы текстлардагы Аксак Тимер дастанының ахырындагы кыйссада «бер кортканың тирмә айылы өзүлде» дигәндә «айылы» сүзе бүтән күчермәләрдә һәм басмаларда башкачарак. Мәсәлән, «Бишенче текст» кулъязмасында ул «иде» дип ялгыш теркәлгән. Хәлфин басмасында (81 биттә) «иве» дип, ә 1882 елгы китапта «йавы» һәм 2011 елда чыккан китапта (63, 87 битләрдә) «бавы» дип бирелгән. 2002 елгы китапның транскрипциясендә (80 биттә) «бавы (терки бавы)» рәвешендә басылган. Ә шул китаптагы өч кулъязма факсимилеләрендә (244, 280 һәм 319 битләрдә) «тирмә ийүе» дип язылган. Чагыштырулардан күренүенчә, бездәге «Икенче текст»тагы «айыл» сүзе дөресрәк. Бу очрактагы «аел» сүзе – ияр-ыңгырчак бавы дигәнне белдерә[147].

«Икенче текст»тагы Амәт дастанында Салчы турында сүз барганда «эчемлекле-ашамлыклы» мәгънәсендәге «эчкеле-йигеле» парлы сүзе 1882 елгы китапта (40 биттә) «Ичкәйекле» дип, 2011 елгы китапта (90 биттә) «Өчкийекле», хәзерге телгә күчермәсендә исә (66 биттә) «Өчкиекле дигән җирдә» рәвешендә, географик атамага әверелеп киткән.

Җыентыкка «Өченче текст» буларак тәкъдим ителгәне бу юлларның авторында саклана торган кулъязмадан алынды. Андагы Чыңгыз хан нәселенә һәм Аксак Тимергә багышланган дастаннар тулы булмасалар да, үзенчәлекле урыннары бар. Әлеге текст кулъязмасында тамга рәсемнәре кызыл төстәге кара белән ясалганлыгы да кызыклы.

Китаптагы «Дүртенче текст» элек З.Максудова карамагында булган, хәзер исә Татарстан Республикасының Милли музеенда (Максудова фондында) саклана торган кулъязмадан алынды[148]. М.Госманов хезмәтендә дефектлы күчермә буларак телгә алынган әлеге кулъязмада Чыңгыз хан нәселе турындагы дастан теркәлгән. Сакланышы начар булса да, бу күчермә XVIII йөз башына караган иң элекке текстларның берсе булуы ягыннан

[147] Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда. Т. I: А–Й. – Казан: Татар. китап нәшр., 1977. – Б. 22.
[148] Бу кулъязманың текстын шактый еллар элек күчереп алган идем.

һәм кайбер борынгы сүзләргә карата З.Максудованың искәрмәләре белән әһәмиятле.

Әлеге текстта Чыңгыз хан Бөртә Кучынны чакырткач, бу хатынның затлы киемнәргә киенүен хикәяләгәндә башмагын сыйфатлаган бер сүз бүтән текстларда төрлечә һәм аңлаешсыз. Ул «Икенче текст»та «ал бәрәң башмакы», Хәлфин китабында (48 биттә) «ал йефәк пашматы»[149], 1882 елгы басмада (17 биттә) «ал рәнк башмакы», 2002 елда чыккан китапта (54 биттә) «ал йефәк пашматы» диелгән (астөшермәсендә башка кулъязмаларда да төрлечә икәнлеге күрсәтелгән). Ә XVIII гасыр башына караган «Дүртенче текст»та ул сүз «һәбәрәң башмакы» дип язылган һәм кулъязманың иясе З.Максудова аңлаешсыз «һәбәрәң» сүзенә «шагрень күн»[150] дигән аңлатмасын теркәгән.

Бу текстта Чыңгыз ханның «...йөз мең үлүмлеләр азад булсун!» дигән сүзләрендә «үлемлеләр» сүзе үлемгә дучар ителгән кешеләр дип аңлашыла. «Икенче текст»та «үлүмле» дигәндә дә шул ук мәгънәдә. Әмма «Өченче текст»та һәм 1882 елгы китапта (18 бит) «үлүмдин», 2002 елгы басмада (55 бит) «үлүмдән» дигән очраклар төгәл мәгънәне биреп бетерми.

XVIII гасыр ахыры кулъязмаларындагы бишенче, алтынчы текстларда һәм XIX гасыр башына нисбәтле «Җиденче текст»та Аксак Тимергә багышланган дастаннар урын алды. «Алтынчы текст» башкалардан җиңелрәк һәм бераз ирекләрәк хикәяләнүе белән аерылып тора. Ул урыны белән (мәсәлән, ахыры) кыскача булса, кайбер өстәп язылган сүзләре һәм өлешләре дә бар. Анда хикәяләү-тасвирлар гадирәк, «Әй, бай!» дип, бүтән текстларда булмаганча эндәш сүзләр очрый. Бүтән текстлардагы «йегетләр» сүзе «йаранлар», «өйләренә» сүзе «авылларына», «бараҗ» дигәне «барча» рәвешләрендә үзгәргән һ.б.

«Җиденче текст»та, сирәк булса да, өстәлгән сүзләр бар, кайбер архаик гыйбарәләр дә үзгәртелгән (мәсәлән, «алысдан» сүзе урынына «ерактан» дип язылган). Дастанда Җадәш бикнең гаиләсен һәм кардәшләрен Аксак Тимер азат итү турында беренче зат (гүяки, Җадәш бик хатыны) исеменнән «...тәмам угылымыз-кызымыз, карендәшләремез берлә йарлыкаб йибәрде» дип хикәяләнүе башка күчермәләрдә очрамый. Шулай ук Инсан биктән дәвам иткән нәсел буыннары бүтәннәрдән аермалы.

«Сигезенче текст»та XVIII гасыр ахырына караган кулъязмадан Амәт дастаны фрагменты күчереп басылды.

Җыентыктагы «Унынчы текст»та (XIX гасыр) «Чыңгызнамә»нең

[149] Хәлфин китабының сүзлегендә «пашматы»ның аңлатмасы юк.
[150] «Шагрень» – гадәттә, ат тиресеннән эшләнгән, кытыршы өслекле йомшак күн дигәнне белдерә.

соңгы ике бүлеге язылган. Алар Мөслиминең «Тәварихы Болгарийә» һәм Таҗетдин Ялчыголның «Тарихнамәи Болгар» һәм башка китаплардагы мәгълүматлар белән аралаш һәм бераз бутабрак язылган[151].

«Унберенче текст» ахыргы ике дастаннан тора. Алар 1885 елда күчерелгәннәр. Анда ханнарның биләмәләре турындагы мәгълүматта башка күчермәләрдән аермалы урыннары бар. Мәсәлән, «Җайык арасы – Чыңгыз хан йорты» диелгән. Башка текстларның берсендә дә андый язма юк. Бүтән текстлардагы Актүбә урынына «Ак Идүл төбә», «Уфа тамагы» урынына «Уфа Идүленең тамагы» дип язылган.

Уникенче сан белән билгеләнгән, XVIII гасыр ахыры кулъязмасыннан алынган текст «Дастане тарих» бүлегенең фрагменты.

Китаптагы «Унөченче текст» 1870 елгы кулъязма җыентык эчендә И.Хәлфин басмасыннан күчерелгән ахыргы ике бүлектән гыйбарәт. Әлеге текстның кулъязмасында Хәлфин Казаный китабыннан күчерелде дип ишарә ителгән булса да, аны Хәлфин басмасы белән чагыштырып карагач, үзгәрешләрнең шактый икәнлеге ачыкланды. Текстологик аермаларның бөтенесен дә нәкъ шушы кулъязманы күчергән кешегә нисбәт итү дөрес булып бетмәскә мөмкин. Чөнки, ул үзе турыдан-туры Хәлфин басмасыннан күчермичә, электәнрәк һәм, ихтимал, берничә мәртәбә күчерелгәндә үзгәрешләргә дучар булган протограф белән эш иткәндер.

Гомумән, бу кулъязма текстында җөмләләр төрле зурлыктагы үзгәрешләр кичергән һәм аларның бозылмаганнары санаулы гына. Кайбер очракларда җөмләдәге сүзләрнең һәм сүзтезмәләрнең урыннары алыштырылган. Кулъязмада төшеп калган аерым җөмләләр булуы белән бергә, кыскартылган сүзтезмәләр һәм махсус үзгәртелгән гыйбарәләр шактый. Мәсәлән, бишенче бүлектә Сарайчык һәм Инҗер турындагы җөмләләр, алтынчы бүлектә «Җанали йагы» турындагы җөмлә юк. Хәлфин китабында «Кыйсме садис фи бәйани тарих» дип исемләнгән алтынчы бүлекнең исеме, киресенчә, басмада булмаган рәвештә, «Мир Тимер хәзрәтләре шәһри Болгарны алдугы бәйанында» дип тулыландырылган. Аксак Тимер исеме текстта да «мир Тимер хәзрәте» рәвешендә теркәлгән. Басма китаптагы «Җим-Җайык» атамасы кулъязмада «Җайык» дип, «Алмалы Атага тигрү» дигәне «Алмалыгача» рәвешендә язылган. Басмадагы борынгы грамматик формалардан «торур» сүзе «дыр» кисәкчәсенә алыштырылган (мәсәлән, «йорты торур» – «йортыдыр». Шулай ук архаиклашкан «өртен» сүзе кулъ-

[151] Мондый характердагы, үзара кушып һәм бутап язылган күчермәләр булуы турында Гали Рәхим һәм Газиз Гобәйдуллин да искәрткәннәр. Казан университеты китапханәсендәге XIX гасырга караган «587т» һәм «1388т» шифрлы кулъязмалар да шундый рәвештә.

язмада «яшерен» дип, «чирү» сүзе кайбер очракларда «гаскәр» дип, «адлары», «сукуб», «җәнарал» сүзләре «исемләре», «дөзәйүб», «генерал» дип үзгәртелгән. «Чыңгызнамә» текстында еш очрый торган «ахры бар» гыйбарәсе әлеге кульязмада «ахрел-әмер»гә алыштырылган. Шул сәбәпле, Хәлфин басмасындагы «ахры бар, Хованский дигән байар» дип басылган сүзләр кульязмага күчергәндә буталып, «Барханский дигән байар» рәвешенә кергән. Казан ханнарын санаганда «андин соң», «соңра», «вә андин» кебек сүзләр кульязмада бөтенләй төшереп калдырылган. Шул ук вакытта, тарихи вакыйгаларны бәян иткәндә «тарих» сүзе алдына һәр очракта «йәнә» сүзе өстәлгән. Басмадагы «татарлар» атамасы кульязмада «мөселманнар» дип бирелгән.

Басма китап һәм «Унөченче текст» кульязмасы арасындагы аермалардан аңлашылуынча, 1870 елда кульязманы күчергән Хәйретдин мулла Фәхретдин улы (яки аннан элгәреге протографны күчергән зат) «Чыңгызнамә»нең бүтән күчермәләре белән дә таныш булган дип фаразларга мөмкин. Кайбер текстологик үзенчәлекләр шундый фикергә этәрә. Әйтик, Хәлфин басмасындагы «татарлар» дигән атама әлеге һәм, гомумән, башка кульязмаларда да «мөселманнар» дип теркәлгән. Басма китаптагы һиҗри 1089 елгы вакыйганы тасвирлаганда «рус вә мөэмин» сүзләре кульязмада «мөэмин, кяферләр» рәвешендә, ягъни башка кульязмалардагыча («кяфер һәм мөэмин», «кяфер, мөэмин») бирелгән. Бөтен күчермәләрдә (шул исәптән, сүз бара торган «Унөченче текст»нықында да) тарихи вакыйгаларның еллары «тарих мең дә...» рәвешендә, ягъни «дә» кисәкчәсе белән язылган. Ә Хәлфин басмасында әлеге кисәкчә төшереп калдырылган. Гомумән, бу җыентыктагы «Унөченче текст» татар археографиясе тарихында билгеле күренеш – басма китапның яңадан кульязма рәвешендә нөсхәләре таралуының дәлиле һәм, шуның белән берлектә, текстларның ни дәрәҗәдә үзгәртелүләргә дучар булганының ачык күрсәткече.

«Ундүртенче текст» – тарихи вакыйгалар турындагы бүлекнең XX гасыр башында теркәлгән фрагменты. Ләкин ул мәгълүм текстларга тулаем тәңгәл килеп бетми. Шуңа карамастан, «Чыңгызнамә»нең әлеге фрагменты аның соңгы чор күчермәләреннән берсе булуы ягыннан игътибарга лаек[152].

---

[152] Казан университеты китапханәсендә «2495т» шифры белән саклана торган, «Чыңгызнамә» текстының фрагменты теркәлгән 1968 елгы кульязма дәфтәр иң соңгы күчермәдер, мөгаен. Анда «Чыңгызнамә» тексты, Мөслими һәм Таҗетдин Ялчыгол әсәрләренең аерым өлешләре белән бергә аралашкан хәлдә, шулай ук шәҗәрә язмалары теркәлгән. «Чыңгызнамә» текстыннан алынган өлешләре: Чыңгыз ханның дөньяга килүе, ханлыкка утыруы, гомере һәм вафаты турында; Чыңгыз ханны эзләп барган бикләрнең исемнәре; Чыңгыз ханның Урдач бигә тәгаен кылган атрибутлары. Бу дәфтәр тексты Марсель Әхмәтҗанов китабында

Чыңгыз нәселенә багышланган дастанда Бөртә Кучын яшереп калган дүрт ир баланың яшьләре кулъязма һәм басма текстларда терлечәрәк күрсәтелгәнен дә искәртергә кирәк.

Барлык текстларда да төшеп калган яки артык язылган сүзләр, язылмыйча калган җөмләләр, бүтәнчә кыскарган урыннары бар. Болар һәммәсе – бөтен төр кулъязмаларга хас күренеш. Шул ук вакытта һәр текстта бүтәннәрендә кабатланмаган сүзләр һәм гыйбарәләр очрый. Андыйларның элеккерәк күчермәләрдә булып, соңгырак чорларныкында төшеп калганнары яки, киресенчә, күчергән кешеләрнең өстәмәләре дә бар.

Исемнәр, атамалар

«Чыңгызнамә» китабындагы Алтын хан, Дуйын-Бәйан, Бөртә-Кучын, Алаңгу, Бүдәнҗар, Билгетай һ.б. исемнәр Чыңгыз хан нәселенә һәм монгол-татар тарихына багышланган әүвәлге әсәрләрдә, язма тарихи истәлекләрдә очрый һәм кабатлана (Дубун-Бәйан, Бурта-Фуҗын, Алангуа һ.б. рәвешләрдә). Әмма Чыңгыз хан нәселе турындагы бу китап текстында андый исемнәр булса да, алар чын тарих белән һәм исемнәре аталган шәхесләрнең чынлыкта булган гамәлләренә тәңгәл килми, чөнки дастаннар – халыкның хыялый фантазиясе иҗаты.

Китап текстында кешеләр, ыру һәм кабилә исемнәре, географик атамалар шактый. Шулардан иң әүвәл Чыңгыз исеменең чыганакларда һәм хәзерге язылышта бирелүенә тукталыйк. Бу исем чыганакларда гарәп хәрефләре белән «Ч.н.к.з.» рәвешендә, еш кына «ч» урнына «җ» хәрефе белән язылган. «Ч» һәм «җ» хәрефләренең иске татар язмаларында параллель һәм чиратлашып кулланылуы мәгълүм күренеш. Иске текстларда йомшак «г» хәрефе урынына еш кына «к» хәрефе язып йөртелгән, ә «н» белән «к» – икесе бергә «ң» хәрефен дә белдергәннәр. Тартык авазларны белдергән «Чнкз» хәрефләреннән хасил исем русча текстларда «Чингиз» (кайчакта: Джингиз) дигән язылышы кабул ителгән. Әмма татар телендә электән алып хәзергәчә бу исем Чыңгыз рәвешендә әйтелгән. Шул сәбәпле, йомшак «г» авазы белән «Чингиз» дип әйтелеш татарчага ятышмавын истә тотып һәм «Чнкз» буларак язылган исемне татарларның барысы да диярлек Чыңыз рәвешендә укыганлыгын исәпкә алып, бу җыентыктагы текстларда шулай бирдек. (Без әлеге исемнең үз заманында һәм үз җирлегендәге яңгыраш, әйтелеш һәм язылышы турында сүз алып бармыйбыз, ә татар язма истәлеге

«Коңгырат нәсел шәҗәрәсенең бер версиясе» дип исемләнеп («Чыңгызнамә»гә бәйлелеге искәртелмәгән хәлдә һәм ялгыш 1965 елгы дип) бастырылды *(Әхмәтҗанов М. Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы..., 2002. – Б. 93–94)*.

буларак, татар чыганакларындагы язылышын һәм татар телендәге әйтелешен күздә тотабыз). «Чыңгызнамә» китабында «...нкз» хәрефләре янәшә килгән бүтән сүзләрдә, мәсәлән, «килдеңез» сүзе шулай ук язылган. Ләкин ул да «нг» буларак укылмый.

I вариант текстының башында бу исем ике «кәф» (к) хәрефе белән язылган һәм аны «Чыңгиз» дип укырга мөмкин[153]. Ә аннан соң шул ук текстның бөтен урынында да «гайн» (каты «гъ») хәрефе белән «Чыңгыз» дип аерымачык язылган[154]. Совет чорында татарча китапларда еш кына, русча текстлардагыча, Чингиз дип һәм китап исеме дә «Чингизнамә» рәвешендә язылган булуын мәкаләнең алдагы бүлекләрендәге мисалларда күреп үттек. Ә элекке хезмәтләрдә I вариант кулъязмасы турында сүз барганда бер үк китапның бер үк битендә төрлечә: «Җенеккез-намә», «җенкиз-намә» һәм «ченкезнамә» дип, шактый гарипләтелгән язылышлар да булган[155].

Чыңгыз рәвешендәге язылыш XIX гасыр һәм XX гасыр башы кулъязмаларында, тарихчыларның хезмәтләрендә дә бар.

Чыңгыз хан турындагы дастан текстында иң абруйлы бикләрнең берсе буларак тасвирланган кеше I вариант текстында Уравыҗ дип, ә II вариант текстларында күбрәк Урдач (шулай ук Урдаҗ, Урадач һәм Урадыҗ рәвешләрендәге) язылышы башлангычта бер үк исемнән үзгәргән. Аның гарәп язуындагы «дәл» һәм «уау» хәрефләренең берникадәр охшаш язылышыннан төрләнеп киткәнлеге аңлашыла. Бу исем 1882 елгы китапта (11 бит) «Уруч (Оруч)» дип басылуы да шуңа бәйле. Төрле текстларда һәм кулъязмаларда Боркыт би исеме дә төрлечә: Йөрүтә яки Җорката дип, ә Муйтан исеменең Мутйан, Мүтйән рәвешләрендә язылышлары очрый.

I вариантта көбәләр турындагы дастанда Сәлмәт дип, аннан соң-

[153] Миркасыйм Госманов I вариантта китап исемендәге ике «к» хәрефе белән язылышка карата бер «к» яисә ике «к» булуда зур аерма юк, «ңг» яки «нг» дип язылырга да мөмкин дигән *(Усманов М. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв..., 1972. – С. 105)*.

[154] Шул ук кулъязма җыентыктагы «Җамигыт-тәварих» текстында тоташтан «Чыңгиз» дип (ике «кәф» белән) язылган булуын искәртергә кирәк. Ә аңа турыдан-туры Рәшидеддин әсәрендәге «Чыңгиз» язылышы күчкәнлеге Березин әзерләп бастырган текстан аңлашыла. Бер үк кеше тарафыннан күчерелгән күләмле «Җамигыт-тәварих» текстындагы бик күп очраган «Чыңгиз» язылышы җыентыкның ахырындагы «Дәфтәри Чыңгизнамә»нең исемендә генә шулай язылганлыгы баштагы әсәр тәэсирендә генә булган. Ягъни, бу кәгазь-язу эше белән мәшгуль хәзерге кешеләрнең һәммәсенә таныш очракка охшаш – бер үк елның саннарын 12 ай дәвамында язып килгәч, яңа елның гыйнвар башында да, инерция белән дигәндәй, иске ел датасын язу күренешен хәтерләтә.

[155] Борынгы татар әдәбияты..., 1963. – Б. 468.

гы тезмә текстта Амәт-Сәлимәт дип язылган исем II вариантта Амәт һәм Самәт буларак теркәлгән.

Бу китаптагы II вариантның 1727 елга караган «Беренче текст»ында бирелгән шәҗәрәдәге исемнәр хәрәкәләр белән язылганга һәм, гомумән, башка билгеле кулъязма һәм басмалардан аермалы исемнәр булуы белән үзенчәлекле. Дөрес, арада төшеп калганнары да бар. Мәсәлән, Нух пәйгамбәр кызларының исемнәре басма текстлардагы[156] белән хәрефкә-хәреф туры килми. Хәрәкәләр белән Өвүз хан дип язылган исем башка китапларда Аваз яки Авыз дип басылган. Шәҗәрәнең ахырындарак язылган Туктамыш хан һәм Алтун хан исемнәре басмаларда юк. Шәҗәрәдә Туктамыш хан Бортак ханның улы, ә Алтун хан Туктагы ханның улы буларак теркәлгән.

Өченче һәм дүртенче текстларда Чыңгыз хан улы Тулиның исеме Туни һәм Тулин рәвешләрендә язылган.

Чыңгыз турындагы дастанда Голәмәлик дигән хатын-кыз исеменең гарәпчә язылышында бөтен хәрефләр дә куелмаганлыктан, аның хәзерге татар язуында бирелеше төрлечә булырга мөмкин. Шуңа күрә китапларда ул Гыйләмалик, Галәмәлик, Галәммалик һ.б. рәвешләрдә басылды. Без Голәмәлик вариантына тукталдык.

«Чыңгызнамә»дәге кайбер хакимнәрнең һәм шәҗәрә язмаларындагы исемнәргә тукталыйк. Аксак Тимер турындагы дастанда Болгар бикләре дип «Икенче текст»та язылган Икъбал, Кол Гали, Хәваши, Мыркаш исемнәре бүтән күчермәләрдә бераз башкачарак язылган. Мәсәлән, бишенче һәм алтынчы текстларда Хәваш, «Бишенче текст»та Мыркашый һәм «Алтынчы текст»та Акбал диелгән. «Җиденче текст»та бу исемнәрнең икесе генә һәм алары да бик бозылып: Кабал һәм Мукаш дип теркәлгән.

Аксак Тимер атасы һәм бабалары дип язылган исемнәр шулай ук төрлечә, мәсәлән, I вариантта: Олукчы, Йарукчы һәм Дарагай, II вариантның икенче һәм бишенче текстларында: Каракчы, Казычы, Олукчы, Тавукчы, Таракчы, Тарагай, ә «Өченче текст»та: Казакчы, Потчы, Олукчы, Тавукчы, Тухчы, Тарагай. Ә бу китапта тексты басылмаган, Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә «2057т» шифры белән саклана торган кулъязма фрагментында бу нәсел буыннары: Казакчы, Олукчы, Тавукчы, Тухчы һәм Тараган дип язылган.

Шул ук дастанда берсе Тау ягына, икенчесе Зәй тамагына китеп урнашкан Инсан бик белән Ихсан бик шәҗәрәләрендәге исемнәрдә дә аермалар бар. Кайбер исемнәр (мәсәлән, Җинтый) төп чыганакларда хәрәкәләр белән язылган. Инсан тармагындагы соңгы исемнәр гадәттә

[156] Басма текстлар дигәндә 1822 һәм 1882 еллардагы китаплар, 2002 елда Сегедта басылган һәм 2011 елда Казанда чыккан китапларны күздә тотабыз.

аерым язылган Үлмәс белән Чукаш «Икенче текст»та бер кеше итеп күрсәтелгән. Агалы-энеле буларак язылган Инсан бик тармагында иң күбе 18 буын, ә Ихсан бик тармагында 11 буын гына[157]. «Жиденче текст»та бүтән күчермәләрдә теркәлгән дүрт исем төшеп калган, әмма Чукаштан соң дәвам иткән биш буын башка текстларда юк.

«Икенче текст»тагы Идегәй исеме Идеги дип тә укылырга мөмкин. Шул ук текстта Идегәй шәҗәрәсендә Әбүлхак һәм аның улы Госман Мәдинәдә падишаһлык итүләре язылган. Башка текстларда Мәдинә урынына Мәдаин диелгән. Шундагы ук Кастанти дигән атама бүтән текстларда Кастантинийә буларак теркәлгән. Ә Мисыр атамасын, гарәпчәдәге охшашрак хәрефләрне ялгыш күчерүдән чыкканча, Сарсара дип язу бу – «Икенче текст» кульязмасына гына хас түгел, ә «Җамигыт-тәварих» текстында һәм башка күчермәләрдә дә шулай ук. Гомумән, Мисыр дип дөрес язылган вариантына караганда, төрле кульязмаларда Сарсара (Сарсар) яки Хархара варианты күбрәктер, ахрысы. 1882 елгы һәм 2011 елгы китапларда да ул «Сарсар» дип басылган.

«Сигезенче текст»та Мингәл (Мингәли) улы Тимәй басмаларда Мәнгәл (Мынгал) улы Тимер рәвешендә басылган.

«Икенче текст»ның «Тарих дастаны»нда Казан ханнары дип 15 исем күрсәтелгән. Анда, шулай ук тугызынчы һәм унынчы текстларда Габдулла ханның ике улы – Алтунбик белән Галимбик бергә язылган. «Унберенче текст»та алар бер-бер артлы теркәлгәннәр. «Унөченче текст»та Алтунбик кенә. Икенче һәм унынчы текстларда Мәмтәк дип язылган хан исеме тугызынчы, унберенче һәм унөченче текстларда Мәмәк буларак теркәлгән. XVIII гасыр башы кульязмасыннан алынган «Тугызынчы текст»та Мөхәммәдәмин белән Илһам хан исемнәре төшеп калган.

Текстларда рус исемнәренең шактый бозылып язылганын да искәртергә кирәк. Күчермәләрдә Иван исеме Ибан, Ипан, Җыван, Хыван һәм Җәван дип, Михайла – Михйала, Михәла дип, Дмитрий – Митрәй һәм Ми-

---

[157] Бу шәҗәрәләрнең аерым өлешләре Т.Ялчыголның «Тарихнамәи Болгар» әсәрендә һәм башка тарихи китапларда бар, аларга бәйле Тау ягындагы кайбер нәсел-токымнар Каюм Насыйри хезмәтләрендә дә язылган. Хәзерге галимнәр һәм төбәк тарихчылары да бу шәҗәрәләр белән кызыксына. Мәсәлән, Г.Дәүләтшин хезмәтләрендә бу нәселләр турында язылган *(Дәүләтшин Г. Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы..., 1999. – Б. 19)*, татар шәҗәрәләрен өйрәнүгә күп көч куйган галим Марсель Әхмәтҗанов шул нәселләрдән дәвам иткән төрле шәҗәрә тармакларын бастырып чыгарды *(Әхмәтҗанов М. Татар кульязма китабы..., 2000. – Б. 90; Әхмәтҗанов М. Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы..., 2002. – Б. 138–149, 265; Әхмәтҗанов М. Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы..., 2009. – Б. 173–178, 214).*

три, Пётр – Путра һәм Битыр, Разин фамилиясе Ракҗин һәм Ражин рәвешләрендә, шәһәр исемнәреннән Мәскәү – Мүскәү, Владимир – Уладимди, Аладимүр һәм бүтәнчә төрләндереп, татарчага җайлаштырып үзгәртелгән.

«Чыңгызнамә» китабындагы «Тикәлек» һәм «Алмалы», шулай ук башка атамаларның «Җамигыт-тәварих»та да булуы – ике текстның да элеккерәк чордагы бер үк чыганакларга нигезләнгәненә бәйле. Болардан тыш, «Чыңгызнамә»дә Ак тиңез (Урта диңгез), Төн диңезе (Төньяк океан), Мальта, Күрәл Урдасы (Европа), Хүнгәр (Венгрия), Һиндстан, Истанбул, Кызылбаш (Персия), Хаҗитархан, Болгар, Биләр, Идел, Ак Идел, Уфа, Зәй, Чирмешән һәм Казан дәрьясы, Зөя суы, Мәскәү, Владимир, Ташкент, Яркәнд, Сәмәрканд һәм бүтән географик атамалар бар.

«Икенче текст»та бер тауның исеме хәрәкәләр белән «Йайәр тагы» дип язылган, аны «Йәйәр» дип тә укырга мөмкин. 1822 һәм 2002 елгы китапларда ул «Йайыр», 1882 һәм 2011 еллардагы китапларда «Байыр» дип басылган.

Ыру тамгалары һәм башка атрибутлар

«Чыңгызнамә» китабындагы ыру тамгаларыннан тирәнтен мәгънә чыгарга мөмкин дип уйламыйбыз һәм алардан хикмәт эзләү урынлы түгел-дер. Чөнки төрле текстларда бер үк кешенең тамгасы төрлечәрәк ясалган. Җиде төрле чыганакта: бу китапка кертелгән ике кульязма тексты, 1822, 1882 һәм 2002 еллардагы басма текстларда, шулай ук 2002 елгы басмадагы «B» һәм «C» нөсхәләре дип билгеләнгән ике кульязма факсимилесендәге тамга рәсемнәрен чагыштыру нәтиҗәсендә тотрыксызлык барлыгы ачыкланды. Кайбер тамгаларның кечкенә генә элементлары бүтәнчәрәк булуы гына түгел, бер үк кешегә нисбәт ителгән тамгалар төрле кыяфәттә ясалган. Мәсәлән, Чыңгыз ханның «кош башы» дигән үз тамгасы ук әйтелгән җиде чыганакта алты төрле рәвештә ясалган. Дастанның төп каһарманының тамгасы төрлечә булу факты үзе генә дә башка тамгаларның ышанычсызлыгына ишарә итә. Бүдәнҗар улы Кыйатның «әвернә» тамгасының нигезе «X» рәвешендәге бер төрле ясалган булса да, аның очларындагы вак элементлары һәр очракта да төрлечә, ә «C» нөсхә кульязмада бөтенләй түгәрәксыман рәвештә. Коңрат улы Сәңләнең «ай» тамгасы да җиде текстта дүрт төрле: О кебек, С-сыман һ.б. Кыбчак би һәм Кирәйәт бинең тамгалары җиде чыганакта алты төрле рәвештә. Болардан Кирәйәт бинең «күз» тамгасы кайсында бер түгәрәк, ә башкасында янәшә ике түгәрәк рәвешендә яисә бөтенләй бүтәнчә ясалган. Майкы, Урдач, Тамйан, Бөрҗан, Катай һәм Калдар биләрнең тамга сурәтләре җиде текстта бишәр төрле итеп ясалган. Калган биләрнең тамгалары да текстларда дүртәр яки икешәр төрле

итеп сурәтләнгән, һәрхәлдә, нәкъ бер төрле генә итеп ясалган тамга рәсеме юк. Гарәп язуын белеп эш йөрткән һәркемгә (шул исәптән, әлеге дастан текстын күчергән кешеләргә) бик яхшы таныш, гади тамгаларның берсе – «һәмзә» (текстта «әмзә») дә җиде текстта ике төрле рәвештә бирелгән.

«Чыңгызнамә» китабындагы 16 төрле тамга рәсемнәренең унысы Рәшидеддиннең «Җамигыт-тәварих» әсәрендәге тамгалар кебек (нәкъ шундый ук яки охшаш)[158]. Шушы чагыштырулардан күренүенчә, «Чыңгызнамә» китабы текстындагы ыру тамгалары чынбарлыкны белдерми. Алар бу очракта күчмә сюжет өлгесе буларак кулланылган һәм әлеге тамгалардан тарихи дөреслек эзләү ялгыш нәтиҗәгә китерергә мөмкин.

Гомумән, татар һәм башка төрки халыкларда тамгалар киң кулланылган. Шунлыктан, «Чыңгызнамә»дәгеләргә охшаш нәсел-ыру тамгалары архив чыганакларында табылачагы гаҗәп түгел. XVII–XVIII гасырлардагы архив чыганакларында теркәлгән башкорт һәм татар тамгалары арасында Рәшидеддин әсәрендәге тамгаларга охшашлары – җиде, ә «Чыңгызнамә» китабындагыга охшаганнары – тугыз данә икәнлеген дә искәртик. Элекке Зөя өязе (Тау ягы) татарларының 1700 елгы документта куйган нәсел тамгалары арсында бер дистәләп төрдәгесе «Чыңгызнамә» китабындагыга охшаш. Кыргыз-казакъларда кулланылган «ай», «күз», «сергә», «тарак», «ачамай», «чүмеч» исемнәрендәге, «Чыңгызнамә» тексты белән бер төрле үк тамга рәсемнәре дә шактый булган[159].

Тамгалар мисалыннан күренгәнчә, Чыңгыз хан тарафыннан biләргә тәгаенләнгән агач, кош һәм оран кебек атрибутларның да мәгънәви әһәмияте чынбарлыкны чагылдырган дип ышанып бетәргә кирәкмидер. «Чыңгызнамә» текстының беренче вариантында тасвирланган көбәләрнең шундый ук исемнәре белән икенче вариант күчермәләрендә ярымлегендар биләрнеке буларак хикәяләнүендә дә сюжет күчмәлеген күрәбез.

«Чыңгызнамә» китабындагы ыру тамгалары һәм бүтән атрибутлар,

[158] Сборник летописей. История монголов, сочинение Рашид-эддина. Перевод с перс. И.Н.Березина. – С.-Петербург: тип. имп. АН. – С. 26–29.

[159] Материалы по истории Башкирской АССР. Ч. I: Башкирские восстания в XVII и первой половине XVIII вв. – М.–Л.: изд-во АН СССР, 1936. – С. 538–544; Катанов Н. Об одной выписи 1700 года, данной татарам Свияжского уезда // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Императорском Казанском университете. Т. XIV, вып. 3. – Казань, 1897. – С. 361–362; Тынышпаев М. Материалы к истории киргиз-казакского народа. – Ташкент: «Вост-киргиз», 1925. – С. 28–30. Алтын Урда һәм аннан соңгы татар ханлыклары чорының нәсел-ыру тамгалары традициясе Идел буендагы фин-угор халыклары вәкилләрендә (кайчак русларда да) XIX гасырга һәм XX гасыр башына кадәр кулланылышта булганын исәпкә алырга кирәк. Әмма төрле халыкларда бер төрле һәм охшаш тамгалар кулланылуы алар арасындагы кардәшлекнең дәлиле түгел.

һичшиксез, текстның аеруча мавыктыргыч өлеше һәм алар галимнәрнең игътибарын җәлеп итүе табигый. Марсель Әхмәтҗанов «Чыңгызнамә»нең 1882 елгы басмасы буенча бикләргә бирелгән агач, кош, оран, тамгалар турында язган, тамга рәсемнәрен ясаган, аларны шәҗәрәләр һәм топонимнар белән бәйләп язган[160]. Галим «Нугай Урдасы» исемле ике китабында (2002, 2009) шулай ук әлеге атрибутлар турында күп язды, 2009 елгы китабының ахырындагы кушымтада «Чыңгыз ханның үз биләренә биргән тамгаларының таблицасы»н да бастырды.

Мария Иванич «Чыңгызнамә»дәге оран, тамга һәм башка атрибутларны анализлап, кызыклы күзәтүләрен ясаган[161]. Ләкин «Рәшидеддин һәм Әбелгазый әсәрләре белән чагыштырганда бер төрле тамгалар берничә генә, димәк, авторлар үзләренә мәгълүм ыруларның чынбарлыктагы тамгаларын тасвирлаганнар» дигән фикере белән килешеп булмый. Шулай ук галимә Чыңгыз хан турындагы дастандагы тамга сурәтләренең төрле чыганакларда төрлечә ясалган булуы турында бөтенләй искәртмәгән. Мәкаләсенә кушымта итеп, тамга һәм башка атрибутларның Сегед басмасы (2002) өчен әзерләгән вариантындагы атамалар һәм тамга рәсемнәре тәкъдим ителгән[162]. Югыйсә шул басма өчен кулланылган кулъязма факсимилеләрендә үк төрлелек күренеп тора.

«Чыңгызнамә» дастанында бикләргә нисбәт ителгән атрибут (агач, кош, оран һәм тамга) исемнәре дә кулъязмаларда һәм бу китапта басылган текстларда төрлечәрәк язылган. Оран атамалары, ихтимал, тагын да борынгырак чорга бәйледер. Тарихтан билгеле булганча, оран итеп, гадәттә, ыру-кабилә исеме алынган. Текстлардагы «коңрат» һәм «барлас» кебекләре шундыйларга охшаш, ә «байгонгәр» дигәне гаскәрнең уң канаты мәгънәсендәге «барангар» дигән гаскәри терминны хәтерләтә.

Көбә исемнәре

I вариант текстында «Дастан» дип аерым исемләнгән һәм II вариантта Чыңгыз хан нәселенә багышланган дастан текстының ахырындарак сугыш киемнәре (беренчесендә «көбә», икенчесендә «савыт»[163]) турында язылган. Татар халкының «Идегәй» дастанында да «Кигәне көмеш ак савыт»

[160] Әхмәтҗанов М. Нугай Урдасы һәм аның татар этник тарихына мөнәсәбәте // Из истории Золотой Орды: сборник. – Казань, 1993. – Б. 145–152.
[161] Иванич М. «Дафтар-и Чингиз-наме» как источник по истории кочевых обществ..., 2002. – С. 320–323.
[162] Шунда ук. – Б. 328.
[163] Икенче вариант текстларында да «көбә» сүзе бар, мәсәлән, «Дүртенче текст»та «...батыр йегетләрнең көбәсен» дигән гыйбарәдә очрый. Ә Аксак Тимер дастанында бары тик «көбә» сүзе генә кулланылган.

дип, көбә мәгънәсендә «савыт» сүзе кулланылган. Шул ук дастанның икенче урынында «Нургыба атлы көбә» дигәннән көбә дип тә аталып, аерым исемнәре булганлыгы аңлашыла[164].

«Чыңгызнамә»нең беренче вариантында көбәләр ханнарга нисбәт ителсә, икенче вариантта Чыңгыз ханның үзенеке һәм улларыныкы, шулай ук хан тарафыннан бикләренә тәгаенләп бирелгән итеп тасвирланган. Көбәләрнең кемгә нисбәт ителүе һәм исем-атамаларында охшашлыклар да бар.

Ханнарга нисбәт ителгән көбәләр төгәл 20 исемдә, II вариантның «Икенче текст»ында шулай ук – 20, «Өченче текст»та – 21, Хәлфин басмасында 20 исемдә. Димәк, алар исәп-сан ягыннан бер төрле үк дияргә мөмкин. Әмма II вариант текстларында башта һәркемнеке аерым хикәяләп аталган, ахырында исемнәре җыеп әйтелгән. Шуларда кайбер савыт (көбә) исемнәре тәңгәл килмәгән очраклар бар. Әйтик, җыеп язылган урында икенче һәм өченче текстларда «керәүкә» исеме булса да, аның кемгә тәгаенләнгәне билгесез. «Өченче текст»та «калдай» дигәне дә бар. Әлеге савыт-көбәләрнең аерым кешеләргә тәгаенләнгән һәм җыеп язылган урыннарында, шулай ук төрле кулъязмаларда савыт атамалары төрлечәрәк күрсәтелгән. Мәсәлән, *айкултык/аркултык/култык; борчак/корчак/койырчак; сәгъбәр/сәфбәр; күклык/күк йака; кабак/каты кабак; көрләч/көрләү; кускач/комкач*.

Чыңгыз ханның «буйан» һәм Йүчи ханның «каратау» исемле көбәләре ике варианттагы текстларда да бер төрле үк. Болардан тыш, ике вариант текстларында төрле кешеләргә нисбәт ителгән, әмма атамалары бер үк төрле көбә-савыт исемнәре: *бөктәр, айкултык, чәчәкүз, каты кабак, бозаубаш, алтун сандук, күк йака, ун карыш, өйелмә, көйләксә, йөрәк (ут йөрәк), баркалсак (боз калпак)*. I варианттагы «борак» белән II варианттагы борчак (кобурчак) бер үк сүздән чыккандыр. Димәк, барлыгы 15 атама бер төрле үк диярлек. I вариант текстындагы «пәйгамбәр» II вариантта «сәгъра (сәгъбәр), 1822 елгы китапта (56 биттә) «сәгыйр» һәм 1882 елгы басмада (21 биттә) «сәйгар», 2002 елгы китапта «сыгыр» (60 бит) рәвешендә, төрлечә язылган сүз, фикеребезчә, бөтенесе бер үк. Аларның гарәп хәрефләре белән язылышлары охшашрак булганга, «пәйгамбәр» сүзенең башындагы «п» (б) һәм «и» хәрефләре астында куелган ноктлар күчерүчеләр тарафыннан астына өч нокта куелган «син» (с) хәрефе буларак кабул ителеп, ялгыш язудан чыккан булса кирәк.

Шуны искәртик, II вариантның «Икенче текст»ындагы Чыңгыз хан улы «Тулиның «ут йөрәк» дигән савыт иде» җөмләсе бүтән кулъязмаларда һәм басма китапларда юк. Хәлфин басмасында (56 биттә) кемнеке икәнлеге әйтелмәгән, ләкин атамаларны җыеп язганда «ут йөрәкә» дигәне дә бар.

[164] Идегәй: татар халык дастаны. – Казан: Татар. китап нәшр., 1988. – Б. 144, 225.

Көбә-савыт исемнәренең күпчелеге аңлаешлы сүзләр булса да, кайберләренең мәгънәләренә төшенеп булмый.

Галимә Мария Иванич хан тарафыннан ыру башлыкларына көбәләр өләшү турында бүтән чыганаклардан билгеле түгел дигән. Галимә «Чыңгызнамә»дә язылганның асылын ачыклау бик читен дип белдергән, көбә-савытларның мәгънәсен ачарга омтылган[165].

Истанбул шәһәре рәсеме

«Чыңгызнамә» китабының кайбер кульязмаларында һәм басмаларында Истанбул шәһәренең лабиринтсыман сигез катлы схематик рәсеме бар. Ул рәсем кайбер күчермәләрдә дүртпочмаклы, ә кайберләрендә түгәрәк шәкелдә ясалган, күчермәләрдә еш кына рәсем ясалмыйча, текст арасында якынча ярты бит күләмендә буш урын калдырылган. Андый буш бит калдыру, күрәсең, протографларына ук хас булган. Рәсеме булса да, булмаса да текстларда «Истанбул шәһәренең сыйфаты ошбудыр» яки «Истанбул шәһәренең күренешедер» рәвешендәге җөмлә язылган була. Кайбер очракларда шундый җөмләдән соң рәсеме дә ясалмыйча һәм буш урын да калдырмыйча, текст дәвам иткән.

Бу китапта басыла торган «Алтынчы текст»та Истанбул шәһәренең түгәрәк шәкелдәге рәсеме бар[166].

Гали Рәхим Аксак Тимернең сигез кат койма белән әйләндерелгән Истанбул шәһәрен ала алмавын бәян иткән урында, Хәлфин басмасын күздә тотып, болай дип искәрткән: «Китапта бу койманың планы дәреҗ ителгән. Бу план буенча, шәһәргә керер өчен шул сигез кат койма арасыннан бик озын чуалчык юл (лабиринт) аркылы узарга кирәк. Робгузиның «Кыйсасел-

---

[165] Иванич М. «Дафтар-и Чингиз-наме» как источник по истории кочевых обществ..., 2002. – С. 323–324.

[166] Казан университеты китапханәсендәге «135т» шифрлы кульязманың 9а кәгазендә дүртпочмаклы лабиринт рәсеме ясалып, эченә болай дип язылган: «Шәһри Кастантини бу торур. Аксак Тимер алган бу торур, һичшиксез, алгандур». Лабиринтның беренче каты эченә исә: «Шәһри Кастантининең капусы пу торур, һичкем ала алмас» дип язылган. Ә шул ук китапханәдәге «726т» шифрлы кульязманың 21б кәгазендә һәм «3570т» кульязманың 6б кәгазендә рәсем булырга тиешле битләренең яртыдан кимрәк өлешләре буш калган. 1882 елгы басма китапның 29 нчы битендә «Истанбул шәһәренең сыйфаты ошбудур» дигән җөмләдән соң рәсеме юк, текст дәвам итеп киткән. Димәк, ул басма өчен кулланылган кульязма күчермәдә дә рәсем булмаган. 2002 елгы басма өчен кулланылган төп кульязманың факсимилесендә (240 биттә) түгәрәк шәкелдәге рәсем бар һәм аның эченә Хәлфин басмасындагы кебек үк сүзләр язылган. Шул ук китаптагы «С» кульязмасы факсимилесендә (314 биттә) рәсем ясалмыйча, ярты бит күләмендә буш урын калган.



Рабгузи китабындагы (1881) Кастантинийә шәһәре сызымы

әнбийа»сында да Истанбулның (Канстантинийә) шундый ук лабиринт планы бар; ләкин Робгузида аның формасы дүртпочмаклы, «Әхваль...»дә түгәрәк»[167].

1822 елгы басманың 70–71 битләре арасында аерым биттә түгәрәк рәвештәге рәсем бирелгән. Схеманың эчендә гарәп хәрефләре белән «Хисаре Кастантинийә Искәндәре Руми (Искәндәр Руминың Константинополь ныгытмасы) диелгән. Искәндәр Руми – Искәндәр Зөлкарнәйн, ягъни Александр Македонский. Нәкъ шул ук рәсем 2011 елгы китапта да (59 һәм 84 битләрдә) кабатланган.

Рабгузиның «Кыйсасел-әнбийа» китабында (1881 елгы Казан басмасында 436 биттә) дүртпочмак шәкелендәге сигез катлы схематик рәсем

[167] Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы. Беренче җилд: борынгы дәвер. Өченче бүлек..., 1922. – Б. 45. *Дәреҗ итү – бастыру.*

бар һәм аның эченә «Кастантинийә» дип язылган. Аның алдында Искәндәр Зөлкарнәйн галәйһиссәлам кыйссасы бәйан ителеп, рәсемгә мөнәсәбәтле мондый юллар басылган: «Әймешләр Зөлкарнәйн галәм ичендә күб биналар кубарды, әмма Кастантинийәдә бер хисар кубарды – йите кат, камугын тизгүнмәгүнчә ул хисарга керсә булмас. Ул хисарның сурәте бу торур»[168].

Менә бу Кастантинийә – Истанбул рәсеме дә күчмә сюжетларга охшаш бер өлге булган һәм ул, ихтимал, Рабгузида гына түгел, ә Зөлкарнәйнгә багышланган бүтән кыйсса һәм риваять китапларында да ясалып һәм шулардан күчерелеп йөртелгәндер.

«Ханнар»ның биләмәләре

«Чыңгызнамә» китабындагы бу бүлек турында (Хәлфин басмасы нигезендә) Гали Рәхим болай дип язган: «...Монда саналган ханнар тарихка мәгълүм кешеләр түгел; аларның күбесе шул заманда (Казан алыныр алдыннан) татар илләрендә утырган феодаллар булырга кирәк»[169]. Чынлыкта, анда тарихта исемнәре билгеле кешеләр дә бар.

Күләме белән кечкенә генә бу текстның башлангычы әүвәлге чордан язылып-күчерелеп һәм өстәлеп килгән дип аңлашыла. Ул I вариант текстында «Дастане мөддәт» дип, икенче вариант текстларында «Дастанел-мәкян», «Фасыл фи дастани вәл-мәҗалис вәл-мәкян» һәм башкачарак аталган. Бу җыентыкта әлеге бүлек барлыгы алты текстта (I вариант һәм II вариантның икенче, тугызынчы, унынчы, унберенче һәм унөченче текстларында) урын алды.

Китап текстының I вариантында барлыгы 13 биләмә, ә II вариантның икенче һәм унберенче текстларында шулай ук – 13, тугызынчы һәм унынчы текстларда – 15 (бусында соңгырак чор өстәмәләре белән 24) биләмә турында язылган. Ике варианттагы мәгълүматлар тулаем диярлек охшаш булса да, җитди аермалары күзгә ташлана. Андыйлардан беренче вариантта язылган «Шәһри Болгар» белән «Тубулдан бире» дигән атамалар икенче вариант текстларында юк. «Шәһри Болгар – Бүләр ханның йорты ирде. Аждаһа илан алды. Алыблар [берлә] сукыштылар, йиңделәр, соңра салыб качдылар» дигән язмадагы «Шәһри Болгар» икенче вариантта «Зәй тамагы» буларак теркәл-

---

[168] Кыйсасел-әнбийаи Рабгузи. – Казан: ун-т табыгханәсе, 1881. – Б. 435. *Әймешләр* – сөйлиләр; *кубарды* – корды; *хисар* – ныгытма, кальга, крепость; *тизгүнмәгүнчә* – әйләнеп үтмичә. Зөлкарнәйн кыйссасында Аксак Тимер дастанына башкача охшашлыклар да бар. Мәсәлән, башка бер шәһәрне ничек алырга белмичә хәйлә кору, Һиндстан патшасына илче җибәрү, үзе урынына улын патша итеп калдырып, зур гаскәр белән юлга чыгуы, аның белән бергә Хозыр галәйһиссәлам дә булуы һәм башка тасвирлар Аксак Тимер дастанында да берникадәр кабатланган.

[169] Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы. Беренче җилд: борынгы дәвер. Өченче бүлек..., 1922. – Б. 39.

гән һәм Аксак Тимер дастаны эчендә киңрәк тасвирланган. Икенче вариант текстларындагы «Бохара – Болгар ханның...» дигәндәге «Болгар» атамасы дөреслектә Болгаер (Әбелхәер) дигәннән бозылган. «Тубулдан бире – Күчүм ханның йорты» дигән мәгълүмат шулай ук икенче вариант текстларында юк. Беренче вариант текстында язмалар бөтенесе дә диярлек «ирде» (ягъни «иде») дип, үткән заман формасында теркәлгән, бары тик «Күчүм ханның йорты» дигәндә генә «ирде» сүзе юк. Бу очракта «ирде» сүзе күчерүчеләр тарафыннан төшереп калдырылмаган булса, әлеге «Дастане мөддәт»нең мәгълүматы XVI гасырның икенче яртысында теркәлгән дип фаразларга мөмкин. Ә икенче вариант текстларындагы мәгълүматлар барысы да «...йортыдыр» рәвешендә, ягъни текст язылган замандагы кебек итеп теркәлгән. Ләкин төрле гасырларда яшәгән реаль шәхесләрнең исемнәренә карата андый сүз кулланылуы стилистик яктан ышанычлы түгел.

Икенче вариантта гына булган өстәмә мәгълүматлар әйтеп үтелгән «Бохара...»дан тыш, «Чирмешән – Өмәрхуҗа ханның...; Ак Идел тамагы – Кара ханның...; Уфа тамагы – Тирә ханның...» өлешләре бар.

Һәр ике варианттагы мәгълүматлар икесе дә уртак бер чыганактан таралган булса кирәк. Ә «Унынчы текст»тагы «Ык, Сөн, Миаҗ, Иртеш» һ.б. атамалар «Чыңгызнамә»дән алынганлыгы күрсәтелгән булса да, алар, нигездә, Мөслиминең «Тәварихы Болгарийә» һәм Т.Ялчыгол китапларыннан өстәлгән.

Беренче варианттагы «Индәр» атамасы икенче вариантта «Инчер, Инҗер, Инчы», I варианттагы «Айдархан» икенче вариантта «Аждархан, Әчтерхан, Ачтырхан», беренче вариантта «Күңелбәдәр» дип язылганы «Кябер, Кябид, Кәлә, Кәлибөдүр» рәвешләрендә. Шулардан «Тугызынчы текст»та «Кябид» Сибәркә ханга, ә «Унберенче текст»та «Кәлә» Биргән ханга нисбәт ителгән. I варианттагы «Өч Үзән» язылышы II вариант текстларында «Өй-Үзән» яки «Үзән» дип кенә теркәлгәнен күрәбез. Кеше исемнәрендә дә төрлелек бар: I варианттагы «Чалбак» икенче вариантта «Чалсак, Чалбак, Чалпак» диелгән. Икенче вариант текстларында үзара аермалы атама-исемнәр тагын да бар. Аларны бу җыентыкта кульязмаларның үзләрендәгечә бирергә тырыштык.

I вариант текстындагы «Җанибәк ханның кызын алыб качкан уйсын Гайса угылы Амәт ирде, аны куа барган алчын [Алау] ирде» дигән хәбәр икенче варианттагы «Гайса улы Амәт» дастанында язылганнарга туры килә. I варианттагы Бачман ханның олы агасы Тирә хан һәм аларның энесе Йүчи ханның йорты Чагатау турындагы мәгълүматларның II вариант текстларында берникадәр чагылышы бар. Аларда ага-эне булулары турында әйтелмәсә дә, Тирә хан биләмәсе итеп Уфа тамагы, ә Чагатау атамасы «Чаган хан» дип үзгәртелгән.

Елъязма мәгълүматлары

Тарих турындагы дастан – елъязмалар бүлеге бу җыентыкта II вариантның төрлечә күләмдәге җиде тексты нәшер ителде. Алар һәммәсе дә бер төрле үк түгел, аермалары бар. Текстларда кайбер еллар ялгыш һәм аерым мәгълүматлары хаталы.

Гомумән, текстларның тулыракларыннан икенчесендә 20-дән артык төп вакыйга язылган. Анда бүтәннәрендә булмаган хәбәрләр язылуы белән бергә, кайбер вакыйгалар төшеп калган.

Әйтелгән җиде текстның өчесе (икенче, тугызынчы һәм уникенче текстлар) Сәед Җәгъфәр күтәрелешен язып тәмамланган, «Унөченче текст» Пётр патшаның 1722 елгы Персия походын теркәп, «Унынчы текст» – 1736 елдагы Акай явын хәбәр итеп, ә «Ундүртенче текст» 1743 елдагы койрыклы йолдыз вакыйгасы белән тәмамланган. «Унынчы текст»та Сәед Җәгъфәр күтәрелеше турындагы мәгълүматтан соң, күчерелгәннәрнең чыганагы «Чыңгызнамә»[170] күрсәтелгән. Кулъязмада әлеге чыганактан соң тагын бер вакыйга – 1736 елгы Акай явы турында өстәп язылган.

Тарихи вакыйгаларга багышланган бүлектәге фактлар тарихчылар тарафыннан күп тикшерелеп, кайбер мәсьәләләр турында төрле фикерләр, версияләр һәм фаразлар язылган. Гомумән, галимнәр андагы даталарның берничә елга ялгышрак күрсәтелгәнлеген искәрткәннәр. Елъязмаларда Иске һәм Яңа Казанда татарлар ничә ел яшәүләре турындагы мәгълүматны, Казан ханнарының исемнәре тулы түгеллеген һәм буталчыграк булуын да галимнәр җентекләп өйрәнгән.

Дастанда язылган иң әүвәлге дата – һиҗри буенча 700 (милади белән 1300/1301) елда Аксак Тимернең Болгарны җимерүе турындагы мәгълүмат дөреслеккә туры килми һәм ул иң күп тикшеренүләргә сәбәпче булган. Калган хәбәрләр турында зур бәхәсләр юк диярлек. Шаһгалинең 33 ел ханлык итүе турындагы мәгълүмат шулай ук дөрес түгел. Кайбер хезмәтләрдә Шаһгалинең 1519 елда хан булган вакытыннан 1552 елга кадәрге ара тоташ исәпләп шулай язылгандыр дигән аңлатма бар. Казан алынган ел итеп күпчелек текстларда 1554 елга туры килә торган һиҗри 961 ел язылган булса да, кайбер күчермәләрдә (икенче һәм унөченче текстлар) дөрес дата – 1552 елга тәңгәл 959 ел күрсәтелгән.

Кабатланмый торган урыннардан «Икенче текст»тагы 977 (1569/1570) елда Шыгали хан вафаты турындагы һәм «1085 елда кенәз Фидур Аләксәйавич

[170] Кулъязмада, гади татар сөйләм теленә хас булганча, «Чыңгызлама» диелгән. Моңа охшаш күренеш «Нурнамә» китабы һәм «Җавапнамә» язмасы атамаларын өлкән буын арасында хәзер дә «Нурлама», «Җаваплама» дип телгә алынуда сакланган.

хан булды» дигән хәбәрләр бүтәннәрендә юк. (Шаһгали хан чынлыкта 1567 елда дөнья куйган). Әлеге ике мәгълүмат басма китапларның берсендә дә юк. Степан Разин восстаниесе турындагы хәбәр ике кулъязмада гына: «Икенче текст»та «1079 елда Раҗин йагы» дип, ә «Унынчы текст»та «1080 елда Ракҗин йагы» рәвешендә язылган. Соңгысында 1079 елда «бәлид кыргыз» дип теркәлгәне дә шул ук күтәрелешне күздә тоткан. Ләкин бу очракта кулъязманы күчергән кеше кыргыз-казакъ халкы белән ялгыш бутаган, чөнки текстта Дон казаклары күздә тотылган. Шул ук восстание «Тугызынчы текст»та «бәлид казакъ йагы»[171], «Унөченче текст»та «казакъ урыс берлә» рәвешендә һәм «Ундүртенче текст»та «1075-тә казакъ» явы буларак язылган. Текстлардагы 1089 (1678) елдан соңгы төрле фетнәләр һәм мөселманнарны чукындыру турындагы хәбәр «Унөченче текст»та язылмаган.

«Ундүртенче текст», соңгырак чор күчермәсе булганлыктан, аны теркәгән кешенең башка чыганаклардан хәбәрдарлыгы сизелеп тора. Ул текстта буталчыклар булса да, Казанны алган патшаның исеме «Ибан Грузный», «сар Ибан» һәм «Калталы Ибан» дип аталган. Шыгали хан «залим куштан» дип каһәрләнгән, Сөембикә дә яулап алучыларга каршы көрәшкән итеп тасвирланган.

Елъязма күчермәләрендәге 1050 (1640–1641) елда «Иркә (иргә) чирүе» дигән сүзләрнең дөрес булмавына Н.Катанов та, Г.Рәхим дә игътибар итеп, аңлатканнар. Ягъни, «Иркә чирүе» бүтән баш күтәрүләр белән бергә саналганда, аерым бер шәхес җитәкчелегендәге восстание кебек күзалланса да, асылда, мәгънәсе бүтәнчә. Дөрес укылышта әлеге гыйбарә «иргә чирү»[172] (яки «ирләргә чирү») диелергә тиешле булган. Нәкъ шул чорда патша Михаил Фёдорович әмере белән ир-атлар гаскәргә алынганлыгы мәгълүм. Тексттагы халык баш күтәрүләренең барысы да «ягы» яисә «явы» дип аталуы да моңа дәлил булып тора. Югыйсә, кайбер хезмәтләрдә

[171] Монда шуңа игътибар итәргә кирәк, кайбер текстларда язылган, фарсы телендә «әшәке» «кабәхәт» мәгънәләренә ия «пәлид» (бәлид) сүзен Гали Рәхим «елъязма авторы югары сыйныф вәкиле булганга, күрәсең, шулай сыйфатлагандыр» дигән *(Гали Рәхим: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык..., 2008. – Б. 156)*. Ләкин «пәлид» сүзе бу очракта «кяфер» мәгънәсендә, ягъни мөселман казакъ халкы (кыргыз-казакъ) түгеллеккә, ә православие динендәге «казак» катлавына ишарә иткәндер. «Тугызынчы текст»ның 1737 елгы русчага тәрҗемәсендә «Белит» исемле казак дип аталуы, әлбәттә, ялгышлык.

[172] Күрәсең, борынгырак истәлекләрдә очрый торган палеографик үзенчәлек – «чирү» сүзенең ахырындагы озын «ү» авазын белдерү өчен «йа» хәрефен язудан буталчык килеп чыккандыр. Андый очракларда, гадәттә, «әлиф» өстәп язылган булса, кайбер кулъязмаларда «йа» хәрефе белән дә теркәлгән. XIV гасырдагы Болгар кабер ташларындагы «булды» мәгънәсендәге «бултуу (болтыы)» сүзенең ахырындагы озын «у» (о) авазын белдерер өчен дә «йа» хәрефе язылган.

«Иркә» дигәне, имеш, «Илейка» (яки Ирейка) атлы бер рус кешесе булган дип ялгыш аңлатмалар да күренә.

Мөселманнарны чукындыру турындагы мәгълүматта (бу җыентыктагы икенче, тугызынчы һәм унынчы текстларда) «куллар куеп» дигән гыйбарә чынлыкта «каравыллар» булырга тиеш. Кульязмаларда «куллар» дип ялгыш теркәлүе, ихтимал, электән үк бозып язылган нөсхәләрдән таралган.

«Унөченче текст»та 1707–1708 еллардагы татар-башкорт күтәрелеше турындагы мәгълүматта Сидор Аристов баш булып йөрүе сүзләреннән ул кеше восстание башлыгы кебек аңлашыла. Ләкин, чынлыкта, ул баш күтәрүчеләрне бастыру өчен 770 кешелек атлы сугышчылар гаскәрен җитәкләгән.

Бу җыентыкта тарихи вакыйгаларның елларына карата астөшермәләрдә кыскача искәрмә бирү белән чикләндек. Әйткәнебезчә, аларга күренекле тарихчы галимнәр тарафыннан тәфсилле анализлар ясалган һәм матбугатта басылган. Шулай ук җыентыгыбызда текстларның алдарак урнашканына бирелгән искәрмәләр бүтәннәрендә кабатланмады. Бары тик яңа дата яисә бүтәнчә мәгълүмат өстәлгән урыннарга гына астөшермәдә аңлатма язылды.

Дастаннарның теле һәм кульязмаларның палеографик үзенчәлекләре

«Чыңгызнамә» текстында, һичшиксез, тел тарихы буенча да бик бай материал тупланган. Борынгы төрки язма истәлекләрнең бай традициясенә нигезләнгән бу китап турында электән язган галимнәр аның тел үзенчәлекләренә дә игътибар иткәннәр. Ибраһим Хәлфин текстта иске һәм гамәлдән чыккан сүзләр булуын искәрткән һәм үзе әзерләгән басмага сүзлеген дә хәзерләгән. Китапның телен тәфсилләп тикшергән Гали Рәхим аны татарча дип билгеләгән. Миркасыйм Госманов китапның телен «сөйләм теленә бик якын, эзлекле кыпчак-татар язма теле» дип тәгаенләгән һәм аның башлангычы Алтын Урда чорындагы әдәби кыпчак теленнән килә дип язган[173].

«Чыңгызнамә» текстында борынгы чор тел үзенчәлекләренең шактый булуы турында галимнәр белдергән фикерләргә үз тарафыбыздан да кайбер мисалларны өстик. Мәсәлән, кульязмаларда «җир» сүзенең иске язма һәм басма китаплардагыча «йир» дип язылган булуыннан тыш, «ир» дигән борынгыча формасы да очрый. «Алар» һәм «елаштылар» кебек сүзләрнең күчермәләрдә «улар» һәм «илашдылар» рәвешендә теркәлүе дә борынгылык күрсәткече.

Текстта «җәя» сүзе «йәйә» дип язылган булса, бик гаҗәп булмас иде, әмма «йа» (йә) дип кенә бирелүе борынгырак дәвергә хас. Борынгы төрки

[173] Усманов М. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв..., 1972. – С. 125.

телдә салават күпере дә нәкъ шулай – «йа» (йә, йәй) дип аталган. (1882 һәм 2011 еллардагы басмаларда «йа» сүзе «йал» дип ялгыш язылганын алда искәрткән идек).

I вариант текстында: «син» хәрефе астына өч нокта, «уау» өстенә өч нокта, «йа» астына ике нокта, ноктасыз «хә» астына мөһмәл (ноктасыз хәреф билгесе) куелган. Кулъязманың 74б кәгазендә «кеше» сүзендә «шин» хәрефенең өстендә һәм ялгышлык белән астында да өчәр нокта куелган. Хәрефләр, сүзләр төшеп калган, эшкәртелмәгән-буталчык җөмләләр бар. Хәрәкәләр шактый куелган, кайбер сүзләрнең ахырларындагы «сәкен» хәрәкәсе күчерүче тарафыннан шуңа охшаш түгәрәк «ә» хәрефе буларак язылып, «ирер, үр, тәбигъ» сүзләре «ирерә, үрә, тәбиғә» дип, сузык хәрефкә беткән сүзләрдә исә «һ» буларак, мәсәлән «көнгә, таба» сүзләре «көнгәһ, табаһ» рәвешендә язылган. Кулъязмада «диб, диде» күбрәк һәм «тиб, тиде» азрак теркәлгән. Сөйләмнән күчкән «тарбаза» (дөресе – «дәрвазә») кебек кайбер очраклар да күренә.

I вариант текстындагы ирен-ирен w авазы борынгы гарәп язулы текстларда «фа» (ф) хәрефе белән белдерелгән[174]. «Чыңгызнамә» текстындагы «төүкерсә», «сыу» «көү» (төwкерсә, сыw, күw) кулъязмада «ф» хәрефе белән язылганнар. «Дастане мөддәт» тексты башындагы «Кәф уралы» дигән атама да, ихтимал, «Кәү» булырга тиештер.

Шул ук кулъязмадагы палеографик үзенчәлекләрдән «ошбу» сүзенең ахырында әлиф өстәп, «ошбуа» рәвешендә язылганга Г.Рәхим игътибар иткән булган һәм ул бу язылышны гарәп теле грамматикасы йогынтысы белән аңлаткан[175]. Ләкин бу очракта хикмәт башкада дип уйлыйбыз. Әлеге кулъязмадагы «каршы» сүзе берничә урында (мәсәлән, 77а кәгазьдә) «каршуа» дип язылганын һәм II вариантның «Беренче текст»ындагы Көнү исеменең дә ахырына «әлиф» өстәлеп «Көнүә» рәвешендә теркәлүен искәртергә кирәк. Мондый очракларда сүз ахырындагы сузык «у» һәм «ү» авазларының озын икәнлегенен белдерер өчен «әлиф» өстәү гадәте булган[176]. Гомумән, I вариант кулъязмасында хәрәкәләрнең күп кулланылган

[174] Мондый палеографик үзенчәлек бигрәк тә Алтын Урда чоры әдәби истәлеге – Котбның 1342 елда иҗат ителгән «Хөсрәү вә Ширин» әсәренең һәм Мәхмүд Болгариның 1358 елда язылган «Нәһҗел-фәрадис» китабы һ.б. әсәрләрнең күчермәләрендә киң кулланылган.

[175] Рахим А. О новом списке татарского исторического сочинения XVII века..., 1927. – С 136–138, 143.

[176] Гарәп язулы борынгы текстларга хас әлеге палеографик үзенчәлек турында әлегрәк тукталган идек: Кыз хикәяте / төз.авт.: Мәрданов Р. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2012. – Б. 33–34.

булуы һәм башка палеографик үзенчәлекләр дә бу текстның борынгырак чорга каравын раслый.

Аерым сүзләр һәм гыйбарәләр XVIII гасыр ахыры һәм XIX гасыр башындагы кулъязма күчерүчеләргә дә аңлашылмаслык дәрәҗәдә архаиклашкан булган[177]. Мәсәлән, бу китаптагы «алысдан» сүзе – «алдан» яки «асдан» дип, «ләшкәр» – «шөкер» дип, «сойургасаң» сүзе дә төрлечә бозылган һ.б. Тексттагы «казгу» (кайгы) сүзе архаиклашкан булуы сәбәпле «Чыңгызнамә»нең 1882 елгы басмасында (3 биттә) «кызы» рәвешендә һәм 2011 елгы басмада да (70 биттә) «кызы» дип бирелгән.

Чыңгыз хан турындагы дастанда «биләр менеб барган атларын Чыңыз ханны булганлары өчүн азад идделәр» дигән җөмләдәге бик борынгы «булганлары» сүзе язма әдәбиятта очрый[178]. Борынгы төрки телдә «булу» – «табу» мәгънәсендә, ягъни әйтелгән җөмләдәге «булганлары» хәзергечә «тапканнары» дигәнне белдерә. 2011 елгы басмада «Чыңгыз ханыны булганлары өчен» (76 биттә) гыйбарәсенең хәзерге әдәби телгә күчермәсе (49 биттә) «Чыңгыз ханныкы булган өчен» дип ялгыш аңлатылган.

Аксак Тимер турындагы дастанның ахырында «мугыллыкны ташлаб хасс мөселман булсаңыз» дип, Амәт һәм Самәт ханнарны мөселманлыкка өндәү сүзләре бәян ителгән. Андагы бер сүзгә аерым аңлатма таләп ителә. II вариантның «Икенче текст»ында «мугълыкны», «Бишенче текст»та «мугъ лыкны» һәм «Алтынчы текст»та «мугалыкны» дип язылган сүз, беренче карашка гарәп телендәге «мөгъләкъ» (бикле, ябык, аңлашылмаган) сүзен бозып язылганга охшаса да, чынлыкта, ул башкача мәгънәгә ия. Борынгы чор кулъязмаларына хас булганча, ике тартык авазны белдергән бер үк хәрефләр янәшә килгәндә берсе генә язылганлыгын истә тотып, «л» хәрефләре икәү булган әлеге сүз, асылда, «мугыллыкны» (мугаллыкны) – ягъни, монголлыкны-мәҗүсилекне дигән мәгънә күздә тотылган. Контекст эчендә ул сүзнең төп мәгънәсен төшенмәгән хәлдә дә, мәҗүсилек күздә тотылганлыгы аңлашыла. 1882 елгы басмада ул сүз (элекке күчермәләрендәге варианты аңлашылмаганга) «бу азгунлыкны» дип басылган (36 бит). 2002 елгы китапта «муглыкны» дип бирелгән һәм сүзлегендә «мәҗүсилек»

---

[177] «Чыңгызнамә»дә архаик сүзләр шактый булуының кайбер мисалларына алдарак, китапның Венгрия басмасы уңаеннан тукталган идек. Димәк, текстта тәҗрибәле тюркологлар өчен дә читен гыйбарәләр бар дип әйтергә мөмкин.

[178] Бу сүз турында галим Җәвад Алмаз «Урхун-Енисей язмаларында, борынгы уйгыр телендә, «Хөсрәү вә Ширин», «Мәхәббәтнамә» әсәрләрендә, Ибне Моханна сүзлегендә бар. Чыгытай телендә кулланылмый. Татар әдәби телендә, «Кыйссаи Йосыф» традициясе буларак, Октябрьгәчә кулланыла» дип язган *(Алмаз Җ. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» дастаны // Совет әдәбияты. – 1960. – №2. – Б. 113).* «Октябрьгәчә» дигәндә 1917 елның Октябрь революциясе күздә тотылган.

мәгънәсендәге «Heide[n]tum» дип язылган (81, 173 битләрдә, «n» хәрефе басмада төшеп калган).

Мәсгуд Гайнетдинов Аксак Тимер дастанының ахыры турында болай язган: «Автор бүлекне, халык гыйбрәт алсын диптер, «беттек» дигән сүзләр белән тәмамлый»[179]. Гәрчә монда дастан текстындагы бер генә сүзе аталган булса да, аның «сүзләр» дип күплек санда бирелүе дә аптыраш тудыра. Борынгы кулъязмаларда очрый торган «бетедем» (яздым) сүзенең күплек санда «бетедек» (бетедүк) дигәнне М.Гайнетдинов ялгыш аңлата. Аерым бер сүзне контексттан, җөмләдән аерып алып аңлатканда төп мәгънәсенә төшенү читенрәк, әлбәттә. Ләкин текстның үзенә мөрәҗәгать иткәндә серләр ачыла, «халык гыйбрәт алсын диптер» рәвешендә, фаразлаган кебек язуга ихтыяҗ булмавы да аңлашыла, ул турыда текстның үзендә үк «...аның дастаны халык арасында сөйләнә калсун, халык андин гыйбрәт алсун тиб, дастанны бетедүк» диелгән. Күргәнебезчә, беренчедән, «халыкка гыйбрәт» мәсьәләсе дастанның үзендә үк ачык әйтелгән һәм, икенчедән, җөмлә ахырындагы «дастанны бетедүк» сүзләре һичничек «беттек» мәгънәсенә туры килә алмый. Һәрхәлдә, татар телендә язылган мондый нәфис-сәнгати әсәрдә ул урынсыз. Сүз уңаеннан әйтик, Сәлим Гыйләҗетдинов тарафыннан әзерләнгән 2011 елгы китапта да (88 биттә) бу сүзләр «дастанны бетдек» дип бирелгән, ә текстның хәзерге татар әдәби теленә күчермәсендә «дастанны әйттек» рәвешендә басылган (63 бит).

Икенче вариантның икенче һәм дүртенче текстларында диалоглардагы «һа» ымлыгы бүтән текстларда «һай» буларак язылган. Ә беренче вариант текстында ул бөтенләй юк, андагы сөйләм тасвирларында «аһ» ымлыгы гына кулланылган.

«Чыңгызнамә»нең төрле күчермәләрендә *т/д, б/п, җ/ч* хәрефләре вариантлар белән (мәсәлән, *тиде/диде, алапа/алаба*) һәм үзара бутап язылган очраклар шактый. «Ч» урынына «җ» хәрефе һәм «п» урынына «б» язылу күренеше киң таралган булу белән бергә, боларның киресенчә мисаллары да аз түгел. Мәсәлән, «ошбу» сүзе урынына «ошпу», «җыен» урынына «чыен», «Җүчи» урынына «Чүчи», «бараҗ» урынына «барач» кебек язылышлар бар.

Кулъязма күчермәләрендәге хаталарның шактые хәрефләрнең еш кына бер яки ике нокталарын төшереп яисә өстәп язудан һәм охшаш хәрефләрне ялгыш күчерүдән чыккан, шул сәбәптән, төп чыганакларда *д/у, р/ә, р/д, р/з, р/у, т/н, қ/ф, т/қ, п/б, п/с, с/х, с/ш, ч/х/җ* хәрефләре үзара бутап язылганнар. Нәтиҗәдә, сүзләрнең мәгънәләре үзгәргән яки хаталы булып чыккан.

[179] Гайнетдинов М. Дастаннар китабы..., 1979. – Б. 174. Галимнең шул ук фикере «Хакыйкать юлыннан» җыентыгында да (2001, 30 бит) кабатланган.

Хәрефләр һәм иҗекләр төшеп калган һәм сирәк булса да өстәлгән. Сүзләрдә бер төрле үк хәреф ике мәртәбә кабатланганда бер генә хәреф язылган.

Текстлардагы язылышка күрә, күпчелек очракта «сән» дип укыла торган сүзнең ачык итеп «син», «сине» дип язылган очраклары да бар.

Кулъязмаларда хәрефләрне буташтырулар, орфографик хаталар, текст өзеклекләре кебек кимчелекләр, гомумән, һәр күчермәдә бар. Аларны кулъязманы күчергән аерым затларның кимчелеге-игътибарсызлыгы итеп кенә карау дөрес булмас, чөнки шул ук кешеләр кулланган күчергеч-протограф та хаталы булу ихтималы исәпкә алынырга тиеш. «Чыңгызнамә»нең сакланып калган иң әүвәлге – XVIII гасыр башына караган күчермәләрендә дә хаталар булуы моңа дәлил. Гомумән, китапның төрле күчермәләрендә хаталар һәм аермалы сүзләрнең булуы – әлеге текстның электән үк күп күчерелеп, киң таралуына да бәйле. Шулай ук иске кулъязма истәлекләрне күчергән кешеләр югары белемгә ия затлар түгеллеген истә тоткан хәлдә, күчермә текстларга карата хәзерге заман таләпләрен дә куеп булмый.

Кулъязмалардагы хаталарның күбесе элеккерәк чордан – XVII гасыр ахыры–XVIII гасыр башыннан киләдер. Тарихтан билгеле булуынча, Казан алынганнан соң татар халкы берничә гасыр наданлыкта-караңгылыкта калган. «Чыңгызнамә»дәге кайбер хаталы язылышлар аның башлангыч чорыннан ук дәвам итеп килгәнлеге күренә. Мәсәлән, барлык кулъязмаларда диярлек, гарәп теленнән кергән «касд» сүзе нигезендә ясалган «кастында» «т» хәрефе белән, «холкы» сүзе дә төркичә әйтелешкә яраклаштырып «кылыкы» дип язылган. Бу Хәлфин басмасында (51 биттә) «кылык» һәм 1882 елгы басмада (19 бит) шулай ук «кылыкы» дип басылган. «Һәмзә» (хәреф исеме) төрки-татар сөйләменә хас булганча, сүз башындагы «һ» авазын әйтмәүгә бәйле рәвештә «әмзә» дип язылган. Дастан текстында бу сүзнең тамга исеме буларак кулланылып, гарәп әлифбасындагы «һәмзә» хәрефе сурәтендә ясалган булуы – аның бүтәнчә мәгънәдә түгеллеген раслый.

Кулъязма текстларында бер үк сүзләрнең төрлечә язылышларын бу китапта төп чыганаклардагыча бирергә тырыштык, мәсәлән: *аглай/йыглай/илай; алапа/алаба; анлар/улар; асыл/аслый; Балын/Банын; бараҗ/барач; болар/бонлар; йолкыб/җолкыб; Йүчи/Җүчи/Чүчи; капу/капуг/кабу; Кинҗә/Кинчә; Күрүкле/Күрекле; кыдырыб/кызырыб; падишаһ/бадишаһ; пешүрде/бешүрде; посташ/бosташ; Салҗут/Салҗуд; сары/сарыг; тиде/диде; Тимер/Тимүр; Тули/Туни/Тулин; угыл/угул; Уладимүр/Аладимүр/Ывладимүр/Үләдимүр; урус/урыс; фута/бута; Һиндстан/Һиндустан; чавыр/чавырын/җавыр; чатыр/чадыр; элгәрү/илгәрү; эленмәде/йеленмәде; эстәб/истәб* һ.б. Шулай ук кайбер исемнәрнең дә бераз үзгәрешле вариантлары кулъязмалардагы кебек калдырылды яисә астөшермәдә искәртелде.

Хәрәкәләр белән язылган кайбер сүзләр ничек язылган булса, шулай бирелде (мәсәлән, «Икенче текст»та «йибәрде» сүзе хәрәкәләр белән «йәбәрде» дип теркәлгән).

Текстлардагы сүзләрнең дөресрәк укылышын тәэмин итү өчен өстәмә «қ» һәм «ғ» хәрефләрен кулландык.

Дастаннардагы тезмә юлларны шигъри рәвештә бирүне мәгъкуль күрдек.

Кулъязмаларда бернинди дә пунктуацион билгеләр юк, шунлыктан, текстлардагы бөтен тыныш билгеләре безнең тарафтан куелды.

Текстларда кулъязманың битләре башланган урыннар ике кыекча сызык белән аерып (// 16а кәгазь) рәвешендә күрсәтелде. Текст өзеклекләре [...] рәвешендә билгеләнде.

Китапның ахырында бу җыентыкка текстлары кергән кулъязмаларның тасвирламасы һәм сүзлек бирелде.

***

Китапны басмага әзерләү дәвамында күрсәткән ярдәмнәре өчен Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең директор урынбасары Ирек әфәнде Һадиевка, китапханәнең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире Айрат әфәнде Заһидуллинга һәм бүлек хезмәткәрләренә, КФУның Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе сирәк һәм кулъязма китаплар бүлеге мөдире Эльмира Исхак кызы Әмирхановага һәм бүлек хезмәткәрләренә, Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты язма һәм музыкаль мирас үзәге мөдире Илһам әфәнде Гомәровкә ихлас рәхмәтләремне юллыйм.

БЕРЕНЧЕ ВАРИАНТ

// *(70а кәгазь)* ДӘФТӘРИ ЧЫҢГЫЗНАМӘ[1]

Дәфтәрнең әүвәл башындин сөйләйәлек. Әүвәл башы – нәғачи бабаларындан сөйләйәлек.

Ақ тиңезнең эчендә Мальта шәһәре дигән бар ирде. Ул шәһәрнең ханы Алтун хан дигән ирде. Ханишенең аты Көрләвеч дигән. Ике падишаһдин бер қыз туғды, атыны Ғөләмәлик Күрекле дип қуйдылар. Күрекленең һөнәре андағ ирде кем:

Көлсә – қу ағачға йапрақ бөтәр ирде,
Басса – тақыр йиргә үлән бөтәр ирде,
Сачен тараса – йенҗү түгелер ирде,
Төүкерсә – алтун төкерүр[2] ирде.

Әмма дөнйада артуқ туғмыш ирде. Қырық қолач алтын сарай төзеделәр, ул қызны айға-көнгә күргүзмәй, ул сарайда қуйдылар. Қашында Үрдәхан дигән дайәсе бар ирде, тәқи үзгә дайәләре дә бар ирде – атлары мәғлүм ирмәс. Вә ләмма анларның мәшһүре Үрдәхан ирде.

Бу қызын хан адәмиғә күргүзмеше йуқ ирде. Әмма хан гяһ-гяһ килеб күрә торған ирде.

Қач йыллардин соң қыз буй йитте. // *(70б кәгазь)* Бер көн уйнабултурурлар ирде, қыз әйде:

– Үрдәхан! Бу сарайдан чықарсән – нә күрүрсән? – диде. – Әмма йаруқлуқ бу сарай эчендәмедүр, кинә ташқару да бармудур? – диде.

Анда Үрдәхан әйде:

– Әмма бу йаруқлық сәнең йөзүң торур. Әмма дөнйа ташқару киңдүр, Ай-Көн бардур, йаруқы мондан артуқдур, – диде.

Анда Ғөләмәлик:

– Аһ, Үрдәхан! Мәнгә күргүзсәң булурму? – диде.

Анда Үрдәхан әйде:

– Сән күрсәң, үләрсән! – диде.

Ғөләмәлик әйде:

– Үлсәм дә, күргүз мәнгә?! – диде, иркенә қуймады.

---

[1] Текст Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендәге сирәк һәм кулъязма китаплар бүлегендә «40т» шифры белән саклана торган кулъязмадан алынды. Исемендә «дәфтәр» сүзе ике мәртәбә кабатлап язылган.

[2] Кулъязмада «түгелер» дип ялгыш язылган.


دفتر دفتر چنگز نامه

دفتر یکی اوّل باشندین بیلالک اوّل باشی نعاجی بیالرندان بیلالک آق
تنکز نیکی ایچنده مالتاشر شهری دیکان بار ایردی اول شهرنینک خانی التون خان دیکان
ایردی خاننینک آتی کورلاوج دیکان ایکی پادشاهدین بر قیز توغدی آتنی علماالک
کورکلی دیب قویدیلار کورکلی نینک حضری اندانغ ایردی کم کولپه قونغاجق یپراق بتار
ایردی با سبب تقیر یرکا اولان بتار ایردی ساچین تاراسه ینجو توکار ایردی
توفکرسه آلتون توکار ایردی اما دنیادا ارتوق توغمش ایردی قریق قولاج التون سری
توزی دیلر اول قیزنی آی غه کونکا کورکوزماس اول سرایده قویدیلار قاشنده اورده
خان دیکان دیاسه بار ایردی تیک اوزکا دیالرده بار ایردی اتلاری معلوم ایرماس
والماالارنینک مشهوری اورده خان ایردی بو قیزنی خان آدیغه کورکوزمش یوق
ایردی اما خان کاه کاه کیلب کورا تورغان ایردی قیچ یللاردین سونک قیز بوی یتی

I вариант кульъязмасы

Анда Үрдәхан тәрәзүне ачмаға башлады, қыз бақуб ултурур. Тәрәзүне ачды, қыз үлгән мәңизлек исе китте. Бу дайәләр үлгән санадылар, чулашыб йығладылар.

Көн тәүлеге булды – исе йуқ йатур[3] ирде. «Имди ханға нә диб әйтүрмез?» – тиб, сағыш итеб ултурур ирделәр, қыз исен йыйғыб алды. Дайәләре шад булдылар, қыздин сөаль қыйлдылар:

– Нә күрдең? – диделәр.

Ул әйде:

– Бағанағы күргән Көнемдин қорсағыма бер уғлан булды[4]. Атама нә диб әйтүрсез? – тиде.

Ханның килә торған вақыты йиткән ирде (вақыт-вақыт[5] қызын күрмәгә килә торған ирде). Ул вақытта хан йитеб килде, қызын күрде – қызының битенә сибкел төшүбдүр. Хан қызына әйде:

– Аһ! Битеңә сибкел төшүбдүр, қызым, сәнгә нә булды? – диде.

Қазгу берлә эвенә килде, әйде:

– Аһ, Көрләвеч! Икәвемез хәләл җефеткә килгәли мондай ойат эш килгәне йуқ ирде. Қызымызға бер бәла булубдур, битенә сибкел төшүбде[р]. Нәйтсә булур? – диде ирсә, Көрләвеч әйде:

– Моны бу йиргә, бу йортға *// (71а кәгазь)* биреб булмас.

Хан әйде:

– Имди андағ булса, нәйтсә булур? – диде.

[Көрләвеч] әйде:

– Моны, гүзәл кимә[6] берлә тиңезгә йибәрәлең! – диде.

Хан әйде:

– Раст әйдең! Андағ булсун! – диде.

Хан алтундин гүзәл[7] кимә төзделәр. Қач көнләрдин соң Ғөләмәлик Күреклене қырық қырқыны берлә, күк кәбтәре, алтын қузы[8] берлә, тутый қошы берлә, төкәнмәс азуқ, сүнмәс чырақ берлә кимәгә салыб йибәрделәр Төн тиңезенә. Торғу дигән тағдан салыб йибәрделәр. Әйделәр кем, «бер насыйблеккә төш булғай!», – диделәр.

---

[3] Кулъязмада «йатру» дип хаталы язылган.

[4] Бу сүз ялгыш ике мәртәбә язылган.

[5] Кулъязмада «вақыты» дип ялгыш язылган.

[6] Кулъязмада «гүнәрле кимәдә» дип хаталы язылган. «Гүзәл» дигән сүз күчерүче (бәлки, протографын күчергән кеше) тарафыннан ялгыш «гүнәрле» дип язылган. Бу очракта бары тик «гүзәл» сүзендәге «за» һәм «ләм» хәрефләренең төп элементлары, гүяки, бераз кул калтыраганга яки каләм очы төртелүдән, бозыбрак язылган.

[7] Кулъязмада «гүнәрле» дип хаталы язылган.

[8] Кулъязмада «қуры» дип хаталы язылган.

Андан берничә ҡач көнләр үткәндин соң, ишеттеләр[9]: Торматай Чәчәннең уғылы Тумавыл Мәргән дигә[н] бер асыл зат атасына ачы булуб, ил читенә чыкыб йатур иркән ҡырыҡ ҡазаҡы берлә. Ул кешенең арасында ҡаравылчы Шәбә суҡыр дигән ҡаравылчы бар ирде. Бер көн ултурур ирделәр, Шәбә суҡыр әйде:

– Алысдан бер ҡара күренүр, – диде.

Анда Мәргән әйде:

– Нә нәрсәдүр? – диде.

Шәбә суҡыр әйде:

– Кимәгә охшайдур, – диде. Кинә Шәбә суҡыр әйде: – Мәргән! Мән сәндин шуны үтүнәмән, – диде, – ул кимәнең эче сәнең булсун, тышы мәнем булсун?! – диде.

Мәргән әйде:

– Күзгә күрүнмәгә[н] нәрсәнең нәсен әйәр кеше?.. Хуш, алай булса, сәнең булсун! – диде.

Шәбә суҡыр тәғзыйм берлә ҡоллуҡ итте, йәнә әйде:

– Бер алтун кимә торур, – диде, – эчендәге һәм андин хасыйлраҡ торур, – диде. – Бер ҡара тағ ҡабат торур, үтә күрәрмән, – диде. – Таңла төш ваҡытында килүр булғай, – диде.

Шәбә суҡырның айтган ваҡытында кимә килде. Ҡ[ат]ырға, йаҡты бер алтун кимә торур, һич йоруҡын белмәделәр ишеге ҡайдин иркәнен, ачмаға йоруҡ белмәделәр. «Нәйтсә булур?» диде.

// (71б кәгазь) Шәбә суҡыр әйде:

– Аһ, Мәргән, атыб бозғыл! – диде.

Мәргән айды:

– Туры атайынму, ҡыйа атайунму? – диде.

Шәбә суҡыр әйде:

– Туры атсаң, эчендә җанлыҡ булса, тигәр булғай, – диде. – Ҡыйа атыб бозғыл! – диде.

Ҡыйа атыб, кимәне бозды. Кимәнең эчендин ҡырык кырҡыны берлә, алтун ҡузы[10] берлә, тутый ҡошы берлә, күк кәбтәре берлә Ғөләмәлик Күрекле чыкты.

Бу кимәне ҡыйа атыб бозған өчүн, Ҡыйат Тумавыл Мәргән диб аның өчүн ат ҡуйдылар. Имди бу ҡыйат дигән халыҡ аның нәселедүр, аның өчүн аның оруғыдур диделәр.

Йәнә ул кимәнең эчен Тумавыл Мәргән алды, тышын Шәбә суҡыр ташыды.

[9] Кульязмада «эчтеләр» дип ялгыш язылган.
[10] Кульязмада «куры» дип хаталы язылган.

Йәнә ул кичәгесен Тумавыл Мәргән Ғөләмәлик Күрекле берлә чадыр қорыб йатур булды. Анда Ғөләмәлик Күрекле әйде:

– Мәнең бу қорсағымдағы бала дөнйадағы адәмдин дәгүлдүр, нурдан пәйда булғандур, – диде. – Һәрайинә, бераз көнгә сабыр қыйлсаңыз, нә булур?! – диде.

Анда Тумавыл Мәргән әйде:

– Сезне безгә Тәңре биргәндүр. Без ул көнгә бақмасбыз, – диде.

Ғөләмәлик күрүкле әйде:

– Һәрайинә, без күкдә йөргән ақ шоңқар дик нәрсә ирдүк, безне сезгә Тәңре биргәндүр. Һәрайинә, алай да булса, күңелемне қалдурмасаң булур ирде?

Анда Тумавыл Мәргән әйде:

– Нә мондағ күб сүз әйтүрсән?! – диде. – Бер сабыр ике сабырынча хәддегә қуймасдур, вай-вай, таһирә! – диде.

Ғөләмәлик Күрүкле әйде:

– Һәрайинә, сез ирсез, күб қару итеб булмас, – диде.

Ул кичә чадыр қоруб йатдылар ирде.

Үзе буғаз, үзе қыз,
Уразлы иргә йулуғыр!
Йәнә үзе буғаз ирмеш.
Кинә үзе мондағ *// (72а кәгазь)* нәрсәне,
Һич адәм мондин үзгәне
Һич күрмеше йуқ ирмеш[11].

Андин соң қач көнләр кичте. Андин соң қорсақдағы уғлан туғды ирде, атын Тәңре биргән дуйу[н]лықдыр диб, Дуйын-Бәйан атадылар.

Ул уғул туғандин соң Торматай Чәчән дөнйадин вафат булды диб ишеттеләр. Йәнә ата[сы] үлгәндин соң Тумавыл Мәргән йортына килеб, ханлық сөрделәр. Йәнә Ғөләмәлик Күрекледән Тумавыл Мәргәндин йәнә ике уғул туғды: Бүдәнәтай, Бөлгүтай дигән ирде.

Ул ике уғул туғандин соң Ғөләмәлик Күрекленең күңеле йаман булды. Анда Тумавыл Мәргән әйде:

– Халық «уғул» тисә – сөйүнер, сән «уғул» тисәң – хурланурсән? – диде. – Нә өчүн мондағ булурсән? – диде.

Ғөләмәлик әйде:

– Вә ләмма халык уғул тисә сәвенер, без аның өчүн хурланурмыз – без нурдан йараған Дуйын-Бәйанның қазғусындан үләмән! – диде.

– Хуш, имди нә әйтмәгә хурланәсән? – диде.

Ғөләмәлик Күрекле әйде:

[11] Кулъязмада «иремеш» дип ялгыш язылган.

Қоланға ийәргән – чәчәккә аунар,
Дуңызға ийәргән – балчыкға аунар.
Сән хан баласы ирдең,
Мән сәнгә ийәреб ни күрдүм?

– дигәймән, – диде. – Имди сән үлсәң, йортны бу ике уғылың тотарлар, мәнең бу уғылум, бу Дуйын-Бәйанға бирмәсләр! – диде. – Имди [бу ике] уғылыңны моңғулға йибәрген!? – диде.

Анда Тумавыл Мәргән бу ике уғылын моңғулға йибәрде, дай хашқадан йитешәр хашқа қуштылар. Бу ике уғул моңғулға киттеләр. Йорт Дуйын-Бәйанға қалды.

Бу ике уғул киткәндин соң, бу Дуйын-Бәйанға қыз алды. Нур тағында Кәнти дигән шәһәр бар ирде, ул шәһәрдә *// (72б кәгазь)* йите солтан бар ирде, анларның иң кечесе Толунсул дигәннең қызын алдылар. Ул қызның аты Алаңғу дигән ирде.

Ул қызны алғандин соң Тумавыл Мәргәннең Аллаһ ғөмерен бетүрде, вафат булды. Дуйын-Бәйанга ханлық қалды, ханлықны ул сөрде.

Йәнә бу Дуйын-Бәйандин, Алаңғудин өч уғул туғды: олусының аты Бүдәнҗар, андин кечесенең аты Қағынҗар дигән, өчүнчесенең аты Салжу[т] дигән ирде. Имди қатаған дигән халық андин чықыбдур, бу Қағынҗарның нәселедүр[12]. Имди салжут дигән халық бу Салжутның тохымыду[р], бу салжут дигән андин чықыбдур.

Бу өч уғул туғандин соң Дуйын-Бәйан, Аллаһ ғөмерен бетүрде, вафат булды. Үләрендән өч [көн] борун халқын йыйғыб васыйәт әйде:

– Аһ, халық уғылы! Алған хатуным [берлә] тереклекдә бергә үләлек дигәнләр [ирдек]. Безләр үләсе булдуқ, сезләр қалур булдуңыз. Имди сезләргә васыйәтем ул булсун, – диде. – Бу мәндин туғған бу өч уғул йортын белмәс, ата-анасыны белмәс, күзләре малға туймас – ошбундағ хәрамзадә улурлар. Боларның өчүндер кем: бересе сиһшәнбә кичәсе пәйда булғандур, андин икесе сиһшәнбә көндүзе пәйда булуб вөҗүдгә килделәр – аның өчүн белмәсләр[13], – диде. – Имди болар йортға лайық дәгүлдүр! – диде. – Имди мән үлгән[дин] соң Алаңғуға төш-төн булуб килүрмән, – диде, – андин бер уғул булур. Ул уғул йортқа лайық булур, аны сақлаңыз!? – диде. – Имди мәнем билгүм ул булур, – диде, – төңлүкдән көн булуб инәрмән, ишекдин бүре булуб чықармән! – диде.

---

[12] Бу урында Бүдәнҗарның ыругы турындагы сүзләр төшеп калган булса кирәк.

[13] Тексттагы сишәмбе көн турындагы сүзләр, күрәсең, кайбер ырымнарга бәйледер. Чөнки аерым инанулар буенча, атнаның сишәмбе һәм чәршәмбе көннәре иң начар көннәр булып исәпләнгән. Сишәмбе – кан көне дип саналган, шул көндә Кабил Һабилне үтергән, берничә пәйгамбәрне дә сишәмбе һәлак иткәннәр.

Йәнә бу васыйәтләрне қыйлғандин соң, өч көн булуб ирде – Дуйын-Бәйан, Аллаһ ғөмерен бетүрде, вафат булды.

// (73а кәгазь) Дуйын-Бәйан үлгәндин соң бу өч уғылы хәлайықға қан қойдылар[14]: байларның айыры өркәчле нәрен, айағы чалыш йурғасын, муйны озун арғамағын, бәһадур йегетләренең көбәсен алды, бикләрнең қызларын алды, халық уғылына шундағ көч итте – халықның[15] чыдарлықы қалмады.

Шул вақытында «Ағамыз үлүбдүр, – диб, – җиңгәмез[16] тол қалыбдур», – тиб, Бүдәнәтай, Бөлгүтай, утуз ир бикләре берлә, зийарәтға килделәр. Күрделәр – җиңгәләре қазғу берлә йаман булуб ултурур ирде. Үгүтләделәр, әйделәр кем:

Үлсә үләр китәр,
Қалғаны йортын[17] көтәр,

– диде. – Һәрайинә, үлгән артындин үлгән йуқ,

Күңелне бик тот,
Йортыңны йахшы көт!

– диделәр.

Вә йәнә[18] Бүдәнәтай, Бөлгүтай тубчақ атларын менеб, ау аулай киттеләр. «Җиңәмезгә уйунға шайәд кийек табарбыз», – диб, Бар тағына бардылар, ау аулаб бақтылар. Ауларына бер чөкүгү дигән кийек төште. Тере тотуб алдылар. Андин үзгә нәрсә табмадылар. Йәнә эүгә қайттылар.

Йулда килә торғач бер йирдә чәнгәл йығачы бар ирде, йығачлардан бер атлуғ кеше чықа килде. Қаршы бардылар, йулуқтылар.

– Қайдан килүрсән? – диб сордылар.

Анлар әйделәр:

– Қытай-Хотандин босыб киләбез, – диделәр. – Атамыз Маңғытай би дигәндүр, – диде. – Өч айдан бирү ачбыз, – диде, – имди үләбез, – диде. – Бу кийекне безгә ғинайәт қыйлсаңыз, нә булур? – диделәр.

Анда Бүдәнәтай әйделәр:

– Бер тол җиңәмез бар, – диде, – аңа уйунға алыб барабыз, – диде, – биреб булмас, – диде.

---

[14] «Кан қойдылар» гыйбарәсе ялгыш булса кирәк. Монда бер сүз һәм кушымча төшеп калгандыр, ихтимал, дөресе «қан-йәш қойдырдылар» рәвешендә булырга тиештер.

[15] Кулъязмада «халқының» дип ялгыш язылган.

[16] Кулъязмада «җиңгелгәмез» дип хаталы язылган.

[17] Кулъязмада «тортын» дип хаталы язылган.

[18] Кулъязмада «вай» дип хаталы язылган.

Андин ул әйде:

– Һич булмаса, мәнең бер уғылымны алың, буны бирә күреңез? Без ач үлмәлек, – диде.

Анда Бөлгүтай әйде Бүдәнәтайгә:

– Бу кийек бер қазан ит ирмеш, йылқы бақыб, қымыз тотурға бу [уғыл] йахшыдур! – диде. – Азуқ, итеңезне *// (73б кәгазь)* биреб алыңыз! – диде.

Бер қуйнуң бер ботын биреб, бу уғылыны алдылар. Аты Балын дигән ирде, Балын уғылы Қайулдар дигән төмән маңғыт төбе бер төб, атасы Қайулдар бу төмән маңғыт андан чықыб торур.

Йәнә бу уғылны алыб килделәр, җингәләренә бирделәр, әйделәр:

– Җиңәм! Йылқыңны бақыб, қымызыңны тотарға йахшыдур, – диде. Бүдәнәтай, Бөлгүтай әйде:

– Артымыздан йаман хәбәр килебдүр, Таңғутдан илче килебдүр, без қайтабыз! – диделәр.

Анда Алаңғу әйде:

– Бераз тора төшсәңез, нә булур? – диде.

Анлар әйде:

– Торуб булмас! – диделәр.

– Һич булмаса, энеләреңезгә ғақыл-үгүт бирсәңез нә булур? – диде.

Анлар әйделәр:

– Без нә ғақыл, нә үгүт бирәлек? – диделәр. – Имди безнең сүзүмез энеләремә әйтүр шул, қашындағы бикләренә әйтүр сүзүмез, васыйәт-үгүтемез, ғақылымыз улдур:

Қарыйларындин киңәш сорсын,
Тәңресенә тәүбә қыйлсун!
Қарыйларын түргә кичүрсүн,
Кечекләрдин хезмәт қылдурсун!
Йау илнең йат нөгәрегә серен әймәсүн,
Қаласының төбен ур итсүн!
Тарбазасының аузын киң итсүн,
Хасыйле – йахшыны кире салмасун!
Бите йахшыдан төкәлмәсен!
Тимерчедән киңәш сормасун,
Қассабчыдан киңәш сормасун,
Үтмәкчедән киңәш сормасун!
Һәркем, күргән күргәнен әйтүр,
Күтәргән үтмәген сатар.

Һәрайинә, қош чөймәгән қош чөйсә,
«Қарғадан қу алдырурмән! – дир[19].
Мал көтмәгән мал көтсә,
Малға қу ут утлатур.
Түрә көтмәгән түрә көтсә,
«Адәми итене йийәрмән!» – дир.

Аның тик адәмиләр, мәнең энеләремне шундағ кешеләр йаман итеб торадур булғай! – диде. – Һәрайинә, белмәгәнләр белүрләр, үгрәнмәгәнләр үгрәнүр, – диде. *// (74а кәгазь)* – Һәрайинә, бөләр йортның билгүсе ул булур:

Үз ағасын йаманлар,
Кеше ағасын мақтар.
Үз йортын йаманлар,
Кеше йортыны мақтар.
Олусы тотуб торуб,
Кечесе сөйләр.
Мысқылчы-айыңчы булур!

– диде.

Уңар йортның[20] билгүсе ул булур:
Олуғларын түргә кичүрүб,
Кечесен хезмәт қыйлдур[ур].
Тәңресенә тәүбә қыйлур.
Олуғларындин киңәш сорсун!
Ирән ат менгән қызыл битле
Уғландин киңәш сормасун!

– диде. – Безнең әйтүр сүзүмез ошбудур, монларны тотса, йаман булмасдур. Тота белсәләр, ошбу киңәш йитәр, – диделәр. Ошбу үгүтләрене үгрәткәндин соң Бүдәнәтай, Бөлгүтай бикләре [берлә] қайттылар.

Анлар қайтқандин соң бу өч уғылы Алаңғуның халықға көч иттеләр, борунғыдан[21] йаман эш қыйлдылар.

---

[19] «Чөйсә» сүзе кульязмада «чөйшә» дип хаталы язылган. Бу икеюллык башка китапларда, мәсәлән, Әбелгазыйның «Шәҗәрәи төркийә» әсәрендә: «Қош чөймәгән қош чөйсә, / Қарға берлә қаз алдурурмән! – дир» рәвешендә язылганлыгы Будагов сүзлегендә дә күрсәтелгән *(Лөгате төрки: сравнительный словарь турецко-татарских наречий. Т. I / сост. Будагов Л.З. – СПб, 1869. Репринтное издание. – С. 501).*
Аерма бары тик «Қарғадан қу» (аккош) һәм «Қарға берлә қаз» сүзләрендә генә. Бу юллар әлеге әсәрләргә уртак чыганактан алынган булса кирәк.
[20] Кульязмада «йортынның» дип хаталы язылган.
[21] Кульязмада «бууынғыдан» дип хаталы язылган.

Бу йаманлық берлә қач көнләр үткәндин соң халық уғылының чыдары қалмады, Алаңғуға йығлаша килеб әйделәр:

– Аһ, Алаңғу! Безнең итемез бетүб, сөңләкемез[22] қалды, чыдар хәлемез қалмады! – диделәр, йығлашдылар.

Анда Алаңғу әйде:

– Дуйын-Бәйан үләрендән өч көн борун әйтмәдемү, «Мән Алаңғуға төш-түл булуб килүрмән» димәдеме? Килгәндүр, андин мәнгә бер уғлан булғандур, ырысыңыз[23] булса, уғул булғай, – диде.

Бу сүзне ишеткәндин соң, сәвенешеб қайттылар. Андин соң бу сүз аларға мәшһүр булды – бу [өч] уғул һәм ишеттеләр. Бикләре берлә Алаңғуға килделәр, ултурдылар.

Алаңғу әйде:

– Нә йомуш берлә килдеңез? – диде.

Анда уғланлар әйделәр:

– Бер өтүрүк сүз ишетеб килдүк, – диделәр. – Инде сән «Қорсағымда уғлан бар» тәйүрсән! – диделәр.

Анда Алаңғу әйделәр:

– Мәнең сүзем нә *// (74б кәгазь)* өчүн өтүрүк булсун? – диде. – Атаңыз үләрдән өч көн борун әйтмәдемү «Мән төш-түл булуб килүрмән» димәдемү? Төш-түл булуб килде, андин мәнгә бер уғлан булды! – диде.

Уғланлары әйделәр:

– Өтүрүк булмай, нәдүр сүзүң? – диде.

Сән төплән балуқмусән, қомға аунаб бала табмаға?
Мани дигән қошму сән, көн эссесендән бала табмаға?
Қавын-қарбузму сән, ирсез орлық йыймаға?
Қаз анасыму сән, тиңезгә көүә ултуруб бала табмаға?
Ләүме сән, сыу эчеб бала табмаға?
Тавықму сән, көлгә аунаб бала табмаға?

– Сән төнәве көнге бер ботға сатыб алған Балындан уйнаш итеб табғансән! – диделәр.

Анда Алаңғу әйде:

– Үземдән туған уғланларсыз, мәне қурқытасән? – диде.

Анда анлар әйде:

– Йуқ, қурқытмаймыз, – диде. – Өтүрүк сүз әйткән өчүн әйтәбез! – диделәр.

Алаңғу әйде:

– Мәнең сүзем нә өчүн өтүрүк булсун? – диде. – Ин[ан]масаңыз,

[22] Кулъязмада бу сүзнең ахыры хаталы язылган.
[23] Кулъязмада «ызымыңыз» дип хаталы язылган.

изыңыз[24] сах, кеше инанғудай кешедән, билгүсе улдур – төңлекдән көн булуб инәр, ишекдән бүре булуб чықар, – диде.

Бу сүзгә бу өч [уғул] мөтәхәйир булуб қайттылар, ил инанғудай кешедән өч кеше бар ирде: бересе – төрекмән Килмөхәммәд дигән ирде, андин бересе – қыбчақ Қарабай дигән ирде, йәнә бересе – йөз Уравыҗ дигән ирде. Бу өч кешегә нарасидә уғланлар һәм инанур ирделәр. Ушандағ растлық[25] адәмләр ирде.

Алыб иңделәр Алаңғуға белдүрмәй. Таң мәң булуб ирде, көн булуб, йар[у]қын инде. Бу өч кешенең исе китте. Таң йаруғандин соң исен йыйыб алдылар. Анда Килмөхәммәд әйде:

– Без исергән дик булуб ултурурмыз, – диде. – Бағанағы нә йаруқын ирде? – диде. – Ул бүре булса, *// (75а кәгазь)* чыдамас, йаләремезне чикләң! – диде. – Йайнең тавышына бүре туқтас булур, – диделәр. Йаләрен тартыб чәкләделәр – йылқы йаллы күк бүре чыка килде. Артын[а] қараб «Чыңғыз, Чыңғыз!» диде дә, чәнгәллеккә төште. Болар белделәр, «Бу Дуйын-Бәйанның үзе ирмеш!» – диделәр. Тәқи халық уғылына әйделәр:

– Раст ирмеш!– диделәр.

Халық һәм инандылар. Бу сүз ғаләмғә мәшһүр булғандин соң қач көнләр үткән ирде, Алаңғу хәмүләсендән бушанды – бер уғул туғды: алтун изарлық[26], йағрынында мөһере бар ирде, ул мөһернең эчендә Җәбраил ғәләйһиссәламнең аты бар ирде. Үзе ир чырайлық, бүре йағрылық. Атын Чыңғыз қуйдылар, бу Чыңғызны күргән кеше «ишегендә үләйен» дир ирде, қашында ултурған кемсә май дик эрер[27] иде, «Атым, тунум, малым, башым сәнең булсун!» дир ирде. Пәйғамбәрләрдин үзгә ханларда мондин артуқ хан дөнйаға килде тиб булмас. Әмма ғаләмдә бер артуқ туған падишаһ ирде.

Әмма атасындин қалған халқы бу Чыңғызға аудылар. Халық уғылы бу өч уғылны ташладылар, Чыңғызға нөгәр була башладылар. Борунғы өч уғул күрә алмас булдылар, «уйнашдан туған уғул йортны көтәр булды» диб, Чыңғызны үлтүрмәк өчүн килделәр бикләре берлә.

Анларның эшен белделәр, әйделәр:

– Сездин бу уғул йортқа лайықрақ охшар! – диделәр. – Алур булсаң, атаң малын өләшеб алғын! Андин үзгә сезнең һәм қулыңыз һәм сүзеңез үтмәс! – диде.

Анда бу өч уғул үз аралары сүзләшделәр: «Моны белдерә үлтүрүб булмас, – диделәр, – белдүрмәй үлтүрәлек», – диделәр дә, *// (75б кә-*

[24] Бу сүз кулъязмада «иңлытыңыз» рәвешендәрәк, хаталы язылган.
[25] Кулъязмада «растлықы» дип ялгыш язылган.
[26] Кулъязмада «идарлық» дип хаталы язылган.
[27] Кулъязмада «эрерә» дип хаталы язылган.

газь) андин соң атасының малын өләшеб алдылар. Дүрт өлүшкә бүлүб айырдылар. Дуйын-Бәйанның бер алтунлы-җәүһәрле садағы дүртесенең арасында қалды. Әйделәр: «Анам кемгә ханлық бирсә – ул алсун!» – диделәр. Анда Чыңғыз садақдан дәмасын өзде. Йәнә малны өләшеб алғандин соң, анасына килделәр, әйделәр:

– Атамызның садағы сән кемгә ханлық бирсәң – ул алсун! – диделәр.

Анасы әйде:

– Сез мәнем сүзүм тота[р]мусыз? – диде.

Һәркем үз йортын йаманлаған – йат йортға табиғ[28] булур.
Үз ағасын йаманлаған – йат дошманға хур булур.
Үз анасын йаманлаған – йаралы булу[р]

– диде. – Сез мәнем сүзүм тотмазсыз! – диде.

– Бәли, тотамыз! – диделәр.

– Тотар булсаңыз, һәрқайсыңыз тулуғдан ингән көнгә[29] қурлы қурыңызны салыңыз! – диде. – Кемнең қуры көнгә эленеб туқтаса, ул – хан булсун! – диде.

Анда өч уғылының алтун қурлары бар ирде, Чыңғызның йебәк қуры бар ирде. Әүвәл бу өч уғылы қурларын салдылар, һич туқтамады, йиргә төште. Чыңғыз йебәк қурыны салды, ул туқтады эленеб. Торған барча хәлайық күрделәр.

Бу өч уғыл андағ сақындылар:

– Ай, анамыз җаду ирмеш! – диб, күңелләре бозман киттеләр. Үз араларында әйделәр: «Бу Чыңғызны үлтүрмәй булмас!» – диделәр.

Анлар қайтыб киткәндин соң қач көнләр үткәндин соң, Чыңғыз уғлан[лар] берлә қазақ чықты. Анасына әйде:

– Мән ошбу Тикәлек[30] суыны қыдырыб китәрмән. Тикәлекнең [башында] Көргүрлән дигән [тағда] бер йыш қара йығач булур диб ишетәмән. Шул[31] қара йығачда торармән, қош кизләб атармән, ул қошның йонын суға йолқармән. Ул қошның йоны су берлә килүр – мәнем аманлығымны андин белгәйсез! – диде. // *(76а кәгазь)* – Ау аулармән, айу, арслан йөгүртүрмән, – диде.

Өч уғул: берсе йөзнең булур ирде, берсе маңғытның, берсе «ақтуған» оранлы илнең булур ирде. Бу өч уғул берлә қазақ киттеләр.

Йәнә халық уғылы күренешкә килделәр ирсә, қана Чыңғыз – йуқ

[28] Кулъязмада «табиғә» дип хаталы язылган.
[29] Кулъязмада «көнгәһ» дип хаталы язылган.
[30] Кулъязмада «Тикәлекне» дип ялгыш язылган.
[31] Кулъязмада «сул» дип ялгыш язылган.

торур, қанда барғанын белмәделәр. Имди инәр димәк булғунча Чыңғыз [йук] булды. Алаңғудан сордылар:

– Хан қайда булды? – диб.

Алаңғу әйде:

– Йәш уғул жанын қурқутыб қачқан, ул боса, – диде.

Анда халық уғылы чулашыб йығлашдылар:

– Һич булмаса, безнең күземезгә күргүзмәй жанымызны алсаңчы?! Күргүзүб жанымызны нә өчүн алдың? – диб, андағ фөрйад әйләделәр.

Анда Алаңғу әйде:

– Андағ бик сәвәр булсаңыз, иртә килсүнләр йите ыру-илнең кеше[се]! Килең, мән йулын үгрәтәйен, – диде.

Йәнә борунғы өч уғул халық уғылына андағ көч иттеләр, «Қана сезнең йахшы табқан түрәңез?» – диб, борунғыдин йаман көнләр салдылар, халық уғылына зарулук[32] иттеләр, халықның һич чыдарлығы қалмады.

Йәнә йите ру илнең йите кеше килделәр, йулын сорадылар.

Анда Алаңғу әйде:

– Барың, сыуға қараб торуңлар! – диде. – Хәбәре килүр, – диде.

Бардылар, суға бақыб тордылар – һич нәрсә күрмәделәр. Қайтыб килделәр. Алаңғуға әйделәр:

– Нәрсә күрмәдүк? – диделәр.

Алаңғу әйде:

– Һич нәрсә суда күрмәдеңезмү? – диде.

Анлар әйделәр:

– Бер қәүм қошның йоны ақыб бара торур, – диде.

– Имди, андағ булса, мәнең уғылым хәбәре ушал йондур, – диде. – Уғылым сүзе мондағ ирде, – диде, – «Ушал Тикәлекне қыдырыб китәрмән, қош кизләб атармән, йонын суға йолқармән!» – диде. – Шул қошның йоныдур! – диде. – // *(76б кәгазь)* – Эзләр булсаңыз, Тикәлекнең башында[33] Көргүрлән дигән тағ булур, ушал йирдә торарлар, – диделәр. – Чыңғызны күрәр булсаңыз, борунғы Чыңғыз дәгүлдүр.

Ақ атлы, ақ тунлы,
Алтун бүрекле, алтун садақлы,
Ир чырайлы, көрчи сынлы

– ушандағ кеше булуб күренүр! – диде. – Анларны андин табарсыз – айу берлә арслан йөгү[р]түрләр, айу ақырур, арслан қычкырур – андин белүрсез! – диде. – Қашында өч уғул бардур, нәчүк булмас йулуқсаңыз,

---

[32] Бу сүзнең дөресе, ихтимал, «золумлуқ» сүзеннән бозып язылган яисә «азарлық» (җәбер, хәсрәт), «зарарлық» булгандыр.

[33] Кулъязмада «башыны» дип ялгыш язылган.

әүвәл «ақ-тый-лақ» диб қычқырғайсыз! – диде. – Анда аваз бирмәсә, «ақ-ту-ған, ақ-ту-ған» диб қычқырғайсыз, анда аваз бирмәсәләр, «ту-ту» диб чарлағайсыз! – диде. – Анда аваз бирмәсә, ғәиб булғаныдур, – диде.

Ошбу сүзләрне айтғандин соң, бу кешеләр Тикәлекне қыдырыб киттеләр. Тикәлекнең[34] башыға өч ай (туқсан көндә) барыб йиттеләр. Бер үчә қыйа тағының башыға менеб қарадылар кире: артларында бер ақ сарай, күк сарай күренүр. Ул сарайға таба[35] қайттылар. Ул сарайға бер азинада[н] килделәр, сарайға бармадылар. Бер тағның мәхәлендә йаттылар. Йәнә бер вақыт булуб ирде, кеше сөйләшкән тик булуб аваз килде, тәқи қырғы чарлаған тик булды. Белделәр – кеше авазыға охшар аваздур. Бер кешенең авазы килде, әйтүр: шул тағ мәхәлендә айу бар, кеше йулының йуйыға охшар. Үзе шул мәхәлендән үтмәгәндүр, – диде. – Атының йулы йуқ чықа йатур, – диде. Болар һич аваз бирмәделәр.

Йәнә бераз көндин соң айуын ақыртыб, арсланны қычқыртыб, ау аулады чыққанға охшады. Болар аңа қаршу бардылар, бер кеше йитеб килде – ақ атлы, ақ тунлы, алтун бүрекле, алтун садақлы, ир чырайлы, көрчи сынлы бер адәмдүр. Ул әйде: *// (77а кәгазь)*

– Нә кешесез? – диде.

Анда болар әйде:

– Дуйын-Бәйан! – диделәр.

Ул кеше күзләрендән аһ оруб [ғәиб булды], чулашыб йығлашдылар. Йәнә қайттылар, урынларыға йаттылар.

Йәнә бер қач көнләр кичкән ирде, йәнә ау аулай чықғанға охшады, болар қаршу бардылар. Борунғы тик тәқи йәнә қаршу чықа килде, әйде:

– Нә кеше торурсыз? – диде. – Безне аңдыб йөрүрсез? – диде.

Анда болар әйде:

– Сәнең дәрдеңнән үлә йөрүрбез, – диделәр дә, чулашыб йығлашдылар.

Боларны күрүб Чыңғыз тәқи йығлады. Йәнә Чыңғыз әйде:

– Монда сезне кем үгрәтеб йибәрде? – диде.

Болар әйделәр:

– Анаң йибәрде, – диделәр.

– Ул сезне анам йибәрсә, қана мәнгә анамның бүләге? – диде.

Майқы қулындин бер йөзекне чықарыб бирде.

Чыңғыз йөзекне күрде, көлде. Әйде:

– Эш чын булса, билек – Майқы, сәнең булсун! – диде. – Үзгәләр

[34] Кулъязмада «Тикәрлекнең» дип ялгыш язылган.
[35] Кулъязмада «табаһ» дип хаталы язылган.

күңлеңезгә йаман санамаңыз?! – диде. – Әгәр Майқы булмаса, мән сезгә йуқ ирдем, сез мәнгә йуқ ирдеңез! – диде.

Анда Чыңғыз хан әйде:

– Кил, имди қуышқа қайталық! – диделәр. – Аш-су ашаб[-эчеб], уйнаб-көлүб ултыралық! – диде.

Қуышларыға бардылар:

Хали-бисатлар түшәклек торур.
Төкәнмәс арақы, бал, чағыр,
Шәраб, сүнмәс чырақ торур.

Қач көндин анда мәкян тоттылар. Йәнә бер көн Чыңғыз хан әйде:

– Бу арақы берлә чағыр-шәраб безгә нәрсә бирмәсдүр! Кил, имди киңәш итеб ултуралық!

Ул бикләр әйде:

– Без кұбдән күңлүм алайдур дидүк, – диделәр.

Чыңғыз хан әйде:

– Имди, сез безгә килебсез, нәчә ыру халық берлә берсез? – диде.

Анда анлар әйделәр:

– Арғысын сорсаң: тәләңүт, чығытай, муйтан, төрекмән, кирәйәт, оңут, қаған, зунғаз, орғут берлә бербез! – диде. – Биргесен сорсаң: арнау, бөкәчке, тәрәс, зимән, *// (77б кәгазь)* тама, йаба, барлас, қағас, қот, қаңлық, уйсын – бербез[36], – диде.

– Сән безнең булсаң, без анларның ирен ир уйла[ға]н йиремез йуқ, кешесен кеше уйлаған йиремез йуқ ирде, – диделәр.

Чыңғыз хан әйде:

– Кил имди, сез[не] безгә, безне сезгә Тәңре йулықтурғаны өчүн менгән атларымызны азад йибәрәлек! – диде.

Анлар:

– Хуш! – диделәр, азад йибәрделәр, йәйәү қалдылар, ханны нә берлә алыб китәрен белмәделәр.

Анда Балын уғылы Қайулдар әйде:

– Мән орыслықымдан бер һөнәр чықарайын, – диде, арба йасады, дүрт көбчәкле.

Ханның алтун тәхетен ул арбаға қордылар, ханны ул арбаға ултурттылар, кинә үзләре тарттылар.

Уйсын Майқы бинең айақы қысқа ирде, анлар шайы[37] йөри белмәде. Әйде:

---

[36] Мондагы ыру-кабилә исемнәренең кайберләре төп чыганакта хаталы язылганнары белән бергә, безнең тарафтан ялгыш укылганнары да булуы мөмкин.
[37] Кулъязмада «шайыр» дип хаталы язылган.

– Йаранлар! Мән сезнең дик йөрәйү белмәзмән, мән хан берлә арбаға ултурайын, – диде. – Қайсыңыз тартмаса, тайақ берлә күтегә төртеб күрсәтәйен, – диде.

Анлар әйде:

– Алай булсун! – диделәр.

Хан берлә арбаға ултурды, қайсысы тартмаса, тайақ берлә күтегә төртеб[38] күрсәтә. Шул[ай] китте[ләр].

Қач көнләрдин соң барыб йиттеләр. Төнлә барыб сарайға керделәр. Хан элгәрү керде. Андин үзгәләре қайсысы керәрен белмәделәр. Майқы әйде:

– Арба тартған үгүз инәрму йә аны йиккән ийәсе инәрму? – диде.

Хан әйде:

– Ийәсе инмәй, үгүз инәрму соң?! – диде. [...][39]

***

Чыңғыз уғылы Йүчи, Йүчи уғылы Сайын, Сайын уғылы Сартақ, Сартақ уғылы Бортақ, Бортақ уғылы Туғалы, Туғалы уғылы Туқтай уғылы ханға Алай диб әйтүрләр. Ноғрайбирде хан («Күкин йуйған Көтән хан» диделәр), Қыйат уғылы Үзбәк, Үзбәк уғылы Җанибәк, Җани[бәк] уғылы «нәр буйлы» Бирдебәк *// (78а кәгазь)* солтан.

Хан соңы «нәр буйлы» Бирдебәкдән киселде,
Нәр муйны ақ җандан киселде.
Хан Җанибәкнең заманында халық олусы Иделдә булды,
Би игисе хан Җанибәкнең заманында булды.

Хан Җанибәкнең заманындағы бикләрнең атлары болардур: маңытай Борулдай, уйшын Ғәйсә уғылы Амәт, алчын Алау, ақ маңғыт Тимер би, инҗеле[40] Котлыбуға, сиҗут Ғәли би, қыйат Астай уғылы Җирқотлы, Алача уғылы Бимамай қыбчақ, ширин Үрәктимүр, арғын Қарахуҗа, барын Сарай би, борқыт Алатай би, мәмән Әзмәт би, тама Үзәкчү, җәлайыр Батыр би, қыбчақ Мәнгәл уғылы Тимер би, қоңрат қырық сөнгеле Қазарбулат бәһадурның уғылы Бик би[41].

Ас қызы, Қарасач қыбчақ қызы Тайдулы ханым Җанибәк ханға әйде:

Ас қызын алдыңыз,
Безне күңүлдән салдыңыз.

[38] Кулъязмада «күртеб» дип хаталы язылган.

[39] Текст шушы урында тәмамланмыйча һәм дәвамы язылмыйча калган.

[40] Бу атаманың дөресе, бәлки, «илчеген» булгандыр.

[41] Монда күрсәтелгән исемнәрнең кулъязмадан төрлечә укылырга мөмкин булган бер өлеше И.Мөстәкыймов мәкаләсендә (2009) дәлилләнгән вариантта бирелде.

Һәрайинә, туйар ирсәм туйғаймән,
Үземдән туған туқыз солтан сау булсун!

– диде.

Хан Җанибәкнең заманында
Тимер иде бикеңез,
Тиңез ирде халқымыз,
Ул Тимердән соңратын
Таңилә кичәр көнемез.

Дастан

Имди ханларның көбәләренең атлары будур: Чыңғыз ханның «буйан» дигән көбә ирде, Йүчи ханның «қаратау» дигән көбә ирде, Сайын ханның «бөктәр» дигән көбә ирде, Сартақ ханның «сафиҗөйсез» дигән көбә ирде, Бортақ ханның «өйтәңтәр» дигән көбә ирде, Туғалы ханның «тимерқалай» дигән көбә ирде, Туқтағы ханның «йөрәк» дигән көбә ирде, Эчен ханның «айқултық» дигән көбә ирде, Ибраһим ханның «пәйғамбәр» дигән көбә ирде[42], Сафагәрәй ханның үз көбәсенең аты «җиҗәк күз» дигән көбә ирде, Шығали *// (78б кәгазь)* ханның «қаты қабақ» дигән көбә ирде, Бүләр ханның «барқалсақ» дигән көбә ирде, Аққүбәк ханның «бозаубаш»[43] дигән көбә ирде, Йамғурчы ханның «алтун сандуқ» дигән көбә ирде, Күчүм ханның «күкйақа»[44] дигән көбә ирде, Ғәли ханның «ун қарыш» дигән көбә ирде, Ақмәтгәрәйнең «өйүлмә» дигән көбә ирде, Қасим ханның «[кө]йләксә» дигән көбә ирде, Иркилде солтанның «алтун чәкә» дигән көбә ирде, Авәз ханның «барақ» дигән көбә ирде, Сәлмәт ханның «бараҗ» дигән көбә ирде.

***

Һәрайинә, болар халық [бү]ләр ирде,
Бит ақым бәһасе, бараҗым, сәнгә йазуқ булды.
Әүвәл тәхет Сайын хандин төзүлде.
Амәт-Сәлимәт ханның заманында
Тай тулаб, тәхет бозулды.
Хан Җанибәк ханланыб,
Үземез бер булды ирде.
Әйләсе алты ханның йортын ашадуқ,

---

[42] Ибраһим ханныкы ике мәртәбә кабатлап язылган.
[43] Кулъязмада: «бораубаш».
[44] Кулъязмада: «күкйафа».

Үземез ала булды ирсә,
Үз йортымызны үземез йуйдук.
Дөнйа зәүқын уздурдук,
Алтмышда алты башмақ туздурдук,
Нә ади йахшы халық ирдүк,
Хан[ы]мыздан соңратын иллә
Үтүнсездән йуйылдуқ.
Һәрайинә, ат менеб қош чөйгәнләр,
Көбә кийеб, қылыч қоршағанлар иде.
Олы маллар сөргәнләр,
Авыр хәзинә тотғанлар,
Адәмне күзә элмәгәнләр,
Дөнйа узмаз тик күрәр ирдүк.
Без дөнйаны күрмәгән тик булдуқ,
Без дә сез дик ирдүк,
Сез дә бездәй булурсыз,
Әмма кемнәр үтмәгән дөнйадур?
Бу дөнйаны тағат берлә уздурыңыз!

– диделәр.

Дастане мөддәт

Имди ханларның йортларындин Кәф уралының Индәр – Хәким ханның йорты ирде.

Сарайчық – Чалбақ ханның йорты ирде.

Айдархан – Тимер Қотлы ханның йорты ирде.

// (79а кәгазь) Күңелбәдәр – солтан Бәркә ханның йорты ирде.

Өч Үзән – Туқтамыш ханның йорты ирде.

Шәһри Болғар – Бүләр[45] ханның йорты ирде. Аждаһа йылан алды. Алыблар [берлә] суқыштылар, йиңделәр, соңра салыб қачдылар.

Қазан – Шығали хан йорты ирде.

Тора – Орус ханның йорты ирде, Идел-Йайықның башы ирде.

Тубулдан бире – Күчүм ханның йорты.

Ақтүбә – Бачман ханның йорты ирде. Бачман ханның олуғ ағасы булур ирде Тирә хан дигән. Ошбу Тирә хан аның йорты – ул тағның башында бер уба бар и[р]меш, ханның сарайы ул ирмеш. Анларның кем, энесе Йүчи хан дигән. Ул Йүчи ханның йорты Чағатау, Тый тамақындан түбән Алмалы Атаға тигрүр ирде.

Җим берлә Йайық арасы – Җанибәк хан йорты ирде. Җанибәк ханның

[45] Кулъязмада «Буа» дип хаталы язылган.

қызын алыб қачқа[н] уйсын Ғәйсә уғылы Амәт ирде, аны қуа барған алчын [Алау] ирде.

***

Туқтамыш хан уғланларының атлары бу торур: Искәндәр, Әбүсәғәд, Җәла[л]еддин, Җәббарбирде, Көчүк, Қадыйрбирде. Сигез уғылы торур, икесенең аты мәғлүм ирмәс.

Туқтамыш бөлгән вақытында ике уғылын алыб асрады Гәрәй бай дигән [кеше]. Туқтамышның ул ике уғланы[н] алыб Қырымға хан күтәрделәр. Уғул[лар]ның аты будур: Искәндәр, Әбүсәғәд[46].

***

Йүчи ханның унйите уғылының атлары болардур: Сайын, Вирәдебақу, Бәркәчү, Бирдекә, Шибан, Йүкәҗе, Маңғут, Ибән, Боғра, Җаладдин, Соңғуй, Җибай, Нөвәл, Мөхәммәд, Удыр, Туғайтимер, Мәскүм[47].

Чыңгиз ханның дүрт уғылы болардур: Йүчи, Чәдай, Күкдәй, Тули.

***

// (79б кәгазь) Мир Тимер хан нәселләре болардур:

Тохымы барлас дигән халық торур. Хасыйле ханға җәйан уғланлары ирде, хан нәселе торур. Мәшһүр бабасы Олуқчы, аның уғылы Йаруқчы, аның уғылы Дарағай, аның уғылы Мир Тимер торур. Барч[а] мәшһүр булған қырық кеше берлә йорт алған. [А]ның берсе җаду[48] булған диб әйтүрләр.

Валлаһу әғләмү бис-саваби.

---

[46] Кулъязмада бу исем хәрәкәләр белән «Әбүсәғәд» дип язылган.

[47] Чыганакта исемнәр бер төрле язылып, дөресе ничек тиешлеге И.Мөстәкыймов мәкаләсендәге (2009) кушымта таблицада күрсәтелгән. Без монда кулъязмадагыча язылышларын гына бирдек. И.Мөстәкыймов тарафыннан «Саин-Дизди» һәм «Вурды-Баку» дип укылган исемнәрдәге «Дизди» һәм «Вурды» өлешләре, ихтимал, кулъязмада бер үк сүзнең ялгыш ике мәртәбә кабатлап язылуыннан чыккандыр. «Саин» исеменнән соң ул хәрәкәләр белән «Дирәди» («Дизди» түгел), ә аннан соң хәрәкәсез генә (ләкин беренче хәрефе «уау» белән «В.р.д.и.» рәвешендә язылган. Шунлыктан, Саин исемен аерым һәм аннан соңгы исемне Дирәдибаку (Вирәдибаку) дип укырга мөмкин.

[48] Бу өч сүз кулъязмада начар таныла.

ИКЕНЧЕ ВАРИАНТ

БЕРЕНЧЕ ТЕКСТ[1]

// (773об. кәгазь) Дәфтәри Чыңызнамә

Фасли дастани нәсли Чыңыз

Хәзрәти Нух пәйғамбәр ғәләйһиссәламнең[2] түрт уғылы, тәқи түрт қызы бар ирде. Бере – Хам, бересе – Сам, өчүнчесе – Кәнған, түртүнчесе – Йәфәс ирде. Тәқи олуғ қызы аты – Рәҗәб ирде, икенчесенең аты – Зәхәб, өчүнчесенең аты – Рөхәт, түртүнчесенең аты – Рахәт ирде. Әмма Рәҗәб үзүнең аслый қызы ирде. Зәхәб, Рөхәт, Рахәт – өчәгүсе хәзрәти Нух пәйгамбәр ғәләйһиссәламнең доғасилә көчүкдин, ишәкдин, мышықдин улуб ирделәр[3].

Әмма Хамның нәселе ғәрәб халқыдур, Самның нәселе ғәҗәм халқыдур. Кәнған туфанда һәлак булды, нәселе киселде. Йәфәснең нәселе Рум халқыдур, Йәфәсне Абулҗа хан тиб һәм әйтүрләр. Абулҗа хан угылы Бақыр хан, [аның уғылы Уҗан хан][4], аның уғылы Өвүз хан, аның уғылы Күк хан, аның уғылы Боғра хан, аның уғылы *// (773«а»об. кәгазь)* Қара хан, аның уғылы Көнү Мәргән хан, аның уғылы Уҗамбоғрыл хан, аның уғылы Сам Саучы хан, аның уғылы Салар Саучы хан, аның уғылы Сәңәборун хан, аның уғылы Қачу Мәргән хан, аның уғылы Қачуман хан, аның уғылы Қарадамал хан, аның уғылы Торматай Чәчән хан, аның уғылы Тумавыл Мәргән хан, аның уғылы Дуйын-Бәйан хан, аның уғылы *// (773«б»об. кәгазь)* Чыңыз хан, аның уғылы Йүчи хан, аның уғылы Сайын хан, аның

[1] Россия дәүләт борынгы актлар архивында (Мәскәү) 248 фонд, 17 нче тасвир, 1164 саклану берәмлегенең 773об.–773«в»об. кәгазьләреннән алынды. XVIII гасырның беренче яртысында рус колонизациясенә каршы татар-башкорт хәрәкәте җитәкчеләреннән берсе Солтанморат Көчек улының Казакъ ханы Әбелхәергә 1727 елда язган күләмле хатында «Чыңгызнамә» әсәренең керешендәге шушы өлеше язылган.

[2] Кулъязмада «ғһмнең» дип кыскартып язылган.

[3] Пәйгамбәрләр тарихына багышланган китапларда Нух галәйһиссәламнең бер генә кызы булып, башкаларының Аллаһы Тәгалә боерыгы белән яралулары, шулай ук Нух улларының нәселләре кемнәр икәнлеге турындагы мәгълүматлар тәфсилләп сөйләнгән *(Кыйсасел-әнбийаи Рабгузи. – Казан: ун-т табыгханәсе, 1881. – Б. 52–54)*.

[4] Квадрат җәяләр эчендәге сүзләр кулъязмада төшеп калган. Монда 1882 елгы басма китаптан күчереп өстәлде *(Һәза китабе фасли дастани нәсли Чынңыз хан вә һәм Аксак Тимер нәселендән бәйан идәр: тарих йиде йөз йылында. – Казан: Кукубин табыгханәсе, 1882. – Б. 2)*.



Беренче текст кульязмасы

уғылы Сартақ хан, аның уғылы Бортақ хан, аның уғылы Туқтамыш хан, аның уғылы Туғалы хан, аның уғылы Туқтағы хан, аның уғылы Алтун хан, аның уғылы Үзбәк хан, аның уғылы Җанибәк хан, аның уғылы Бирдебәк хан, аның уғылы Шайбақ хан, *// (773«в»об. кәгазь)* аның уғылы Мортаза хан, аның уғылы Күчүм хан, аның уғылы Ғәли хан, аның уғылы Арслан хан, аның уғылы Борһан-солтан хан. Әмма Борһан-солтан урус қулунда мөртәд булды. [...][5].

[5] Бу урында «Чыңгызнамә» әсәренең тексты төгәлләнеп, хатта шәҗәрә бу рәвештә дәвам итеп язылган: «Аның уғылы Ғалим хан, аның уғылы Көчүк хан, аның уғылы Солтанморад хан, аның ағасы Бәхтегәрәй батур солтан, энесе Әхмәд солтан берлә, Мансур ахун берлә Ибраһим солтанлардур...». Солтанморатның Казакъ ханына язган бу хатының дәвамы кулъязмалар тасвирламасында бирелде.

ИКЕНЧЕ ТЕКСТ1[1]

[Дастане Чыңыз]

// (1а кәгазь) [...]

...[хамилә] улыбдур. Қызына әйде:

– Әй, қызым! Сибкел битеңә төшүбдүр, нә бәла булды? – диде.

Йәнә үзе қазғу берлә эүгә килде. Әйде кем:

– Аһ, Көрләвеч! Икемез хәләл җефет булғалы мондай ойат эш килгәне йуқ ирде, қызымызға бер бәла булубдур. Нә қыйлса булур? – диде.

Анда Көрләвеч әйде:

– Имди моны бу йиргә, бу йортқа биреб булмас, аның өчен кем – адәм уғылы шайтан берлә бәрабәрдүр: күб сүзләр, күб авазлар чықар, – диде. – Имди әйлә улса, гүзәл кимә[2] берлә төн диңезенә салыб йибәрәлең! – диде.

Андин соң кимә төзүделәр, қырық қыз-қырқыны берлә, күк күгәрчене берлә, алтын қузы[3] берлә, тутый қошы, сүнмәс чырағы берлә, төкәнмәс азығы берлә Тора тағындан [Төн] диңезенә алтун кимәгә салыб йибәрделәр. Вә йәнә әйделәр:

– Бер насыйблеккә йулуқғай, – диб.

Андин соң бер қач көн кичте ирсә, ул вақытда Торымтай Чәчәннең уғылы Тумавыл Мәргән дигән атасына ачы ирде, ил ташына чықыб йатур ирде. Қашында қырық кешесе бар ирде, әмма эчендә бер қаравылчысы бар ирде, Шәбә суқур дигән ирде, төрүкмән ирде, маңла[йында] бер күзе бар ирде. Бер көн әйде:

– Әй, Тумавыл Мәргән! Алдан бер *// (1б кәгазь)* қара күренүр, – диде.

Анда Тумавыл Мәргән әйде:

– Ул нә қарадур? – диде.

Ул Шәбә суқур әйде:

– Бер алтун кимәдүр, – диде. – Бер торатау дик қыйат торадур, үтә

---

[1] Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «2224т» шифры белән саклана торган кулъязмадан алынды. Кулъязманың башындагы бер кәгазе төшкән, калган кәгазьләре үзара буталып тегелгән һәм, шунлыктан, монда күрсәтелгән кәгазь номерларының тәртибе төрлечә.

[2] Кулъязманың шушы урынында һәм моннан соңгы абзац башындагы җөмләдә «кимәйә» дип хаталы язылган.

[3] Кулъязмада «куры» дип хаталы язылган.

күрәрмән, – диде. – Мән сәндин шуны үтүнәмән – эче сәнең булсун, тышы мәнең булсун, – диде. – Ул кимә таңла төш вақытында килүр булғай, – диде.

Андин Тумавыл Мәргән әйде:

– Хуш, алай булсун! – диде.

Андин ул кимә таңласы төш вақытында килде. Күрделәр – бер алтун кимә торур, һич бозмаға йоруғын-йүнен белмәделәр. Анда Шәбә суқур төрекмән әйде:

– Әй, Мәргән, атыб бозғыл[4]! – диде.

Андин Тумавыл мәргән әйде:

– Туру атайынму, қыйа атайынму? – диде.

Шәбә суқур төрекмән әйде:

– Туру атсаң, эчендә җанлық нәрсә булса, тигәр булғай. Қыйа атыб бозғыл! – диде.

– Хуш, алай булса қыйа атайын, – тиб, уқун йаға кизләб, йасын тултуруб андағ атты кем, кимәнең өч тақтасын ырғытыб ийәбәрде.

Имди кимәне қыйа атыб бозған өчүн Қыйат[5] Тумавыл Мәргән тиб әйтүрләр. Имди қыйат халқының асылы-төбе болардур.

Йәнә ул кимәне бозғандин соң Ғөләмәлик Күрүкле чықты қырык қызкырқыны берлә, күк күгәрчене берлә, алтун қузы[6] берлә, тутый [қошы] // *(2а кәгазь)* берлә. Барчасын Тумавыл Мәргән алды. Кимә тышын Шәбә суқур төрекмән алды.

Андин соң Тумавыл Мәргән ул кичә чадыр қоруб, қызны алыб йатур булды. Ғөләмәлик Күрүкле әйде:

– Әй, Мәргән! Безне сәнгә Тәңре биргәндүр. Қачан да булса мән сәнеңмән. Мәгәр бер анча көнгә сабыр қылсаң булур ирде, қорсағымда бер бала бардур, – диде. Вәләкин бу қорсағымдағы бала адәмдән булған дәгүлдүр, нурдан-Қойашдан пәйда булғандур, – диде.

Анда Тумавыл Мәргән әйде:

– Мән ул қорсақдағы балаңа бақман, алыб йатурмән, – диде.

Анда Ғөләмәлик Күрүкле әйде:

– Әй, Мәргән! Һәрайинә күкдә йөрүгән ақ шонқар ирдек, сезнең қарағай тик буйуңызға қунайын[7]. Сез ир кешесез, күб қару итеб булмас, – диде. – Әмма күңелемне қалдурмасаң булур ирде? – диде.

Андин Тумавыл Мәргән әйде:

– Хуш, сәнең күңелеңне һич қалдурмазмән, – тиде.

---

[4] Кулъязмада «борғыл» дип ялгыш язылган.
[5] Кулъязмада бу сүздән соң ялгыш «тиб» сүзе язылган.
[6] Кулъязмада «қуры» дип хаталы язылган.
[7] Кулъязмада «қунабән» дип хаталы язылган.

Андин соң ул кичә чадыр қоруб йаттылар[8], морадларын табтылар. Андин Тумавыл Мәргән әйде:

– Әй, Ғөләмәлик Күрүкле! Бу қорсағыңдағы бала Қойашдан булғаны чын ирмеш. Адәмдән булған булса, қыз булмас ирдең, – диде. Сөйү[клеге артуқ булды.

Андин Ғөләмәлик Күрекле әйде][9]:

– Мәнгә ышанмасмусән, мән[10] *// (2б кәгазь)* ғөмерүмдә ир йөзүн күргәнем йуқ ирде. Бу көн, бу кич сәне күрдүм, – диде.

Андин Тумавыл Мәргән әйде:

Үзе буаз, үзе қыз,
Уразлы иргә төш булды,

– тиде. – Ашуқмағым ул ирде, – тиде.

Андин Ғөләмәлик Күрүкле әйде:

– Мәнем қәдеремне йахшы белгел! – тиде.

Андин Тумавыл Мәргән әйде:

– Әй, Ғөләмәлик Күрүкле! Мәнем сөйүгемнең нишаны улдур кем, мәнең

ағачым қарағай,
шонқар – қошым,
сачен тарағай,
тамғам ичамай

булсун! – тиде. Ул сәбәбдин Қыйат ичамай тамға тиб һәм әйтүрләр, сыйфаты ошбулардур:[11]

Андин йәнә бер анча көндин соң қорсақдағы бала туғды, аның атыны Тәңре биргән дуйынлықдур тиб, Дуйын-Бәйан атадылар.

Йәнә бер анча көнләрдин соң Тумавыл Мәргәннең атасы Торымтай Чәчән үлде. Тумавыл Мәргән атасы йортына[12] барыб ултурды, хан булды. Ханлықға ултурғандин соң Ғөләмәлик Күрүкледән ике уғул туғды: берсен Бүдәнәтай, икенчесен Билгүтай атадылар.

Ул ике уғул туғандин соң Ғөләмәлик Күрүкленең күңеле йаман булды. Анда Тумавыл Мәргән әйде:

---

[8] Кулъязмада «йатты» дип ялгыш язылган.

[9] Кулъязманың бу урынында текстка өзеклек кергән. Квадрат җәяләр эчендәге текст өлеше 1882 елгы басмадан күчерелеп өстәлде *(Һәза китабе фасли дастани нәсли Чыңңыз хан... – Б. 5)*.

[10] Кулъязмада бу сүз 2б кәгазь башында да ялгыш кабатлап язылган.

[11] Кулъязмада тамга рәсемнәре ясалырга тиешле ярты юл күләмендәге урын буш калган.

[12] Кулъязмада «йорқына» дип хаталы язылган.

– Әй, Ғөләмәлик Күрүкле! Халық уғыл *// (3а кәгазь)* табса, сәвенүрләр, сән нә өчүн уғыл табуб күңлүңә[13] йаман булды? – тиде.

Анда ул Ғөләмәлик Күрүкле әйде:

– Мән боруңғы уғылым Дуйын-Бәйан өчүн қайғурурмән, – тиде.

Қоланға ийәргән – чәчәккә аунар,
Дуңузға ийәргән – балчықға аунар.
Сән хан уғылы дәгелсән,
Йортқа лайық дәгелсән, – дийерләр.

Үзе хәлен белмәсләр
Күзе малға туймаслар.
Бу Бүдәнәтай, Билгүтай
Йортқа лайық ирмәсләр.

Мән арслан баласы ирүрмән,
Сезгә килеб нә күрүдүм?

димәгәймән, – диде.

Анда Тумавыл хан әйде:

– Хуш, имди нә итмәгә қуйарсән? – диде.

Ғөләмәлик Күрүкле әйде:

– Сән үлсәң, йортуңны уғланларың Бүдәнәтай, Билгүтай биләр. Мән нурдин-Қойашдин булған уғылум Дуйын-Бәйан өчүн қайғырурмән, – тиде. – Имди бу ике уғылумыз Бүдәнәтай, Билгүтайны қалмақға йибәргел!? – диде.

Андин соң Тумавыл Мәргән ике уғылы Бүдәнәтай, Билгүтайны қалмаққа ийәбәрде, тәқи икесенә йитешәр нөгәр қушты. Улар қалмақда барыб мәқам-йорт тоттылар, бер йирдә тордылар. Имди қалмақ түрәләренең асылы-төбе Бүдәнәтай, Билгүтайдиндур.

// (3б кәгазь) Йәнә ул икәү киткәндин соң бу Дуйын-Бәйанға қыз алдылар. Алтун хан нәселендән йите солтан бар ирде, аның кечесе Төлүкле дигә[н] ирде. Аның қызы Аланғуны Дуйын-Бәйанға алдылар[14].

Йәнә ул Дуйын-Бәйан берлә Аланғудин өч уғул туғды: берсенең аты Бүдәнжар, икенчесенең аты Қағынжар, өчүнчесенең аты Салжут. Қыйат[15] ыруғы Бүдәнжардин торур, тәқи қатай халқының ыруғы Қағынжардин торур, тәқи салжут халқының ыругы Салжутдин торур.

Имди Тумавыл Мәргән йегерме йыл ханлық сөрде. Андин соң Дуйын-

[13] Кулъязмада «күнәңлүңә» дип хаталы язылган.
[14] Кулъязмада «әйделәр» дип ялгыш язылган.
[15] Кулъязмада «қыйа» дип ялгыш язылган.

Бәйан унтуқуз йыл ханлық сөрде[16]. Йәнә Дуйын-Бәйан үзе үләрендән өч көн борун халқын, бикләрен йыйыб әйде:

– Аһ, әй, қалтақ халық уғылы! Белеңләр – үлүмдән һич қотулғумыз йуқ ирмеш, әҗәл йитеб килсә, дару-дәрман булмас ирмеш. Мән алған хатунум Аланғу берлә бергә үләлем дигәнләр ирдек. Имди әҗәл ирешде – мән үләмән, сезләр қаласыз. Имди сезләргә, әй, халық уғылы, васыйәт сүзүм булсун! – тиде. – Бу мәндин туған өч уғул: Бүдәнҗар, Қағынҗар, Салҗут – болар йо- // *(4а кәгазь)* -рт тотмаққа лайық йахшы ирмәсләрдүр. Имди йәнә, әй, халық уғылы! Мән үлгәндин соң хатунум Аланғуға төш-түл булуб кәлүрмән. Анда бу йортқа йахшы лайық бер уғул пәйда булур, – диде. – Әй, халық уғылы, һәрайинә аны көткәйсән! – тиде. – Имди йәнә билгүм ул булур кем – мән үлгәндин соң көн булуб инәрмән, бүре булуб чықармән, мәне андин белеңез! – тиде.

Бу сүзне хәлайыққа васыйәт қылғандин соң Дуйын-Бәйан дөнйадин үтте-китте. Әмма Дуйын-Бәйан дөнйадин үткәндин соң[17] қалмақдағы ике энесе Бүдәнәтай, Билгүтай ишетебләр кем, «Ағамыз Дуйын-Бәйан үлде, җингәмез Аланғу тол қалды» тиб, үдәргә килделәр. Утуз үзбәк нөгәрләре берлә үдәрен үдәрләделәр. Йәнә Бүдәнәтай, Билгүтай әйделәр:

– Җингәмез Аланғуның қайғура-қайғура, ағамыз көйүкендин күңеле йаман булуб торур, – тиб, тубчақ атларын менеб ау аулай чықтылар. Йайәр тағына бардылар, кийек ауладылар. Бер кийекне терекләй тотуб алыб қайттылар. Анлар қайтыб килә торғанда урмандан бер қәвем кешеләр чықтылар, барыб йулуқтылар[18].

Болар:

– Сорсаңыз, Қатай шәһәрендин босуб киләбез, – диделәр. Анлар // *(4б кәгазь)* әйделәр:

– Сезләр һәм нә кешеләр?

Болар әйделәр:

– Без[19] қалмақ халқының түрәләре Бүдәнәтай, Билгүтайбыз, – диделәр.

Улар әйделәр:

– Без өч айдин бире босыб киләбез, азығымыз төкәнде, ачмыз, – диделәр. – Безгә, рәхим итеб, бер нимә бирсәңез йә ошбу кийекне безгә бирсәңез нә булур? – диделәр.

Болар әйделәр:

---

[16] Кулъязмада бу җөмлә ялгыш тагын бер тапкыр кабатлап язылган.

[17] Кулъязмада бу сүздән соң ялгыш «ду» иҗеге язылган.

[18] Кулъязманың бу урынында бер җөмлә төшеп калган. Әсәрнең 1882 елгы басмасында текстның әлеге урынында болай диелгән: «Сордылар: «Һай, қайдин килүрсез, ни кешеләрсез?» *(Һәза китабе фасли дастани нәсли Чыңңыз хан... – Б. 7).*

[19] Кулъязмада «бу» дип ялгыш язылган.

– Һа, түрәңездән нә өчүн босдуңыз, бигрәк ач бул[д]уңыз? – диделәр.

Улар әйделәр:

–Түрәләремез ач қылды, залим булды, чыдай алмадуқ – босдуқ, – диделәр.

Болар әйделәр:

– Хуш, алай да булса, бу терек кийекне бирмәсбез, – диделәр. – Бер тол қалған җингәмез бардур, ағамыз үлгәнгә қайғурадур. Аңа уйунға алыб барабыз, күңеле ачылсун, – диделәр.

Улар әйделәр:

– Әй, йаранлар! Йуқ ирсә безнең бер уғыл баламызны алыңыз, безгә бу кийекне биреңез? Без ачбыз, ач үлмәйәлең, – диделәр.

Болар уларға қуйнуң бер ботын биреб, уғыл баласын алдылар. Бүдәнәтай, Билгүтай әйделәр:

– Җингәмезгә уйунға бу йахшыдур, – диделәр, сәвенделәр.

Ул алған уғулның аты Балын дигән ирде. Аның атасының аты Маңқытай би дигән ирде. Ачлығдан, дәрмансызлықдан би уғыл[ы] Балынны бер ботқа бирделәр. Бүдәнәтай, Билгүтай ул уғулны алыб килделәр, җингәмезнең йылқысын бақыб[20] [...]

// (13а кәгазь) ... алтунлы-гәүһәрле садақы бар ирде, бәһасен табмадылар, өләшмәй қуйдылар. «Имди анамыз кемгә ханлық бойурса – бу садақны ул алсун!» – диделәр. Өлешенә[21] тигән малларын алғандин соң, садақны алыб анасы қатыға килделәр:

– Әй, анамыз! Сез кемгә йарлықаб ханлық бирсәңез, бу алтунлы садақны ул уғылуң алсун! – тиделәр.

Анда Аланғу әйде:

– Аһ, әй, балаларым!

Үз йортын йаманлаған – үзгә йортта [сүгеш][22] булур,
Үз анасын йаманлаған – дошманға тотқун булур,
Үз кешесен йаманлаған – йат дошманға хур булур.

– Сез шомлар мәнең сүзүм тотармусыз? – тиде.

Ул өчәү әйделәр:

– Бәли, хуш тотарбыз, – тиделәр.

– Имди сезләр тотар булсаңыз, тәрәзәдән төшкән көнгә футаллы футаңызны[23] салыңыз. Кемнең футасы аңар эленеб туқтаса – ул уғылум хан

---

[20] Бу сүз кустодта язылган. Аннан соң текстка өзеклек кергән, кулъязманың ике кәгазе төшкән.

[21] Кулъязмада «өлештә» дип ялгыш язылган.

[22] Бу сүз кулъязмада язылмыйча, буш урын калган.

[23] Кулъязмада «футаныңызны» дип хаталы язылган.

булсун! Тәқи бу алтунлы-гәүһәрле садақны һәм ул алсун! – тиде ирсә, Аланғуның бу сүзене анлар хуш күрделәр. Билләрендән алтунлы футаларын салыб бақтылар. Өчәвесенең һәм футасы эленмәде. Мәгәр Чыңызның йебәк футасы бар ирде, ул салды, аның футасы эленеб туқтады. Анлар бу эшне күреб таңға қалдылар. *// (13б кәгазь)* Ачуланыб әйделәр:

– Бу анамыз Аланғу ғайәт җаду ирмеш, күземезне бағлады, – тиделәр. Күңелләренә[24] йаман алыб китделәр. Әмма һәрдаим Чыңызны үлтермәк қасдында[25] йөрүр ирделәр.

Андин соң бу йәш уғыл Чыңыз «бу ағаларым мәнгә дошман булдылар, мәне анлар үлтүрүрләр» тиб, башындин қурқуб, қазақ чықыб китәйен тиб киңәш итеб, бер ике-өч йегет үзенә ийәртеб, анасы Аланғуға килде. Әйде:

– Әй, анам! Мән имди бу йирдән-йортдан китәрмән. Ошбу Тикәлек суының[26] башында Көргүрләрән дигән қара тау бардыр. Ул тағда мәқам-йорт тотармән, қош-қорт аулармән. Ул аулаб алған қош җонын җолқармән, аны суға йибәрүрмән. Безнең тереклегемезне ул қош җонындин белгәйсез. Айу ақыртырмән, арслан йөгертүрмән – һәркем мәне эзләй-сорай барур булса, мондин белсүнләр, – тиде. Үзләре китделәр, анасы илай қалды.

Иртәгесен халық уғылы күренешкә килделәр ирсә, Чыңызны күрмәделәр, тәқи сордылар:

– Чыңыз ханымыз қайдадур? – тиб. Истәб табмадылар, чулашыб, чымырғанышыб илашдылар. Андин соң килеб Аланғудин сордылар, ул әйтмәделәр.

Чыңыз хан қазақ чықыб киткәндин соң, *// (14а кәгазь)* ағалары Бүдәнҗар, Қағынҗар, Салҗут халық уғылына золым-көч итделәр. Халық уғылы чыдамайын, Аланғуға килеб әйделәр:

– Аһ, Аланғу! Ул угылуң Чыңызны безгә күргүзенчә, күргүзмәй җанымызны алсаң ирде. Имди нә өчүн күргүзүб җанымызны алдың? – тиделәр. Йәнә чулашыб илашдылар.

Анда Аланғу әйде:

– Аһ, әй, халық! Андағ булсаңыз, уғылымыз Чыңызны сорсаңыз, иртә берлә биш[27]-алты руның йахшы-лайық кешеләре килеңезләр, мән анларға йулын-эзен күрсәтәйен, – тиде.

Андин соң, иртә берлә алты руның лайық кешеләре килделәр, сордылар:

– Йулы қайдадур? – тиделәр.

---

[24] Кулъязмада «күңәлләренә» дип хаталы язылган.
[25] Кулъязмада «қастында» дип хаталы язылган.
[26] Кулъязмада «шунун» дип ялгыш язылган.
[27] Кулъязмада «пиш» дип хаталы язылган.

Анда Аланғу әйде:

– Хуш, имди барыб, шул Тикәлек суыға бақыб торуңыз, хәбәре килүр! – тид[е].

Болар су йақасына барыб, бақыб тордылар – һич нәрсә күрмәделәр[28]. Мәгәр бер қәүм қош җоны күрделәр. Қайтыб килделәр. Анда Аланғу сорды:

– Нә күрдүңез? – тиде.

Анлар әйделәр:

– Йуқ, нәрсә күрмәдүк. Мәгәр бер қәүм қош [җоны] күрдүк, – тиделәр.

Анда Аланғу әйде:

– Һа, кил имди, мәнең уғылум Чыңызның хәбәре ушал сез күргән қош җоныдур! – тиде. – Имди сезләр ошбу Тикәлек суыны қызырыб эзләңез, Тикәлек суының башында *// (14б кәгазь)* Көргүрлән дигән қара тауның башында биш-алты ағач булур. Ушал йирдә «мәқам тотармән, қош аулармән, җонын йолқыб Тикәлек суына салыб йибәрермән», тигән ирде[29]. Ул эзне эзләб барыңыз! – тиде. – Әмма Тикәлек суының иске-қарый йоласы улдур кем, көндез ташыб, қабағындан ашар, кичәсе хисабына төшәр, – тиде. Анда йәнә Аланғу анларға әйде:

– Имди сезләр ул йиргә барыб йитеб һәр нә йулуқсаңыз, күрсәңез, «Сезләр монда нә кешеләрсез?» тиб сорағанда «Дуйын, Дуйын» дигәйсез! Әмма мәнең уғылум Чыңызның төсе-нишаны улдур кем:

Ақ тунлы, күк атлы, алтун бүрүкле,
Йөзе ғәйәт күрүкле;
Алтын садақлы, ир җөрәкле,
Җәбраил дик сынлы, нәселле торур,
Атын қамчыласа, ғәиб булған тикдүр

– андин аны белгәйсез, – тиде.

Әмма Чыңыз ханны истәй барған бикләрнең атлары болардур: Уйшын Майқы би, икенчесе Қалдар би, өчүнчесе Урдаж[30] би, түртүнчесе Қыпчақ би, бишенчесе Тамйан би, алтынчысы Кирәйәт би, йитенчесе Борқыт би, сикезенчесе Тимүр Қотлу би, туқузунчысы Муйтан би, унунчысы Таңғут ирде. Бу ун бик киңәш қыйлыб, Чыңыз ханны сәвеб, аны истәмәк қасдында[31] булдылар. Әмма түрт бик буны эстә- *// (15а кәгазь)* -мәгә өнәмәделәр, «Қулдағы ханымызны хурлаб, алысдан истәмәзбез», – тиделәр. Анларның берсе Қоңрат би, икенчесе Қатай би, өчүнчесе Салжут би, түртүнчесе Қыйат ирде. Әмма бу Қатай, Салжут, Қыйат – өчәгүсе халық

[28] Кулъязмада «күрмәмәделәр» дип ялгыш язылган.
[29] Кулъязмада «тигәндүр» дип ялгыш язылган.
[30] Кулъязмада: Урадыж.
[31] Кулъязмада «қастында» дип хаталы язылган.

уғылын биләр ирделәр. Қоңрат би анларның ышанычлы киңәшчесе ирде. Қоңрат би Чыңыз ханны истәмәклеккә бармады.

Әйтелгән ун кеше ул Қоңратға бақмадылар, китделәр. Әмма Уйшын Майқы би үзгә бикләргә белдүрмәй, Аланғудин бер мөһерле йөзүген алды. Андин Тикәлек суын қызырыб китделәр, өч айда барыб йитделәр. Бер йүчә қыйа тағға менеб қарадылар, артларында бер ақ сарай, бер күк сарай күрделәр. Йәнә қайтыб, бер азина китделәр, ул сарайларға инмәделәр. Анда бер тау бар ирде, ул тауның қабағында йатдылар. Бер азина тордылар, һич нәрсә-нишан белмәделәр. Мәгәр бер азинадин соң бер аваз килде қарға чарлаған дик, кеше сүзләгән тик. Қараб-йөреб бақтылар, бераз кеше килебдүр, йулының [йуйы чықа йатур][32]. Шул тағның қабағындан бире килмәгән охшайдур тиделәр. Әмма болар һич аваз бирмәделәр. Йәнә авазлары тынды[33], ул көн һич нәрсә белмәделәр.

Иртәгесен айу ақырды, арслан қычқырды, белделәр кем – «Чыңыз хан *// (15б кәгазь)* ау аулай чықды», – тиделәр. Болар ул авазны ишеткәч йөгерүб бардылар кем: бер күк атлы, ақ тунлы, алтун бүрүкле, алтун садақлы, ир чырайлы, Җәбраил дик күрүкле, нәселле, йусынлы Чыңызны таныдылар вә белделәр – ул килгән Чыңыздур!

Чыңыз анларға әйде кем:

– Сезләр безләрне изыб йөрүрсез, нә кешеләр сез? – тиде.

Болар әйделәр:

– Дуйын, Дуйын! – тиб.

Болардин ул сүзне ишеткәндин соң күзләрендин ғәиб булды. Болар йәнә йығлашыб қайтдылар. Ул кич қайғуруб йатдылар. Андин йәнә иртә булды ирсә, оранлары берлә чарладылар: «Ақ-ту-ған, ту-ты-йақ, тый-лақ!» – тәйү чақурдылар, һич нәрсә аваз килмәде.

Андин йәнә ике-өч көн йаттылар. Йәнә бер көн айу ақырды, арслан қычқурды – белделәр кем, «Чыңыздур, ау аулай чықты!» – тиб, сәвенешделәр. Йәнә барыб күрделәр, ушал кешенең үзедүр.

Андин боларға Чыңыз хан әйде:

– Һа, сезләр кемләрсез? Һәрдаим безне андыб[34] йөрүрсез? – тиде.

Болар әйделәр:

– Дуйын, Дуйын! – тиб, йәнә чулашыб, илашыб тордылар.

Болар болай йығлағанға Чыңыз хан үзе һәм йығлады. Йәнә әйде:

– Һа, сез нә өчүн монда килдеңез? – тиб сорды.

Болар әйделәр:

---

[32] Кулъязмада бу өч сүз юк. Монда «Өченче текст»тан алынды.
[33] Кулъязмада «килде» дип ялгыш язылган.
[34] Кулъязмада «андин» дип ялгыш язылган.

– Сәнең артыңдан үләйек тиб йөрүрбез, – диделәр.

Анда ул Чыңыз *// (16а кәгазь)* хан әйде:

– Һа, сезне монда килүргә кем үгрәтте? – тиде.

Болар әйделәр:

– Безләргә, рәхим қыйлыб, сойурғаб анаңыз Аланғу үгрәтде, – диделәр.

Анда Чыңыз хан әйде:

– Хуш, имди андағ булса, қани мәнгә анамның бер билгүсе барму? – тиде ирсә, үзгә бикләр тик тордылар, әмма Уйшын Майқы би қулунда Аланғудан алған мөһерле йөзүкне чықарыб бирде.

Анда Чыңыз хан йөзүкне алыб бақты ирсә, Аланғуның мөһерле йөзеген таныды, тәқи көлүб әйде:

– Әй, Майқы би! Әгәр мән хан булсам, биклек сәнең булсун! – тиде. – Әгәр сән бу мөһерле йөзүкне алыб килмәсәң, мәнгә анамның бер нишанын килтүрмәсәң, мән сезгә йуқ ирдем, тәқи сез мәнгә иш-йулдаш булмас ирдеңез! – тиде. – Әмма бу сүздин үзгә бикләрем сезләр һәм күңлүңезгә йаман алмаңыз, сезләр барчаңыз мәнем җанымсыз! – диде. – Килеңез, имди қуышқа қайталық, анда барыб ултуралық, – тиде.

Сарайға бардылар, бер азина анда йатыб, аш йиделәр, төрлү шәрабләр эчтеләр[35], сүнмәс чыраг, төкәнмәс аш йиделәр.

Андин соң йәнә Чыңыз хан әйде:

– Килеңез, имди киңәш итеб ултуралың! Сезләр кем, безне истәб килебсезләр, ничә ру халық берлә берсез? – тиде.

Болар айақға үрә торуб үтүнделәр, *// (16б кәгазь)* тәқи әйделәр:

– Әй, олуғымыз, ханымыз! Безләрдин кем сорсаңыз, безләр монда сезне истәй килгән ун кешемез, туқуз рудан, – тиделәр. – Әмма Қалдар би йалғуз үзедүр. Анаңыз Аланғу безгә қушуб иде, – тиделәр. – Әмма Коңрат би сезне истәй килмәлеккә өнәмәде, ул үзе, тәқи руы ағаларның қашындадур, – тиделәр. – Без сезнең мөбарәк йөзүңезне арзулаб артуңыздан үлә-йитә килдүк, сезгә қушулдуқ һәм үземез, һәм барча ру халқымыз сезләрнең[36] қолуңмыз! – тиделәр.

Анда Чыңыз хан анлардин бу сүзне ишетте ирсә, сәвенүб әйде:

– Әй, бикләрем, олуғларым! Имди бу көндин соң сез – мәнең, мән – сезнең! – тиде.

Анда болар Чыңыз хандин бу сүзне ишетеб ғәйәт сәвенделәр:

– Имди сине безләргә Тәңре бирде, аның шөкерлеге өчүн бу менеб

[35] Кулъязмада «иченләр» дип хаталы язылган.
[36] Кулъязмада «безләрнең» дип ялгыш язылган.

килгән атларымызны азад йибәрәле, – тиделәр. Менеб барған атларын Чыңыз ханны булғанлары өчүн азад идделәр.

Андин соң Чыңыз хан боларга әйде:

– Һа, мәне нә берлә илтәрсәз? – тиде.

Анлар [нә] берлә алыб барасын белмәделәр. Әмма Қалдар би әйде:

– Мән бер һөнәр чықарайын, – тиде.

Болар әйделәр:

– Күрсәт! – тиделәр.

Һичкем ирсә белмәс ирде, үз остадлығындан *// (17а кәгазь)* бер арба йасады, әйде:

– Арба пирен[37] сорсалар, Балын би уғылы Қалдар би тимәк кирәк.

Анда йәнә арба төзеб тәмам қылғандин соң, Чыңыз ханны арбаға ултурурға үтүнделәр. Чыңыз хан килеб арбаны қарадылар, тәқи «Хуш қыйлыбсән!» тиб, Қалдар би[не] мақтады.

Андин соң Чыңыз ханны арбаға ултуртдылар. Бу барған бикләр үзләре арбаны сүрәделәр-тарттылар. Анда Уйшын Майқы би әйде:

– Әй, бикләр! Мән сезнең шайыңыз бара алмандур, айақым қысқадур, – тиде.

Анда бу бикләр әйделәр:

– Имди нитәк қылурсән?

Анда Майқы би әйде:

– Мән хандин үтүнәйен, рөхсәт булса, хан берлә арбаға ултурайын, қайсыңыз арба тартмаса, мән аны тайақ берлә күтегә төртәйен, – тиде.

Болар әйде:

– Хуш, алай ит! – тиделәр.

Андин соң Майқы би Чыңыз хандин үтүнде, тәқи әйде:

– Әй, ханым! Айақым қысқадур, арбаны тарта алмандур. Сойургасаң[38], мән сәнең берлә арбаға ултурур ирдем? – тиде.

Анда хан әйде:

– Хуш, ултур! – диде.

Андин соң бу бикләр бер анча көнләрдин соң килә-килә[39] Чыңыз ханны алыб, Аланғуның шәһәренә йиттеләр. Аланғуға хәбәр қыйлыб, сарайға инделәр. Әмма анда Чыңыз ханның[40] артындан қайсысы инәрен белмәделәр. Анда Майқы би *// (17б кәгазь)* әйде:

---

[37] Кулъязмада «йирен» дип ялгыш язылган.

[38] Кулъязмада «хойурғасаң» дип хаталы язылган.

[39] Кулъязмада «килгәли» дип ялгыш язылган.

[40] Кулъязмада «ханының» дип ялгыш язылган.

– Әй, ханым! Сездән соң арба тартҡан үгүз инәрме йә аны йиккән ийәсе инәрмү? – тиде ирсә, анда хан әйде:

– Ийәсе инмәй, үгүз инәрмү? – тиде ирсә, Майқы би рәван йөгүрүб керде, ханның уң йанында урун алды. Үзгәләре йәнә ултурды.

Иртәгесен Чыңыз хан дүрт ру иленең кешесенә олуғ қырғын[41] итделәр. Ушал олуғ қырғында Бүдәнжар, Қағынжар, Салжутны, [тәқи Қоңрат бине тәмам қырдылар, үлтүрделәр, әман бирмәделәр.

Әмма ул вакытда][42] Қоңрат батырның бер қыз қәрендәше бар ирде, Бөртә Қучын атлығ ирде. Ул Бөртә Қучын ул олуғ қырғында һәлак булмасун тиб, түрт уғулны алыб қалды, йәшереб асрар ирде. Берсе Бүдәнжар уғылы ирде, икенчесе Қағынжар уғылы, өчүнчесе Салжут угылы ирде, түртүнчесе ағасы Қоңрат бинең уғылы ирде. Һичбер халыққа белдүрмәде. Анда халық уғылы айыңлашыб, тиргәшеб чықардылар. Тәқи Чыңыз ханға барыб әйттеләр ирсә, Чыңыз хан ачуланыб әйде[43]:

– Кеше кешеләр йәшерүбдүрләр, кемдүр? – тиде.

Анда торған бикләр әйделәр:

– Әй, ханым! Қоңрат бинең қыз қәрендәше Бөртә Қучын йәшерүбдүр, – тиделәр.

Анда хан әйде:

– Барыңлар, аны монда тиз китүрүңләр! – тиде ирсә, рәван уқ бардылар, Бөртә Қучынға әйделәр:

– Тиз бул! Сәне Чыңыз хан *// (18а кәгазь)* өндәйүр, – тиделәр.

Анда Бөртә Қучын ул сүзне ишетте ирсә, «Хуш, барайын» тиб тора салыб, сырт[44] кеш тунын йилбәгәй[45] йабынды, тәқи бер ал һәбәрәң[46] башмақы бар ирде – аны киде[47], тәқи бер қара төлке бүрке[48] бар ирде – башыға аны киде. Тәқи ул йәшерүб алыб қалған түрт уғулны үзе берлә бергә алды. Ул уғланларның қайсысы ун йәшәр, берсе унбер йәшәр, тәқи берсе унөч йәшәр, тәқи берсе унтүрт йәшәр ирделәр. Бу уғланлар ғәйәт күрүклүк уғланлар ирделәр. Бөртә Қучын үзе һәм алардин биш артуқ ирде. Андағ сылу кешене ул заманда һич кеше күрмеше йуқ ирде. Тәңре қөдрәте

---

[41] Кулъязмада «қуғын» дип хаталы язылган.
[42] Квадрат җәяләр эчендәге текст өзеге кулъязмада төшеп калган. Монда «Дүртенче текст»тан алынды.
[43] Кулъязмада «әйдисә» дип ялгыш язылган.
[44] Кулъязмада «хәйрәт» дип ялгыш язылган.
[45] Кулъязмада «йилегәй» дип хаталы язылган.
[46] Кулъязмада «бәрәң» дип хаталы язылган.
[47] Кулъязмада «кидек» дип ялгыш язылган.
[48] Кулъязмада «бүрек» дип ялгыш язылган.

берлә пәйда булмыш ирде: қырық қолач саче бар, артындан ике дайәсе алтун табаққа сачен салыб йөрүтүр ирде.

Анда халық уғылы әйделәр:

– Әй, Бөртә Қучын! Сән бу сыйфатлы күрүклү кеше, нә өчүн мондай эш қыйлдың, бу уғланларны йәшүрдүң, уғры булдуң? – тиделәр.

Анда Бөртә Қучын әйде:

– Әй, халық! Мән сезгә нә эш қыйлдым? Уғры булсам, ханға уғры булдум, – тиб җаваб бирүр ирде.

Андин соң Бөртә Қучынны уғланлар берлә Чыңыз ханға алыб килделәр. Хан тәқи моның күркен, озын сачен күрүб таңға қалды. Тәқи әйде:

– Әй, Бөртә Қучын? Нә мәнгә уғры булдуң, *// (18б кәгазь)* бу уғланларны йәшүрдең? – тиде.

Анда Бөртә Қучын үтүнүб әйде:

– Әй, ханым! Мән сәне айаған өчүн айаб уғры булдум, йәшердүм, – тиде.

Анда Чыңыз хан әйде:

– Ничүк сән мәне айадың? – тиде ирсә, Бөртә Қучын әйде:

– Әй, ханым! Сәнең җаныңға көч булур, – тидем.

Анда хан әйде:

– Мәнем җанымға ничүн көч булур? – тиде.

Бөртә Қучын әйде:

– Әй, ханым! Аның өчүн кем, Нух пәйғамбәр ғәләйһиссәлам заманында Ходай Тәбарәкә вә Тәғалә кяферләргә қәһер қыйлыб, туфан суын йибәрде, кяферләрне туфан суыға батурды, йуқ қыйлды. Тәқи ул туфанда һәр җанлықның, иркәк-тешинең нәселе-тохымы киселмәсүн тиб, Нух пәйғамбәр ғәләйһиссәламнең кимәсендә қотқарды, азад қыйлды. Сән хан булсаң да, Тәңре Тәғаләнең қолы дәгү[л]мүсән? Арслан кийек иркәч аша сикереб, артындағын қайтыб алмас, азад қыйлур, йибәрүр. Әй, ханым, сән адәмсән! Мәне, тәқи бу уғланларны азад қыйлсаң булмасму? Ул ачиғылыйғ йаман қырғында халық уғылы боларның қәдерен белмәсләр, үлтүрүрләр, боларның тохымы-нәселе, руы[49] киселмәсен тиб алыб қалдым, – тиде.

Анда Чыңыз хан әйде:

– Әй-һәй, сәнең шул йахшы дәли[ле]ң, сүзең өчүн, тәқи сәннең диңез тик күңлүң өчүн йөз мең үлүмле азад булсун! – тиде.

Кил имде, әй, Бөртә Қучын!
Мәнең қаты[50] [...]

---

[49] Кулъязмада «руқ» дип хаталы язылган.
[50] Бу сүз кустодта язылган. Аннан соң текстка өзеклек кергән, бер кәгазе төшкән.

// (5а кәгазь) ...[туқ]саба, тамғаң «тарақ» булсун! – тиде. Сыйфаты ошбудур:

Андин соң йәнә хан әйде:

– Әй, Җурмат би! Сәнең ағачың өйәнке булсун, қошуң итәлғу булсун, ораның «ақтайлақ» булсун, тамғаң «сынлы сәнәк» булсун! – тиде. Сыйфаты ошбудур:

Андин йәнә хан әйде:

– Әй, Кирәйәт би! Сәнең ағачың җүкә[51] булсун, қошуң қаз булсун, ораның «арбөрү» булсун, тамғаң «күз тамға» булсун! – тиде. Сыйфаты ошбудур:

Андин йәнә хан әйде:

– Әй, Муйтан би! Сәнең ағачың миләш булсун, қошуң торна булсун, ораның «байғъңгәр» булсун, тамғаң «төйушқан» булсун! – тиде. Сыйфаты ошбудур:

Андин йәнә Чыңыз хан әйде:

– Әй, Бөрҗан би! Сәнең ағачың имән булсун, қошуң көҗүгән булсун, ораның «ақтуған» булсун, тамғаң «җағалбай» булсун! – тиде. Сыйфаты ошбудур:

Андин йәнә Чыңыз хан әйде:

– Әй, Борқыт би! Сәнең ағачың чаған[52] булсун, қошуң һөдһөд булсун, ораның «борух» булсун, тамғаң «әмзә» булсун! – тиде. Сыйфаты ошбудур:

Андин соң йәнә хан әйде Қағынҗа[р уғылы] Қатайға:

– Сәнең ағачың артыш *// (5б кәгазь)* булсун, қошуң кавыд булсун, ораның «тыйлақ» булсун, тамғаң «сәрви» булсун! Сыйфаты ошбудур:

Андин йәнә хан әйде:

– Әй, Қалдар би! Сәнең ағачың сандал булсун, қошуң күгәрчен булсун, ораның «азнау» булсун, тамғаң «чүмеч» булсун! – тиде. Сыйфаты ошбудур:

Андин йәнә хан әйде:

– Әй, Салҗут би! Сәнең ағачың көйрүч булсун, қошуң көйелдү булсун, ораның «барлас» булсун, тамғаң «өй тамға» булсун! – тиде. Сыйфаты ошбудур:

Андин йәнә хан әйде:

– Әй, Тимер Қотлы би! Син қара кешедән байлығың берлә, күб мал бирмәклек берлә билек табтуң. Сәнең ағачың җирек булсун, қошын

[51] Кулъязмада «чүкә» дип хаталы язылган.
[52] Кулъязмада «хаған» дип хаталы язылган.

сайысқан булсун, ораның «табан» булсун, тамғаң «йарым тарақ» булсун! – тиде. Сыйфаты ошбудур:

Андин Чыңыз ханның үзенең ораны «җан қаба» ирде.

Чыңыз хан ошбу бикләренең һәрберсен ләшкәр[53] башы қыйлыб, урдалар алғалый йибәрүр ирде. Ул олуғ-ағыр чирүләрдә халық уғылы бер-берсен оранлы ораны берлә табар ирделәр. Имди барча оранларының атлары болардур: әүвәл хан ораны – «җан қаба». Андин соң барча биләрнең оранлары болардур: «аруҗан», «коңрат», «салават», «алач», «тутыйа», *// (6а кәгазь)* «туқсаба», «ақтыйлақ», «арбөрү», «байғљнгәр», «ақтуқған»[54], «борух», «тыйлақ», «арнау», «барлақ», [«табан»].

Йәнә мәғлүм ула кем, Чыңыз хан һәрдаим кийек аулай чықар булса, ошбу әйтелгән биләр қошлары берлә, қошларын алыб чықар ирделәр. Имди ул қошларының атларын барчасын җәмеғ қыйлыб әйтәйен. Ул Чыңыз ханның үз қошы ике баш қарақаш ирде. Үзгә бикләренең қошлары болардур: шонқар, лачын, қарақош, қарчыға, қырғы, бөркүт, итәлғу, қаз, торна, көчүгән, һөдһөд, қавыд, күгәрчен, көйүлдү, сайысқан.

Йәнә мәғлүм ула кем, Чыңыз ханның үзенең ағачы чинар ирде, үзгә бикләрнең ағачларының барчасын җәмеғ қыйлыб әйтәйен: қарағай, алмағач, қайын, тирәк, қарама, өйәнке, җүкә, миләш, имән, чаған, артыш, сандал, көйрүч, җирек.

Йәнә мәғлүм ула кем, ханның тамғасы «қошбаш» дигән ирде, сыйфаты ошбудур:

Үзгә бикләрнең һәм барча тамғаларын җәмеғ қыйлыб әйтәйен: *[уңнан сулга таба тәртиптә]* 

Йәнә мәғлүм ула кем, Чыңыз бикләрнең һәрберсенә орышқа лайық һәйбәтлек булмақ өчүн берәр савыт атаб бирде. Әүвәл Чыңыз ханның савыты *// (6б кәгазь)* «буйан» дигән ирде. [Олу уғылы Йүчинең «қаратау» дигән савыт ирде][55], икенче уғылы Җәдайның «алтун сандуқ» дигән савыт ирде, өчүнче уғылы Кирәйнең «бөктәр» дигән савыт ирде, түртүнче уғылы Тулиның «ут йөрәк» дигән савыт ирде. Андин соң Чыңыз бикләренә һәм савыт бирде: Қыйатқа «қала»[56] дигән савытны бирде, Қоңратқа «айқултық» дигән савытны бирде, Майқыға «сәғрә» дигән савытны бирде. Урдачқа[57] «чәчәкүз» дигән савытны бирде, Тамйанға «көйләксә» дигән савытны бирде, Кыбчаққа «күк йақа» дигән савытны бирде, Журматыға «ун қарыш»

[53] Кулъязмада «шөкер» дип ялгыш язылган.

[54] Кулъязмада «ақрықған» дип ялгыш язылган.

[55] Текстның квадрат җәяләр эчендәге өлеше кулъязмада төшеп калган. Монда «Өченче текст»тан алынды.

[56] Кулъязмада: қал.

[57] Кулъязмада: Урадачқа.



Икенче текст кульязмасы

дигән савытны бирде, Кирәйәткә «өйлә» дигән савытны бирде, Мутйәнгә «қаты қабақ» дигән савытны бирде, Бөрҗанға «қусқач» дигән савытны бирде, Борқытқа «көрләч» дигән савытны бирде, Қатайға «боз қалпақ» дигән савытны бирде, Қалдарға «чоқа турғай» дигән савытны бирде, Салҗутқа «борчақ» дигән савытны бирде, Тимер Қотлыға «бозаубаш» дигән савытны бирде. Имди ошбу савытларның барчасының атларын җәмиғ қыйлыб әйтәйен: «буйан», «алтун сандуқ», «бөктәр», «ут йөрәк», «қала»,

«арқултық», «сәғрә»[58], «чәчәкүз», «көйләксә», «күк йақа», «ун қарыш», «өйлә», «қаты қабақ», «қусқач», *// (7а кәгазь)* «көрләч», «боз калпақ», «чоқа турғай», «қойырчақ», «бозау баш», «керәүкә».

Андин соң Чыңыз хан бу бикләрне тәмамын күз өстендә қашы тик күрәр ирде, ғыйш-ғөшрәт қыйлур ирде. Дөнйасына қуаныб, бадишаһлығына[59] мәғрүр-мәшғүл ирде. Һәрдаим тамаша тәнәғғем қылур ирде.

Андин соң йәнә Чыңыз хан көнләрдә бер көн олуғлары, бикләре берлә ау аулай чықыб, йаланда йөрүр иределәр, йулбарыс дигән кийекне күрделәр, бикләр һәрберсе уқын йаға кизләб[60] йараштурыб қу[й]дылар, қыйаларны ашырдылар. Һичберсе йитә алмадылар. Ахры бар, өч кеше қуыб йиттеләр, йулбарысны атыб йықдылар. Берсе Коңрат батырның уғылы Сәңлә, икенчесе Мең садақлы Урдаж[61], өченчесе Тамйан би – бу өч кеше йулбарыс-ны үлтүрүб, Чыңыз ханға килтүрделәр. Хан боларның бу ирлекләрен күрүб таңға қалыб, һәрберсенә меңәр тәнкә алапа бирде. Һәр йирдә мәҗлесдә боларның ирлекләр[ен] сөйләр ирде.

Йәнә көнләрдә бер көн Чыңыз хан ауға бикләре берлә чықыб йөрийүр ирде. Йаланда бер болан-кийекне күрделәр, қудылар. Бөрҗан бинең бер йөгүрүк аты бар ирде. Йөгерүклекдә андағ ирде кем, боланны йитеб мөйезендән тотар ирде. Бөрҗан би йитеб, *// (7б кәгазь)* кийекне атыб, ханға алдыға килтүрде. Хан аңар һәм илле тәнкә алапа бирде. Һәр көн ошбундағ зәвық қылу[р] иределәр.

Йәнә көнләрдә бер көн хан әйде:

– Әй, бикләрем! Барыңлар, қош аулаб килтүрүңләр! – тиб бойурды. Бикләр һәрберсе қошларын алыб чықтылар. Қошлар[62] аулаб килтүрделәр. Қыйат шоңқар қошы берлә аққош тәбтүрде. Сәңлә лачын берлә торна тәбтүрде, Урдаж[63] қарчыға берлә қаз тәбтүрде, Тамйан қырғы берлә бүдәнә тәбтүрде. Һәрберсе – қошлы қошы берлә тәбтүргән қошларын алыб килделәр, Чыңыз ханның алдыға салдылар. Хан бу қошларны күрүб, һәрқайусына меңәр тәңкә[64] алапа бирде. Әмма Қыйатқа, Сәңләгә, Урдачқа[65], Тамйанға – анларга икешәр мең тәнкә алапа бирде.

Андин[66] соң Чыңыз хан олу уғылы Йүчигә «асыл мал анда бөтәр»

---

[58] Кулъязмада: сәнрә.
[59] Кулъязмада: бар шанлығына.
[60] Кулъязмада «кизләр» дип ялгыш язылган.
[61] Кулъязмада: Урадаж.
[62] Кулъязмада «қошларын» дип ялгыш язылган.
[63] Кулъязмада: Урадыж.
[64] Кулъязмада «тәңлә» дип хаталы язылган.
[65] Кулъязмада: Урадычқа.
[66] Кулъязмада бу сүз урынына ялгыш «тулған ирде» сүзтезмәсе язылган.

тиб, «алтун-көмүш күбдүр» тиб, «йорты киңдүр» тиб, Тәрмиз урдасында ханлыкъга [ку]йды. Тәқи икенче уғылы Җәдайны «ил олысы анда булур» тиб, «төмән төрле халық анда булур» тиб, «олуғ йортдур» тиб, Һиндустан урдасында ханлықға қуйды. Өчүнче уғылы Кирәйгә «ир кийәр савыты ир қушанур, қылычы күбдүр» тиб, «асылзадә халықдур» *// (8а кәгазь)* тиб, Күрәл урдасында ханлықға қуйды. Түртүнче уғылы Түләйне «халықлары рәхимледүр» тиб, «ир йортыдур» тиб, «ир кийәр чуғасы, атласы, турқасы күбдүр» тиб, «эше қаты, ашы татлы, таймас[67] олуғ йортдур» [тиб], Мүскәү урдасында ханлыққа қуйды. Һәрберсе[нә] ошбу әйтелгән урдаларны халқы берлә анларға өләшеб бирде. Ул шәһәрләрдәге ханларның асылы-төбе болардур, асылы Чыңыз хандиндур.

Андин соң йәнә беләсез кем, Чыңыз хан пәйғамбәремез Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу ғәләйһи вәс-сәлләмнең тарихындан соң биш йөз қырық түртүнчедә[68] ирде, дуңыз йылында, зөлқәғдә айында анадин туғды. Андин соң Чыңыз хан йитмеш ике йыл ғөмер кичүрде, ун[өч] йәшендә ханлыққа ултурды, хан булды, илле туқуз йыл ханлық сөрде. Чыңыз ханның туған шәһәре, тотған, торған йорты Қытай ирде. Йәнә йитмеш ике йылдан соңра, туңыз йылында, мөбарәк рамазан айының унтүртүнче көн, тарих алты йөз дә йегерме түртдә дөнйадин вафат булды, сүзе дөнйада қалды.

Фасыл фи дастани Ақсақ Тимер

Имди йәнә хәзрәти Ақсақ Тимер нәселендән сөйләйәлең[69]. Һиндустан шәһәрендә Чыңыз хан *// (8б кәгазь)* уғылы Җәдай хан ирде, ханлық қыйлур ирде. Көнләрдә бер көн йатыб ойыды, йаман төш күрде, куркубсискәнеб уйанды, торды, қалтураб торд[ы]. Фалкярләрне, фал бағучыларны җыйдурды, талиғын қаратды, оқтартды. Фалкярләр, фал бағучылар әйделәр:

– Әй, ханым! Талиғыңда андағ күренүр кем, үз милкеңдә Алмалық дигән авылда бер кешедән хәтәреңез бар торур. Ул кеше Қарақчы уғылы Қазычы, Қазычы уғылы Олуқчы, Олуқчы уғылы Тавуқчы, Тавуқчы уғылы Тарақчы, Тарақчы уғылы Тарағай дигән кешедүр, – тиделәр. – Әмма ул Тарағайның нишаны-билгүсе улдур кем, чавырынында миңе бар, сул күзүндә ақы бар торур. Ул Тарағайның хатуны йөкле торур. Аның қорсағындағы баласындан әҗәлең-үлүмең йитеб торур, – тиделәр.

Анда Җәдай хан фал бағучылардин бу сүзне ишетеб, ул Алмалық авылындағы Тарағайны эстәтеб табтурды. Җәдай хан қашыға алыб

[67] Кулъязмада: туймас.

[68] Башка текстларда «тукузынчыда» (ягъни, 549 елда).

[69] Кулъязмада «сөйләрлең» дип хаталы язылган.

килделәр, қарадылар – ул әйтелгән нишанлары бар ирде, җавырынында миңе, сул күзүндә ақы һәм бар. Җәдай хан сордылар:

– Әй, Тарағай! Сәнең айлу-йөклү хатуның барму?

Ул Тарағай әйде:

– Бәли, бардур, – тиде.

Андин соң Җәдай хан әйде:

– Әй, Тарағай! Сәнең хатунуң қорсағындағы балаң мәне үлтүрүр *// (9а кәгазь)* ирмеш. Ул туғмасдин борун мән аны үлтүрүрмән! – тиб, Тарағайның хатунын алдурды. Ул ахмақ тәқдирне тәдбир берлә бозмақ теләде. Әмма Хақ Тәғаләнең тәқдире нитәк булса – андағ булур.

Андин соң киңәштеләр, «бу хатунны үлтүрәлең» тиб, «эчен йаралық» тиделәр[70], «үлтүрүр булса[71], ул қорсағдағы баласыны тезләб үлтүрәлең, анасы үлмәсүн!» – тиде.

Андин соң ул хатунны йықыб, андағ тезләделәр кем, исе-осы китде, үлә қалды.

Андин хан әйде:

– Имди баласы дәгел, анасы һәм үлде булғай, йибәреңләр! – тиде.

Андин соң ул хатунны күтәреб алыб, арбаға салыб киттеләр.

Андин соң Җәдай хан қурқунычыдин қотулдым тиб торур ирде, ханлығына мәғрүр-мәшғүл ирде.

Андин йәнә бер анча көнләрдин соң ул мескин тезләб имгәнгән[72] хатунның күзе йаруды, бер ир уғлан туғурды. Ул уғланны алыб бақтылар ирсә, бер айақы ақсақ ирде. Анда әйделәр кем: «Ошбундай имгәкдин үлмәй қотулуб туғдуң, жаның[73] тимер икәндүр!» – тиделәр. Ул уғланның атыны ул сәбәбдин Ақсақ Тимер қуйдылар.

Имди хәзрәти Ақсақ Тимернең асылы-төбе барлас дигән ру булур ирде, нәселендә-руында ханларға җәйан уғул *// (9б кәгазь)* ирде. Андин соң йәнә Ақсақ Тимернең атасы һәм анасы үлде, йәтим қалды. Асрарға, күрәргә һич лайық кеше булмады. Ахыр, үзе йөрүрдәй булуб, ир йиткәндин соң қазақ чықыб, йалғуз Шымақи шәһәрегә барды, бер анча йөрүде, Шымақида бозаулар көтмәгә жалға инде. Үзегә үзе кебек үксүз-йәтим йегетләрне ийәләндүрде, алты-йите уғул бер булуб көн дә бозау көтәр ирделәр, тәқи уйнар ирделәр.

Анда Ақсақ Тимер көнләрдә бер көн бер бозуқ кәшанә төбендә йалғуз

---

[70] Кулъязмада текстка өзеклек кергән. «Өченче текст»ның әлеге урынында: «Анда Җәдай хан үзе әйде: «Мәне бу хатунның қорсағындағы бала...» рәвешендә язылган.

[71] Кулъязмада «булсақ» дип ялгыш язылган.

[72] Кулъязмада: икән. Монда «имгәнгән» сүзе «Өченче текст»тан алынды.

[73] Кулъязмада «ханың» дип ялгыш язылган.

тайаныб бақыб торур ирде. Бер айағы ақсақ, тәқи бер күзе суқур қырмусқа килде, тәқи ул кәшанәгә тырмашыб менәргә йабушды. Бер анча йуқару менде, йықылды. Андин соң йәнә һиммәтләнеб, тәқи йабушды, тырмашыб кәшанәнең башыға менәйен, чықайын тигүнчә йәнә түбән йықылды. Бу хәзрәти Ақсақ Тимер қырмусқаның бу эшегә таңға қалыб, қараб торур ирде. Ақсақ қырмусқа, ғарләнмәйен, йәнә өчүнче мәртәбә кәшанә башыға менәргә йабушды. Ахры бар, тырмаша-тырмаша торғач кәшанәнең түбәсегә чықыб китте.

Ул қырмусқадин бу хәзрәт: «Күрдүңмү, бу зәғиф, айақсыз, күзсез қырмусқа һиммәтләнеб йықыла-тора там түбәсегә менде, йуқару чықды. Мән һәм һиммәт берлә хан булуб, ил-көн, шәһәрләр алыб, *// (10а кәгазь)* урдалар алсам, һич таң-ғәҗайеб булмас. Әгәр Тәңре Тәғалә бойурса», тиб, күңеленә бу фикерне салуб йөрүр ирде.

Тәқи ул уғланлар берлә уйнар ирде. Көнләрдә бер көн Ақсақ Тимер әйде:

– Әй, йегетләр! Килеңләр, бер йиргә бер нәрсә қуйалы. Ул қуйған нәрсәне кем элек йөгерүб йитеб алса, аны арамызда хан қыйлайық! – тиде.

Анда ул йегетләр әйделәр:

– Хуш, андағ булсун, – тиб, алысға бер нәрсәне алыб қуйдылар. Тәқи барча уғланлар йөгүрүшделәр. Ақсақ Тимер һәм йөгерүр ирде. Йөгүрүб уғланлар шайы бара алмады, аның өчүн кем – ақсақ ирде. Андин бер уғлан йөгүрүб узуб, «ул қуйған нәрсәне алайын, мән элек хан булайын» тигүнчә, андин борунрақ ул нәрсәне Ақсақ Тимер бүрке берлә ташлаб орды. Тәқи әйде:

– Әй, йегетләр! Сезләрдин борун мән йитдем, мән хан булурмән! – тиде.

Ул берәү әйде:

– Йуқ, сәндин борун йитеб мән алдым! – тиде.

Анда Ақсақ Тимер әйде:

– Һа, сәнең қулың йиткүнчә, мәнем башым йитде, – тиде.

Болар бу сүз өстүндә бәхәсләшеб торурлар ирде, бер ақ сақаллық қарт кеше килде. Болар ул картқа эшләрен сөйләделәр, «Ханлық қайсубезгә тигәр?» – тиделәр.

Анда ул қарт әйде:

– Әй, *// (10б кәгазь)* йегетләр! Сезләр мәнең сүзүмне тотармусыз? – тиде.

Болар әйделәр:

– Әй, баба! Сән һәрни дисәң, эшемезне сәнгә салдуқ, – тиделәр.

Анда ул қарт әйде:

– Әй, йегетләр! Бу ақсақ уғулның сезнең қулуңыздин борун башы йитебдүр, моны хан қылуңыз! – тиде. – Сүз моның сүзедүр! – тиде.

Анда бу үзгә йегетләр әйделәр:

– Әй, баба! Хуш, имди андағ қыйлайын, – тиделәр. Ақсақ Тимерне үзләре араларунда хан қылыб уйнар ирделәр.

Йәнә көнләрдә бер көн Ақсақ Тимер әйде:

– Әй, йегетләр! Һәркем ошбу көтә торған бозаулардин бер бозауны суйуб, барчамызға йидүрсә, арамызда аны хан күтәрәле, – тиде.

Анда йәнә үзгәләре қыйыб бозауны суйа алмадылар. Ақсақ Тимер бер бозауны суйды, бешүрде, ул уғланларға йидүрде. Ашадылар, андин соң Ақсақ Тимерне үз араларында хан күтәрделәр. Андин қайтыб өйләренә килделәр, бозау ийәсенә әйделәр:

– Бозавыңны бүре ашады, – тиб.

Ул һәм нәрсә димәде, «бүрегә бойурған икәндүр» тиде.

Андин соң, көнләрдә бер көн Ақсақ Тимер бу уғланларға әйде:

– Әй, йегетләр! Килеңез, безләр қарақчы булалық, базаркярләрне, сатучыларны тоталық, малын алалық! – тиде.

Анда бу уғланлар *// (11а кәгазь)* әйделәр:

– Хуш булсун! – тиделәр.

Анда Ақсақ Тимер әйде:

– Сезгә сүзүм улдур кем, имди бу кичә һәркайсуңыз һич үзгә нәрсә алмаңыз. Мәгәр йау қоралын қуймаңыз, алыңыз! – тиде.

Анда бер бозуқ кәрвансарай бар ирде, болҗалны анда қуйдылар. Төннүң йарумунда килеб бер-берсенә йулуқдылар, қайсысы көбә кийеб, мылтық алыб, қайсысы уқ-садақ, қылыч алыб, ушал Шымақи шәһәрендән чықыб киттеләр. Һиндустан шәһәрегә барыб, Һиндустан шәһәренең йулын сақлаб йаттылар, узған-барған сатучылар, асламчыларны бастылар, малларын алдылар, олу қарақчылық қылдылар.

Азған-тузған, ата-анадан бизгән уғланлар, байдан қачқан қоллар аңар җыйылдылар, қушулдылар. Һәркем тышдан килеб аңар қушулса, аңар лайық алапалар бирә башладылар. Базаркянләрне, сатучыларны қырдылар, қол-қотанны йулдаш қылдылар, бер ике-өч йөз кешеләр булдылар. Узған-барғанны талар ирделәр, йул көллисе киселде. Кәрван халқы йөрүмәз булдылар.

Анда Һиндустан падишасы Җәдай ханға хәбәр төште – «Йулны қарақ сақлайдур, кешеләрне йөрүтмәйдүр» тиб. Андин соң Җәдай хан илче йибәрде, өч йөз кеше *// (11б кәгазь)* берлә килеб Ақсақ Тимергә әйде:

– Ақсақ! Нә өчүн сән мондағ уғрулуқ қыйлурсән, йулларны бағларсән? – тиде.

Анда Аҡсаҡ Тимернең чирүе ул килгән илчебашын үлтүрделәр, үзгәсен барчасын үзләренә йулдаш ҡылдылар, күб ағыр алапалар бирделәр.

Бу хәбәр йәнә Җәдай ханға ишетүлде. Үртәнде[74], көйде, йәнә икенче мәртәбә илче йибәрде. Ул икенче килгән илченең башын йибәрделәр, үзгәләрен алыб ҡалдылар, йулдаш ҡылдылар. Андин соң Җәдай хан йәнә өчүнче илче йибәрде, «ул ҡараҡларға алтун-көмүш алапа бирәйен, узғанбарғанға, базаркянләргә тимәсүн» тиб.

Анда болар әйделәр:

– Имди Җәдай ханның ҡазнасындан безнең ҡазнабыз күбдүр, кирәк булса бездән алсун, – тиделәр.

Андин йәнә бер анча көнләрдин соң Җәдай хан үзе чирүен йыйыб киләдүр тиб, Аҡсаҡ Тимергә хәбәр төште. Анда Аҡсаҡ Тимер белүргә ҡаршы шымчы йибәрде, хан киләмү иркән тиб. Ул шымчы барыб күрде – Җәдай хан килә йатур. Шымчы барыб анларның арасына керде, Җәдай хан утуз кеше берлә үзе илгәрү килүр ирде. Бу барған шымчыны күрделәр, монлар йәнә сордылар:

– Һа, йулда ҡараҡ күрдүңмү? – тиб сорды.

Бу әйде:

– Йуҡ, һәргиз күрмәдүм, бу йулдан[75] *// (12а кәгазь)* һич шиксез йөрүң, ҡараҡ йуҡдур, – тиделәр.

Болар моның бу сүзенә баҡыб, «ҡараҡ йуҡ ирмеш, безнең килгән хәбәремезне ишетеб ҡачҡандур» тиделәр. Илгәрү узуб киттеләр.

Бу шымчы үз йоруғына китте. Анлардин айырылыб, аулаққа чыққандин соң ҡайтты, Җәдай ханның утуз кеше берлә килә йөргәнен Аҡсаҡ Тимергә килеб әйде.

Анда Аҡсаҡ Тимер әйде:

– Алай булса, тиз имди утуз түәгә йөк йөкләндүрүң! – тиде.

Шул уҡ заман утуз түәгә йөк йөкләделәр. Аҡсаҡ Тимер Җәдай ханның килә торған йулы берлә ҡаршу йөрүделәр. Җәдай хан төшүб йатур ирде, болар ҡаршы бардылар. Җәдай хан боларға алысдан сүзләштеләр:

– Сез йулда ҡараҡ күрдүңезмү? – тиде.

Болар әйделәр:

– Йуҡ, һич күрмәдүк, – тиделәр. Андин соң Җәдай[76] хан боларның ҡашыға килделәр. Анда болар әйделәр:

– Һа, сезләр нә кешеләрсез?

Анлар әйделәр:

---

[74] Кулъязмада «үртәндин» дип хаталы язылган.

[75] Бу ике сүз кустодта язылган.

[76] Кулъязмада «Җәдан» дип ялгыш язылган.

– Безләрне сорсаңыз, без Җәдай ханбыз, қарақларны эстәй чықдуқ, – тиделәр.

Анда болар:

– Андағ булсаңыз, без сатучыларбыз, бездән малыбызның тамғасын алыңыз, безгә һәм йул йөрүргә, сату қылурға йахшы булур, – тиделәр.

Анда Җәдай хан бу сүзгә туқтаб тик торды, бойурды:

– Тамғасын *// (12б кәгазь)* алыңлар! – тиб. – Болар безгә, шайәд, асыл-тансуқ мал алыб килгәндүр, – тиде.

Андин соң Җәдай ханның кешеләре йөкләрне ақтарыб, тамға алайын тигүнчә Ақсақ Тимернең кешеләре берен-берен тотуб үлтүрделәр. Хәзрәти Мир Тимер үзе Җәдай ханны тотты үлтүрүр өчүн. Җәдай хан әйде:

– Аһ, әй, Ақсақ! Мән сәңгә йахшылық қылдым, сән мәнгә йаманлық қыйлурсән, үлтүрүрсән, – тиде.

Анда Ақсақ Тимер әйде:

– Сән ғафилсән, мән – ғафил дәгүлмән! Мән үзүмгә йаманлық қылмазмән, мән үзүмгә йахшылық қылурмән, – тиде. Үлтүрде, башын кисде. Андин соң Ақсақ Тимер үзе Һиндустан шәһәренгә барыб, анда[77] хан булды. Тәқи бу қалған чирүгә чабқун йибәрде, «үзгә йул берлә килсүнләр!» диб. Чирүенә хәбәр төшде ирсә, рәван килеб анлар һәм шәһәргә инделәр. Шәһәрен алдылар. Андин йәнә Җәдай ханның артында қалған чирүе бу хәбәрләрне, бу эшләрне аңламайын, «ханымызға анда йитәрмез, монда йитәрмез» тиб бара торғач, йитә алмай, қайттылар. Ханларын йуғалтыб килделәр ирсә, «шәһәрне Ақсақ Тимер алыбдур» тиб, нәрсә итә белмәделәр, Ақсақ Тимергә бағындылар.

Имди Ақсақ Тимер Һиндустан шәһәрене ошбулай алды тиб[78] [...]

// (25а кәгазь) ...дур. Бу шәһәрне Ақсақ Тимүр оруш-туқуш берлә алмады. Ахры, ошбундағ хәйлә берлә кем, үзене сырхау қыйлды, [тәнегә] сары зәғферан сөр[тде]: тәне, башы, күзе саб-сары булды. Андин соң Шаһ-солтан ханға илче йибәрде мондағ сүз берлә кем: «Әй, Шаһ-солтан! Имди беләсән кем, мәнгә әҗәл ирешде, тәмам тәнем саб-сары зәғферан тик булды. Гөнаһым шомлуқындан имди сәндин үтенәмән кем, мән бу эшләрне, орушмақлықны қуйдум. Рәхим қылыб, сән мәнең берлә бәхилләшсәң ирде?» – тиб, хат йәбәрде.

Ул илче килеб шәһәр қабусында торды, илчелеген белдүрде. Андин ул хатны алыб Шаһ-солтанға илтделәр. Шаһ-солтан қараб күрде, «шайәд

[77] Кулъязмада «андый» дип ялгыш язылган.

[78] Соңгы ике сүз кустодта язылган. Аннан соң текстка өзеклек керә, кулъязманың бер кәгазе төшкән.

йалғандур, хәйлә қыладур» тиб, ышанмады. Ул һәм монуң сырқаулықыны белмәк өчүн кешесен йибәрде, «Барғыл, қараб күргел!» – тиде.

Андин Шаһ-солтанның йибәргән кешесе Ақсақ Тимүрнең чатурыға килеб керде, күрде кем – Ақсақ Тимер сары зәхмәте берлә хәлсез улуб йатур.

Ақсақ Тимүр әйде:

– Әй, илче! Мәнең хәлем усалдур, – тиде.

Андин ул йибәргән кешесе Шаһ-солтанға килеб сөйләде: *// (25б кәгазь)*

– Сырхау улмышдур, хәл эчендәдүр, – тиде. – Ғәйәт илтимас қыйлды кем, «рәхим [итеб, килсә, бәхилләшү]р[79] ирдем», – тиб әйтүр ирде.

Шаһ-солтан аның сүзенә ышаныб, шәһәрнең тәмам қапуғларын ачтурды, үзе һәм ләшкәре берлә чықды, Ақсақ Тимүргә килде. Күрешүб сүзләшә торур иркән, сырқаулықындин терелеб, тора салыб Шаһ-солтанны тотты, үлтүрде. Килеб ләшкәре берлә шәһәргә инделәр. Бу хәйлә берлә ул шәһәрне һәм алдылар. Ул урданы һәм үзегә бақтурды. Бер анча йыллар анда тордылар.

Андин йәнә чирүен йараштуруб, чирүе берлә Шымақи шәһәрегә килде, аны һәм алды, үзегә бағундурды.

Андин узуб йөрүб, Хаҗитархан[80] шәһәрегә килде, орушуб-туқушуб Хаҗитархан һәм алды, бақтурды. Анда биш-алты йыл торды.

Андин соң йәнә Болғар шәһәрегә килүргә йарағланды, күб-күб қатырғалар, кимәләр берлә Болғар шәһәрен алғалый килүргә кимәгә менде. Қайсысы ошбу Идел суының тыш йағындан килделәр, чирүенең саныны-хисабыны Аллаһдан ғәйре кемсә белмәс ирде.

Ушда анлар мондағ олуғ чирүе берлә килмәкдә. Әмма ул дәвердә, ул заманда Болғар шәһәрендә ханлары Ғабдулла хан дигән ирде. *// (26а кәгазь)* Ғабдулла ханға хәбәр ирешде кем, «Ақсақ Тимер киләдүр» тиб. Шул заман Ғабдулла хан ләшкәр йығдурды, ағыр чирү хәзерләб, каршу йөрде. Ахыр, бер-берсигә йулықушуб қаты оруш [қылдылар. Ақсақ Тимернең орышына][81] түзмәделәр, сындылар. Басыб Болғар шәһәренгә [килделәр]: үлгән үлде, қалған шәһәргә берекләнделәр.

Ақсақ Тимүр килеб, шәһри Болғарны йите йыл қамсаб торды. Тарих йите йөз йылда ирде, зөлхиҗҗә айының йегермесендә ирде, шәһри

[79] Кулъязма кәгазенең өске өлеше таушалган булуы сәбәпле, бөтен сүзләре дә укырлык түгел. Квадрат җәяләр эчендәге сүзләр монда «Бишенче текст»тан алынды. Моннан соңгы 26–28 нче кәгазьләрнең дә югары тарафлары дефектлы булганлыктан, кайбер сүзләр башка текстлардан алынды.
[80] Кулъязмада «Хачитархан» дип хаталы язылган.
[81] Квадрат җәяләр эчендәге сүзләр монда «Бишенче текст»тан алынды.

Болғарны алдылар, хәраб қылдылар. Йөз дә йегерме түрт олуғ бикләр бар ирде, анларның тәмамысын қырдылар. Һәрқайусының кә-әмсалел-ләә-ләә әл-мәкнүн тик хатунларыны Ақсақ Тимер йәсир қылды. Ул бикләр эчендә түрт олуғ бикләр бар ирде, аслый шаһзадәләр ирделәр: бере – Иқбал бик, йәнә бере – Қол Ғәли бик, йәнә бере – Хәваши бик, йәнә бере – Мырқаш бик дирләр ирде – тәмамын һәлак қыйлдылар. Күб-күб хәлайық һәлак булдылар. Ғабдулла ханны һәм үлтүрделәр.

Әмма Ғабдулла ханның ике уғылы бар ирде, берсе – Алтунбик, икенчесенең аты Ғалимбик дигән ирде. Жаудин-қырғындин қачуб қалған кешеләр Алтунбик бер[лә] Ғалимбикне урман төбегә илтеб йәшүрделәр. Бере йите йәшендә, тәқи берсе туқуз йәшендә ирделәр. *// (26б кәгазь)* Анларны йахшы асрар ирделәр.

Андин [соң ул Ақсақ Тимүр ул] шәһри Бо[лғарны вәйран қыйлды]. Хәраб қылғандин соң Бүләр шәһәрегә килде чирүе берлән. Бү[ләр шәһәренең қаршусыға килеб][82], ур қазыб йатдылар, оруш-туқуш қыйлмадылар. Ул вақытта Бүләр шәһәренең ханының аты Самәт дигән ирде, көбәсе «бозқалбақ» дигән ирде, халқы бараж дигән халық ирде.

Бараж халқының[83] әүвәл замандағы борунғы йорты ошбу Зәй тамағында улур ирде, алыбларның заманыйда бер Бараж атлығ аждаһа йылан килде. Ул шәһәрнең халқыға көч-зыйан қыла башлады. Чықыб аждаһа берлә суқушдылар, йиңә алмадылар. Ахыр, үзләре шәһәрен салыб қачтылар, Болғар шәһәренең йақыныға[84] барыб, Бүләр суының өстегә йорт-шәһәр салдылар. Ул шәһәрләрегә һәм Бүләр тиб атадылар, ул сәбәбдин аны «Бүләр халқы» тиб әйтүр ирде, оранлары «бараж» ирде.

Анда Самәт хан әйде:

– Аһ, әй, бараж халқым! Борун олуғ бабаларымыз Баражның зыйаныдин қачыб шәһәрләрен салыб, ошбунда килебләр, мәқам-йорт тотублар. Имди Бараждин көчлүрәк Ақсақ Тимүр килде, шәһәремез қаршыға төшде. Нә қылурмыз? – тиде.

// (27а кәгазь) Анда ул бараж халқы әйделәр:

– Әй, ханымыз! Сез белүрсез, ирек сезнеңдүр! – диделәр. – Һәрнә дисәң, иркемез йуқдур, – тиделәр. – Әмма бойурсаң, Ақсақ Тимүр ләшкәре берлә һәм ору[шырбыз – йә үләрмез, йә үлтү]рүрмез! – тиделәр. Анда Самәт хан әйде:

– Имди мәнең қашымда бер вәли кеше бардур, андин сорайын, ул

[82] Бу абзацның ике җөмләсендәге квадрат җәяләр эчендәге сүзләр монда «Алтынчы текст»тан алынды.
[83] Кулъязмада «халықның» дип ялгыш язылган.
[84] Кулъязмада «йағыныға» дип хаталы язылган.

нә бойурур, аның сүзендән чыкмазмыз, – тиде. Ул вәли кешене алдуруб сордылар, тәки әйделәр:

– Ай, безнең олуғымыз! Имди безләр ошбу өстүмезгә, шәһәремезгә килгән Ақсақ Тимүр берлә оруш қыйлалықму? – тиде.

Анда ул вәли әйделәр:

– Хуш, қарайын, – тиб, бер манараның башыға менде. Тәқи Ақсақ Тимүрнең чирүе тарафыға қарады ирсә, күрде кем – хәзрәти Хозыр Ақсақ Тимүрнең чирүендә бергәдүр. Андин соң манарадин төшүб, хан Самәтнең қашыға килде, тәқи әйде:

– Әй, ханым! Орушурға рөхсәт йуқдур! Хәзрәти хуҗаи Хозыр ғәләйһиссәлам аның чирүендә бергәдүр. Тәңре Тәғаләнең бойруқыңға муйун сонмақ кирәкдүр, қабқаларын ачтурғыл! – тиде ирсә, ул хан, тәқи бараҗ халқы йығлашдылар. Тәқи әйделәр:

– Нә қылмақ кирәк, Хак Сөбханәһә Тәғаләнең хөкеменә муйун сонмақ кирәк, – тиб *// (27б кәгазь)* шәһәрләренең тәмам қабқаларын ачтылар, ирек салдылар, орушмадылар.

Андин хәзрәти Ақсақ Тимүр чирүе берлә шәһәргә инделәр, халқыны қырдылар.

Әмма анд[а Ақсақ Тимер кичә үзе шы]мчы[85] булуб, төсүн әверүб хәлайықларның эченгә кереб, сынай йөрүр ирде. Тәқи әйтүр ирде:

– Әй, хәлайықлар, йегетләр! Бөлүклүк, бу қырғын безләргә кемдин торур? – тиб сорар ирде.

Анда ул ултурғанлар әйтүр булсалар: «Безне Ақсақ бөлдүрде, аның шомлуғындан бөлдүк, җуйулдуқ» дигән кешеләрне иртәгесен тәмам руы-тамуры берлә һәлак қылур ирде.

Һәркем гөнаһын үзүндин белеб әйтүр булса ирде «бу бөлүклүк үз шомлуғумыздан безгә йитте» тиб, аны руы берлә үлтүрмәй, талатмай йибәрүр ирде.

Әл-қыйсса

Кичәләрдә бер кич хәзрәти Ақсақ Тимер шымчы булуб бараҗ халқының арасыға кереб әйде:

– Әй, бараҗ халқы! Бу бәла сезләргә қайдин килде?

Анда анлар әйделәр:

– Кемдән ирдүкен белмәймүсән? Убур Ақсақ Тимер килд[е], безне қырды, бөлдүрде, – тиделәр.

[85] Текстның квадрат җәяләр эчендәге өлеше «Бишенче текст»тан алынды.

Анда ул кичә ул җыйын[86] эчендә бер олу бикнең ғақыллық, услық, тол қалған хатуны бар ирде, ул әйде:

– Әй, йегетләр! Бу эшләрне, бу бөлүкләрне үз гөнаһымыз шомлуқындин // *(28а кәгазь)* беләйек. Ул Ақсақ Тимер нә қылур ирде? Тәңре Тәғаләнең тәқдиредүр! – тиде.

Ул хатунның ире Җадәш бик дигән ирде, ул хәзрәти Ақсақ Тимер килмәсдән борун үлгән ирде. Ул Җадәш бикнең ике уғылы бар ирде, берсе – Инсан, икенчесе – Ихсан дигән ирде.

Ул кичнең иртәгесен Ақсақ Тимер ул хатунны уғланлары берлә қашыға алдурды. Болар нә эшкә алдурғанын белмәйен, «безләрне үлтүрүр» тиб, йығлашыб килделәр. Анда Ақсақ Тимер ул хатунға әйде:

– Сән гөнаһыңны үзеңдин белүрсән, «һәр эш безнең үз шомлуғумыздин» тиб әйтүрсән. Имди бу көндин соң сәне тәмам уғылуң-қызың, қәрендәшләрең берлә йарлықадым. Һәрқанда сәүсәңез, ул тарафқа киткәйсез! – тиде. Үзе һәм тәмам чирүгә йар салды:

– Бу кешегә тимәңләр[87], малыны таламаңлар, һич нәрсәсегә зыйан тигүрмәңләр! – тиб, ул бу бөлүклүкне, гөнаһны үзүндән белгән өчүн тәмам уғылы-қызы, қәрендәшләре берлә йарлықаб йибәрде.

Андин соң ул бик, бере Инсан, берсе Ихсан – икеләсе киңәш итеб күчмәгә нийәт қылдылар. Инсан бик әйде:

– Әй, анамыз! Ошбу олуғ Иделнең[88] эч // *(28б кәгазь)* йүнегә – Тау йирегә барурмыз, анда мәқам тотармыз, аның өчүн кем – ул йирдин бәрик йир йуқдур, – тиде.

Анасы һәм аның сүзен йаратыб қабул қыйлды. [Әмма энесе И]хсан[89] бик ул тарафқа барурға өнәмәде, иске бабаларым йортыға – Зәйгә барурмыз, мәқамен-йортын тотармән, – тиде.

Инсан бик әйде:

– Мән ул йиргә бармандур, – тиб, айырылды. Тау тарафыға[90] китде. Анасы һәм аның берлә китде.

Анда барыб, Гөбенә дигән суның буйунда мәқам тотды. Ул Инсандин бер уғыл туғды, атын Сәлман қуйды. Сәлман уғылы Қәдер, Қәдер уғылы Нурдәүләт, Нурдәүләт уғылы Нурхәсән, Нурхәсән уғылы Нурәбдал, Нурәбдал уғылы Қотуш, Қотуш уғылы Мақтым, Мақтым уғылы Иктәй, Иктәй уғылы Мәхмүд, Мәхмүд уғылы Хуҗамөхәммәд, Хуҗамөхәммәд

---

[86] Кулъязмада «чыйын» дип хаталы язылган.
[87] Кулъязмада «бәтмәңләр» дип хаталы язылган.
[88] Кулъязмада «Әүлинең» дип хаталы язылган.
[89] Текстның квадрат җәяләр эчендәге өлеше «Алтынчы текст»тан алынды.
[90] Кулъязмада «тарафықа» дип хаталы язылган.

уғылы Тәвәккәл, Тәвәккәл уғылы Пирмөхәммәд, Пирмөхәммәд уғылы Җанатай, [Җанатай] уғылы Бәбәш, Бәбәш уғылы Үлмәсчуқаш.

Әмма Ихсан бик, Тау тарафыға[91] мәйел қыйлмайын, Зәйгә килд[е]. Ихсандин бер уғыл туғды, атын Әлмөхәммәд қуйды. Әлмөхәммәд уғылы Қаймөхәммәд, Қаймөхәммәд уғылы Туқмөхәммәд, Туқмөхәммәд уғылы Атлақ, Атлақ уғылы Шәмәк, Шәмәк уғылы Туғый, Туғый уғылы Сәман, Сәман уғылы Ындырҗы, Ындырҗы уғылы Тәкәнеш, Тәкәнеш уғылы Бәзәргән ирде. Тамғалары *// (23а кәгазь)* «қуш кәшан», оранлары «бараж» торур.

***

Имди йәнә сүзне [башдин сүзлә]йәле[92]. Ул хәзрәти Ақсақ Тимүр Бүләр[93] шәһәрен вәйран қылғандин соң Мәскәү тарафыға китде, анда ләшкәре берлә барыб Ал[адимүр дигән гәү]р қаласыға йитде, оруш қылғалый нийәт қылды. Гәвүр һәм чирүен ул қаласына җыйдурды. Хәзрәти Ақсақ Тимер барған[94] вақытда кяфер-урус[95] гәвүрнең ханы Михайла атлығ ирде. Хәзрәти Мир Тимер шәһәрләр алыб аңар барған хәбәрләре гәвүргә ирешүб, қаты қурқуғда ирде. Хәзрәти Мир Тимер гәвүрнең қаласы Аладимүргә йитеб ирде, хәзрәти хуҗа Хозыр ғәләйһиссәлам[96] килеб Ақсақ Тимергә әйде:

– Халә[97] бу кяфер берлә орушурға, тәқи қырарға вәғдә ирешмәйдүр! – тиб хәбәр бирде. Әмма бу кяфергә кәрамәтеңне күрсәткел! – тиде ирсә, хәзрәти Ақсақ Тимер шул заман тора салыб өч йәшәр тай берлә кяфер тарафыға атды. Хақ Тәғаләнең қөдрәте берлә, ул ташлаған тай барыб кяфернең таш манасырыны уртара өзүб, бер чақрым йир барыб төште. Тай төшкән йир су булды.

Андин соң кяфергә һәйбәт орунды: теле-ағызы тотулды, қурқудан битләрендә қаны қалмады.

Андин соң хәзрәти Мир Тимер орушмай (вәғдә ирешмәгән өчүн) чирүе берлә қайттылар[98]. *// (23б кәгазь)* Қайтыб Бохара шәһәрегә барурға йүнәлделәр. Килә йөрүгәнендә қайа йирләрендә [Амәт, Самәт] дигән

---

[91] Кулъязмада «тарафықа» дип хаталы язылган.
[92] Кулъязмада 23 кәгазьнең өске өлеше таушалган булуы сәбәпле, бөтен сүзләре дә укырлык түгел. Мондагы ике җөмләдәге текстның квадрат җәяләр эчендә бирелгән өлешләре «Алтынчы текст»тан алынды.
[93] Кулъязмада: Болғар.
[94] Кулъязмада бу сүз «бик хан» дип ялгыш язылган.
[95] Кулъязмада «ләр уш» дип хаталы язылган.
[96] Кулъязмада: ғһм.
[97] Кулъязмада «хани» дип ялгыш язылган.
[98] Кулъязмада бу сүз ялгыш ике мәртәбә язылган.

ике ханға хәбәр төшде «Ақсақ [Тимер киләдүр»][99] тиб. Ту бийә суйуб, халқын йыйыб, «қайу тарафға күчәйек?» тиб киңәш қылды. Анда ул халық уңмаслық қылыб, берәү атын мақтады, берәү этен мақтады, берәү алған хатынын[100] мақтады. Бешкән ит ашалды, киңәш булмады, халық уғылы тарқады. Анда Кинҗә дигән берәү йығлаб әйде:

– Әй, қалтақлар! Үзе ала сан кеше булғунча, үзе ыруы бер қырық кеше булса ирде, һәрайинә, бер эш қылур ирдек.

Әй, қалтақ! Бу нә эшләр?
Ғақилләр буны сүзләр,
Ғақылсызлар көләрләр,
Киңәшкә җыйылурлар.
Қалтақ! Бу нә эш?
Берәү атын мақтар,
Берәү этен мақтар,
Берәү хатунын мақтар –
Киңәш булмас, халқы тарқар,
Ашын ашады – қачар китәр.

Һәрайинә, безнең бөлүклүгемезгә сәбәбдүр, безгә бөлүклүк йақындур! – тиб йығлар ирде. Анда ул Кинҗә әйтүр:

– Әй, йаранлар, халық! Мондин күчәбез, сез монда қалсаңыз[101], Қуй суының башында Олу Убада болҗалый булсун. Без ул тарафға күчәйек!» – тиб[102] әйтүр ирде.

Анда йәнә берәү атының ақ күбүген оруб, чапаланыб, чымырғаныб қычқуруб-бақуруб:

– Һай, ханым! Йау йитте. Ақсақ Тимүр менә *// (24а кәгазь)* килә йөрүр! – тиб хәбәр салды ирсә, хан үзе башлаб күчәр булды ирсә, «Йассы Қамышда ултурурмән» тиб халықға йар салды. Хан күчде, хан берлә халық һәм күчде.

Әл-қыйсса

Күчүб бара торғанда бер қортқаның тирмә айылы өзүлде. Артын қараб бақғунча, қортқаның бүрке төште. Анда берәгү бер имлек тай менгән уғлан килә торур ирде, қарсунда қоруғы, қанҗығында баш күнәге бар ирде. Бу қортқаның бүркен алыб бирәйен тигүнчә, ийәре ауды, тай дулады, йылқы өрүкте. Берәү тайға чабды, үзе белмәгәнләр «Һа, йау йитте!» тиб, халық

[99] Текстның квадрат җәяләр эчендәге өлешләре «Бишенче текст»тан алынды.
[100] Кулъязмада «халқын» дип ялгыш язылган.
[101] Кулъязмада «қалыңыз» дип ялгыш язылган.
[102] Кулъязмада бу сүз ялгыш ике мәртәбә язылган.

уғылы өркүб, башлы башын йаравын қылдылар. Тимә тарафқа туздылар[103]. Анда Ақсақ Тимүрнең чирүе йитеб, ханны, халықны туқтатды, қамсады: үлгән үлде, халық[104] посташ булды.

Анда Ақсақ Тимүр үзе урдасына йитеб, ханны алдыға алдурды, тәқи әйде:

– Әй, Амәт, Самәт! Имди үзүңезне[105] тәмуғ утундин қотқаруб, башыңызны қылычдин аман қылыңыз – мөселман булыңыз! – тиб, үгүт бирде.

Анлар һәм үтүнделәр:

– Ақсақ Тимүр! Әгәр без мөселман булсақ, безгә халқымызны бирүрмүсән? – тиделәр.

Анда ул әйде:

– Әгәр сез раст мөселман булсаңыз, «Лә иләһә иллә Аллаһу Мөхәммәд рәсүлуллаһ» тиб иман килтүрсәңез, Тәңре Тәғалә- *// (24б кәгазь)* -не бер белеб, пәйғамбәрләрне хақ белеб, бер көндә биш вақыт намаз қылыб, бер йылда утуз көн рузә тотуб, җәнабәте ғөсел қылыб, малыңыздин зәкят биреб, әгәр көчүңез йитсә Кәғбәгә барыб тәваф қылсаңыз, муғыллықны ташлаб, хасс мөселман булсаңыз, үзеңүзгә һәм халқыңа тимәндүр! – тиб әйде ирсә, анлар барчасы мөселман булдылар.

Хәзрәти Ақсақ Тимүр анларға дине исламны үгрәттүрде. Бер-ике йыл ул күчәле халық арасында торды, мөселманлықдин тәмам белдүрде. Андин со[ң] үзе, тәқи үзгә чирүе аларға асанлашуб[106], андин китделәр. Болар мөселман булуб монда қалды, һәр йыл бер йиргә күчәр ирделәр.

Әл-қыйсса

Ул хәзрәти Ақсақ Тимер андин узуб йөрүб Бохара шәһәрегә барды, аны алды, Ташкәндне һәм алды, ул вилайәтләрне үзегә бағындырды. Андин Сәмәрқәнд шәһәрегә барды, аны һәм алды. Әмма үзенең һәм ахыр ғөмере анда булды. Хақ Тәғаләнең тәқдире ирешүб, хәзрәти Ақсақ Тимүр һәм ошбу фани дөнйадин үттеләр, рәхмәтуллаһи ғәләйһи рәхмәтән васиғәтән. Қалү: «инна Лилләһи вә инна иләйһи ражиғун».

Андин хәзрәти Мир Тимүрнең қәберенең өстегә таш астанә қубардылар, башыдағы гөнбәзене алтундин, көмүшдин йасадылар, та қийамәткә[107] [...]

[103] Кулъязмада «түнделәр» дип ялгыш язылган.
[104] Кулъязмада «халық» сүзеннән соң ялгыш «булды» дигән сүз язылган.
[105] Кулъязмада «рузуңызны» дип ялгыш язылган.
[106] Кулъязмада «санлашуб» дип ялгыш язылган.
[107] Бу сүз кустодта бирелгән. Аннан соң текстка өзеклек кергән, кулъязманың ике кәгазе төшкән булса кирәк.

[Дастане Ғәйсә уғылы Амәт]

// (19а кәгазь) [...] Алау әйде:

– Әй, Амәт дус! Бер қашық қаным үтүнәйен, антымны йазыб ирдем, үзүмә килде, – тиде.

Амәт әйде:

– Нә күрсәң, аны айғайсән, – тиде.

Идел башына чықды, Идел башында мәқам-йорт тоттылар.

Җанибәк хан үлгәндин соң Бирдебәк килеб қушулды, ханның йарты йортын биләде. Ул вақытда Ачтарханда Тимер Қотлы хан ирде, уғылы-қызы йуқ ирде. Ул заманда Ачтархандан бүрәнә ықтар[ма]ға барған кешеләр ул уғланны табыб алыб килделәр. Алтун бишекле, кеш[е] йөрәкле[108]. Асыл кешенең баласы иркәнен белеб, ханишқа алыб килделәр. Ханиш алыб асрады.

Уғлан ир йиткәндин соң Аждархан эчендә қарақчы була башлады. Халық бу уғланға ачиды, сөймәс булдылар. Халық уғылы йыйылыб килеб ханға әйделәр:

– Әй, ханым! Безне сәүсәң – безне тот, аны сәүсәң – аны тот!– тиделәр.

Анда хан әйде:

– Бу бер уғулда нә булур? Мәнгә халқым кәрәк! – тиде.

Ул уғланны салда алыб килгән өчүн Салчы атаған ирде. Йәнә көнләрдә бер көн Салчы чиругә барды. Анда эчкеле-йигеле йирдә уйунлар үгрәнде, бер қубуздан йөз төрлү йырлар үгрәнде. Анда-монда һәркем берлә сүзгә килүшсә, «Әй, атасыз!» тиб әйтүр булсалар, [әйтүр] ирде:

Ақ Сарайда балчымән,
Әчдарханда тучымән,
Ата сорсаң – белексез[109],
Анам сорсаң – *// (19б кәгазь)* никахсыз,
Үзүм артуқ туған соң
Төбем сораб нидәрсез?

– дир ирде.

Имди Салчы Җанибәк ханның қызындин туған уғылдур[110], ханларға җәйан уғыл[111] торур. Ғәйсә уғылы Амәтнең уғылы[112] торур.

Тәммәт тәмам.

Валлаһу әғләмү бис-саваби.

---

[108] Кулъязмада «йөргәле» дип хаталы язылган.
[109] Кулъязмада «белеңез» дип ялгыш язылган.
[110] Кулъязмада «қыздур» дип ялгыш язылган.
[111] Кулъязмада «қыз» дип ялгыш язылган.
[112] Кулъязмада «қызы» дип ялгыш язылган.

Фасыл фи дастани Идегәй би

(разыйә Аллаһу ғәләйһи вә ғәлә алиһи вә әсхабиһи әҗмәғийн)

Бәгдә визрәтин әү бәгдә әнварил-мәғарифи[113], хосусан ғәләл-имами хәзрәти әмирел-мөэмининә вә имамил-мөслиминә Әбүбәкр сыйддийкис-садыйкы әлләзи һуа хәлифәти[114] рәсүлуллаһи саллаллаһу ғәләйһи вәсәлләм фи күлли наиби әмр.

Шәҗәрә[115].

1 бабасы әмирел-мөэминин Әбүбәкер әс-сиддыйк разыйә Аллаһу ғәнһенең түрт уғылы бар ирде. Икесендән кечек вә берсендән олуғының аты Мөхәммәд ирде, Шам шәһәрендә падишаһ ирде. Аның уғылы солтан Кәғб ирде, ул һәм Шамда бадишаһ булды[116]. Аның уғылы солтан Халид ирде, ул Мисырда[117] бадишаһ булды. Аның уғылы солтан Вәлид ирде, ул һәм Мисырда бадишаһ булды. Аның уғылы Қаид ирде, ул һәм Мисырда бадишаһ булды. Аның уғылы солтан Мәүлүд ирде, ул һәм Мисырда бадишаһ булды. Аның уғылы солтан Әбүлғас ирде, ул Антакийәдә бадишаһ булды. Аның уғылы солтан Сәлим ирде, ул һәм Антакийәдә бадишаһ булды[118]. Аның уғылы Әбүлхак ирде, ул Мәдинәдә бадишаһ булды. *// (20а кәгазь)* Аның уғылы солтан Ғосман ирде, ул һәм Мәдинәдә бадишаһ булды. Аның уғылы солтан Җәлаледдин ирде, ул Қастантида бадишаһ булды. Аның ике уғылы бар ирде, беренең аты Әдһәм вә беренең аты Баба Түкләс ирде. Баба Түкләс Кәғбәдә бадишаһ булды. Баба Түкләснең уғылы Тирмә атлыг ирде. Бу Тирмә Идел-Җайыкда хасил булды. Аның уғылы Қазычы атлыг ирде, ул һәм Идел-Җайыкда хасил булды. Аның уғылы Исламкыйа, ул һәм Идел-Җайыкда хасил булды. Аның уғылы Қадиркыйа, ул һәм Идел-Җайыкда хасил булды. Аның уғылы Қотлукыйа, ул Кәнддә пәйда булды. Аның [уғылы] Идегәй би рәхмәтуллаһи ғәләйһим әҗмәғийн. Қотлукыйаны урус ханы шәһид кыйлды[119].

Әмма Баба Түкләснең түрт уғылы бар ирде: бере Кәғбәдә бадишаһ

[113] Кулъязмада «мәғарикы» дип хаталы язылган.
[114] Кулъязмада бу сүз хаталы язылган.
[115] Кулъязмада «сәҗәрәһү» дип хаталы язылган.
[116] Кулъязмада текстка өзеклек кергән. 1882 елгы басмада әсәр текстының бу урынында: «Аның уғылы солтан Һәрмәз ирде, ул Мисырда падишаһ булды» дигән җөмлә бар *(Һәза китабе фасли дастани нәсли Чыңгыз хан... – Б. 41).*
[117] Кулъязманың бу урынында һәм моннан соңгы өч җөмләдә «Мисырда» атамасы «Сарсарада» дип хаталы язылган.
[118] Кулъязмада текстка өзеклек кергән. 1882 елгы басмада әсәр текстының бу урынында: «Аның уғылы солтан Садәф ирде, ул һәм Антакийәдә падишаһ булды» дигән җөмлә бар *(Һәза китабе фасли дастани нәсли Чыңгыз хан... – Б. 41).*
[119] Кулъязмада «шәһәрдә калдурды» дип ялгыш язылган. Монда 1882 елгы басманың 41 битеннән алынды.

булды, вә бере Кәғбә йанында йатур, вә бере Үргәнечдә йатур, бере Кырымда Өч Үтлүкдә йатур.

Баба Түкләснең бер ривайәт белән мәғлүм өч уғылы бар ирде: беренең аты Ғаббас ирде, Кәғбәнең уң йанында йатур, беренең аты Ғабдеррахман хуҗа торур, ул дәхи Кәғбәдә йатур вә беренең аты Тирмә торур, ул Идел-Җайыкда хасил булды.

Пәйғамбәр саллаллаһу ғәләйһи вәс-сәлләмнең мөбарәк қәберләрен сәйиде наибқа аваз биребдүр, икенче ғәлим Мортаза сәйед торур, *// (20б кәгазь)* өчүнчесе ғәзиз кирамәт Баба Түкләс ата торур. Үзбәк хан мөселман булмышда Үрәкчураны[120] Кәғбә шәһәренгә йибәребдүр. Анда бу өч алыб килеб мөселман булубдурлар.

Валлаһу әғләмү бис-саваби.

Әмма Идегәй би Туқтамыш ханның олусын ул биләде. Идегәй би уғылы Нуразын мирзадур, бөләсен-олусын биләгән.

Фасыл фи дастани вәл-мәҗалис[121] вәл-мәкян

Имди мәғлүм ула, беләсез кем, йортларда Бохара – Болғар ханның йортыдур.

Тора – Орус ханның йортыдур.

Чирмешән – Өм[әр]хуҗа ханның йортыдур.

Өй-Үзәне – Туқтамыш ханның йортыдур.

Җим-Җайық арасы – Җанибәк ханның йортыдур.

Ақтүбә – Пачман ханның йортыдур. Йүчи дигән аның кече энесе булур ирде.

Чаған ханның йорты Торатау тамағындан түбән Алмалы Атаға тигрү ирде.

Ошбу Уфа тамағы – Тирә ханның йортыдур. Андин йәнә Торатауның өстүндә Олуғ Дүбә бар торур, Тирә ханның сарайының урыны ушалдур.

Сарайчық – Чалсақ ханның йортыдур.

Инчыр – Хәким ханның йортыдур. Хәким ханны йир йотты[122], өч йылғача авазы килә йатты, андин соң килмәде.

Вә Аждархан – Тимер Қотлы ханның йортыдур.

Кябер – Бәркә ханның йортыдур.

Қазан – Шығали ханның йортыдур.

---

[120] Кулъязмада «Үрәкҗәван» дип ялгыш язылган. Кадыйргали бәкнең «Җамигыт-тәварих» кулъязмасында (КФУ, «40т») бу исем Үзәкчура дип язылган.

[121] Кулъязмада «вәл-мөхсин» дип ялгыш язылган.

[122] Кулъязмада «ханның йорты» дип ялгыш язылган.

Зәй // *(21а кәгазь)* тамағы – Бүләр ханның йортыдур[123].

[Валлаһу] әғләмү бис-саваби.

Фасыл фи дастани фит-тар[их]

[Йите йөз][124] йылда ирде, Ақсақ Тимүр Болғар шәһәрен алды Ғабдулла хан[дан]. Ғабдулла ханның ике уғылы бар ирде: бере – Алтунбик, бересе – Ғалимбик.

Ул бөлүклүкдин соң килеб, Қазан дәрйасы өстүндә қала йасадылар, шәһәр итделәр. Ул халық йөз дә түрт йыл анда тордылар. Ахыр, ул урунны йаратмайын, андан күчтеләр. Қазан суының тамағында шәһәр төзделәр. Йөз дә илле сикез йыл анда булдылар. Мөселман ханының нәселе анда киселде. Қазан шәһәрендә хан йуқ булды ирсә, ул заманда кяфер уруснең қулунда Шығали хан тотқун ирде, мөселманлар барыб аны килтүрделәр. Қазанда утуз өч йыл ханлық сөрде.

Андин соң кяфер урус көч[әй]үб, ләшкәр берлә шәһәрне алғалый килде. Қалталы Жыван[125] ирде, йите йылғача оруш-сұқуш қылды, мөселманларны ала алмады.

Йәнә Қазан шәһәрен алмасдан борун, Зөйә тамағында кяфер урус қәлғә сұқты. Тубын, малын, қорал[126], азығыны анда қуйды.

Андин соң, ахры бар, Шығали хан урусқа ғаммазлық[127] қыйлыб, урус ханы берлә мөселманлардан өртен-белдермәй берегеб, // *(21б кәгазь)* даруларыға су қойдурды, шәһри Қазанны урус кяфергә бирде. Мөселманлар бу эшдән хәбәрләре йуқ [ирде]. Күб хәлайықлар һәлак булдылар, қырдылар.

Йәнә ул қырғындин соң урус ханы Қазанны биләрдә – ул вақытда тарих туқуз йөз алтмыш бердә ирде. Қазан вилайәтен кяфер урус алды йәкшәнбә көн, ғәқрәб йолдузының икенче көн ирде[128], сычқан йылында ирде.

Имди Қазан шәһәрендә йорт биләгән ханларның атлары болардур: әүвәл – Ғабдулла хан уғылы Алтунбик, Ғалимбик; андин соң Мәхмүд хан; андин соң Мәмтәк хан; андин соң Хәлил хан; андин соң Ибраһим хан; андин соң Мөхәммәдәмин[129] хан; андин соң Мамуқ хан; андин соң Ғәбделләтыйф хан; андин соң Сахибгәрәй хан; андин соң Сафагәрәй хан; андин [соң]

---

[123] Кулъязмада бу җөмлә ялгыш тагын бер мәртәбә кабатлап язылган.

[124] Һиҗри буенча 700 нче ел милади исәп белән 1300-1301 елларга туры килә. Ләкин тарихчылар бу вакыйганың дөрес түгеллеген язалар.

[125] Кулъязмада: «Хыван».

[126] Кулъязмада «қорул» дип хаталы язылган.

[127] Кулъязмада «ғаммарлық» дип хаталы язылган.

[128] Һиҗри 961 елның 2 гакърәб көне милади 1554 елның 23 октябренә туры килә.

[129] Кулъязмада «Мөхәммәдимин» дип ялгыш язылган.

Ғәли хан; андин соң Үтәш хан; андин соң Йәдегәр хан. Әмма Йәдегәр хан заманында – тарих туқуз йөз илле йитедә көн [то]тулды[130].

Йәнә тарих туқуз йөз илле туқузунчы йыл ирде, сычқан йылы, ғәкрәбнең икенче[131] көне ирде, Қазан шәһәрен урус алды.

Йәнә тарих туқуз йөз йитмеш йитедә ирде, Шығали хан дөнйадин барды[132], барыс йылы ирде.

Андин соң тарих мең дә унда[133] ирде, *// (22а кәгазь)* олу ачлық булды.

Андин соң тарих мең дә унйитедә ирде, кенәз Митрәй йағы[134] булды, тавық йылы ирде.

Андин соң тарих мең дә [йегерме] түртдә[135] ирде, Җанали йағы булды, тавышқан йылы ирде.

Андин соң тарих мең дә илледә[136] ирде, иргә чирү[137] булды, йылан йылы ирде.

Андин соң тарих мең дә илле өчдә[138] ирде, кенәз Михайла хан [булды], қуй йылы ирде.

Андин соң тарих мең дә алтмыш бишдә[139] ирде, үләт булды, йәғни мур булды, йылқы йылы ирде.

Андин соң тарих мең дә йитмеш бердә[140] ирде, башқорт урус берлә йағы булды, барыс йылы ирде.

Андин соң тарих мең дә йитмеш туқузда[141] ирде, Ражин йағы булды, йәғни қазақ йағы булды.

Андин соң тарих мең дә сиксән бишенче[142] йыл, тавышқан йылының ахырында кенәз Фидур Аләксәйавич хан булды.

Андин соң тарих мең дә сиксән туқузда ирде, һавада, йәғни асманда

---

[130] Һижри 957 ел милади 1550 елга туры килә. Н.Катанов бу вакыйганың дөреслектә 1551 елның 31 августында булганлыгын ачыклаган.

[131] Һижри 959 елның 2 гакърәб көне милади 1552 елның 23 октябренә туры килә.

[132] Һижри 977 ел милади 1569-1570 елларга туры килә. Чынлыкта, Шаһгали 1567 елда вафат булган.

[133] Һижри 1010 ел милади 1601 елга туры килә.

[134] Һижри 1017 ел милади 1608-1609 елларга туры килә. «Митрәй» дигәндә Лжедмитрий күздә тотылган.

[135] Һижри 1024 ел милади 1615 елга туры килә.

[136] Һижри 1050 ел милади 1640-1641 елларга туры килә.

[137] Кулъязмада «иркә (иргә) чирүе» дип ялгыш язылган.

[138] Һижри 1053 ел милади 1643-1644 елларга туры килә.

[139] Һижри 1065 ел милади 1655 елга туры килә.

[140] Кулъязмада «алтмыш бердә» дип ялгыш язылган. Һижри 1071 ел милади 1660-1661 елларга туры килә.

[141] Һижри 1079 ел милади 1668-1669 елларга туры килә. Степан Разин җитәкчелегендәге халык күтәрелеше 1667–1671 елларда булган.

[142] Һижри 1085 ел милади 1674-1675 елларга туры килә.

бер йакты өлкән йолдуз пәйда булды, көндин-көн йактулуғы артды. Тәмам қырық көнгәчә торды[143]. Көн инеше тарафындин туғуб, көн чығушы тарафыға китәр ирде. Төрлек төслү йолдуз ирде: күкле-йәшелле, қызыллы ирде, күргән адәмиләр таң-ғәҗайебкә қалыб, «бу нә төрлүк *// (22б кәгазь)* нишандур?» тиб, йығлашур ирделәр. Барча җиһан халқы: олуғ-кечек, кяфер һәм мөэмин бу йолдузны әшкярә күрделәр, бичин йылы ирде.

Андин соң кяфер урус мөлкендә төрлүк фетнәләр вә мохалиф ғауғалар була башлады. Йәғни, кяфер урус тәмам бикләре берлә киңәш итеб, қаравуллар[144] қуйуб, үзенең қул астындағы мөселманларны чуқундурмақ нийәтен қылдылар, күб мөселманларны динендән айыруб, мөртәд қылды. Олуғ фетнәләр башлады, күб йирләрдә оруш-суғушлар һәм булды. Ахыр, Хақ Сөбханәһә вә Тәғалә, үзенең рәхмәте берлә, ул йаман киңәшне қылған кяферләрне үзләрен һәлак қылды, үз араларында фетнә салыб, кяфер урус бере-берсен Мәскәү шәһәрендә қырдылар, үзара мохалиф булдылар. Ул йаман киңәшне қылган Фидур атлы хан ирде, Хақ Тәғалә йәш вақытында һәлак қылды[145].

Андин соң тарих мең дә туқсан бердә ирде, кяфер урусның тәхетендә ике хан ханлықға ултурды, ағалы-энеле ирде, икесе бер дәвердә бер заманда тәхет биләб ултурдылар, эт йылы ирде. Берсенең аты Иван, икенчесенең аты Путра ирде, икесе дә Аләксәй ханның уғланлары ирделәр[146].

Андин соң йәнә тарих мең дә туқсан бердә шул ике[147] [...]

[143] Һиҗри 1089 ел милади 1678 елга туры килә. Чынлыкта, бу вакыйга 1680 елның көзендә башланып, 1681 елның язына кадәр, барлыгы 19 атна дәвам иткән. Мөселманнар андый күренешне Аллаһы Тәгаләнең каһәренә тиңләгәннәр.

[144] Кулъязмада «қуллар» дип ялгыш язылган.

[145] Рус патшасы Фёдор Алексеевич (1661–1682) тәхеттә 1676–1682 елларда утырган. Аның чукынмаган татар морзаларының биләмәләрен алу турындагы фәрманы 1681 елның 16 май көнендә чыгарылган.

[146] Һиҗри 1091 ел милади 1680 елга туры килә. Иван һәм Пётр патшалар тәхеткә 1682 елда утырганнар.

[147] Бу сүз кустодта язылган. Аннан соң текст өзелә, кулъязманың соңгы бите төшкән. Башка күчермәләрдән күренүенчә, монда әсәрнең ахырындагы 5–6 җөмлә җитми.

ӨЧЕНЧЕ ТЕКСТ[1]

[Дастане Чыңгыз]

// (25а кәгазь) [...]

– Әй, халық уғылы! Мәнең ирүм Дуйын-Бәйан сезгә әйтмәдемү, «Мән үлгәндин соң төш-түл булуб килүрмән» димәдемү? Имди килүр вақыт килгәндүр ырысыңыз[2] булса, ир уғул булғай, – диде.

Анда Аланғудин бу сүзне ишетеб, халық уғылы сәвенделәр, шад булдылар. Йәнә андин соң Аланғуның бу сүзе халық арасында мәшһүр булдылар, дөнйәгә қачан килүр тиб, аны көтәр ирделәр.

Анда Аланғуның өч уғылы: Бүдәнҗар, Қағынҗар, Салҗут хәлайықдин ишеттеләр. Ачуланышыб, йыйылышыб бер көн аналарына килделәр. Анда Аланғу әйде:

– Әй, балаларым! Имди қалай барасыз? – тәйүр.

Анда анлар әйделәр:

– Сәнең бер өтрүк сүзүң ишетеб килдүк, – тиделәр.

Анда Аланғу әйде:

– Әй, шомлар! Мәнең сүзем [нә] өчүн өтрүк булсун? – диде.

Улар әйделәр:

– Әмма ана, өтрүк булмай, нә булсун? «Қорсағымда бер бала бар» тиб халық уғылуна әйтебсән. Безне уғулға санамай, қорсақдағыны көттүрүрсән. Өтрүк булмай нәдүр? – диделәр.

Сақалунму[3] сән, су эчеб буаз булмаға?
Мани дигән қошму сән, көн эссесенә буаз булмаға?
Қавын-қарбузму сән, ирсез орлық йыймаға?
Тавуқму сән, көлгә аунаб йомуртқа салмаға,
Қыр анасыму сән, күбүк ашаб буаз булмаға?

– Ирең үлгәндүр, «қорсағымда бала бардур» тиб, халықны аздурурсән? – тиделәр. – Иллә сән төнәге көн бер бо- *// (25б кәгазь)* -тқа сатыб алған Банын берлә уйнаш итеб буаз булғансән! – тиделәр.

Анда Аланғу әйде:

---

[1] Р.Мәрдановның шәхси архивында саклана торган кульязмадан алынды. Кульязмада текстның башы юк.
[2] Кульязмада «ырсаңыз» дип хаталы язылган.
[3] Кульязмада: сафалунму.

– Аһ, халык! Бу сүз бу шомларның сүземедүр, йә сезнеңмедүр? – диде.

Анда халық уғылы чулашыб, гөрүлдәшеб әйделәр:

– Бу сүз – бу уғлан[ла]рның сүзедүр, – диделәр.

Анда Аланғу әйде:

– Аһ, әй, халық! Имди ышанмасаңыз, сүзүм улдур – бер ике-өч кеше изыңыз[4], билгүсе улдур кем: көн булуб инәр, бүре булуб чықар, – диде.

Андин соң Аланғуға белдүрмәде, өч кеше изыды[5]. Өч кешенең атлары болардур: берсе – Қыбчақ дигән ирде, икенчесе – Килмөхәммәд дигән ирде, өчүнчесе – Урдач дигән ирде. Бу өч кеше андыдылар. Таң мәмке булған ирде, һавадин бер йаруқын көн инде, күрделәр ирсә, исләре китде. Болар йәнә бер анчадин соң исләрен йыйыб алдылар ирсә, бере-берендин сордылар:

– Байағы көн булуб ингән [нә] ирде? – диделәр. – Килеңез, безләр исергән тик булуб ултурғанча, йаларымызны тартыб чигәлең, бүре булса, чықар, – тиделәр. Андин тора салыб йаларын[6] тартыб чикделәр, күрделәр кем – йылқы йаллы күк бүре чықа килде. Артына қараб «Чыңыз!» тиб өн бирде[7], барыб урман эченә инде. Моны бу өч кеше әшкярә күрделәр, белделәр. Болар йәнә барыб бу эшне Бүдәнҗар, Қа[ғ]ынҗар, Салҗутқа әйделәр.

«Буласы булур, қа- *// (26а кәгазь)* -лмас булмай, безнең өлүшемезне алмас» – диделәр.

Андин соң Аланғу күзе йаруды[8] – ир уғулан туғды, алтун изарлық, йағрынында мөһер, мөһерендә Җәбраил фәрештәнең аты бар торур ирде. Үзе бүре йағрылы, ир чырайлы, күрекле сынлы, йөзен күргән кеше артындин «үләйен» дир ирде, қашында ултурғанлар май[9] дик эрүр ирде. Вә тәқи «атым, тунум сәнең булсун!» дир ирде.

Андин соң Чыңыз үсде, олығайды, халықға ғәделдад қыйлыб, файдалығ булды. Халық уғылы моны сәвеб-үгүб, Чыңызға ийәрә башладылар. Чыңызны «Ғәйәт йахшы хан! – тиб, – ханның җенесе-баласы», – тиб мақтадылар.

Ағалары Бүдәнҗар, Қағынҗар, Салҗут бу Чыңызны күрә алмас булдылар, көнләделәр. Тәқи әйделәр:

---

4 Кулъязмада «андыңыз» дип ялгыш язылган.

5 Кулъязмада «андыды» дип ялгыш язылган.

6 Кулъязмада «аларын» дип ялгыш язылган.

7 Кулъязмада «бирделәр» дип ялгыш язылган.

8 Кулъязмада «йаруы» дип хаталы язылган.

9 Кулъязмада «майыр» дип хаталы язылган.

– Күрүңләр имди, нөгәрләремез, халқымыз уйнашдан туған уғулға авар булды, – диделәр. – Аны үлтүрәйек[10], йуқ ирсә тынмасбыз, – диделәр.

Андин соң йәнә бу өч уғыл киңәш итеб, бер көн йыйылыб килделәр, халыққа йар салдылар:

– Чыңызны үлтүрәбез! – диделәр.

Анда халық уғылы әйделәр:

– Һай, Чыңыз сез өчәүдин йортқа лайықрақ охшайдур, халыққа файдалығдур. Бу Чыңызны сезгә үлтүрүргә бирмәсбез! – тиделәр. – Әгәр мал улса, өләшеб мал алур булсаңыз, атаңызның малын өләшеб алыңыз! – тиделәр. – Йуқ ирсә, аның өчүн без үләбез, – тиделәр. *// (26б кәгазь)* Анда бу өчәү халық уғылундин бу сүзне ишеткәндин соң қуркуб, нәрсә [қыла] алмадылар. (Әмма күңелләрендә әйделәр: «Халық уғылы бу Чыңызга авыбдур, моны билгеле үлтүрүб булмас. Билгүсез – халықға белдүрмәй үлтүрүрбез», – тиделәр).

– Хуш, андағ булсаңыз, атамызның қалған малын өләшеб алурмыз, – тиб, аталарының һәр нә қалған малын өләшеб алдылар. Әмма Дуйын-Бәйанның бер алтунлы-гәүһәрле садақы бар ирде, бәһасен табмадылар[11], өләшмәй қуйдылар. «Имди анамыз кемгә ханлық[12] бойурса – бу садақны ул алсун!» – диделәр. Өлешенә тигән малларын алғандин соң, садақны алыб, анасы қатыға килделәр. Тәқи:

– Әй, анамыз! Сез кемгә йарлықаб ханлық бирсәңез, бу алтынлы садақны ул уғулың алсун! – тиделәр.

Анда Аланғу әйде:

– Аһ, әй, балаларым!

Үз йортын йаманлаған – үнгә йортта сүгүш булур,
Үз анасын йаманлаған – йат дошманға тотғун булур,
Үз кешесен йаманлаған – йат дошманға хур булур.

– Сез шомлар мәнең сүзүм тотармусыз? – тиде.

Ул өчәү әйделәр:

– Бәли, хуш тотарбыз, – тиделәр.

– Имди сезләр сүз тотар булсаңыз, тәрәзәдән төшкән көнгә футаллы футаңызны[13] салыңыз. Қайыңызның бутасы аңар йеленеб туқтаса, ул уғылум хан булсун! Тәқи бу алтунлы-гәү- *// (27а кәгазь)* -һәрле садақны һәм ул уғылым алсун! – тиде ирсә, Аланғуның бу сүзене анлар хуш күрделәр. Билләрендән алтунлы футаларын салыб бақтылар. Өчәвесенең

---

[10] Кулъязмада «үлтүрәйке» дип хаталы язылган.
[11] Кулъязмада «таймадылар» дип ялгыш язылган.
[12] Кулъязмада «халқын» рәвешендәрәк, хаталы язылган.
[13] Кулъязмада «футалыңызны» дип хаталы язылган.

һәм футасы йеленмәде. Мәгәр Чыңызның йебәк футасы бар ирде, ул һәм салды, аның футасы эленеб туқтады. Анлар бу эшне күрүб таңға қалдылар. Ачуларындин әйделәр:

– Бу анамыз Аланғу ғайәт җаду ирмеш, күземезне бағлады, – тиделәр. Күңелләренә йаман алыб китделәр. Әмма һәрдаим Чыңызны үлтүрмәк қасдында[14] йөрүр ирделәр.

Андин соң йәш уғыл Чыңыз «бу ағаларым мәнгә дошман булдылар, мәне алдаб үлтүрүрләр» тиб, башындин қурқуб, қазақ чықыб китәйен тиб киңәш итеб, бер ике-өч йегет үзенә ийәртеб, анасы Аланғуға килде. Әйде:

– Анам! Мән имди бу йирдә[н], бу йортдан китәрмән. Ошбу Тикәлек суынуң башында Күрлән дигән қара тау бардыр. Ул тағда мәқам-йорт тотармән, қош-қорт [ауларман. Ул][15] аулаб алған қош җонын җолқармән, аны суға йибәрүрмән. Безнең тереклегемезне ул қош җонындин белгәйсез. Айу ақуртурмән, арслан йөгүртүрмән – һәркем мәне эзләй-сорай барур булса, мондин белсүнләр, – тиде. Үзләре китделәр, анасы ағлай[16] қалды.

// (27б кәгазь) Иртәгесен халық уғылы күренешкә килделәр ирсә, Чыңызны күрмәделәр, тәқи сордылар:

– Чыңыз ханымыз қайда? – диделәр. Истәб табмадылар, ачуланышыб, чымырғаныб йылашдылар. Андин соң килеб Аланғудин сордылар, ул һәм әйтмәделәр.

Чыңыз хан қазақ чықыб киткәндин соң, ағалары Бүдәнҗар, Қағынҗар, Салҗут халық уғылына золым-көч итделәр. Халық уғылы чыдамайын, Аланғуға килеб әйделәр:

– Аһ, Аланғу! Ул угылуң Чыңызны безгә күргүзгүнчә, күргүзмәй җанымызны алсаң ирде. Имди нә өчүн күргүзеб җанымызны алдың? – тиделәр. Йәнә чулашыб, йығлашдылар[17].

Анда Аланғу әйде:

– Аһ, әй, халық! Андағ булсаңыз, уғылум Чыңызны сөйсәңез, иртә берлә биш-алты руның йахшы-лайық кешеләр килеңез, анларға[18] йулын-эзен күрсәтәйен, – тиде.

Андин соң, иртә берлә алты руның лайық кешеләре килделәр, сордылар:

– Йулы қайдадур? – тиделәр.

Анда Аланғу әйде:

---

[14] Кулъязмада «үлнүрмәк вақытында» дип хаталы язылган.

[15] Квадрат җәяләр эчендәге әлеге ике сүз кулъязмада төшеп калган. Монда «Икенче текст»тан алынды.

[16] Кулъязмада «айларый» дип хаталы язылган.

[17] Кулъязмада «йығлашыб» дип ялгыш язылган.

[18] Кулъязмада «айларға» дип ялгыш язылган.

– Хуш, имди барыб шул Тикәлек суыға бақыб торуңыз, хәбәре[19] килүр! – тиде.

Болар су йақасына барыб, бақыб тордылар – һичнәрсә күрмәделәр. Мәгәр бер қәүм қош җоны[20] күрделәр. Йәнә қайтыб килделәр. Анда Аланғу сордылар:

– Нә курдүңез? – тиде.

Анлар әйделәр:

// (28а кәгазь) – Йуқ, нәрсә күрмәдүк. Мәгәр бер қәүм қош җоны күрдүк, – тиделәр.

Анда Аланғу әйде:

– Һай, кил имди, мәнең уғылум Чыңызның хәбәре ушал сез күргән қош җоныдур, – тиде. – Сезләр ошбу Тикәлек суыны қыдырыб эзләңез, Тикәлек суының башында Күрлән дигән қара тауның башында биш-алты ағач булур. «Ушал йирдә мәқам тотармән, қош аулармән, җонын йолкуб суға ташлармән», тигән ирде. Имди ушал җонны эзләб барыңыз! – тиде. – Әмма Тикәлек суының иске-қарый[21] йоласы улдур кем, көндез ташыб, қабағындин ашар, кичесе хисабына[22] төшәр, – тиде. Анда йәнә Аланғу анларға әйде:

– Имди сезләр ул йиргә барыб йитеб һәр нә йулуқсаңыз, күрсәңез, «Сезләр монда нә кешесезләр?» тиб сорғанда «Дуйын, Дуйын» дигәйсез! Әмма мәнең уғылум Чыңыз төсе-нишаны улдур кем:

Ақ тунлы, күк атлы, алтун бүрүкле,
Йөзе ғәйәт [күрүкле][23];
Алтын садақлы, ир чырайлы,
Җәбраил дик сынлы торур,
Атын қамчыласа, ғәиб булған дикдүр[24]

– андин аны белгәйсез, – тиде.

Әмма Чыңыз ханны истәй барған бикләрнең атлары болардур: Уйшын Майқы би, икенчесе – Қалдар би, өчүнчесе – Урдаж *// (28б кәгазь)* би, түртенчесе – Қыпчақ[25] би, бишенчесе – Тамйан би, алтынчысы – Кирәйәт[26] би, йитенчесе – Йөрүтә би, сикезенчесе – Тимер Қотлу би, туқузунчысы

---

[19] Кулъязмада «хәйре» дип ялгыш язылган.
[20] Кулъязмада «чоны» дип хаталы язылган.
[21] Кулъязмада хаталы язылган.
[22] Кулъязмада «ишәр, кичесе дәрбәнсенә» дип хаталы язылган.
[23] Кулъязмада «ғәйтеб» дип ялгыш язылган. «Күрүкле» сүзе «Икенче текст»тан алынды.
[24] Кулъязмада «диңдүр» дип хаталы язылган.
[25] Кулъязмада «Қыймау» дип ялгыш язылган.
[26] Кулъязмада: Кирәйән.

– Муйтан би, унунчысы – Таңғут ирде. Бу ун бик киңәш қыйлыб, Чыңыз ханны сәвеб, аны истәмәк қасдында[27] булдылар. Әмма түрт бик буны истәмәгә өнәмәделәр, «Қулдағы ханымызны хурлаб, алысдан истәмәсмез», – тиделәр. Анларның берсе – Коңрат[28] би, икенчесе – Қатай би, өчүнчесе – Салҗуд би, түртенчесе – Қыйат ирде. Әмма бу Қатай, Салҗуд, Қыйат – өчәгүсе халық уғылын[29] биләр ирделәр. Қоңрат би анларның ышанычлы киңәшчесе ирде. Қоңрат би Чыңыз ханны истәмәклеккә бармады.

Бу әйтелгән ун кеше ул Қоңратқа[30] бақмадылар, китделәр. Әмма Уйшын Майқы би үзгә бикләргә белдүрмәде, Аланғудин бер мөһерле йөзүген алды. Андин Тикәлек суын қыдырыб китделәр, өч айда барыб йитделәр. Бер йүчә[31] қыйа тағға менеб қарадылар, артларында бер ақ сарай, бер күк сарай күрделәр. Йәнә қайтыб, бер азина килделәр, ул сарайларға инмәделәр. Анда бер тау бар ирде, ул тауның қабағында йаттылар. Бер азина тордылар, һич нәрсә-нишан белмәделәр. Мәгәр бер азинадин соң бер аваз килде қарға чарлаған дик, кеше сүзләгән тик. Қараб-йөреб бақтылар, бераз кеше килебдүр йулының буй[ы] // *(29а кәгазь)* чықа йатур. Шул тағның қабағындан бире килмәгән охшайдур тиделәр. Әмма болар һич аваз бирмәделәр. Йәнә авазлары тынды[32], ул көн һич нәрсә белмәделәр.

Иртәгесен айу ақырды, арслан қычқурды, белделәр кем – «Чыңыз хан ау аулай чықты», – тиделәр. Болар ул[33] авазны ишеткәч йөгүрүшүб бардылар, күрделәр кем: бер күк[34] атлы, ақ тунлы, алтун бүрүкле, алтун садақлы, ир чырайлы, Җәбраил дик күрүкле, сынлы-йусынлы Чыңызны таныдылар вә белделәр. Ул килгән Чыңыз әйде кем:

– Сезләрне безләр танумайбыз. Нимә андин йөрүрсез, нә кешеләр сез? – тиделәр.

Болар әйделәр:

– Дуйын, Дуйын!

Болардин ул сүзне ишеткәндин соң күзләрендин ғәиб булды. Болар йәнә йығлашыб қайтдылар. Ул кич қайғурушуб йатдылар. Андин йәнә иртә булды ирсә, оранлары берлә чарладылар: «Ақ-ту-ған, ту-ты-йақ, ту-тый-лақ, уқ-тый-лақ!» – тәйү чақурдылар, һич нәрсә аваз килмәде.

Андин соң йәнә ике-өч көн йаттылар. Йәнә бер көн айу ақурды,

---

[27] Кулъязмада «қастында» дип хаталы язылган.
[28] Кулъязмада: Қоңрақ.
[29] Кулъязмада «уғлан» дип ялгыш язылган.
[30] Бу сүздән соң кулъязмада ялгыш «би Чыңыз ханны истә» сүзләре язылган.
[31] Кулъязмада «өчҗә» дип хаталы язылган.
[32] Кулъязмада «тытды» дип хаталы язылган.
[33] Кулъязмада «улы» дип ялгыш язылган.
[34] Кулъязмада «күкә» дип хаталы язылган.

арслан қычқурды – белделәр кем, «Чыңыздур, ау аулаб чықты!» – тиб, сәвенешделәр. Йәнә барыб күрделәр – ушал кешенең үзедүр!

Андин боларға Чыңыз хан әйде:

– Һай, сезләр кем? Һәрдаим безне андыб йөрүрсез? – тиде.

Болар әйделәр:

– Дуйын, Дуйын! – тиб, йәнә чулашыб тордылар.

Болар болай йығлаганға Чыңыз хан үзе һәм *// (29б кәгазь)* йығлады. Йәнә әйде:

– Һа, сез нә өчүн монда килдеңез? – тиб сорды.

Болар әйделәр:

– Сәнең артыңдан үлә-йитә йөрүр[мез], – диделәр.

Анда ул Чыңыз хан әйде:

– Һа, сезне монда килүргә кем үгрәтте? – тиде.

Болар әйделәр:

– Безләргә, рәхим қыйлыб, сойурғаб[35] анаңыз Аланғу үгрәтде, – диделәр.

Анда Чыңыз хан әйде:

– Хуш, имди андағ булса, қани мәнгә анамның бер билгүсе барму? – тиде ирсә, үзгә бикләр тик тордылар, әмма Уйшын Майқы би қулундан Аланғудан алған мөһерле йөзүкне чықарыб бирде.

Анда[36] Чыңыз хан йөзүкне алыб бақты ирсә, Аланғуның мөһерле йөзүгене таныды, тәқи көлүб әйде:

– Әй, Майқы би! Әгәр мән хан булсам, биклек сәнгә булсун! – тиде. – Әгәр сән бу мөһерле йөзүкне алыб килмәсәң, мәнгә анамның бер нишанын килтүрмәсәң, сезгә йуқ ирдем, тәқи сез мәнгә иш-йулдаш булмас ирдеңез! – тиде. – Әмма бу сүздин үзгә бикләрем сезләр һәм күңлүңезгә йаман алмаңыз, сезләр барчаңыз мәнем җанымсыз! – диде. – Килеңез, имди қуышқа қайталық[37], анда барыб ултуралық, – тиде.

Сарайға бардылар, бер азина анда йатыб, аш йиделәр, төрлү шәрабләр эчтеләр, сүнмәс чырағы, төкәнмәс аш йиделәр.

Андин соң йәнә Чыңыз хан әйде:

– Килеңез, имди киңәш итеб ултуралы! Сезләр кем, безне эстәб[38] килебсезләр, ничә ру халық берлә берсез? – тиделәр.

Болар *// (30а кәгазь)* айақға үрә торуб үтүнделәр, тәқи әйделәр:

– Әй, олуғымыз, ханымыз! Безләрдин кем сорсаңыз, безләр монда

---

[35] Кулъязмада «дилүйуға би» дип хаталы язылган.

[36] Кулъязмада бу сүздән соң ялгыш «бер» дип язылган.

[37] Кулъязмада «қайалық» дип хаталы язылган.

[38] Кулъязмада «әйтеб» дип ялгыш язылган.

сезне истәй килгән ун кешемез, туқуз рудан, – тиделәр. – Әмма Қалдар би йалғуз үзедүр. Анаңыз Аланғу безгә қушуб иде, – тиделәр. – Әмма Қоңрат[39] сезне истәй килмәккә өнә[мә]де, ул үзе, тәқи руы ағаларның қашындадур, – тиделәр. Без сезнең мөбарәк йөзүңезне арзулаб артуңыздан үлә-йитә килдүк, сезгә қушулдуқ һәм үземез, һәм барча ру халқымыз берлә сәнең қолуңмыз! – тиделәр.

Анда Чыңыз хан анлардин бу сүзне ишетте ирсә, сәвенүб әйде:

– Әй, бикләрем, олуғларым! Имди бу көндин соң сезнеңмән!

Чыңыз хандин бу сүзне ишетеб ғәйәт сәвенделәр, тәқи:

– Имди сәне безләргә Тәңре бирде, аның шөкерлег[е] өчүн бу менеб килгән атларымызны азад йибәрәле, – тиделәр. Менеб барған атларын Чыңыз ханны булғанлары өчүн азад идделәр.

Андин соң Чыңыз хан бонларга әйде:

– Һай, мәне нә берлә илтәрсәз? – тиде.

Анлар нә[40] берлә алыб барасын белмәделәр. Әмма Қалдар би әйде:

– Мән бер һөнәр чықарайын, – тиде.

Бонлар әйделәр:

– Күрсәт! – тиделәр.

Һичкем ирсә белмәс ирде, үз осталықындин бер арба йасады. (Имди арба пирен сорсалар, Балын би уғылы Қалдар би тимәк кирәк).

Анда йәнә арбаны төзүб тәмам қыйлғандин *// (30б кәгазь)* соң Чыңыз ханны арбаға ултурурға үтүнделәр. Чыңыз хан килеб арбаны қарадылар, «Хуш қыйлыбсән!» тиде, Қалдар бине мақтады.

Андин соң Чыңыз ханны арбаға ултур[т]дылар. Бу барған бикләр үзләре арбаны сүрәделәр-тарттылар[41]. Анда Уйшын Майқы би әйде:

– Әй, бикләр! Мән сезнең шайыңыз бара алмамдур, айақым қысқадур, – тиде.

Анда бикләр әйделәр:

– Имди нитәк қылурсән?

Анда Майқы би әйде:

– Мән хандин үтүнәйен, рөхсәт булса, хан берлә арбаға ултурайын, қайсыңыз арбаны тартмаса, мән аны тайақ берлә күтегә төртәйен, – тиде.

Анда болар әйде:

– Хуш, алай ит! – тиделәр.

Андин соң Майқы би Чыңыз хандин үтүнде, тәқи әйде:

---

[39] Кулъязмада: Қоңрақ.

[40] Кулъязмада «йәнә» дип ялгыш язылган.

[41] Кулъязмада «тартар» дип хаталы язылган.

– Ханым! Мәнем айақым қысқадур, арбаны тарта алмамдур. Сән бойурсаң, мән сәнең берлә арбаға ултурурмән? – тиде.

Анда хан әйде:

– Хуш, ултур! – диде.

Андин бу бикләр бер анча көнләрдин килә-килә, Чыңыз ханны алыб, Аланғуның шәһәренә йиттеләр. Аланғуға хәбәр қыйлыб, сарайға инделәр. Әмма анд[а] Чыңыз ханның артындан қайсысы инәрен белмәделәр. Анда Майқы би әйде:

– Әй, ханым! Сездән соң арба тартқан үгүз инәрмү, йә аны йиккән ийәсе инәрмү? – тиде ирсә, анда хан әйде:

– Ийәсе инмәй, үгүз инәрмү? – тиде ирсә, Майқы би рәван йөгерүб керде[42] [...]

// (31а кәгазь) ... – тиде.

Анда Чыңыз хан әйде:

– Ничөн мәне айадыңыз? – дир ирсә, Бөртә Қучын әйде:

– Әй, ханым! Сәнең җаныңға көч булур, – тидем.

Анда хан:

– Мәнең җанымға ничөн көч булур? – тиде.

Бөртә Қучын әйде:

– Әй, ханым! Аның өчүн кем, Нух пәйғамбәр ғәләйһиссәлам заманында Ходай Тәбарәкә вә Тәғалә[43] кяферләргә қәһер қыйлыб, туфан суын йибәрде, кяферләрне туфан суыға батурды, йуқ қыйлды. Тәқи ул туфанда һәр җанлықның – иркәк, тәқи тешилек нәселе-тохымы киселмәсен тиб, Нух пәйғамбәр ғәләйһиссәламнең кимәсендә қотқарды, азад қыйлды. Сез хан булсаң да, Тәңре Тәғаләнең[44] қолы дәгүлмүсән? Арслан кийек иркәч аша сикереб, артындағын қайтыб алмас, азад қыйлыр, йибәрер. Әй, ханым, сән адәмсән! Мәне, тәқи бу уғланларны азад қыйлғайсән? Ул ачиғылығы йаман қырғында[45] халық уғылы боларның қөдсен белмәсләр, үлтүрүрләр, боларның тохымы-нәселе, руы кисел[м]әсен тиб алыб қалдым, – тиде.

Анда Чыңыз хан әйде:

– Имди сәнең шул йахшы дәлилле сүзең өчүн, тәқи сәнең диңез [тик] күңлүң өчүн йөз мең үлүмдин азад булсун! – тиде.

Кил имди, әй, Бөртә Қучын!
Мәнем қаты күңлүмне қалдырмағын,
Үзеңне мәндин айырмағыл! – тиде.

---

[42] Бу сүз кустодта язылган. Аннан соң текстка өзеклек кергән, кулъязманың бер кәгазе төшкән.

[43] Кулъязмада: Тәғәһә.

[44] Кулъязмада: Тәғәһәнең.

[45] Кулъязмада: қырағында.

Анда Бөртә Қучын әйде:

– Хуш, сез мәне сәүсәңез, мән – сезнеңмән! – тиде.

Андин соң Чыңыз ханның күңеле эреде, икеләсе бер-беренә қабул булуб, хәләл җефет булдылар, хәлайыққа олу туй қылдылар, бу дөнйаны уздурдылар.

Йәнә йәшерүн қалмасун кем, Чыңыз ханну- *// (31б кәгазь)* -ң Бөртә Қучындан [түрт] уғылы булды: олу уғылы – Йүчи хан, икенчесе – Җәдай хан, өчүнчесе – Гәрәй хан, түртүнчесе – Туни хан дигән ирде.

Йәнә андин соң Чыңыз хан йахшы қылықы берлә, ғаделдад қылмақ берлә иде. Нәселе, ләшкәре берлә йөрүб, орышуб күб ханларны[46], урдаларны үзегә бақтурған ирде. Тәқи аның аты-чабы дөнйәгә тулған ирде. Андин соң Чыңыз хан үзене истәй барған бикләргә [һәр]берсенә урун-мәқам тәғәйен билгелү қыйлыб, ил-көн бирде. Андин соң Чыңыз хан ошбу бикләрнең барчасына үзлү үзегә тамға, қош, ағачын, оранлар биреб, бау-бау халық қыйлыб айырды. Әүвәл башлаб Будәнҗар уғылы Қыйатға[47] әйде:

– Сәнең аға[чы]ң қарағай булсун, қошуң шонқар булсун, ораның «аруҗан» булсун, тамғаң «ичамай» булсун, [йәғни] «әвернә тамға» булсун! – тиде. Сыйфаты ошбудур:

Йәнә андин соң Чыңыз хан әйде, Қоңрат[48] би уғылы Сәңләгә әйде:

– Әй, сәнең ағачың алма ағач булсун, қош[ың] лачын булсун, ораның «қоңрат» булсун, тамғаң «ай тамға» булсун! – тиде. Сыйфаты ошбудур:

Андин соң Чыңыз хан әйде:

– Әй, Уйшын Майқы би! Сәнең ағачың қарағач булсун, қошың қарақош булсун, ораның «салават» булсун, тамғаң «сергә» булсун! – тиде. Сыйфаты ошбудур:

Андин соң Чыңыз хан *// (32а кәгазь)* Урдач бигә әйде:

– Әй, Мең садақлы Урдач! («Мең» тимәклек андин қалды – ул Урдач би ғайәт дә бай кеше ирде, орушыға чықар булса мең садақлы кеше берлә чықар ирде). Чыңыз хан Урдачқа әйде:

– Сәнең ағачың қайын булсун, қошуң қарчыға булсун, ораның «алач», тамғаң «қош қабырғасы»[49] булсун! – тиде. Сыйфаты ошбудур:

Андин соң йәнә хан әйде:

– Әй, Тамйан би! Сәнең ағачың тирәк булсун, қошуң қырғы булсун,

---

[46] Кулъязмада «җанларны» дип ялгыш язылган.

[47] Кулъязмада «Қыйайға» дип ялгыш язылган.

[48] Кулъязмада «Қоңрана» дип хаталы язылган.

[49] Кулъязмада: қарға.

оранын «тутыйа» булсун, тамғаң «ырғак» булсун! – тиде. Сыйфаты ошбудур:

Андин соң йәнә хан әйде:

– Әй, Қыбчак би! Сәнең ағачың карама булсун, қошуң бөркет булсун, ораның «туқсаба» булсун, тамғаң «тарак» булсун! – тиде. Сыйфаты ошбудур:

Андин соң йәнә хан әйде:

– Әй, Җурматы би! Сәнең ағачың өйәнке булсун, қошуң итәлғу булсун, ораның «ақтыйлақ» булсун, тамғаң «сынлы сәнәк» булсун! – тиде. Сыйфаты ошбудур:

Андин соң хан әйде:

– Әй, Кирәйәт би! Сәнең ағачың җүкә булсун, қошуң қаз булсун, – тиде. – Ораның «арбу» улсун, тамғаң «күз тамға» булсун! – тиде. Сыйфаты ошбудур:

Андин соң йәнә хан әйде:

– Әй, Муйтан би! Сәнең ағачың миләш булсун, қошуң торна булсун, ораның «байғљнгәр» булсун, тамғаң «қуйушқан» булсун! – тиде. Сыйфаты ошбудур:

Андин соң йәнә Чыңыз хан әйде:

– Әй, Бөрҗан // *(32б кәгазь)* би! Сәнең ағачың имән булсун, қошуң көчүгән булсун, ораның «ақтуған» булсун, тамғаң «чағалбай» булсун! – тиде. Сыйфаты ошбудур:

Андин соң йәнә Чыңыз хан әйде:

– Җорқата би! Сәнең ағачың чаған булсун, қошуң һөдһөд булсун, ораның «борух» булсун, тамғаң «әмзә» булсун! – тиде. Сыйфаты ошбудур:

Андин соң йәнә хан әйде Қағынҗар уғылы Қатайға:

– Сәнең ағачың артыш булсун, қошуң қавыд булсун, ораның «тыйлақ» булсун, тамғаң «сәрвә» булсун! Сыйфаты ошбудур:

Андин соң йәнә хан әйде:

– Қалдар би! Сәнең ағачың сандал булсун, қошуң күгәрчен булсун, ораның «арнау» булсун, тамғаң «чүмеч» булсун! – тиде. Сыйфаты ошбудур:

Андин соң йәнә хан әйде:

– Әй, Салҗуд! Сәнең ағачың көйрүч булсун, қошуң көйүлдү булсун, ораның «барлас» булсун, тамғаң «өй тамға» булсун! – тиде. Сыйфаты ошбудур:

Андин соң йәнә хан әйде:

– Әй, Тимер Қотлы би! Сәнең ағачың җирек булсун, қошың сайысқан



Өченче текст кулъязмасы

булсун, ораның «табан» булсун, тамғаң «йарым тарақ» булсун! – тиде. Сыйфаты ошбудур: ع

Йәнә Чыңыз ханның үзенең ораны «җан қаба»[50] ирде.

Чыңыз хан ошбу әйткән бикләренең һәрберсен ләшкәр башы қыйлыб, урдалар алғалый[51] йибәрүр ирде[52]. Ул олуғ-ағыр чирү- // *(33а кәгазь)* -ләрдә халық уғылы [бер-]берсен оранлы ораны берлә [та]бар ирделәр. Имди барча оранларның атлары болардур: әүвәл хан ораны – «җа[н қа]ба». Андин соң барча биләрнең оранлары болардур: «а[р]уҗан», «коңрат», «салават»[53],

[50] Кулъязмада: «җан қабан».

[51] Кулъязмада «алғаный» дип хаталы язылган.

[52] Кулъязмада бу сүз алдында ялгыш «йөрүр» дип язылган.

[53] Кулъязмада: салаван.

«алач», «тутыйа»[54], «туқсаба», «ақтыйлақ», «ау бүрү», «байғълнгәр», «ақтуған», «борух», «тыйла[қ]», «арнау», «барлас», «табан».

Йәнә мәғлүм ула кем, Чыңыз хан һәрдаим кийек аулар чыҡа булса, ошбу әйтелгән биләр қошлары берлә, қошларын алыб чықар ирделәр. Имди ул қошларның атларын барчасын җәмиғ қыйлыб [әйтәйен]. Әүвәл Чыңыз ханның үз қошы ике баш қарақаш ирде. Үзгә бикләрнең қошлары болардур: шонқар, лачын, қарағуш, қарчыға, қырғы, бөркет, итәлғу, қаз, торна, көчүгән, һөдһөд, кувыд, күгәрчен, көйүлдү, сайысқан.

Йәнә мәғлүм ула кем, Чыңыз ханның үзенең ағачы чинар ирде, үзгә бикләренең һәм ағачларының барчасын җәмиғ қыйлыб әйтәйен: қарағай, алмағач, қарағач, қайын, тирәк, қарама, өйәнке, җүкә, миләш, имән, чаған, артыш, сандал, көрүч, җирек[55].

Йәнә мәғлүм ула кем, Чыңыз ханның үзенең тамғасы «қошбаш» дигән тамға ирде, сыйфаты ошбудур:

Үзгә бикләр[нең] һәм барча тамғаларын җәмиғ қыйлыб әйтәйен: *[уңнан сулга таба тәртиптә]* 

Йәнә мәғлүм ула кем, Чыңыз хан дигән[56] бикләрнең һәрберсенә орушқа лайық һәйбәтлек булмақ // *(33б кәгазь)* өчүн берәр савытны атаб бирде. Әүвәл Чыңыз ханның үзенең савыты «буйан» дигән савыт[57] ирде. Олу уғылы Йүч[и]нең «каратау» дигән савыт ирде[58], икенче уғылы Җәдайның «алтун сандуқ» дигән савыт[59] ирде, өчүнче уғылы Кирәйнең «бөктәр» дигән савыт ирде[60]. Қоңратқа «айқултық» дигән савытны бирде, Майқыға «сәғбәр» дигән савытны бирде. Урдачқа[61] «чәчәкүз» дигән савытны бирде, Тамйанға «көйләксә» дигән савытны бирде, Қыбчаққа[62] «күклық» дигән савытны бирде, Җурматыға «ун қарыш» дигән савытны бирде, Кирәйәткә «өйелмә» дигән савытны бирде, Муйтанға «қабақ» дигән савытны бирде, Бөрҗангә «қомқач» дигән савытны бирде, Борқытға «көрләү» дигән савытны бирде, Қатайға «боз қалбақ» дигән савытны бирде, Қалдарға

[54] Кулъязмада: тутыйла.
[55] Кулъязмада «чирек» дип хаталы язылган.
[56] «Дигән» сүзе бу урында «әйтелгән» мәгънәсендә.
[57] Кулъязмада «бубан дигән савытны» дип ялгыш язылган.
[58] Кулъязмада «савытыны орды» дип ялгыш язылган.
[59] Монда һәм моннан соңгы җөмләдә «савытны» дип ялгыш язылган.
[60] Кулъязмада «бирде» дип ялгыш язылган. Шуннан соң текстка өзеклек кергән. Әсәрнең элеге урынында «Икенче текст»та болай язылган: «түртүнче уғылы Тулиның «ут йөрәк» дигән савыт ирде. Андин соң Чыңыз бикләренә һәм савыт бирде: Қыйатқа «қала» дигән савытны бирде».
[61] Кулъязмада: Урадачқа.
[62] Кулъязмада «Қыбчатқа» дип ялгыш язылган.

«чоқа турғай» дигән савытны бирде, Салжутқа «қобурчақ»[63] дигән савытны бирде, Тимер Қотлыға[64] «бозаубаш» дигән савытны бирде. Имди ошбу савытларның барчасының атларын җәмиғ қыйлыб әйтәйен: «буйан», «алтун сандуқ», «бөктәр», «ут йөрәк», «қалдай», «қултуқ», «сәфбәр», «чәчәкүз», «көйләксә», «күк йақа», «ун қарыш», «өйелмә», «қаты қабақ», «қомкач», «көрләч», «боз калбақ», «чоқа турғай», «қорчақ», «бозаубаш», «керәүкә».

Андин Чыңыз хан бу бикләрне тәмамысын күз өстендә қашы тик күрүр ирде, ғыйш-ғөшрәт қыйлур ирде. Бу дөнйасына қуаныб, батшаһлығына мәғрүр-мәшғүл ирде. Һәрдаим тамаша[65] тәнәғғем қылур ирде.

Андин // *(34а кәгазь)* соң йәнә Чыңыз хан көнләрдә бер көн уғланлары, бикләре берлә ау аулай чықыб, йаланда йөрүр ирделәр, йулбарус дигән кийекне күрделәр. Бикләр һәрберсе уқын йаға кизләб йаруштуруб қордылар, қыйаларны ашурдылар. Һичберсе йитә[66] алмадылар. Ахры бар, өч кеше қуыб йитделәр, йулбарысны атыб йықдылар. Берсе Коңрат батырның уғылы Сиңлә, икенчесе Мең садақлы Урадаж, өчүнчесе Тамйан – бу өч кеше йулбарысны үлтүрүб, Чыңыз ханға кәлтүрделәр. Хан боларның бу ирлекләрен күрүб таңға қалыб, һәрберсенә мең тәнк[ә] алапа бирде. Һәр йирдә мәҗлесдә боларның ирлекләрен сөйләр ирде.

Йәнә көнләрдә бер көн Чыңыз хан ауға бикләре берлә чықыб йөрүр ирде. Йаланда бер болан[67]-кийекне күрделәр. Бөрҗан бинең бер йөгүрәк аты бар ирде. Йөгерүклеге андағ ирде кем, боланны йитеб мөйүзендән тотар ирде. Бөрҗан би йитеб, кийекне атыб йықты, ханның алдыға килтүрде[68]. Хан аңар һәм илле тәнк[ә] алапа бирде. Һәр көн ошбундағ зәвық қыйлур ирделәр.

Йәнә көнләрдә бер көн хан әйде:

– Әй, бикләрем! Барыңлар, қош аулаб килтүрүңләр! – тиб бойурды. Бикләр һәрберсе қошларын алыб чықтылар. Қошлар аулаб килтүрделәр. Қыйат шонқар қошу берлә аққош тәбтүрде. Сиңлә лачын берлә торна тәбтүрде, Урадаж қарчыға берлә қаз тәбтүрде, Тамйан қыйрғы берлә бүдәнә тәбтүрде. Һәрберсе – қошлы қош берлә тәбтүргән қошларны // *(34б кәгазь)* алыб килделәр, Чыңыз ханның алдыға салдылар. Хан бу қошларны күрүб, һәрқайусына меңәр тәнк[ә] алапа бирде. Әмма Қыйатқа, Сиңләгә, Урадажға, Тамйанға – аларга икешәр мең тәнк[ә] алапа.

Андин соң Чыңыз хан олу уғылы Чүчигә «асыл мал анда бөтәр» тиб,

---

[63] Кулъязмада: қобурхақ.
[64] Кулъязмада «Қоқлыға» дип ялгыш язылган.
[65] Кулъязмада «шәмаса» дип хаталы язылган.
[66] Кулъязмада «йитәр» дип ялгыш язылган.
[67] Кулъязмада «йалан» дип ялгыш язылган.
[68] Кулъязмада «килтүрүде» дип хаталы язылган.

«алтун-көмүш күбдүр[69]» тиб, «йорты киңдүр» тиб, Тәрмиз урдасында ханлыкға куйды. Тәки икенче уғылы Җәдайны «ил олусы анда булур» тиб, «төмән төрле[70] халық анда булур» тиб, «олуғ йортдур» тиб, Һиндустан урдасында ханлык[ка] куйды. Өчүнче уғылы Кирәйне[71] «ир кийәр савыты ир кушанур, кылычы[72] күбдүр» тиб, «асылзадә халыкдур» тиб, Күрәл урдасында ханлыкка куйды. Тәки түртүнче уғылы Тулины «халыклары рәхимледүр[73]» тиб, «ирәү йортыдур[74]» тиб, «ир кийәр чуғасы, ат[л]асы, туркасы күбдүр» тиб, «эше каты, ашы татлы, таймас олуғ йортдур» тиб, Мүскәү урдасынд[а] ханлыкка куйды. Һәрберсенә ошбу әйтелгән урдаларны халкы[75] берлә анларға өләшеб бирде. Ул шәһәрләрдәге ханларның асыл йебе болардиндур, асылы Чыңыз хандур.

Андин соң йәнә беләсез кем, Чыңыз хан пәйғамбәремез Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу ғәләйһи вәс-сәлләмнең тарихындин соң биш йөз кырык тукузынчыда ирде, туңуз йылында, зилкәғдә айында анадин туғды. Анд[ин] соң Чыңыз хан йитмеш ике йыл ғөмер кичүрде, унөч йәшендә ханлыкка ултурды, хан булды, илле тукуз йыл ханлык сөрде. Чыңыз ханның туған шәһәре, *// (35а кәгазь)* тотған, торған йорты Кытай ирде. Йәнә йитмеш ике йылдан соң, туңыз йылында, мөбарәк рамазан айының унтүртүнче көн, тарих алты йөз дә йегерме түртдә дөнйадан вафат үтде, сүзе дөнйада калды.

Фасыл фи бәйани дастани Аксак Тимер

Имди йәнә хәзрәти Аксак Тимер нәселендән сөйләйәлең. Һиндустан шәһәрендә Чыңыз хан уғылы Җәдай хан иде, ханлык[76] кылур ирде. Көнләрдә бер көн йатыб ойыды, йаман төш күрде, куркуб-сискәнеб уйанды, дер-зер калтураб торды. Фалкярләрне, фал бағучылар[ны] җыйдурды, талиғын каратды, октартды. Фалкярләр, фал бағучылар әйделәр:

– Әй, ханым! Талиғыңдан андағ күренүр кем, үз милкеңдә Алмалык дигән авылда бер кешедән хәтәреңез бар торур. Ул кеше Казакчы уғылы Потчы, [Потчы] уғылы Олукчы, Олукчы уғылы Тавукчы, [Тавукчы] уғылы Тухчы, Тухчы уғылы Тарағай дигән кешедүр, – тиделәр. – Әмма ул Тарағайның[77] нишаны-билгүсе улдур кем, чавырынында миң бар,

[69] Кулъязмада «күбләр» дип ялгыш язылган.
[70] Кулъязмада «түәрле» дип хаталы язылган.
[71] Кулъязмада «Кирәбне» дип хаталы язылган.
[72] Кулъязмада «фылычы» дип хаталы язылган.
[73] Кулъязмада «рәхимлемар» дип хаталы язылган.
[74] Кулъязмада «йорныдур» дип хаталы язылган.
[75] Кулъязмада «халык» дип ялгыш язылган.
[76] Кулъязмада «халикның» дип ялгыш язылган.
[77] Кулъязмада «Тарағлының» дип ялгыш язылган.

сул күзүндә ақы бардур. Ул Тарағайның хатуны йөкле торур. Аның қорсағындағы баладин әҗәлең[78]-үлүмең йитеб торур, – тиделәр.

Анда Җәдай хан фал бағучылардин бу сүзне ишетеб, ул Алмалық авыл[ын]дағы Тарағайны[79] эстәтеб табтурды. Җәдай хан қашыға алыб килделәр, қарадылар – ул әйтелгән нишанлары бар ирде, чавырынында миңе, сул күзүндә ақы бар торур. Һәм Җәдай хан сордылар:

– Әй, Тарағай! Сәнең айлу-йөклү хатуның барму?

Ул Тарағай *// (35б кәгазь)* әйде:

– Бәли, бардур, – тиде.

Андин соң Җәдай хан әйде:

– Әй, Тарағай! Сәнең хатунуң қорсағындағы балаң мәне үлтүрүр ирмеш. Ул туғмасдин борун мән аны үлтүрүрмән! – тиб, Тарағайның хатунын алдурды[80]. Ул ахмақ тәкдирне тәдбир берлә бозмақ теләде. Әмма Хақ Тәғаләнең[81] тәкдире нитәк булур[82].

Андин соң киңәштеләр, «бу хатунны үлтүрәлек» тиб, «эчен йаралық» тиделәр. Анда Җәдай хан үзе әйде:

– Мәне бу хатунның қорсағындағы бала үлтүрүр булса, ул қорсағындағы баласыны қызлаб-тезләб үлтүрүң, анасы үлмәсүн! – тиде.

Андин соң ул хатунны йықыб, андағ тезләделәр кем, исе-осы китде, үлә қалды.

Андин хан әйде:

– Имди баласы дәгел, анасы һәм үлде[83] китте.

Андин соң Җәдай хан қур[к]ынычдин қотулдым тиб торур ирде, ханлықға мәғрүр-мәшғүл ирде.

Андин йәнә бер анча көнләрдин соң ул мескин тезләб имгәнгән хатунның күзе йаруды, бер ир уғлан туғу[р]ды. Ул уғланны алыб бақтылар ирсә, бер айақы ақсақ ирде. Анда әйделәр кем:

– Ошбундай имгәкдин[84] үлмәй қотулуб туғдуң, җаның тимер икәндүр! – тиделәр. Ул уғланның атыны һәм ул сәбәбдин Ақсақ Тимер қуйдылар.

Имди хәзрәти Ақсақ [Тимер]нең асылы-төбе барлас диган ру булур

---

[78] Кульязмада «аның» дип ялгыш язылган.

[79] Кульязмада «Тарағайлы» дип хаталы язылган.

[80] Кульязмада «Тарағай сәнең хатунын үлдүрде» дип ялгыш язылган.

[81] Кульязмада: Тәғәһәнең.

[82] Әлеге җөмлә «Икенче текст»та бу рәвешле: «Әмма Хақ Тәғаләнең тәкдире нитәк булса – андағ булур».

[83] Кульязмада текстка өзеклек кергән. «Икенче текст»ның әлеге урынында болай язылган: «...булғай, йибәреңләр! – тиде. Андин соң ул хатунны күтәреб алыб, арбаға салыб».

[84] Кульязмада «имгән көндин» дип ялгыш язылган.

ирде, нәселендә-руында ханларға җәйан уғул ирде. Андин соң йәнә Ақсақ Тимернең атасы-анасы үлде, йәтим қалды. Асрарға, күрәргә һич лайық кеше бу- *// (36а кәгазь)* -лмады. Ахыр, үзе йөрүрдәй булуб, ир йиткәндин соң қазақ чықыб, йалғузы Шымақи шәһәрегә барды, бер анча йөрүде, Шымақида бозаулар көтмәгә җалға инде. Үзегә үзе кебек үксүз-йәтим йегетләрне ийәләндүрде, алты-йите уғул бер булуб, көн дә бозау көтәр ирделәр, тәқи уйнарлар ирде.

Анда Ақсақ Тимер көнләрдә бер көн бер бозуқ кәшанә[85] төбендә йалғуз тайаныб йатыб бақыб торур ирде. Бер айағы ақсақ, тәқи бер күзе сукур қырмусқа килде, тәқи ул кәшанәгә тырмашыб менәргә йабушды[86]. Бер анча йуқару менде, йықылды. Андин соң йәнә һиммәтләнеб тәқи йабушды, тырмашыб кәшанәнең башыға менәйен, чықайын тигүнчә йәнә түбән йықылды. Бу хәзрәти Ақсақ Тимер қырмусқаның бу эшегә таңға қалыб, қараб торур ирде. Ақсақ қырмусқа, ғәрләнмәйен[87], йәнә өчүнче мәртәбә кәшанә башыға менәргә йабушды. Ахыр, тырыша-тырмаша бар[а] торғач, кәшанәнең түбәсегә чықыб китте.

Ул қырмусқадан бу хәзрәти Ақсақ Тимер аны күрде, йәнә әйде:

– Бу зәғиф, айақсыз, күзсез қырмусқа һиммәтләнеб, йықыла-тора, тәмам түбәсегә менде, йуқару чықды. Мән һәм һиммәт берлә хан булуб, ил-көн, шәһәрләр алыб, урдалар алсам – һич таң-ғәҗәйеб булмас. Әгәр Тәңре Тәғалә[88] бойурса, – тиб, күңеленә бу фикерне салуб йөрүр ирде.

Тәқи ул уғланлар берлә уйнар ирде. Көнләрдә бер көн Ақсақ Тимер әйде:

– Әй, йегет- *// (36б кәгазь)* -ләр! Киленңләр, бер йиргә бер нәрсә қуйалы. Ул қуйған нәрсәне кем элек йөгерүб йитеб алса, аны арамызда хан қыйлайық! – тиде.

Анда ул йегетләр әйделәр:

– Хуш, андағ булсун, – тиб, алысқа бер нәрсәне илтеб қуйдылар. Тәқи барча уғланлар йөгүрүшделәр. Ақсақ Тимер һәм йөгүрүр ирде. Йөгүрүб уғланлар шайы бара алмады, аның өчүн кем – ақсақ ирде. Андин бер уғлан йөгүрүб узуб, «ул қуйған нәрсәне алайын, мән элек хан булайын» тигүнчә, андин борунрақ ул нәрсәне Ақсақ Тимер бүрке берлә ташлаб орды. Тәқи әйде:

– Әй, йегетләр! Сезләрдин борун мән йитдүм, мән хан булурмән! – тиде.

---

[85] Кулъязмада «бозау йәшәнәсе» дип хаталы язылган.
[86] Кулъязмада: йапушды.
[87] Кулъязмада «ғаләрәнмәйен» дип хаталы язылган.
[88] Кулъязмада: Тәғәһә.

Ул берәүсе әйде:

– Йуқ, сәндин борун йитеб мән алдум! – тиде.

Анда Ақсақ Тимүр әйде:

– Һай, сәнең қулуң тигүнчә, мәнем башым тиде, – тиде.

Болар бу сүз өстүндә бәхәсләшеб торурлар ирде, бер ақ сақаллы қарт[89] кеше килде. Болар ул картқа эшләрен сөйләделәр, «Ханлық қайсубызгә тигәр?» – тиделәр.

Анда ул қарт әйде:

– Әй, йегетләр! Сезләр мәнем сүземне тотармусыз? – тиде.

Болар әйделәр:

– Әй, баба! Сән һәрни дисәң, эшүмезне сәнгә салдук, – тиделәр.

Анда ул қарт әйде:

– Әй, йегетләр! Бу ақсақ уғулның сезнең қулуңыздин борун башы йитебдүр, моны хан қылуңыз! – тиде. – Сүз моның сүзедүр! – тиде.

Анда бу үзгә йегетләр әйделәр:

– Әй, баба! Хуш, имди [андағ] қыйлайық, – тиделәр. *// (37а кәгазь)* Ақсақ Тимүрне үзләре араларында хан қыйлыб уйнар ирделәр.

Йәнә көнләрдә бер көн Ақсақ Тимүр әйде:

– Әй, йегетләр! Һәркем ошбу көтә торған бозаулардин бер бозау суйуб, барчамызға йидүрсә, арамызда аны хан күтә[рә]ле, – тиде.

Анда йәнә үзгәләре қыйыб бозауны суйа алмадылар. Ақсақ Тимүр бер бозауны суйды, бешүрде, ул уғланларға йидүрде. Ашадылар, андин соң Ақсақ Тимерне үз араларында хан күтәрделәр. Андин қайтыб өүләренә килделәр, бозау ийәсенә әйделәр:

– Бозавыңны бүре ашады, – тиб.

Ул һәм нәрсә димәде, «бүрегә бойырған икәндүр», тиде.

Андин соң көнләрдә бер көн Ақсақ Тимер бу уғланларға әйде:

– Әй, йегетләр! Килеңез, безләр қарақчы булайық, базаркянләр, сатучыларны тотайық, малын алайық! – тиде.

Анда бу уғланлар әйделәр:

– Хуш булсун! – тиделәр.

Анда Ақсақ Тимүр әйде:

– Сезгә сүзүм улдур кем, имди бу кичә һәрқайсуңыз һич үзгә нәрсә алмаңыз, мәгәр йау қоралын қуймаңыз, алыңыз! – тиде.

Анда бер бозық кәрвансарай[90] бар ирде, булжа[л]ны анда қуйдылар. Төннең йарумунда килеб бер-берсенә йулуқтылар. Қайсысы көбә кийеб,

[89] Кульязмада бу сүзнең алдында ялгыш «қат» дигән сүз язылган.
[90] Кульязмада «кәрвай сәди» дип хаталы язылган.

мылтық алыб, қайсысы уқ-садақ, қылыч алыб ушал Шымақи шәһәрендән чықыб киттеләр.

Һиндустан шәһәрегә барыб, Һиндустан шәһәренең йулын сақлаб йаттылар, узған-барған с[ат]учылар, асламчыларны бастылар, *// (37б кәгазь)* малларын алур ирделәр, олу қарақчылық қыйлдылар.

Азған-тузған, ата-анадан бизгән уғланлар, байдан қачқан қоллар аңар җыйылдылар, қушулдылар. Һәркем тышдан килеб аңар қушулса, аңар лайық алапалар бирә башладылар. Базаркянләрне, сатучуларны қырдылар, қол-қотунны йулдаш қылдылар, бер ике-өч йөз кешеләр булдылар. Узған-барғанны талар ирделәр, йул көллисе киселде, кәрван халқы йөрүмәз булдылар.

Анда Һиндустан падишасы Җәдай ханға хәбәр төшерделәр – «йулны қарақ сақлайдур, кешене йөрүтмәйдүр» тиб. Андин соң Җәдай хан илче йибәрде, өч йөз кеше берлә килеб Ақсақ Тимергә әйделәр:

– Әй, Ақсақ! Нә өчүн сән мондағ уғурылуғ қылурсән, йулларны[91] бағларсән? – тиде.

Анда Ақсақ Тимүрнең чирүе ул килгән илчебашын үлтүрделәр, үзгәсен барчасын үзләренә йулдаш қылдылар, күб ағыр алапалар бирделәр.

Бу хәбәр йәнә Җәдай ханға ишетүлде. Үртәнде, көйде, йәнә икенче мәртәбә илче йибәрде. Ул икенче килгән илченең башын йибәрделәр, үзгәләрен алыб қалдылар, йулдаш қылдылар. Андин соң Җәдай хан йәнә өчүнче илче йибәрде, «ул қарақларға алтун-көмүш алапа бирәйен, узған-барғанға, базаркянләргә тимәсүн» тиб.

Анда болар әйделәр:

– Имди Җәдай ханның қазнасындан безнең қазнабыз[92] [...]

---

[91] Кулъязмада «булларны» дип хаталы язылган.

[92] Бу сүзнең «...набыз» өлеше кустодта язылган. Текст шунда өзелә, кулъязманың ахыргы битләре җуелган.

ДҮРТЕНЧЕ ТЕКСТ[1]

[Дастане Чыңыз]

// (1а кәгазь)[2] [...] [қайтты]лар. Анлар қайтыб килә тор[ғанда] ...
кешеләр чықтылар, бар[ыб] ...
[сор]дылар:
– Һа, қандин килүрсез? ...
Әйделәр:
– Һа, безләрне сорсаңыз ...
босуб киләбез, – диделәр. Анлар әйделәр:
– Сез[ләр] ...
// (1б кәгазь)[3] ... [булд]уң? – диделәр.
Улар әйд[еләр]:
... [қыл]ды, залим булды, чыдай
... [дид]еләр.
Болар әйделәр:
– Хуш,
... [те]рек кийекне бирмәсбез, – диделәр.
... қалған җингәмез бардур, ағамыз үлгәнгә
// (14а кәгазь)[4] ... [киңә]ш сорма,

Тимүрчедән киңәш сорма[ғыл]
[Қассабчыда]н киңәш сорма!
Күргән күргәнен әйтүр,
Күтәргән итмәген сатар.

---

[1] Татарстан Республикасының Милли музеенда «18369-141» шифры белән (Зәйнәп Максудова фондында) саклана торган кульъязмадан алынды. Аеруча дефектлы (бер чите ертылган) кәгазьләрдә язылган текст фрагментлары монда, асыл нөсхәсенә охшашрак итеп, яртышар юл чамасында бирелде һәм ертык өлешләре өчәр нокта белән билгеләнде.

[2] Кульъязманың үзендәге кәгазь номерлары ялгыш кабатланганнары да бар һәм алар текстның тәртибенә туры килми. Шунлыктан, аларның текст тәртибенчә тиешле саннарын төп текстта дөресләп язып, астөшермәдә кульъязманың үзендәге бит саны күрсәтелә. Безнең тарафтан шартлы рәвештә 1а дип билгеләнгән кәгазь фрагменты кульъязмада 11а буларак язылган.

[3] Кульъязмада 11б кәгазь.

[4] Кульъязмада 2а кәгазь.

Имди тәңресенә тәүбә қылсун, сүзүм мондин артуқ йукдур, – диделәр. Йәнә бу сүзләрне әйткәндин соң Буд- *// (14б кәгазь)*[5] [-әнәтай]...

... [байла]рның айры өркәчле нәр[6] төйәсен, айағы чалыш йурғасын, муйыны озун арғамағын, батыр йегетләрнең көбәсен, йахшы бикләрнең қызларын алдылар. Бу эшкә халық уғылы күнмәс-чыдамас булдылар, җыйылыб килеб Аланғуға[7] [...]

// (3а кәгазь)[8] көн инд[е] ...

[Бо]лар йәнә бер ...

[алд]ылар ирсә ...

булуб ингән ...

– Килеңез, безләр[9] исергән ...

йаларымызны тартыб чигәлик, бүре ...

чықар, – тиделәр. Андин тора салыб йаларын [тар-]

тыб чикделәр, күрделәр кем – йылқы йаллы күк бүре чықа килде. Артыға қараб «Чыңыз, Чыңыз!» тиб аваз бирде, барыб урманы[10] эченә инде. [Мо]ны бу өч кеше әшкярә күрделәр.

// (3б кәгазь)[11] ... [Б]үдәнҗар

... «[Бул]асы бу[лур]

... [өлүше]мезне алма[с]»

... [Ала]нғуның күзе

... [уғла]н туғды, алтун изар[12][лық]

... мөһерендә Җәбраил фәрештә[нең а]ты бар торур ирде. Үзе бүре йағрылы, [ир] чырайлы, күрүкле сынлы, йөзен күргән кеше артындин «үләйен» дир ирде, қашында ултурғанлар май дик эрүр ирде. Вә тәқи «атым, тунум сәнең булсун!» дир ирде.

Андин соң *// (4а кәгазь)*[13] Чыңыз үсде, олығайды, халыққа ғәделдад

---

[5] Бу кәгазьнең өске яртысы ертылып җуелган һәм әлеге текст фрагменты кульязманың 2б кәгазендә язылган.

[6] Кульязмада «нәрә» дип хаталы язылган.

[7] Бу сүз кустодта язылган. Аннан соң текстка өзеклек кергән.

[8] Кульязмада 3а кәгазь. Кәгазьнең өске сул чите ертылган булуы сәбәпле, өстәге алты юлының тексты тулы түгел.

[9] Кульязмада «болар» дип ялгыш язылган.

[10] Кульязмада бу сүзнең алдында язылган «һәб» (дөресе «барча, бөтен» мәгънәләренә ия «һәп») сүзе ялгыш язылган булса кирәк. Чөнки, беренчедән, аның мәгънәсе контекстка ярашмый һәм, икенчедән, әсәрнең башка күчермәләрендә андый сүз юк.

[11] Кульязмада 9б кәгазь. Кәгазьнең өске уң чите ертылган булуы сәбәпле, өстәге алты юлының тексты тулы түгел.

[12] Кульязмада «ираз» дип хаталы язылган.

[13] Кульязмада 10а кәгазь.

қыйлыб, файдалығ булды. Халық уғылы моны сәвеб-үгүб, Чыңызға ийәрә башладылар. Чыңызны «Ғәйәт йахшы хан[14] тиб, ханның чағасы-баласы» тиб, мақтадылар.

Ағалары Бүдәнжар, Қағынжар, Сал[жу]т бу Чыңызны күрә алмас булдылар, көнләделәр. [Тәқи] әйделәр:

– Күрүңләр имди, нөгәрләремез, халқымыз уйнашдан туған уғулға авар булдылар, – тиделәр. – Аны үлтүрәйек, йуқ қылайық, йуқ ирсә тынмасбыз, – диделәр.

Андин соң йәнә бу өч уғул киңәш итеб, бер көн йыйылыб килделәр, *// (4б кәгазь)*[15] халыққа йар салдылар:

– Чыңызны үлтүртәбез! – диделәр.

Анда халық уғылы әйделәр:

– Һа, Чыңыз сез өчәвеңездин[16] йортқа лайықрақ охшайдур, халыққа файдалығдур. Бу Чыңызны сезгә үлтүрүргә бирмәсбез! – диделәр. – Әгәр мал өләшеб, мал алур булсаңыз – атаңызның малын өләшеб алыңыз! – тиделәр. – Йуқ ирсә, аның өчүн без үләбез, – тиделәр.

Анда бу өчәү халық уғулындин бу сүзне ишеткәндин соң құрқуб, нәрсә қыла алмадылар. (Әмма күңелләрендә әйделәр: «Халық уғылы бу Чыңызга авыбдур, моны билгеле *// (5а кәгазь)*[17] үлтүрүб булмас. Билгүсез – халық[қа белдүр]мәй үлдүребез», – тиделәр).

– Хуш, андағ [булса], атамызның қалған малын өләшеб алурбыз, – [тиб], аталарының һәр нә қалған малын өләшеб алды[лар]. Әмма Дуйын-Бәйанның бер алтунлы-гәүһәрле садақы бар ирде, бәһасен табмадылар, өләшмәй қуйдылар. «Имди анамыз кемгә ханлық бойурса, бу сад[ақны] ул алсун», – диделәр. Өлүшенә тигән малларын алғандин соң, садақны алыб, анасы қаты[ға] килделәр. Тәқи әйделәр:

– Әй, анамыз! Сез кемгә йарлықаб ханлық бирсәңез, бу алтунлы садақны ул уғылуң *// (5б кәгазь)*[18] [алсун], – тиделәр.

Анда Аланғу әйде:

– Аһ, әй, балаларым!

---

[14] Кульъязмада «ханы» дип ялгыш язылган.

[15] Кульъязмада 10б кәгазь.

[16] Кульъязмада «өчәңездин» дип ялгыш язылган.

[17] Кульъязмада 11а кәгазь. Кәгазьнең өске сул чите таушалып ертылган булуы сәбәпле, текстының 1–7 нче юлларындагы башлангыч сүзләре танылмый һәм алар квадрат җәяләрдә бирелде.

[18] Кульъязмада 11б кәгазь. Кәгазьнең өске уң чите таушалып ертылган булуы сәбәпле, текстының 1–7 нче юлларындагы башлангыч сүзләре танылмый һәм алар квадрат җәяләрдә бирелде.

[Үз йортын] йаманлаған – үзгә йортда сүгүш [булур],
Үз анасын йаманлаған – дошманға тотғун [булу]р,
Үз кешесен йаманлаған – йат дошманға [х]ур булур.

Сез шомлар мәнең сүзүм тотарму[сы]з? – тиде.

Ул өчәү әйделәр:

– Бәли, хуш то[тарбыз], – тиделәр.

– Имди сезләр тотар булсаңыз, тәрәзәдән төшкән көнгә футаллы футаңызны салуңыз. Қайыңыз футасы аңар эленеб туқтаса, ул уғылум хан булсун. Тәқи алтунлы-гәүһәрле садақны һәм ул уғылум алсун, – тиде ирсә, Аланғуның[19] [...]

// (6а кәгазь)[20] ... [белсүн]ләр, – тиб әйде. Үзләре китделәр, анасы илай [қалды].

Иртәгесен халық уғылы күрүшкә килделәр ирсә, Чыңызны күрмәделәр, тәқи сордылар:

– Чыңыз ханымыз қайдадур? – тиб. Истәб табмадылар, чулашыб, чымырғаныб илашдылар. Андин соң килеб Аланғудин сордылар, ул һәм әйтмәделәр.

Чыңыз хан қазақ чықыб киткәндин соң, ағалары Бүдәнжар, Қағынжар, Салжут халық уғылуна золым-көч итделәр. Халық уғылы чыдамайын килеб, Аланғуға әйделәр:

– Аһ, Аланғу! Ул угылуң Чыңызны безгә күргүзгүнчә, күргүзмәй *// (6б кәгазь)*[21] жанымызны алсаң ирде. Имди нә өчүн күргүзүб жанымызны алдың? – тиделәр. Йәнә чулашыб илашдылар.

Анда Аланғу әйде:

– Аһ, әй, халық! Андағ булсаңыз, уғылум Чыңызны сорсаңыз, иртә берлә [биш]-алты руның йахшы-лайық кешеләре килеңез, мән анларға йулын-эзен күрсәтәйен, – тиде.

Андин соң, иртә берлә алты руның лайық кешеләре килделәр, сордылар:

– Йулы қайдадур? – тиделәр.

Анда Аланғу әйде:

– Хуш, имди барыб шул Тикәлек суыға бақыб торуңыз, хәбәре килүр! – тиде.

Болар су йақасына барыб, бақыб тор- *// (7а кәгазь)*[22] -дылар – һич нәрсә

---

[19] Бу сүздәге «-ның» кушымчасы кустодта язылган. Аннан соңгы бер кәгазе ертылып җуелган булуы сәбәпле, текстка өзеклек кергән.
[20] Кульъязмада 12а кәгазь.
[21] Кульъязмада 12б кәгазь.
[22] Кульъязмада 13а кәгазь. Кәгазьнең уртасыннан түбәнге сул як чите ертылып җуелган булуы сәбәпле, текстының 6–11 нче юлларының ахыргы сүзләре танылмый.

күрмәделәр. Мәгәр бер қәүм қош җоны күрделәр. Йәнә қайтыб килделәр. Анда Аланғу сорды:

– Нә күрдүңез? – тиде.

Анлар әйделәр:

– Йуқ, нәрсә күрмәдүк. Мәгәр бер қәүм қош җоны күрдүк, – тиделәр.

Анда Аланғу әйде:

– Һа, кил имди, мәнең уғылум Чыңызның хәбәре [ушал сез күргә]н қош җоныдур, – тиде. – Имди [сезләр о]шбу Тикәлек суыны қыдырыб эз[ләңез, Тикәлек] суының башында Көргүрлән дигән [қара тауның] башында бишалты ағач булур. «У[шал йирдә] мәқам тотармән, қош аулармән, җоны[н йол-] // *(7б кәгазь)*[23] -қуб [суға ташлармән», тигән ирде. Имди ушал җонны][24] эзләб барыңыз! – тиде. – Әмма Тикәлек суының иске-қарый йоласы[25] улдур кем, көндез ташыб, қабағындан ашар, кичәсе хисабына төшәр, – тиде.

Анда Аланғу анларға әйде:

– Имди сезләр ул йиргә барыб йитеб һәр нә йулуқсаңыз, күрсәңез – «[Сезләр] монда нә кешесез?» тиб [сорғанда] «Дуйын, Дуйын» дигәйсез. Әмма мәнең у[ғылум Чыңы]з төсе-нишаны улдур кем:

Ақ [тунлы, күк ат]лы, алтун бүрүкле,
Йөз[е] ғәйәт [күрүкле][26];
Алтун [садақлы], ир чырайлы,
Җәбраил дик сынлы торур,
[Атын] қамчыласа, ғәиб булған тикдүр

– андин // *(8а кәгазь)*[27] аны белгәйсез, – тиде.

Әмма Чыңыз ханны истәй барған бикләрнең атлары болардур: Уйшын Майқы би, икенчесе – Қалдар би, өчүнчесе – Урдаж би, түртүнчесе – Қыпчақ би, бишенчесе – Тамйан[28] би, алтынчысы – Кирәйәт би, йитенчесе – ... би, ... [Муйта]н би ... Бу ун бик ... [сәве]б, аны истәмәк қасдында[29] булдылар. Әмма [түрт] бик буны эстәмәгә өнәмәделәр, «Қулдағы ханымызны хурлаб, алысдан истәмәзмез», – тиделәр. // *(8б кәгазь)*[30] Анларның берсе – Қоңрат

[23] Кулъязмада 13б кәгазь.

[24] Текстның биредә квадрат җәяләр эчендә бирелгән өлеше кулъязмада язылмыйча төшеп калган. Әлеге кәгазьнең уртасыннан түбәнге уң як чите ертылып җуелган булуы сәбәпле, текстының 6–11 нче юлларындагы башлангыч сүзләре танылмый.

[25] Кулъязмада «йоқласы» дип хаталы язылган.

[26] Бу сүз кулъязмада юк, монда «Икенче текст»тан алынды.

[27] Кулъязмада 14а кәгазь. Әлеге кәгазьнең уртасында якынча өч юл күләмендәге өлеше ертылып җуелган булуы сәбәпле, текстының 6–8 нче юлларындагы сүзләрнең кайбер фрагментлары гына сакланган.

[28] Кулъязмада «Тамнай» дип хаталы язылган.

[29] Кулъязмада «қастында» дип хаталы язылган.

[30] Кулъязмада 14б кәгазь. Кәгазьнең уртасында якынча өч юл күләмендәге өлеше

би, икенчесе – Қатай би, өчүнчесе – Салҗут би, түртүнчесе – Қыйат. Әмма бу Қатай, Салҗут, Қыйат – өчәгүсе халық уғылын биләр ирделәр. Қоңрат би анларның ышанычлы киңәшчесе ирде. Қоңрат би Чыңыз [...]

... Майқы би үзгә бикләргә [белд]үрмәй, Аланғудин бер мөһерле йөзүген алды. Андин Тикәлек суын[31] қыдырыб китделәр, өч айда барыб йитделәр. Бер үчә қайа тағға менеб қарадылар, ар- *// (9а кәгазь)*[32] -тларында бер ақ сарай, бер күк сарай күрделәр. Йәнә қайтыб, бер азина килделәр, ул сарайларға инмәделәр. Анда бер тау бар ирде, ул тауның қабағында йатдылар. Бер азина тордылар, һич нәрсә-нишан белмәделәр. Мәгәр бер азинадин соң бер аваз килде қарға чарлаған дик, кеше сүзләгән тик. Қ[араб-йөр]үб бақтылар, бераз кеше килебдүр, йулының буйлу чықа йатур. Шул тағның қабағындан бире кил[мә]гән охшайдур тиделәр. Әмма болар һич аваз бирмәделәр. Йәнә авазлары килде, ул көн һич нәрсә белмәделәр.

Иртәгесен айу ақырды, арслан қычқырды, *// (9б кәгазь)*[33] белделәр кем – «Чыңыз хан ау аулай чықты», – тиделәр. Болар ул авазны ишеткәч йөгүрүб бардылар, күрделәр кем: күк атлы, ақ тунлы, алтун бүрүкле, алтун садақлы, ир чырайлы, Җәбраил дик күрүкле, сынлы-йусынлы Чыңыз ханны таныдылар вә белделәр. Ул килгән Чыңыз әйде кем:

– Сезләр[34] безләрне андыб йөрүрсез, [нә] кешеләр сез? – тиде.

Болар әйделәр:

– Дуйын, Дуйын! – тиб.

Болардин ул сүзне ишеткәндин соң күзләрендин ғәиб булды. Болар йәнә йығлашыб қайтдылар. Ул кич қайғуруб йатдылар. Андин йәнә иртә булды ирсә, оранлар *// (10а кәгазь)*[35] берлә чарладылар: «Ақ-ту-ған, ту-ты-йақ, тый-лақ, ақ-тый-лақ!» – тәйү чақурдылар, һич нәрсә аваз килмәде.

Андин йәнә ике-өч көн йатдылар. Йәнә бер көн айу ақырды, арслан қычқурды – белделәр кем, «Чыңыздур, ау аулай чықты!» – тиб, сәвенешделәр. Йәнә барыб күрделәр – ул кешенең үзедүр!

Андин боларға Чыңыз хан әйде:

– Һа, сезләр [кемләр][36] сез һәрдаим безне андыб йөрүрсез? – тиде.

Болар әйделәр:

ертылып җуелган булуы сәбәпле, текстының 6–8 нче юлларындагы сүзләрнең кайбер фрагментлары гына сакланган.

[31] Кулъязмада «суының» дип ялгыш язылган.

[32] Кулъязмада 15а кәгазь.

[33] Кулъязмада 15б кәгазь.

[34] Кулъязмада «сезләрне» дип ялгыш язылган.

[35] Кулъязмада 1а кәгазь. Бу урыннан кулъязманың сигез кәгазьдән торган, З.Максудова тарафыннан «4 нче төп» дип аталган өлеше дәвам итә.

[36] Кулъязмада бу сүз урынына «сезләр» сүзе ялгыш тагын бер мәртәбә язылган.

– Дуйын, Дуйын! – тиб, йәнә чулашыб, илашыб тордылар.

Болар болай йығлағанға Чыңыз хан үзе һәм йығлады. Йәнә әйде:

// (10б кәгазь)[37] – Һа, сезләр нә өчүн монда килдеңез? – тиб сорды.

Болар әйделәр:

– Сәнең артындан үлә-йитә йөрүрбезләр, – диделәр.

Анда ул Чыңыз хан әйде:

– Һа, сезне монда килүргә кем үгрәтте? – тиде.

Болар әйделәр:

– Безләргә, рәхим қыйлыб, сойурғаб анаңыз Аланғу үгрәтде, – диделәр.

Анда Чыңыз хан әйде:

– Хуш, имди анда булса, қани мәнгә анамның бер билгүсе барму? – тиде ирсә, үзгә бикләр тик тордылар, әмма Уйшын Майқы би қулунда Аланғудан алған мөһерле йөзүкне чықарыб бирде.

Анда Чыңыз хан йөзүген алыб бақты ирсә, Аланғу- *// (11а кәгазь)*[38] -ның мөһерле йөзүген таныды, тәқи көлүб әйде:

– Әй, Майқы би! Әгәр мән хан булсам, биклек сәнең булсун! – тиде. – Әгәр сән бу мөһерле йөзүген алыб килмәсәң, мәнгә анамның бер нишанын килтүрмәсәң, мән сезгә йуқ ирдем, тәқи сез мәнгә иш-йулдаш булмас ирдүңез! – тиде. – Әмма бу сүздин үзгә бикләрем сезләр һәм күңлүңезгә йаман алмаңыз, сезләр барчаңыз мәнем жанымсыз! – диде. – Килеңез, имди қуышқа қайталық, анда барыб ултуралық, – тиде.

Сарайға бардылар, бер азина анда йатыб, аш йиделәр, төрлү шәрабләр *// (11б кәгазь)*[39] эчтеләр, сүнмәс чыраған, төкәнмәс аш йиделәр.

Андин соң йәнә Чыңыз хан әйде:

– Килеңез, имди киңәш итеб ултура[лы]! Сезләр кем, безне эстәб килебсезләр, ничә руда халық берлә берсез? – тиде.

Болар айақға үрә торуб үтүнделәр, тәқи әйделәр:

– Әй, олуғымыз, ханымыз! Безләрдин кем сорсаңыз, безләр монда сезне истәй килгән ун кешемез, туқуз рудан, – тиделәр. – Әмма Қалдар би йалғуз үзедүр. Анаңыз Аланғу безгә қушуб иде, – тиделәр. – Әмма Қоңрат сезне эстәй килмәде, өнәмәде, ул үзе, тәқи руы ағаларың қашындадур, – тиделәр. – Без сезнең *// (12а кәгазь)*[40] мөбарәк йөзүңезне арзулаб артуңыздан үлә-йитә килдүк, сезгә қушулдуқ һәм үзүмез, һәм барча ру халқымыз берлә [сә]нең қолуңмыз! – тиделәр.

---

[37] Кулъязмада 1б кәгазь.

[38] Кулъязмада 2а кәгазь.

[39] Кулъязмада 2б кәгазь.

[40] Кулъязмада 3а кәгазь.



Дүртенче текст кулъязмасы

Анда Чыңыз хан анлардин бу сүзне ишетте ирсә, сәвенүб әйде:

– Әй, бикләрем, олуғларым! Имди бу көндин соң сез – мәнеңсез! – диде.

Анда болар Чыңыз хандин бу сүзне ишетеб ғәйәт сәвенделәр, тәки әйделәр:

– Имди сәне безләргә Тәңре бирде, аның шөкерлеге өчүн бу менеб килгән атларымызны азад йибәрәле, – тиделәр. Менеб барған атларын Чыңыз ханны булғанлары өчүн азад идделәр. Андин соң Чыңыз хан боларга *// (12б кәгазь)*[41] әйде:

[41] Кулъязмада 3б кәгазь.

– Һа, мәне нә берлә илтәрсәз? – тиде.

Анлар нә берлә алыб барасын белмәделәр. Әмма Қалдар би әйде:

– Мән бер һөнәр чықарайын, – тиде.

Бонлар әйделәр:

– Күрсәт! – тиделәр.

Һичкем ирсә белмәс ирде, үз осталықыдан бер арба йасады. (Имди арба пирене сорсалар, Балын би уғылы Қалдар би тимәк кирәк).

Анда йәнә арба төзүб тәмам қыйлғандин соң Чыңыз ханны арбаға ултурурға үтүнделәр. Чыңыз хан килеб арбаны қарадылар, тәқи «Хуш қылыбсән!» тиб, Қалдар бине мақтады.

Андин соң Чыңыз хан арбаға ултурдылар. Бу барған бикләр үзләре арбаны сүрәд- *// (13а кәгазь)*[42] -еләр-тарттылар. Анда У[й]шын Майқы би әйде:

– Әй, бикләр! Мән сезнең шайыңыз бара алмандур, айақым қысқадур, – тиде.

Анда бикләр әйделәр:

– Имди нитәк қылурсән?

Анда Майқы би әйде:

– Мән хандин үтүнәйен[43], рөхсәт булса, хан берлә арбаға ултурайын, қайсыңыз арбаны тартмаса, мән аны тайақ берлә күтегә төртәйен, – тиде.

Анда болар әйде:

– Хуш, алай ит! – тиделәр.

Андин соң Майқы би Чыңыз хандин үтүнде, тәқи әйде:

– Ай, ханым! Мәнең айақым қысқадур, арбаны тарта алмандур. Сойурғасаң, мән сәнең берлә арбаға ултурур ирдем? – тиде.

Анда хан *// (13б кәгазь)*[44] әйде:

– Хуш, ултур! – диде.

Андин бу бикләр бер анча көнләрдин килә-килә, Чыңыз ханны алыб, Аланғуның шәһәренә йитделәр. Аланғуға хәбәр қылыб, сарайға инделәр. Әмма анда Чыңыз хан артындан қайсусы инәрен белмәделәр. Анда Майқы би әйде:

– Әй, ханым! Сезләрдән соң арба тартқан үгүз инәрму, йә аны йиккән ийәсе инәрму? – тиде ирсә, анда хан әйде:

– Ийәсе инмәй, үгүз инәрму? – тиде ирсә, Майқы би рәван йөгерүб керде, ханның уң[45] йанында урун алды. Үзгәләре йәнә ултурды.

---

[42] Кулъязмада 3а кәгазь.
[43] Кулъязмада «үтәнәйен» дип хаталы язылган.
[44] Кулъязмада 4б кәгазь.
[45] Кулъязмада «унын» дип хаталы язылган.

Иртәгесен Чыңыз хан түрт ру иленең кешесенә олуғ қырқын итделәр. Ушал *// (14а кәгазь)*[46] қырғында Бүдәнжар, Қағынжар, Салжутны, тәқи Қоңрат бине тәмам қырдылар, үлтүрделәр, әман бирмәделәр.

Әмма ул вақытда[47] Қоңрат батырның бер қыз қәрендәше бар ирде, Бөртә Қучын атлығ ирде. Ул Бөртә Қучын ул олуғ қырғында һәлак булмасун тиб, түрт уғулны алыб қалды, йәшерүб асрар ирде. Берсе Бүдәнжар уғылы ирде, икенче Қағынжар уғылы ирде, өчүнчесе Салжут угылы ирде, түртүнчесе ағасы Қоңрат бинең уғылы ирде. Һичбер халыққа белдүрмәде. Анда халық уғылы айыңлашыб[48], тиргәшеб чықардылар. Тәқи Чыңыз ханға барыб әйтделәр ирсә, *// (14б кәгазь)*[49] Чыңыз хан ачуланыб әйде:

– Кеше кешеләр йәшерүбдүрләр, кемдүр? – тиде.

Анда торған бикләр әйделәр:

– Әй, ханым! Қоңрат бинең қыз қәрендәше Бөртә Қучын йәшерүбдүр, – тиделәр.

Анда хан әйде:

– Барыңлар, аны монда тиз килтүрүңләр! – тиде ирсә, рәван уқ бардылар, Бөртә Қучынға әйделәр:

– Тор, тиз бул! Сәне Чыңыз хан өндәйдүр, – тиделәр.

Анда Бөртә Қучын бу сүзне ишетте ирсә, «Хуш, барайын» тиб, тора салыб, сырт кеш тунын йилбәгәй йабынды, тәқи бер ал һәбәрәң башмақы бар ирде – аны киде, тәқи бер қара төлке бүрке бар ирде – башыға аны киде. Тәқи ул йәшерүб алыб қалған *// (15а кәгазь)*[50] түрт уғулны үзе берлә бергә алды. Ул уғланларның қайсысы ун йәшәр, берсе унбер йәшәр, тәқи берсе унөч, тәқи бере унтүрт йәшәр ирделәр. Бу уғыллар ғәйәт күрүкле уғыллар ирде. Бөртә Қучын үзе һәм алардин биш артуқ ирде. Андағ сылу кешене ул заманда һич кеше күрмеше йуқ ирде. Тәңре қөдрәте берлә пәйда булмыш ирде: қыр[ық қол]ач саче бар ирде, артындан ике дайәсе алтун табаққа сачен салыб йөрүтүр ирде.

Анда халық уғылы әйделәр:

– Әй, Бөртә Қучын! Сән бу сыйфатлы күрүклү кеше, нә өчүн мондай эш қыйлдың, бу уғланларны *// (15б кәгазь)*[51] йәшүрдүң, уғры булдуң? – тиделәр.

Анда Бөртә Қучын әйде:

---

[46] Кулъязмада 5а кәгазь.

[47] Кулъязмада «вақытында» дип ялгыш язылган.

[48] Кулъязмада «аңлашыб» дип ялгыш язылган.

[49] Кулъязмада 5б кәгазь.

[50] Кулъязмада 6а кәгазь.

[51] Кулъязмада 6б кәгазь.

– Әй, халық! Мән сезгә нә эш қыйлдым? Уғры булсам, ханға уғры булдум, – тиб җаваб бирүр ирде.

Андин соң Бөртә Қучынны уғланлар берлә Чыңыз ханға алыб килделәр. Хан тәқи моның күркен, озун сачен күрүб таңға қалды. Тәқи әйде:

– Ай, Бөртә Қуч[ын! Нә өчүн] мәнгә уғры булдуң, бу уғланларны йәшүрдең? – тиде.

Анда Бөртә Қучын үтүнүб әйде:

– Әй, ханым! Мән сәне айаған өчүн айаб уғры булдум, йәшердем, – тиде.

Анда Чыңыз хан әйде:

– Ничүк сән мәне айадуң? – тиде ирсә, Бөртә Қучын әйде:

// (16а кәгазь)[52] – Әй, ханым! Сәнең җаныңға көч булур, – тидем.

Анда хан әйде:

– Мәнең җанымға ничөн көч булур? – тиде.

Бөртә Қучын әйде:

– Әй, ханым! Аның өчүн кем, Нух пәйғамбәр ғәләйһиссәлам[53] заманында Ходай Тәбарәкә вә Тәгалә кяферләргә қәһер қыйлыб, туфан суын йибәрде, кяферләрне туфан суыға батурды, йуқ қылды. Тәқи ул туфанда һәр җанлықның, иркәк-тешинең нәселе-тохымы киселмәсүн тиб, Нух пәйғамбәр ғәләйһиссәләмнең[54] кимәсендә қотқарды, азад қылды. Сән хан булсаң да, Тәңре Тәғаләнең қолы дәгүлмүсән? Арслан кийек иркәч аша сикереб, артындағын қайтыб алмас, азад қылур, йибәрер. Әй, ханым, сән адәмсән! *// (16б кәгазь)*[55] Мәне, тәқи бу уғланларны азад қылғайсән? Ул ачиғлық йаман қырғында халық уғылы боларның қәдерен белмәсләр, үлтүрүрләр, боларның тохымы-нәселе, руы киселмәсүн тиб алыб қалдым, – тиде.

Анда Чыңыз хан әйде:

– Имди сәнең шул йахшы дәлилле сүзүң өчүн, тәқи сәнең диңез тик күңлүң өчүн йөз мең үлүмлүләр азад булсун! – тиде.

Кил имди, ай, Бөртә Қучын!
Мәнең қаты күңлүмне қалдурмағыл,
Үзүңне мәндин айырмағын! – тиде.

Анда Бөртә Қучын әйде:

– Хуш, сән мәне сәүсәңез, мән – сезнеңмән! – тиде.

---

[52] Кулъязмада 7а кәгазь.
[53] Кулъязмада: ғһмнең.
[54] Кулъязмада: ғһмнең.
[55] Кулъязмада 7б кәгазь.

Андин соң Чыңыз ханның күңеле эреде, икеләсе бер-беренә қабул булуб, *// (17а кәгазь)*[56] хәләл җефет булдылар, хәлайыққа олу туй қылдылар, бу дөнйаны уздурдылар.

Йәнә йәшерүн қалмасун кем, Чыңыз ханнуң Бөртә Қучындан түрт уғылы булды: Олусы – Йүчи хан, икенче – Җәдай хан, өчүнчесе – Кирәй хан, түртүнчесе – Тулин хан дигән ирде.

Йәнә [...][57]

// (17б кәгазь)[58] ... билгелү қыйлыб, ил-көн бирде[59], сойурғаб ирде. Андин соң Чыңыз хан ошбу бикләрнең барчасына үзлү үзенә тамға, қош, ағачын, оранлар биреб, бау-бау халық қылыб айырды. Әүвәл башлаб Бүдәнҗар уғылы Қыйатқа әйде:

– Сәнең ағачың қарағай булсун, қошуң ш[онқар...][60]

---

[56] Кулъязмада 8а кәгазь.

[57] Кәгазьнең түбәнге яртысы ертылып, 6 юл күләмендәге тексты җуелган.

[58] Кулъязмада 8б кәгазь.

[59] Кулъязмада «ирде» дип ялгыш язылган.

[60] Кәгазьнең түбәнге яртысы ертылып, 6 юл күләмендәге тексты җуелган. Кулъязманың дәвамы юк, текст шул урында өзелә.

БИШЕНЧЕ ТЕКСТ[1]

// *(18а кәгазь)* **Фасыл [фи] дастани Ақсақ Тимер**

Имди йәнә хәзрәти Ақсақ Тимер нәселендин сөйләйәлек. Һиндустан шәһәрендә Чыңыз хан уғылы Җәда[й] хан ирде, ханлық қыйлур ирде. Көнләрдә бер көн йатыб ойыды, йаман төш күрде, қурқуб-сискәнеб уйғанды, торды, қалтырады. Фалларны, фал бағучыларны җыйдурды[2], // *(18б кәгазь)* талиғын қаратды, оқтартд[ы].

Фалкярләр, фал бағучылар әйделәр:

– Әй, хан! Талиғыңда андағ күренүр кем, үз милкеңдә Алмалық тигән авылда бер кешедән хәтәреңез бар. Ул кеше Қарақчы уғылы Қазычы, уғылы Олуқчы, уғылы Тавуқчы, уғылы Тарақчы, уғылы Тарағай дигән кешедүр, – тиделәр. – Әмма ул Тарағайның нишаны[3]-билгүсе улдур: чәү[ре]нендә миңе бар, сул күзүндә ақ бар торур. Ул Тарағайның хатуны йөклү торур. Аның қорсағындағы баласындан әҗәлең-үлүмең йитеб торур, – тиделәр.

Анда Җәдай хан фал бағучылардин бу сүзне ишетеб, ул Алмалық авылындағы Тарағайны эстәб табдурды. Җәдай хан қашыға алыб килделәр, қарадылар – ул нишанлары[4] бар ирде, чәү[ре]нендә миң, сул күзендә ақ бардур[5], – тиде.

Андин соң Җәдай хан әйде:

– Әй, Тарағай! Синең хатуның қорсағындағы баладан мәңгә хәтәр бар! – тиб, Тарағайның хатунун алдурды. Ул ахмақ тәқдирне тәдбир берлә[6] бозмақ теләде. Әмма Хақ Тәғаләнең[7] тәқдире нитәк улур[8].

Андин соң киңәштеләр, «бу хатунны үлтүрәлең» тиб, «эчен йаралың»

[1] Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «584т» шифры белән саклана торган кулъязмадан алынды.
[2] Кулъязмада «чыйдурды» дип хаталы язылган.
[3] Кулъязмада «таншаны» дип хаталы язылган.
[4] Кулъязмада «нишанларыны» дип ялгыш язылган.
[5] Кулъязмада текстка өзеклек кергән. «Икенче текст»ның бу урынында «Җәдай хан сордылар: – Әй, Тарағай! Сәнең айлу-йөклү хатуның барму? Ул Тарағай әйде: – Бәли, бардур» дип язылган.
[6] Кулъязмада «нәрсәрлә» дип хаталы язылган.
[7] Кулъязмада: Тәғәһәнең.
[8] Бу җөмлә «Икенче текст»та бу рәвешле: «Әмма Хақ Тәғаләнең тәқдире нитәк булса – андағ булур».

тиделәр[9], «үлтүрүр булса, ул қорсағындағы баласыны тезләб үлтүрүң, анасы үлмәсүн!» – тиде.

Андин соң // *(19а кәгазь)* хатунны йықыб, андағ тезләделәр[10] кем, исеосы китте, үлә қалды.

Андин йәнә хан әйде:

– Имди баласы дәгел, анасы һәм үлде.

Болар андин соң бу хатунны арбаға салыб китделәр. Андин Җәдай хан қурқунычындин қотулдым тиб торур ирде, ханлықға[11] мәғрүр-мәшғүл ирде.

Андин йәнә бер анча көнләрдин соң ул мескин тезләб имгәнгән[12] хатунның күзе йаруды[13], бер ир уғлан туғырды. Ул уғланны алыб бақтылар ирсә, бер айақы ақсақ ирде. Анда әйделәр кем, «ошбундай имгәкүндин үлмәй қотулуб туғдуң, җаның тимер икәндүр!» – тиб әйделәр. Ул уғланның атыны ул сәбәбдин Ақсақ Тимер қуйдылар.

Имди [хәзрәти Ақсақ Тимернең асылы-төбе барлас дигән ру булур ирде, нәселендә-руында ханларға җәйан уғул] ирде[14]. Андин соң йәнә Ақсақ Тимернең атасы һәм анасы үлде, йәтим қалды. Асрарға, күрәргә лайуқ һич кеше булмады, алмады. Ахыр, үзе йөрүрдәй булуб, ир йиткәндин соң қазақ чықыб, йалғузы Шымақ[и] шәһәрегә барды, бер анча йөрде, Шымақида бозаулар көтмәгә җалға инде. Үзегә үзе кебек үксүз-йәтим йегетләрне ийәлән[д]үрде, алты-йите уғул бер булуб, һәр[15] көн бозау көтәр ирделәр, тәқи уйнар ирделәр.

Анда Ақсақ Тимер көнләрдә бер көн бозуқ // *(19б кәгазь)* кәшанә төбүндә йалғуз тайаныб торур ирде. Бер айақ[ы] ақсақ, тәқи бер күзе суқур ирде бер қырмысқа килде, тәқи ул кәшанәгә тырмашыб менәргә[16] йабушды. Бер анча йуқару менде, йықылды. Андин соң йәнә, һиммәтләнеб, тәқи йабушд[ы], тырмашыб кәшанәнең башыға менәйен, чықайын тигүнчә йәнә түбән йықылды. Бу хәзрәти Ақсақ Тимер қырмысқаның бу эшегә таңға қалыб, қараб торур ирде. Ақсақ қырмусқа, ғарләнмәзен, йәнә өчүнче

[9] «Өченче текст»ның әлеге урынында: «Анда Җәдай хан үзе әйде: «Мәне бу хатунның қорсағындағы бала...» рәвешендә язылган.
[10] Кулъязмада «қызладылар» дип ялгыш язылган.
[11] Кулъязмада «халлықға» дип хаталы язылган.
[12] Кулъязмада: иткән. «Имгәнгән» сүзе «Өченче текст»тан алынды.
[13] Кулъязмада «сүзе бармаз» дип ялгыш язылган.
[14] Бу җөмлә кулъязмада «Имди хозыр Бәғйан уғылы ирде» рәвешендә бозылыб һәм кыскартып язылган. Мондагы квадрат җәяләр эчендәге өлеше «Икенче текст»тан алынды.
[15] Кулъязмада «бер» дип ялгыш язылган.
[16] Кулъязмада «менәзғә» дип хаталы язылган.

мәртәбә кәшанә башыға менәрғә йабушды. Ахры бара-тырмаша торғач кәшанәнең түбәсенгә чықыб китде.

Ул қырмысқадан бу хәзрәт күрде – бу зәғиф, айақсыз, күзсез қырмысқа һиммәтләб түбәсенгә менде, йуқары[17] чықды. «Мән һәм һиммәт берлә хан булуб[18], ил-көн, шәһәрләр алыб, урдалар[19] алсам, һич таң-ғәҗайеб булмас, әгәр Тәңре Тәғалә бойурса» тиб, күңелүнә бу фикерне салыб йөрүр ирде.

Тәқи ул уғланлар берлә уйнар ирде. Көнләрдә бер көн Ақсақ Тимер әйде:

– Әй, йегетләр! Килеңләр, бер йиргә бер нәрсә қуйалың. Ул қуйған нәрсәне кем элек йөгерүб йитеб алса, аны арамызда хан қыйлайық! – тиде.

Анда ул йегетләр әйделәр:

– Андағ булсун, – тиб, алысға бер нәрсәне алыб қуйдылар. Тәқи барча уғланлар йөгү[ре]шделәр. Ақсақ *// (20а кәгазь)* Тимер һәм йөгерүр ирде[20]. Йөгүрүб уғланлар шайы бара алмады, аның өчүн кем – ақсақ ирде. Андин бер уғлан йөгүрүб, «ул нәрсәне мән алайын, мән элек хан булайын» тигүнчә, андин борунрақ ул нәрсәне Ақсақ Тимер бүрке берлә ташлаб орды. Тәқи әйде:

– Әй, йегетләр! Сезләрдин борун мән йитдем, мән хан булайын! – тиделәр.

Ул берәве әйде:

– Йуқ, сәндин борун мән йитеб алдым!

Анда Ақсақ Тимер әйде:

– Һай, синең қулуң йиткүнчә, мәнең башым йитде!

Болар бу сүзне әйтеб бәхәсләшеб торурлар ирде, бер ақ сақаллығ қарт кеше килде. Болар ул қартқа эшләрен сөйләделәр, «Ханлық қайумезгә тигәр?» – тиделәр.

Анда ул қарт әйде:

– Әй, йегетләр! Мәнем сүзүмне тотармусыз? – тиде.

Болар әйделәр:

– Әй, баба! Сән һәрнә дисәң, эшемезне сәнгә салдуқ, – тиделәр.

Анда ул қарт әйде:

– Әй, йегетләр! Бу ақсақ уғулның сезнең қулуңыздан борун башы йитебдүр, моны хан қылуңыз! – тиде. – Сүз моның сүзедүр! – тиде.

Анда үзгә йегетләр әйделәр:

---

[17] Кулъязмада «боқары» дип хаталы язылган.

[18] Кулъязмада бу сүздән соң ялгыш «ике» сүзе язылган.

[19] Кулъязмада «урдылар» дип ялгыш язылган.

[20] Кулъязмада «имди» дип ялгыш язылган.

– Әй, баба! Хуш, имди қыйлайық, – тиделәр. Ақсақ Тимерне үзләре араларында хан қылыб уйнар ирделәр.

Йәнә көнләрдә бер көн Ақсақ Тимер әйде:

– Әй, йегетләр! Һәркем ошбу көтә торған бозаулардин *// (20б кәгазь)* бер бозауны суйуб, барчамызға йидерсә, арамызда аны хан күтәрәле, – тиде.

Анда йәнә үзгәләре қыйыб[21] бозауны суйа алмадылар. Ақсақ Тимер бозауны суйды, бешүрде, ул уғланларға йидүрде[22]. Ашадылар, андин соң Ақсақ Тимерне үз араларында хан күтәрделәр. Андин соң қайтыб авы[л] ларына килделәр, бозау ийәсенә әйделәр:

– Бозавыңны бүре ашады, – тиб[23].

Ул һәм нәрсә димәде, «бүрегә бойурған икәндүр» [тиде].

Андин соң бер көн Ақсақ Тимер уғланларға әйде:

– Әй, йегетләр! Безләр қарақчы булалық, базаркянләрне, сатучыларны тоталық, малын алайық! – тиде.

Анда бу уғланлар әйделәр:

– Хуш булсун! – тиделәр.

Анда Ақсақ Тимер әйде:

– Сезгә сүзүм улдур кем, имди бу кичә һәрқайуңыз һич үзгә нәрсә алмаңыз, мәгәр йау қоралын қуймаңыз! – тиде.

Анда бер бозық кәрвансарай бар ирде, болҗалны[24] анда қуйдылар. Төннең йарымында килеб бер-берсенә йулукты[лар]. Қайсы көбә кийеб, мылтық алыб, қайсы уқ-садақ берлә қылыч алыб, ушал Шымақи шәһәрендән чықыб киттеләр. Һиндустан[25] шәһәренең йулын сақлаб йаттылар, узған-барған, сүтүчеләрне, асламчыларны басыб, малларын алур ирделәр, олу *// (21а кәгазь)* қарақчылық қылдылар.

Азған-тузған, ата-анадан бизгән уғланлар, байдан қачқан қоллар аңар җыйылдылар[26], қушулдылар. Һәркем тыщдан[27] килеб аңа қушулса, аңар лайық алабалар бирә башладылар. Базаркянләрне, сатучыларны[28] қырдылар, қол-қотанны йулдаш қылдылар, бер ике-өч йөз кеше булдылар[29].

---

[21] Кулъязмада «қайтыб» дип ялгыш язылган.
[22] Кулъязмада «бойуруды» дип хаталы язылган.
[23] Кулъязмада бу сүздән соң «әйде» дип ялгыш язылган.
[24] Кулъязмада «бүгәлне» дип хаталы язылган.
[25] Кулъязмада «Һиндсәван» дип хаталы язылган.
[26] Кулъязмада «чилвыйлар» дип хаталы язылган.
[27] Кулъязмада «тышуан» дип хаталы язылган.
[28] Кулъязмада «баразкянләрне, су сақучыларны» дип хаталы язылган.
[29] Кулъязманың бу урынында текст бераз кыскарган. «Икенче текст»ның әлеге өлешендә түбәндәгечә ике җөмлә бар: «Узған-барғанны талар ирделәр, йул көллисе киселде. Кәрван халқы йөрүмәз булдылар».

Анда Һиндус[т]ан бадишаһ[ы] Җәда[й] ханға хәбәр төште – «йулны қарақ сақлайдур, тиб, – кешеләрне йөретмәйдүр» тиб. Андин соң Җәда[й] хан илче йибәрде, өч йөз кеше берлә килеб Ақсақ Тимергә әйде:

– Әй, Ақсақ Тимер! Нә өчүн сән мондағ уғурылық қыйлурсән, йулларны бағларсән?

Анда Ақсақ Тимернең чирүе[30] у[л] килгән [илче]башын үлтүрделәр, үзгәсене барчасын йулдаш қылдылар[31], күб ағыр алаба бирделәр.

Бу хәбәр йәнә Җәдай ханға ишетүлде. Үртәнде, көйде, йәнә икенче мәртәбә илче йибәрде. Ул икенче[32] килгән илченең башын йибәрделәр, үзгәләрен[33] алыб қалдылар, йулдаш қыйлдылар. Җәдай хан йәнә өчүнче илче йибәрде, «ул қарақларға алтун-көмүш алуб барайын, узған-барғанларға, базаркянләргә тимәсүн» тиб.

Анда болар әйделәр:

– Имди Җәдай ханның хәзинәсендән безнең хәзинәбез күбдүр, кирәк булса бездән алсун! – тиделәр.

Андин йәнә бер анча көнләрдин *// (21б кәгазь)* соң Җәдай хан үзе чирүен[34] йыйыб киләдүр тиб, Ақсақ Тимергә хәбәр төште. Анда Ақсақ Тимер белүргә қаршы шымчы йибәрде, хан киләмү иркән тиб. Ул шымчы барыб күрде – Җәда[й] хан килә йатур. Шымчы барыб анларның арасында керде, Җәдай хан утуз кеше берлә үзе элгәре килүр ирде. Бу барған шымчыны күрделәр, монларға йәнә сордылар:

– Һай, йулда қарақ күрдеңмү? – тиб сорды.

Бу әйде:

– Йуқ, һәргиз күрмәдүм, бу йулдан һич шиксез[35] йөрүң, қарақ йуқдур, – тиде.

Болар[36] моның бу сүзене бақыб, «қарақ йуқ ирмеш, безнең килгән хәбәремезне ишетеб қачқандур» тиделәр. Элгәрү узуб киттеләр.

Бу шымчы үз йоруғына киттеләр. Андин айырылыб, аулақға чыққандин соң қачды, Җәдай ханның утуз кеше берлә килә йөрүгәнен Ақсақ Тимергә килеб әйде.

Анда Ақсақ Тимер әйде:

– Алай булса, тиз имди утуз түәгә йөк йөкләндүрүң! – тиде.

Шул уқ заман утуз түәгә йөк йөкләделәр. Ақсақ Тимер Җәдай ханның

---

[30] Кулъязмада «чүрүене» дип ялгыш язылган.
[31] Кулъязмада «қылыйдылар» дип хаталы язылган.
[32] Кулъязмада «илчегә элек» дип ялгыш язылган.
[33] Кулъязмада «үзгәләренә» дип ялгыш язылган.
[34] Кулъязмада «чирдин» дип ялгыш язылган.
[35] Кулъязмада «тиңез» дип ялгыш язылган.
[36] Кулъязмада «боларның» дип ялгыш язылган.

[килә] торған йулы берлә каршу йөрделәр. Җәдай хан төшүб йатур ирде, болар каршу йөрделәр. Җәдай хан боларға алысдан[37] сүзләште:

– Нә кешеләрсез? Йулда қарақ күрдеңмү? – тиде.

Болар әйделәр:

– Йуқ, һич күрмә- *// (22а кәгазь)* -дүк, – тиделәр.

Андин соң хан боларның қашыға килделәр. Анда болар әйделәр:

– Һай, сезләр нә кешеләрсез?

Анлар әйделәр:

– Безләрне сорсаңыз, без ханбыз – Җәдай, қарақларны эстәй чықдуқ, – тиделәр.

Анд[а] болар әйделәр:

– Андағ[38] булсаңыз, без сатучылармыз, бездән малымызның тамғасын алыңыз, безгә һәр йул йөрүргә, сату қылурға йахшы булур, – тиделәр.

Җәдай хан бу сүзгә туқтаб тик торды, бойурды:

– Тамғасын алыңлар! – тиб. – Болар безгә, шайәт, бер асыл-таңсуқ мал алыб килгәндүр, – тиде.

Андин соң Җәдай ханның кешеләре йөкләрне ақтарыб, тамға алайын тигүнчә Ақсақ Тимернең кешеләре берен-берен тотуб үлтүрделәр. Хәзрәти Мир Тимер[39] үзе Җәдай ханны тотты[40] үлтүрүр өчүн. Әйде:

– Аһ, әй, Ақсақ! Мән сәнгә йахшылық қыйлдым, сән мәнгә йаманлық қыйлурсән, – тиде.

Анда Ақсақ Тимер әйде:

– [Сән ғафилсән, мән – ғафил дәгүлмән! Мән үзүмгә йаманлық қылмазмән][41], мән үземгә йахшылық қылурмән, – тиде. Үлтүрде, башын кисде. Андин соң Ақсақ Тимер үзе Һиндустан шәһәренә барыб, хан булды. Тәқи бу қалған чирүегә чабкун[42] йибәрде, «үзгә[43] йул берлә килсүнләр!» тиб. *// (22б кәгазь)* Чирүенә хәбәр төшде ирсә, рәван килеб анлар һәм шәһәргә инделәр. Андин йәнә Җәдай ханның артындин қалған чирүе бу хәбәрләрне, бу эшләр белмәйен, «ханымызға анда йитәрмез»[44] тиб бара торғач, йитә

---

[37] Кулъязмада «алсун» дип ялгыш язылган.

[38] Кулъязмада бу сүзнең алдында ялгыш «безне» сүзе язылган.

[39] Кулъязмада «йәртәм» дип хаталы язылган.

[40] Кулъязмада «тотутты» дип хаталы язылган.

[41] Квадрат җәяләр эчендәге бу җөмләләр кулъязмада «Ғафил дәгүлмән, ғафилмән. Үзенгә йаманлық қылмазсән» рәвешендә, мәгънәләре буталчык итеп язылган. Дөрес вариант монда «Икенче текст»тан алынды.

[42] Кулъязмада «җабықдан» дип хаталы язылган.

[43] Кулъязмада «үзегә» дип ялгыш язылган.

[44] Кулъязмада «җанымызға анда нитәрмез» дип ялгыш язылган.

алмай, қайттылар. Ханларын йуғалтыб килделәр ирсә, «шәһәрне Ақсақ Тимер алыбдур» тиб, нәрсә итә белмәделәр, Ақсақ Тимергә бағындылар.

Имди Ақсақ Тимер Һиндустан шәһәрен ошбулай алды тиб әйтүрләр. Әмма аңа Тәңре Тәғалә[45] үзе йулдаш булғандур шәһәрләр-йортлар алмақға, урдалар вәйран булмақлықға аны сәбәб қылғандур. Һәр нә йахшы-йаман эш Тәңре Тәғалә әмере-тәқдире берләдүр. Аның бойурығындан тыш һич булмасдур.

Андин соң ул Ақсақ Тимер ләшкәре[46] берлә йаулаб алмаған йортны қуймады. Тәңре Тәғаһә аңа йар булды ирсә, дөнйаны үзенгә бақтурды.

Йәнә тәқи йәшерүн қалмасун кем, хәзрәти Ақсақ Тимернең ике уғылы бар ирде: берсе – Сафый дигән, икенчесе – Уфый дигән ирде. Олу уғылы Сафыйны хан үз урыныға Һиндустан шәһәрегә ханлықға қуйды.

Хәзрәти Мир[47] Тимер үзе ләшкәре берлә Истанбул шәһәрен алурға *// (23а кәгазь)* йарағланды. Авыр чирү жыйдурды[48], күб-күб филләргә, тәқи күб-күб түәләргә хәзинәдән маллар, тәқи күб-күб қораллар йөкләтде. Сансыз-сақышсыз ләшкәр берлә Һиндустан қәвем[е] берлә тәбрәделәр, тағ-таш тулуб йөрделәр. Мисыр шәһәрегә килделәр, о[ру]шуб-қырылушуб, ахры бар, аны алдылар.

Андин йөрүб Истанбул шәһәрен алғалый килделәр, бер йирдә төшделәр, қундылар. Сафлар бағлаб, орушқа хәзерләнеб тордылар.

Әл-қыйсса

Ул заманда Истанбул бадишаһының аты Шаһ-солтан дигән ирде, аңар хәбәр төшде кем, «Ақсақ Тимер шәһәреңне алғалый, урдаңны хәраб қылғалый [киләдүр]» тиб. Хан Шаһ-солтан һәм ағыр чирү хазир қыйлыб йарағландурды, Ақсақ Тимергә қаршу чығарды[49]. Ике чирү килеб бер-берсигә қаршу қундылар. Аларға анда күб қаравыллар йасаб қуйдылар, сафлар бағлаб тордылар. Иртәгесен ике чирү бер-берсенгә қаршу[50] андағ орышдылар кем, Шаһ-солтанның чирүен Ақсақ Тимер чирүе қырдылар, қачурдылар. Андин килеб Истанбул шәһәренә берекләнделәр[51]. Ақсақ Тимер чирүе берлә килеб шәһәр хисар қылды, йәғни *// (23б кәгазь)* қамады.

---

[45] Кулъязмада бу урында һәм моннан соңгы җөмләдә: Тәғәһә.

[46] Кулъязмада «шөкере» дип ялгыш язылган.

[47] Кулъязмада «Йәр» дип хаталы язылган.

[48] Кулъязмада «җирүде» дип хаталы язылган.

[49] Кулъязмада «чығарур» дип ялгыш язылган.

[50] Кулъязмада бу сүз ялгыш ике мәртәбә язылган.

[51] Кулъязмада текстның «Ақсақ Тимер чирүе қырдылар, қачурдылар. Андин килеб Истанбул шәһәренә берекләнделәр» өлеше ялгыш шушы абзацның иң башында язылган.

Шәһәр ғәйәт би[йе]к шәһәр ирде, биш йыл қамаб торды, һичбер кешесен ала алмады. Шәһәре сигез қабат ирде, һич алурға йурығын табмадылар.

Имди Истанбул шәһәренең сыйфаты ошбудур.

Бу шәһәрне Ақсақ Тимер оруш-туқуш берлә алмады. Ахры, ошбундағ хәйлә төзде кем, үзе[не] сырхау қылды, тәнегә сары зәғферан сөртде: тәне, күзе, башыны сап[52]-сары булды. Андин соң Шаһ-солтан ханға илче йибәрде мондағ сүз берлә кем: «Әй, Шаһ-солтан![53] Имди беләсән, әҗәл ирешде, тәмам тәнем зәғферан тик булды гөнаһым шомлуқындан. Имди сәндән үтүнәмән кем, мән бу эшләрне, орушмақлықны қуйдум. Рәхим қыйлыб, *// (24а кәгазь)* сез минем берлә бәхилләшәсәң ирде?!» – тиб, хат йибәрде.

Ул илче килеб шәһәр қапусында торды, илчелеген белдүрде. Андин ул хатны алыб Шаһ-солтанға илттеләр[54]. Шаһ-солтан қараб күрде, «шайәд йалғандур, хәйләдүр» тиб, ышанмадылар. Ул һәм моның сырхаулықыны белмәк өчүн кешесен йибәрде, «Барғыл, қараб күргел!» тиде.

Андин Шаһ-солтанның йибәргән кешесе Ақсақ Тимернең чатырыға килеб керде кем, Ақсақ Тимер сары зәхмәте берлә хәлсез улуб йатур.

Ақсақ Тимер әйде:

– Әй, илче! Минең хәлем усалдур, – тиде.

Андин ул йибәргән кешесе Шаһ-солтанға килеб сөйләде:

– Сырхау улмышдур, хәл эчендәдүр, – тиде. – Ғәйәт илтимас тиде кем, «Рәхим итеб килсә, бәхилләшүр ирдем?!» – тиб әйтүр ирде.

Солтан аның сүзенә ышаныб, шәһәрнең тәмам қапуғларын ачтурды, үзе һәм[55] ләшкәр берлә Ақсақ Тимергә килде. Күрешүб сүзләшә торур иркән, сырхаулықындин тора салыб Шаһ-солтанны тотты, үлтүрде. Килеб ләшкәре-чирүе шәһәргә инделәр. Бу хәйлә берлә ушал шәһәрне һәм алдылар. Ул урданы[56] һәм үзегә бақтурды. Бер анча йыллар анда торды.

Андин йәнә чирүен йараштуруб, *// (24б кәгазь)* чирүе берлә Шымақиға килде, аны һәм алды, үзенгә бағындурды.

---

[52] Кульязмада «сәлә» дип хаталы язылган.

[53] Кульязмада текстның бу урынында 6 юл текст күләмендә буш урын калган. Ул бу әсәрнең башка кульязмаларындагыча, Истанбул шәһәренең схематик рәсеме өчен калдырылган булуы аңлашыла (бу абзацтан алдагы «Имди Истанбул шәһәренең сыйфаты ошбудур» дигән җөмлә шуңа дәлил). Тик, ни сәбәптәндер, кала рәсеме ясалмаган.

[54] Кульязмада «илнеләр» дип хаталы язылган.

[55] Кульязмада «һәр» дип ялгыш язылган.

[56] Кульязмада «ураданы» дип хаталы язылган.

Андин узуб йөрүб, Хаҗитархан[57] шәһәрегә килде, орышуб-туқуб Хаҗитарханны[58] һәм алды, бақтурды. Анд[а] биш-алты йыл торды.

Андин йәнә Болғар шәһәрегә килүргә йарағланды, күб-күб қатырләргә, кимәләр берлә шәһри Болғарны алғалый килүргә кимәгә менде. Қайусы ошбу Идел[59] суының тыш йағындан килделәр, чирүенең санын Аллаһдин ғәйре кемсә белмәз ирде.

Ушда анлар мондағ олуғ чирү берлә килмәкдә. Әмма ул дәвердә, ул заманда Болғар шәһәрендә ханлары Ғабдулла дигән ирде. Ғабдулла ханға хәбәр ирешде кем Ақсақ Тимер киләдүр тиб. Шул заман Ғабдулла хан ләшкәр йығдурды, ағыр чирү хәзерләб қаршу йөрде. Ахыр, бер[60]-берсигә йулықушуб қаты оруш қылдылар. Ақсақ Тимернең орышына түзмәделәр, сындылар[61]. Килеб Болғар шәһәрегә килделәр, үлгән үлде, қалған шәһәргә берекләнделәр.

Ақсақ Тимер килеб, шәһри Болғарны йите йыл қамаб торды. Тарих йите йөздә йегерме йылда, зөлхиҗҗә айының йегермесендә ирде – шәһри Болғарны алдылар, хәраб қылдылар. Йөз дә йегерме түрт олуғ бикләр бар ирде, анларның тәмамысын қырдылар. Һәркайсының кә-әмсалел-лөә-лөә *// (25а кәгазь)* әл-мәкнүн тик хатунларыны Ақсақ Тимер йәсир қылды. Ул бикlә[р] эчендә түрт олуғ бикләре бар ирде, асыл шаһзадәләр ирделәр: бер[е] – Иқбал бик, йәнә бере – Қол Ғәли бик, йәнә бере – Хәваш бик, йәнә бере – Мырқашый бик дирләр ирде, тәмамын һәлак қыйлдылар. Күб-күб хәлайықлар һәлак булды. Ғабдулла ханны үлтүрделәр.

Әмма Ғабдулла ханның ике уғылы бар ирде, берсе – Алтунбик, икенчесе – Ғалимбик дигән ирде. Җаудин качуруб[62] қалған кешеләр Алтунбик берлә Ғалимбикне урман төбегә илтеб йәшүрделәр. Бере йите йәшендә, вә берсе туқуз йәшендә ирделәр. Йахшы асрар ирделәр.

Андин соң Ақсақ Тимер шәһри Болғар[ны] вәйран қылыб хәраб[63] қылғандин соң Бүләр шәһәрегә [килде] чирүе берлән. Бүләр шәһәренең қаршусыға килеб улар ур қазыб йатдылар, оруш-туқуш қыйлмадылар. Ул вақытта[64] Бүләр шәһәренең ханының аты Самәт дигән ирде, көбәсе «бозқалбақ» дигән ирде, халқы барач дигән халық ирде.

Бараҗ халқының әүвәл замандағы борунғы йорты ошбу Зәй тамағында

---

[57] Кулъязмада «Чачи Тимерхан» дип хаталы язылган.
[58] Кулъязмада «Чачи Тарханны» дип хаталы язылган.
[59] Кулъязмада «ошпу Ул» дип хаталы язылган.
[60] Кулъязмада «бара» дип ялгыш язылган.
[61] Кулъязмада «менделәр» дип ялгыш язылган.
[62] Кулъязмада «чаудин қалғуныны» дип хаталы язылган.
[63] Кулъязмада «хәйран» дип ялгыш язылган.
[64] Кулъязмада «вақту» дип хаталы язылган.

ирде, алыбларның заманыда бер Бараж атлығ аждаһа[65] йылан килде. Ул шәһәрнең халқыға көч // *(25б кәгазь)* қыйла башлады. Чықыб аждаһа берлә суқушдылар, йиңә алмадылар[66]. Ахыр, үзләре шәһәрен салыб қачтылар, Болғар[67] шәһәренең йақыныға барыб, Бүләр суының өстегә йорт-шәһәр салдылар. Ул шәһәрләрегә Бүләр тиб атадылар, ул сәбәбдин аны «бараж[68] халқы» тиб әйтүр ирде, оранлары[69] «бараж» ирде.

Анда Самәт хан әйде:

– Аһ, әй, бараж халқы! Борун олуғы бабаларымыз Баражның зыйанындин қачыб, шәһәрләрен салыб ошбунда килебләр, мәқам-йорт тотублар. Имди Баражыдин көчлүрәк Ақсақ Тимер килде, шәһәремез қаршусыға төшде. Нә қылурмыз? – тиде.

Анда бараж халқы әйделәр:

– Әй, ханым! Сез белүрсез, ирек сезнеңдүр! – диделәр. – Һәрнә дисәң, иркем[ез] йуқдур, – тиделәр. – Әмма бойурсаң, Ақсақ Тимер ләшкәре берлә һәм орышурбыз – йә үлдүрү[р]мез, йә без үләрбез! – тиделәр.

Анда Самәт хан әйде:

– Имди мәнем қашымда вәли[70] кеше бардур, андин сорайын, ул нә бойурса, аның сүзендин чықмазмыз, – тиде.

Ул бер вәли кешене алдуруб сордылар, тәқи әйделәр:

– Әй, безнең олуғымыз! Имди безләр ошбу өстемезгә, шәһәремезгә килгән Ақсақ Тимүр берлә оруш қыйлалықму? – тиде.

// (26а кәгазь) Анда ул вәли әйде:

– Хуш, қарайын, – тиб, бер манараның башыға менде. Тәқи Ақсақ Тимернең чирүе тарафыға қарады ирсә, күрде кем – хәзрәти [Хозыр] Ақсақ Тимер чирүендә бергәдүр. Андин соң манарадин төшүб, хан Самәтнең қашыға килде, тәқи әйде:

– Әй, ханым! Орушға рөхсәт йуқдур! Хәзрәти хужаи Хозыр ғәләйһиссәлам[71] аның чирүендә бергәдүр. Тәңре Тәғаләнең[72] бойурықынға муйун сонмақ кирәк, қабқаларны ачтурғыл! – тиде ирсә, ул хан, тәқи бараж халқы йығлашдылар. Тәқи әйделәр:

---

[65] Кулъязмада «ардаһа» дип хаталы язылган.
[66] Кулъязмада бу җөмләдәге «аждаһа» сүзе «ардаһа» дип хаталы язылган һәм җөмлә ахырындагы сүздә «-ылар» кушымчасы ике мәртәбә ялгыш кабатлап язылган.
[67] Кулъязмада «Бүләр» дип ялгыш язылган.
[68] Кулъязмада: Бүләр.
[69] Кулъязмада «урунлары» дип ялгыш язылган.
[70] Кулъязмада «ул» дип ялгыш язылган.
[71] Кулъязмада: «хәзрәти ғһм».
[72] Кулъязмада: Тәғәһәнең.

– Нә қылмақ кирәк, Хақ Сөбханәһә вә Тәғаләнең[73] хөкеменә муйун сонмақ кирәк, – тиб, шәһәрнең тәмам қабқасын ачқайлар, ирек[74] салдылар, орушмадылар.

Андин хәзрәти Ақсақ Тимер чирүе берлә шәһәргә инделәр, халқыны қырдылар.

Әмма анда Ақсақ Тимер кичә үзе шымчы булуб, төсене әверүб, хәлайықларның йечегә кереб, сынай йөрүр ирде. Тәқи әйтүр ирде:

– Ай, хәлайықлар, йегетләр! Бу бөлүклүк, бу қырғын безләргә кемдин торур? – тиб сорар ирде.

Анда ул ултурғанлар әйтүр булсалар: «Безне [Ақсақ бөлдүрде, аның шомлуғындан бөлдүк, жуйулдуқ» дигән кешеләрне][75] иртәгесен тәмам руы-тамуры берлә һәлак қылур ирде.

// (26б кәгазь) Һәркем гөнаһыны үзендин[76] белеб әйтүр булса ирде «бу бөлүклүк үз шомлуғымыздан безгә йитте» тиб, аны руы берлә үлтүрмәй, таламай йибәрүр ирде.

Әл-қыйсса

Кичәләрдә [бер кичә] хәзрәти Ақсақ Тимер шымчы булуб бараж халқының арасығa кереб әйде:

– Әй, бараж халқы! Бу бәла сезләргә қайдин килүр?

Анда анлар әйделәр:

– Кемдин ирдүкен белмәймүсән? Убур Ақсақ Тимер килде, безне қырды, бөлдүрде, – тиделәр.

Анда ул кичә ул жыен[77] эчендә бер олуның ғақыллығ, услығ тол қалған хатыны[78] бар ирде, ул әйде:

– Әй, йегетләр! Бу эшләрне, бу бөлүклекләрне үз гөнаһымыз шомлуғындан беләлик. Ул Ақсақ Тимер нә қылур ирде? Тәңре Тәғаләнең тәкдиредүр! – тиде.

Ул хатунның ирүе Жадәш бик дигән ирде, ул хәзрәти Ақсақ Тимер килмәсендин борун[79] үлгән ирде. Ул Жадәш бикнең ике уғылы бар ирде, берсе – Инсан, берсе – Ихсан дигән ирде.

Ул кичәнең иртәгесен Ақсақ Тимер *// (27а кәгазь)* ул хатунны

---

[73] Кулъязмада: Тәғәһәнең.
[74] Кулъязмада «иркек» дип хаталы язылган.
[75] Квадрат җәяләр эчендәге текст өлеше кулъязмада төшеп калган. Монда «Икенче текст»тан алынды.
[76] Кулъязмада «үзбәндин» дип хаталы язылган.
[77] Кулъязмада «чыйын» дип хаталы язылган.
[78] Кулъязмада «хан» дип ялгыш язылган.
[79] Кулъязмада «бүлән» дип хаталы язылган.

уғланлары берлә қашыға алдурды. Болар нә эшкә алдурғанын белмәйләр, «безләрне үлтүрүргә» тиб, йығлашыб килделәр. Анда Ақсақ Тимер ул хатунға әйде:

– Сән гөнаһыңны үзеңдин белүрсән, «һәр эш безнең үз шомлуғымыздан» тиб әйтүрсән. Имди бу көндин соң сәне тәмам уғылуң-қызың, қәрендәшләр[ең] берлә йарлықадым. Һәрқанда сәүсәңез, ул тарафға киткәйсез! – тиде. Үзе һәм тәмам чирүегә йар[80] салды:

– Бу кешегә тимәңләр, малыны таламаңлар, һич нәрсәсегә зыйан тигүрмәңләр! – тиб.

Ул бу бөлүклүкне, гөнаһны[81] үзендин белгән өчүн тәмам уғылы-қызы, қәрендәшләре берлә йарлықаб йибәрде.

Андин соң ул бик[ләр]: бере – Инсан, берсе – Ихсан киңәш [итеб], күчмәгә тиб [нийәт] қыйлдылар. Инсан бик әйде:

– Әй, анамыз! Ошбу Иделнең эче йүнегә[82] – Тағ [йирегә] барурмыз, анда мәқам-йорт тотармыз, ануң[83] өчүн кем, ул йирдән бәрик йир йуқдур, – тиде.

Анасы һәм аның сүзен йаратыб иде. [...][84] Айырылдылар, тағ тарафыға китде. Анасы һәм аның берлә анда барыб, Гөбенә дигән[85] суның // *(27б кәгазь)* буйунда мәқам тотды. Ул Инсандин уғылы туғды, [атын] Сөләйман қуйды. Сөләйман уғылы Нурдәүләт, Нурдәүләт уғылы Нурхәсән, Нурхәсән уғылы Ну[р]әбдал, Нур[ә]бдал уғылы Қотуш, Қотуш уғылы Махтым, Махтым уғылы Икнәл, Икнәр уғылы Мәхмүд, Мәхмүд уғылы Мөхәммәдхуҗа, Мөхәммәдхуҗа уғылы Тәвәккәл, Тәвәккәл уғылы Пирмөхәммәд, Пир[мөхәммәд] уғылы Җинтый, Җинтый уғылы Йәш, Йәш уғылы Үлмәс, Үлмәс уғылы Чуқаш.

Әмма Ихсан бик Тағ тарафыға мәйел қыйлмайын, Зәйгә килде. Ихсандин уғул туғды, атыны Әлмөхәммәд қуйды. Әлмөхәммәд уғылы Қаймөхәммәд, Қаймөхәммәд уғылы Туқмөхәммәд, Туқмөхәммәд уғылы Атлақ, Атлақ уғылы Шәммас, Шәммас уғылы Туғый, Туғый уғылы Сәман, Сәман уғылы Ындачы, Ындачы уғылы Тәкәнәс, Тәкәнәс уғылы Базаргән ирде. Тамғалары «қуш [кәша]н», оранлары «бараҗ» торур.

---

[80] Кулъязмада «бар» дип ялгыш язылган.
[81] Кулъязмада «кәндемне» дип ялгыш язылган.
[82] Кулъязмада «бүнегә» дип хаталы язылган.
[83] Кулъязмада «идүк» дип ялгыш язылган.
[84] Монда кулъязмада текстка өзеклек кергән. Әсәрнең әлеге урынында «Алтынчы текст»та болай язылган: «Әмма энесе Ихсан ул тарафқа барурға өнәмәде, иске бабаларым йортына барурмән, анда мәқам-йорт тотармән», тиде. Инсан бик әйде: «Мән ул йиргә барурмән, анда мәқам тотармән».
[85] Кулъязмада «дигәр» дип хаталы язылган.

***

Имди йәнә сүзне [башдин сүзләйәле. Ул хәзрәти Ақсақ Тимүр][86] Бүләр[87] шәһәрен вәйран қылгандин соң Мәскәү тарафыға китде. Анда ләшкәр берлә барыб, Уладимир[88] дигән гәүр қаласыға йитделәр, оруш қылғай нийәт[89] қыйлды. Гәүр һәм чирүен үз қаласына җыйдурды[90]. Хәзрәти Ақсақ Тимер барган вақытда кяфер-урус гәүрнең ханы Михайла[91] атлығ ирде. Хәзрәти Мир Тимүр шәһәрләр алыб, аңа // *(28а кәгазь)* барған хәбәрләре ирешүб, гәүр қаты қурқуғында ирде. Хәзрәти Мир Тимүр гәүрнең қаласы Уладимүргә йитеб ирде, хәзрәти хуҗа Хозыр ғәләйһиссәлам[92] килеб Ақсақ Тимүргә әйде:

– Халә бу кяфер берлә орушқа, тәқи қырарға вәғдә ирешмәйдүр! – тиб хәбәр бирде. Әмма бу кяфергә кәрамәтеңне күрсәткел! – тиде ирсә, хәзрәти Ақсақ Тимер шул заман тора салыб, өч йәшәр тай берлә кяфер тарафыға атды. Хақ Тәғаләнең қөдрәте[93] берлә, ул ташлаған тай барыб, кяфернең таш манараны уртара өзүб, бер чақрым йир барыб төште. Төшкән йире су булды.

Андин соң кяфергә һәйбәт орунды[94]: қулы-ағызы тотулды, қурқудан битләрендә қаны қалмады[95].

Андин соң Мир Тимүр орушмай (вәғдә ирешмәгән өчүн) чирүе берлә қайттылар. Қайтыб Бохара шәһәрегә баруրға йүнәлделәр. Килә йөрүгәнендә қайа йирләрендә[96] Амәт, Самәт дигән ике ханға хәбәр төшде «Ақсақ Тимер киләдүр» тиб. Ту бийә суйуб, халқын йыйыб, «қайу тарафға күчәйек?» тиб киңәш қылды. Анда ул халық уңмаслық // *(28б кәгазь)* қылыб, берәү атын мақтады, берәү этен мақтады, берәү хатунын мақтады. Бешкән ит-аш ашалды, киңәш булмады, халық уғылы тарқалды. Анда Кинҗә дигән берәү йығлаб әйде:

– Әй, қалтақлар! Үзе ала сан кеше булғунча, үзе[97] руы бер қырық кеше булса ирде, һәрайинә бер эш қылур ирдек.

Әй, қалтақ! Бу нә эшләр?
Ғақилләр буны сүзләр, көләрләр,

---

[86] Квадрат җәяләр эчендәге текст өлеше кулъязмада төшеп калган. Монда «Алтынчы текст»тан алынды.
[87] Кулъязмада «Болғар» дип ялгыш язылган.
[88] Кулъязмада «барын, Уладимди» дип хаталы язылган.
[89] Кулъязмада «тиб» дип ялгыш язылган.
[90] Кулъязмада «чыйдурды» дип хаталы язылган.
[91] Кулъязмада «уруш сәүрнең ханы Минмала» дип хаталы язылган.
[92] Кулъязмада: хәзрәти ғһм.
[93] Кулъязмада: Тәғәһәнең; «қөдрәте» сүзе «қорны» дип хаталы язылган.
[94] Кулъязмада «орунуы» дип хаталы язылган.
[95] Бу җөмлә кулъязмада ялгыш тагын бер тапкыр кабатлап язылган.
[96] Кулъязмада «йирләрдән дә» дип ялгыш язылган.
[97] Кулъязмада «үре» дип ялгыш язылган.

Киңәшкә жыйылурлар.
Қалтақлар! Бу нә эш?
Берәү атын мақтар,
Берәү этен мақтар,
Берәү хатунын мақтар –
Киңәш булмаз, халқы тарқар,
Ашын ашады – қачар китә[р].

– Һәрайинә, безнең бөлүклүгүмезгә сәбәбдүр, безгә бөлүклек[98] йақындур! – тиб йығлар ирде. Анда ул Кинҗә әйтүр:

– Әй, йаранлар, халық! Мондин күчәрбез, сез монда қалсаңыз[99], Қуй суының башында Олу Убада болҗал булсун. Без ул тарафға күчәйек! – тиб әйтүр ирде.

Анда йәнә берәү атының ақ күбүген оруб[100], чабаланыб, чы[мы]рғаныб, қычқуруб бу тиде:

– Һай, ханым! Йау йитте. Ақсақ Тимүр бона киләдүр! – тиб хәбәр салды ирсә, хан үзе башлаб күчәр булды ирсә, «Йассы *// (29а кәгазь)* Қамышда ултурурмән» тиб, халықға йар салды. Хан күчде, хан берлә халық һәм күчде.

Әл-қыйсса

Бара торғанда бер қортқаның тирмә айылы[101] өзүлде. Артын қараб бақғунча, бүрк[е] төште. Анда берәгү бер имлек тай менгән уғлан килә торур ирде, қарсында қоруғы[102], қанҗығында баш күнәге[103] бар ирде. Бу қортқаның бүреген алыб бирәйен тигүнчә, ийәре ауды, [тай] дулады, йылқы өрүкте. Берәү тайға чабды, берәү йылқыға чабды[104], үзгә белмәгәнләр «Һай, йау йитте!» тиб, халық[105] уғылы өркүб, башлы башын өн қылдылар. Тимә[106] тарафға туздылар. Анда Ақсақ Тимернең чирүе йитеб, ханны, халықны тотды, қамады, туқта[т]ды: үлгән үлде, халық босташ булды.

Анда Ақсақ Тимер үзе урдасына йитеб, ханны алдыға алдурды, тәқи әйде:

---

[98] Кулъязмада «бөлүклең» дип хаталы язылган.
[99] Кулъязмада «қалыңыз» дип ялгыш язылган.
[100] Кулъязмада «өзүб» дип ялгыш язылган.
[101] Кулъязмада «иде», «әйде». Монда «айылы» дигән сүз «Икенче текст»тан алынды.
[102] Кулъязмада «қосруғы» дип хаталы язылган.
[103] Кулъязмада «башкүзәк» дип хаталы язылган.
[104] Кулъязмада «чамабды» дип хаталы язылган.
[105] Кулъязмада «халқы» дип ялгыш язылган.
[106] Кулъязмада «қаймыр » дип хаталы язылган.



Бишенче текст кулъязмасы

– Әй, Амәт, Самәт! Үзеңезне тәмуғ утундин қотқарыб, башыңызны қылычдин аман қылыңыз, [мөселман булыңыз][107] – тиб, үгүт бирде.

Анлар һәм үтүнделәр:

– Әй, Ақсақ Тимер! Әгәр без мөселман булсақ, безгә халқымызны бирүрмүсән? – тиделәр.

Ул әйде:

[107] Бу сүзләр кулъязмада төшеп калган. Монда «Икенче текст»тан алынды.

– Әгәр сез раст мөселман булсаңыз, «Лә иләһә илла Аллаһу Мөхәммәд рәсүлуллаһ» тиб иман килтүрсәңез, Тәңре Тәғаләне[108] бер белеб, пәйғамбәрне хақ белеб, бер көндә биш вақыт намаз *// (29б кәгазь)* қылыб, бер йылда утуз көн рузә тотуб, җәнабәтдин ғөсел қылыб, малыңыздин зәкят биреб, әгәр көчүңез йитсә Кәғбәгә тәваф қылсаңыз, муғыллықны ташлаб, хасс мөселман булсаңыз, үзеңүзгә һәм халқыңа тимәндүр! – тиб әйде ирсә, анлар барчасы мөселман булдылар.

Хәзрәти Ақсақ Тимүр анларға дине исламны үгрәттүрде. Бер-ике йыл ул күчмәле[109] халық арасында торды, мөселманлық динене белдүрде. Андин соң үзе, тәқи үзгә чирүе берлә аларға асанлашуб[110], андин китделәр. Болар мөселман булуб монда қалдылар, һәр йыл бер йиргә күчәр ирделәр.

Әл-қыйсса

Ул хәзрәти Ақсақ Тимер андин узуб йөрүб Бохара шәһәрегә барды, аны һәм алды, [Ташкәндне һәм алды][111], ул вилайәтләрне үзегә бағындурды. Андин соң Сәмәрқәнд шәһәрегә барды, аны һәм алды. Әмма үзенең һәм ахыры анда булды. Хақ Тәғаләнең[112] тәқдире ирешүб, хәзрәти Ақсақ Тимер ошбу фани дөнйадин үттеләр, рәхмәтуллаһи ғәләйһи рәхмәтән васиғәтән. Қалү: «инна Лилләһи вә инна иләйһи ражиғун»[113].

Андин хәзрәти Мир Тимернең қәбер өстегә таш астанә қубардылар, башыдағы гөнбәзене алтундин, көмүшдин қубардылар, та қийамәткәчә аның дастаны халық арасында *// (30а кәгазь)* сөйләнә қалсун, халық андин ғибрәт алсун тиб дастанны бетүдек[114]. Өмидүмез улдур кем, укуғучы, тыңлағучы, йазғучы доға қылыб, фатиха берлә йад қылалар, фани дөнйаға мәғрүр-мәшғүл булуб, Хақ Сөбханәһә вә Тәғаләнең бойурған бойуруғларындан[115] йөз әверүб, мәхрүм-мәғбүн улмаңыз – қаты зыйандур, олу хурлуқдур. Инша Аллаһу, Тәңре Тәғалә барча мөселманларға тәүфиқны рәфиқ[116] қылыб, пәйғамбәремез Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу ғәләйһи вәсәлләм шәфағәтендин насыйблық қыйла биргел. Амин, Раббил-ғаләмин Мөхәммәд вә алиһи әҗмәғийн.

Тәммәт тәмам, шәд әст.

---

[108] Кулъязмада: Тәғәһәне.
[109] Кулъязмада «күчәне» дип хаталы язылган.
[110] Кулъязмада «саланлашуб» дип хаталы язылган.
[111] Бу сүзләр кулъязмада төшеп калган. Монда «Икенче текст»тан алынды.
[112] Кулъязмада: Тәғәһәнең.
[113] Кулъязмада: йәрҗиғун.
[114] Кулъязмада «бенедүк» дип хаталы язылган.
[115] Кулъязмада «бойуруғларығуан» дип хаталы язылган.
[116] Кулъязмада «әфиқ» дип хаталы язылган.

АЛТЫНЧЫ ТЕКСТ[1]

// (35а кәгазь) **[Дастане Ақсақ Тимер]**

[...] айлу-йөклү хатуның барму?

Ул Тарағай әйде:

– Бәли, бардур, – тиде.

Андин соң Җәдай хан әйде:

– Әй, Тарағай! Сәнең хатуныңыз қорсағындағы балаң мәне үлтүрүр ирмеш. Ул туғаныңдин борун мән аны үлтүрүрмән, – тиде.[2]

Тарағайның хатуныны алдурды. Ул ахмақ тәкдирен тәдбире берлә бозмақ теләде. Әмма Хак Тәғаләнең тәкдире нитәк[3] улур.

Андин соң киңәштеләр, «бу хатунны үлтүрәлек» тиб, «эчен йаралық» тиделәр.

Иллә Тарағай әйде:

– Әй, ханым! Үлтүрү[р] булсаңыз, ул қорсағындағы баласыны тезләб-тезләб үлтүрәлең, – тиде, – анасы үлмәсүн?!

Андин соң ул хатунны йықыб, андақ тезләделәр кем, исе-осы китте, үлә қалды.

Андин хан[4] әйде:

– Имди баласы дәгүл, анасы һәм үлде. Йибәреңләр! – тиде.

Ул хатунны күтәреб арбаға салыб киттеләр.

Андин Җәдай хан әйде:

– Имди, шөкер, қуркунучдин қортудум, – тиб торур ирде.

Андин соң йәнә анча көнләрдин соң ул мескин тезләб имгәнгән[5] ул хатунның күзе йаруды, бер ир уғлан қубты. *// (35б кәгазь)* Уғланны алыб бақтылар ирсә, бер айақы ақсақ ирде. Анда әйделәр кем: «Ошбу нидәй

---

[1] Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1024т» шифры белән саклана торган кулъязмадан алынды. Кулъязманың башындагы бер бит чамасы тексты сакланмаган.

[2] Кулъязманың бу урынында ялгыш «Әй, солтан! Сән, – тиде» сүзләре язылган.

[3] Кулъязмада «нең» дип хаталы язылган. Бу җөмлә «Икенче текст»та бу рәвешле язылган: «Әмма Хак Тәғаләнең тәкдире нитәк булса – андағ булур».

[4] Кулъязмада «хатун» дип ялгыш язылган.

[5] Кулъязмада: икән. «Имгәнгән» сүзе «Икенче текст»тан алынды.

имгәкдин[6] үлмәй қотулуб туғдуң, жаның тимер икәндүр!» – тиделәр. Ул уғланның атыны һәм ул сәбәбдин Ақсақ Тимер қуйдылар.

Имди хәзрәти Ақсақ Тимернең асылы[7]-төбе барлас дигән ырув булур иде. Нәселендә, ырувында ханларға җәйаны ул ирде. Андин соң Ақсақ Тимернең атасы һәм анасы үлде, йәтим қалды. Асрарға, күрәргә һичбер лайық кеше булмады. Ахыр, үзе йөрүде. Ир улуб, ир йиткәндин соң қазақ үзе йалғуз чықыб Шымақи шәһәрегә барды, бер анча йөрде, Шымақида бозаулар көтмәгә жалға керде. Үзегә үзе кебек үксез-йәтим йегетләрне ийәләндүрде, алты-йите уғул бер улуб, көн дә бозау көтәр ирделәр, тәқи уйнар ирделәр.

Йапанда Ақсақ Тимер көнләрдә бер көн бозуқ кәшанә төбүндә йалғуз тайаныб бақыб торур ирде. Бер айақы ақсақ, тәқи бер күзе сукур бер қырмусқа килде, тәқи ул кәшанәгә менәргә йабушды. Бер анча йықару менде, йықылды. Андин соң йәнә һиммәтләнеб, *// (36а кәгазь)* тәқи йабушды, тырмашыб кәшанәнең башыға менәйен, чықайын тигүнчә йәнә түбән йықылды. Хәзрәти Ақсақ Тимер қырмусқаның бу эшегә таңға қалыб, қараб торур ирде. Ақсақ [қырмусқа], ғарләнмәйен, йәнә өчүнче мәртәбә кәшанәгә менәргә йабушды[8]. Ахры бары, тырмаша-тырмаша торғач кәшанәнең түбәсенгә чықыб китте.

Ул қырмусқа һиммәтләнеб тора[9], там түбәсенгә менде, йуқару чықды, мән һиммәт берлә хан булуб, ил-көн, шәһәрләр алыб, урдалар алсам, һич таңға-ғәжайеб булмас. Әгәр Тәңре Тәғалә бойурса» тиб, күңлеғә бу фикерне салыб йөрүр ирде.

Тәқи уғланлар берлә уйна[р] ирде. Көнләрдә бер көн Ақсақ Тимер әйде:

– Әй, йегетләр! Килең, бер йиргә бер нәрсә қуйалы. Ул қуйған нәрсәне кем элек йөгерүб йитеб алсақ, аны арамызда хан қыйлайық, – тиде.

Андин ул йегетләр әйделәр:

– Хуш, андағ булсун, – тиб. Алысға[10] бер нәрсәне алыб қуйдылар. Тәқи барча уғланлар йөгерүшделәр. Ақсақ Тимер һәм йөгерүр ирде. Йөгерүб уғланлар шайы бара алмады, аның өчүн кем – ақсақ ирде. Андин бер уғлан йөгерүб узуб, «ул қуйған *// (36б кәгазь)* нәрсәне алайын, мән элек хан

[6] Кулъязмада «имәгәкдин» дип хаталы язылган.
[7] Кулъязмада «усылы» дип хаталы язылган.
[8] Кулъязмада: йапушды.
[9] Кулъязмада монда текстка өзеклек кергән. Әсәрнең әлеге урынында «Икенче текст»та болай язылган: «Ул қырмусқадин бу хәзрәт: «Күрдүңмү, бу зәғиф, айақсыз, күзсез қырмусқа һиммәтләнеб, йықыла-тора...».
[10] Кулъязмада «алсақ» дип ялгыш язылган.

булайын» тигүнчә, андин борунрак ул нәрсәне Ақсақ Тимер бүрүге берлә ташлаб орды. Тәқи әйде:

– Әй, йегетләр! Сезләрдин борун мән йитдүм, мән хан булурмән! – тиде.

Ул берәү әйде:

– Йуқ, сәндин борун йитеб мән алдум! – тиде.

Анда[11] Ақсақ Тимер әйде:

– Сәнең қулуң йитгүнчә, мәнем башым йитде! – тиде.

Болар бу сүз өстендә бәхәсләшеб торурлар ирде, нәгяһ бер ақ сақаллығ қарт кеше килде. Болар ул қартқа эшләрен сүзләр ирделәр, «Ханлық қайсумызға тигәр?» – тиделәр.

Анда ул қарт әйде:

– Әй, йегетләр! Сезләр мәнең сүзүмне тотармусыз? – тиде.

Болар әйделәр:

– Әй, баба! Сән һәрнә диң, эшемезне сәнгә салдуқ, – тиделәр.

Анда ул қарт әйде:

– Әй, йегетләр! Бу ақсақ уғулның сезнең қулуңыздан борун башы йитебдүр, моны хан қыйлуңыз! – тиде. – Сүз моның сүзедүр! – тиде.

Анда бу үнгә йегетләр әйделәр:

– Әй, ба[ба]! Хуш, имди қыйлайық! – тиделәр. Ақсақ Тимүрне үзләре араларында хан итәр ирделәр.

Вә йәнә[12] көнләрдә бер көн Ақсақ Тимүр әйде:

– Әй, йегетләр! Һәркем ошбу көтә торған бозаулардин бер бозауны[13] // *(37а кәгазь)* кем суйуб, барчамызға йидүрсә, арамызда аны хан күтәрәлек, – тиделәр.

Анда йәнә үзгәләре һичқайсы бер бозауны суйа алмадылар. Ақсақ Тимүр үзе бер бозауны суйуб, пешүрде, ул уғланларға йидүрде. Ашадылар, андин соң Ақсақ Тимүрне үз араларында хан күтәрделәр. Андин қайтыб авылларына килделәр, бер бозау ийәсенә әйделәр:

– Әй, бай! Бозавыңны бүре ашабдур, – тиб әйделәр.

Ул һәм нәрсә димәде, «бүрегә бойурған икәндүр» тиде.

Вә йәнә андин соң көнләрдә бер көн Ақсақ Тимер уғланларға әйде:

– Әй, йегетләр! Киленезләр, безләр қарақчы булайық, бәзүргәнләрне, сатучыларны тоталық, малын алалық! – тиде.

Анда бу уғланлар әйделәр:

– Хуш булсун! – тиделәр.

---

[11] Кулъязмада «андақ» дип ялгыш язылган.
[12] Кулъязмада «уйнә» дип хаталы язылган.
[13] Кулъязмада «бозау йәнә» дип ялгыш язылган.

Анда Ақсақ Тимүр әйде:

– Сезгә сүзем улдур кем, имди бу кичә һәрқайсуңыз һич үзгә нәрсә алмаңыз, мәгәр йау қоралын қуймаңыз, алыңыз! – тиде.

Анда бер бозуқ кәрвансарай бар ирде, болҗалны анда қуйдылар. Ул төннең йарымында килеб бер-беренә йулуқтылар. Қайсысы көбә кийеб, мылтық алыб, қайсы уқ-садақ, қылыч алыб, ушал Шымақи шәһәрендән чықыб киттеләр[14]. Һиндустан // *(37б кәгазь)* шәһәрегә барыб, Һиндстан шәһәренең йулын сақлаб йаттылар, узған-барған сатучыларны, асламчыларны бастылар, малларын алур ирделәр – олу қарақчылық қыйлдылар.

Азған-тузған, ата-анадин бизгән уғланлар, байдан қачқан қоллар аңар җыйылдылар, қушулдылар. Һәркем тышдан килеб аңар қушулса, аңар лайық алаба бирә[15] башладылар. Базүргәнләрне, сатучыларны қырдылар[16], қол-қотанны йулдаш қыйлдылар, бер ике-өч йөз кеше булдылар. Узған-барғанны талар ирделәр, йул киселде, кәрван халқы йөрүмәз булдылар.

Ан[да Һинд]устан падишасы Җәдай ханға хәбәр төште – «йулны қарақ сақлайдур, кешене йөрүтмәйдүр» тиб. Андин соң Җәдай хан илче йибәрде, өч йөз кеше килеб Ақсақ Тимүргә әйде:

– Әй, Ақсақ! Нә өчүн сән мондағ уғрылық[17] қыйлурсән, йулларны бағларсән? – тиделәр.

Анда ул Ақсақ Тимүрнең чирүе ул килгән илчебашын үлтүрделәр, үзгәсен барчасын үзләренә йулдаш қыйлдылар, күб ағыр алапалар бирделәр.

Бу хәбәр йәнә Җәдай ханға ишетүлде. Үртәнде, көйде, вә йәнә ике[нче] мәртәбә илче йибәрде. Ул илченең // *(38а кәгазь)* башын йибәрделәр, үзгәләрен алыб қалдылар, үзләрегә йулдаш қыйлдылар.

Андин соң Җәдай хан вә йәнә өчүнче илче йибәрде, «ул қарақларға алтун-көмүш алапа бирәйен, узған-барғанға, базүргәнләргә тимәсүн» тиб.

Анда болар әйделәр:

– Имди Җәдай ханның қазнасындан безнең қазнамыз күбдүр, кирәк булса бездән һәм алсун! – тиделәр.

Андин йәнә бер анча көнләрдин соң Җәдай хан үзе чирүен йыйыбдур тиб, Ақсақ Тимүргә хәбәр төште. Анда Ақсақ Тимүр боларға қаршы шымчы йибәрде, хан киләмү иркән тиб. Ул шымчы барыб күрде кем – Җәдай хан килә йатур. Шымчы барыб анларның арасына керде, Җәдай хан үзе утуз кеше берлә элгәрү килүр ирде. Бу барған кешене күрделәр, мондин сордылар:

– Һай, йулда қарақ күрдүңмү? – тиб.

---

[14] Кулъязмада «кешеләр» дип ялгыш язылган.

[15] Кулъязмада «алалса бара» дип ялгыш язылган.

[16] Кулъязмада «қырадлар» дип хаталы язылган.

[17] Кулъязмада «умхарулық» дип хаталы язылган.

Бу әйде:

– Йуқ, һәргиз күрмәдем, бу йулда, һичшиксез, қарақ йуқдур, – тиде[18].

Моның бу сүзенә бақыб, «қарақ йуқ ирмеш, – тиделәр, – мәгәр ки безнең килгән хәбәремезне ишетеб қачқандур» тиделәр. Элгәрү узуб киттеләр.

Бу шымчы үз йоруғына китте. Анлардин айырылыб, аулакқа чыққандин // *(38б кәгазь)* соң қачты, Җәдай ханның утуз кеше берлә килә йөрүгәнен Ақсақ Тимүргә килеб әйде.

Анда ул Ақсақ Тимүр әйде:

– Алай булса, тиз имди утуз түәгә малларны, қомачларны йөкләндүрең! – тиде.

Шул уқ заман утуз түәгә йөкләделәр.

Андин соң Ақсақ Тимүр Җәдай ханның килә торған йулы берлә қаршу бардылар. Җәдай хан төшүб, чатурун қоруб йатур ирде, болар қаршу бардылар. Җәдай хан боларға алысдан[19] хәбәр бирде:

– Һай, нә кешеләрсез?

Болар әйделәр:

– Без сатучылармыз.

– Хуб, хуб! Йә, йулда қарақ күрдеңезмү? – тиделәр.

Болар әйделәр:

– Йуқ, һич без күрмәдүк, – тиделәр.

Андин соң Җәдай хан боларның қашыға килделәр.

Анда болар әйделәр:

– Һай, сезләр нә кешеләрсез? – тиделәр.

Анлар әйделәр:

– Безләрне сорсаңыз, Җәдай ханбыз, қарақлар эстәйү чықдуқ, – тиделәр.

Анда болар әйделәр:

– Андағ булсаңыз, без сатучылармыз, бездән малымызның тамғасын[20] алыңыз, безгә һәм йул йөрүргә[21], сату қылурға йахшы булур, – тиделәр.

Анда Җәдай хан бу сүзгә[22] туқтаб тик торды, бойурды:

– Тамғасын алыңызлар! – тиб. – Болар безгә, шайәт, бер асыл-тансуқ мал алыб // *(39а кәгазь)* килгәндүр, – тиде.

Андин соң Җәдай ханның кешеләре йөкләренә ақтарыб[23], тамға алайын тигенчә Ақсақ Тимүрнең кешеләре бер[ен]-берен тотуб үлтүрә башладылар. Хәзрәти Тимүр үзе Җәдай ханны тотты.

---

[18] Кулъязмада «тиделәр» дип ялгыш язылган.
[19] Кулъязмада «асдан» дип ялгыш язылган.
[20] Кулъязмада «таухасын» дип хаталы язылган.
[21] Кулъязмада «йөрүргәһ» дип хаталы язылган.
[22] Кулъязмада «сәнгә» дип ялгыш язылган.
[23] Кулъязмада «ақтартыб» дип ялгыш язылган.

Җәдай хан әйде:

– Аһ, әй, Ақсақ! Мән сәнгә йахшылық қыйлдым, сән мәнгә йаманлық қыйлурсән, – тиде.

– Ғафил – сән, мән дәгүлмән! Сән үзенгә йаманлық қыйлурсән, мән үзүмгә йахшылық қыйлурмән, – тиде. Ханны үлтүрде, башын кисте.

Андин соң Ақсақ Тимүр үзе Һиндустан шәһәрегә барыб, анда хан булды. Тәқи бу қалған чирүенә хәбәр төште ирсә, рәван килеб анлар һәм шәһәргә инделәр[24]. Шәһәрен алды. Андин йәнә Җәдай ханның артында қалған чирү[е] бу хәбәрләрне, бу эшләрне белмәйен, «ханымызға анда йитәрмез, монда йитәрмез» тиб бара торғач, йитә алмай, қайттылар. Ханларын йуғалтыб килделәр ирсә, «шәһәр[не] Ақсақ Тимүр алыбдур» тиб, нәрсә итә[25] белмәделәр, Ақсақ Тимүргә бағындылар.

Имди Ақсақ Тимүр Һиндустан шәһәрен ошбулай алды тиб әйтүрләр. Әмма аңа Тәңре Тәғалә үзе йар-йулдаш булғандур, шәһәрләр- *// (39б кәгазь)* йортлар алмақға, урдалар вәйран булмақлықға аны сәбәб қыйлғандур. Һәм йахшы[-йаман] эш Тәңре Тәғалә әмере-тәқдире берләдүр. Аның бойурығындин тыш һичбер эш булмасдур[26].

Андин соң ул Ақсақ Тимүр ләшкәре берлә йөрүб алмаған йорутны қуймады. Тәңре Тәгалә аңар үзе йар булды ирсә, дөнйаны үзенә бақтурды.

Вә йәнә тәқи йәшерүн қалмасун[27] кем, хәзрәти Ақсақ Тимүрнең ике уғылы бар ирде: берсе – Сафый дигән, икенчесе – Вафый дигән ирде. Олуғ уғылы Сафыйны хан қыйлыб, үз урыныға Һиндустан шәһәренгә ханлық[қа] қуйды. Хәзрәти Мир Тимер үзе ләшкәре берлә Истанбул шәһәрен алурға йарағланды. Авыр [чирү] җыйдурды, күб-күб филләргә, тәқи күб түәләргә хәзинәдән маллар, тәқи күб-күб қораллар[28] йөкләтде. Сансыз-сақышсыз ләшкәре берлә, Һиндустан қәвеме берлә тибрәделәр, тағ-таш тулуб йөрүделәр. Мисыр шәһәрегә килделәр, орушуб-қырулушуб, ахры бары, аны алдылар.

Андин йөрүб узуб Истанбул шәһәрен алғалый килделәр, бер йирдә төшүб қундылар. *// (40а кәгазь)* Сафлар бағлаб, орушқа хәзерләнеб тордылар.

Әл-қыйсса

Ул заманда Истанбул падишаһының аты Ша[һ]-солтан хан дигән ирде, аңар хәбәр төшде кем, «Ақсақ Тимүр шәһәренгә алғалый, урдаңны

---

[24] Кулъязмада «андылар» дип ялгыш язылган.
[25] Кулъязмада «нәрсәдин» дип ялгыш язылган.
[26] Кулъязмада «булмашдур» дип хаталы язылган.
[27] Кулъязмада «қалмашун» дип хаталы язылган.
[28] Кулъязмада «қортлар» дип ялгыш язылган.

бозғалый киләдүр» тиб. Хан Шаһ-солтан һәм авыр чирү хәзер қыйлыб йарағландурды[29]. Ақсақ Тимүргә қаршу чығарды. Ике чирү килеб бер-берсигә қаршу қундылар. Араларында күб қаравыллар[30], йасавыллар қуйдылар, [сафлар бағ]лайу тордылар. Иртәгесен орушқа ике чирү бер-берсегә қаршу [кил]еб андағ орушыблар кем, Шаһ-солтанның чирүен Ақсақ Тимүр чирүе қырдылар, қачурдылар. Андин килеб Истанбул шәһәренә берекләнде[31]. Ақсақ Тимүр чирүе қуа килделәр, шәһәрне хисар қыйлдылар, йәғни шәһәр ғайәт би[йе]к шәһәр ирде, биш йыл қабсаб тордылар, һичберсен ала алмадылар. Шәһәре сигез қабат ирде, алурға йорығын табмадылар.

Имди Истанбул шәһәренең сыйфаты ошбудур.

// (40б кәгазь)

Рәсемнең эчендәге язуы: Истанбул шәһәренең [күрене]шүдүр

Истанбул шәһәренең рәсеме

[кустодта] Бу шәһәрне Ақсақ [...][32]

// (41а кәгазь) ... ошбу Идел суының тыш йағындин килделәр, чирүенең саныны-хисабыны Аллаһдан ғәйре кемсәнә белмәс ирде.

Ул заманда Болғар шәһәрендә ханлары Ғабдулла дигән ирде. Ғабдулла

---

[29] Кулъязмада «ағландыдыр диб» рәвешендә ялгыш язылган.

[30] Кулъязмада «қарақлар» дип ялгыш язылган.

[31] Кулъязмада «беркелләнде» дип хаталы язылган.

[32] Кулъязманың бу урынында бер кәгазе төшкәнлектән, текстка өзеклек кергән.

ханға хәбәр ирешде кем, «Ақсақ Тимүр киләдүр» тиб. Шул заман Ғабдулла хан ләшкәр йығдурды, ағыр чирү хәзерләб қаршу[33] йөреде. Ахры бары, бер-берсигә йулықушуб[34] қаты орыштылар. Ақсақ Тимүрнең орышыға түзмәделәр, сындылар. Килеб Болғар шәһәрегә керделәр, үлгән үлде, қалған шәһәрегә берекләнде.

Ақсақ Тимүр килеб, шәһри Болғарны йите йыл қабсаб торды. Тарих йите йөз йылда ирде, зөлхиҗҗә айының йегермесендә ирде – шәһри Болғарны алдылар, хәраб қыйлдылар. Йөз дә йегерме түрт олуғ бикләр бар ирде, анларның тәмамысын қырдылар. Һәркайусының кә-әмсалел-лөә-лөэ әл-мәкнүн тик хатунлары бар ирде, анларның тәмамысын Ақсақ Тимүр йәсир қылды. Ул бикләр эчендә түрт олуғ бикләре бар ирде, асыл шаһзадәләр ирделәр: бере – Ақбал бик, йәнә бере – Қол Ғәли бик, йәнә бере – Хәваш, йәнә бере – Мырқаш бик дирләр ирде *// (41б кәгазь)* – тәмамысын һәлак қыйлдылар. Күб-күб хәлайықлар һәлак булдылар. Ғабдулла ханны һәм үлтүрделәр.

Әмма Ғабдулла ханның ике уғылы бар ирде, берсе – Алтунбик, икенчесенең аты Ғалимбик дигән ирде. Җаудин-қырғындин қачуруб қалған кешеләре Алтун[бик берлә Ғалим]бикне урман төбенгә илтеб йәшүрделәр. Берсе йите йәшендә, вә берсе туқуз йәшендә ирделәр. Анларны йахшы асрар ирделәр.

Андин соң ул Ақсақ Тимүр шәһри Болғарны вәйран қыйлды. Хәраб қылғандин соң Бүләр шәһәрегә килделәр чирүе берлә. Бүләр шәһәренең қаршусыға килеб, ур қазыб[35] йатдылар, оруш-туқуш қылмадылар. Ул вақытта Бүләр шәһәренең ханы Самәт дигән ирде, көбәсе «бозқалбақ»[36] дигән ирде, халқы барач дигән халқы ирде.

Барач халқының әүвәл замандағы борунғы йорты[37] ошбу Зәй тамағында улур ирде. Алыбларның заманы ирде, бер Барач атлығ аждаһа йылан килде, у[л] шәһәрнең халқыға көч-зыйан қыла башлады. Чықыб аждаһа берлә суқушдылар, йиңә алмадылар. Ахыр, үзләре шәһәрен *// (42а кәгазь)* салыб қачтылар, Болғар шәһәренең йақыныға барыб, Бүләр суының өстегә йорт[38]-шәһәр салдылар. У[л] шәһәрләрегә һәм Бүләр[39] тиб атадылар. Ул сәбәбдин халқыны «барач» тиб әйтүрләр ирде тәқи оранлары «барач» ирде.

Анда ул Самәт хан әйде:

– Аһ, барач халқы! Борун олуғ бабаларымыз Барачның[40] зыйанындин

---

[33] Кулъязмада «қаршур» дип хаталы язылган.
[34] Кулъязмада «йул қушуб» рәвешендә аерып язылган.
[35] Кулъязмада «үтәзеб» дип хаталы язылган.
[36] Кулъязмада «бер қалмақ» дип ялгыш язылган.
[37] Кулъязмада: йорут.
[38] Кулъязмада: йорут.
[39] Кулъязмада «Болғар» дип ялгыш язылган.
[40] Кулъязмада «-ның» кушымчасы ялгыш ике мәртәбә язылган.

қачыб, шәһәрләрен салыб ошбунда килебләр, мәқам-йорт[41] тотдылар. Имди Барачдин көчлүрәк Ақсақ Тимүр килде, шәһәремез қаршусыға төшде. Нә қыйлурмыз? – тиде.

Ул барач халқы әйделәр:

– Әй, ханым! Сезләр ни бойурсаңыз ир[к]еңез бардур! – диделәр. – Әмма бойурсаңыз, Ақсақ Тимүр ләшкәре берлә һәм орушурмыз, йә үлтүрү[р]мез! – тиделәр.

Анда Самәт хан әйде:

– Хуш, имди мәнең қашымда бер кеше бардур, андин сорайын, ул [нә] бойурса, аның сүзендин чықмазмән, – тиде.

Ул кешене алдуруб сордылар кем, тәқи әйделәр[42]:

– Әй, безнең олуғымыз вәли! Йа, имди безләр ошбу өстүмезгә килгән Ақсақ Тимүр *// (42б кәгазь)* берлә оруш қыйлалықму? – тиде.

Ул вәли әйделәр:

– Хуш, қарайын, – тиде, бер манараның башыға менде. Тәқи Ақсақ Тимүрнең чирүе тарафыға қарады ирсә, күрде кем – хәзрәти [Хозыр] Ақсақ Тимүрнең чирүендә бергәдүр. Андин соң манарадин төшүб, хан Самәтнең қашыға килде, тәқи әйде:

– Әй, ханым! Орушурға[43] рөхсәт йуқдур! Хәзрәти хуҗаи[44] Хозыр ғәләйһиссәлам аның чирүендә бергәдүр. Тәңре Тәғаләнең бойурықыңға муйун сонмақ кәрәкдүр, қапқаларны ачтурғыл! – тиде ирсә, ул хан, тәқи ул барча халқы йығлашдылар. «Ни қыйлмақ кирәк, Хақ Сөбханәһә Аллаһу вә Тәғаләнең хөкеменә муйун сонмақ кирәк» тиб, шәһәрен қапқаларын ачтылар, ирек салдылар, орушмадылар.

Андин соң хәзрәти Ақсақ Тимүр чирүе берлә шәһәргә[45] инделәр, халқыны қырдылар[46].

Әмма анда Ақсақ Тимүр кичә үзе шымчы булуб, төсене[47] әверүб, хәлайықлар эченгә кереб, сынай йөрүр ирде. Тәқи әйтүр ирделәр:

– Әй, хәлайықлар, әй, йегетләр! Бу бөлүклүк, бу қырғын безгә кемдин торур? – тиб сорар ирде.

Анда ул ултурғанлар әйтүр булсалар: «Безне *// (43а кәгазь)* Ақсақ

[41] Кулъязмада: йорут.
[42] Кулъязмада бу сүздән соң ялгыш «ул» сүзе язылган.
[43] Кулъязмада «орушуруғ» дип хаталы язылган.
[44] Кулъязмада «хаэчә» дип хаталы язылган.
[45] Кулъязмада «шәһәрегә» дип ялгыш язылган.
[46] Кулъязмада «қарадылар» дип ялгыш язылган.
[47] Кулъязмада «түәсен» дип ялгыш язылган.

Тимүр бөлдүрде, анын шомлығындин бөлдүк, жуйулдук»[48] дигән кешеләрне иртәгесен тәмамысын рувы-тамуры берлә һәлак қыйлур ирде.

Һәркем гөнаһны үзүндин[49] белеб әйтүр булса ирде «бу бөлүклүк[50] безгә үз шомлығумыздан йитте» тиб әйтсә ирде, аны рувы-тамуры берлә үлтүрмәз[51] ирде, анларны тәмамысын йарлыхар ирде.

Әл-қыйсса

Кичәләрдә бер кичә хәзрәти Ақсақ Тимүр шымчы булуб барач халқының арасыға кереб әйде:

– Әй, барач халқы! Бу бәла сезләргә қайдин килде?

Анда анлар әйделәр:

– Кемдин ирдүкен белмәдемүсән? Убур Ақсақ Тимүр килде, безне қырды, бөлдүрде[52], – тиделәр.

Анда ул жыйын эчендә бер олу бик[нең] ғақыллығ, услығ тол қалған бер хатун[53] бар ирде, ул әйде:

– Әй, йаранлар! Бу эшләрне, бу бөлүклүкләрне үз гөнаһымызның шомлықундин беләлең. Ул Ақсақ Тимүр нә қылур ирде? Тәңре Тәғаләнең тәкдир[е]дүр! – тиде.

Ул хатунның ире Жадәш бик дигән ирде, [ул хәзрәти Ақсақ Тимер килмәсендин борун үлгән ирде][54]. Анын ике уғылы бар ирде, әүвәл бере – Инсан, вә йәнә икенчесе – Ихсан *// (43б кәгазь)* дигән ирде.

Ул кичә үтте, иртәгесен Ақсақ Тимүр ул хатунны вә тәқи уғыллары берлә үз қашыға алдурды. Болар ни эшкә алдурғанын белмәйен, «безләрне үлтүрүр охша[й]» тиб, йығлашдылар. Анда Ақсақ Тимүр ул хатунға әйде:

– Сән гөнаһыңны үзеңдин белүрсән, «һәр эш безнең үз шомлығумыздин» тиб әйтүр ирдүң. Сине имди бу көндин соң тәмам уғылуң-қызың, қәрәндәшләрең берлә йарлықадым. Һәрқанда сәүсәңез, ул тарафқа киткәйсез! – тиде. Үзе һәм тәмам чирүгә йар салды:

– Бу кешенең малыны таламаңызлар, һич нә ирсәсенә зыйан тигүрмәңләр[55]! – тиде, ул хәфифә бу бөлүкләрне, үз гөнаһына, үзендин белгән өчүн тәмам уғылы-қызы, қәрәндәшләре берлә йарлықадум.

---

[48] Кулъязмада «чуйулдуқ» дип хаталы язылган.
[49] Кулъязмада «үзүнедин» дип ялгыш язылган.
[50] Кулъязмада «бөлүлүклүк» дип хаталы язылган.
[51] Кулъязмада «үлтүрмез» дип хаталы язылган.
[52] Кулъязмада «бөлдүрүде» дип хаталы язылган.
[53] Кулъязмада «хатун бер» дип ялгыш язылган.
[54] Квадрат җәяләр эчендәге текст өлеше кулъязмада төшеп калган. Монда «Бишенче текст»тан алынды
[55] Кулъязмада «тигрүмәңләр» дип хаталы язылган.

Андин соң ул бик: берсе Инсан, берсе Ихсан – икеләре киңәш итеб, күчмәгә нийәт қыйлдылар. Олуғ[ы] Инсан әйде:

– Әй, анамыз! Ошбу олуғ Иделнең эч[56] йүнегә – Тау йирегә барурмән, анда мәқам тотармән, аның өчүн кем, ул ирдин бәрик йир йуқдур, – тиде.

Анасы һәм аның сүзенә *// (44а кәгазь)* йақын булды, қабул қыйлды. Әмма энесе Ихсан бик[57] ул тарафқа барурға өнәмәде, «иске бабаларым[58] йортыға барурмән, анда мәқам-йорт тотармән» тиде.

Инсан бик әйде: «Мән ул йиргә барурмән, анда мәқам тотармән»[59]. Анасы һәм аның берлә китде.

Анда барыб, Гөбенә[60] дигән суның буйунда мәқам тотды. Ул Инсандин[61] бер уғылы туғды, [атын] Сәлман қуйды. Сәлман уғылы Қәдер, Қәдер уғылы Нурдәүләт, Нурдәүләт уғылы Нурхәсан, [Нурхәсан] уғылы Нурәбдәл, Нурәбдәл уғылы Қотуш, Қотуш уғылы Мақтым, [Мақтым] уғылы Игәнәй, Игәнәй уғылы Мөхәммәд, Мөхәммәд уғылы Чучамөхәммәд, Чучамөхәммәд уғылы Тәвәккәл, Тәвәккәл уғылы Пирмөхәммәд, Пирмөхәммәд уғылы Җантый, Җантый уғылы Бәбәш, Бәбәш уғылы Үлмәс, Үлмәс уғылы Чуқуш.

Әмма энесе Ихсан бик Тау тарафыға мәйел қыйлмайын, Зәйгә килде. Ихсандин бер уғылы туғды, [атын] Әлмөхәммәди қуйдылар. Әлмөхәммәди уғылы Қалмөхәммәд, уғылы Тәкәнеш, уғылы Базаргяни ирде. Тамғалары «қуш кәшан», оранлары «барач» торур.

***

Имди йәнә сүзне[62] башдин сүзләйәле. Ул хәзрәти Ақсақ Тимүр Бүләр шәһәрен вәйран *// (44б кәгазь)* қылғандин соң Мәскәү тарафыға китделәр. Анда ләшкәре берлә барыб, Ывладимүр дигән гәүр қаласыға йитде, оруш қылғалый нийәт қылды. Гәүр һәм чиргүен ул қала астына җыйдурды. Хәзрәти Ақсақ Тимүр барған вақытда Үләдимүрнең ханы Михайла[63] атлығ ирде. Хәзрәти Тимүрнең шәһәрләр алыб, аңа[64] барған хәбәрләре гәүргә

[56] Кулъязмада «һич» дип ялгыш язылган.
[57] Кулъязмада «әммәли эзәсе Ихсанның» дип хаталы язылган.
[58] Кулъязмада «искин балаларым» дип ялгыш язылган.
[59] Бу урында кулъязмада текстка өзеклек кергән. «Икенче текст»та әлеге җөмлә ахырындагы «тотармән» сүзеннән соң болай язылган: «– тиде. Инсан бик әйде: «Мән ул йиргә бармандур, тиб, айырылды. Тау тарафыға китде».
[60] Кулъязмада «Кәйнә» дип хаталы язылган.
[61] Кулъязмада «Ишандин» дип хаталы язылган.
[62] Кулъязмада «сүзенә» дип ялгыш язылган.
[63] Кулъязмада «Михйала» дип хаталы язылган.
[64] Кулъязмада «аңла» дип ялгыш язылган.

ирүшүб, қаты қурқуғда ирде. Тимүр гәүрнең қаласы Аладимүргә йитеб ирде, хәзрәти хуҗаи Хозыр ғәләйһиссәлам[65] килеб, Ақсақ Тимүргә әйде:

– Халә бу кяфер берлә орушурға вә тәқи қырарға вәғдә ирүшмәйдүр! – тиб хәбәр бирде. Әмма бу кяфергә кәраматеңне күрсәткел! – тиде ирсә, хәзрәти Ақсақ Тимүр шул заман тора салыб, бер өч йәшәр тай берлә кяфер тарафыға атды. Хақ Тәгаләнең қөдрәте берлә, ул ташлаған тай барыб, бу кяфернең бер таш манасырыны уртара өзүб йибәрде, бер чақрум йир баруб төште. Тай төшкән йир су булды.

Андин соң кяферләргә һәйбәт орунды, тәқи ағызы тотулды, қурқуғындан *// (45а кәгазь)* битләрендә[66] қаны қалмады.

Андин соң хәзрәти Мир Тимүр орушмайын (вәғдә ирмәгәне өчүн) чирүе берлә қайттылар. Қайтыб Бохара шәһәрегә барурға йүнәлделәр. Килә йөрүгәнендә қайа йирләрдән[67] Амәт, Самәт дигән, күчмәле [халық ханнары] бар ирде, анларға хәбәр төшде «Ақсақ Тимүр киләдүр» тиб[68]. Ту [бийә] суйуб, халқын йыйыб, «[қайу тарафға] күчәлек?» тиб киңәш қыйлды. Анда ул халық уңмаслық қыйлыб, берәве атын мақтады, берәве этен мақтады, вә йәнә берәве алған хатунын мақтады. Бешкән ит ашалды, киңәш булмады, халық уғылы тарқарды. Анда бер Кинчә дигән [берәү бар] ирде, ул йығлаб әйде:

– Әй, қалтақлар! Үзе ала сан[69] кеше булғунча, үзе, ыруы бер қырық кеше булса ирде, һәрайинә бер эш қылур ирдүк.

Әй, қалтақлар!
Бу ни эшләр?
Ғақыллулар ни сүзләр,
Ғақылсызлар ни сүзләр?
Ғақылсызлар көлә: сезләр
Киңәшкә җыйылур,
Киңәш итмәсләр.
Бу ни эшләр булды –
Берәү *// (45б кәгазь)* атыны мақтар,
Берәү этен мақтар,

---

[65] Кулъязмада: хучаи Хозыр ғм.
[66] Кулъязмада «питләрендә» дип хаталы язылган.
[67] Кулъязмада «йирләнде» дип ялгыш язылган.
[68] Кулъязмада моннан соң түбәндәгечә язылган:
«Бу ни эшләр?
Ғақыллулар ни сүзләр?
Ғақылсызлар ни сүзләр?»
Ләкин текстның бу өлеше әлеге урында язылуы ялгыш. Андый юллар төп текстта (берничә җөмләдән соң) үз урынында да язылган.
[69] Кулъязмада «иле лисан» дип хаталы язылган.

Берәү хатунун мақтар –
Киңәш булмас,
Халық уғылы тарқар?
[Ашын ашады – қачар китәр][70].

– Һәрайинә, безнең бөлүклүгемезгә сәбәбдүр, безгә бөлүклек йақындур! – [тиб] йығлар ирде. Анда ул Кинчә әйтүр:

– Әй, йаранлар, хәлайықлар[71]! Сез монда қалсаңыз[72], Қуй суының башында Олу Убада[73] болҗал булсун. Без ул тарафға күчәйек! – тиб әйтүр ирде.

Анда шул заман берәү атның ақ күбүген орыб, чапавыл берлә, қычқуруб бу тиде:

– Һай, хан! Җау[74] йитде. Ақсақ Тимүр мона килә йөрүр! – тиб хәбәр салды[75] ирсә, ханы үзе башлаб күчәр булды ирсә, «Мән ошбу Йассы Қамышда[76] ултурурмән», тиб халқына йар салды. Хан күчде, хан берлә хәлайықлар һәм күчделәр.

Әл-қыйсса

Күчүб бара торғанда бер қортқаның тирме айылы өзүлде. Артын қараб баққунча, бүреге төште. Анда берәү имлек тай менгән уғлан килә торур ирде, қарсында қоруғы, қанчығасында баш күнәге бар ирде. Бу қортқа бүркен // *(46а кәгазь)* алыб бирәйен тигүнчә, ийәре ауды, [тай] дулады, йылқы өрүкте. Берәү тайға чабты, берәү йылқыға чапты, үзгә белмәгәнләр «Һай[77], йау йитте!» тиб, халық уғылы өркүб, башлы башын йарау қыйлдылар, һәр тарафға туздылар. Анда ул Ақсақ Тимүрнең чирүе йитеб, ханууны вә тәқи халықны қамаб, туқтатыб тотдылар: үлгән үлде[78], босташ вә һәм булдылар.

Анда Ақсақ Тимүр үзе урдасына йитеб, ханны алдыға алдурды, вә тәқи [әйде]:

– Әй, Амәт, Самәт! Имди үзеңезне тәмуғ утундин қотқарыб, башыңызны қылычдин аман қыйлыңыз – мөселман булуңыз! – тиб, үгүт бирде.

Анлар һәм үтүнделәр, әйделәр:

---

[70] Бу юл кулъязмада язылмыйча калган. Монда «Икенче текст»тан алынды.
[71] Кулъязмада берничә сүз төшеп калган. Текстның бу урынында «Икенче текст»та «Мондин күчәбез» дигән сүзләр теркәлгән.
[72] Кулъязмада: қалыңыз.
[73] Кулъязмада «Олур Үтбәдә» дип ялгыш язылган.
[74] Кулъязмада «чау» дип хаталы язылган.
[75] Кулъязмада «салары» дип хаталы язылган.
[76] Кулъязмада «йәше йатқа» дип ялгыш язылган.
[77] Кулъязмада «һау» дип хаталы язылган.
[78] Кулъязмада «өйгән булды» дип ялгыш язылган.

– Әй, Ақсақ Тимүр! Әгәр без мөселман булсақ, безнең халқымызны үзүмезгә бирүрмүсән? – тиделәр.

Анда ул Ақсақ Тимүр әйде:

– Әгәр сез раст мөселман булсаңызлар, «Лә иләһә иллә Аллаһу Мөхәммәд рәсүлуллаһ» тиб иман килтүрсәңез, Тәңре Тәғаләне бер белеб, пәйғамбәрләрне вә хақ белеб торсаңыз, бер көндә биш вақыт намаз қылыб, бер йылда утуз көн рузә тотуб, җәнабәтдин соң ғөсел қыйлыб, малыңыздин зәкят биреб, *// (46б кәгазь)* әгәр көчүңез йитеб Кәғбәгә барыб тәваф қыйлсаңыз, муғаллықны ташлаб, хасс мөселман булсаңыз, үзүңүзгә һәм халқыңа тимәндүр[79]! – тиб әйде ирсә, анлар барчасы мөселман булдылар.

Хәзрәти Ақсақ Тимүр анларға дине исламны үгүрәтүр ирде. Бер-ике йыл ул күчмәле халық арасында торды, мөселманлықдин тәмам белдүрде. Андин соң үзе, тәқи үзгәнең чирүе[80] [қ]алдылар. Вә һәр[81] йыл һәр бер йиргә күчәр ирделәр.

Әл-қыйсса

Ул хәзрәти Ақсақ Тимүр андин үтүб йөрүб Бохара шәһәрегә бардылар, аны һәм алдылар, Ташкәндне[82] [вә Йәркәндне] һәм алдылар, ул вилайәтне һәм үзегә бағундурдылар. Андин соң кем Сәмәрқәнд[83] шәһәрегә бардылар, аны һәм алдылар. Әмма ул[84] хәзрәти Ақсақ Тимүрнең үзенең ахры ғөмере анда булды. Хақ Тәға[лә]нең тәкдире ирешүб, хәзрәти Ақсақ Тимүр һәм ошбу фани дөнйадин бақи йиргә үтте, вә рәхмәтуллаһи ғәләйһи рәхмәтән васиғәтән. Қалү: «инна Лилләһи вә инна иләйһи раҗиғун».

Андин соң хәзрәти Ақсақ Тимүрнең [қәбере] өстегә таш астанә қубардылар, *// (47а кәгазь)* башыдағы гөнбәз[не] алтундин, көмүшдин йасадылар.

Валлаһу әғләмү бис-саваби.

Тәммәт тәмам, шәд әст.

---

[79] Кулъязмада «йитмәнидүр» дип хаталы язылган.

[80] Кулъязмада текстка өзеклек кергән. «Бишенче текст»ның бу урынында түбәндәгечә язылган: «...берлә аларга асанлашуб, андин китделәр. Болар мөселман булуб монда...»

[81] Кулъязмада «һу» дип ялгыш язылган.

[82] Кулъязмада «қашындагын» дип ялгыш язылган.

[83] Кулъязмада: Сәмәрқәнз.

[84] Кулъязмада «әүвәл» дип ялгыш язылган.

ҖИДЕНЧЕ ТЕКСТ[1]

[Дастане Ақсақ Тимер]

// (2а кәгазь) [...] күзүндә ақы бар торур. Ул Тарағайның хатуны йөкле торур. Аның қорсақындағы баладин әҗәлең-үлүмең һәйбәт торур, – тиделәр.

Анда Җәдай хан фал бағучылардин бу сүзне ишетеб, ул Алмалық авылындағы Тарағайны эстәтеб табтурды. Җәда[й] хан қашыға алыб килделәр, қарадылар – ул әйтелгән нишанлары бар ирде, чавырында миңе, сул күзүндә ақы һәм бар торур. Җәдай хан сордылар:

– Әй, Торағай! Сәнең айлу-йөклү хатуның барму?

Ул Тарағай әйде:

– Бәли, бардур.

Андин соң Җәдай хан әйде:

– Әй, Тарағай! Синең хатуның қорсақындағы балаң мәне үлтүрүр ирмеш. Ул туғмасындан борун мән аны үлтүрүрмән! – тиб, Тарағайның хатунун алдурды. Ул ахмақ тәкдирне тәдбир берлә бозмақ теләде. Әмма Хақ Тәғаләнең тәкдире нитәк бозулур.

Андин соң киңәштеләр, «бу хатунны үлтүрәлек» тиб, «эчен йаралық» тиделәр. Анда Җәдай хан *// (2б кәгазь)* үзе әйде: «Әй, йаранлар! Бу хатунның қорсақындағы бала мәне үлтүрүр булса, ул қорсақындағы баласыны тезләб-тезләб үлтүрең, анасы үлмәсүн!» – тиде.

Андин соң ул хатунны йықыб, андағ тезләб-тезләб тезләделәр кем, исе-осы китде, үлә қа[л]ды.

Анда хан әйде:

– Имди баласы дүгел, анасы һәм үлде буғай[2].

Андин соң Җәдай хан әйде:

– Қурқынычындин қотулдым, – тиб торур ирде. Ханлықға мәғрүр-мәшғүл улды.

---

[1] Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «2499т» шифры белән саклана торган кулъязмадан алынды. Кулъязманың башында ярты бит чамасы тексты билгесез.

[2] Кулъязмада текстка өзеклек кергән. «Икенче текст»ның бу урынында «йибәреңләр! – тиде.
Андин соң ул хатунны күтәреб алыб, арбаға салыб киттеләр» дигән сүзләр язылган.

Андин соң бер анча көнләрдин соңра ул мескин тезләб имгәнгән[3] хатунның күзе йаруды[4], бер ир уғлан туғурды. Ул уғланны алыб бақтылар ирсә, бер айақы ақсақ ирде. Анда әйделәр кем: «Ошбундағы имгәкдин үлмәй қотулуб туғдың, жаның тимер икәндүр!» – тиделәр. Ул уғланның атыны һәм ул сәбәбдин Ақсақ Тимер қуйдылар[5].

// (3а кәгазь) Имди хәзрәти Ақсақ Тимернең тө[бе] барлас дигән ру булур ирде, нәселендә-руында ханларға җәйан уғул ирде. Андин соң йәнә Ақсақ Тимернең атасы-анасы үлде, йәтим қалды. Асрарға, күрәргә һич лайық кеше булмады. Ахыр, үзе йөрүрдәй[6] булуб, ир йиткәндин соң қазақ чықыб, йалғузы Шымақ шәһәрегә барды, бер анча йөрүде, андин Шымақда бозау көтмәгә йалға керде. Үзегә үзе кебек йәтимләрне ийәләндерде, алты-йите уғул бер булуб һәр көн бозау көтәр ирде, болар тәқи уйнарлар ирделәр.

Анда[7] Ақсақ Тимер көнләрдә бер көн бер бозуқ[8] кәшанә төбендә йалғуз тай[а]ныб бақыб торур ирде. *// (3б кәгазь)* Бер айағы ақсақ ирде, тәқи бер күзе суқыр қырмысқа килде, тәқи ул кәшанегә тырмашыб[9] менәргә йабушды. Бер анча йуқару менде, йықылды. Андин соң йәнә һиммәтләнеб, тәқи йабушды[10], тырмашуб менәргә ябушды, тырмашуб кәшаненең башыға менәйен, чықайын тигүнчә йәнә түбән йықылды. Бу хәзрәти Ақсақ Тимер қырмысқаның бу эшегә қараб, таңға қалуб, қараб торур ирде. Ақсақ[11] қырмысқа, ғарләнмәйен, йәнә өчүнче мәртәбә кәшане башыға менәргә йабушды. Ахры, тырмаша торғач кәшане түбәсегә чықыб ултурды.

Ул қырмысқадан бу хәзрәти Ақсақ Тимер аны күрде, йәнә әйде: «Бу зәғиф, айақсыз-күзсез[12] қырмысқа һиммәтләнеб йықыла торғач тәмам түбәсегә менде, йуқару чықды. Мән һәм һиммәт берлә хан *// (4а кәгазь)* булуб, ил-көн, шәһәрләр алыб, урдалар алсам, һич таң-ғәҗайеб булмас. Әгәр Тәңре Тәғалә бойур[са]», тиб, күңлүнә бу фикерне салуб йөрүр ирде.

Тәқи ул уғланлар берлә уйнар ирде. Көнләрдә бер көн Ақсақ Тимер әйде:

---

[3] Кулъязмада: икән. Монда «имгәнгән» сүзе «Өченче текст»тан алынды.
[4] Кулъязмада «барыды» дип ялгыш язылган.
[5] Мондагы соңгы өч сүз кустодта язылган.
[6] Кулъязмада «бөрүдәй» дип хаталы язылган.
[7] Кулъязмада «андағ» дип ялгыш язылган.
[8] Кулъязмада «бозау» дип ялгыш язылган.
[9] Кулъязмада «кәтерматыб» дип хаталы язылган.
[10] Кулъязмада моннан алдагы җөмләнең «бер анча» дигән сүзләреннән башлап шушы урынга кадәрге текст өлеше ялгыш кабатлап язылган.
[11] Бу урында ялгыш «Тимер» дип язылган.
[12] Кулъязмада «айақсыз-қулсыз» дип ялгыш язылган.

– Әй, йегетләр! Килең, бер йиргә бер нәрсә қуйалы. Ул қуйған нәрсәне кем элек йөгерүб алса, аны арамызда хан қыйлалық! – тиде.

Анда ул йегетләр әйделәр:

– Хуш, андағ булсун, – тиб, – алысқа бер нәрсә илтеб қуйалық. Тәқи барча уғланлар йөгерүшделәр. Ақсақ Тимер [һәм] йөгерүр ирде. Уғланлар ышайы бара алмады, аның өчүн кем – ақсақ ирде. Андан бер уғлан йөгерүб узуб, «ул қуйған нәрсәне алайын, мән элек хан булайын» тигүнчә, андин борунрақ ул нәрсәне Ақсақ Тимер бүрке берлә ташлаб орды. Тәқи әйде:

– Әй, йегетләр! Сездин борун мән йитдүм, мән хан булурмән! – тиде.

Ул берәүесе әйде:

– Йук, *// (4б кәгазь)* сәндин борун мән алдым! – тиде.

Анда Ақсақ Тимер:

– Һай, сәнең қулың йиткүнчә, мәнем башым йитде!

Бонлар бу сүз өстүндә бәхәсләшеб торурлар ирде, бер сақаллы қарт кеше килде. Болар ул қартқа эшләрен сөйләделәр, «Ханлық қайсумызга тигәр?» – тиделәр.

Анда ул қарт әйде:

– Әй, йегетләр! Сезләр мәнем сүземне тотармусыз? – тиде.

Болар әйделәр:

– Әй, баба! Сән һәрнә дисәң, эшемезне сәнгә салдуқ, – тиделәр.

Анда ул әйде:

– Әй, йегетләр! Бу ақсақ уғулның сезнең қулыңыздин борун башы йитүбдүр, моны хан қыйлуңыз! – тиде. – Сүз моның сүзедүр! – тиде.

Анда бу үзгә йегетләр әйттеләр:

– Әй, баба! Хуш, имди [андағ] қыйлайын, – тиделәр. Ақсақ Тимерне үзләре араларунда хан қыйлыб уйнар ирделәр.

Йәнә көнләрдә бер көн Ақсақ Тимер әйде:

– Әй, йегетләр! Һәркем ошбу көтә[13] торған бозаулардан бер бозау суйуб, барчамызға йидүрсә, арамызда аны хан күтәрәле *// (5а кәгазь)*, – тиде.

Анда йәнә үзгәләре қыйыб бозауны суйа алмадылар. Ақсақ Тимер бер бозауны суйды, пешүрде, ул уғланларға йидүрде. Ашадылар, андин соң Ақсақ Тимерне үзләре араларында хан күтәрделәр. Андан қайтыб өйләренә килделәр, бозау ийәсенә әйделәр:

– Бозавыңны бүре ашады, – тиб.

Ул нәрсә димәде, «бүрегә бойурған икәндүр» тиде.

Андин соң, көнләрдә бер көн Ақсақ Тимер бу уғланларға әйде:

---

[13] Кулъязмада «көти» дип хаталы язылган.

– Әй, йегетләр! Килеңез, безләр қарақчы булайық, базаркянләрне, сатучыларны тоталық, малын[14] алайық! – тиде.

Анда ул уғланлар әйделәр:

– Хуш булсун! – тиделәр.

Анда Ақсақ Тимер әйде:

– Сезгә сүзем улдур кем, имди бу кичә һәрқайсуңыз һич үзгә нәрсә алмаңыз. Мәгәр йау *// (5б кәгазь)* қоралын қуймаңыз, алуңыз! – тиде.

Анда бер бозуқ кәрвансарай[15] бар ирде, болҗалны анда қыйлдылар. Төннең йарымында килеб бер-берсенә йулуқды, қайсысы көб[ә] мылтық алыб[16] киттеләр. Һиндустан шәһәренең йулын сақлаб йатдылар, узған-барған сатучылар, асламчыларны[17] бастылар, малларыны алдылар, олу қарақчылық қылдылар.

Азған-тузған, ата-анадин бизгән уғланлар, байдан қачқан қоллар аңар җыйылдылар, қушулдылар. Һәркем тышдан килеб аңар қушулса, аңар лайық алапалар бирә башладылар. Базиркянләрне, сатучыларны қырдылар, қол-қотанны йулдаш қылдылар, бер ике-өч йөз кеше булдылар. Узған-барғанны талар ирделәр, йул киселде. Кәрван халқы йөремәс[18] булдылар.

Анда Һиндустан падишаһ[ы] Җәдай ханға хәбәр төште – «Йулны қарақ сақлар, кешене йөрт- *// (6а кәгазь)* -мәйдүр» тиб. Андин соң Җәдай хан[19] илче йибәрде. Өч йөз кеше берлә килеб:

– Ақсақ Тимер! Нә өчүн уғрылық қыйлурсән, йулларны бағларсән? – тиде.

Анда Ақсақ Тимернең чирүе ул килгән илчебашын үлтүрделәр, үзгәсен барчасын үзләренә йулдаш қылдылар, күб ағыр алапалар бирделәр.

Бу хәбәр йәнә Җәдай ханға ишетүлде. Үртәнде, көйенде, йәнә икенче мәртәбә[20] илче йибәрде. Ул икенче килгән илченең башын йибәрделәр, үз[гә]ләрен алыб қалдылар, йулдаш қылдылар. Андан соң Җәдай хан йәнә өчүнче [илче] йибәрде, «ул қарақларға алтун-көмүш алапа биреб, узған-барғанға, базаркянләргә тимәсүн» тиб.

Анда болар әйделәр:

– Имди Җәдайның қазнасындин безнең қазнамыз күбдүр, кирәк булса бездин алсунлар, – тиделәр.

---

[14] Бу сүз кулъязмада ялгыш ике мәртәбә язылган.

[15] Бу сүзнең «кәрван» өлеше хаталы язылган.

[16] Кулъязмада текстка өзеклек кергән. «Икенче текст»ның бу урынында «қайсысы уқ-садақ, қылыч алыб, ушал Шымақи шәһәрендән чықыб» дигән сүзләр язылган.

[17] Кулъязмада «исламчыларны» дип ялгыш язылган.

[18] Кулъязмада «йөресән» дип хаталы язылган.

[19] Кулъязмада «Җәдай хан» сүзләре хаталы язылган.

[20] Кулъязмада «мәрйәнә» дип хаталы язылган.

Андин соңра йәнә бер анча көнләрдин соң Җәдай хан үзе чирүен йыйыб киләдүр тиб әйделәр, Ақсақ Тимергә хәбәр төште. Ақсақ Тимер белүргә шымчы йибәрде, Җәдай хан киләмү иркән тиб. Ул шымчы барыб күрде – Җәдай хан *// (6б кәгазь)* килә йатур. Шымчы барыб[21] анларның арасына керде, Җәдай хан утуз кеше берлә үзе килүр ирде. Бу барған шымчыны күрделәр, мондин сордылар:

– Йа, йулда[22] қарақ барму? – тиделәр, – күрдеңмү?

Бу әйде:

– Йуқ, һәргиз күрмәдүм, бу йулда һич шиксез йөрүн, қарақ йуқдур, – тиде.

Болар моның бу сүзенә бақыб, «қарақ йуқ ирмеш, безнең килгән хәбәремезне ишетеб қачқандур» тиделәр. Илгәрү узыб китделәр.

Бу шымчы үз йоруғына[23] анлардин айырулыб, аулаққа чыққандин соң қачты, Җәдай хан утуз кеше берлә килә йөргәнен Ақсақ Тимергә килеб әйде.

Анда Ақсақ Тимер әйде:

– Алай булса, тиз[24] имди утуз түә йөге йөкләндүрең! – тиде.

Шул уқ заман утуз түә йөге йөкләделәр. Ақсақ Тимер Җәдай ханның килә торған йулы берлә қаршу булдылар. Җәдай хан төшүб йатур ирде, болар қаршу бардылар. Җәдай хан болар берлә йырақдин сүзләшде:

– Ни кешеләрсез? Йулда қарақ күрдеңезмү? – тиде.

// (7а кәгазь)[25] Бонлар әйделәр:

– Йуқ, [һич күрмәдүк, – тиделәр. Андин соң] Җәдай хан боларның қашыға килделәр. Анда болар әйделәр:

[– Һа, сезләр нә кешеләрсез?

Анлар әйделәр:

– Безләрне сорсаңыз, без Җәдай ханбыз, қарақларны эстәй чықдуқ, – тиделәр.

Анда болар:

– Андағ] булсаңыз, без сатучыларбыз, [бездән малыбызның тамға]сын алың, үзебезгә һәм йул [йөрүргә, сату қылу]рға йахшы [булур], – тиделәр.

Анда Җәдай хан [бу сүзгә туқтаб тик] торды, бойурды:

---

[21] Кулъязмада «барыр» дип ялгыш язылган.
[22] Кулъязмада «йундаш» дип хаталы язылган.
[23] Кулъязмада «бойуруғына» дип ялгыш язылган.
[24] Кулъязмада «бурса тын» дип хаталы язылган.
[25] 7 нче кәгазьнең өске тарафы кыйгач рәвештә ертылып төшкән. Шунлыктан, 7а һәм 7б кәгазьләрдәге квадрат җәяләр эчендәге текст өлешләре «Икенче текст»тагыча бирелде.

– Тамғасын а[лыңлар! – тиб. – Болар безгә, ша]йәт, бер тансу[к] мал алыб килгәндү[р, – тиде].

Андин соң Җәдай ханның кешеләре йөкләрне ақтарыб, тамға алайын тигүнчә Ақсақ Тимернең кешеләре берен-берен тотуб үлтүрделәр. Хәзрәтемез Ақсақ Тимер үзе Җәдай ханны тотты үлтүрүр өчүн. Җәдай хан әйде:

– Аһ, Ақсақ! Мән сәнгә йахшылық қыйлдым, сән мәнгә йаманлық қыйлурсән, үлтүрүрсән, – тиде.

Анда Ақсақ Тимер әйде:

– Сән // *(7б кәгазь)* [ғафилсән, мән – ға]фил дәгүлмән[26]! [Мән үзүмгә] йаманлық қыйлмазмән, мән [үзүмгә йахшылық қылурмән], – тиде. Үлтүрде, башын [кисде. Андин соң] шәһәренгә барыб], анда хан булды. Тәқи бу қалған [чирүгә чабқун] йибәрде, «үзгә йул берлә килсүнләр!» [диб. Чирүенә] хәбәр төшде ирсә, рәван килеб анлар [һәм шәһәргә инд]еләр. Шәһәрне алдылар. Андин бу Җәдай [ханның арты]нда қалған чирүе бу хәбәрләрне, бу эшлә[рне аңлама]йын, «ханымызға анда йитәрмез, монда йитәрмез» тиб бара торғач, йитә[27] алмай, қайтдылар. Ханларын йуғалтыб килделәр ирсә, «шәһәрне Ақсақ Тимер алыбдур» тиб, һич нәрсә итә белмәделәр, Ақсақ Тимергә бағындылар.

Имди Ақсақ Тимер Һиндустан шәһәрене ошбулай[28] алды тиб тәйүрләр. Әмма аңа Тәңре үзе йулдаш булғандур шәһәрләр-йортлар алмаға, урдалар вәйран булмақлыққа аны сәбәб қылғандур. Һәр йахшы[29] [...]

// (8а кәгазь) Бу шәһәрне Ақсақ Тимүр оруш-туқуш берлә алмады. Ахры, ошбундағ хәйлә төзде кем, үзене сырхау қыйлды, тәмам тәне[гә] сарығ зәғферан сөртде: тәне, башы, күзе сары булды. Андин соң Шаһ-солтан ханға илче йибәрде мондағ сүз берлә кем: «Әй, Солтан! Имди беләсән, мәнгә әҗәл ирешде, тәмам тәнем сары булды һәм [гөнаһым] шомлықындан имди сәндин үтен[ә]мән кем, бу эшләрне, орушмақлықны қуйдум. Рәхим қыйлыб, сән мәнең берлә бәхилләшсәң ирде?» – тиб, хат бөтеб бирде.

Ул илче килеб шәһәр қабусына варды, илчелеген [белдүрде]. Андин ул хатны алыб Шаһ-солтанға илттеләр. Солтан қараб күрде, «шайәд йалғандур» диб, «хәйләдүр» тиб, ышанмадылар. Ул һәм моның сырхаулықын белмәк өчүн кешесен йибәрде, «Барғыл, күргел!» – тиде.

Андин Шаһ-солтанның йибәргән кешесе Ақсақ Тимүрнең чадырыға килеб керде, күрде кем – Ақсақ Тимер сары зәхмәте берлә хәлсез улуб йатур.

---

[26] Кулъязмада «дәгүлсән» дип ялгыш язылган.
[27] Кулъязмада «йәнә» дип ялгыш язылган.
[28] Кулъязмада «ошбулар» дип ялгыш язылган.
[29] Бу ике сүз кустодта язылган. Аннан соң кулъязманың бер кәгазе төшкәнлектән, текстка өзеклек кергән.



Җиденче текст кулъязмасы

Аҡсаҡ Тимүр әйде:

– Әй, // *(8б кәгазь)* илче! Мәнем хәлем усалдур, – тиде.

Андин соң ул йибәргән кешесе Шаһ-солтанға килеб сөйләде:

– Сырхау улмышдур, хәл эчендәдүр, – тиде. – Ғәйәт илтимас қыйлды кем, рәхим итеб әйтде, – тиде.

Шаһ-солтан аның сүзенә [ы]шаныб, шәһәрнең тәмам қапуларын ачтурды һәм ләшкәре[30] берлә чықды, Ақсақ Тимер[гә] килде. Күрешүб сүзләштерүр иркән, сырхаулықындин торуб, Ша[һ]-солтанны тотты, үлтүрде. Килеб ләшкәр-чирүе шәһәргә инделәр. Бу хәйлә берлә ул шәһәрне һәм алдылар. Ул урда[ны] һәм үзегә бақтурды. Бер анча йыллар анда торды.

Андин йәнә чирүе йараштурды, Шымақ шәһәрегә килде, уны һәм алды, үзегә бағундурды.

Андин узуб[31] йөрүб, Хаҗитархан шәһәрегә килде, орушуб-туқушуб Хачитарханны һәм алды, бақтурды. Анда биш[32]-алты йыл торды.

Андан соң йәнә Болғар шәһәрегә килүргә йарағуланды, күб-күб қатырғалар, ким[ә]ләр берлә Болғар шәһәрене *// (9а кәгазь)* алғалый килүргә менде. Қайсы ошбу Идел [суының тыш йағындан] килделәр, чирүенең саныны-хисабыны Аллаһдан ғәйре кеше белмәс ирде.

Ушда анлар мондағ олуғ чирү берлә килмәкдә. Әмма ул заманда-дәвердә, ул заманда ханлары Ғабдулла хан дигән ирде. Ғабдулла ханға хәбәр ирешде кем, «Ақсақ Тимер киләдүр» тиб. Шул заман Ғабдулла хан ләшкәрене йыйдурды, ағыр чирү хәзерләб, қаршу торды. Ахры, бер-берсенгә йулуқушуб қаты оруш қылдылар. Ақсақ Тимернең орышыға түзмәделәр, сындылар. Килеб шәһри Болғарға керделәр: үлгән[дин] қалғаны шәһәрегә берекләнделәр.

Ақсақ Тимер килеб, шәһри Болғарны [йите] йыл қамады торды. Тарих йите [йөз] йылда ирде, зөлхиҗҗә айының йегермесендә ирде, шәһри Болғарны алдылар, хәраб қыйлдылар. Йөз дә йегерме түрт олуғ бикләр бар ирделәр, анларның тәма[мысын] қырдылар. Һәрқайусы- *// (9б кәгазь)* -ның кә-әмсалел-ләә-ләә әл-мәкнүн хатунларыны Ақсақ Тимер [ә]сир қылды. Ул бикләр эчендә түрт олуғ бикләр бар ирде, асыл шаһзадәләр ирде. Болар: бер[е] – Қабал бик, бере – Муқаш бик дирләр ирде – тәмамын һәлак қыйлдылар. Күб-күб хәлайық [һәлак] булдылар. Ғабдулла ханны һәм үлтүрделәр.

Әмма Ғабдулла ханның ике уғылы бар ирде, берсе – Алтунбик, икенчесенең аты Ғалимбик [дигән ирде. Җаудин-қырғындин қачуб қалған кешеләр Алтунбик берлә Ғалимбикне][33] урман төбегә илтеб йәшүрделәр. Бере йите йәшендә, берсе туғыз йәшендә ирделәр. Анлар[ны] йахшы асрар ирделәр.

---

[30] Кулъязмада «ләскәре» дип хаталы язылган.
[31] Кулъязмада бу ике сүз ялгыш икешәр мәртәбә кабатланган.
[32] Кулъязмада «пиш» дип хаталы язылган.
[33] Квадрат җәяләр эчендәге текст өлеше кулъязмада төшеп калган. Монда «Икенче текст»тан алынды.

Андин соң Ақсақ Тимер шәһри Болғарны вәйран қылыб, хәраб қылғандин соң Бүләр[34] шәһәренең қаршусыға килеб, ур қазыб йатдылар, оруш-туқуш қыйлмадылар. Ул вақытта Бүләр шәһәренең ханы Самәт[35] хан дигән ирде, көбәсен «безқабақ» дигән, халқы бараҗ дигән халқы ирде.

Бараҗ халқының әүвәл замандағы төб йорты ошбу Зәй тамағында улур ирде, алыбларның заманы ирде[36], *// (10а кәгазь)* бер Бараҗ атлығ аждаһа йылан килде. Ул шәһәрнең халқыға көч-зыйан қыйла башлады. Чықыб аждаһа берлә суғышдылар, йиңә алмадылар. Ахыр, үзләре Болғар[37] шәһәренең йақыныға барыб, Бүләр суының өстегә йорт-шәһәр салдылар. Ул шәһәрләрегә һәм Бүләр тиб атадылар, ул сәбәбдин халқыны бараҗ Бүләр берлә халқы тиб әйтүр ирделәр, оранлары[38] «бараҗ» ирде.

Анда Самәт хан әйде:

– Аһ, әй, бараҗ халқы! Борун олуғ баба[лары]мыз Бараҗның зыйанындан[39] қачыб шәһәрләрен салыб, ошбундағ килебләр, мәқам-йорт тотублар. Имди Бараҗдин көчле Ақсақ Тимер килде, шәһәремез қаршусыға төшде. Ни қыйлурмыз? – тиде.

Анда[40] ул бараҗ халқы әйделәр:

– Әй, ханым! Сезләр белүрсезләр, ирек[41] сезнеңдүр! Безләрә һәрни дисәң, иркемез йукдур, – тиделәр. – Әмма бойурсаң, Ақсақ Тимер ләшкәре берлә орушырмыз – үлтүрүрмез йә без үләр- *// (10б кәгазь)* -мез[42]! – тиделәр. Анда Самәт әйде, хан әйде:

– Имди мәнем қашымда бер вәли кеше бардур, андин сорайын, ул ни бойурур, аның сүзендин чықмазмыз, – [тиде. Ул вәли кешене алдуруб сордылар, тәқи әйделәр:

– Ай, безнең олуғымыз! Имди][43] безләр ошбу өстүмезгә, шәһәремезгә килгән Ақсақ Тимер берлә оруш қыйлайынму? – тиде.

Анда ул вәли әйтүр:

– Хуш, қарайын, – тиб, бер манараның башыға менде. Тәқи Ақсақ Тимернең чирүе тарафыға қарады ирсә, күрде кем – хәзрәти Ақсақ Тимернең

---

[34] Кулъязмада «Болғар» дип ялгыш язылган.
[35] Кулъязмада «Сынтәт» дип хаталы язылган.
[36] Бу сүз кустодта язылган.
[37] Кулъязмада «Бүләр» дип ялгыш язылган.
[38] Кулъязмада «авыл атлары» дип ялгыш язылган.
[39] Кулъязмада «йанында» дип ялгыш язылган.
[40] Кулъязмада «андағ» дип ялгыш язылган.
[41] Кулъязмада «лик» дип хаталы язылган.
[42] Бу сүз хаталы язылган.
[43] Квадрат җәяләр эчендәге текст өлеше кулъязмада төшеп калган. Монда «Икенче текст»тан алынды.

Хозыр чирүендә бергәдүр. Андин соң ул манарадин төшүб, Самәт қашыға килде, тәқи әйде:

– Әй, ханым! Орышурға рөхсәт йуқдур! – тиде. – Хозыр хужа ғәләйһиссәлам аның чирүендә бергәдүр – тиб. – Тәңре Тәғаләнең тәқдирегә буйун сонмақ кирәк, қапқаларны ачтурғыл! – тиде ирсә, ул хан, тәқи бараж халқы йығлаштылар. Тәқи әйделәр:

– Ни қылмақ кирәк, Хақ Сөбханәһә вә Тәғаләнең хөкемене буйун сонмақ кирәк, – [тиб] шәһәрләренең тәмам қапқаларын ачтылар, *// (11а кәгазь)* ирек салдылар, орушын қыйлмадылар.

Андин хәзрәти Ақсақ Тимүр чирүе берлә шәһәргә инделәр вә халқыны қырдылар.

Әмма анда Ақсақ Тимер киче берлә үзе шымчы булуб, төсүн әверүб хәлайықларның эчегә кереб, сынай йөрүр ирде.

– Әй, хәлайықлар, йегетләр! Бу бөлүклүк, бу қырғын безгә кемдин торур? – тиб сорар ирде.

Анда ултурған, торғанлар әйтүрләр булса: «Безне Ақсақ Тимер бөлдүрде, аның шомлуғындан бөлүклү булдуқ[44]» дигән кешеләрне иртәгесен тәмам руы-тамуры берлә, қәүме берлә һәлак қыйлур ирде.

Һәм гөнаһыны үзүндин белеб әйтүр булса ирде «бу бер бөлүклүк үз шомлуғумыздин безгә йитте» тиб, руы берлә үлтүрмәй, таланмай йибәрүр ирде.

Әл-қыйсса

Кичәләрдә бер кич хәзрәти Ақсақ Тимер шымчы булуб бараж халқының арасыға инде, тәқи әйде:

– Әй, бараж халқы! Бу бәла сезләргә қайдин килде?

Анда анлар:

– Кемдә[н] ирдүкен белмәдемү сән? Убур Ақсақ Тимер *// (11б кәгазь)* килде, безне қырды, бөлдүрде, – тиделәр.

Анда ул киче ул жыйын[45] эчендә бер олу бикнең[46] ғақыллық, услық, тол қалған[47] хатуны бар ирде, ул әйде:

– Әй, йегетләр! Бу эшләр, бу бөлүклүкләр үз гөнаһымыз шомлықындан булды. Ул Ақсақ Тимер ни қыйлур ирде? Тәңренең тәқдиредүр! – тиде.

Ул хатунның ире Жадәш бик дигән ирде, ул хәзрәти Ақсақ Тимер

---

[44] Кулъязмада «йулдуқ» дип хаталы язылган.
[45] Кулъязмада «чыйын» дип хаталы язылган.
[46] Кулъязмада «олу бик бар ирде, аның» дип ялгыш язылган.
[47] Кулъязмада «усайық тулған» дип хаталы язылган.

килмәсдин борун үлгән ирде. Ул Җадәш бикнең ике уғылы бар ирде, берсе – Инсан[48], икенчесе – Ихсан ирде.

Ул кичәнең иртәгесен Ақсақ Тимер ул тол хатунны уғланлары берлә қашыға алдурды. Болар ни эшкә алдурғанын белмәйен, «безләрне үлтүрүр» тиб, йығлашыб килделәр. Ақсақ Тимер ул хатунға әйдүр:

– Сән гөнаһын үзеңдин белүрсән, «һәр эш безнең үз шомлуғымыздан» тиб әйтүрсән. Имди бу көндин соң сән[е] тәмам уғылуң-қызың, қәрендәшләрең берлә йарлықадым. Һәрқанда барсаңыз, сәүсәңез – ул // *(12а кәгазь)* тарафға киткәйсез! – тиде. Үзе һәм тәмам чирүгә [йар] салды:

– Бу кеше тимәңләр[49], малыны таламаңлар һәм нәрсәсегә зыйан тигүрмәңләр! – тиб, ул бөлүклүкне, гөнаһны үзүндин тигән өчүн тәмам уғылумыз-қызымыз, қәрендәшләремез берлә йарлықаб йибәрде.

Андин соң ул бик, бере Инсан бик, [берсе Ихсан – икеләсе киңәш итеб күчмәгә нийәт қылдылар. Инсан бик][50] әйде:

– Әй, анам! Мән ошбу олуғ Иделнең эч йүнегә – Тау йирегә барурмән, анда мәқам-йорт тотармән, аның өчүн кем – ул һәр йирдән бәрик йирдүр, – тиде.

Анасы һәм аның сүзене йаратыб қабул қыйлды.

Әмма энесе Ихсан бик ул [тарафқа барурға өнәмәде, иске бабаларым йортыға – Зәйгә барурмыз, мәқамен-йортын тотармән, – тиде.

Инсан бик әйде:

– Мән ул йиргә бармандур, – тиб, айырылды. Тау][51] тарафыға китде. Ан[а]сы һәм аның берлә китде.

Анда барыб, Гөбенә[52] дигән суның буйында мәқам тотды. Инсандин бер уғул туғды, атыны Сөләйман қуйды. Уғылы Қәдер, Қәдер уғылы Нурдәүләт, уғылы Нур, уғылы Әбдал, уғылы Хуҗамөхәммәд, Хуҗамөхәммәд уғылы Тәвәккәл, Тәвәккәл // *(12б кәгазь)* уғылы Пирмөхәммәд, Пирмөхәммәд уғылы Җантый, Җантый уғылы Бәйеш, Бәйеш уғылы Үлмәс, Үлмәс уғылы Чуқаш, Чуқаш уғылы Йанбулай, Йанбулай угылы Мөхәммәд, Мөхәммәд угылы Ғәбдеррахман мулла, Ғәбдеррахман мулла угылы Ғәбделғәзиз, икенче Мөхәммәдшәриф. Ғәбделғәзиз уғылы Ғабдулла, икенче Ғәбдессәлам.

Әмма Ихсан бик Тау тарафыға мәйел[53] қыйлмайын, Зәйгә килде.

---

[48] Кулъязмада: Инсаф.

[49] Кулъязмада «бәтмәңләр» дип хаталы язылган.

[50] Квадрат җәяләр эчендәге текст өлеше кулъязмада төшеп калган. Монда «Икенче текст»тан алынды.

[51] Квадрат җәяләр эчендәге текст өлеше кулъязмада төшеп калган. Монда «Икенче текст»тан алынды.

[52] Кулъязмада «Гөйнә» дип хаталы язылган.

[53] Бу сүз кулъязмада хаталы теркәлгән.

Ихсандин бер уғул туғды – Шәмәк, Шәмәк уғылы Туғ[ый], Туғый уғылы Сәман, Сәман уғылы Ындурчы, Ындурчы уғылы Тикәнеш, Тикәнеш уғылы Бәзәргян ирде. Тамғалары «қуш кәшан», оранлары[54] «бараҗ» торур.

***

Имди йәнә сүзен башдин сөйләйәле. Ул[55] хәзрәти Ақсақ Тимер Бүләр шәһәрен вәйран қыйлғандин соң Мәскәү тарафыға китде, анда ләшкәре берлә баруб Аладимүр дигән гәүрнең қаласыға йитде, орыш[56] қылғай нийәт қылды. Вә гәүр һәм[57] чирүен *// (13а кәгазь)* ул қаласыға җыйдурды. Хәзрәти Ақсақ Тимер барған вақытда кяфер-урыс гәүрнең ханы Мих[а]йла атлығ ирде. Хәзрәти Мир Тимер шәһәрләр алыб[58] аңар барған[59] хәбәрләре гәүргә ирешүб, қаты қурқуғда ирде. Хәзрәти[60] Мир Тимер гәүрнең қаласы Аладимүргә йитүб ирде, хәзрәти хуҗа ғәләйһиссәлам[61] килеб Ақсақ Тимер[гә] әйде:

– Халә[62] бу [кяфер берлә орушурға, тәқи қырарға вәғдә ирешмәйдүр! – тиб хәбәр бирде. Әмма бу][63] кяфергә кәрамәтеңне күрсәткел! – тиде ирсә, хәзрәти Ақсақ Тимер шул заман тора салыб өч йәшәр тай берлә кяфер тарафыға атды. Хақ Тәғаләнең қөдрәте берлә, ул ташлаған тай барыб кяфернең таш[64] манасырыны уртара өзүб, бер чақрым йир[65] барыб төште. Тай төшкән йир су булды.

Андин соң хәзрәти Мир Тимер орушмай (вәғдә[66] ирешмәгән өчүн) чирүе берлә қайттылар[67]. Қайтыб Бохара[68] шәһәрегә барурға йүнә[л]деләр. Килә йөргәнендә қайа йирләрендә Амәт, Самәт *// (13б кәгазь)* дигән, күчәле ике ханға хәбәр төшде «Ақсақ Тимер киләдер» тиб. Ту бийә суйуб, халқын йыйыб, «қайу тарафға күчәлек?» тиб киңәш қыйлдылар. Анда ул халық

---

[54] Кулъязмада «орунлары» дип хаталы язылган.
[55] Кулъязмада «үкәл» дип хаталы язылган.
[56] Кулъязмада «ун» дип ялгыш язылган.
[57] Кулъязмада «гәүһәр» дип ялгыш язылган.
[58] Кулъязмада «алаб» дип хаталы язылган.
[59] Кулъязмада «барағау» дип хаталы язылган.
[60] Кулъязмада бу сүздән соң «хуҗа» дип язылган.
[61] Кулъязмада: ғһм.
[62] Кулъязмада «хилә» дип ялгыш язылган.
[63] Квадрат җәяләр эчендәге текст өлеше кулъязмада төшеп калган. Монда «Икенче текст»тан алынды.
[64] Кулъязмада бу сүз хаталы язылган.
[65] Кулъязмада «йитәр» дип ялгыш язылган.
[66] Кулъязмада ике сүз ялгыш кушылып, «орушмадығында» дип язылган.
[67] Кулъязмада бу сүз ялгыш ике мәртәбә язылган.
[68] Кулъязмада «бу Хорасан» дип ялгыш язылган.

уңмаслық қыйлыб, берәү[69] атын мақтады, берәү тунун мақтады, берәү алған хатунун мақтады. Пешкән ит-аш ашалды, киңәш булмады, халық уғылы тарқады. Анда Кинчә дигән берәү йығлаб әйде:

– Әй, қалтақлар[70]! Үзе ала сан кеше булғунча, үзе ыруы бер қырық кеше булса ирде, һәрайинә, бер эш қыйлур ирдүк.

Әй, қалтақ! Бу ни эшдүр?
Ғақилләр буны сүзләр,
Ғақылсызлар көләрләр,
Киңәш җыйурлар.
Қалтақ! Бу ни [эш]?
Берәү атын мақтар,
Берәү хатунын мақтар,
Берәү [тунун мақтар] –
Киңәш булмас, халық уғылы тарқар,
Ашын ашады[71] – қачар китәр.

Һәрайинә, безнең бөлүклүгемезгә[72] сәбәбдүр, безгә бөлүклек йақындур! – тиб йығлар ирде. Анда ул Кинҗә әйтүр:

– Әй, йаранлар, халық уғылы! Без мондин күчәйек, сез монда қалсаңыз[73], Қуй суының башында Олу Убада[74] болҗалый булсун. Без ул тарафға күчәйек!» – тиб әйтүр ирде.

Анда йәнә берәү атының ақ күбүкдин[75] [...]

[69] Кулъязмада «серәү» дип хаталы язылган.
[70] Кулъязмада «қалталықлай» дип хаталы язылган.
[71] Кулъязмада «ашарды» дип хаталы язылган.
[72] Кулъязмада «бөклүмезгә» дип хаталы язылган.
[73] Кулъязмада «қалыңыз» дип ялгыш язылган.
[74] Кулъязмада «Убарда» дип хаталы язылган.
[75] Соңгы ике сүз кустодта язылган. Дәфтәр ахырындагы бер кәгазе җуелган булуы сәбәпле, текст шул урында өзелә.

СИГЕЗЕНЧЕ ТЕКСТ[1]

[Дастане Ғәйсә уғылы Амәт]

// (1а кәгазь) [...] солтан[ның] атасы ирде, уғланлар ачуы килеб, атасыға сүз [әйтделәр: «Уғу]л кирәк булса, [туқуз] уғулың бар, бер уқ қыз – аны сән күб кұрәрсән?! – тиделәр.

[Андин соң] ачиғланыб қызны үлтүрүргә кеше йибәрде[2]. Тайдулы[ның ике арғама]қ [бар и]рде. Беренең аты Ашытча дигән ирде, бересенең аты Тутғыча ди[гән] ирде. [Бу ик]е атны қушландуруб, қызны қачурсун тиб йибәрде.

Бирдебәккә хәбәр төште. [Қызны алу]б қачты, Чиркәскә барыб мәкян тотты.

Җанибәк ханның бу эшегә халықның күңеле йаман булды. «Уғланларын қуа башлады» тиб әйтүр ирделәр. Хан халықның күңеле йаман булғанын белеб, бер көн әйде кем:

– Кем мәнең уғылумны килтүрсә, [қызымны] аңа бирүрмән, – тиде.

Анда Ғәйсә уғылы Амәт әйде:

– Имди, ханым, әгәр сорғалый булсаң, мән килтүрүрмән! – тиде.

Хан әйде:

– Хуш, алай булсун! – тиде.

Ғәйсә уғылы Амәт әйде:

– Мәнгә сән халықның күз алдында ачиғланған булғыл?! – тиде. Анда барыб алдарыма[3] йахшы булур, – тиде.

[Бу] эшләре күб кеше белмәс ирде. Амәтнең китәр көнне [...][4] дигел, кичә берлә килүрсән, дәхи зынҗырны тақды қалды.

Амәт бинең бер қолы бар ирде, ул қолға қылыч бирде, «Барыб Бирдебәкне сән қылыч берлә чабқан улғыл! Вәли[5] қылычның йөз[е] берлә чабмағыл!» – тиде.

Қолы йөгерүб [йитде], Бирдебәкне қылычның сырты берлә орды.

---

[1] Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1147т» шифры белән саклана торган кулъязмадан алынды. Кулъязманың башында бер бит чамасы тексты билгесез.

[2] Кулъязмада «йиәрде» дип хаталы язылган.

[3] Кулъязмада «улдыралым» дип ялгыш язылган.

[4] Кулъязманың бу урынында текстка шактый зур өзеклек кергән.

[5] Кулъязмада «ди» дип ялгыш язылган.

Бирдебәк ачиғланыб: «Бу [нә] эшдүр?! – тигүнчә, андин соң Амәт үзе йөгүрүб барды, қолуның әлендән[6] *// (1б кәгазь)* қылычны тартыб алды, қолыны үлтүрде. Андин соң килүб [ханиш]не һәм үлтүрде, ул қортқаны һәм үлтүрде. Андин соң солтан Бир[дебәккә] әйде:

– Алған хатуның мондағ эшен қылды, үзгәләре нә қылмасдур?! – тиде. – Кил бир[е], ханға қайтурбыз, – тиде.

Анда ул Бирдебәк әйде:

– Хуш, а[лай] булсун! – тиде.

Күчүб қайтты. Амәт берлә Бирдебәк үзләре элгәрү килделәр, хан [каршу] чықты. Мәнгәл дигән байның өйегә төштеләр, чағыр-шәраб эчтеләр. Хан исерүб йоқлаб йатты. Мәнгәли бай йуқ ирде, хан йалғуз йатур ирде. Мәнгәли уғулы Тимә[й] килде, күреклү кеше ирде. Күңлүндә әйде: «Моңар[7] қызым тигәр иркән, – тиде.

Ул уғул торуб, тәғзыйм итде.

Амәт тора килде, әйде:

Охшарму, бикләр, охшарму, – тиб,
Нәчә дәүләт бар булса?
Арғамақның айағын
Йебәк бер[лә] тушарму?
Тимер игәб таш атқан,
Ғәйсә уғылы Амәт барында
Мәнгәл уғылы Тимәйгә
Қызын бирмәк охшарму?

– тиде.

Қырық қырқын ийәртеб Қырымға[8] китте. Қырымдан қул теләде. Қырым мөселманға чирү йибәрмәде. Хүнгәргә[9] барды, ул дәхи йибәрмәде. Андин Қызылбашға барды, Қырымдан қурқыб, ул дәхи бирмәде.

Қайтыб, ил эченә басыб, шымчы йибәрде. Хан ауға чыққанда қызыны алыб қачты, Зөйә тағында барыб, Идел йақасында торды. Имди аны «Қыз тавы» дирләр.

Хан аудин қайтыб килеб бақты, Амәт қызны алыб қачқанын белде. [...][10]

---

[6] Кулъязмада «әленендән» дип хаталы язылган.
[7] Кулъязмада «Мәнгәл» дип ялгыш язылган.
[8] Кулъязманың бу урынында һәм моннан соңгы җөмләләрдә Қырым атамасы «Қызым» дип ялгыш язылган.
[9] Кулъязмада «Қотеңәргә» дип хаталы язылган.
[10] Текст шул урында өзелә. Текст ахырының якынча бер кәгазь күләмендәге өлеше юк.

ТУГЫЗЫНЧЫ ТЕКСТ[1]

[Дастане Идегә би]

// (1018б кәгазь) [...][2] Қотлуқыйаны урус ханы шәһид[3] кыйлдурды.

Әмма Баба Түкләснең түрт уғылы бар ирде: бере Кәғбәдә бадишаһ булды, вә бер[е] Кәғбә йанында торур, вә бере Үргәнечдә йатур, бере Қырымда Өч Үтлүкдә йатур.

Баба Түкләснең бер ривайәт белән мәғлүм өч уғылы бар ирде: беренең аты Ғаббас ирде, Кәғбәнең уң йанында йатур, беренең аты Ғабдеррахман хуҗа торур, ул дәхи Кәғбәдә йатур вә беренең аты Тирмә торур, ул Идел-Җайықда хасил булды.

Пәйғамбәр саллаллаһу ғәләйһи вәс-сәлләмнең мөбарәк қәберләрен сәйиде нақыйбқа аваз биребдүр, икенче ғалим Мортаза сәйед торур, өчүнчесе ғәзиз кирамәт Баба Түкләс ата торур.

Үзбәк хан мөселман булғанда Үрәкчураны[4] Кәғбә шәһәреғә йибәребдүр. Анда бу өч алыб килеб мөселман булубдур.

Валлаһу әғләмү бис-саваби.

Әмма Идегә би Туқтамыш ханның олусын ул биләде. Идегә би уғылы Нуразын мирзадур, бөләсен-олусын биләгән.

Фасыл фи дастани вәл-мәҗалис[5] вәл-мәкян

// (1018а кәгазь) Имди мәғлүм ула, беләсез кем, йортларда Бохара – Болғар ханның йортыдур.

Тора – Орус ханның йортыдур.

Чирмешән – Өмәрхуҗа ханның йортыдур.

Өй-Үзән – Туқтамыш ханның йортыдур.

Җим-Җайық арасы – Җанибәк ханның йортыдур.

Ақ Идел тамағы – Қара ханның йортыдур.

---

[1] Россия дәүләт борынгы актлар архивында (Мәскәү) 248 фонд, 17 нче тасвир, 1164 саклану берәмлегенең 1016–1018 кәгазьләреннән алынды.

[2] Бу бүлекнең башындагы бер кәгазь чамасындагы тексты юк.

[3] Кулъязмада «шәһәрдә» дип ялгыш язылган.

[4] Кулъязмада «Чәван» дип хаталы язылган.

[5] Кулъязмада «вәл-мәхс» дип хаталы язылган.

Ақтүбә – Бачман[6] ханның йортыдур. Йүчи дигән аның кече энесе булур ирде.

Чахан ханның йортыдур Торатау тамағындан түбән Алмалы Атаға[7] тигрү ирде.

Ошбу Уфа тамағы – Тирә ханның йортыдур. Андин йәнә Торатауның урыны ушалдур.

Сарайчық – Чалсақ ханның йор[ты]дур.

Инчы – Хәким ханның йортыдур. Хәким ханны йир йотты[8], өч йылға-ча авазы килә йатты, андин соң килмәде.

Аждархан – Тимер Қотлу ханның йортыдур.

Кябид – Сибәркә ханның йортыдур.

Қазан – Шығали ханның йортыдур.

Зәй тамағы – Бүләр ханның йортыдур.

Валлаһу әғләмү бис-саваби.

Фасыл фи дастани фит-тарих

Тарих йите йөз *// (1017б кәгазь)* йылда ирде, Ақсақ Тимер Болғар шәһәрене алды Ғабдулла хандан. Ғабдулла ханның ике уғылы бар ирде: берсенең аты – Алтунбик, бересе – Ғалимбик.

Ул бөлүклүкдән соң килеб, Қазан дәрйасы өстүндә қәлғә йасадылар, шәһәр итделәр. Ул халық йөз дә түрт йыл анда тордылар. Ахыр, ул урунны йаратмайын, андан күчтеләр. Қазан суының тамағында[9] шәһәр төзделәр. Йөз дә илле сикез йыл анда булдылар. Мөселман хан нәселе анда киселде. Қазан шәһәрендә хан йуқ булды ирсә, ул заманда кяфер урусның қулунда Шығали хан тотқун ирде, мөселманлар барыб аны килтүрделәр. Ул Қазанда утуз өч йыл ханлық сөрде.

Андин соң кяфер урус күчүнеб, ләшкәре берлә шәһәрне[10] алғалый килде. Қалталы Җәван ирде, йите йылғача оруш-суқуш қыйлды, мөселманларны ала алмады.

Йәнә Қазан шәһәрен алмасдин борун, Зөйә суының тамағында *// (1017а кәгазь)* кяфер урус қәлғә суқты. Тубун, малын, қорал[11], азығын анда қуйды.

Андин соң, ахры бар, Шығали хан урусқа ғаммазлық қыйлыб, урус ханы берлә мөселманлардан өртен-белдүрмәй берегеб, дарыларға су

[6] Кулъязмада: Бахман.

[7] Кулъязмада «Атаныға» дип хаталы язылган.

[8] Кулъязмада «ханның йорты» дип ялгыш язылган.

[9] Кулъязмада «тамағындан» дип ялгыш язылган.

[10] Кулъязмада «шәһәрен» дип ялгыш язылган.

[11] Кулъязмада «қоры» дип ялгыш язылган.



Тугызынчы текст кулъязмасы

қойдурды, шәһри Қазанны кяфергә бирде. Мөселманлар бу эшдән хәбәрләре йук [ирде]. Күб адәмиләр һәлак булдылар, қырдылар. Йәнә ул қырғындин соң урус ханы Қазанны биләде – ул вақытда тарих туқуз йөз алтмыш бердә ирде. Қазан вилайәтен кяфер урус алды йәкшәнбә көн, ғәқрәб йолдузының икенче көн ирде, сычқан йылында ирде.

Имди Қазан шәһәрендә йорт биләгән ханларның атлары болардур:

әүвәл – Ғабдулла хан уғылы Алтунбик, Ғалимбик; андин соң Мәхмүд хан; андин соң Мәмәк хан; андин [соң] Хәлил хан; андин соң Ибраһим хан; андин соң Мамуқ хан; андин соң Ғәбде- *// (1016б кәгазь)* -лләтыйф хан; андин соң Сахибгәрәй хан; андин соң Сафагәрәй хан; андин соң Ғәли хан; андин соң Үтәш хан; андин соң Йәдегәр хан (әмма Йәдегәр хан заманында – тарих туқуз йөз йегерме сикездә[12] көн тотулды); андин соң Шығали хан. Андин соң урус алды.

Андин соң тарих мең дә унда ирде, олу ачлық булды.

Андин соң тарих мең дә ун йитедә ирде, кенәз Митрәй йағы булды, тавық йылы ирде.

Андин соң тарих мең дә йегерме түртдә ирде, Җанали йағы булды, тавышқан йылы ирде.

Андин соң тарих мең дә илле йитедә[13] ирде, иргә чирү[14] булды, йылан йылы ирде.

Андин соң тарих мең дә илле өчдә ирде, кенәз Михайла хан булды, қуй йылы ирде.

Андин соң тарих мең дә алтмыш бишдә ирде, үләт булды, йылқы йылы ирде.

Андин соң тарих мең дә йитмеш бердә ирде, башқорт урыс берлә йағ булды, барыс йылы ирде.

Андин соң тарих мең дә йитмеш *// (1016а кәгазь)* туқузда ирде, бәлид қазақ йағы булды.

Мең дә сиксән туқузда ирде, һавад[а], асманда бер йақты өлкән йолдуз пә[й]да булды[15], көндин-көн йақтулуғы артды. Тәмам қырық көнгәчә торды. Көн инеше тарафындин туғуб, көн чығушы тарафыға китәр[16] ирде. Төрлүк төслү йолдуз ирде: күкле-йәшелле, қызыллы ирде, күргән адәмләр таң-ғәҗәйебкә қалыб, «бу нә төрлүк нишандур?» тиб, йығлашур ирделәр. Барча җиһан[17] халқы: олу-кече, кяфер, мөэмин бу йолдузны әшкярә күрделәр, пичин йылы ирде.

Андин соң кяфер урыс мөлкендә төрлү фетнәләр вә мөтәхәлиф ғауғалар пәйда[18] була башлады. Йәғни, кяфер урус тәмам бикләре бер-бере

[12] Һиҗри 928 ел милади буенча 1522 елга туры килә. Ләкин кулъязмадагы бу дата дөрес түгел. Башка текстларда ул 957 (1550) ел диелгән.
[13] Һиҗри 1057 ел милади 1647 елга туры килә. Башка кулъязмаларда бу дата 1050 (1640) ел дип теркәлгән.
[14] Кулъязмада «иркә (иргә) чирүе» дип ялгыш язылган.
[15] Кулъязмада «булур» дип ялгыш язылган.
[16] Кулъязмада «кинәр» дип хаталы язылган.
[17] Кулъязмада «чиһан» дип хаталы язылган.
[18] Кулъязмада «бәйда» дип хаталы язылган.

берлә киңәш итеб, қаравуллар[19] қуйуб, үзенең қул астындағы мөселманларға чуқындурмақ нийәтен қыйлдылар, күб мөселманларны динендән әвереб, мөртәд қыйлды. Олуғ[20] фетнә башлады, күб йирләрдә оруш-суқушлар һәм *// (1015б кәгазь)* булды. Ахыр, Сөбханәһә вә Тәғалә үзенең рәхмәте берлә ул йаман киңәш қылған кяферләрне үзләрен һәлак қылды, үз араларында фетнә салыб, кяфер урус бере-бересен Мәскәү шәһәрендә қырдылар, мөтәхәлиф булдылар. Ул йаман киңәшне [қылган] Фидыр атлы хан ирде, Хақ Тәғалә йәш вақытында һәлак қылды.

Андин соң тарих мең дә туқсан бердә ирде, кяфер урысның тәхетендә ике хан ханлықға ултурды, ағалы-энеле ирде, икесе бер дәвердә, бер заманда тәхет биләб ултурдылар, эт йылы ирде. Берсенең аты – Иван, икенчесенең аты – Питыр[21] ирде, икүсе дә Аләкчәй ханның уғланлары ирделәр.

Андин соң йәнә тарих мең дә туқсан бердә, шул ике хан ултурған эт йылында ирде, башқорт халқының арасында бер мөселман пәйда[22] булды, халықны дингә өндәр ирде. Әүлийалар кәрамәте һәм үзүндә бар ирде. Аты ул ханның Сәйед Җәғфәр хан[23] тиб әйтүр ирделәр. Ахыр бар[24], халық уғылы, *// (1015а кәгазь)* башқорт халқы ул ханны ханға санамадылар, аның бойу[ры]ғынча йөрмәделәр, кяфер урысқа қайтыб килделәр. Ахыр, Хақ Сөбханәһә вә Тәғаләнең ғазаб тәқдире берлә кяфер урысның қулунда бағланыб, ғаҗиз булуб қырылдылар, урусқа йәсир булдылар, дин-имандин һәм мәхрүм булдылар. Ғаммазларның эше һәмишә ошбундақдур.

---

[19] Кулъязмада «қуллар» дип ялгыш язылган.
[20] Кулъязмада «Ул» дип ялгыш язылган.
[21] Кулъязмада: Битыр.
[22] Кулъязмада «бәйда» дип хаталы язылган.
[23] Сәед Җәгъфәр житәкчелегендәге халык күтәрелеше 1681–1683 елларда булган.
[24] Кулъязмада «йар» дип ялгыш язылган.

УНЫНЧЫ ТЕКСТ[1]

// (4б кәгазь) **Дастанел-мәкян**

Имди, беләсезләр кем, йортларда Бохар[а] – Болғар ханның йортыдур.

[Тора] – Орыс ханының йортыдур.

Чирмешән – Өмәрхуҗыл ханның йортыдур.

Үзән – Туқтамыш ханның йортыдур.

Җим[2]-Җайық арасы – Җанибәк ханның йортыдур.

Ақ Идел тамағы – Қара хан йортыдур.

Чаған тамағы – анығ кече энесе Йүчи ханның йортыдур.

Уфа тамағы – Тирә ханның йортыдур. Тир[ә] ханның әүвәлге йорты Саратауның өстүндә Олуғ Бабадур. Тирә ханның сарай[ы]ның уруны ушалдур.

// (5а кәгазь) Сарайчық – Чалбақ ханның йортыдур.

Инчыр – Хәлим ханның йортыдур.

Ақтүбә – Пачман ханның йортыдур.

Әчтерхан – Тимер Қотлы ханның йортыдур[3].

Қазан – Шығали ханның йортыдур.

Зәй тамағы – Бүләр ханның йортыдур.

Минзәлә – Бирдебәк хан йортыдур[4].

Ық[5] – Кичә ханның йортыдур.

Сөн – Тупчақ ханның йортыдур.

Чирмәсән-Қармасан – Нүкәй ханның йортыдур.

Әй – Қошытаймас ханның йортыдур.

Миаҗ – Қуҗақ ханның йортыдур.

Уй – Илчеғол ханның йортыдур.

Тубыл – Теләүле ханның йортыдур.

---

[1] Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1230т» шифры белән саклана торган кульязмадан алынды.

[2] Кульязмада «Җелем» дип ялгыш язылган.

[3] Кульязманы күчерүче бу урында «Ақтүбә – Пачман ха» дип, икенче мәртәбә яза башлап туктаган.

[4] Текстның «Минзәлә» дип башланган урыныннан алып, «Иртеш»...» дигән юлына кадәрге өлеше, гәрчә төп чыганагы рәвешендә «Чыңызнамә» әсәре күрсәтелгән булса да, нигездә, Таҗетдин Ялчыголның «Тарихнамәи Болгар» әсәреннән алынган.

[5] Кульязмада маддәле әлиф белән «Ақ» дип язылган.

Унынчы текст кулъязмасы

Иртеш – Байық ханның йортыдур.

(«Чыңызнамә» мин ғәйниһи).

Дастане тарих

// (5б кәгазь) Тарихның йите йөз йылында ирде, Ақсақ Тимер Болғар шәһәрене алды Ғабдулла хандан. Ғабдулла ханның ике уғылы бар ирде: бере – Алтунбик, бере – Ғалимбик ирде.

Ул бөлүклекдин[6] соң килеб, Қазан дәрйасы өстендә қәлғә йасадылар, шәһәр итделәр. Ул халық йөз дә түрт йыл анда тордылар. Ахры, урыныны йаратмайун, андин күчтеләр. Қазан суының тамағында шәһәр төзеделәр. Йөз дә илле сикез йыл анда булдылар. Мөселман ханының нәселе анда киселде. Қазан шәһәрендә хан йуқ булды ирсә, ул заманда кяфер урус қулында Шығали хан тотқун ирде, мөселманлар барыб аны килтүрделәр. Қазан шәһәрендә ханлықға күтәрделәр. Ул Қазанда утуз өч йыл ханлық қыйлды.

Андин кяфер урус көчәйүб, ләшкәр берлә Қазан шәһәрене алғалый килде. Қалталы Ибан[7] ирде, йите йылғача оруш-суқуш [қылды], мөселманларны ала алмады.

Қалталы Ибан Қазан шәһәрене алмасдан борун, Зөйә суының тамағында кяфер урус қала сукты. Тубын, қоралун[8], азығун анда қуйды.

Андин соң, ахры бар, Шығали хан урусқа ғаммазлық қыйлыб, урыс хан[ы] берлә берегүб, мөселманларның дарыларына су қойдурды, шәһри Қазанны кяфергә бирде. Мөселманлар бу эшдән хәбәрләре йуқ ирде. Күб адәмиләр һәлак булдылар.

Андин соң урус ханы Қазанны биләде – ул вақытда тарих туқуз йөз алтмыш бердә ирде, кяфер урус алды йәкшәнбә көнне, ғәқрәб йолдызының икенче көне ирде, сычқан йылында ирде.

Қазан шәһәрендә йорт биләгән ханларның атлары болардур: *// (6а кәгазь)* әүвәл – Ғабдулла ханның уғылы Алтунбик, Ғалимбик; андин соң Мәхмүд хан; андин соң Мәмтәк хан; андин соң Хәлил хан; андин соң Ибраһим хан; андин соң Илһам хан; андин соң Мөхәммәдәмин хан; андин соң Мамуқ хан; андин соң Ғәбделләтыйф хан; андин соң Сахибгәрәй хан; андин соң Сафагәрәй хан; андин соң Ғәли хан; андин соң Үтәш хан; андин соң Йәдегәр хан (әмма Йәдегәр хан заманында – тарих туқуз [йөз] илле йитедә көн тотулды); андин соң Шығали хан. Андин соң кяфер урус алды.

Андин соң тарих мең дә унда ирде, олуғ ачлық булды.

Андин соң тарих мең дә унйитедә ирде, кенәз Митри йавы булды, тавық йылы ирде.

Андин соң тарих мең дә йегерме түртдә ирде, Җанали явы булды, тавышқан йылы[9] ирде.

Андин [соң тарих] мең дә илле өчдә[10] ирде, кенәз Михәла хан булды, қуй йылы ирде.

---

[6] Кулъязмада «бөллүклекдин» дип хаталы язылган.
[7] Кулъязмада: Ипан.
[8] Кулъязмада «қоралуан» дип хаталы язылган.
[9] Кулъязмада «Азауға чирү барды, йылан йылы» дип ялгыш язылган.
[10] Кулъязмада «өчүдә» дип хаталы язылган.

[Андин] соң тарих мең дә йитмеш бердә ирде, башқорт урус берлә йау булды, барыс йылы ирде.

Андин соң тарих мең дә йитмеш туқузда ирде, бәлид қазак[11] берлә урус йау булды, эт[12] йылы ирде.

Андин соң тарих мең дә сиксәндә[13] ирде, Ракҗин йавы булды.

Тарих мең дә сиксән туқызда ирде, асманда бер йақты йолдуз пәйда[14] булды, көн йақтылуғы кеби қырық көнгәчә торды. Көн инеше[15] тарафдин туғуб, көн чығушы тарафына[16] китәрләр ирде. Төрлүк *// (6б кәгазь)* төслү йолдуз ирде: күкле-йәшелле, қызыллы ирде, күргән адәмиләр таң-ғәҗәб қалды, «бу ни төрлүк нишандур?» диб йығлашур ирделәр. Барча олуғ-кечесе, кяфере вә мөэмине бу йолдузы әшкярә күрделәр, бичин йылы ирде.

Андин соң урус мөлкендә[17] төрлүк-төрлүк фетнәләр вә мөхтәлиф ғауғалар пәйда була башлады. Йәғни, кяфер урус тәмам бикләре [берлә] киңәш[18] итеб, қаравуллар[19] қуйуб, қу[л] астындағы мөселманларны чуқындурмақ нийәтен қыйла башлады[20], күб мөселманларны динендән айыруб, мөртәд қыйлды. [Олуғ фетнәләр башлады, күб йирләрдә оруш-суғушлар һәм булды][21]. Ахры, Хак Сөбханәһә вә Тәғалә[22] үзенең рәхмәте берлән ул йаман киңәш қыйлған[23] кяферләрне үзләрен һәлак қыйлды, үз араларында фетнә салыб, кяфер урус [бер]е-берсен Мәскәү шәһәрендә қырдылар, мөхтәлиф булдылар. Ул йаман киңәшне қыйлган Фидур[24] атлы хан ирде, Хак Тәғалә йәш вақытында һәлак қыйлды[25].

[11] Кулъязмада «қырғыз» дип ялгыш язылган.
[12] Кулъязмада «айыт» дип хаталы язылган.
[13] Һиҗри 1080 ел милади 1669-1670 елларга туры килә.
[14] Кулъязмада «бәйда» дип хаталы язылган.
[15] Кулъязмада «ишене» дип ялгыш язылган.
[16] Кулъязмада «тарафдин» дип ялгыш язылган.
[17] Кулъязмада «меңдә» дип ялгыш язылган.
[18] Кулъязмада «киткәш» дип хаталы язылган.
[19] Кулъязмада «қуллар» дип ялгыш язылган.
[20] Кулъязмада «баслады» дип хаталы язылган.
[21] Квадрат җәяләр эчендәге текст өлеше кулъязмада төшеп калган. Монда «Икенче текст»тан алынды.
[22] Кулъязмада бу урында һәм моннан соңгы җөмләдә: Тәғәһә.
[23] Кулъязмада «қыйлғыл» дип ялгыш язылган.
[24] Кулъязмада «Фиди» дип хаталы язылган.
[25] Кулъязманың бу урынында «Чыңгызнамә» китабыныкы булмаган түбәндәгечә текст өзеге дәвам иткән: «Атамыз Адәм ғәләйһиссәлам халиқ улындуғы бәғдендә күкдә заһир улған ғәләмәтләрнең әүвәле қойруқлы йолдуз пәйда (кулъязмада: «*йолдур бәйда»*) улмақдур. Чөнки ул йолдуз Қабил Һабиле үлдүрдүге вақытында заһир улды. Андин соң туфан вақытында заһир улды. Андин соң ғад қәүм, вә сәмүд қәүм, вә Салих ғәләйһиссәлам қәүм һәлак улдуқы вақытларда заһир улды. Муса ғәләйһиссәлам заһир улдуқы вакыт заһир улды вә фирғәвен нәйлә ғөррәт улдуқы

Андин соң тарих [м]ең дә туксан бердә ирде, кяфер уруснын тәхетендә ике хан ханлыкъга ултурды, [ағалы-энеле ирде. Икесе бер дәвердә, бер заманда тәхет биләб ултурдылар, эт йылы ирде. Берсенең аты – Иван, икенчесенең аты – Питыр ирде, ике]се[26]дә Аләксәй ханның уғланлары ирде. Шул ике хан ултурған эт[27] [йылын]да ирде. Вә һәм шул тарихда кяфер-урус мәсҗидләре хәраб әйләде, эт йылы ирде.

Вә шул тарихда башқорт халқының арасында бер мөселман хан пәйда[28] булды, халықны дине ислам[ға] өндәр ирде, әүлийалар кәрамәте һәм үзендә бар ирде. Ул ханны[29]Сәйед Җәғфәр хан тиб әйтүр ирделәр. Ахры бар, башқорт халқы ул ханны ханға санамадылар, аның бойруғунча йөрмәделәр, кяфер урусқа ғаммазлык қыйлдылар. Кяферне сәвеб, аның берлә мәшвәрәт итеб[30] һәлак қыйлдылар. Ахры, ул башқорт халқыны Хақ Тәғалә[31] ғазабы берлә кяфер урус қулында ғаҗиз булуб қырылдылар, урусқа йәсир булдылар. Дин-имандин һәм мәхрүм булдылар. Қийамәт диген мөбтәля булдылар. Сәйед Җәғфәр хан доғасындин ғаммазлар эше һәмишә ошбудур.

(«Чыңгызнамә»[32]).

Тарихның мең дә йите йөздә утуз алтынчы йылда (1736) – Ақай йавы чықғандур, ғәфләт улынмайа.

вақыт заһир улды. Бәдер (кулъязмада: «*Бур»*) ғазасында вә Ғосман вә Ғәли ғәнһүма үлдүрүлдүге вақытларда заһир улды. Хөләфаи ғаббасийәдән бәғзе кемсәләр үлдүрелдеге вақытларда заһир // *(7а кәгазь; кәгазьнең чите ертылган булуы сәбәпле, бөтен сүзләрен дә уку мөмкин түгел)* [...] брансус безнең урус бадишаһысы илән орыш қыйлған [...] әр-разый билләһи вәл-мәһди билләһи вәл-мөқтәда билләһи вәл-мөғтәзз билләһи кеби хасил [...] ...ық итделәр. Бу қойруқлы йолдузның туғмақы хәүф-хәтәрләр вә зилзилә [...] ғәламәтедүр. («Мөхазәрәтел-әваил», нәқәлә минәш-шәҗәрәти).

26 Квадрат җәяләр эчендәге текст өлеше кулъязмада төшеп калган. Монда «Тугызынчы текст»тан алынды.

27 Кулъязманың бу урынында һәм моннан соңгы җөмләдә «эт» сүзе «айт» дип хаталы язылган.

28 Кулъязмада «бәйда» дип хаталы язылган.

29 Кулъязмада «хатунны» дип ялгыш язылган.

30 Кулъязмада «айтеб» дип хаталы язылган.

31 Кулъязмада: Тәғәһә.

32 Кулъязмада «Чыңғызлама» дип хаталы язылган.

УНБЕРЕНЧЕ ТЕКСТ[1]

[Дастане мәкян]

// (35а кәгазь) Бәғдә мәғлүм ула, беләсез кем, йортларда ничә хан булған, қайсы урун қайу хан йортыдур:

Чирмешән – Өмәрхуҗаның йортыдур[2].

Өййе Озун – *// (35б кәгазь)* Туқтамыш ханның йортыдур.

Җайық арасы – Чыңыз хан йортыдур.

Ақ Идүл тамақы – Боғра ханның йортыдур.

Ақ Идүл төбә – Пачман ханның йортыдур.

Чаған ханның йорты Тутый тамағында Алма Ата вә йәнә тигрү ирде.

Ошбу Уфа Идүленең тамақы – Тир[ә] ханның йортыдур. Андин соң йәнә Саратау өстүндә бер олуғ уба[3] вардур, Тирә ханның сарай урыны ушалдур.

Сарайчық – Чалбақ ханның йорты.

Уфа – Хәким ханның йортыдур. Хәким ханны йир йотды, өч йылғача авазы килә йатды, андин соң килмәде.

Әчдәрхан – Тимер Қотлы хан уғылының йортыдыр.

Кәлә – Биргән ханның йортыдур.

Қазан – Шығали ханның йортыдур.

Зәй тамақы – Бүләр ханның йортыдур.

Валлаһу әғләмү бис-саваби.

Фасыл фи бәйанит-тарих

Тарих йите йөз йылда ирде, Ақсақ Тимер шәһри Болғарны алды, Ғабдулла ханны[4] үлтүрде. Ғабдулла ханның ике уғылы бар ирде: берсе – Алтунбик, берсе – Ғалимбик.

Ул Бүлге[5] суындан килеб, Қазан дәрйасы өстүндә қала йасадылар,

---

[1] Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «981т» шифры белән саклана торган кульязмадан алынды.

[2] Кульязмада бу урында «йорт» сүзе ялгыш кабатлап язылган.

[3] Кульязмада: упа.

[4] Кульязманың бу урынында һәм моннан соңгы җөмләдә «Ғабдуллаҗанны» дип ялгыш язылган.

[5] «Бүлге» – Волга атамасыннан үзгәргән Идел исемен белдерә һәм ул кульязмага Мөслиминең «Тәварихы Болгарийә» китабы тәэсирендә шул рәвештә теркәлгән.

Унберенче текст кульъязмасы

шәһәр итделәр. Ул халық йөз дә түрт йыл анда тордылар. Ахыр, ул урынны йаратмайын, андин күчеб, Қазан суының тамақында шәһәр төзеделәр. Йөз дә илле сикез йыл анда булдылар. Мөселман халқы ханының нәселе

анда киселде[6]. *// (36а кәгазь)* Қазан шәһәрендә хан йуқ булды. Ул заманда кяфер урыс қулында Шығали хан тотқун иде, мөселманлар аны барыб килтүрделәр, Қазан шәһәрендә ханлыққа күтәрделәр. Ул Қазанда утуз өч йыл ханлық сөрде.

Андин кяфер урыс көчәйеб, ләшкәр берлә Қазан шәһәрене [алғалый] килде. Қалталы Жәван хан ирде, йите йылғача оруш қылдылар.

Мөселман шәһәрен[7] алмасдан борун, Зөйә суының тамақында кяфер урыс қала суқды. Тубын, малын, қор[а]лын анда қуйды.

Ахры бары, Шығали хан урысқа ғаммазлық қыйлыб, урыс ханы берлә берегүб, мөселманлардан өрентүн-белдермәй, дарыға су қойды, шәһри Қазанны урыс кяфергә бирде. Мөселманлар бу эшдин хәбәрләре йуқ ирде. Күб адәмиләр һәлак булдылар, кяферләр бик қырдылар. Мөселманларны һәлак итеб қырғандин соң урыс ханы Қазанны биләде – [ул] вақытда тарих туқыз йөз алтмыш бердә ирде. Қазан вилайәтен кяфер урыс [алды] ғәқрәб йолдызы, якшәнбә көн ирде, сычқан йылында ирде.

Қазан шәһәрендә йорт биләгән ханларның атлары болардур:

Әүвәл – Ғабдулла хан; андин соң уғылы Алтунбик, йәнә Ғалимбик; андин соң Мәхмүд хан; андин соң Мәмтәк хан; андин соң Хәлил хан; андин соң Ибраһим хан; *// (36б кәгазь)* андин соң [Илһам хан]; андин соң Мөхәммәдәмин хан; андин соң Мамық хан; андин соң [Ғәбделләтыйф ха]н; андин соң Сахибгәрәй хан; [андин соң Сафагәрәй хан; анд]ин соң Ғәли хан; андин соң Үтәш [хан; андин соң Йәдегә]р хан (әмма Йәдегәр хан заманында – тарих туқыз йөз [йегерме си]кездә көн тотулды). Андин соң Шығали хан. Андин соң [кяфер урыс] алды.

Андин соң тарих мең дә унда ирде, олуғ ачлық булды.

Андин соң тарих мең дә унйитедә ирде, кенәз Митри [йағы] булды, тавық йыл[ы] ирде.

Андин тарих мең дә йегерме [түртдә] ирде, Жанали йағы булды, тавышқан йылы ирде.

Андин тарих мең дә [илледә] ирде, иргә чирү[8] булды, йылан йылы ирде.

Андин соң тарих мең дә [илле өчдә] кенәз Михайла [хан] булды, қуй йылы ирде.

Андин соң тарих [мең дә] йитмеш [бердә] ирде, башқорт урыс берлә йағы булды, барыс йылы ирде.

---

[6] Бу сүз кустодта язылган.
[7] Кулъязмада «шәһәрендә» дип ялгыш язылган.
[8] Кулъязмада «иртә чирүе» дип ялгыш язылган.

Андан соң тарих мең дә йитмеш туқызда ирде, қазақ урыс берлә йағы булды, эт йылы ирде.

Андин тарих мең дә сиксән туқызда ирде, һавадин-[ә]смандин бер йақты йолдыз пәйда булды, көндин-көн йақтылуқы артды. Тәмам қырық көнгәчә торды. Көн инеше тарафындан туғыб, көн чығушы тарафындин китәр ирде. «Бу бер төрлүк нишандур» диб, халық йығлашур ирделәр. Барча җиһан халқы: олуғ-кече, кяфер, мөэмин бу йолдузны әшкярә[9] [...]

[9] Бу сүз кустодта язылган. Аннан соң кулъязманың бите төшкәнлектән, текст өзелә.

УНИКЕНЧЕ ТЕКСТ[1]

[Дастане тарих]

// (1а кәгазь) [...] кяфер бер-берсен Мәскәү шәһәрендә қырдылар, мөхтәлиф булдылар. Ул йаман киңәшне қыйлган Фидур атлы[2] хан ирде, Хақ Тәға[лә] йәш вақытында һәлак қылды.

Кяфер урысның тәхетендә ике [хан] ханлықға ултурды[3], ағалы-энелү ирде. Икесе бер дә[вердә], эт йылы ирде. Берсенең аты Иван, икенчесенең аты Питыр ирде, икесе дә Аләкчәй[4] хан уғланла[ры] ирде.

Андин соң *// (1б кәгазь)* йәнә тарих мең дә туқсан бердә шул ике[5] хан утурған эт йылында ирде, башқорт халқының арасында[6] бер мөселман хан пәйда[7] булды, халык[н]ы дингә өндәр ирде. Әүлийалар кәрамәт[е] һәм үзендә бар ирде. Ханны Сәйед Җәғфәр хан тиб әйтүр ирделәр. Ахры бар, халық уғылы[8], башқорт халқы ул ханны ханға санамадылар[9], аның *// (2а кәгазь)* бойыруғынча йөрмәделәр, кя[фер у]русқа ғаммазлық қыйлдылар. Аны ташлаб, кяфер сәвеб, кя[фер у]руска қа[й]тыб килделәр. Ахыр, Хақ Сөбханәһә вә Тәғаләнең ғазаб тәкдире берлә кяфер уруснын қулында бағланыб, ғаҗиз булуб, қырылдылар вә [уру]сқа йәсир булдылар, дин-имандин һәм мәхрүм булдылар. Ғаммазларның эше һәмишә ошбундақдур.

---

[1] Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1360т» шифры белән саклана торган кулъязмадан алынды.
[2] Кулъязмада «Фәлдә ил» дип хаталы язылган.
[3] Кулъязмада «ултуды» дип хаталы язылган.
[4] Кулъязмада «Лчәй» дип хаталы язылган.
[5] Кулъязмада «шуар ик» дип хаталы язылган.
[6] Кулъязмада «халқы йәнә адашынла» дип хаталы язылган.
[7] Кулъязмада «бәйда» дип хаталы язылган.
[8] Кулъязмада «хыйлқы уғыл» дип хаталы язылган.
[9] Кулъязмада «санадылар» дип ялгыш язылган.

УНӨЧЕНЧЕ ТЕКСТ[1]

// (26а кәгазь) **Қыйсме хамис фи бәйани мәсакин вә мәкян**

Имди мәғлүм улсун ки, йортларда Бохара – Болғар ханының йортыдыр.

Тора – Орыс ханның[2] йортыдыр.

Чирмешән – Ғөмәр ханның йортыдыр.

Өй-Үзән (йәғни, Қырым) – Туқтамыш ханның йортыдыр.

Җайық – Җанибик ханның йортыдыр.

Ақ Идел тамағы – Қарай хан вә Боғра ханның йортыдыр.

Ақтүбә – Бачман ханның йортыдыр. Тутый тамағындан түбән Алмалығача ирде.

Вә Уфа тамағы – Тирә ханның йортыдыр. Әмма Тора тавының өстендәге Уба – Тир[ә] хан сарайының урыныдур.

[Сарайчық – Чалпақ ханның йортыдур.

Инҗер – Хәким ханның йортыдур][3]. Әмма Хәким ханны йир йотуб, өч йылғача авазы *// (26б кәгазь)* килә йатды.

Ачтырхан – Тимер Қотлу хан йортыдыр.

Кәлибөдур (Кәлибули) – Бәркә ханның йортыдыр.

Қазан – Шығали ханның йортыдыр.

Зәй тамағы – Бүләр ханның йортыдыр.

Қыйсме садис ки Мир Тимер хәзрәтләре шәһри Болғарны алдуғы бәйанында[4]

Тарих йите йөздә (мөхәққақ қәүл илән сикез йөздә)[5] ирде, Мир Тимер хәзрәте Ғабдулла хандин Болғар шәһәрене алды ирсә, ушал Ғабдулла ханның ике уғылы вар иде, берсе Ғалимбик вә берсе Алтунбик иде.

---

[1] Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1321т» шифры белән саклана торган кульъязмадан алынды.

[2] Кульъязмада «ханының» дип ялгыш язылган.

[3] Кульъязмада бу урында текстка өзеклек кергән. Квадрат җәяләр эчендәге ике җөмлә Хәлфин басмасыннан (1822 ел) алынды *(Әхвале Чыңыз хан вә Аксак Тимер... – Б. 86).*

[4] 1822 елгы басмада бу бүлек «Қисме садис фи бәйани тарих» дип исемләнгән *(Әхвале Чыңыз хан вә Аксак Тимер... – Б. 87).*

[5] Һиҗри 700 ел милади 1300-1301 елларга, ә 800 нче ел – 1397-1398 елларга туры килә.



Унөченче текст кульязмасы

Ул бөлүкдин килүб Қазан (бәғзе нөсхәләрдә Қашан йазылмышдур) дәрйасы өстендә қәлғә йасайу, шәһәр итделәр. Хәлайық йөз дә дүрт йыл анда дормақлә, ахрел-әмер, урынуны йаратмайуб, күчүб, Қазан суы тамағында шәһәр төзәйү, илле сикез йыл анда булдылар. Мин бәғдә мөселман ханларының нәселе киселүб, Қазан шәһәрендә хан қалмады ирсә, ул заманда урыс қулында Шығали хан тотқун ирде – мөселманлар аны варыб

килтүрделәр. Қазан шәһәрендә ханлықға күтәреб, Шығали хан Қазанда утыз өч йыл ханлық сөрде.

Андин соң урыс көчләнеб, Қалталы Жыван ирде, ләшкәре берлән Қазан шәһәрен алурға килде. Йите йылғача орыш-суқыш қыйлуб, мөселманларны ала алмады.

Әмма урыс Қазан шәһәрен алмасдан борун, Зөйә суының тамағында қәлғә дөзәйүб, тубларын, малын, вә қорал, вә азықларын анда қуйды.

Ахрел-әмер, Шығали хан мөселманлардин йәшерен ғаммазлық қыйлуб, нифақлық сәбәбле урыс ханы илә берекде. Дарыларыға су қойуб, Қазан шәһәрене урысқа бирде. Әмма мөселманлар бу эшдин бихәбәр улмақ илә күб адәмләр һәлак улуб қырылдылар қырылдылар.

Урыс Қазан шәһәрене 52-нчедә алуб, Қазан вилайәтен биләде[6].

Бәс ул қырылғандин соң урыс ханы туқыз йөз алтмыш бердә, сычқан йылыда, ғәқрәб бөрженең икенчесендә, йәкшәнбә көн *// (27а кәгазь)* вә милад илә мең дә биш йөз илле икедә алуб, Қазан вилайәтен биләде.

Имди Қазан шәһәрендә йорт биләгүче ханларның исемләре мәғлүмләнә: әүвәл – Ғабдулланың уғылы Алтунбик хан; Мәхмүд хан; Мәмәк хан; Хәлил хан; Ибраһим хан; Илһам хан; Мөхәммәдәмин хан; Мамық хан; Ғәбделләтыйф хан; Сахибгәрәй хан; Сафагәрәй хан; Ғәли хан; Үтәш хан; Йәдегәр хан заманы – туқыз [йөз] илле йитедә көн тотулды. Вә Шығали ханны мин бәғдә урыс алды.

Вә йәнә тарих бең дә унда олуғ ачлық булды.

Йәнә тарих бең дә унйитедә, тавық йылы ирде, кенәз Митри йағы булунды.

[Тарих бең йегерме түртдә, тавышқан йылы, Жанали йағы булды][7].

Йәнә тарих бең дә илледә, йылан йылы ирде, иргә чирү[8] булды.

Йәнә тарих бең дә илле өчүнчедә, қуй йылы ирде, кенәз Мих[әй]лә хан булды.

Йәнә тарих бең дә алтмыш беренче йылда үләт булды[9].

Йәнә тарих бең дә йитмеш беренчедә, барыс йылында ирде, урыс берлә башқорт йағы улды.

---

[6] Хәлфин басмасында (1822 ел) бу рәвешле аерым җөмлә юк, ә моннан соңгы җөмлә ахырындагыча бирелгән. «52 нчедә» дигәндә милади 1552 ел күздә тотылган.

[7] Кулъязмада бу урында текстка өзеклек кергән. Квадрат җәяләр эчендәге җөмлә Хәлфин басмасыннан (1822 ел) алынды *(Әхвале Чыңыз хан вә Аксак Тимер... – Б. 89).*

[8] Кулъязмада «иркә (иргә) чирүе» дип ялгыш язылган.

[9] Һиҗри 1061 ел милади буенча 1651 елга туры килә. Бу җөмлә Хәлфин басмасында (1822 ел): «Тарих бең алтмыш бишенче, йылқы йылы, үләт булды» рәвешендә бирелгән *(Әхвале Чыңыз хан вә Аксак Тимер... – Б. 89).*

Йәнә тарих бең дә йитмеш туқызда ирде, қазақ урыс берлә йағ булды[10].

Йәнә тарих бең дә сиксән туқызда, пичин йылы ирде, асманда йақтылу йолдуз пәйда улуб, көндин-көн йақтылуғы артмақлә, тәмам қырық көнгәчә[1111] торды. Вә йәнә көн инеш тарафындан туғмақлә, көн чықыш тарафына кидеб, төрлүк төсле, йәғни: күкле-йәшелле, қызыллу йолдыз ирде, барча хәлайық – җиһанда улғучы мөэмин вә кяферләр бу йолдызы әшкярә күрүб, таң-гәҗайебә қалмақ илә «бу нә төрлек нишанәдер?» дәйү, йығлашурлар иделәр.

Йәнә тарих бең дә туқсан бердә, эт йылы ирде, урысның тәхетендә ике хан булды, берсе – Иван вә берсе Питыр адлу, ханлықға ултуруб, ағалы вә энеле – икесе бер дәвердә вә бер заманда тәхетә ултурдылар. Бонлар икесе дә Аләкси ханның уғылларыдур.

Йәнә шул тарихда, туқсан беренчедә, эт йылында, шул ике хан ултурған заман иде, башқорт халқы арасындан бер мөселман әһле кәрамәт улуб, пәйда булынуб, *// (27б кәгазь)* хәлайықны дине ислама өндәйүрде, исеме Сәйед Җәғфәр иде. Ахрел-әмер, башқорт халықлары аны ханға ғаммазлық қыйлуб, бойурғанча йөрмәйүб, урысқа қайту килделәр. Ахрел-әмер, бәғзесе қырылуб, вә бәғзесе мөртәд, вә бәғзесе әсир улдылар[12].

Вә йәнә тарих бең дә йөз дә алтынчыда ирде, урыс Азауны алуб иде. Йәнә унсигез йылдан соң қайта мөселманлар алдылар[13].

Вә йәнә тарих бең дә йөз дә унтуқызда[14] иде, башқорт йағы булуб, Ысидур Аристыф дигән баш улуб йөрде. Ахрел-әмер, башқортлар Қазан халкы арасына килүб, халықны үзләренә бағындырдылар вә күб илләрен вә манастырларын йандурмақ илә вә хатун-қызларны әсир вә кәнизәк идеб, Қазан халқы башқорт илә бостылар. Қазанда чирү чықыб, мөселманларға Ишбулат дигән мулланы баш итделәр вә урыс ғәскәренә Раман Иваныч

---

[10] Бу җөмлә Хәлфин басмасында (1822 ел): «Вә тарих бең йитмеш туқызынчы, эт йылында, пәлид қазақ урус берлә йағ улды» рәвешендә бирелгән *(Әхвале Чыңыз хан вә Аксак Тимер... – Б. 89).*

[11] Кулъязмада бу сүз алдында ялгыш «көн» дип язылган.

[12] Бу абзац Хәлфин басмасында (1822 ел) түбәндәге рәвештә: «Андин шул тарихда, бең туқсан беренчедә, эт йылында, шул ике хан ултурған заманы ирде, башқорт ханы арасында бер мөселман, әүлийалар кәрамәте үзүндә күрүлмәклә, пәйда улынуб, хәлайықы ислам динегә өндәйүрде вә исеме Сәйед Җәғфәрдүр. Ахры бар, хәлайық вә башқорт халықлары аны ханға санамайын, ташлайуб, бойруғынча йөрмәделәр, вә ғаммазилық илә урусы сәвеб вә урусқа қайту килделәр. Ахырларында, бәғзесе қырылуб, вә бәғзесе әсир вә бәғзесе мөртәд улдылар» *(Әхвале Чыңыз хан вә Аксак Тимер... – Б. 90).*

[13] Һиҗри 1106 ел милади 1694-1695 елларга туры килә. Бу вакыйга, чынлыкта, 1696 елда булган һәм 15 ел узгач – 1711 елда кире кайтарылган.

[14] Һиҗри 1119 ел милади 1707-1708 елларга туры килә.

Лимкә дигәнне баш итделәр. Әмма урыс чирүе Нуғай йулы Солтан Ғәли илендә торуб, башқортлар илән суғышдылар. Вә йәнә Йөри йулы Баландыш дигән илдә Мамanув дигән генерал торыб суғыш қыйлдылар. Қазан халқының уғыл-қызлары әксәре әсир улуб, күб мөселманлары әсир әйләделәр. Олуғ бөлекләр булыныб, ахры, Бархански дигән байар падишаһның хөкеме берлән килүб туқтатды[15].

Вә йәнә андин соң тарих бең дә йөздә утыз бишенчедә[16], қуйан йылы ирде, падишаһ Қызылбаш өлкәсенә барыб, өч қәлғәсен алдылар: әүвәл – Сулақны, йәнә Бакуны, вә Гилән-Зәминне алды.

(Әл-мәнқүл мин рисаләти Хәлфин Қазаный).

---

[15] Бу абзац Хәлфин басмасында (1822 ел) түбәндәге рәвештә: «Вә йәнә тарих бең дә йөз дә унтуқыз ирде, башқорт йағы булуб, Сидур Аристуф дигән урус башлайу баш улуб йөрде. Ахры бар, башқорт Қазан хәлайықы арасына килүб, халықны үзләренә бағундурдылар вә күб илләре, манастырларны йандурмақ илә күб рус вә маржа вә қызларыны йәсир қыйлуб, Қазан халқы башқорт берлә бостылар. Қазандан чирү чықыб, татарларға Ишпулат дигән мулланы баш итделәр вә урус чирүенә Раман Иваныч Лимкау дигәнне баш идүб, әмма урус чирүе Нуғай йулы Солтанғәли дигән илдә торуб, башқорт берлә қаршу суқышдылар. Вә йәнә Йөри йулы Баландыш дигән илдә Мамануф җәнәрал торуб суқыш қыйлды. Әмма Қазан халқы күб-күб уғылы-қызы йәсир улуб, вә татарлар дәхи шөйлә йәсир ителделәр. Олуғ бөлеклекләр улыныб, ахры бар, Хованский дигән байар падишаһның хөкеме берлә килүб туқтатды» *(Әхвале Чыңыз хан вә Аксак Тимер... – Б. 90–91). Мамaнув, Мамануф* – стольник Афанасий Дмитриевич Мамонов.

[16] Һиҗри 1135 ел милади 1722-1723 елларга туры килә.

УНДҮРТЕНЧЕ ТЕКСТ[1]

[Дастане тарих]

*// (1а кәгазь)*Қазан қаласы русларға бирелү …[2] Пуқраудa[3]. Қазанны суғышыб алучы Ибан Грузный, «сар Ибан» вә «Қалталы Ибан» диб әйтәләр иде. Йәғни, ул русның …[4] булған бик күб һәлакәт берлә тәмам. 7 җыл суғышыб алған, һаман да тиз генә алачақ түгел икән, Шоғали хан дигән залим қуштан мөселманлардан йәшереб дарыларға су сибтереб, тупларға қом тутырыб қуйған. Шул сәбәбле мөселманлар абтырағанлар. Хәтта Сөйембикә ханым сулама вә майлар, қайнар сулар сиптереб тырышқан. Ахрел-әмер, бик озаққа киткәч, чыдый алмағанлар. Мөселманлар, шулай да, бик җегетләрчә суғышыб бирелгәнләр.

Йәнә дә бер мең дә йитмешдә[5] башқортлар урыс берлә суғыш қылдылар, барыс җылы ирде.

Йәнә мең дә җитмеш бишдә[6] қазақ йағы булды.

Бер мең дә сиксән туқызда һавада бер олуғ йолдыз пәйда булыб, олуғ-кечек һәммәләре әшкярә күрде, күкле-йәшелле булыб торур ирде. Қырық көн қәдәр торды. Мондан соң рус арасында фетнәләр була башлады.

Йәнә мең дә туқсан бердә башқорт арасында бер мөселман пәйда

[1] Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «711т» шифры белән саклана торган кульязмадан алынды. Текстта 1798 елда Павел патшаның Казанга килүе турындагы хәбәр бүтән язмалар арасында ялгыш бутап теркәлгән. Ул мәгълүматны текстның ахырына күчердек.

[2] Тексттагы мәгълүматлар буталуы сәбәпле, бу урында ялгыш 1798 ел язылган иде.

[3] Православие динен тотучыларның Пукрау (Покров) бәйрәме искечә ел исәбе белән 1 нче (хәзергечә 14 нче) октябрьгә туры килә. Бу бәйрәм исеме мондагы текстка Мөслиминең «Тәварихы Болгарийә» исемле китабыннан кергән. Ул китапта «русиялеләрнең «Пукрау» Казан алынган өчен һәр елда, октябрь башында» билгеләнә торган шатлык-бәйрәм көннәре дигән мәгълүмат бар.

[4] Кульязмада бу урындагы «монында ору(?)» рәвешендә язылган ике сүз аңлашылмый.

[5] Һиҗри 1070 ел милади 1659-1660 елларга туры килә.

[6] Һиҗри 1075 ел милади 1664-1665 елларга туры килә.

булыб, кә-әннә сахибе кәрамәт ул ир әүлийадан булыб, кәрамәт ийәсе иде. Җәғфәр хан диб әйтер иделәр.

Бер мең бер йөз илле икедә (1152-дә)[7] башқорт русқа бәйғәт бирделәр.

1156-да[8] һавада бер қойрықлы олуғ йолдыз пәйда булыб, қойрығы қойаш байыш тарафында булыб, төн бераз узғач байыр иде.

1798 нче җылда, ул вакытта рус падишаһы Павыл Питруич дигән рус булған. Падишаһ үзе 24 нче майда Қазанға килгән ике уғылы берлән, шунда Қазан[н]ың төрле кешеләренә алтын сағәтләр һәдийә қылған[9].

---

[7] Һижри 1152 ел милади 1739 елга туры килә.

[8] Һижри 1156 ел милади 1743 елга туры килә.

[9] *Қазанға килгән ике уғылы берлән* – рус императоры Павел I бу язмада күрсәтелгән вакытта уллары Александр һәм Константин белән Казанга килеп, бер атна торып киткән.

КУЛЪЯЗМАЛАРНЫҢ ТАСВИРЛАМАСЫ

I ВАРИАНТ

Беренче вариант текстының кулъязмасы Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсендәге сирәк һәм кулъязма китаплар бүлегендә «40т» шифры белән саклана. Кадыйргали бәкнең мәшһүр «Җамигыт-тәварих» әсәре һәм «Дәфтәри Чыңгызнамә» текстлары теркәлгән әлеге кулъязма истәлек аеруча әһәмиятле булганлыктан, галимнәр аңа зур игътибар биргән. Ул Г.Рәхим, А.Фәтхи, М.Госманов тарафыннан тәфсилле тасвирланган[1]. Шунлыктан, монда аерым тасвирлау ихтыяҗы юк. «Чыңгызнамә»нең бу тексты тулы килеш матбугатта беренче мәртәбә басыла, аерым өзекләре И.Мөстәкыймов мәкаләсендә (2009) чыкты.

Үзебездән өстәп шуны гына искәртәбез, Г.Рәхимнең рус телендәге мәкалђсендә «Җамигыт-тәварих» текстының ахыргы язылган бите һәм кулъязма җыентыкның иң соңгы битенең факсимиле күчермәләре бирелгән.

Бу кулъязма турында басылган мәкаләләргә һәм мәгълүматларга кереш мәкаләбездә күзәтү ясалды.

II ВАРИАНТ ТЕКСТЛАРЫ

«Беренче текст» кулъязмасы Мәскәү шәһәрендәге Россия дәүләт борынгы актлар архивында саклана (248 фонд, 17 нче тасвир, 1164 саклану берәмлеге, 773об.–773«в»об. кәгазьләр). Татар-башкорт каршылык хәрәкәте җитәкчеләреннән Солтанморат Көчек улының Казакъ ханы Әбелхәергә 1727 елда язган күләмле хатына «Чыңгызнамә»нең керешендәге шәҗәрә өлешен теркәгән. Мәгълүмат тулылыгы өчен әлеге хатны да монда ахырынача күчерү кирәкле дип табылды.

Хат тексты озынча кәгазьгә кара төстәге кара белән, ярымнәсех төрендә эре итеп язылган. Саклanышы яхшы.

Текст (773об. кәгазьдә) «Баб. Вә биһи нәстәгин. Бисмилләһир-Рахмәнир-Рахим» сүзләре белән башланган һәм шунда ук «Дәфтәри Чыңызнамә. Фасли дастани

[1] Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты тарихы. Беренче җилд: борынгы дәвер. Өченче бүлек: 17, 18 һәм 19 нчы гасырларда иске әдәбият. – Казан: Татарстан җөмһүриятенең дәүләт нәшрияты, 1922. – Б. 16–20, 22, 35–37, 42–43; Рахим А. О новом списке татарского исторического сочинения XVII века // Вестник Научного общества татароведения. №7. – Казань: издание Академического центра Татнаркомпроса, 1927. – С 136–138, 143–146; То же // Гали Рәхим: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык / төз. Мәрданов Р., Һадиев И. – Казан: Җыен, 2008. – Б. 196–200, 207–212; Кулъязмалар тасвирламасы. XII чыгарылыш. Татар әдипләре һәм галимнәренең кулъязмалары. Өченче бүлек / төз. А.Фәтхи. – Казан: ун-т нәшр., 1968. – Б. 18; Усманов М. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв.: «Сборник летописей», «Дафтар-и Чингиз-наме», «Таварих-и Булгария», татарские шаджара. – Казань: изд-во ун-та, 1972. – С. 36.

нәсли Чыңыз» дип исемләнгән. Әлеге дастаннан алынган «...Әмма Борһансолтан урус қулунда мөртәд булды» дигән җөмләдән соң, хат авторы түбәндәгеләрне язган.

«...Аның уғылы Ғалим хан, аның уғылы Кучүк хан, аның уғылы Солтанморад хан, аның ағасы Бәхтегәрәй батур солтан, энесе Әхмәд солтан берлә Мансур ахун берлә Ибраһим солтанлардур. Қырым, Рум йорутында кяфер урыс ақ қан берлә яудур. Ул йақдин алар йөрүмәкчедүр. Қырым, Рум, Хунгәр дә бирү. Әмма мән – йаман Солтанморад солтан бу йақдин қазақ, қарақалпақ қолун, чирүене алыб, түрт йул иштәк-башқорт йорты да йау тиб, ислам қылычы чапармыз тиб килдүк, Ширбаз, Җанбәк батур берлә илче булуб, қазақ, қарақалпақны чақыра. Инша Аллаһу Тәғалә, амин.

Сәнәти 1140, сәфәр бителде бу хатны.

Йылайыр Ширбаз, Җанбәк батур берлә килдүк, антумыз-ширтүмез бар ирде қарақалпақ, қазақның чирүене алыб, атланурмыз тиб, инша Аллаһу Тәғалә, амин.

Әд-доғаи сәламнамә.

Бисмилләһир-Рахмәнир-Рахим. Һу әл-Моштақ.

Йырақ йирдин йакын күңел берлә Қырым, Рум, Хунгәр әгзәм, һәммә нуғай берлә башқорут халқы йир үпә, тез чүгә, әд-доғаи әс-сәлам әйттеләр. Солтанларның солтаны, ханларның ханы, җанларның җаны Әбүлхәйер Мөхәммәд батур ханға әд-доғаи әс-сәлам қыйладурлар. Инша Аллаһу Тәғалә, амин.

Мин, йаман Солтанморад солтандин сүз улдур: Әбүлхәйер ханға эне була килдүк, қолы буламыз, қылычын чапамыз үлгәнчә, инша Аллаһу Тәғалә, амин. Валлаһи, билләһи, таллаһи, өтүрүк имәсдүр. Әүвәл Ходай орысун, икенче Мөхәммәд пәйғамбәремез орсун, өчүнче хәзрәти хуҗа орсун, өтүрүк булса, инша Аллаһу Тәғалә, амин.

Әбүлхәйер хан мең йәшәсүн, оҗмахда урыны улсун, инша Аллаһу Тәғалә, амин.

Мин – Солтанморад хан битедүм бу хатны сәнәти сәфәр бителде[2] 1140».

Һижри 1140 нчы елның сәфәр ае хәзерге (григориан) календаре белән 1727 елның сентябрь-октябрь айларына туры килә.

Хатның русчага тәрҗемәсе шул ук архив эшенең 771–772 нче кәгазьләрендә сакланган. Тик анда кайбер сүзләрнең төшеп калганлыгы белән бергә, хаталы язылганнары да бар. Аны, нигездә, имлясын саклаган хәлдә, түбәндә күчереп бирәбез.

«В присланном листе киргис-каисацкои Малои Орды от Абулхаир хана для объявления главным командиром, полученном чрез перевотчика Рамана Уразлина 1737-м году сентября 1 дня.

По переводу написано:

Во имя всемогусчаго и всесчедрого бога о роде, славе киргис хана.

У пророка Ноя были четыре сына и четыре дщери, а именно из сынове – сын Хам, второи – Сам, третеи – Канган, четвертои – Яфяс. А первая дочери Резяп, вторая Зяхап, третия Рехат, четвертая Рахят. А Резяб была у него настоясчая дочь, а те три родились: Зехап – от суки, Рехат – от ишеки, Рахат – от кошки. А Хамова

[2] әл-Моштақ – сагынычлы, күрергә теләнгән (Аллаһы Тәгаләнең мактаулы сыйфаты); өтүрүк имәс – ялган түгел; бителде – язылды.

колена – арабия, а от Сама – газямцы (сиречь[3], окроме арабия все другие нацы). А Канган во время потопа пропал и поколена от него пересеклась. А от Яфяса – римленя. А оного Яфяся называли некоторые Абулчои ханом. А у Абулчы хана сын Бакирхан, у него сын Увыз хан, у него сын Кук хан, у него сын Бугар хан, у него сын Кара хан, у него сын Кунва Мерген хан, у него сын Уджам Бугрил хан, у него сын Сам Сучи хан, у него сын Салер Сочи хан, у него сын Санаберук хан, у него сын Кучу Мерген хан, у него сын Коземан хан, у него сын Караммал хан, у него сын Турумтаи Чечен хан, у него сын Тумеул Мерген хан, у него сын Доюн Баян хан, у него сын Чингиз хан, у него сын Иючи хан, у него сын Саин хан, у него сын Сертак хан, у него сын Бырютак хан, у него сын Тохтамыш хан, у него сын Тугали хан, у него сын Тогтагаи хан, у него сын Алтын хан, у него сын Бердебек хан, у него сын Шабик хан, у него сын Муртаза хан, у него сын Кучюк хан, у него сын Гали хан, у него сын Араслан хан, у него сын Бурган-султан хан (а онои Бурган-салтан восприял християнскои закон), у него сын Галим хан, у него сын Кучюк хан, у него сын Салтанмурат хан. У него большои брат Бактигиреи батыр султан[4], у него ж братьи меншие Ахмет салтан, Мансур ахун, Ибраим султан.

Как крымцы, так урумцы (сиречь, турки) против россииского белого царя имеют воины с стороны им, а з другои с каисаками и каракалпаками, будучи в башкирскои орде, мне – худому Султану-Мурату иметь же воину. И затем приехали посланником Ширбазы, Дженбек батырем для призыву каисаков и каракалпаков, уповая на господа Бога, аминь.

Писана сие письмо 1140-м году.

С Елаир, Шербазьем, Дженбек батырем приехали мы по прежнеи нашеи присяге, с которыми было в одном согласии, взяв каисачье и каракалпачье воиско итти на Россию.

Да во имя всемогсучаго и всесчедраго Бога, от дальнего разстояния, ближним сердцем, крымцы, румцы (сиречь, турки) и нагаицы и башкирцы из салтанов салтан, ис ханов хан Абулхаир Мухаммет багатырь хану с мольбою поклон отдаю до лица земли.

От меня – худова Салтанмурата салтана Абулхаир хану следуюсчие слова, что приехали мы к тебе и хотим быть меншими братьями и рабами, и служить вечно, и уповаем на Бога, аминь. И подлинно, неложно. (В начале убеи Бог, потом убеи Мухаммет и хазряти ходжа, ежели неправда).

Умножи Бог Абулхаир хану ево веку до тысечи лет и быть ему в раю.

Уповаю на Бога, аминь.

Сие писал я – Салтанмурат хан, 1140 года».

Монда күчерелгән хат тексты архив эшендәге кәгазьнең бары тик бер ягына язылган өлеше генә. Кәгазьнең икенче ягында да төп эчтәлеге шундый ук рухтагы хат теркәлгән. Тик безнең бу җыентыкка кагылышлы булмаганга, анысын күчерү ихтыяҗы юк.

Солтанморатның әлеге хаты эчтәлеге һәм стиле ягыннан төрки хөкемдарлар-

[3] сиречь – то есть; иными словами.

[4] В тексте ошибочно: «у него ж братьи меншие Бахтыгирей батыр салтан».

ның традицион дипломатик хатларына охшаш дияргә мөмкин. Адресатны «солтанларның солтаны, ханларның ханы, җанларның җаны» дип купшы рәвештә зурлау, «мең яшәсүн...» дигән теләк сүзләре, хат авторы үзен «йаман» дип, ырудашларын «йир үпә, тез чүгә» дип сыйфатлаган түбәнчелек сүзләре шуны дәлилли.

Хат текстының палеографик җәһәтенә килгәндә, ул үзенчәлекле өслүбтә язылган. Гарәп хәрефләренең үзара пропорцияләре һәм бер-берсенә ялганутоташуларында кагыйдәләргә ярашмау, аерым сүзләрнең хаталы булуы (әйтик, «батур» сүзен «бертур» дип язу), кайбер хәрефләрнең төп элементлары язып бетерелмәү (мәсәлән, «илче» сүзендәге «ч» хәрефе) күзәтелә. Аерым сүзләрнең өлешләре кабатланган булуы, мәсәлән, «Бәхтегәрәй» исемендәге «Бә» иҗеге ялгыш ике тапкыр, «солтаны» һәм «ханы» сүзләрендә «-ны» кушымчасы икешәр мәртәбә язылган очраклар бар. «Гайн» (гъ) хәрефенең сүз башындагы язылышы специфик рәвештә, бормалы итеп язылган. Хатның датасын белдергән 4 саны да шуңа охшаш. Датаның елы янындагы «сәфәр» сүзен, язылышына күрә, «сыгыр» дип укырга да мөмкин кебек. Тик ул очракта, беренчедән, «сыер елы» мәгънәсе күздә тотылган дип фаразланса, анда, һичшиксез, «елы» дигән сүз дә язылыр иде. Икенчедән, 1140 нчы һиҗри ел көнчыгыш календарендәге «сыер елы»на туры килмәгән һәм аңа якындагы еллар да «сыер елы» булмаган. Шулай ук ике нокталы хәрефләрнең ноктaларын вертикаль кую, «син» (с) хәрефе астындагы өч ноктаны кыек сызыкча белән белдерү, сүз ахырындагы «йа» хәрефе астына икешәр нокта кую үзенчәлекләрен, текстта хәрәкәләрнең мул кулланылган булуын да искәртергә кирәк.

Бу хатның авторы Солтанморат Көчек улы турында тарихи хезмәтләрдәге мәгълүматлар каршылыклы. Рус империясенең мөселман җирләрен басып алуына каршы көрәш җитәкчесе, каракалпак ханының улы буларак яисә башкорт дип аталган бу шәхеснең XVIII гасыр башында гаскәри ярдәм алу максаты белән Кавказ, Кырым һәм Төркиягә барганлыгы язылган. Алдар-Күчем җитәкчелегендәге татар-башкорт күтәрелеше вакытында әлеге Солтанморатка ант итеп, Казанны алган очракта аны хан итеп күтәрү нияте булган. 1708 елның башында ул Казан астындагы баш күтәрүчеләр тупланган Саурыш авылына килгән. (Архив документында исеме Солтан-Морат, Морат һәм Солтан-Хуҗа дип, төрлечә язылган)[5]. Ул 1708 елда үз сугышчылары белән Кавказдагы Терек кальгасына һөҗүм иткәч русларга әсир булып төшкән. Тарихи документларга нигезләнгән кайбер хезмәтләрдә Солтанморат шул елда Казанга алып килеп асып үтерелгән дип языла[6]. Архив документында язылганча, 1708 елның 20 апрелендәге сорау алуда Морат Көчек улы үзен «башкорт солтаны дип йөртүче» буларак аталган. Сорау алуда әтисе каракалпак һәм

---

[5] Материалы по истории Башкирской АССР. Ч. I: Башкирские восстания в XVII и первой половине XVIII вв. – М.–Л.: изд-во АН СССР, 1936. – С. 43, 45, 223, 225.

[6] Алишев С. Каһарман бабайлар: татар крестьяннарының сыйнфый һәм милли азатлык хәрәкәте тарихыннан очерклар. – Казан: Татар. китап нәшр., 1976. – Б. 13; Мустакимов И. Новые документы по истории Волго-Уральского региона начала XVIII в. // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2006. – №2. – С. 55; История татар с древнейших времён. В семи томах. Т. V: татарский народ в составе Российского государства (вторая пол. XVI – XVIII вв.). – Казань, 2014. – С. 497.

кыргызларның ханы булганын, үзен башкортлар солтан итеп сайлап куйганлыгын әйткән, аннан соң Кубаньга, Кырымга, Төркиягә барганын, Кавказда сугышуын белдергән[7]. 1708 елның 16 июнендә аны җәзага тарту турында патша әмере игълан ителгән һәм 1709 елгы бер документта кабыргасыннан асылганлыгы әйтелгән[8].

1708 елда асылган кеше исеменнән 1727 елда язылган хат булу факты, әлбәттә, аптыраш тудыра. Ләкин кайбер мәгълүматларга караганда, әлеге Солтанморат 1709 ел башында яңадан каракалпаклар ханы сыйфатында башкортлар арасында пәйда булган. Шул вакытта һәм 1720 нче елларда ул тагын русларга каршы яу әзерләүче буларак тасвирланган. 1722 елгы архив документларында Теректа 1708 елда әсир итеп алынган һәм Казанда асылган Морат ханның исән булуы турында мәгълүматлар бар[9]. Карасакал җитәкчелегендәге соңгырак күтәрелеш уңаеннан 1742 елдагы тикшерү эшендә үзен Солтан Морат хан дип белдергән һәм Казанда асып үтерү җәзасына хөкем ителгәч, котылу җаен тапкан һәм ыргакка асудан калган ярасын күрсәткән кеше, имеш, Габдрахман исемле бер качкын дигән хәбәр дә бар[10].

Солтанморат Көчек улы исеменнән 1727 елда Казакъ ханы Әбелхәергә язылган (бу китапта тексты өлешчә басылган) хатның авторы үзен Чыңгыз ханның Нух пәйгамбәрдән үк килгән шәҗәрәсен дәвам итеп Көчек улы Солтанморат буларак күрсәткән. Шул ук хатның монда тексты басылмаган өлешендә авторы үзен Солтанморат дип атап, башыннан кичкән әүвәлге хәлләрне тасвирлаган һәм русларга каршы сугышу өчен хәрби ярдәм сораган. Хат текстына караганда, аны әйтелгән кеше язган булуы шик уятмый.

«Икенче текст» кулъязмасы Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «2224т» шифры белән саклана.

Күләме 41 кәгазьдән торган җыентык ике өлештән, ягъни бергә тегелгән ике төрле кулъязма китаптан гыйбарәт. Аларның беренчесендә (1а–28б кәгазьләрдә) «Чыңгызнамә» китабының тексты язылган. Ул Россиядә эшләнгән яшькелт төстәге кәгазьгә XIX гасыр башында теркәлгән. Кәгазендәге су билгеләре 1791–1808 нче елларга карый.

Җыентыкның тышлыгы юк. Форматы 16,5х21,5 см. Кустодлары бар.

Текстларны күчергән һәм кулъязманың иясе булган кешеләрнең исемнәре язылмаган.

Беренче кулъязманың сакланышы начар: юан җеп белән тегелгән төбе таркалган диярлек, юешләнү кичергән, кәгазь читләре таушалып тетелгән (бигрәк тә, 20–28 кәгазьләрнең югары өлешләре зарарланган). 22–28 кәгазьләрнең өске өлешләре укмашып ябышкан һәм уалып төшкәнлектән, язулары тулаем укырлык түгел. 1а, 5а, 6а, 8а, 9б, 12б, 13а, 16б, 18б, 20а, 21б, 22б, 24б, 25а, 26б һәм 27а кәгазьләре аеруча пычрак. Болардан тыш, төрле бөҗәкләр таплаганга күрә, кайбер битләрдәге

[7] Материалы по истории Башкирской АССР. Ч. I..., 1936. – С. 238–243; История Татарии в документах и материалах. – М: Соцэкгиз, 1937. – С. 332–296.
[8] Материалы по истории Башкирской АССР. Ч. I..., 1936. – С. 256, 522.
[9] Шунда ук. – Б. 49–52, 295, 299–300.
[10] История Татарии в документах и материалах. – М: Соцэкгиз, 1937. – С. 413.

аерым сүзләрне танып уку шактый кыен. Чөнки язу карасы төсенә охшаш тапларның хәреф нокталары белән буталуы зур читенлек тудыра. Кульязманың 7а, 8а, 9б, 19а, 19б һәм 22б кәгазьләре бөҗәкләр «һөҗүме»ннән аеруча зарарланган.

Җыентыкның 1а–28б кәгазьләрендә «Чыңгызнамә» китабының бөтен бүлекләре язылган булса да, ул тулы түгел. Текстның башындагы һәм ахырындагы берничәшәр бите төшкән, шулай ук кульязма дефектлы булуы сәбәпле, урыны-урыны белән текст эчендә өзеклек кергән. Текстның башында һәм 12 нче кәгазьдән соң – берәр кәгазе, 4 нче кәгазьдән соң ике кәгазе, 24 нче кәгазьдән соң шулай ук ике кәгазе төшкән. Кульязманың кәгазьләре әүвәл таркалганнан соң үзара бутап тегелгән. Шунлыктан, текстка күрә кульязманың кәгазьләре мондый тәртиптә урнашырга тиеш: 1–4, 13–18, 5–12, 25–28, 23–24, 19–22.

«Чыңгызнамә» тексты бер биттә 11x16 см мәйданда һәм уналтышар юл итеп язылган. Имлясы тотрыклы, хаталары күп түгел. Текст көрән төстәге кара белән, нәсех төрендә язылган, аерым хәрефләрнең язылышы сөлс һәм тәгъликъ төрләрендәгечә. Палеографик үзенчәлекләренә килсәк, «уау» хәрефе өстенә өчәр нокта куелган, «б» хәрефе урынына «п», ә «җ» урынына «ч» һәм кайбер сүзләр хәрәкәләр белән язылган очракларны әйтергә мөмкин. «Кәф» хәрефенең төп өлешенә кушыла торган авыш таяксыман сызыкчасы урынына күпчелек очракта һәмзәгә охшашрак бормалы «кәф» ишарәте («һәмзәтел-кәф», «шәрәтел-кәф») язылган. Текстның кайбер урыннарында ялгыш язып, сызылган төзәтмәләр бар.

Кульязма җыентыкның 29а–41б кәгазьләрендә дини риваятьләр теркәлгән. Ул өлеше башка кеше тарафыннан, караңгы көрән төстәге кара белән, тәгъликъ төрендә язылган. 29а–30а кәгазьләрдәге аерым гыйбарәләрне язганда кызыл төстәге кара кулланылган.

Җыентыктагы бу өлешнең сакланышы тагын да начаррак: 29 нчы кәгазьнең түбәнге өчтән бер өлеше генә сакланган, ә 30–41 кәгазьләрнең өске өчтән бер өлешләре тетелеп җуелган.

Кульязма җыентык 2009 елда Татарстан Республикасының Милли китапханәсе һәм КФУның берләштерелгән фәнни-археографик экспедициясе вакытында Мари Иле республикасының Бәрәңге районындагы Портянур авылында яшәүче Гариф Һадиевтан алынган.

«Өченче текст» кульязмасы Р.Мәрдановның шәхси архивында саклана.

Ул аерым ике кульязма китап калдыгын кушып тегелгән җыентыкның икенче өлешен тәшкил итә. Берләштереп тегелгән булсалар да, әлеге кульязмалар арасында мәгънәви һәм башка төрле бәйләнеш юк. Өстәвенә, аларның кәгазьләре дә төрле форматта булуы белән бергә, беренчесе ак төстә, ә икенчесе яшькелт-зәңгәрсу төстә. Шунлыктан, монда бары тик Чыңгыз хан нәселе һәм Аксак Тимер дастаннары теркәлгән 25а–37б кәгазьләрне тасвирлау белән чикләнәбез.

Россиядә эшләнгән, яшькелт-зәңгәрсу төстәге кәгазенең форматы 17x21 см. Филиграньнәре 1780–1790 нчы елларга карый һәм, шуңа күрә, текстның күчерелгән вакыты XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башы дип билгеләнә.

Кулъязманың тышлыгы юк, төбе ак җеп белән тегелгән.

Текст көрән төстәге кара белән, тәгъликъ төрендә язылган. 31б–33а кәгазьләрдә Чыңгыз хан тарафыннан биләргә тәгаенләгән тамга рәсемнәре кызыл төстәге кара белән ясалган. Шулай ук 35а кәгазьдәге Аксак Тимергә багышланган дастан атамасының «Фасыл фи» дигән өлеше кызыл төстәге кара белән язылган.

Кустодлары бар. Кулъязманы күчергән кешенең һәм аның иясенең исемнәре күрсәтелмәгән.

Кулъязманың сакланышы уртачадан түбән: ул юешләнү кичергән, кәгазьләренең читләре таушалган һәм өлешчә тетелгән, битләрендә пычрак таплар бар.

Бу кулъязмада «Чыңгызнамә» тексты тулы түгел, аның башы һәм ахыры юк. Ягъни, башындагы биш кәгазь чамасы күләмендә кәгазе җуелган. Шулай ук 30 һәм 31 кәгазьләр арасында бер кәгазе төшкән булуы сәбәпле текстка өзеклек кергән. Ахырында Аксак Тимер дастаны язылган 7-8 кәгазе төшкән.

Текст кәгазь битләрендә уналтышар юл күләмендә һәм язылган мәйданы 10(11)х15(15,5) см зурлыгында. Палеографик үзенчәлекләренә килгәндә, тексттагы кайбер сүзләр хәрәкәләр белән язылган, «ч» хәрефе урынына еш кына «җ», ә «б» урынына «п» хәрефе язылган һәм «уау» хәрефе өстенә өчәр нокта куелган. Имлясы тотрыксыз, хаталары шактый. Кайбер урыннарында артык хәрефләр яки иҗекләр язылып сызылган.

Әлеге кулъязманы 2001 елда Татар дәүләт гуманитар институты студенты Фәрһад Шәйхуллов Татарстан Республикасының Азнакай районындагы Татар Шуганы авылыннан алып килеп, бу юлларның авторына биргән иде.

Бу кулъязманың фоторәсеме басылды:

Татар китабы = Татарская книга: альбом / төз. Мәрданов Р., Һадиев И. – Казан: Татар. китап нәшр., 2013. – Б. 96.

«Дүртенче текст» кулъязмасы Татарстан Республикасының Милли музеенда педагог, тел-әдәбият белгече, археограф Зәйнәп Максудова (1897–1980) фондында «18369-141» шифры белән саклана. «Чыңгызнамә»нең беренче бүлеге язылган дефектлы кулъязма өч өлештән тора: беренчесе – юка кәгазь белән тышлап тегелгән һәм гарәп язуы белән «3 нче төп» дип билгеләнгән 7 кәгазьдән; икенчесе – шулай ук юка кәгазь белән тышлап тегелгән һәм «4 нче төп» дип билгеләнгән 8 кәгазьдән; өченчесе – 11 һәм 14 саннары куелган куш битнең түбәнге ертык өлешеннән гыйбарәт фрагмент. Аларга З.Максудова тарафыннан зәңгәр төстәге химик кара белән гарәп саннары куелган һәм әлеге өч өлеш барлыгы 17 кәгазьне тәшкил итә. Кульязманың бит саннарын текст тәртибенә туры китереп урнаштырганда, ике кәгазьдән торган фрагмент 1 һәм 2 нче, ә «3 нче төп» өлешенең 9–15 нче битләре – 3–9, «4 нче төп»нең 1–8 нче битләре, чынбарлыкта, 10–17 нче кәгазьләрне тәшкил итәр иде.

Кәгазенең форматы 10х16 см, һәр битендәге тексты 11 юл күләмендә һәм язуы 6,5х11,2(11,5) см мәйданны тәшкил итә. Кустодлары бар.

Текст тулы түгел, башы һәм ахыры юк, уртасында да өзеклек кергән.

Кульъязманың тексты көрән төстәге кара белән, гарәп язуының нәсех төрендә (кайбер хәрефләре тәгъликъ язуы кагыйдәләренчә) язылган. Имлясы тотрыклы, хатасыз диярлек. Кайбер сүзләр хәрәкәләр белән язылган. Аерым очракларда «уау» хәрефенең өстенә өчәр нокта куелган.

Кульъязма истәлекнең үзендә датасы күрсәтелмәгән, ә кәгазендәге филиграньнары аның 1663–1697 елларда Европада эшләнгәнлеген белдерә. Димәк, бу ядкәр XVIII гасырның башында күчерелгән дип билгеләргә мөмкин.

Шәмәхә төстәге химик кара белән «3 нче төп» дип язылган юка кәгазенең алгы тарафында гади карандаш белән гарәп хәрефләрендә «Дастане Чыңыз хан вә Аксак Тимүр. Тәхминән[11] 17 нче гасыр башларында язылганга охшый» дип теркәлгән. (Бу дата дөрес түгел). Тышлык вазыйфасындагы кәгазьнең ахыргы битендә карандаш белән «7 листов» (ягъни, җиде кәгазьдә) дигән язуы бар. Ә икенче өлешенә шәмәхә төстәге кара белән «4 нче төп» дип язылган һәм анысының тышлык рәвешендәге соңгы кәгазенә авторучка белән «8 листов» (ягъни, сигез кәгазьдә) дип язылган.

Кызганычка каршы, кульъязманың сакланышы начар, ул бик таушалган, кәгазьләре өлешчә ерткаланып җуелган. Куш бит калдыгы фрагментының 11 саны куелган беренче кәгазе 7,5х8,5 см зурлыгында булып, аның ертылган өске өлеше сакланмаган, тексты кәгазьнең ике ягында да түбәнге тарафындагы бишәр юлдан гыйбарәт. Шул ук фрагментның 14 саны белән билгеләнгән, 10х8,5 см зурлыктагы кәгазендә дә бишәр юл тексты бар. «3 нче төп» дип тәгаенләнгән өлешенең бөтен кәгазьләре дә урталай ертылган хәлдә, 9 нчы сан белән билгеләнгән кәгазьнең өске тарафының тегелгән ягы гына өлешчә сакланган. 11 нче кәгазьнең чите ертылып юкка чыккан. 11 һәм 12 нче кәгазьләр арасындагы бер кәгазе ертылып җуелган. 13 нче кәгазьнең аскы яртысының чите ертылып чыккан. 14 нче кәгазьнең уртасындагы бер өлеше шулай ук ертылып төшкән. Сакланган кәгазьләренең дә читләре бик нык таушалган булуы сәбәпле, язулары бозылган һәм уңган.

Кульъязманың «4 нче төп» дип билгеләнгән өлеше, чагыштырмача тулырак хәлдә. Аның кәгазьләре урталай ертылган булса да, җуелмаганнар һәм текстына әлләни зарар килмәгән диярлек. Кульъязма истәлекнең элекке иясе З.Максудова тарафыннан әлеге ике төпнең дә ертык бит читләре, бөтенләй таркалып китмәсен өчен, юка кәгазь белән ябыштырылган.

«4 нче төп»нең 4б кәгазендә З.Максудова тарафыннан карандаш белән «қырқын» сүзенә «кисеш, кырылыш» дигән аңлатма һәм 5б кәгазь читенә ябыштырылган өстәмә кәгазьгә химик кара белән гарәп хәрефләрендә «кеш – соболь; һәбәрәң – шагрень күн» дигән искәрмәләр теркәлгән.

Зәйнәп Максудованың шәхси архивындагы дефектлы күчермә буларак, бу кульъязма телгә алынган: Усманов М. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. ..., 1972. – С. 102.

[11] *тәхминән* – якынча.

«Бишенче текст» кульъязмасы Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «584т» шифры белән саклана.

Гомуми күләме 62 кәгазьне тәшкил иткән, XVIII гасыр ахырына нисбәтле җыентык Россиядә эшләнгән кәгазьгә язылган. Филиграньнәре 1780 нче елларга нисбәтле.

Кульъязманың тышлыгы юк, төбе җеп белән тегелгән. Форматы 17х21,5 см.

Андагы текстлар нәсехкә якын төрдә, көрән төстәге кара белән, ә кайбер башлам өлешләре һәм аерым гыйбарәләр кызыл кара белән язылган. Кустодлары бар.

Сакланышы уртача: кульъязма юешләнү кичергән, аерым битләре пычрак һәм төбеннән аерылган, кәгазь читләре таушалып тузган.

Текстларны күчергән кешенең һәм кульъязма иясенең исемнәре күрсәтелмәгән.

Җыентыкның 1а–18а кәгазьләрендә дини риваятьләр язылган. Бу текстның башы юк, ахыры бар.

18а–30а кәгазьләрдә «Аксак Тимер дастаны» теркәлгән. Дастанның бер биттә язылган мәйданы 11х16,5 см күләмендә һәм тексты тулы битләрдә 14–15 юллы итеп язылган. 23б кәгазендә Истанбул шәһәренең схематик рәсеме ясалырга тиешле буш урын калдырылган булуы сәбәпле, 8 юл гына теркәлгән.

Дастанның тексты тулы. Аның исеме текст башында (18а кәгазьдә) кызыл төстәге кара белән «Вә биһи нәстәгыйн, Фасыл дастани Аксак Тимер» дип язылган. Палеографик үзенчәлекләреннән кайбер сүзләргә хәрәкәләр куелганлыгын, «җ» хәрефе урынына «ч» язылган очраклар булуын әйтергә мөмкин. Имлясы бик тотрыклы түгел, хаталары шактый, кайбер хәрефләрнең нокталары куелмаган.

Кульъязманың 30б кәгазендә шигъри юллар һәм шигъри табышмаклар, 31а кәгазьдә дога фрагментлары теркәлгән. 31б–62б кәгазьләрендә намаз шартларына багышланган, гарәп телендәге әсәр теркәлгән. Аның башы бар, ахыры юк.

Җыентык китапханәгә Татарстан Республикасының Кукмара районындагы Манзарас авылында яшәүче Гөлнур Шакировадан 1995 елның июнь аенда Р.Мәрданов тарафыннан алынган иде.

Бу кульъязма турында мәгълүмат басылды:

1) Мәрданов Р. Кукмара төбәге тарихыннан кайбер сәхифәләр // Хезмәт даны (Кукмара). – 1995. – 30 сентябрь;

2) Мәрданов Р. Китапларда милләт язмышлары... – Казан: «Милли китап» нәшр., 2010. – Б. 34, 65.

«Алтынчы текст» кульъязмасы Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1024т» шифры белән саклана.

Гомуми күләме 61 кәгазьдән торган, XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башына нисбәтле җыентык Россиядә эшләнгән зәңгәрсу-яшькелт төстәге кәгазьгә язылган. Филиграньнәре 1790 нчы елларга карый.

Кульъязманың тышлыгы юк, төбе юан җепләр белән тегелгән. Форматы 16х20(20,5) см.

Барлык текстлары да бер кеше тарафыннан, тәгъликъ төрендә, көрән төстәге кара белән язылган. Кустодлары бар. Текстларны күчергән һәм кульъязма иясе булган кешеләрнең исемнәре күрсәтелмәгән.

Сакланышы уртача диярлек: 1–8, 18, 40, 49 һәм 56 нчы кәгазьләре түбеннән аерылган. 40 нчы кәгазьнең уртасында янып, 2 см диаметрлы үтәли тишелгән урыны бар. Җыентыкның аерым битләре шактый пычрак, күп битләре таплы, кәгазь читләре таушалган. Кульъязманың ертылган бит читләре (аеруча, түп тарафы) XIX гасырда реставрацияләнгән, 57 нче кәгазьнең ертылган өлеше җеп белән тегеп тоташтырылган.

Кульъязманың 1а–6б кәгазьләрендә хәзрәти Галигә багышланган хикәятләр, 7а–18б кәгазьләрдә «Кыйссаи Сәкам» тексты, 19а–20б кәгазьләрдә фарсы телендәге шигырьләр язылган. 21а–34б кәгазьләрдә XV гасыр госманлы төрек авторы Раушанинең «Чубаннамә» исемле шигъри әсәре һәм аның һәр юлының татар теленә тәрҗемәсе теркәлгән. Бу тексттагы бүлекчә исемнәре кызыл кара белән язылган.

Җыентыкның 35а–47а кәгазьләрендә Аксак Тимергә багышланган дастан язылган. Текстның башы юк (бер кәгазе җуелган), ахыры бар. 40 һәм 41 кәгазьләр арасында да бер кәгазе төшеп югалган. Текст кәгазь битләрендә 14–15 юл күләмендә һәм язылган мәйданы 10(10,5)х15(15,5) см зурлыгында.

Дастан язылган текстның палеографик үзенчәлекләреннән кайберләре: протографында «нун» (н) хәрефенең сүз ахырындагы аерым язылышы шикәстә язуындагыча булганлыктан, «ны» һәм «не» рәвешендә күчерелгән урыннары бар, шулай ук протографтагы «син» (с) хәрефе астындагы өчәр нокта бу кульъязмадагы кайбер очракларда ялгышлык белән нокталары өскә куелып «шин» (ш) рәвешендә язылган.

Кульъязманың 47а–54а кәгазьләрендә шәргый мәсьәләләр, 54б–61б кәгазьләрдә «Китабел-каһкаһә» исеме астында дини риваятьләр язылган.

Җыентык китапханәгә Оренбург өлкәсенең Северный районындагы Бакай авылы имамы Хәлиулла ага Габделхәеровтан 1996 елның 11 апрелендә Р.Мәрданов тарафыннан алынган иде.

Бу кульъязма турында мәгълүмат басылды:

1) Мәрданов Р. Якутлар табыладыр вакыт белән... // Бердәмлек (Самара). – 1996. – 2–8 июль;

2) Мәрданов Р. Китапларда милләт язмышлары... – Казан: «Милли китап» нәшр., 2010. – Б. 45, 65.

«Җиденче текст» кульъязмасы Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «2499т» шифры белән саклана.

XIX гасыр башында Россиядә эшләнгән кәгазьдә «Аксак Тимер дастаны» язылган.

Күләме 12 кәгазь. Кульъязманың тышлыгы юк, төбе юан җеп белән тегелгән. Форматы 11х17(18) см.

Тексты көрән төстәге кара белән, бозык һәм шактый тотрыксыз рәвештә, татар тәгъликына тартым төрдә язылган. Кустодлары бар.

Текстны күчергән һәм кульъязма иясе булган кешеләрнең исемнәре теркәлмәгән. Фәкать 4б кәгазьнең түбәнге өлешендә «Мәдрәсәи Йагкуб хәзрәт» дигән язуы бар.

Сакланышы уртачадан түбән дәрәҗәдә: 8 һәм 13 кәгазьләре төбеннән аерылган, 7 кәгазьнең югары почмагы ертылып җуелган, 9 кәгазьнең өске өлеше ертылып чыккан. Элек юешләнү кичергәнлектән, битләре зарарланган, тапланган һәм почмаклары таушалган.

Аксак Тимер турындагы дастанның тексты тулы түгел, башы һәм ахыргы өлешләре сакланмаган. Башыннан ярты бит чамасы тексты юк, 7 һәм 8 кәгазьләре арасында бер кәгазе һәм ахырында да бер кагазе төшеп җуелган.

Дастанның бер биттә язылган мәйданы 8(9)x13,5(14,5) см зурлыгында һәм 13(17) юл күләмендә.

Текстта хаталар шактый, сызып төзәтелгән урыннары бар. Кайбер хәрефләр, иҗекләр һәм сүзләр, шулай ук аерым җөмлә өлешләре һәм тулы җөмләләр дә төшеп калган. Палеографик үзенчәлекләрдән «уау» хәрефенең өстендә өчәр нокта куелганын, «син» һәм «шин» хәрефләренең ахырындагы ярымтүгәрәк өлешләренең очы эчкә таба борылып, «нун» (н) хәрефенә охшаган язылышларны әйтергә мөмкин.

Кульъязманы китапханәгә мәшһүр татар рәссамы һәм скульпторы Бакый Урманченың (1897–1990) улы Айдар әфәнде 2017 елның 11 июнендә тапшырды.

Кульъязма истәлек урталай бөкләнгән А4 форматындагы кәгазь эчендә (1 һәм 14 кәгазьләр). 1а кәгазьгә шәмәхә төстәге кара белән гарәп хәрефләрендә Б.Урманче кулы белән «Аксак Тимер тарихы. Бу кульъязманы Фәезханов «Аксак Тимер»е белән чагыштырып карарга» дип язылган. Ашыгыч рәвештә язылган бу мәгълүматта Хәлфин урынына ялгыш Фәезханов фамилиясе теркәлгән.

«Сигезенче текст» кульъязмасы Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1147т» шифры белән саклана.

Гайса улы Амәт турындагы дастанның фрагменты (башы һәм ахыры юк) Россиядә эшләнгән бер кәгазьнең ике тарафына XVIII гасыр ахырында көрән төстәге кара белән, тәгъликъ төрендә теркәлгән. Кәгазендә су билгеләре юк.

Форматы 15,5x19,5 см.

Сакланышы начар: кәгазь читләре тетелгән һәм ерткаланган.

Бу кульъязма һәм «Унберенче текст» кульъязмасы китапханәгә Татарстан Республикасының Теләче районындагы Олы Мишә авылында яшәүче Шәйхаттар Нәҗметдиновтан китапханә хезмәткәре Айрат Заһидуллин тарафыннан 1996 елның 17 августында алынган.

«Тугызынчы текст» фрагменты Мәскәү шәһәрендәге Россия дәүләт борынгы актлар архивында сакланган (248 фонд, 17 тасвир, 1164 саклану берәмлеге, 1015а–1018б кәгазьләр)[12]. Кульъязма «Чыңгызнамә» китабыннан аерып алынган

[12] Бу чыганакның архив эшенә ничек эләгүе турындагы мәгълүмат А.Фәтхинең 1968 елда чыккан мәкаләсендә язылган (Фәтхи А. Мәгърифәт төбәкләре һәм әдәби багланышлар // Казан утлары. – 1968. – №2. – Б. 103–122; Шул ук //Альберт Фәтхи: мәкаләләр һәм истәлекләр / төз.

ахыргы дүрт биттә Идегәй бигә багышланган бүлекнең ахыры, төрле ханнарның биләмәләренә һәм тарихи вакыйгаларга багышланган бүлекләр сакланган.

Бу текст XVIII гасыр башында күчерелгән. Аның ахырында «Тәммәт тәмам. Кәтәбәт Мостафа бине Котлугмөхәммәд» дип язылып, күчерүчесенең исеме күрсәтелгән.

Кулъязма фрагментының сакланышы яхшы. Көрән төстәге кара белән нәсех төрендә язылган текстының имлясы тотрыклы, хаталары аз. Кайбер урыннарында төзәтеп һәм өстәп язылган сүзләр бар. Кустодлары бар. Текст кәгазь битләрендә уникешәр юл күләмендә теркәлгән.

Бишенче һәм алтынчы бүлекләрнең рус теленә 1737 елгы тәрҗемәләре архив эшенең 1013–1014об. кәгазьләрендә урын алган. Ул мәгълүмат тәрҗемәченең кайбер өстәмә аңлатмалары белән тулыландырылган һәм, шунлыктан, имлясын саклаган хәлдә, аны монда тулаем күчерәбез. Тексттагы тәрҗемәче өстәмәләре җәяләр эчендә аерып бирелде, тыныш билгеләре безнең тарафтан куелды.

«Копия №2. С вырезанных ис татарскои книшки четырех листах написано:

Статья о чём следует ниже

Понеже изъясняетца о жилищах прежних татарских ханов, где кто жительство имел, а имянно:

Бухар – Булгара хана жилище.

Тобольск – Урус хана жилища.

Черемшан – Умирхучи хана жилище (которое имеетца в Казанском уезде на Нагаиской дороге, на Закамскои стороне).

Уюзан – Токтамыша хана жилища (а оная Уюзан река в Уфинском уезде на Нагаискои дороге, от города Уфы разстоянием в пятнатцати верстах, пала в Уршак реку).

Между Эмбы и Яика рекам – жилище Дженыбека хана.

Бельское устье – Кара хана жилище.

Актюба – Басмана хана жилище (состоит на устье Сакмары реки). Брат у него меньшеи именем Иючи.

Туратавское устье до самого Алмалы Аты – Чахана хана жилище (сиречь, гора имеетца в вотчине юрматынских башкирцов, где впала Селеук река в Белую реку).

На устье Уфы реки – Тиря хана жилище (разстоянием от Уфы в четырех верстах).

Саралчик – Чалсак хана жилище (а Саралчик имеетца на реке Яике, между Яицкого и Гурьева городков).

Анчи – Хакима хана жилища. А после жилья Хакима хана из-под земли слышен был голос до трёх лет, а после того не слыхали.

Астрахань – Тимер Кутлы хана жилища.

Кабит – Сиберка хана жилища.

Казань – Шигалия хана жилища.

Заинское устье – Булара хана жилища.

Р.Мәрданов. – Казан: «Тамга» нәшр., 2007. – Б. 71); шулай ук кыскача мәгълүмат басылды: История татар с древнейших времён. В семи томах. Т. V..., 2014. – С. 551.

Статья

По-татарски 700 году (ныне тому 450 лет) Темир Аксак взял город Булгар у Абдуллы хана. У Абдуллы хана были два сына, называемые: первои – Алтунбек, второи Алимбек. После того раззорения переселились на речке Казанке и зделали город, в котором жили сто четыре года. А после оное место им не показалось, переселились на устье Казанки реки и зделали город и жили тут сто пятьдесят восемь лет. Мусульманских ханов наследники тут пресеклись. А как в Казани мусульманских ханов не стало, во оное время Шигали хан был в России под караулом, и мусульмана за ним ездили и, привезя в Казань, удостоили в ханы, которои был в ханстве тритцать три года.

А после того русские приезжали с воиском для взятья города Казани, царь по-татарски Калталы Иван (сиречь, царь Иван Васильевич) и бились з семь лет, токмо мусульманов взять не могли. И до взятья города Казани на Свияжском устье россииские зделали город и во оном городе оставили пушки, припасы, провиант и всякои багаж. А после того Шигали хан, изменя мусульманов с россиискими, соединясь с россииским царем, без ведома мусульманов, порох залил водою и город Казань отдал россииским. Мусульмани о том несведомы, многих людеи раззорили и порубили. А после раззорения россиискии царь завладел Казанью по-татарски 961-м году (ныне тому 189 год), в воскресныи день, октября 2 дня.

А когда владели Казанью ханы именами были: первои – Абдулла хан и дети ево Алтунбек, Алимбек. После того Махмут хан, Мемяк хан, Халил хан, Ибраим хан, Мамук хан, Абдуллатив хан, Сахип Гереи хан, Сафа Гереи хан, Али хан, Утеш хан, Ядыгер хан. Токмо во время Ядыгер хана по-татарски 928-м году (ныне тому двести дватцать два года) было солнешное затмение. Потом у Шигали хана взял Казань россиискои царь.

И в 1010 году (ныне тому 140 лет) великии был голод.

В 1017 году (тому ныне 133 года) была князь Дмитриевская воина.

В 1024 году (ныне тому 126 год) была Енелеевска воина.

В 1057 году (ныне тому 93 год) была Иркинская воина. В том году князь Михаила в России был царем.

В 1063-м году (ныне тому 85 год) был мор.

В 1071 году (ныне тому 79 год) башкирцы бунтовали на Россию.

В 1079 году (ныне тому 71 год) была казачья воина, называемая Белита казака.

В 1089-м году (ныне тому 61 год) был небеснои знак – явилась великая и разноцветная: синея-зеленая и красная звезда, о которои многие были в сумнении и страхе и плакали, которую видели как большие так и малыя и говорили: «Что де за притчина явилась на небеси?» Яснением прибавлялась до сорока днеи, и оная звезда из западу выходила и на восток садилась. Но после в россииском государстве стали всякие бедствы и противности, и содом[13] зачались являтца, что россииские командиры приговоря подписались в том, что подданных мусульманов крестить и многих мусульманов, отбив от мусульманства, крестили. И во оном возмущении во

[13] *содом* – беспорядок.



Копия

№ 2.

С вырезанных из татарской книжки четыре листа написано:

Статья о чем следует ниже:

Понеже изъясняется о жилищах прежних татарских ханов где кто жительство имел именно:

Бухар: Булгара хана жилище, Тоболть, Урус хана жилища, Черемшан, Умир Бахучи хана жилище которое имеется в Казанском уезде на Ногайской дороге на Казанской стороне: Икзан Тохтамыша хана жилища [illegible], Икзан река [illegible] уезде на Ногайской дороге от города Уфы разстоянием в пятнадцати верстах [illegible] реку между Эмбы [illegible] река в жилище Дженыбека хана: Бельское устье Кара хана жилище, Аштуба басмана, хана жилище состоит на устье Сакмары реки брат у него меньшей именем Ивчи: [illegible] устье до самого [illegible], Чахана хана жилище сиречь [illegible] имеется в отчине юрматынских башкирцов где впала [illegible] река в Белую реку на устье Уфы реки Тир хана жилище разстоянием от Уфы в четырех верстах, Сарайчик Чалсан хана жилище а Сарайчик имеется на реке Яике между жилого Гурьева городка [illegible] хана жилища а после жилья [illegible] хана из под земли слышен был голос до трех лет а после того не слыхали, Астрахань Тимер Кутлы хана жилища: [illegible] Сиберна хана жилища: Казань Шигалиев хана жилища: Заинское устье Булара хана жилища:/

Статья по татарски, 700: го

ныне тому „450“ лет:/

Темир Аксак взял город Булгару у Абдуллы хана а у Абдуллы хана были два сына называемые первой Алтунбек, второй Алимбек; после того разоренья переселились на реке Казани и зделали город

МОСКОВСКІЙ АРХИВЪ МИНИС. ЮСТИЦІИ

Текстның русчага тәрҗемәсе

многих местах были драки, за что господь бог милостию своею у оных беззаконных россииских людеи разорил самих меж собою – на Москве друг-друга порубили и стала разность. И оного замысления был царь именем Фёдор, которого господь бог в молодых ево летех жизнь пресек.

В 1091 году (ныне тому 59 год) в России царствовали два брата в одном време[ни], первои именем Иван, второи – Петр, Алексеевы дети. И в том же году между башкирским народом явился некоторои мусульманенин именем Сеит Ефар хан, в котором виделись святыя признаки и призывал народ в закон. А башкирскои народ оного Сеита Сефара хана ханом не почитали и по ево велению не поступали, и оставя ево приехали в Россию, за что оные народы гневом божьим обязуя к России, оставлены в погибели. И многие в полону в России от закону своего остались, и поныне изменникам тож будет чинитца.

(А в конце имя писателя пишет тако: «писал Мустафа Кутлумухамметев»).

Переводил переводчик Араслан Бекметев и татарским письмом руку приложил.

[Скрепа:] *В.Татищев.*

17 окт[ября] 1737 [г.]»

Бу кулъязма турында, «Дәфтәри Чыңгызнамә» әсәренең соңгы – елъязмага багышланган өлеше XVIII гасырның 30 нчы елларында Татищевка билгеле булган дип, М.Госманов хезмәтендә искәртелгән[14]. Тик анда күрсәтелгән 900–905 дигән бит саннары архив эшенең иске пагинациясен белдерә, соңгы пагинация буенча алар 1013–1018 кәгазьләргә туры килә. Шулай ук М.Госманов хезмәтендә «Чыңгызнамә»нең елъязма өлеше (6 нчы бүлеге) генә күрсәтелгән булса да, чынлыкта, архив эшендә Идегәй би бүлегенең ахыры, шулай ук 5 нче бүлек тексты һәм аның да рус теленә тәрҗемәсе булуын искәртергә кирәк.

«Унынчы текст» кулъязмасы Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1230т» шифры белән саклана.

Гомуми күләме 14 кәгазьдән торган кулъязма истәлек XIX гасыр башына карый. Ул Россиядә эшләнгән кәгазьгә ачык көрән төстәге кара белән, тәгъликъка якын төрдә язылган. Кәгазендәге филиграньнәре 1775 һәм 1808 нче елларга нисбәтле.

Кулъязманың тышлыгы юк. Форматы 17,7х21,5 см. Кустодлары бар. Текстларны күчергән кешенең һәм кулъязма иясенең исемнәре күрсәтелмәгән.

Сакланышы уртачадан түбән: җеп белән тегелгән төбе таркалган, 1–3 һәм 6–8 нче кәгазьләренең төп яклары тетелеп таушалган, 1а, 8б һәм 9а кәгазьләр шактый пычранган.

Җыентыкның 1а–4б кәгазьләрендә гает вәгазьләре теркәлгән.

4б–7а кәгазьләрдә «Чыңгызнамә» китабының ахыргы ике бүлеге язылган. «Дастанел-мәкян» дип исемләнгәне 4б кәгазьдә башланып, 5а кәгазьдә тәмамланган. Ә «Дастани тарих» бүлегенең исеме 5а кәгазьнең соңгы юлында теркәлеп, тексты 7а кәгазьгә хәтле дәвам иткән. Бу бүлекләрнең текстлары тулы, арага Хи-

[14] Усманов М. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. ..., 1972. – С. 101.

саметдин Мөслиминең «Тәварихы Болгарийә» әсәренең аерым өлешләре дә язылган. «Дастанел-мәкян» һәм «Дастане тарих» текстларының ахырларында «Чыңгызнамә»дән күчерелгән булулары күрсәтелгән.

Җыентыкның 7б–8б кәгазьләрендә Х.Мөслиминең «Тәварихы Болгарийә» әсәре вариантының фрагменты теркәлгән.

9а–14б кәгазьләрдә Таҗетдин Ялчыголның «Тарихнамәи Болгар» әсәре язылган. Аның башы һәм ахыры юк.

Җыентыкның китапханәгә кемнән һәм кайчан алынган булуы төгәл билгеле түгел. Бары тик Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге фондына 1995–2002 еллар арасында кергәнлеген әйтергә мөмкин.

«Унберенче текст» кулъязмасы Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «981т» шифры белән саклана.

36 кәгазьдән гыйбарәт җыентык Россиядә эшләнгән кәгазьгә көрән төстәге кара белән, тәгъликъ төрендә язылган.

Кустодлары бар. Кулъязманың иясе тарафыннан кәгазьнең түбәнге өлешендә карандаш белән пагинация куелган. 1 нче кәгазьдә 6 нчы бит буларак башланып, өзлексез дәвам иткән һәм соңгысы (36б кәгазь) 77 нче бит дип билгеләнгән.

17б кәгазь читендә карандаш белән «Тәварих китабы» дигән, җыентыкның гомуми исеме теркәлгән.

Кулъязманың тышлыгы юк, төбе юан җеп белән тегелгән. Форматы 17,5х22 см.

35а кәгазендә күчерүчесе болай дип язган: «Мөсәүвәдү һәзиһир-рисаләти Җәлаледдин бине Пулат әл-Баландыши мөвәллидән вә карьяи җәдид тәваттәнән... фи сәнәи 1885, фи бөрҗе нуябер, фи йаумиһи 26». Ягъни, бу кулъязманы Баландыш авылыныда (хәзерге Теләче районында) туган һәм Яңавылда[15] яшәгән Җәлалетдин Пулат улы исемле кеше 1885 елның 26 ноябрендә күчереп төгәлләгән.

Кулъязманың сакланышы уртачадан түбән: ул элек юешләнү кичергән, кәгазь почмаклары бөкләнгән һәм таушалган, беренче кәгазе төбеннән аерылган, 1а һәм 36б кәгазьләре шактый пычранган һәм язулары өлешчә зарарланган. 28 һәм 29 кәгазьләр арасында төбеннән өч кәгазе кисеп алынган, ләкин текстта өзеклек юк.

Җыентыкның 1а–35а кәгазьләрендә Мөслиминең «Тәварихы Болгарийә» тексты язылган. Башы юк.

35а–36б кәгазьләрдә «Чыңгызнамә»нең соңгы ике бүлеге теркәлгән. Ахыры юк. Текст кәгазь битләрендә 16 юл күләмендә һәм мәйданы 11х17 см зурлыгында. 35б кәгазьдәге «Фасыл фи бәйанит-тарих» һәм 36а кәгазьдәге «Казан шәһәрендә йорт биләгән ханларның исемләре» дигән, бүлекчә рәвешендәге атама зур хәрефләр белән аерып язылган.

Кулъязманың 30а кәгазе читендә 1930 нчы елларда яңалиф (латин) хәрефләрендә кара төстәге химик кара белән кыска җыр фрагменты язылган.

Бу кулъязма китапханәгә «Сигезенче текст» кулъязмасы белән бергә алынган.

[15] Хәзерге Теләче районындагы Олы Мишә авылы халык телендә Олы Яңавыл дип, ә Урта Мишә авылы Кече Яңавыл дип йөртелә.

«Уникенче текст» кулъязмасы Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1360т» шифры белән саклана.

25 кәгазьдән торган җыентык Россиядә эшләнгән кәгазьгә XVIII гасыр ахырында көрән төстәге кара белән, тәгъликъ төренә якын рәвештә язылган. Кәгазендәге су билгеләре 1780 нче елларга карый.

Кулъязманың тышлыгы юк, төбе юан җеп белән тегелгән.

Форматы 9,5(10)х17 см. Бер битендәге язу мәйданы 7(7,5)х12,5 см.

Сакланышы начар: кәгазьләре шактый таушалган, 1 нче һәм ахыргы (25 нче) кәгазьләре төбеннән аерылган.

«Чыңгызнамә»нең «Дастане тарих» бүлеге кулъязма җыентыкның 1а–2а кәгазьләрендә теркәлгән. Текстның башы юк. Ахырында «Тәммәт тәмам булды, җомга көн тәмам булды» дигән сүзләр язылган.

2б–25б кәгазьләрдә дини риваятьләр һәм төрле хикәятләр язылган. Хикәятләрнең башындагы сүзләр һәм кайбер җөмләләр кызыл кара белән язылган.

Җыентыктагы барлык текстларның да имлясы тотрыксыз, хаталары күп.

Татарстан Республикасының Буа районындагы Иске Тинчәле авылында сакланган бу кулъязманы Казан шәһәрендә яшәүче Рәүф Ибраһимов 2000 елның 5 гыйнварында китапханәгә тапшырды.

«Унөченче текст» кулъязмасы Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1321т» шифры белән саклана.

Барлыгы 132 кәгазьдән торган, Россиядә эшләнгән кәгазьдәге кулъязма җыентык 1870 елга карый. Анда төрле әсәрләр һәм материаллар бергә тупланган.

Кулъязманың тышлыгы юк, төбе җеп белән тегелгән. Форматы 17(17,3)х21,5 см.

Барлык текстлар да бер үк кеше тарафыннан, тотрыклы имляда, тәгъликъ төрендә, көрән төстәге кара белән һәм кызыл төстәге караны мул кулланып язылган. Текстларның күпчелек өлеше кызыл кара белән сызылган кысага алынган.

Кустодлары тотрыклы түгел. Җыентыкның иясе тарафыннан гарәп саннары белән битләрнең өске читендә пагинация куелган. Пагинация саннары 1а–95а кәгазьләрдә 2–176 саннары белән билгеләнгән.

Кулъязмадагы текстларны күчергән кеше – Хәйретдин мулла Колларыйның исеме берничә урында күрсәтелгән. Мәсәлән, 106а кәгазьдә «Мулла Хәйреддин ибне мулла Фәхреддин әл-мәрхүм әл-Колларый әл-Болгарый» дип, ә 39б кәгазьдә исеме янында «1870 сәнәдә» дип тә язылган.

Сакланышы уртача: җыентыкның беренче кәгазе төшеп югалган, 7, 125 һәм 132 нче кәгазьләре төбеннән аерылган. Кайбер кәгазьләре тапланган һәм читләре таушалган.

Җыентыкның 1а–26а, 28а–37а кәгазьләрендә Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихы Болгарийә» әсәре язылган. Аның башы юк (бер кәгазе җуелган).

26а–27б кәгазьләрдә «Чыңгызнамә»нең Ибраһим Хәлфин бастырган (Казан, 1822) китабыннан бишенче һәм алтынчы кыйсемнәре (бүлекләре) күчерелгән. Текстның ахырында «әл-мәнкуль мин рисаләти Хәлфин Казаный» (Хәлфин Каза-

ный китабыннан күчерелде) дип, чыганагы күрсәтелгән. Текстта кайбер җөмләләр һәм сүзләр кәгазь читендә өстәп, шулай ук берничә сүз төзәтеп язылган.

37а–39б кәгазьләрдә дин тарихына караган, гарәп телендәге һәм төрки-татарча төрле китаплардан кыскача күчермәләр урын алган.

40а–56б кәгазьләрдә гарәп телендәге «Тәэвиле әнвагыр-рөэйә» исемле әсәр күчереп язылган.

57а–61б кәгазьләрдә Әрдәшир Болгарыйның «Фи кыяфәти җинсел-инсан» исемле шигъри әсәре теркәлгән.

61б кәгазьдә Габдеррәхим Утыз Имәни шигыре язылган.

61б–74а кәгазьләрдә төрле догалар һәм «Хәйател-хәйван» китабы тәрҗемәсеннән, «Тәфсире мәдарик» һәм татарча, гарәпчә, фарсыча башка китаплардан күчерелгән, төрле мәсьәләләргә караган өзекләр бар.

74б–95а кәгазьләрдә төрле календарь вариантлары һәм таблицалары, аларның аңлатмалары, халык сынамышлары, фараз-юраулар, аерым даталарга бәйле кайбер тарихи язмалар, шулай ук дини бәйрәмнәр җәдвәле һәм аңлатмалары, Русиядәге ярминкәләр турында мәгълүматлар һ.б. язылган.

84а кәгазьдәге июль ае календаре эчендә Пугачёв күтәрелешенә бәйле түбәндәгечә тарихи мәгълүмат теркәлгән: «1774 сәнәи русийә июльнең 12 нче числасында, шинбә көн, печән өстендә, җөмадиел-әүвәл айының ундүртенче көн, сабах вакытында, Йәмилйан Пугачуф шәһре Казанны алурга җәңгә шөруг әйләде. Икенде вакытына диген шәһәрне ут илә йакдыруб фәтех әйләде».

95б кәгазьдә кыска шигырьләр, 96а–107а кәгазьләрдә гарәп телендәге «Гыйльмет-тыйбб» китабыннан күчермә һәм тыйббка бәйле башка язмалар урын алган.

107б–132б кәгазьләрдә «Әл-мөҗәррибәт мин әт-тыйбби фи шифаил-әбдан» исемендәге, татар телендәге тыйбб-дәва китабы күчерелгән.

Бу җыентыкны китапханәгә Казан шәһәрендәге «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкерте Мәхмүт Шәрәфетдинов Буа шәһәреннән алып килеп 1997 елның 26 май көнендә тапшырган иде. (Мәхмүт хәзрәт хәзерге вакытта танылган дин әһелләреннән берсе, Казан шәһәренең «Шамил» мәчете имам-хатыйбы).

Бу кульязманың фоторәсеме басылды:

1) Татар китабы = Татарская книга: альбом / төз. Мәрданов Р., Һадиев И. – Казан: Татар. китап нәшр., 2013. – Б. 96.

Шул ук фоторәсем «Үтәмеш хаҗи. Чыңгызнамә» дигән ялгыш мәгълүмат белән бирелгән:

1) Татар әдәбияты тарихы. Сигез томда. Т 2: XV–XVII гасырлар. – Казан: Татар. китап нәшр., 2014. – фототуплам.

«Ундүртенче текст» кульязмасы Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «711т» шифры белән саклана.

«Чыңгызнамә»нең тарихи вакыйгалар турындагы бүлегенең бер өлеше XIX гасыр ахырында типографиядә басылган, 19,5х28 см зурлыгындагы китапның

катыргы тышлыгына – арттагы (өченче тарафындагы) форзац битенә теркәлгән. Ул 16х17,5 см мәйданга шәмәхә кара белән XX гасыр башында язылган.

Текст китап вариантына тулаем тәңгәл килеп бетми.

Сакланышы яхшы.

Шул ук тышлыкта башка язмалар, мәсәлән, кунак каршылауга бәйле хәдис һәм шигъри юллар, аларның шәрех-аңлатмалары һ.б. бар.

Катыргы китап тышлыгының кемнәр кулында булганлыгы түбәндәге язудан аңлашыла. Анда башка кеше кулы белән гарәп хәрефләрендә болай язылган: «1969 нчы елда 24 нче июньдә Пүкәл Габдеррәкыйб мөәзин кызы Әкълимә китереб бирде, мин кабул итеп алдым – Габделбәр бине мулла Низаметдин әл-Мичәни, сүммә Шәмәрдәни»[16].

Кулъязма китапханәгә Удмуртия Республикасының Кизнер шәһәре мәчетеннән 1996 елның май аенда Р.Мәрданов тарафыннан алынган иде.

[16] *Пүкәл, Мичән* – хәзерге Татарстан Республикасының Саба районындагы авыллар. Шәмәрдән – Саба районындагы посёлок. Сүммә – соңрак.

СҮЗЛЕК

ағыр – олы, зур, күп, көч, хөрмәт, кадер
ад – ат, исем
ади – шөһрәтле, шанлы
азина – атна
айғайсән – әйт
айлу-йөклү – авырлы
айтған – әйткән
айыл – каеш
айыңлашыб – хурлап, гаепләп
айыңчы – хурлаучы
ал – бик яхшы, югары сыйфатлы
ала – күп, төрле
алапа – гаскәргә бирелә торган хезмәт хакы, бүләк
алғалый – алырга
алғын – ал
алман – алмыйм
алыс – ерак
аман, әман – имин
андағ – шундый
андыб – сагалап
анча – ничә
арзу – теләк, омтылыш
артуқ – өстен, иң яхшы
асанлашуб – хушланып, канәгать булып
аслый – асыл
асман – күк йөзе
астанә – төрбә
атайын – атыйм
атлығ, атлуғ – атлы, исемле
аты-чабы – даны, шөһрәте
ахрел-әмер, ахры бар – ниһаять, ахыр чиктә
ачиғ, ачы – хәсрәт, ачу, үпкә
ачиды – рәнжеде, кайгырды

әвернә – аркылы-торкылы, хачсыман рәвештәге әйләнә торган җайланма
әйәр, әйде – әйтер, әйтте

әйлә – шулай
әйтәйен – әйтим
әксәр – күпчелек, күбрәк
әл – кул
әшкярә – ачык, ачыктан-ачык

бағанағы – баягы
бағыну – буйсыну
базаркян, базаркяр – сәүдәгәр, сатучы
бақғунча – караганчы
бақман – бакмыйм, карамыйм
бармандур – бармам
барыңлар – барыгыз
бәғдә визрәтин әү бәғдә әнварил-мәғарифи хосусан ғәләл-имами хәзрәти әмирел-мөэмининә вә имамил-мөслиминә Әбүбәкр сыйддийқис-садыйқи әлләзи һуа хәлифәти рәсүлуллаһи салла Аллаһу ғәләйһи вәсәлләм фи күлли наиби әмр – хатадан соң яки мәгърифәт нурыннан соң, бигрәк тә, пәйгамбәрнең (аңа Аллаһның салаватлары һәм сәламнәре булсын) бөтен эштә вәкаләтле варисы, мөэминнәрнең әмире һәм мөселманнарның имамы, тугры Әбүбәкер Сиддыйкка
бәғзе – кайбер
бәйғәт – буйсыну турындагы ант
бәли – әйе
бәрик – бәрәкәтле, мөбарәк
бәһадур – баһадир
бең – мең
бер анча – бераз
берәгү – бирәү
бирәйен – бирим
бит ақым – абруй(?)
бихәбәр – хәбәрсез
бичин (пичин) – маймыл
болжқал (болжқар), болжқалый – гаскәрнең туплану урыны, килешенгән урын яки вакыт
босуб – посып
бөлә – бүлек, төркем
бөлүклүк – бөлгенлек, афәт
бөржқ – ай
бөтәр – мул булып үсәр (үлән)
бөтеб – язып
брансус – француз
буғаз – буаз, йөкле
булғалы – булгач

булған – тапкан

валлаһу әгләмү бис-саваби – чын дөреслекне Аллаһ белә
вар – бар
вәйран – харап булу, юкка чыгу
вәли – ләкин
вәли – изге
вәл-мәҗалис вәл-мәкян – яшәгән урыннар һәм торган җирләр (биләмәләр)
вөҗүд – туу

ғаза – изге сугыш
ғақил, ғақыллық – акыллы
ғаммаз – хыянәтче
ғафил – ваемсыз, игътибарсыз
ғәделдад – гаделлек, гадел хөкем
ғәҗәм – фарсы
ғәиб булу – юкка чыгу
ғәләйһиссәлам – аңа Аллаһның сәламе булсын (пәйгамбәрләргә карата әйтелә)
ғәқрәб – чаян
ғәнһүма – аларның икесе турында
гәүр (гәвүр) – кяфер
ғинайәт – ярдәм
ғыйш-ғөшрәт – кәеф-сафа, күңел ачу, рәхәт чигү
гяһ-гяһ – вакыт-вакыт, кайчагында

дайә – тәрбияче хатын-кыз
дай хашқа – тәҗрибәле асылзат сугышчы
дару – дары
дәгелсән, дәгүлмән, дәгүлмүсән – түгелсең, түгелмен, түгелсеңме
дәма – кызыгу, ышаныч
дәрд – авыру
дәхи – тагын
дигәйсез – дип әйтегез
дигел, димәгәймән – әйт, димәм
диген – хәтле
дик, тик – кебек
дуйынлық – бәхет

җаду – сихерче
җалға инде – ялланды
җанлық – җан иясе
җау-қырғын – һөҗүм, сугыш

җәйан – хатын-кыз ягыннан туган, чит, кан кардәш булмаган
җәмеғ қыйлыб – җыеп
җәнабәте ғөсел қылыб – шакшыларны юып
җәнәрал – генерал
җәң – сугыш

заһир улған – пәйда булган
зынҗыр – чылбыр, богау

иги – яхшы
изарлық – биләүле
изыб – эзләп, табып, җибәреп
ийәңче – такмакчы
икеләсе – икесе
илай – елый
илән – белән
илгәрү – элгәре, алдан
ил-көн – ыру-кабилә, халык, җәмәгать
иллә – әмма, ләкин, фәкать
имди – инде
инде – иңде, керде
ирән – җирән
ирде – иде, иреште
ирдүкен – икәнен
иркәк-теши – ир-хатын
иркән – икән
иркәч – кәҗә; *кийек иркәч* – кыр кәҗәсе
ирлек – батырлык, кыюлык
ирмәс – булмас
ирмеш – икән
ис-ос – аң, зиһен
истәб – теләп, эзләп
истәмәзбез – теләмибез, эзләмибез
итәлгу – лачынның бер төре
итмәген – икмәген
ичамай (ачамай) – аркылы-торкылы, хачсыман

йа – җәя
йағ – яу, сугыш
йағрын – арка, җилкә
йалға (җалға) ину – хезмәткә яллану
йаравын – котылу, коткару

йараглану – хәзерләнү
йаран – иптәш, сугышчы
йаратмайын – яратмыйча
йар булды ирсә – ярдәмче булса
йар салу – халыкка игълан итү, белдерү, әмер итү
йаруқлуқ – яктылык, нур
йаруқын көн – якты нур
йәйәү – җәяү
йәсир – әсир
йебәк – ефәк
йенжү – энже
йибәрәле, йибәрәлең, йибәрген – җибәр
йиде, йидүрсә, йийәрмән – ашады, ашатса, ашармын
йомуртқа – йомырка
йоруг, йоруқ – кирәк-ярак, йомыш
йоругын-йүнен – җаен, ысулын
йөрийүр – йөрер
йуйылдуқ – җуелдык
йулуқгай – юлыксын
йу (йуй) – чит, кырый
йусын – намуслы, тәртипле, әдәпле
йүн – як, тараф, ил
йүчә – биек
йыгач – агач
йыгдурды – җыйдырды
йыйгыб, йыйыб – җыеп

қабат – биек
қабу, қапуг – капка
қазақ чыгу – ырудашлардан аерылып китү
қазгу – кайгы
қайа – янәшә, чит
қалай – кая
қалмақ – калмык
қалтақ – хәсрәт, кайгылы, бәхетсез
«қалү инна Лилләһи вә инна иләйһи ражиғун» – әйт: Аллаһ тарафыннан яратылганбыз һәм аның хозурына кайтабыз *(Коръәннең «Бәкарә» сүрәсендәге 156 нчы аятьтән)*
қамсаб – камап
қана, қанда, қандин – кайда, кая, кайдан
қанжыга – ияргә әйбер беркетү өчен җайланган каеш
қарақчы – карак, юлбасар

қарсунда қоруғы – беләгендә арканы
қарый – борынгы, карт, өлкән
қасд – ният, максат
қассабчы – итче
қатырға – катер, галера, сугыш көймәсе
қач – күпме
қашы – каршы
кә-әмсалел-ләә-ләә әл-мәкнүн тик – кыйммәтле энҗе кебек
кә-әннә – кебек, шикелле
кәбтәр (кәбүтәр) – күгәрчен, хәбәрче күгәрчен
қәлгә – кала, ныгытма, крепость
кәрамәт – могҗиза
қәүл – сүз, хәбәр
қәһер – җәза
кәшанә – төрбә
кизләү – укны җәягә кую, кору
кийек – кыргый җанвар, болан
килә йатур – килеп бара
килгәли – килгәч
кинә – янә, тагын
китәйен – китим
қолан – кыргый ат
қол-қотан – кол, хезмәтче, әшәке җан
көйүк – кайгы, хәсрәт
көлли – бөтенләй, тулаем
көн булуб инәрмән – нур булып иңәрмен
көн инеше – көнбатыш
көрчи – нигезле, төпле
көү – күбек
көчүк – эт
қу ут – коры, кипкән үлән
қу – аккош
қубару – кору, төзү
қузы – бәрән
қуй – сарык
қуйалы – куйыйк
қур – алтынлы яки көмешле киң билбау
қурлы – мирас булып калган, ата-бабадан килгән
қушландуруб – куш итеп, парлап
күзе йаруды – бала тапты
күнәк – турсык, күн савыт
күргәли – күргәч, күргәннән бирле

күренеш – ханга баш ию, хөрмәт тантанасы
күргүз – күрсәт
күрүклү, күрүклүк – чибәр, гүзәл
кучәле – күчмә
қыдыру, қызыру – бөтен җирдән җентекләп эзләү, йөрү, гизү
қыйа – кыек
қыйсме садис – алтынчы бүлек
қыйсме хамис фи бәйани мәсакин вә мәкян – яшәгән урын-җирләр турындагы бишенче бүлек
қыр – корт
қырғы – лачынның бер төре
қырғын, қырқын – кисеш, кырылыш

Лә иләһә иллә Аллаһу Мөхәммәд рәсүлуллаһ – Аллаһтан башка илаһи зат юк, Мөхәммәт Аллаһның илчесе
ләмма – ләкин, кайчан
ләү (лү) – елан, аждаһа
ләшкәр – гаскәр

манасыр – монастырь, чиркәү
мәйел қыйлмайын – теләмичә
мәқам тоту – яшәү
мәнең – минем
әл-мәнқүл мин рисаләти – китаптан күчерелгән
мәңизлек – охшаш, кебек
мәхәлендә (мәхәлл) – янында, тирәсендә
әл-мәһди билләһи, әл-мөқтәда билләһи – Аллаһ юлында тугры
милад илә – милади ел белән
мин бәгдә – шуннан соң
мин ғәйниһи – нәкъ үзендәгечә
мондағ – мондый
моңғул – монгол
мур – эпидемия; рус телендәге «мор» сүзе
мохалиф – каршылыклы
әл-мөғтәзз – кодрәтле
мөддәт – урын, вакыт аралыгы
мөйез – мөгез
мөлек – патшалык
мөртәд – диннән язган, башка дингә күчкән
мөтәхәйир – хәйран калу, гаҗәпләнү
мөхәққақ – ышанычлы
муғыллық – мәҗүсилек

муйун сонмақ – буйсынырга
мышық – мәче

нарасидә уғлан – сабый бала
нәғачи – ана ягыннан булган бабалар
нәйлә ғөррәт улдуқы – ничек һөҗүм иткән
нәйтсә – нишләсә
нәқәлә минәш-шәҗәрәти – шәҗәрәдән күчерелде
нәр – дөя, Урта Азия һәм Әфганстандагы озын яллы дөя
нимә – нәрсә
нитәк – ничек, нинди
нифақ – икейөзлелек, алдау
нишан – билге
нөгәр – хезмәтче, хәрби, иптәш

оқтару – аңлату, фаразлау
олу – олуг, аксөяк
оран – аерым бер ыруның яки гаскәри берәмлекнең махсус яуга чакыру авазы, пароль; гадәттә, ыру башлыгының исеме яки шартлы бер сүз белән белдерелгән
орыслық – тимерчелек, остаханә, осталык
ошбундағ – шундый, шулай

өртен – яшерен
өтрүк, өтүрүк – ялган, хәйлә
өчәгү – өчәү

пәлид (бәлид) – яман, шакшы
пир – нигез салучы
посташ (босташ) – вәйран булу, юкка чыгу

разыйә Аллаһу ғәләйһи вә ғәлә алиһи вә әсхабиһи әҗмәғийн – Аллаһ аннан, җәмәгатеннән һәм сахабаларының барысыннан риза булсын
разыйә Аллаһу ғәнһе – Аллаһ аннан риза булсын
растлық – тугры, дөрес
рәван – тиз, шунда ук
рәхмәтуллаһи ғәләйһим әҗмәғийн – аларның барчасына Аллаһның рәхмәте булсын
рәхмәтуллаһи ғәләйһи рәхмәтән васиғәтән – аңа Аллаһның киң рәхмәте булсын
ру, оруғ – ыру

савыт – көбә, сугыш киеме

садақ – ук-җәя савыты
сақалун – тау чыпчыгы, купшыл
салыб – ташлап, калдырып
сар – патша; рус телендәге «царь» сүзе
сах – саф, дөрес, тугры
сахиб – ия
сач – чәч
сәвәр – сөяр, яратыр
сәвеб-үгүб – сөеп һәм мәрхәмәт итеп
сәвенүр – сөенер
сәйиде наиб – сәеднең алмашы
сойурғаб – бүләкләп, ярлыкап
соңратын – соң, соңыннан
сорғалый булсаң – сорасаң
сөаль – сорау
сөйләйәлең – сөйлик
сөйүк – сөю, мәхәббәт
сөңләк – сөяк
су йақасы – су чите, яр буе
сулама – сумала
сычқан – тычкан

табиғ – буйсынучы
тавышқан – куян
тағ – тау
тағат – гыйбадәт
та қийамәт – кыяматкәчә
талиғ – язмыш, киләчәк
там – түбә, өс
таңла – иртәгә
таң мәмке – таң алды
тарбаза – капка, шәһәр капкасы; фарсы телендәге «дәрвазә» сүзе
таһирә – саф, пакь
таш – тыш
ташқару – тышта
тәбрәде – кузгалды, юлга чыкты
тәбтүрде – тоттырды
тәғзыйм – олылау, хөрмәтләү
тәдбир – чара, гамәл
тәйү, тәйүрсән – дип, дисең
тәқи – тагын, янә
тәммәт тәмам – бетте, тәмам

тәнәггем – нигъмәтләнү, хозурлану
тезләү – тез белән изү
тигән – дигән
тигәр булғай – тияр
тигрү, тигрүр – хәтле, кадәр
тигүнчә – дигәнче
тиде ирсә – дигәч
тимә (тигмә) – төрле
тимәк, тимәклек – дияргә, әйтү
тимәңләр – тимәгез
тимер игәб, таш атқан – кылычны һәм мылтыктан атуны белгән, оста сугышчы, баһадир
тиңез – диңгез
тора салыб – кинәт, тиз генә
тохым – токым
төмән – мең
төнәве көн – төнәген, кичә
төсүн әверүб – кыяфәтен үзгәртеп
төш булғай – юлыксын
төш-түл – төшләнү, саташу, йокы
ту бийә – колынламаган бия
тубчақ ат – җиңел-җитез ау аты
туғмақ – туу
туғуб – туып
туқуш – сугыш
тулуғ – тәрәзә
тун – өс киеме
турқа – постау, ефәк
тучы – байракчы
түә – дөя

уба – калкулык, тау
улар – алар
улсун, улуб, улур – булсын, булып, булыр
ултур – утыр
ултыралық, ултуралың – утырыйк
уны – аны
уразлы – бәхетле
усал – начар, яман
услық – акыллы, зирәк
ушал – шул
ушандағ – шулай, шулай ук, шул рәвешле

үгрәтү – өйрәтү
үдәргә – мәетне искә алырга
үләйен – үлим
үләлек, үләлем – үләрбез
үлдүрдүге – үтергән
үлмәйәлең – үлмик
үнгә – башка, чит
үтмәкче – икмәкче
үчә (йүчә) – биек

файдалыг – файдалы
фалкяр – күрәзәче
фасл – бүлек
фәтех әйләде – яулап алды
фөрйад – кычкырып елау
футаллы фута – ялтыравыклы (алтынлы) билбау

хазир қыйлыб – хәзерләп
халә – хәзер, бу вакытта
хали-бисат – келәм-палас
халиқ улындуғы бәғдендә – яратылганның соңында
халық уғылы – халык, җәмәгать
хамилә – йөкле
ханиш – хан хатыны, ханша
хасыйл – яхшы, файдалы
хәдд – чик
хәлайық – халык, кешеләр
хәмүлә – йөк, көмән
хәрамзадә – уйнаштан туган
хөләфаи ғаббасийә – габбаси хәлифәләре

һәбәрәң – йомшак күн
һәдийә – бүләк
һәйбәт – куркыныч, мәһабәт, хөрмәт
һәйбәт орунды – коты чыкты, курыкты
һәрайинә – һәрвакыт, һәрхәлдә, шиксез, әлбәттә
һәргиз – һичкайчан, һич тә
һәрнә – һәрни
һиммәт – тырышлык

чавыр (чавырын), җавырын – җилкә

чағыр – шәраб, аракы
чапавыл – чапкын
чарлағай, чарлады – кычкыр, кычкырды
чәнгәл йығачы (чәнгәллек) – куаклык, куаклар арасы, вак агачлы урман
чикде – тартты, киерде
чирү – гаскәр
чуға – постау
чулашуб – аһ-зар белән елау
чықарайын – чыгарыйм
чымырғануб – кычкырып елау, дәһшәттән ыңгырашу
чыраг, чырақ – ут, учак

шом – явыз, мәкерле
шөйлә – шундый

ықтарма – агызу
ырыс – бәхет

эв, эү – өй
эстәтеб – эзләтеп
эчкеле-йигеле – эчемлекле-ризыклы, аш-сулы

РЕЗЮМЕ

Двадцать третий выпуск серии «Татарская археография» посвящён сборнику исторических дастанов под названием «Чингиз-наме» («Дафтари Чингиз-наме»), в который вошли эпические произведения о роде Чингиз-хана; о Хромом Тимуре; об Амате, сыне Айсы; об Идигей-беке; о владениях; об истории. Каждый дастан был представлен в виде отдельной главы. Предлагаемое издание включает 15 списков данного сборника.

Интересна история его изучения. С начала XIX века исследованием и публикацией дастанов занимались И.Хальфин, Х.Френ, К.Фукс, И.Березин, С.Кукляшев, Н.Катанов, Г.Губайдуллин, А.Рахим и другие видные деятели науки и просвещения. Огромен вклад в изучение «Чингиз-наме» историка М.Усманова, который тщательно исследовал произведение, наряду с другими татарскими историческими источниками (1972). Учёные Ш.Абилов, В.Хаков, М.Гайнутдинов, М.Ахметзянов, С.Гилязутдинов, Д.Исхаков, М.Иванич, И.Мустакимов и другие в своих работах анализировали содержащиеся в книге фольклорные, литературные, исторические, этнические и генеалогические сведения. Сборник дастанов до настоящего времени остаётся в центре внимания многих исследователей.

Книга «Чингиз-наме» была распространена в виде многочисленных рукописных списков. Тексты отдельных дастанов печатались, начиная с первой четверти XIX века. В более полном виде книга впервые была издана в Казани в 1822 г., затем в 1882 г. и позднее в 2000 и 2011 годах. А в 2002 году в Венгрии (г. Сегед) было опубликовано специальное научное издание текста «Дафтари Чингиз-наме».

В настоящее время известны 67 списков разного объёма (полных, состоящих из нескольких глав и неполных) в архивах, библиотеках, музеях и у частных лиц. Большинство из них (44 единицы) хранится в г. Казани.

В Национальной библиотеке Республики Татарстан имеется 11 списков книги «Чингиз-наме», тексты десяти из них опубликованы в данном сборнике. В сборник включены ещё пять списков: один – из фонда Научной библиотеки им. Н.И.Лобачевского Казанского (Приволжского) федерального университета, два – из фонда Российского государственного архива древних актов (Москва), один – из Национального музея Республики Татарстан и один текст из личного архива.

Содержание и структура текста рукописи из библиотеки университета отличается от остальных и определён как I вариант, а другие составляют II вариант. В результате сравнительного исследования установлено, что текст I варианта является более ранним. Такое же предположение было выдвинуто в статье историка И.Мустакимова (2009).

Во вступительной статье к книге представлены историография исследования

«Чингиз-наме» («Дафтари Чингиз-наме») и сведения о его рукописных списках и изданиях. Отдельная глава посвящена авторству и структуре сборника дастанов. Освещены вопросы, касающиеся мотивов и общеизвестных сюжетов, встречающихся в других произведениях, рассмотрены особенности текстов, в том числе языковые и палеографические.

Все тексты (более полные и фрагментарные), представленные в данном издании, ранее не публиковались. В книге, наряду с текстами самих рукописей, приведены образцы факсимиле списков, описание рукописей и словарь.

ЭЧТӘЛЕК

Мәрданов Р. ТАРИХИ ДАСТАННАР ТУПЛАМЫ 3
«Чыңгызнамә» китабының кулъязмалары 15
Китапның басмалары 19
Тәнкыйди текст турында 37
Авторлык мәсьәләсе, китапның калыбы һәм кайсы вакытка каравы 38
Күчмә сюжетлар һәм аларның чалымнары 49
Текстның I варианты 54
II вариант текстлары 68
Исемнәр, атамалар 75
Ыру тамгалары һәм башка атрибутлар 79
Көбә исемнәре 81
Истанбул шәһәре рәсеме 83
«Ханнар»ның биләмәләре 85
Елъязма мәгълүматлары 87
Дастаннарның теле һәм кулъязмаларның палеографик үзенчәлекләре 89

I ВАРИАНТ*:* Дәфтәри Чыңгызнамә 95

II ВАРИАНТ
Беренче текст: Фасли дастани нәсли Чыңыз 116
Икенче текст: Дастане Чыңыз 119
Фасыл фи дастани Аксак Тимер 136
Дастане Гайса угылы Амәт 149
Фасыл фи дастани Идегәй би 150
Фасыл фи дастани вәл-мәҗалис вәл-мәкян 151
Фасыл фи дастани фит-тарих 152
Өченче текст: Дастане Чыңгыз 155
Фасыл фи бәйани дастани Аксак Тимер 169
Дүртенче текст: Дастане Чыңыз 174
Бишенче текст: Фасыл фи дастани Аксак Тимер 186
Алтынчы текст: Дастане Аксак Тимер 202
Җиденче текст: Дастане Аксак Тимер 216
Сигезенче текст: Дастане Гайса угылы Амәт 229
Тугызынчы текст: Дастане Идегә би 231
Фасыл фи дастани вәл-мәҗалис вәл-мәкян 231
Фасыл фи дастани фит-тарих 232
Унынчы текст: Дастанел-мәкян 236
Дастане тарих 237
Унберенче текст: Дастане мәкян 241
Фасыл фи бәйанит-тарих 241

Уникенче текст: Дастане тарих... 245
Унөченче текст: Кыйсме хамис фи бәйани мәсакин вә мәкян................ 246
Кыйсме садис ки Мир Тимер хәзрәтләре шәһри
Болгарны алдугы бәйанында... 246
Ундүртенче текст: Дастане тарих 251

КУЛЪЯЗМАЛАРНЫҢ ТАСВИРЛАМАСЫ 253
СҮЗЛЕК.. 272
РЕЗЮМЕ... 284

ЧИНГИЗ-НАМЕ
(ДАФТАРИ ЧИНГИЗ-НАМЕ)

(на татарском языке)

Составитель: Раиф Марданов
Ответственный редактор: Ирек Хадиев
Оформление: Ильдар Габидуллин

Басарга кул куелды 22. 04. 2019. Форматы 60х84 1/16.
Тиражы 100 данә. Заказ № 413.
Татарстан Республикасы Милли китапханәсе.
«Милли китап» нәшрияты.
420111, Казан шәһәре, Кремль ур., 33.

Подписано к печати 22. 04. 2019. Формат 60х84 1/16.
Тираж 100 экз. Заказ № 413.
Национальная библиотека Республики Татарстан.
Издательство «Милли китап».
420111, г. Казань, ул. Кремлевская, 33.

Отпечатано в редакционно-издательском отделе
Национальной библиотеки Республики Татарстан.
420111, г. Казань, ул. Кремлёвская, 33.